ISSN 0206-



# Казан утлары

9.1988



# КАЗАН УТЛАРЫ

АИЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ
ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

1988

9

(791)

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН


## *Бу санда*


ПРОЗА ҺӘМ ПОЭЗИЯ

Х. КАМАЛОВ. Үлгәннән соң яздым. *Роман* 3

Н. АРСЛАНОВ. Яшьлегемә кайтып. *Шигырьләр* 65
Р. ХАРИС. *Яңа шигырьләр* 72
Г. РӘХИМ. Туган якта. *Шигырьләр* 76
З. МАНСУРОВ. Җир җимертеп яшәү. *Шигырьләр* 79

Р. МОСТАФИН. Кабан күле серләре. *Тарихи-документаль повесть* 82

ӘДӘБИ МИРАС

Мәҗмугы-л-хикәят 111

АБДУЛЛА АЛИШНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

И. СУНКИШЕВА. Тугрылык. *(А. Алишның тоткынлыктагы иҗаты турында)* 142
А. АЛИШ. Сагынам илемне. *Шигырьләр* 145

БӘХӘС ДӘВАМ ИТӘ: «ЗАМАН ҺӘМ ШИГЫРЬ»

Ф. БӘШИРОВ. Шигърият язмышы — халык язмышы 148
А. ИБРАҺИМОВ. Бер булсын — бергәйле булсын 153
Ә. ГАБИДИ. Ихластан сөйләшик! 157
И. ХӘБИБУЛЛИН. Авыллар сезне көтә 158

БИБЛИОГРАФИЯ

Т. САЛАХОВ. Сәнгать тарихына зур өлеш 160

ОСТАХАНӘ

Г. КАШАПОВ. Әпсәләмәв хатлары 162

УФАДА КУЛЬТУРАБЫЗ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Аксаков йорты 169

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

Х. ГОБӘЙДУЛЛИН. Бер рәсемнең тарихы 170

АКТУАЛЬ ТЕМАГА

**Э. ЕНИКИ. Чынбарлык һәм туган тел** 171

**Г. САТТАРОВ. Исемнәрдә — ил тарихы** 176

ГАРӘП ӘЛИФБАСЫ НИГЕЗЕНДӘ ТАТАРЧА УКУ-ЯЗУ

**Беренче дәрес** 183

БОРЫНГЫ БОЛГАР ШӘҺӘРЛӘРЕ

**Ф. ГАРИПОВА. Ашлы.** 186

ЮМОР ҺӘМ САТИРА

**Р. ГАФФАР. Тотка.** ***Хикәя.*** 188

**Культура тормышы көндәлеге** 191

**Тышлыктагы рәсемнәр** 192

*Баш редактор*

РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
*(баш редактор урынбасары)*
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары —
53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-65,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

Продолжение романа Х. КАМАЛОВА «Написал после смерти», начало историко-документальной повести Р. МУСТАФИНА «Тайны озера Кабан». Стихи Н. АРСЛАНОВА, Р. ХАРИСА, Г. РАХИМА, З. МАНСУРОВА.
В рубрике «Литературное наследие» публикуются образцы татарской народной прозы XVIII века.
К 80-летию А. Алиша. Статья И. СУНКИШЕВОЙ. Стихи А. АЛИША, написанные в фашистских застенках.
«Литературная критика». Продолжение дискуссии «Время и поэзия»: статьи Ф. БАШИРОВА, А. ИБРАГИМОВА, А. ГАБИДИ, И. ХАБИБУЛЛИНА.
«Библиография» — рецензия на книгу С. М. Червонной «Искусство Татарии».
«Литературная мастерская» — Письма А. Абсалямова.
«Памятники татарской культуры в Уфе» — дом Аксакова.
Публицистическая статья А. ЕНИКИ «Действительность и родной язык».
«К истории культуры» — статья Г. САТТАРОВА.
По просьбам читателей с этого номера начинаются уроки по изучению навыков чтения и письма на основе арабской графики.
«Города древней Булгарии»: город Ошель (Ашлы) — статья Ф. ГАРИПОВОЙ.
«Юмор и сатира» — рассказ Р. ГАФФАРА.
Дневник культурной жизни.
На наших обложках: кожаная мозаика — ичеги. Памятники архитектуры Казани — Азимовская мечеть (XIX в).

Җаваплы секретарь *Флүс ЛАТЫЙПОВ*
Техник редактор *Р. Сөләйманова*. Корректорлар *Т. Сибгатуллина*, *Г. Салихҗанова*.

Производствога бирелде 29.06.1988 ел. Басарга кул куелды 22.08.1988 ел. ПФ 11250. Офсет ысулы белән басылд.
Кәгазь форматы 70×108. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 65049. Заказ А-260. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1988 ел.

## ПРОЗА

**Хисам Камалов**

# ҮЛГӘННӘН СОҢ ЯЗДЫМ

РОМАН



Кендек әбисе булып даны чыгуына Туфайлов эченнән бик пошына иде. Шуның аркасында үзен рәсми генә тотарга тырышуы җимерелде, ахрысы. Хатын-кызлар аңа үзләренең зары белән еш килә башлады. Бу нәрсә әйбәт түгел иде. Чөнки йә Фроловтан зарланалар, йә баш хирург Уразаевның кырыслыгыннан кимсенеп, ул гаделсез дип елыйлар иде. Туфайлов исә арада буфер ролен башкарырга тиеш. Начальникларның тәнкыйть-шелтәләре хаклы һәм гадел булуын дәлилләп бирергә бурычлы. Кешеләрне башлыкларга каршы кую куркынычы һәрчак булып тора. Шул ук вакытта гаделлекне дә сакларга кирәк. Уразаевны шәхсән өнәмәсә дә, ул аны якларга мәҗбүр иде. Әмма соңгы вакыттаТуфайловның аңа карата булган мөнәсәбәте уңай якка үзгәрә башлады. Ул «бишминутлык»ларда врачларның, шәфкать туташларының җитешмәгән якларын каты итеп әйтә дә сала, тәкәллеф саклап маташмый. Шул ук вакыт Альбин белән Рувим аның үз кимчелекләрен йөзенә бәреп әйтә. Уразаев чыдам, каршы килеп, үзенең башлык булуыннан файдаланып, чәпчеми. Барысын да эченә сеңдереп утырамы, әллә эченә бер сүз дә үткәрмиме, билгесез. Үз кул астында эшләүчеләр белән бер дә кычкырышмый ул. Нинди генә каты сүз әйтсәләр дә, кеше алдында җавап кайтармый. Аның шул ягы Туфайловка ошый иде. Ул үзе тиз «кабынып», җитәкче өчен кирәкле тотрыклылыкны югалтып җибәрә. Рядовой белән җитәкче арасында ниндидер рәсмилек булырга тиеш. Бүтәнчә, җитәкчелек юкка чыга... Әйе, Уразаевта җитәкче кешегә кирәкле сыйфатлар күп икән. Ул һәр елауны елау дип, һәр зарны зар дип кабул итми, бу хәлнең икенче ягын исәпкә ала, аңа төрле яклап якын килә. Боларның барысы нәтиҗәсендә госпитальдә тәртип бераз әйбәтләнү ягына борылды. Уразаевтан шүрлиләр дә иде.

Уразаевның баш хирург булуына Альбин белән Рувим кимсенәләр иде шикелле. Моны алар әйтми, ләкин эш вакытында барыбер беленеп куя. Хәрәкәтләреннән кайчак төртеп чыга. Шул «бишминутлык» вакытында Уразаевка һәрчак каршы төшәләр. Аның кимчелеген конкрет фактлар белән күрсәтеп бирәләр. Әмма күп чак арттырып җибәрәләр. Мин-минлекләре нык кына сиздерә. Каршылыклар шәхескә күчә. Гаделлек югала. Бу хәл эшкә зыян китерә.

---

Дәвамы. Башы 8 нче санда.

Альбин белән Рувимның баш хирургка һәр сүздә шырпы кадарга гына торулары әйбәт түгел иде. Фролов бер көнне Туфайловка:

— Син алар белән сөйләш әле,— диде.— Әгәр үзләрен тыймасалар, мин җаен табармын. Артыкка җибәрә башладылар...

Ничек сөйләшергә, ничек дипломат булырга? Алар икесе дә үз эшләренең осталары, нык укыган кешеләр. Формаль яктан алганда баш урынына дәгъва кылырлыклары да бар. Ләкин холык-фигыльләре белән башлык эшенә ярап бетмиләр иде кебек. Фролов моны яхшы сизгән булырга тиеш. Хәзер Туфайлов та Фроловның алдан күреп һәм мәсьәләнең асылын аңлап эш итүен төшенә башлады.

Башта Туфайлов Альбин белән сөйләшеп утырды. Бик җитди борчылып, үзенең җитешмәгән якларын аның алдында ачып салды, үзен-үзе чыбыркылады. Менә миңа шундый сыйфат комачаулый, диде. Аннары шаяртуга күчеп:

— Альбин Васильевич, сезнеңчә, баш булу өчен нинди сыйфатлар кирәк? — дип, аңа текәлде. Борғаланырга урын калдырмаслык итеп туры карады. Җавап бирмәсә дә, бу сорау аны уйландырырга тиеш иде. Альбинның маңгаенда уй җыерчыклары пәйда булды. Аннары чибәр йөзенә елмаю нурлары чыкты.

— Башлык булу өчен, минемчә, кырыс характер, каты куллы булу да җитә торгандыр,— диде.

Туфайлов шулай ук елмая төшеп:

— Ә сездә андый сыйфатлар бармы? — дип сорап куйды. Альбинның йөзе сүнеп китте, җитдиләнде, аннан соң битендә тагы җылы төсмерләр күбәйде.

— Миндә андый сыйфатлар юк шул,— диде ул кызганычлы көрсенү белән.

— Ә Уразаевта андый чалымнар бармы? — дип Туфайлов сүзне икенче эзгә борды.

— Ул үзен күрсәтә башлады,— диде Альбин.— Ләкин аны бик нык чарлыйсы бар әле...

— Сез аңа тәнбиһне шул максаттан ясыйсызмы?

— Тагы нинди ниятем булсын?

— Сезнең урынны биләгәнгә рәнҗү...

— Минем тәнкыйтьне шулай дип бәялисезме? Моннан соң бер сүз дә әйтмәм,— дигәч Альбинның мөлаем йөзе сүнеп калды.

— Юк инде, Альбин Васильевич, сез нәрсә, кирегә борырга гына торасыз,— дип Туфайлов «бу кәкрене» төзәйтергә ашыкты. Әмма тегенең сүнгән йөзе кабат җанланмады, җитди булып калды.

— Сез кешеләрне җәллисез,— диде Туфайлов хирург эндәшми торгач.— Мин сезне бик хөрмәт итәм!

Альбин башын түбән иде, күзлеген сөрткән итте, үзе ни әйтергә белми, йөзе таркау иде. Аның сүзне озынга җибәрәсе килмәвеннән шактый гына кәефе киткәнлеге сизелде.

Рувим белән дә шулай читләтеп кенә, тирәнгә кермичә сөйләшкәннән соң, «бишминутлыклар» шау-шусызрак үтә башлады.

Сигезенче март уңае белән хатын-кызлар өчен торак йорттагы бер бүлмәдә кичә оештырганнар иде. Кечкенә генә, тыйнак кына бәйрәм. Кухнядагы кызлар пилмән пешереп китергәннәр. Әз генә эчемлек тә куелган иде. Әмма врачлар, шәфкать туташларының аңа карыйсылары килмәде. Госпиталь палаталарында яралылар газапланып яткан вакытта кәефләнеп утыруны күңелләре күтәрми иде. Кичә бик күңелсез, сүрән башланды һәм шулай дәвам итәчәк иде. Болай әйбәт түгел иде. Туфайловка хатын-кызлар ябырылды.

— Македоновны чакырыйк,— диделәр.

Хатын-кызны аңламассың, үзләре еш кына: «Македонов бәйләнә», дип елап керәләр, аңа рәнҗеп зарланалар, ә хәзер шуны үзләренең табынына чакыралар. Туфайлов уртәлә-уртәлә Македоновны алып керде.

Ул бик шат, үзенең кирәге чыкканга авызы ерылган: замполит өнәмәсә дә, хатын-кыз ярата аны! Гитарада уйнап, җырлап җибәрде. Чынлап та, кичәгә җан керде. Кызлар Македонов тирәсендә, майлы чүлмәк янында йөргән мәчеләр кебек, бөтереләләр. Миша да Миша, дип өзеләләр, теге яки бу җырны җырлавын үтенәләр иде. Македонов та усал, хатын-кызлар ярата торган кызганыч, моңлы, йөрәккә үтә торган җырларны тезә генә... «Язмыш кешеләр белән шаяра. Йә чөя ул аны югары, йә упкынга ташлый заяга, мәрхәмәтсез язмыш куллары...»

Кичәдә Туфайлов өчен уңайсыз хәл дә булды. Җырдан соң патефон куйдылар. Пластинкада вальс иде. Танцы башланды. Мәнә шул чакта Анна Сергеевна үзенә кавалер итеп Туфайловны сайлап алды. Аннары тагын, тагын! Туфайлов уңайсызланды, тартынды, әмма баш тарта алмады. Анна Сергеевна бөтен барлыгы белән Туфайловка бирелгән төстәрәк хәрәкәтләр ясарга тырышты. Гадәттә йомык йөзле, моңсу күзле хатынның бүген кәефе күтәренке, күзләре дә очкынлы иде.

Икенче вальсны биегән чакта Анна Сергеевна тагы да кыюланды, дәртләнде, биек күкрәкләрен Туфайлов беләгенә кысты. Бию борылышларында аякларын Туфайлов аякларына ныграк тидергән кебек итеп алды, һәм шыпырт тавыш белән Туфайлов колагына ашыга-ашыга:

— Вафа, мин сине яратам,— диде.— Ләкин син бу тиле икән дип көлмә. Миңа җавап та бирмә. Дәшмә, ишет кенә. Мине яратырга уйлама да! Үзем генә яратам, синең яратуың кирәкмәс! Ихластан әйтәм. Сәерме? Син дә миңа тойгыларыңны белгертсәң, ара катлаулана. Арага сүз керер, хыянәт керер. Юк, теләмим. Мин үзем генә яратсам, берни дә керми. Килештек!

Аның шул сүзендә вальс туктады, икесе ике урынга барып утырдылар. Анна Сергеевна ягына карамаска тырыша иде. Аның сүзләре Туфайловны гаҗәпләндерде дисәң, аз булыр. Бер авызы пешкәч, ул һәр хатын-кызга шик белән карый һәм үзен алардан ерак тота иде. Берсе белән дә якыннан аралашмый, бары рәсми төстә генә сөйләшә. Анна Сергеевна белән дә бик аз сүзле булды, бары эш кирәге буенча гына сөйләште кебек. Аннары аның эчендә хатын-кыз янына якын баруны тыя торган нәрсәдер утыра иде. Нәрсәдер инде ул? Мираны һаман оныта алмаумы? Әйе, аның җанында Мира сызып калдырган сызыклар исән, тере. Тиз генә җуелмаслар кебек. Ул аптырый: бергә торган ир белән хатын ничек бер-берсен ташлыйлар да икенче кеше белән бик тиз һәм ансат кушылып китәләр? Хисләрне шул хәтле тиз алыштырып була микәнни?

Анна Сергеевнага табигать тышкы матурлыкны җәлләгән шул. Яңак очлары калкынып тора, күзләре эчкә баткан. Борыны да ямьшек, әмма гәүдәсе сыгылмалы, нәфис. Шулай да йөз ямьсезлеге беренче булып күзгә бәрелә иде. Туфайлов белә: Анна Сергеевнаның күңеле бик саф, җаны бик бай аның. Ул кешеләрне бик җәлли, аларга ярдәм итәр өчен бер нәрсәсен дә кызганмый. Кискен авыкта әллә ничә яралыга үзенең канын биреп коткарып калды. Бу кичне ни өчен ул Туфайлов белән генә биеде? Үзенең тойгыларын әйтергә җайлы булган өченме? Әллә менә мине ямьсез дип йөрсәгез дә, нинди кешене караттым, дип үзен күрсәтергә теләпме? Хатын-кыз үзе карата алган кеше белән бик горурлана диләр? Анна Сергеевна шулай шаярасы иттеме? Сез аны рәсми, салкын кеше дип белеп, аңардан бераз шикләнеп йөрисез, ә ул минем якын дустым, дип үзенең батырлыгын күрсәтер өченме? Тыйнак һәм кыюсыз хатынга бу нәрсәләр бер дә ябышмый иде.

Шул мәл ишектә Уразаев күренде. Ул Туфайловны дәшеп алды. Ниндидер мөһим сүзе бар кебек иде. Үзе әз генә кәефләнгән дә, ахрысы. Туфайловка шулай тоелды. Уразаев аны коридорның теге башындагы бүлмәсенә алып керде. Бүлмәдә ике караватъ, бер өстәл, ике-өч артлы урындык, хуҗалардан калган, госпитальнеке түгел...

Утырышкач, Уразаев аска төбәлгән килеш папирос алып авызына

капты да, кабызып, Туфайловка күтәрелеп карады һәм тигезсез тавыш белән:

— Иптәш Туфайлов, ачык кына сөйләшик әле,— диде.— Нигә сез мине өнәмисез? — Ул туры карап торды да папиросын суырды, карашын аңа кадаган көе тотты. Туфайлов, бу шаярып сөйләшә, дип, ахрысы, елмайды, яктырып китте. Бер сүз дә әйтмичә, шул килеш карап торды.

— Юк, мин җитди,— дип Уразаев бик ныклы тонда үзенең фикерен куәтләде. Туфайловның йөзендәге нур сыпырып ташлагандай юкка чыкты.

— Кайдан алай әйтәсез, иптәш Уразаев? — диде ул баш хирургның сорау алгандагы тон белән сөйләшүенә гаҗәпкә калып.

— Рувим белән Альбинның миңа шырпы кадап торуларыннан сизәргә була, иптәш замполит.

— Мин аларны сезгә каршы котыртаммы әллә?

— Алай ук дип уйламыйм, сез алар яклы, монысы анык!

— Сез дә тәнкыйть итәсез, алар да... Үзара тәнкыйть файдалы диләр бит...

— Алар бит күбрәк минем шәхескә тукыналар, иптәш замполит, үзегез дә беләсез...

— Хәзер тукынмаслар, мин алар белән сөйләштем.

— Шулай да сез мине өнәмисез? Мине партиягә алмау өчен тырышачаксызмы?

— Анысы бүтән мәсьәлә, иптәш Уразаев...— Туфайлов бу кешенең ертлачлыгына шаккатты. Кара, ничек итеп мине алдан эшкәртмәкче була. Кем әйткән аңа минем өнәмәүне? Фроловмы? Әллә шуны эшләрме икән? Юк, ышанмыйм. Мин Уразаевка начар карый идем, әмма хәзер фикерем яхшы якка борыла башлады. Ләкин менә бу ертлачлыгы миндә дә нииндидер хаклык булганын раслый түгелме?

— Рекомендация бирерсезме?

— Уйларга кирәк булыр, билгеле...

— Әйтегез, курыкмагыз. Без монда икәү генә, шаһитлар юк.

— Лаек түгел дип кистереп әйтә алмыйм, әмма бу кат-кат уйлауны сорый торган нәрсә,— диде Туфайлов гаҗәпләнүе арта барган төстә.

— Сез генә чиста инде бик. Адәм баласы гөнаһсыз була алмый ул! Һәркемдә дә ни дә булса бар. Беркем дә фәрештә түгел. Кат-кат уйлыйсы бар, имеш!

— Моның белән ни әйтмәкче буласыз? — диде Туфайлов ачуы килеп, ләкин тавышын күтәрүдән үзен тыйды.

— Сез күпме генә киртә куйсагыз да, барыбер партиягә керәчәкмен! Шуны гына әйтмәкче булам.

— Мин киртә куймыйм, әмма үз фикеремне әйтәчәкмен,— диде Туфайлов ныклы тавыш белән.

— Ачыктан-ачык сөйләштек, рәхмәт! — дип Уразаев урыныннан торды һәм киң итеп елмайды да Туфайловка кулын сузды. Сөйләшүне әйбәт бетерәсе килә иде аның. Ул үзенең Туфайловтан шүрләп тормаганын күрсәтәсе килгән кебек иде. Туфайловның да арада урнашкан киеренкелектән котыласы килде. Болай яшәве бик читен. Ул аның кулын иптәшләрчә кысты:

— Бер-беребезгә кинә тотмыйк, иптәш Уразаев,— диде.— Эшкә генә зыян. Шулай бит?

Теге ияк какты, йөзе яктыра төште. Үзен җиңүче итеп санаган кебек иде. Туфайлов та елмайды һәм йөз нурын сүндермичә ишеккә атлады.

* * *

Әнвәрнең яралы аягы бот төбеннән аяк бармакларына кадәр шеште, кызыл-кучкыл төскә керде. Тездән бөгелгән көе тораташ каткан иде.

Бер тамчы кыймылдата алмый, сызлавы җанга төшә, ялгыш кына кыймылдатып куйса да авыртудан аңын җуя, шул сызланудан ярым аңгыминге хәлдә ята. Тышкы дөньяны бөтенләй диярлек кабул итә алмый, аны күрми, ишетми. Бар нәрсәне ярасы сызлау томалап бетерә иде. Иң аянычы, тамагына берни капмый, бигрәк тә тәнгә иң кирәк нәрсә — шикәрне авызына якын да китерә алмый. Нәрсәдән шулайдыр инде? Бәрәңге ашыйсы килә, әмма аны юк диләр. Беркөнне Ася апа пилмән пешереп алып килде. Яраланганнан бирле андый тәмле ризык ашаганы юк иде. Менә бүген тагы пилмән китергән. Ак тәлинкәгә салып бирде. Әнвәр, кырын ауган килеш шыр сөяккә калган үтә күренмәле кулы белән кашыкны көчкә-көчкә йөртә иде. Маңгаеннан борчак-борчак тир тама. Ашына тама иде. Ася, зәгыйфь балага караган шикелле, жәлләгән йөз белән күзәтеп утыра.

— Син кем булып эшләдең? — дип сорап куйды ул.

— Ат көтүчесе.

— Аягыңны киссәләр, нишләрсең?

— Белмим.— Әнвәр, Асяның ни әйткәнен аңлап та бетермичә, шулай диде. Аңа күп нәрсәләр барып җитми. Сүзләрнең дә асыл мәгънәләрен белеп җиткерә алмый ул. Һәм шуңа, ни генә сорасалар да, «Белмим» дип җавап кайтара. Алда нинди куркыныч, афәт барлыгын абайларга да көче җитми. Бар мәгънәләрне шул сызлау юкка чыгарып бетергән. Уйлау, хәвефләнү, саклану инстинктларын җимереп ташлаган. Өйләдән соң аның беләгенә шприц белән кадап кан җибәрделәр. Тагы да авыр булды, температурасы кырыкка сикергән иде. Янә аңыннан китеп ята башлады.

Бер-ике көннән соң бил турының бик каты кисеп авырттыруы аны аңына китерде. Ул күзләрен ачты. Аркасына бик юан энә белән укол кадыйлар иде. Тукта, нишләп биредә әле ул? Бөтен җир ап-ак. Бу операция ясый торган бүлмә, ә ул операция өстәлендә ята икән. Уколдан соң, кәкрәеп каткан яралы аягын яздылар, бер дә авырту сизмәде. Аннары шул аякны кызгылт йодка буядылар...

Бот төбенә эч ягыннан үткен әйбер белән сызып җибәрделәр. Әнвәр авыртудан кинәт тартылды, авырту тагы кабатлангач кычкырып җибәрде. Аның кулларын ныклап тоттылар, исән аягын да бәйләп куйганнар иде. Авыртуга чыдап булырлык түгел иде. Нигә аңа наркоз бирмәделәр икән? Шуны да күпсенделәрме? Күпкә җиңел булыр иде... Кисеп-ачытып авырту баш миен тырнап үтә шикелле, һич тә чыдар әмәл юк. Бар чара шул кычкыру. Әнвәр тоташ кычкырып ята башлады. Ике беләгенә дә тагы укол кададылар. Әмма бернинди җиңеллек сизелмәде. Әнвәр үкерде, үкерде дә татарча сүгенде. Хирургны тиргәде. Ул сүзләрне, мәгънәләрне бутый иде. Сүзләре бәйләнешсез чыга. Беләкләренә тагы укол кададылар. Шунда аның тәне тотлыкты. Кычкырган тавышы авыз эченнән ары узмый. Авызы лыгыр-лыгыр килеп тора. Кычкыра-кычкыра хәле тәмам беткән иде. Ләкин җанны кисә торган авырту аның бәгырен телгәли. Ул башын әле бер якка, әле икенче якка ташлый. Тир агудан мендәре юешләнеп, манма су булган. Шәфкать туташлары: «Түз, жаныкаем,— дип өзгәләнеп башын, битен сыпыралар, юмалыйлар. Маңгаендагы бөрчек-бөрчек тирләрне тампон белән сөртеп торалар.— Хәзер бетә, түз, түз...»

Бераздан, Әнвәр ничек исен җуйганын абайламый калды. Тәмам мингерәүләнеп беткән иде. Бер мәл шытыр-шытыр итеп сөякне кискән чакта ул исенә килде һәм авыртудан кычкыра башлады. Ләкин кычкырырга көче юк иде. Тәмам хәле бетеп тынды. Операция әле озак дәвам итте, әмма ул инде берни дә белмәде.

Әле аңында чакта да аңа үзенең нинди зур бәхетсезлеккә дучар булуы турында бернинди ачыну, үкенү өше уйлар килмәде. Үлүем ихтимал бит дигән сагаюлы уй да. Кешене камчы белән кыйнаганда бераздан тәне берни сизми башлый, аңа барыбер була. Әнвәр дә нәкъ шундый хәл-

дә иде. Бар нәрсәгә битараф булып калды. Аның өчен дөньяда шул яра авыртуы гына бар, башка берни дә, бернәрсә дә юк иде. Ул көн тойгысын, төнне һәм вакытны тоюны да югалтты. Кайчан яраланган, хәзер кайсы ай, аларны белми иде.

Ничә көннән соңдыр, ул күзләрен ачты. Беләгендәге кан тамырына шприц энәсе кадап куелган, ул нечкә шланг белән дүрт почмаклы кызыл савытка тоташтырылган. Кызыл пыяла савытны шәфкать туташы югары күтәреп тора. Савыт эчендә куе кызыл сыеклык. Нәрсә бу? Аңа тагы кан җибәрәләр икән. Нигә болай шланг белән? Аңа бит шприц белән генә җибәрәләр иде? Кан озак акты. Шприц белән кан бик тиз тамырларга кереп бетә иде. Ул нидер сизенеп аяк буена кулын сузган иде, кулы чокырга-бушлыкка төште дә китте. Уң аяк урыны буш иде. Менә шул мизгелдә генә аягы киселгәнлеге миенә бик каты китереп сукты. Яра сызлавын да оныттырып торды. Әмма бу озакка бармады, сызлау барча вөҗүден ду китерде, уйларын үзенә чылбырлады.

Исән аяк балтырына да шприц китереп кададылар. Шприц нечкә кызгылт шланг белән пыяла савытка тоташтырылган иде. Савытта су шикелле үтә күренмәле сыеклык. Шул тәнгә агарга тиеш икән. Тамырга түгел, тән итенә ага. Шуңа күрә ярты тәүлеккә кадәр агып тора икән... Бусы тән температурасын төшерер өчен, ди.

Әнвәр һаман тамагына ризык кабул итә алмый иде. Операция булгач, күпмедер вакыттан соң, аңа аппетит өчен бер микстура спирт бирә башладылар. Аш алдыннан шуны эчеп җибәрә торган булды. Ризыкларны яхшырттылар шикелле. Ул тамагына әз-мәз капкалап алган итә иде. Кичке аштан соң укол бирәләр, бар сызлау-авыртулар бетеп китә. Күзне йокы баса. Төнге өчләрдә уколның көче бетә, ахрысы. Каты сызлау тагы үз зынҗырына ала. Әнвәр түзеп ята-ята ыңгыраша. Аннан кычкырып җибәрә. Палатадагылар йоклый кебек. Аның кычкыруына Ася килеп җитә. Әнвәр Асяга өмет белән карый һәм аңардан укол теләнергә тотына. Ася аның янына килеп утыра, кулларыннан тота, юмалый, үтенә, түзәргә куша. Әнвәр һаман ыңгыраша. Күңелгә тиярлек тавыш чыгарып уфылдый. Ләкин Ася укол бирми. Әнвәрне одеалына бала кебек төреп ала да алдына утырта. Әнвәрнең башы Асяның мендәрдәй биек күкрәге өстенә ята. Ул аны шыңшыган саен күкрәгенә ныграк кыса. Менә хәзер кычкырып кара инде! Әнвәр бик нык ояла һәм сызлауларга түзеп тора... Ася аны шулай тынычландырып утыра, бу эштән бер дә җиксенми, бар җаны белән аның хәлен җиңеләйтергә тели. Ыңгырашу басыла төшкәч, ул аны кире үз урынына бала кебек итеп сала да икенче палатадагы авыр яралылар янына чыга.

Әнвәр чыдап ята, бүтән йоклый алмый. Иртән Анна Сергеевна килә. Махсус кереп иң элек аның хәл-әхвәлен белешә. Хәле авыр булса, шунда ук нindидер дару алып килеп эчертә. Шәфкать туташларына нинди укол кадарга кирәклеген әйтеп, күрсәтмә бирә.

Анна Сергеевна үзе бик боек йөри иде. Палатага кергәндә күзләре яшьтән кызарып беткән була. Җиңел яралылар кызыксына: безнең врачка нәрсәдер булган, диләр...

Анна Сергеевнаның бетерешкән кыяфәттә йөрүе тикмәгә түгел иде. Теге генерал хатынын Туфайлов белән икәү исән-имин бәбәйләткәч, хәлдән таеп, Анна Сергеевна бүлмәсенә кайттылар, чәй кайнатып эчтеләр, Анна Сергеевна шунда ничектер ачылды, кайгысын сөйләде. Туфайловны якын итүе булгандыр инде.

— И, Вафа, бик зур хәсрәтем бар,— дип куйды чәйле стаканына кайгылы төбәлгән рәвештә. Аның чыгыбрак торган яңак очларында гаҗизлек төсмерләре беленә иде.— Минем абый әсир төшкән һәм немецларга хезмәт иткән. Аерым бүлек кешесе килеп миннән сорау алды. Абый фамилиясен үзгәрткән, ничек ул шундый хәлгә төшкән?..— Анна Сергеевнаның тамагына күз яше төере утырды да сүз бүленде. Ул, сер бирмәскә тырышып, тамагына учын куйды, уфылдады. Аның ир-ат янын-

да кыланчыклана торган гадәте юк, аңа бик авыр иде. Туфайлов та, чәен уртлаудан уңайсызланып, тынып калды. Бу очракта юату сүзләре бик көчсез, кешене үртәгән кебек чыга.

— Ниләр күрмәде ул бичара,— диде Анна Сергеевна, бераздан зиһенен туплап. Сүзләре тигезрәк чыга башлады.— Комсомолдан кудылар үзен... Менә шуның нәтиҗәсе...

— Кимсеттеләр, немецларга хезмәт итүе дә шунардан димәкче буласызмы? — дип сүз кушты Туфайлов, дәшми тору уңайсыз булганга күрә.

— Соң башкача бу хәлне ничек аңлатырга?

— Холык-фигыле ниндирәк иде соң?

— Нинди дип, бүтәннәр ничек, ул да шулай,— диде Анна Сергеевна. Бераз уйланып торганнан соң өстәде: — Дөрес, бераз мактана торган гадәте бар иде... Менә син ир-ат, әйт, ничек кеше хыянәтче булып китә? Куркак булгангамы? Әллә күңеленә кимсенү төйнәлгәнгә күрәме?

— Ничек дим, төрлечә булуы мөмкиндер, әмма хыянәттә бер сәбәп тә исәпкә алынмый бит, Анна Сергеевна,— диде Туфайлов.

— Немецлар бит йә үлем, йә безгә хезмәт итәсез, дип мылтык терәгәннәр. Әсирләрне ачтан үтергәннәр. Кеше бары җан саклау өчен, мәҗбүри генә аларга хезмәткә керә. Бу да исәпкә алынмыймы?

— Исәпкә алынмый, барыбер хыянәт санала.

— Ягъни, кеше немецка хезмәт иткәнче, үлемне сайларга тиеш?

— Әйе, нәкъ шулай!

— Үзеңә шундый куркыныч янамаганда, үзең шул хәлгә калмаганда, фикер йөртү җиңел! — дип куйды Анна Сергеевна, кәефе китеп.

— Әйе, җиңел,— диде Туфайлов тыныч кына.

— Менә син үзең нишләр идең?

— Шундый мөшкел хәлгә калсам, рас миңа шундый әшәке җирәбә чыккан икән дип, корбанга барыр идем. Ватан белән үземне чагыштырып карар идем, ватан нинди зур, ә мин черки генә! Башымны шулай юкка чыгарып, үлемне сайлар идем. Юк, мин патриот булып сөйләнүдән җирәнәм. Мин үзем куркак кеше, Анна Сергеевна, Сталинград янында чолганышта калгач, күп уйландым. Немецларга эләгеп, әшәке хәлгә калсам, дип, үземне үлемгә әзерләдем. Шул чагында курыкканнарым! Чолганышта чакта бер төнне ике санитарыбыз юкка чыкты. Каядыр качтылар. Дошман ягына китмәгәннәрдер, әмма бу хәлдән ялгыз гына котылу ансатрак дип уйлаганнардыр...

— Аны бик рәнҗеттеләр, шуларны оныта алмагандыр, бичара.

— Юк, рәнҗүләрне эшкә кушарга ярамый,— диде Туфайлов.— Миңа да күп ударлар булды. Мин тау институтына кергән идем. Шунда провокация ясап гаеп тактылар һәм укудан чыгардылар.

— Шулай ук булдымыни? Сине дә рәнҗеттеләрме? — Анна Сергеевнаның күз аклары ачылып ялтырап алды.

— Ничек кенә. Михневич дигән активист бар иде. Гел минем тирәдә сырпаланып йөрде. Пивнушкаларга да бергә кергәли идек. Егетләрнең сүзе ни хакында? Кызлар хакында. Төркемдәге кызлар турында ни дә булса әйткән булганмындыр. Кинәт беркөнне җыелыш җыеп мине тикшерә башладылар. Персональ эш. Мин фәлән кыз турында ул саф түгел, дип әйткәнмен, имеш. Михневич миңа шундый гаеп тага. Теге кыз, имеш, шул сүздән авырган, больницага кергән. Ул кыз бик чибәр иде, күпләргә ошый иде. Ни дә булса минем авыздан ычкынгандыр. Ләкин андый ямьсез нәрсә башыма да килгәне юк иде. Әмма ничек гаебеңне кире кагасың? Төймәдән дөя ясау модада чак.

— Безнең Мишаның да дошманнары күп иде...

— Дошман каян була? Дустан була... Михневич та дус булып йөрде.

— Нишләтерләр инде бичараны? — дип көрсенде Анна Сергеевна.

Туфайлов, юату әмәле таба алмаганга, үз тарихын сөйләргә тотынды:

— Кызык, Михневич белән тагы очрашырга туры килде,— диде —

РС батареясы командиры булган. Немец чигенгәндә болар залп бирә-бирә эзәрлекләп барганнар. Бер урман эченнән кинәт немец танклары килеп чыккан да боларга ташланган. Чигенергә маташканда машина янында снаряд ярылып расчетны сафтан чыгарган. Машинаны калдырып чигенгәннәр. Ә «Катюша»ны дошманга калдырырга ярамый, шартлатырга тиешле. Болар өлгерә алмаган. Машинаны шартлатмаган өчен Михневичны трибуналга биргәннәр. Ләкин ул мин контужен булдым, берни ишетмим, дип барган. Госпитальгә салганнар. Безнекенә. Ул чынлап та берни дә ишетми иде кебек. Сынау үткәрделәр бугай. Мине танып алды да — артымнан калмый гына. Килә дә миңа язу төртә: «Миңа ышанып бетмиләр, контузиямне ми эшчәнлеген зарарлаган итеп куйдыр, зинһар». Мин аңлыйм, әгәр авыру тарихына шундый бер сүз язылса, трибуналдан котылып калачак ул. Бер килә, ике килә. Барча врачларны тинтерәтеп бетерде. Нишлисең, зур врачлар белән сөйләшеп карадым. Әйе, шундый диагноз мөмкин, диделәр. Һәм язып та куйдылар... Бер сүз кеше язмышын хәл итә бит, бер сүз!

— Чынлап та, теге җырдагы кебек, язмыш кешеләр белән шаяра,— дип тирән сулады Анна Сергеевна. Аның керфек очларында яшь бөртекләре үлән бәбәкләренә кунган чык тамчылары кебек елтырый иде. Абыйсын җәлләү хисе йөрәген өзгәлидер инде...

— Синең кебекләр сирәк шул, Вафа,— диде хуплаган кебек итеп Анна Сергеевна. Чөнки ул Туфайловның бу эшен шәхси уңышы, өстенлеге итеп санавын чамалап алган иде.— Безнең Миша бәхетсез җан, начар кешеләргә юлыккандыр, аңлы рәвештә андый адым ясавына ышанмыйм.

Шул чак Анна Сергеевнаның бүлмәдәше Таня кайтып керде. Аның кыяфәте бик арыган, күз төпләре зәңгәрләнеп тора иде. Анна Сергеевна, кайгыртучы кеше кебек, тизрәк урыныннан торды:

— Әллә берәр хәл булдымы, Таня?

— Кан тапшырырга туры килде,— диде кыз бил каешын чишеп. Аның сыгылмалы матур гәүдәсе, төз муены, бар нәрсәсе килешле булган йөзенең матурлыгы соклану уята иде.

— Нигә шундый ашыгычлык?

— Әнә Әнвәрнең йөрәге туктый башлаган. Ася тревога куптарды да...

— Аңа дүрт көн элек кенә Ася үзе биргән кан җибәрелгән иде бит?

— Белмим. Ася белән Лия Никифоровна төнлә дежур вакытта тагын хәле начарланган...

— Анна Сергеевна, борчылма, ял ит!— диде Туфайлов ишеккә таба бара-бара. Чөнки Таня, гимнастерка төймәләрен ычкындырып, чишенеп ташларга җыена иде. Әмма Анна Сергеевна яралы егет өчен чынлап борчыла калды. Чөнки аңында: «Кан җибәрү урынлы булдымы икән?»— дигән шик уянган иде. Тиз генә җыенды да яралылары янына ашыкты.

## 7

Операциядән соң Әнвәрнең хәле һаман кыл өстендә тирбәлде. Үзенең гомеренә дә, барысына да битараф төстә ята иде. Аңына килеп җитә алмаганга шулай ул. Әмма врачлар, шәфкать туташлары аның гомере өчен көрәшә иде. Бер дә өзми тукландыру уколлары ясап торалар: кан тамырына глюкоза җибәрәләр. Аннан тыш яшь организм үзе дә яшәү өчен тырыша иде. Менә әкрен генә, шыпырт кына яшәү көче әҗәлне чигендерергә тотынды. Әнвәргә Ася биргән канны җибәргәннәр иде. Шуннан күзе ачылды. Иң авыры беренче адым, аннары китә ул...

Әнвәрне уколлар белән йоклатып тоттылар. Гомере өчен бик кискен, авыр мизгелләрне дә шул йокы эчендә үткәреп җибәрде, ахрысы. Шул йокы белән үлгәнен дә белми калган булыр иде. Кризис үткәчрәк, Әнвәр

күзләрен ачты, аның янында Ася утыра иде. Әнвәрдә кайдадыр бик еракта югалып менә хәзер генә кайтып төшкән чакта була торган тойгы иде. Ул Асяны исенә төшереп озак кына карап ятты. Шул элеккеге Асямы соң бу, әллә бүтәнме? Әйе, шул Ася икән! Хәтеренә төште. Ася да аңа гаҗәпләнеп, көлемсерәгән килеш карап тора. Йөзе әчке шатлык белән яктырып китә. Учы белән Әнвәрнең битеннән сөя-сөя әйтә:

— Ну, малайка, сират күперен үттең, хәзер яшәргә тиешсең!— дининдидер сер ачкандай сөенеп. Әнвәр аның нигә сөенгәнен аңлап җитмәгән көе аңгыра бозау карашы белән тик карап ята. Әмма эчендәге ниндидер сиземләү, тоныкк аң Ася шатлыгын аңлаган кебек була һәм Әнвәр шәфкать туташының күңеле өчен генә елмайган итә.

Ләкин кич булды исә хәл начарлана, яра бик каты сызларга тотына. Әнвәр түзеп ята да шыңшырга, уфылдарга керешә. Ася кизү торганда алай газапланырга туры килми. Ул ничектер җаен таба, врачлар кушмаса да, укол биреп, Әнвәрне йоклата...

Менә операциядән соң беренче «перевязка»ны алу вакыты җитте. Ася керде дә Әнвәрне нәкъ бала кебек итеп одеалына төрде һәм кочагына күтәреп алды, аннары бәйләү бүлмәсенә алып китте. Әнвәр авыр түгел иде, ярты гәүдәсе юк, калган тәнендә дә тире белән сөяк кенә. Асяның таза беләкләре аны очыртып кына илтте һәм бәйләү өстәленә китереп салды. Бәйләүче шәфкать туташы эшкә тотынды. Яра өстендәге канга каткан бинтны йомшарту өчен дару белән чылатып чыкты һәм әкрен генә кубара башлады. Әнвәрнең күзеннән утлар чәчрәп китте, ул кычкырып җибәрде. Аны килеп тоттылар, беләгенә укол кададылар. Шул арада бәйләүче шәфкать туташы яра өстендәге бинтны кубарып төшерде. Яра кискән агач төбе чаклы зур иде. Рувим Михайлович яраны карады да: молодец!— диде һәм Әнвәрнең тирдән манма су булган башыннан сыйпап сөеп торды. Яраны барысы да әйбәт дип таптылар.

Бәйләүче, яраны бик җентекләп спирт белән чистарткannan соң, өстенә стрептоцид порошогы сипте, ап-ак булганчы сипте. Аннары токмач җәймәсе кадәр марля алып, шуңа сары дару сеңдереп чыкты. Ике учы белән шул җәймәне яра өстенә япты. Икенче шәфкать туташы ярага бинт чолгарга кереште. Аның куллары җитез йөри иде.

Бәйләү беткәч, Ася тагы Әнвәрне одеалына төреп алды да, биек күкрәкләренә кысkan килеш, палатага алып китте. Бик иплән кенә караватына китереп яткырды.

* * *

Госпитальдә тормыш тыныч кына бармый иде. Көн дә нәрсә булса да килеп чыга. Бер төнне движоктан Наузинь Ингельне кулга алып киттеләр. Шәһәрдән диверсантлар эзләгәндә аңа шик төшә. Шикләнер өчен аңарда барча сыйфатлар бар: үзе җирле латыш егете, әтисенең кайда икәнлеген эт тә белми, әнисе биредән мәҗбүри күчерелгән. Диверсант тотарга теләгән кешенең шул билгеләргә әһәмият итми хәле юк. Ә диверсантны табарга кирәк. Мондый очракны аклый торган нигез: агачны кискәндә йомычка очмыйча мөмкин түгел.

Туфайлов Ригада семинарда иде, кайтуына шундый аяныч хәл. Ул бик борчылды, нишләргә белмәде. Ингель язмышы аның өстендә иде, шул җаваплылык намусын чәнчеп тора. Фролов янына бик кайгылы йөз белән килеп керде. Әмма начальник тыныч иде, хәтта битараф сыман да тоелды. Без бирни дә эшли алмыйбыз, тикшерсеннәр, гаебе булмаса, чыгарырлар, бу нәрсә турында сүз алып бару мәгънәсез эш бит, дигәнне аңлаткан чырай белән. Туфайлов бераз аптырап китте, чөнки Фролов бөтенләй Ингель эшеннән читләшкән шикелле иде. Тыштан ул балага очраган кеше яклы булып сөйләшә, хәтта кайбер эшләр дә

эшләгән була. Әмма яшертен генә үзен читтә калдыру чарасын эзли. Ә бу юлы ул яшеренеп тә тормады, Ингельне коллективтан сызып, эштән чыгарып ук куйган.

— Нигә болай ашыгу?— диде Туфайлов.

— Аның ышанычлы түгел икәне күптән билгеле иде бит инде, нәрсә белмәгән булып маташасыз?— дип Фролов каты гына итеп әйтеп куйды.

Туфайлов, эченә суык йөгергәнен сизгән хәлдә, ишеккә юнәлде. Начальник белән аның фикерләре, ниятләре туры килми. Алар икесе дә җитәкче, ә уйлары аерым-аерым. Болай булырга тиеш түгел бит! Дөрес, моңарчы да каршылыклар чыга торган иде. Тыныч кына фикер алышып, бер уртак ниятка килә торганнар иде. Фролов үзен болай алдан ачык-тан-ачык читләштереп куймый иде кебек. Һәрхәлдә, Туфайловка шулай тоела иде. Бу юлы сөйләшәсе дә килмәде. Димәк, биредә Ингель мәсьәләсеннән дә җитдирәк хәл бар. Нәрсә булыр бу? Әллә миннән арынасы киләме икән? Уразаевны үзенә бик якынайтты, нәрсәдер серләре бик килешә башлады. Туфайлов Уразаевны партиягә алуга каршы иде, рекомендация дә бирмәде ул аңа. Уразаев тыштан берни белгертмәде, ачуын эчкә яшерә ала торган ихтыярлы кеше икән. Һаман элеккеге мөнәсәбәтне саклаган рәвештә тыныч кына йөри. Әнә шул тынычлыгы, битараф төсе борчый Туфайловны. Чөнки белә: Уразаев моны болай гына калдырмаячак. Астан сиздерми генә ниндидер эш алып бара булыр. Уразаевның тышкы кыяфәтендә ниндидер астыртынлык бар иде: юка соры чәчен бер якка тарап куюы, алга чыгып торган очлы борыны, кечкенә авызы, эчкә баткан күзләре аны тычканга охшаталар иде. Андый кешеләрнең җир астыннан да юллары була... Хәер, нигә курка әле ул? Бу бит нидәндер, кемнәндер куркудан туган уйлар?

Туфайлов движокка барып керде. Ни күрсен, ике механик ике почмакта бөгәрләнеп йоклап яталар. Моторны сүткән булганнар. Имеш, Наузинь дизельне ватып киткән... Детальләр белән идән тулган. Җыярга көчләреннән килмәгән. Шәфкать туташларыннан спирт теләнеп алганнар да лыкынганнар. Македонов үзе дә аларны спирт белән узындыра иде. Ул бер көн нестроевиклар арасыннан бер механик табып алып кайткан иде. Бер-ике көннән беленде, ул моторны юньләп белми икән. МТСта бухгалтер булып эшләгән. Бу юлы Фролов та механикларга карата йомшаклык күрсәткән шикелле. Монысы инде Туфайловка күләгә төшерү өчен эшләнгәнне сизелеп тора. Чөнки Ингель аның мактаулы кадры санала иде. Менә ул мактаулы кеше безне нинди хәлгә куйды дип әйтергә бөтен нигез бар. Македонов кичә сөйләшкәндә аңа шундый чәнечкеләр җибәргәләде.

— Аны алганга сөенгән кебек итәсең, ә үзеңнең движокны җибәрергә кулыңнан килми,— диде аңа Туфайлов шулай ук төрттереп. Македонов, елмаеп, башын селкеп куйды, йомшады. Җитдиләнгән төстә әйтте:

— Иптәш замполит, сез ул латыш малае белән булышмагыз, бәладән башаяк. Алар бит барысы да буялып беткәннәр, үзегезгә авырлык килә күрмәсен диюем.

Ул Туфайловның җавабын да көтмичә, тизрәк китеп барды. Туфайловны үҗәтләнү тойгысы биләп алды. Нәрсәдән куркып барысы да шул уңган егеттән баш тарта? Туфайлов аны йолып ала алган очракта да бирегә эшкә куймаслар шикелле сөйләшәләр. Кеше чын күңелдән хезмәткә бирелгән, бүтәннәргә файда китерә. Тагын да яхшылык китерәчәк ул. Аның бер гаепсез булуына Туфайлов үзенә ышанган кебек ышана. Бу бит Наузиньның туган җире! Нигә аны туган җирендә риясыз эшләүдән аерырга? Нигә аңа берниндн нигезсез шикләнеп карарга?

Ул бүген үк Ингельне юллап йөри башларга ният беркетте.

* * *

Уразаев партиягә керер өчен эшне ашыктырып йөри иде. Өч рекомендация алган. Берсен Фролов үзе биргән. Туфайловның үз фикере ачык: Уразаевны партиягә алырга иртәрәк, дип саный ул. Моның өчен дәлилләре дә житәрлек: эшендә чатаклыклар килеп чыккалый. Иң мөһиме, коллектив алдында абруе чамалы. Чөнки операцияләр ясаганда осталыгы аксавы, булдыклылыгы житенкерәмәве үзен сиздереп тора. Алдында аңа ялагайланып елмаялар, артында яманлап сөйлиләр иде. Моныcы гадәти хәл. Ул баш хирург булгач, күрсәтмәләр бирергә, эшләргә мәжбүр итәргә тиеш. Бу нәрсә кайберәүләрнең мин-минлегенә тия, канәгатьсезлек тудыра. Әмма Уразаев эш өчен чынлап тырыша иде. Һәр чак булдырып кына чыгара алмый, шунысы кызганыч. Теләге бик көчле, ләкин мөмкинлекләре теләгенә караганда күпкә ким тоела. Ул шуны әрсезлеге, кырыслыгы белән тутырмакчы була иде. Уразаевның шундый кимчелекле якларын исеннән уздырып алгач, Туфайлов уйлап куйды: Ә бит кешене өнәп бетермәсәң, аның житешмәгән якларын бик күп табасың? Мин дә шул чиккә төшеп фикер йөртәм, ахрысы. Болай ярап бетмәс.

Уразаевның партия сафы өчен житлегеп бетмәгәнлеген Фроловка белгерткән иде, тегенең күзләре әле бер, әле икенче якка йөгергәләргә тотынды. Бу аның ачуы килә башлау билгесе иде. Ул ачуын тыеп кала белә торган кеше, шулай да муенында кызыл сызыклар сызылып менде. Туфайлов курка калды. Уразаев турындагы әз генә кире фикергә дә шул чаклы ачу кайнап чыгар икән. Алар, ахрысы, бик якыннар? Элек тә бергә эшләгән булганнар икән. Моңарчы нигәдер әйтмәделәр? Аларны бергә хезмәт итү генә түгел, тагы да тирәнрәк, мөһимрәк нәрсәләр бергә бәйли шикелле. Юк, биредә хикмәт аның яраткан кешесе Уразаевта гына түгел, ә Фроловның никадәр мине өнәмәвендә. Ярар, Уразаев таләпчән булсын, ди. Фролов аның шул сыйфатын беренче итеп куя. Ул ягын Туфайлов та хуп күрә. Әмма кеше башкаларга таләпчән булып та үзенә таләпчән түгел икән, бу хәл төрле рухи канәгатьсезлекләр китереп чыгара. Уразаев күбрәк үзенең власть көченә исәп тота, ахрысы. Ярар, шулай булсын. Мин Фроловка ышанам, төпле кеше, шуңа күрә аның ниятенә каршы килмим. Уразаевка каршы килеп нәрсә ота ул? Бүген булмаса иртәгә барыбер партиягә керәчәк. Туфайловны читләтеп үтеп керәчәк. Нигә үзеңә дошманнар жыярга? Уразаев, начальник әйтмешли, үсә торган кадр, үзгәрер, камилләшер. Кеше үзгәрмичә генә тормый бит?

Туфайлов жыелышны алдан юнәлеш биреп әзерләмәде. Сөйләүчеләргә үз фикерен белгертүдән дә тыелды ул. Астан гына Уразаевның хәстәрлек күреп йөргәнен сизсә дә дәшмәде. Әйдә, Фролов теләгәнчә булсын, диде.

Жыелыш гадәттәге тәртип белән барды. Уразаев үзенең биографиясен кыскача гына сөйләп бирде. Шуннан соң рекомендация бирүчеләр үзләренә йөкләгән бурычларын өсләреннән төшерделәр. Туфайлов жыелышны жанлырак итеп уздырырга тырыша иде. Анда күп нәрсәләр ачыктан-ачык әйтелергә һәм тикшерелергә тиеш. Кешеләрнең үзләренә йөкләгән эшкә мөнәсәбәтләре нинди, яхшымы, начармы — шул нәрсәләр ачыклансын. Жыелыш коллективтагы ялган дуслыкларны, берәү кимчелеген икенчесенең ышыклап килүен дә ачып салсын!

— Күптән түгел бүлмәмә бер танышым килеп керде,— дип башлады Рувим.— Һәм мине күккә чөеп мактарга кереште. Мактау мине һәрчак сагайта. «Хирургия осталыгына сездән өйрәнергә телим, үзегезгә ассистент итеп алсагыз иде»,— ди. Мин әйтәм, «сез дипломлы хирург, ассистентлык дәверен узгансыз»,— дим. Танышым өстәлгә бер шешә чыгарып куйды, мин капкаларга әзерләдем. Бер рюмка салгач, бу әйтә: «Нигә сез мине яратмыйсыз, миннән көнләшәсез?»— ди кинәт кенә. «Сездән көнлә-

шергә, аллам сакласын,— мин әйтәм,— яратмауга килгәндә, анысы йөрәк эше, аңа боерык биреп булмый. Ә нигә мин сезне яратырга тиеш?» Шуннан танышым шаркылдап көлеп җибәрде: «Бетте, бетте!» Мин бит сезне сынар өчен генә шулай әйткән идем»,— дип гафу үтенә башлады. «Нәрсәгә мине сынарга?»— дигән идем, үзенең хәлен сөйләп бирде. «Минә партиягә керергә телим, ләкин дошманнарым күп, миңа каршы киләләр, күралмыйлар», дип зарлана башлады. Ул үзен кызгандырырга тели иде. Һәм җыелышта миннән уңай фикер әйтүемне үтенде. Мин, билгеле, аптырап калдым. «Күренеп торган житешсезлекләргә ничек күз йомыйм? Нигә эшегезгә тырышлык салып, осталыгыгызны камилләштерәсе урында, партия сафына кереп, шул кимчелекләрне капламакчы буласыз?»— дидем ачыктан-ачык. Танышым, кулын селтәп, чыгып китте. Бу кеше, сизенгәнсездер, Уразаев иде. Үзенең булдыксызлыгын партия ярдәме аша белдертмәскә тырышу бар аңарда. Бу бер дә әйбәт нәрсә түгел. Иң элек эшеңне яхшыртырга кирәк. Үз мөмкинлегеңне белмичә үҗәтләнү безнең эштә бик һәлакәтле нәрсә, ул бары яралылар башына гына була. Мин яралыларны кайгыртып әйтәм.

Рувим Михайлович сөйләгәндә Уразаев йөзенә берни дә чыгармады, шулай да эчтән ачы елмаеп утырганлыгы ничектер беленә иде. Аның кайдадыр өстә ныклы таянычы бар, дип нәтиҗә чыгарды Туфайлов, Уразаевның ирен кырыйлары кинаяле тартышып куйгач.

Анна Сергеевнаның Уразаев белән мөнәсәбәте киеренке иде. Туганы немецларга эшләгәне беленгәч, Уразаев аны кыерсыта башлады. Хәер, бу нәрсә Анна Сергеевнаның үзенә генә шулай тоелгандыр бәлки. Абыйсы вакыйгасы белән үзен кимсетелгән санап, авыр кичереп йөри иде.

Анна Сергеевна бик ачынып сөйли башлады.

— Газизов Андрей дигән яралыга Уразаев операция ясады,— диде һәм, дулкынлануын басар өчен, учын күкрәгенә куеп, бераз тынып торды, аннары дәвам итте:— Ләкин яраларыннан кан китте. Күпме дарулаunion сак та туктамады. Уразаев тагы кан тамырларын тегә торган операция ясады. Кан барыбер туктамады. Яралы үлем хәлендә. Мин яраны Альбин Васильевичка да күрсәттем. Ул: «Кан тамырлары алты-җиде сантиметр тән эчендә тегелеп, бикләнергә тиеш, монда шул кагыйдә үтәлмәгән, ахрысы», дигән нәтиҗә чыгарды. Менә, иптәшләр, хирург булган кеше шул элементар нәрсәне дә үти алмасын әле?! Кан тамырлары тән-яра тышында тегелеп бикләнсә, басымга чыдамый, шартлап тишелә, яралы кан агудан һәлак була. Хәзер Газизовның хәле кыл өстендә.

Анна Сергеевна утыргач, тынлык булып алды. Уразаев бу юлы тыныч-битараф төстә генә утыра алмады, ул кешеләрнең йөзләренә текәлеп карап-карап куя иде. Өстәл өстенә бер-берсенә куйган кулларындагы нечкә бармаклары аз гына дерелдиләр иде шикелле. Анна Сергеевна сүзләрен ул үзе кире какса, көчсез, ышандырмый торган булып чыгачак иде. Бары көчле абруйлы һәм властьлы кеше генә аның өстенә ташланган гаепләргә башка төс, башка чалым бирә алыр иде. Моны Фролов та бик яхшы сизеп утыра иде, ахрысы, ул сүз сорады.

— Яралының хәле шулай соңгы чиккә җитеп начарлануы тулысы белән аның үзеннән,— диде.— Аңа ампутация моннан ике ай элек булырга тиеш иде, ул үзе баш тартты. Менә аның безгә язган ике гаризасы,— Фролов катыргыларын шап-шоп ачып ике бит кәгазь селкеде.— Ике аягында да газ гангренасы әллә кайчан ук башланган иде. Ул карышты, ампутациягә үлсәм дә риза булмыйм, дип барды. Кан туктамауның сәбәпләре күп төрле. Күп әгъзалар авыруы, мәсәлән, бавыр сәламәт булмавы һәм башкалар. Тамырларны тегү, томалауда гына түгел хикмәт. Аннары ярадан кан китү башлыча тән урталарында була. Яралыга ярдәм итүне движок эшләмәү, ут булмау бик кыенлаштыра. Шәм белән нечкә эштә бик җайсыз. Сыйфат ягына суга. Моның өчен бер Уразаевны гына гаепләсәк, гадел булмас иде. Ут булмау госпиталебезнең гомуми бәласе. Бирегә замполитның да, минем дә гаебем зур. Моны ачык танырга кирәк.

Икенчедән, һәрберебез кемне дә булса ошатабыз яки кемне дә булса ошатмыйбыз. Нәкъ Рувим Михайлович бая әйткәнчә, моңа безнең аңыбыз катнашмавы да мөмкин. Ләкин мондый хисләребезне эш процессына кертмәскә тиешбез. Менә, Рувим Михайлович, сезгә иптәш чын күңелдән килгән, ә сез аны начарга борып алгансыз...

— Мин дөрес аңлаганмын, андый юл белән партиягә кермиләр...

— Нинди юл? Менә күз алдыбызда тикшерәбез бит?— дип Фролов тәкәллефле елмайды.

— Кешеләргә алдан басым ясау юлы белән...— Рувим Михайлович бу сүзләрне әйткәндә, Фролов аңа ирек бирү, юл кую төсендә елмаеп торды. Сүзне тирәнгә җибәрәсе килмәгәнлеге күренеп тора иде. Шуңа күрә Фролов каршы бер сүз дә әйтмәде, «сүзем бетте», дип урынына утырды. Ася да Уразаевның житешсез якларын белә иде. Фролов аны ышыкылавын күреп әйтмәскә булды. Шулай да сорау бирде:

— Уразаев операция ясарга гел атлыгып, комарланып тора. Ни өчен икән?

Әмма Уразаев берни ишетмәгән төс белән утырды. Әһәмият итмәде, җавап та бирмәде. Аның калын тирелегенә исең китәрлек иде.

Бүтән сүз алучы булмагач, Уразаев сөйли башлады. Ул эш өчен, госпиталь өчен гаять борчылган, кайгырган кыяфәттә чыгыш ясады.

— Биредә вакланулар булды, аларга тукталып тормыйм,— диде.— Мин принципиаль мәсьәләләр буенча гына әйтергә телим. Бер принципсыз кеше эшкә күпме зыян китергәнен движокның эшләмәвеннән күрергә мөмкин. Замполит принципсызлык күрсәтеп Наузиньны механик итеп эшкә ала һәм штатка беркетә. Ә шул кеше бераздан диверсант булып чыга.

— Диверсантлыгы исбат ителмәгән!— дип реплика ташлады Туфайлов. Уразаев берни булмагандай:

— Исбат ителәчәк!— дип сүзен дәвам итмәкче булды.

— Ә исбат ителмәсә?— диде Туфайлов. Уразаев кулын селекте:

— Барыбер безнең кеше түгел,— дип куйды.

— Сез аны белмисез бит, нигә алай әйтәсез?— Туфайлов тегеңә карулашасы итте.

— Белергә дә теләмим,— диде Уразаев үзенә көч тойган төстә.— Ут булмау һәм шуның аркасында яралыларның газап чигүләре тулысы белән сезнең өстә! Моның өчен җавап бирергә туры киләчәк...

— Бәлки сезнең яраларны тегә белмәвегез өчен дә мин җаваплыдыр?— диде Туфайлов, ачуы килеп. Уразаевның да очлы борынының ике ягына кызыллыклар чыкты, иреннәре дерелди башлады, шулай да ул үз артында көч тойган кебек, бер дә шикләнмичә, тагы да ертлачлана гына бара иде.

— Сез миңа каршы төркем туплап карадыгыз, әмма бирни дә барып чыкмады, иптәш Туфайлов, барын да белеп торабыз, простаклар юк монда,— диде алдындагы кәгазьләрне әле болай, тегеләй актаргалап.

— Нинди төркем, ачыклавыгызны үтенәм!— диде Туфайлов катыгына. Кинәт тынлык урнашты. Җыелышның һавасы тыгызланды, киеренкелек артты. Фролов торып басты да әйтте:

— Бернинди группа-мазар да юк! Уразаев, чама тойгысын югалтма! Авыз өчен баш җавап бирә!— диде ныклы һәм властьлы итеп. Ул аңа артык шукланган малайны тыйган өлкән ага төсендә карап куйды. Киеренкелек бераз кимегәндәй булды. Уразаев, яктырып елмайган килеш, ике җилкәсен дә биеткәләп, янәсе, минем гаебем юк, сез әйтәсез икән, баш өсте, дигәндәй, начальникка тугрылыгын, аның сүзен закон дип кабул итүен белдерәсе килде шикелле. Шуның белән бергә начальникның аны яратуы белән дә масаеп алганлыгы беленеп калды.

Фроловның Уразаевны кинәт бүлдерүе, сүздән туктатуы Туфайловның күңеленә хуш килде. «Бернинди группа юк!»— дип кистерүе Фроловның һәрчак аек акыллы һәм башлык була белүен күрсәтә иде.

Аның үзара вакланышулардан өстен торуы Туфайловны һәрвакыт сокландыра иде, хәзер тагы шуңа иманы камил булды.

Туфайлов чыгыш ясамады. Җыелышны алып баручы Уразаевны тавышка куйды. Туфайлов уңай якка кул күтәрде. Юк, Уразаевтан курыкмый, шулай да ул хәзер үтми калса, житәкчелек өчен матавык килеп чыгачак иде. Иң элек бу чатаклык Фроловка сугачак. Туфайлов шуңа борчылды һәм уңай якны сайлады. Тавышны санадылар һәм, кирәк бит шулай булырга, уңай якка нәкъ бер тавыш кына артык иде. Бу инде Туфайлов булгандыр. Ничек зиһен житте, дип бу нәрсәгә үзе дә сөенеп куйды. Үзенә хәерхаһ карамаган кешеләргә дә ачу тота белмәве ярдәм иткәндер күрәсең.

* * *

Әнвәр ярты төннәр узгач бил турын нәрсәдер кайнарлаткан сыман тоеп уянып китте. Палата дөм-караңгы. Ул учын ярасы өстенә китерде һәм айнып киткәндәй булды: ярадан кан ага иде. Кулны пешерерлек кайнар иде ул кан һәм учына ябыша иде. Нәрсә бу? Нишләп болай? Кан калын бинт аша тибеп ага. Шул нәрсә Әнвәрне куркытты һәм шәфкать туташын дәшәргә мәжбүр итте. Алар ак җәймәне яра өстенә яптылар һәм учлары белән бастылар. Әмма шул дүрт учның бармак араларыннан кан барыбер тибеп чыга иде. Төнге сәгать өч икән. Врач килеп житкәнче кан һаман агудан туктамады. Әнвәр хәле китүен, күз аллары караңгылана башлавын сизде. Әмма нишли ала ул? Асяның ак халаты да кызылга манылган иде. Ул Әнвәрне шул канлы җәймәләргә төргәләп күтәрде дә операционныйга алып килде. Аны өстәлгә яткыргач, ике шәм яндырып куйды. Ул арада хирург килеп житте. Альбин Васильевич шәфкать туташына ярадан бинтны тизрәк сүтеп алырга кушты. Үзе тизтиз операциягә әзерләнде. Әнвәрнең пульсын минут саен тикшереп торды. Пульс бик тиз начарлана бара иде. Ул бик әкренәйде, кырык-илле тирәсенә барып төште. Һаман түбәнгә таба юнәлгән иде. Нишләргә? Каян килеп чыккан бу афәт? Ни сәбәптән? Аякка ампутацияне Уразаев ясаган, ул хәзер командировкада. Ярый әле, ампутациягә ассистентлык иткән Лия Никифоровна килеп житте. Альбин Васильевич хәзер үк яралыга кан жибәрергә кирәк дигән тәкъдимне хуп күрде һәм хәстәренә кереште. Беренче группа кан кирәк иде. Андый кан аптекада да юк икән.

— Нишлибез?— дип шәфкать туташы тагы Альбин каршына килеп басты.

— Беребезгә кан бирергә туры килә,— диде Лия Никифоровна хирургны әзерләнүдән бүлдермәс өчен.— Кемдә беренче группа кан?

Ася кан тапшырырга, яралыга ярдәм итәргә әзерлеген белгертте. Чөнки «малайка»ның хәле начарлануына бик борчылып, кайгырып торды. Аны Әнвәр ята торган операция өстәле янәшәсендәге биегрәк өстәлгә урнаштырдылар. Беләгендәге кан тамырына шприц энәсе кертеп нечкә кызыл шланг аша тоташтырып шуны Әнвәр беләгендәге энәгә китереп куштылар. Лия Никифоровна сәгатенә карап вакытны билгеләде. Шлангның бер өлеше пыяла иде, бер башында «груша»сы да бар иде. Менә Асяның каны Әнвәрнең кан тамырларына ага башлады. Пыяла көпшәдән кызыл сызык хәрәкәте ачык күренә иде.

Альбин Васильевич, лупалы пыяла куйган калын күзлеген киеп, яраны җентекләп карады, тикшерде. Унжиде кан тамыры һәм артериянең тишелгәнен, җөе ычкынганын белде. Озын энә белән операция эшенә кереште. Кан тамырларын яңабаштан тегеп, томалап чыгарга кирәк иде.

Әнвәрнең кычкырыр көче юк иде, ул йөрәк өзгеч итеп ыңгырашты да ыңгырашты. Элек гомере кыл өстендә торган чакларда аңа бер дә үлем турында уй килгәне булмады. Бу юлы Әнвәргә «үләм, ахрысы», дигән уй килде. Исән аягын, кулларын ничектер тоймый ул. Тәне калтырый да калтырый. Тәндә үлем тартышуы шулай була бугай. Менә аның

өстенә ниндидер авыр караңгылык ишелеп төшә дә аның тынын кыса. Әх, шул күкрәкне баскан нәрсәне умырып алып ташларга! Менә тыны кысылганнан кысыла бара. Шул мизгелдә хирургның яра эченә бик тирәнгә энә кертеп җибәргәнен дә сизгән кебек була ул. Әмма кинәт моңарчы колагына кергән тавышлар тоныкланып калды, ераклашты. Кыл нечкәлеге генә булып ишетелгән тавыш та өзелде, ул берни дә ишетми, кабул итми торган булды.

Әнвәр ике-өч тәүлек һушына килә алмыйча ятты. Адәм баласы үзе дә эт җан икән инде, ярты гәүдәсе кисеп алынган, тире белән сөяктән генә торган тәндә тагы җан әсәре үзен сиздерде, яшәү ритмын югалта башлаган йөрәге, каяндыр көч алып, тигезрәк тибә башлады.

Әнвәр тагы каядыр бүтән дөньяда бик озак булып кайткан кебек хис кичерә иде. Мондагы бар нәрсәне бик сагынып кайткан ул. Бар нәрсә аңа сәер һәм кадерле булып тоела. Менә аның үзен дә биредә сагынып көтеп торганнар шикелле. Врачлар, шәфкать туташлары аның күзләрен ачуына сөенә. Килеп битләреннән, башыннан сөеп китәләр иде. Бар нәрсә яңа, бар нәрсә әйбәт булып тоела аңа.

Ул кабат тамагына ашый башлады. Көндез аны һавага чыгаралар. Ася Әнвәрне калын юрганга ныклап төрә дә, кочагына күтәреп, ишегалдындагы печән җәйгән бер арбага китереп сала. Тын алырлык итеп калдырылган юрган мөешеннән Әнвәр карап ята. Аның күзләренә госпиталь урнашкан йортның арткы стенасы күренә. Стена өстән аска таба әз генә чатнап төшкән. Бомбага тоту галәмәтедер инде. Чыпчыклар чыркылдаганы ишетелеп китә. Якында машина килеп туктаганы, сикереп төшкән аяк тавышлары ыгы-зыгылы тормыш барлыгын искәртәләр. Барча тавышлар, хәрәкәтләр күңелдә шатлык уята. Әлек бер дә алай түгел иде. Бәлки мин дә яшәрмен? Аяксыз көе яшәп булыр микәнни? Шул мәл кинәт йортның сары стенасы яктырып китте. Кояш болытлар арасыннан чыккан икән. Көн җилсез, җылы. Кар беткән шикелле, көннең җылылыгы шуны белгертә. Стенадагы кояш яктысы күбәйгәннән күбәя сыман. Кояш, син дә исән икән, менә мин дә үлмәдем әле. Нигә үлмәдем икән мин? Бу килеш кемгә генә кирәгем булыр икән? Үзем дә интегәм, бүтәннәрне дә интектерәм...

Шулай авыр уйлар эчендә ята торгач, Әнвәр саф һавадан изрәп йоклап китә. Йоклый алсаң, аңардан да рәхәт нәрсә юк. Яралар сызлавы онытылып, кайгылы уйлар баш миен каезламый тора.

Төш җиткәч, Ася яки бүтән берәрсе Әнвәрне кочагына күтәреп палатага алып керә. Әнвәр әле утыра алмый, ярым яткан килеш иң әлек микстурага салып куелган спиртны эчә, аннары шулпасын, боткасын ашап куя. Хәлләр менә шулай бер эзгә төшә башлады.

Ләкин төн килүгә яра аеруча нык сулкылдап авыртырга тотына, нишләргә белмичә газапланасың, гүя тәнне учакка салып яндыралар. Әнвәр ыңгыраша-ыңгыраша шәфкать туташын чакыра. Ася, баланы юаткан төстә, «малайка»ның колагына тукый:

— Беләсеңме, морфий организм өчен бик зарарлы, ул йөрәкне бетерә. Ә иң хәтәре, кеше аңа өйрәнсә, алкоголик шикелле була, сафтан чыга. Син алай үз-үзеңне бетерергә тиеш түгел! Аңлыйсыңмы? Мин бит синең өчен әйтәм...

Асяның кочагы кайнар, тәнне җылыта, әмма кыз кочагында сөрхәнтәй кебек яту уңайсыз. Аның колак яфрагы сестраның күкрәк сәдәфенең катылыгын тоеп тора, тагы да читен булып китә. Ул шыңшудан тәмам туктый һәм Асядан урынына яткыруны үтенә.

Икенче төнне Әнвәрнең хәле тагы да авырая. Ул гел ыңгырашып кына ята. Түзә алмас төскә керә. «У-у-у», дип кычкырып-кычкырып куя. Тагы Ася килеп җитә. Анна Сергеевна аны «малайка» өчен генә бүген дежурга калдырган иде. Әш шунда, башка шәфкать туташы булса, яралының ялынуына түзә алмый, аңа морфий уколы кадау ихтималы бар иде. Ә бу исә һәлакәт булачак. Ул инде өченче төнен морфийсыз үткәрә. Мор-

фийдан бездерү кагыйдәсен бер дә тайпылдырмый үтәргә кирәк. Шунсыз аның бер мәгънәсе дә юк.

Ася «малайка»ны юатуның барча чараларын кулланып бетерде. Менә тагы ах-ух килеп газапланган, күңелгә төшәрлек итеп ыңгырашкан Әнвәр янына килеп утырды. Ул күзгә карап, Асяның кулына ябыша: үләм, морфий, морфий!— ди-ди ялвара, үзенчә ачуланган була. Сестраны кансызлыкта гаепләгән итә, усалланып ала. Ася бер сүз дәшми тыңлап утыра. «Малайка»ның ачуы тынгач, аның кулларын ала да, башын аңа ия төшеп, үзенең иңнәренә куя.

— Йә, мине яратасыңмы?— ди балага эндәшкән рәвештә.— Йәле, мине ике куллап коч әле! Йә, мине ярат әле, ә?— дип аңа йөзен якынайта. Әнвәр ни дип әйтергә, ни эшләргә белмәгәч:

— Яратам, морфий гына бир!— дип ялвара, ыңгыраша.

Ася тагы «малайка»ның кулларын үзенең муенына берәм-берәм күтәреп куя:

— Йә, коч инде, нигә кочмыйсың?— ди эретә торган йомшак тавыш белән.

Әнвәр кызның муеныннан кочмакчы булып омтылыш ясый, ләкин коры сөяк кулларның бер дә җегәре юк икән, алар җансыз таяклар кебек, Асяның иңнәреннән шуып төшәләр. Кыз тагы ул кулларны тартып үзенең биек күкрәкле иңнәренә китереп сала. Әнвәргә бу бер дә сәер тоелмый, ул үзенең бала кебек булып беткәнен аңламый әле, аны аңларлык зиһене юк, барча аңын шул авырту томалап бетергән... Ася гаҗәп киң холыклы, үзенең авырыксынганын бер дә сиздерми. Шулай төннең яраны иң авырттыра торган вакытын уздырып җибәрәләр. Сәгать дүртләрдә күзгә йокы төшкәндәй була. Ася «малайка»ны юрганына әйбәтләп төрә дә, икенче палатага чакыра кергән няня артыннан китә. Авыр яралы бер «малайка» гына түгел бит.

Дүртенче төнне Ася үзенең башыннан кичкән кайбер нәрсәләрне сөйләп утырды.

— Бүген хәлең әйбәтрәк, малайка, сизәсеңме?— диде.— Менә шулай тагы берничә көн түзсәң, батыр буласың, морфий тырнагыннан котыласың. Үзең дә сөенерсең әле,— ди-ди битләрен сөйде.

Әнвәр аның сүзләрен аңлап җиткерми иде, шулай да морфийның начар нәрсә икәне аңына керде. Тик ничек итеп авыртуны «тыңламый» торырга? Әх, үлсә, бер сызлавы да калмас иде. Авырту йөрәккә төшеп сулкылдаган чакларда аның чынлап та үләсе килә.

— Бервакыт мин бик зур бәлагә тардым,— дип сөйләде Ася.— Теге фронтка якын урнашкан госпитальдә. Яралы лейтенант. Тубык сөяге чәрдәкләнгән. Тиешенчә эшкәртеп бәйләдем. Ләкин аягында гангрена башланды. Лейтенант сәнәктән көрәк булган нәрсә, моны миннән күрде. Аягын кискәч, тәмам ерткычка әйләнде. Мине гаепләп язып биргән. Тиешле җиргә. Мине сорау алырга йөртә башладылар. Шунда ампутация ясаган Альбин Васильевич белән замполит Туфайлов органнарга барып минем гаебем юклыкны исбат итә алдылар. Озак йөрде алар. Шул чак курыкканнарым! Үземне-үзем гаепле саный башлагандай булдым. Лейтенант, терелеп чыккач, минем белән дуслашырга маташып карады. Мин үземнең гаебем бар сыман тоя идем, аңа күңелем катса да, йомшак булырга тырыштым. Мин шулай булган саен үзен иркенрәк тота бу. «Әйдә, өйләнешәбез», ди лейтенант бер көнне. «Андый нәрсә белән шаярмыйлар», мин әйтәм. Ышанмыйм, үзенең теләгенә ирешү өчен генә әйткәнне сизәм, артык ачуланмыйм. Аңардан һаман куркам мин. Шул куркуым аңа итагатьле булырга куша. Ә ул кулына ныграк ирек бирә бара, екмакчы була. Мин бирешмим. Ул мине тагы куркытуга күчә. Үзе бик мөһим урында эшли икән. Тылда ничектер минага элеккән булган. Хәзер тагы тылга китәм, ди. Бар нәрсә дә безнең кулда, дип, миңа яный-яный гайрәт чәчә, куркытып кулга төшермәк итә. Мин таш

булдым да каттым. Аңа булган курку катыш хөрмәтем дә бетте. Ләкин үзем тагы да ныграк куркам. Властьлы кеше нәрсә эшләтмәс. Менә ул кызарган борыны, кысылган зур авызы белән миңа таба килә дә нык кулларын билемә батыра, мин, тилгән тырнагыннан ычкынырга тартышкан чеби кебек, ничек кирәк алай кулларын каерып-каерып ташлыйм. Теге хәлдән тая, мин дә арыйм, күлмәкләремне рәтләштерәм. Бәхеткә, шул мәл бүлмәдәшем кайтып керде дә тегене оялтып чыгарып җибәрде. Җитәрме? Инде сәгать дүрт булып киләдер...

Бишенче төнне Әнвәр бик газапланып ятты. Дежурда Таня иде. Кичтән аның хәлен белергә килеп китте дә бүтән күренмәде. Әнвәр бер тамчы да йоклый алмады. Иртәнгә йончылып, ватылып беткән иде. Обходка кергән Анна Сергеевна да дару бирмәде:

— Түз, соңыннан әйбәт булыр,— дип юатты, башыннан, аркасыннан сөйде.

* * *

Төн урталарында Туфайловны штабка чакырып машина килде.

— Ни өчен?

Шофер җилкәсен генә җыерып куйды: белмим.

Соңгы вакытларда Туфайлов үз өстендә болытлар куеруын сизенеп йөри иде. Штабтан килгән кешеләр мөнәсәбәтеннән, Фроловның аңа карата тәкәллеф күрсәтүеннән ниндидер салкынлык беленеп кала торган булды. Нинди гаебем бар икән? Шул латыш егетен араларга йөрүем ошамады микән? Мин эш өчен тырышам бит. Кешеләрчә буласым килә. Кешеләрчә гамәл итәргә мөмкин түгел микәнни? Ингель хосуси милек җәмгыятендә тәрбияләнгән, совет кешеләрен начар дип белә. Мин үземне аңа яхшы яктан күрсәтәсем килә. Үз күзе белән күрсен безнең ниндилекне, белсен. Бу бит иң үтемле сүзләрдән дә үтемлерәк. Биредәге җирле яшьләрне без шулай тәрбияләргә тиеш. Картларга исәп тотып булмый, яшьләрне кулдан ычкындырырга ярамый. Киләчәк яшьләрнеке, яңа азат ителгән халыкларны тәрбияләү бик мөһим бурыч бит!

Ул бүлмәгә кергәндә озын өстәлнең ике ягында лейтенантлар, капитаннар погоннарын ялтыратып тезелеп утыралар иде. Ары баштагы өстәлдә штаб замполиты Оскар Иванович Нужный. Аның калын бите хәстәрле җитдилек белән тулган. Бүтән кешеләрдә дә шундый хәстәрле чырай иде. Туфайловны бер кырыйдагы тумбочка янына утырттылар.

Нужный, торып, көн тәртибен игълан итте.

— Өлкән лейтенант Туфайловның партия мәнфәгатенә каршы килә торган эше турында,— диде һәм докладчыга сүз бирде.

Сөйләүче яшь кенә лейтенант иде. Бик пөхтә киенгән. Якасындагы ак целлулоид аның нурлы йөзенә ниндидер мөлаемлык өсти кебек иде. Алгы сызыкта булмаганлыгы әллә каян сизелеп тора...

Көн тәртибен ишетүгә Туфайлов бик гаҗәпләнеп-аптырап калды. Партиягә зыян китерә торган берни дә эшләмәде бит ул?

Менә сөйләүче гомуми кереш сүздән конкретлыкка күчте.

— Туфайлов безгә дошман элементны яклап йөри,— диде.— Яклау гына түгел, аны коткаруны таләп итә! Шуның белән партия сәясәтенә каршы эш эшли һәм уставны дорфа рәвештә боза. Туфайловка тиешле органнар тарафыннан кисәтү ясалды, әмма ул аны танырга теләмәде. Инстанциягә рапорт язып, Наузиньны чыгаруларын катгый куйды. Шушы хәрәкәте белән идеологик хата ясады һәм үзенең ялгышуларын тирәнәйтте. Шуңа гаҗәпләнергә кала: идея ныклыгы булмаган, аумакай кеше ничек партия җитәкчесе итеп куелган? Бу аянычлы ялгышны төзәтми мөмкин түгел...

Икенче сөйләүче дә шул Ингель мәсьәләсен куертты, Туфайловны белә торган кеше кебегрәк бик кискен фикерләр әйтте. Әмма Туфайлов аны күргәне юк иде шикелле. Бик тә сөйләү осталыгын күрсәтәсе килә

аның, үз сөйләвенә үзе соклана сыман иде. Туфайловның уйлары, торбадан басым белән кудырыла торган су шикелле, ургылып-ургылып башына менде. Анда тынычлану таба алмыйча бөтен тәненә таралды. Ингель хакында ул ялгышты микәнни? Шәһәрдәге диверсиягә катнашы булмагандыр бит? Төгәл генә әйтмиләр. Нидер беләләр, ләкин әйтми калдыралар. Ул яшь кеше, аны бутаулары да бар. Адәм баласына күпме генә кирәк?! Финнарга әсир калган берәүне төрле ысуллар кулланып: «Мин фин шпионы»,— дип язган кәгазьгә кул куйдырганнар. Сөргеннән кайткач сөйләп утырган иде. Ул алымнар әле гамәлдән чыгарылмагандыр?

Фролов башлы, уңган кеше. Туфайлов аңардан күп нәрсәгә өйрәнде. Талантлы житәкче үз янындагы берничә урта кул кешене әйбәт кенә эшләтә ала. Талантлы зат янындагылар, эшлекле булмасалар да, эшлекле күренә. Җитәкченең башы яхшы эшләве бар коллективка житә. Бер талант канаты астына шактый күп урта кул һәм сәләтсезләр тупланып, яхшы гына яшиләр. Туфайлов та аның эшлекле икәнен тиз күреп алды. Ниятләренә каршы килмәде. Тик кайбер кешеләргә карата гына аларның фикерләре аерылды. Әмма моны Туфайлов калкытмады. Алар бер тапкыр да сүзгә килмәделәр. Шул ук вакытта якынлык та булмады. Фролов үзенең бар эшне булдыра торган булуын белә иде. Мөстәкыйль, беркемнең булышуына мохтаҗ түгел. Туфайловка ничек караганын анык кына белеп булмый. Ул аны, мөгаен, шулай кирәк булганга күрә генә түзеп торган булгандыр. Әмма Туфайлов аңа чын күңелдән әйбәт карый иде.

Хәзер Фроловка үзен коткарып калу зарур, дип уйлап куйды Туфайлов. Шуның өчен ул үзен миннән аерып куярга тиеш була. Телиме, теләмиме, бу шулай инде... Биредә акланмыйча чара юк. Аклану исә гаепләнә торган кешене каралту хисабына гына. Үзеңә удар аласың килмәсә, шуны эшләргә мәҗбүр буласың.

Фролов та шул юлдан китте.

— Мин аның сәяси йомшаклыгын сизгән кебек булдым, ләкин тиешле нәтиҗәләр ясый белмәгәнмен,— диде.— Аның бу идеологик ялгышлары очраклы булмаса кирәк. Яралылар, персонал белән якыннан бәйләнешкә кергәндә, Туфайлов тиешле югарылыкта кала алмый иде. Шуны аңлап җиткермәгәнмен. Хәзер генә күзләрем ачылды. Бу сөйләшү бик зур сабак миңа. Билгеле, мондый идея чатаклыклары белән тулган кеше безгә иш була алмый.

Мине үзеннән әйбәт аерып куйды, дип Туфайлов аңа күз төшереп алды. Фроловның йөзенә кайгыртучан төсмер ягылган иде. Юк, аңа мин үпкәли алмыйм, дигән фикер килде Туфайловка. Ул талантлы кеше булганга күрәме? Әллә монда Фроловның аны яклавы мөмкин булмагангамы? Болай әхлакый яктан караганда ул аны якларга тиеш. Килешеп, әйбәт эшләделәр. Туфайлов көчен бизмәнгә сала торганнардан түгел, «мин синең эшлеклелегеңне ошатам», дип әйткәне дә бар. Юк, ул Туфайловның уңай якларын да искә алырга тиеш иде. Әмма кешенең сәяси ялгышын тикшергәндә андый дәлилләр бик көчсез ул. Мин абайламый ялгыш якка кереп киткәнмен, ахрысы. Эш белән артык мавыкканмын. Кешечә булырга тырышканмын. Табигый омтылыш, җан теләгән нәрсә. Ничек тә булса берәүгә игелек итәргә ашкыну. Игелекне дә белеп эшләргә кирәк шул! Мин бит бу хакыйкатьне белә идем, нигә вакытында тыела белмәдем икән?! Бар күңелең белән эшкә омтылып, уңны-сулны күреп җиткермисең. Җан бит яхшылык эшләргә тартыла, шуңа атлыгып кына тора. Бу тойгыдан да рәхәт тойгы юк минем өчен. Менә нәрсә харап иткән икән мине.

Чираттагы сөйләүченең фамилиясен әйткәч, Туфайлов аңа томырылып карады һәм шаккатып калды. Бу аның юлында инде ничәнче мәртәбә очраучы Михневич иде. Теге чакта «контужен булдым» дип хәйләләгән икән. Кара, ничек сөйли. Бу тирәдә күренгәне юк иде, дивизиядә

берәр яшерен эштәдер, мөгаен. Кая кереп оялаган, имансыз! Карьера өчен атасын да кызганмый торган кеше.

— Туфайлов медперсонал җыелышында шундый сүзләр сөйләгән,— диде Михневич һәм кәгазьдән укый башлады.— «Алгы сызыкта кайбер командирларның ялгышы өчен сугышчы актык гомере белән түли, ә врач, шәфкать туташлары ялгышы аркасында яралы гомерен исраф итәргә тиеш түгелдер бит! Алгы сызыкта, ут эчендә каушап калулар кайчак булса да, дәвалаучыларның ялгышырга хаклары юк!» Бу, иптәшләр, ким дигәндә, данлыклы Совет армиясе командирларына яла ягудан башка нәрсә түгел. Монда Туфайлов үзенең эчен ачып биргән, черек үзәген күрсәткән. Шушындый аполитичный кешеләр безнең сафта була алмый.

Мине элек тә белгәнен әйтмәде, дип уйлады Туфайлов. Әйтергә курыкты, ахрысы. Чөнки теге вакытта аның симуляция ясап калганы хәзер көн кебек ачык. Шул нәрсә ачылыр дип шүрләгәндер, мөгаен.

Ул утыргач, Нужный торып басты.

— Барысы да аңлашылды, ачыкланды,— диде.

Туфайловны яхшы белә бит, йә тегеләй, йә болай, дип, бер сүз дә әйтмәде, тавышка куйды. Туфайловка соңгы сүз дә биреп тормады. Әллә аның үз ялгышын танып, шуны кичереп утырганын шәйләдеме? Хәер, сөйләсә дә үзен акларлык бернинди дәлил дә китерә алмый ул. Мин кешеләрчә булырга тырыштым дип әйтү, бу шартларда бик балаларча яңгырар иде. Туфайлов болай ук булыр дип көтмәгән иде, эчендә нииндидер өмете бар иде... Бу хәл миенә бик каты китереп суккан кебек булды һәм ул берни ишетмәскә әйләнде. Сөйләгән кешеләрнең иреннәре кыймылдаганны күрә, сүзләрен аңламый иде. Бу кайгы шул чаклы йотты аны, җыелыш бетүен дә сизми калды.

Бүлмәсенә кайтып, чишенми-нитми, караватына чалкан ауды. Шунда гына үзенең кыйналган кебек бик нык хәлдән тайганлыгын тойды. Әмма уйлары арымаган икән. Баш сөягенә бәрелә-бәрелә мине авырттырып агалар иде. Бары да бетте. Юк, артык баш китәрлек берни дә булмады. Син исән-сау, ә бит алгы сызыкта кешеләр һәлак тә була. Шулай да нинди түбән тәгәрәү, нинди хурлык! Мира ишетсә, ни дияр? Иптәшләр нәрсә әйтерләр? Ни йөз белән хәзер аларга күренергә кирәк? Юк, булмый! Бу түбәнлеккә түзә торган түгел. Аппеляция белән берни булдырып булмас. Мәгънәсе чыкмас.

Ул торып, ишекле-түрле йөрергә тотынды. Тумбочкасыннан баш даруы алып капты. Ничек ул шундый хәлгә төште? Кем ышаныр миңа? Хәер, бик тиз ышанырлар. Кешенең начар ягына бик тиз ышаналар. Менә үземне ышандырырга кирәк. Җанны! Җан кабул итми. Юк, болай булырга тиеш түгел, ди. Ә бит алар хаклы, дип, каршы төшә икенче аваз. Шушындый очрак бүтән берәү белән булса, син үзең дә шулар кебек чыгыш ясар идең. Мондый ялгыш гафу ителмәскә тиеш шул. Гафу ителсә, тәртип какшый башлый. Ә ныклы идея тәртибе булмаса, бер көрәштә дә җиңә алмыйсың. Яхшы күңеллелек эшкә комачау итә торган нәрсә. Тик тойгысыз да яшәү мөмкин түгел. Тойгы кайбер кануннарга каршы бара. Табигатьтән шулай килә ул. Тойгыларны аң-акыл белән җиңәргә кирәк. Мин бит моны бик яхшы белә идем, үзем исә шуны гамәлдә тота белмәгәнмен.

Штабка барганда Михневич очрады. Әллә сагалап торган инде. Туфайлов танымаган төс белән үтеп китә башлаган иде, үзе дәште. Исәнләшми генә сөйләшә башладылар.

— Теге чагында симуляция ясагансың!— диде Туфайлов каты гына. Михневич бу сөйләшүгә әзер шикелле тоелды, бер дә исе китмәде, ул җиңүче кыяфәтендә иде.

— Симуляция түгел, җайлашу,— дип ачы тәкәллефле елмайды.— Кем җайлаша, шул яши, иленә хезмәт итә. Җайлашмасаң, илгә хезмәт итә алмыйсың.

— Сугышка бармас өчен симуляция ясагансың!— дип кул селекте Туфайлов, сүзләренең көче юк дигән төстә. Михневичның түгәрәк тук йөзендә җыерчыклар пәйда булды. Өстенлек, бернинди курыкмау җыерчыклары.

— Җайлашмаган зат бетә, үлә. Табигать законы. Сиңа да җайлашырга киңәш итәм,— диде ул һәм, кинәт кенә борылып, икенче якка китеп барды. Куна тактасы кебек төз, туры аркасы, икесен ике якка ташлабрак атлаган аяклары аның каты күңелле кеше булуын белгертеп калды.

Штабта аңа: «Бу эш белән вакыт уздырып йөрмә, тагы да начаррак ясап куюлары бар,— диделәр.— Иң яхшысы, алгы сызыкка кит»,— дип киңәш бирделәр. Үзенең дә шул хакта башына килде. Ә бит анда үтерүләре бар. Монда әле мин түбән тәгәрәсәм дә исән-имин. Гомер белән чагыштырганда минем хурлык нәрсә ул. Хурлык медаль түгел, күкрәккә такмыйлар. Әмма бу хурлык белән калу да егетлек түгел инде. Ул врач бит, беренче траншеяга ук илтеп куймаслар әле. Санитар пункты, ни әйтсәң дә, тылдарак. Менә шул обстановкада тормышны яңадан башларгамы? Тормышны башлап булырмы соң?

Бер көн уйлап торганнан соң, икеләнүен җиңә алды һәм алгы сызыктагы санбатка җибәрүләрен сорап рапорт язды. Үтенечен шунда ук канәгатьләндерделәр.

Туфайловның юклыгын госпиталь башлыгы: «Бездән аны күчерделәр», дип аңлатты. Шулай да шиккә төштеләр. Бераздан эшнең асылын белеп алдылар. Анна Сергеевна гына курыкмады. Сүз җае чыкканда, безнең элеккеге замполит болай итә иде, дип, Туфайловның уңай сыйфатын әйтеп куя иде.

Шулай да госпитальдә Туфайлов исемен кычкырып әйтүче берәү булды. Ул — Мира. Аның элеккеге хатыны. Эш шунда, әлеге Митава шәһәрендә санитар поезды әзерләнә иде. Поезд яралыларны Казан шәһәренә илтәчәк. Менә шунда врач сыйфатында Мира да китәргә тиеш икән. Шуның өчен бүген Мира белән Рудный алгы сызыкка якын госпитальдән бирегә килгәннәр. Аңлашыла: Мираның вакыты житкән, көмәне зурайган, әмма хәрби киемнән. Каешын буш кына каптырган, портупеяларында гына эленеп тора. Үзе тагы да матурланып киткән кебек, битләрендә бернинди сипкелләр дә, тутлар да юк. Аксыл шома булып тора бите.

Мира госпитальгә аяк басу белән: «Туфайлов кая?»— дип, ишекләрне ачып, кычкырып эзләп йөрде. Аның бәлагә юлыкканын, билгеле ишетмәгән иде.

Фролов Рудныйның танышы иде. Алар хәл-әхвәлләрне сөйләшеп утырган чакта, бүлмәгә чәче-башы тузган Мира килеп керде.

— Туфайловны нишләттегез? Эх сез, сатлыклар!— диде дә үкереп елап җибәрде. Рудный аны бүлмәдән алып чыга башлады. Үзе Фроловка борылып:

— Шундый вакыты инде!— ди-ди гафу үтенде.

Икенче көнне санитар поезды юлга кузгалды. Рудный Мираны бик кадерләп озатты, дулкынланмаска, борчылмаска кушып, кат-кат тукыды.

Госпиталь бетү, икенче профильгә күчү сәбәпле, күп яралыларны шушы поездга төяделәр. Алар арасында Әнвәр дә бар иде.

## Икенче бүлек

### 1

Урман буенда алды белән җиргә кадалып төшкән немец танкысы тора. Аның бер як бронясы снаряд тиеп тишелгән, тәгәрмәч чылбыры

өзгәләнеп беткән. Шунда җыелган солдатлар танкка төбәлгәннәр. Ә рота командиры мөлаем йөзле, таза гына гәүдәле майор Мамак немец танкысының «йомшак» җирләре турында сөйли.

— ПТРдан атып танкка бик күп зыян салырга була,— ди.— Мәсәлән, аның арттагы өченче тәгәрмәче турына төзәп, бензобагына тидерергә, ягъни, яндырырга була. Бу аның иң «йомшак» ноктасы. Аннары алгы бронядагы ярыкларга туры тигереп, күзәтү приборын сафтан чыгарырга, ягъни, сукырайтырга мөмкин.

Майор устав кушканча формаль сөйләми, эшне өстән төшерү өчен түгел, ә сугышчыларга файдасы тисен дип тырыша иде. Ул күп атакаларда катнашкан, шуңа солдатларның да йомшак ягын чамалаган. Танкны күрмәс борын аңардан курку тойгысы бик хәтәр. Шуны бетерергә кирәк.

— Курыкмасаң, танк сине берни дә эшләтә алмый,— диде Мамак житди төстә.— Якын дистанциядә дә ул чаклы куркыныч түгел. Әйтик, син траншеяда, танк утыз-кырык метрларда. Нишли ала ул? Пулемет утыннан окобыңа ышыкланасың. Тик каушама! Курыкма! Танк һаман шуыша. Ашыкмый гына гранатаңны әзерлисең... Егерме метрлап калгач, тәгәрмәч астына томырасың. Бетте! Нәрсәсе булса да зарарланмый калмый. Ә яндыргыч шешә ыргытсаң, бигрәк тә шәп, шундук дөрли башлый. Иң мөһиме, танкны күргәч, югалып калмаска! Әгәр граната ыргытырга өлгерә алмыйсың икән, траншея төбенә ят. Танк траншея аша үтеп киткәч, торасың да артына граната — гөрс! Экипажы һөҗүм итсә, автоматыңны төзә.

— Ә гамәлдә болай ансат булмыйдыр?— дип кайсыдыр сүз кыстырды.

— Әйе, моны колагыгызга нык киртләгез!— диде Мамак бүлдерүчегә мөлаем карап алып.— Һөҗүмдә берни дә ансат булмый. Тик дошманның көчен арттырып күрмә, югалып калма. Моны шуның өчен әйтәм: беркем дә үзен куркак дип санамый, шулай бит? Әмма үзен куркак дип уйламаган кеше кискен бер мизгелдә каушый да кала! Һөҗүм вакытында салкын канлылык бик мөһим! Югалып калып, пуляга күкрәк кую батырлык түгел. Кемнәр танктан курка? Йә? Дәшмисез, димәк, барыгыз да куркасыз! Дөрес! Башта мин дә шулай курка идем. Бервакыт немец танклары һөҗүм иткәндә үземне сынап карамакчы булдым. Ирме мин, ниһаять, түгелме? Үземне кулга алып, танк килгәнен күзәтәм. Әкрен килә. Гранаталарны әзерләп куйдым. Траншея стенасына ябышып торам. Тез буыннары калтырый. Әһә, калтырыйсыңмы, паразит, дим үз-үземә. Үземне үчеклим. Танк килеп житә язганын сизми дә калдым, граңатаны алдым да түш астынарак төбәп ыргыттым. Шартлавын көтәм. Юк! Гранатам ни өчендер шартламады. Ул арада танк якынайган иде инде. Миннән әз генә читтәрәк траншея аша үрмәли теге. Кинәт ыргылдым да артына яндыргыч шешәләр томырдым. Факел кебек ялкын кабынды. Шуннан танк дигән нәрсәдән шүрләвем бетте.

Туфайлов бик бирелеп тыңлый иде, әллә кайдан аның янында замполит пәйда булды. Ул, кул ымы белән Мамакка нидер әйтте дә, Туфайловның җиңеннән тартты. Туфайлов Мамакка карады, теге шунда ук кулы белән «Бар!»— дигән ишарә ясап, сөйләвен дәвам итте.

Замполит Ваһапов артыннан атлаганда Туфайловның башында төрле уйлар чарпаланды. Мамак аны ротаның өлкән санитары итеп билгеләгән иде. Аның карамагына өч кеше дә куйды. Туфайлов аларны яра бәйләргә өйрәткәли башлаган иде. Санитарлык башка төр вазифалардан әйбәтрәк. Мамак моны элеккеге танышлыкка карап та эшләде шикелле. Мамак госпитальдә яткан чакта килеп чыккан бәлане Туфайлов аның өстенә аудармады. Мамак каршында ул ниндидер дәрәҗәдә сыналган кеше иде инде. Туфайловны монда күргәч тә әллә ни гаҗәпләнмәде. Тик бәлагә төшүенә кайгырган төстә сөйләште. «Ни өчен?»— ди-

гән сорау бирмәде. Хәзерге заманда андый сорау бирергә ярамый иде. Сәбәпләр күбрәк бездән тормый. Эзли башласаң, аларның очына чыга торган түгел. Иң акыллысы — хәзерге язмышың хакында гына уйлау һәм шуңа күнү... «Язмыш ирдәүкә, гомер бер тәңкә!»— диде дә, Мамак конкрет бурыч турында күрсәтмәләр бирә башлады. Санбатка дип килгән җирдән Туфайлов һөҗүмгә әзерләнүче шушы ротага эләкте. Боерык. Нишлисең? Боерык тикшерелми.

Ә замполит белән ул беренче сөйләшүдән үк уртак тел тапты. Ничектер фикерләр туры килә иде. Ваһапов бер дә як-ягына каранып сөйләшми. Булганны яра да сала иде. Монда барысы да азау ярганнар җыелган, дип сөйләнде ул хәзер блиндажына Туфайловны алып керешли. Болар, парин, сүзгә ышанмый. Кичергән, күреп белгән нәрсәләрен генә реаль дип саный. Кайсы чиныннан төшерелгән, кайсы әсирлектә булган. Барысы да үзләре теләп фронтка килгәннәр. Гариза биреп. Болай боерыкка карышмый үзләре, Мамакны курку катыш хөрмәт итәләр... Командирдан бераз шүрләп торулары әйбәт.

Блиндажга кереп лампага ут элдергәч, Ваһапов ник чакырганын аңлатырга кереште.

— Ярам ачылды дип йөргән бер солдат килер,— диде.— Яхшылап кара: ярасын бозмаганмы? Нигәдер шикле...

Замполит чыгып, кемгәдер кычкырды һәм бер чытык йөзле, юка гәүдәле солдатны ияртеп кире керде. Солдат монда килүнең максатын белә иде, җир сәкегә арты белән чүмәште дә чолгауларын сүтә башлады. Замполит лампа филтәсен төзәткән булып, астан гына солдатны күзәтә иде.

Яра балтыр итендә икән. Уч төбе хәтле бар, ялкынсынып, җете кызыл булып тора. Пуля яки ярчык тиеп яраланганга охшамый иде. Бу шикне әйтергәме, юкмы? Туфайлов әйтми торырга булды һәм кайда, ничек яраланганын сораштырды. Солдат үзенең оккупацияләнгән авылда качып ятуын һәм шул чакта немец пулясыннан яралануын әйтеп бирде. Ләкин Ваһапов өчен болар гына җитми иде, Туфайлов яраны дару куеп бәйләгән арада бик нык төпченде. Солдатның һәр сүзенә бәйләнеп сораша иде. Шунда ничектер очы-очка ялганмаган нәрсәләр дә күренде шикелле.

Солдат чыгып киткәч, Ваһапов:

— Бозган мөгаен, шайтан! — диде Тафайловка туры текәлеп. Ул аңа да ышанмаган кебек карый иде. Туфайловның баягы шиге солдат сөйләгәннәрдән соң беткәндәй булган иде. Ярасын бозганга охшый, дип, намусына йөк аласы килмәде.

— Яраның ачылуы мөмкин,— диде Туфайлов ышанычлы төстә.

Ваһапов һаман ышанмаган караш белән төбәлеп тора иде. Туфайловның йөзенә аның ышанычсыз каравына үпкәләгән төсмерләр чыкты.

— Һөҗүм алдыннан була торган хәл. Сирәк булса да,— дип аңлатырга кереште Ваһапов. Йөзендә эш өчен кайгыртучанлык төсмере иде.— Бик төгәл исәп: ярасын караганчы, төзәткәнче вакыт үтә. Солдат бу һөҗүмгә барудан котылып тора. Аннары тагы күз күрер...

Туфайлов нидер аңлап җитмәгән төстә замполитка карап:

— Үзләре теләп килгәннәр бит? — диде.

— Төрле кеше бар шул.

Ул шуны да аңламыйсыңмы дигән чырай белән икенче бер солдатны чакырып алып керде. Монысының күзләре эренләп тора иде. Шулай да трахомага охшамаган. Туфайлов аның күзләрен бор сыекчасы белән юып, витаминлы дару җибәрде. Ваһапов аның хәл-әхвәлен, күзенең мондый хәлгә ничек төшүен белеште. Солдатның сөйләвендә хәрәмләшү сизелми кебек иде. Ваһапов һаман ышанып җитмәде. Солдат ишек артында югалуга, Туфайлов йөзенә ышанмавы ныграк чыга барган Ваһаповка аптырап карап алды:



*А. Тимергалина рәсеме.*

— Ашказаны начар эшләүдән дә күзләр авыртуы мөмкин,— дип, витаминнар турында сөйләп китте.

Ваһапов барыбер Туфайловның эшен ошатып бетермәгән иде. Санитар моны үзе дә сизде. Ваһапов хакындагы уңай тәэсиренең хәзер кире якка авышканын тойды. Ләкин аны гаепләмәде. Үз гамәленнән белгәнчә, төрле кеше белән үзеңне төрлечә тотмыйча мөмкин түгел. Мөнәсәбәтләр бик катлаулы.

— Миңа да ышанмыйсыз, ахрысы? — диде Туфайлов уңайсызланып. Ләкин Ваһапов уңайсызланмады, тавышы да кырыс иде.

— Ышанырга мин дурак түгел әле! — диде.— Мин сине сынаганым юк, ничек ышаныйм! Нигә аптырадың? Ышаныч бит бары ышанмау аркылы гына туа! Теге егет ярасын, монысы күзен бозган булырга охшый, ә?

— Бер-ике көннән бинтны чишеп карарбыз.

— Беленерме? Авырганга сабышмаслармы? Әйтәм бит, монда таш астыннан чыккан халык!

— Артык шикләнү шулай да әйбәт түгел!

— Һе, ышанмау — оештыра, ышану — тарката, дигән борынгылар,— диде Ваһапов үзен бик нык хаклы санап. Туфайлов тагы аптырап калды. Башта танышканда үзен ачык күңелле итеп ошаттырган Ваһаповмы соң бу? Замполитның йөзе артык дәрәҗәдә җитди һәм властьлы иде. Ваһапов һаман тәрбияләп чыныктырган, заман нидаларына бик бирелгән һәм шуның аркасында җитәкче урынында тора торган кеше, ахрысы? Кара син аны, принцибы да бар! Бар ачышлар ышанмау аша гына туа ала. Бу сүзләрне кайдадыр ишеткән иде ул, тик мәгънәсен генә төшенмәгән иде. Менә хәзер шуны аңлаган кебек булды.

Ваһапов ни җитте генә кеше түгел! Юкка гына аны замполит итеп куймаганнар бу төрле хәтәр хәл аша узган кешеләргә!

— Ышану — алдану ул, ә без алданмаска тиеш!— диде Ваһапов һәм сүз беткәнне белгертеп урыныннан кузгалды. Алар блиндаждан чыгып папирос кабыздылар, дәшми генә бер-ике суырдылар да аерылдылар.

Туфайлов медикаментлар алыр өчен санчастькә барырга тиеш иде. Шул хакта әйтергә дип, замполит янына керде. Анда монгол йөзле, тәбәнәк буйлы, ләкин калын иңле бер солдат бар иде. Ваһапов, аны чыгарып җибәргәч:

— Әнә Акимов сизгерлек күрсәтеп кергән,— диде әле генә киткән солдатка ымлап. Өстәл сыман җайлаган әрҗәгә терсәкләре белән таянды.— Мин качып яткан авылда Крынкин староста булып торды, ди. Ант итә. Ышанырга да, ышанмаска да белмисең.

— Тикшерсеннәр,— диде Туфайлов шул эш белән шөгыльләнүчеләрне күздә тотып. Әмма Ваһапов аның фикеренә кушылмый иде.

— Һөҗүм алдыннан була торган хәл,— дип сөйләп китте.— Узганында да шулай ике солдат бер-берсенә яла яккан булып баш катырдылар.

— Ул Акимов ниндирәк киек?

— Эт белсен, аның бу эше тегеләрнеке кебек хәйлә генә түгелме? Шуңа охшый! Бәла болар белән!

— Әйткәннәре хак булып чыкса? — диде Туфайлов ни киңәш итәргә белмәгәннән генә.

Ваһапов авыр уфылдады. Йөзенә тирән кайгы төсмерләре чыкты. Ул үзе дә кайчандыр шул «сизгерлек» дигән нәрсә аркасында каза күргән шикелле иде. Кичерешләре әле дә җуелмаган сыман. Бу хакта ачылып берни сөйләшеп булмый, хәерсез. Һәркем үзенекен эчтән генә кичерергә мәҗбүр. Мондый сизгерлек белән җаны риза түгел, әмма үзе шул принципны тормышка ашырырга тиеш! Чөнки яшәр өчен шулай кирәк! Гомер иткәндә ир-атка күпме шундый ихтыяри-мәҗбүри эшләрне

башкарырга туры килми! Икесе дә бер нәрсә турында уйлый, ләкин сөйләшә алмыйлар... Ахырда сүзсез генә кузгалып блиндаждан чыктылар. Туфайлов урман эченә санчастька юнәлде. Ваһапов танк янында барган занятиегә килде. Мамак әле һаман ничек каушап калмаска кирәклек хакында сөйли иде. Чөнки курку дигән нәрсә серле ул. Менә шуның серләрен ачып салырга, аның сер булуын әз генә булса да бетерергә кирәк.

— Танк күренгәч тә үзеңне кулга ал! Сукыр ич ул. Сиңа берни эшли алмый ул! Бервакыт шулай булды: ике солдатның боеприпаслары бетә. Ә каршыга танк ажгыра. Болар куркып калмаган, посып торган да танк өстенә сикереп менгән һәм, шинельләрен салып, тегенең күрү ярыкларын каплаганнар! Бетте! Приклад белән шакып команда бирәләр немецларга. Шулай үзебезнең якка алып кайттылар! Югалып калмау менә нишләтә ул!

— Юләр фрицлар булгандыр алар! — дип кайсыдыр төрттерде.

— Юк, нормаль фрицлар иде! Бик күп мәгълүмат бирделәр,— диде Мамак житди итеп.

— Ә ничек каушамаска соң?

— Каушамау бары үзеңнән тора,— дип дәвам итте Мамак.— Кеше каушап, кайчак үзен-үзе һәлак итә. Үз үлеменә үзе сәбәп була. Миңа бер карт солдат каушамау серен өйрәтте. Син, диде, эчтән генә үзеңә: юк, каушамыйм, курыкмыйм, дип, гел туглап тор! Дога укыган кебек, һаман бер сүзләрне кабатла да кабатла! Авыз тутырып бар көчең белән кабатла! Ә танк бик әкрен шуыша ул. Син ашыкма, исеңне җый, гранатаңа запал куйгач аякларыңны җайла да ыргыт!

— Ә дога укырга ярыймы? — диде кайсыдыр курыккanрак тавыш белән.

— Ярый, ярый, тик каушамагыз гына! — дип елмайган итте майор, ләкин солдатларны аңлаганлыгын белгертеп, житди тонга күчте.

Кичен Ваһапов гаепләне чакыртты.

— Әйе, Акимов безнең якларда булдым, ди,— дип сөйли башлады Крынкин.—Ул Носовода торган, мин Крынкинода. Ара алтмыш чакрым. Безнең—авыл түгел, ә хутор. Берничә йортлы гына. Бутый ул Акимов, койрык болгый. Әллә нинди ачулы кеше, без бер расчетта идек. Тынышып булмады, сержант аерды. Акимов яңа иптәше белән дә сөзешә, яна ярап булмый. Крынкин әзрәк сөйли дә уфтанып тирән сулап ала, замполитка һәм Туфайловка карап куя. Тегеләрнең йөзендә аның бер сүзенә дә ышанмау ачык беленеп тора. Крынкин дулкынлана, ышандыра алмавына үртәлә кебек. Ничек тә ачык сөйләргә тырыша, тәгаенләп тасвирлый. Болар һаман ышанмаган төсләрен үзгәртмиләр. Ваһапов каты гына бәрелеп берничә сорау бирде. Ялганын тотмакчы булды. Крынкин каушап калмады, бар сорауларга да ышанып булырлык итеп җавап кайтарды. Шулардан Крынкинның Акимов белән сүз берләшмәве беленгән кебек булды. Замполит бераз йомшады, ләкин кырыслыгы бетмәде.

— Немецлар килгәндә мин дуңгыз фермасында эшли идем. Хуторда шул ферма гына иде. Дуңгызларның беразын алдылар, үрчем бирә торганнарын калдырдылар. Хауф дигән русча белә торган немецны башлык итеп куйдылар. Чигенәселәрен алдан сиздек тә 120 баш ана дуңгызны урман эченә яшердек. Үзебез дә качтык. Ике айлап шунда яттык. Фашистлар киткәч тә дуңгызларны фермага алып кайттык. Ә безне, немецларга булышкансыз, дип гаепләделәр. Бездә бит хәлне тикшереп аңлау юк, тизрәк гаеп япсарып җәза бирергә булсын!

— Немецларга эшләгәнсез бит!— диде кырыс тавыш белән Ваһапов.

— Сез нишләр идегез, мылтык төзәп торсалар? Шул шартларда! Йөз егерме баш малны саклауны исәпкә дә кертмәделәр. Менә хурлык кайда! Ни өчен Крынкино? Минем әти төзегән хутор ул. Кулак иде, ялчылар тотты. Мал абзарлары салдырды. Ә мин яшь. Комсомолга

язылдым. Активист булдым. Әтиемне, әниемне авылдан сөрүдә катнаштым. Хуторда колхоз төзедек. Ферма зурайды, күп керем бирә иде. Кырыгынчы елны Воронежда авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә катнаштым. Ә эти-әни Себердә, мине каргый-каргый, мохтаҗлыкта дөнья куйганнар...— Крынкинның тамагына төер тыгылды, ике күзеннән бите буйлап яшьләр тәгәри иде.

— Миңа эти-әни каргышы төште! — диде карлыккан тавыш. Ул бүтән сөйли алмады, гаҗизләнеп кулын селтәп куйды, борынын тартты, яшьләре тагы ныграк тама башлады.

— Тыңла,— диде Ваһапов әмер биргәндәй.— Сиңа беркемнең дә каргышы төшмәгән!

— Каргыш түгел, ә язмышың шулай килеп чыккан! — дип өстәде Туфайлов араны йомшартырга итеп.— Үкенмә!

— Әйе, булмаганны! — Ваһаповның йөзе хәерхаһ төс алды.— Булган, беткән!

— Менә монда бетмәгән шул! — диде Крынкин күкрәгенә йодрыгы белән сугып.— Үкенмә, имеш! Үкенмәгән зат фашист була ул! Алар бер әшәкелекләре өчен дә үкенми, чөнки аларда әхлак юк!

— Ә ник кулакка чыгардың соң?

— Яшь чакта кем ялгышмаган, кем шаукымга бирелмәгән!? — Крынкинның тавышы әрнүле чыкты.

Дошман белән бергә-бер килгән чакта сугышчы җанындагы әнә шундый рәнҗү-кимсенүләр хәлиткеч нәрсә булуы мөмкин! Куркып калу гына түгел, күңелгә утырган шундый таш та сугышчының ныклыгын бетерә. Әхлакый ныклык бик зур нәрсә ул! Ә әхлак бары гаделлек белән генә нык була, гаделлек аша чыныга. Шуңа күрә тормышта килеп туган һәр гаделсезлек дошман тегермәненә су кою ул!

Крынкин чыгып киткәч, озак кына сүзсез утырдылар. Ә баш миләре эшләде, уйларына әнә шундый хәзер тел белән әйтеп булмаган, әмма гамәли эшләр нәтиҗәсендә туган фикерләр килде.

Ваһапов кинәт кенә Туфайловка төбәлде:

— Синдә дә рәнҗү бармы? — диде тәкәллефле елмаеп, ихласлыкка этәргәндәй.

— Юк, иптәш замполит...

— Сүз өчен генә сорамыйм.

— Мин дә сүз өчен генә әйтмим. Уйландым, аңладым. Чөнки җәмгыять һәрнәрсәне дә гафу итсә, ул яши алмый, һәлак була!

— Ай-яй, тирәннән син?

— Чыны да шулай аның. Җәмгыять яшәр өчен, чикне бозып чыккан һәр әгъзасына җәза бирергә тиеш! Шунсыз үзе бетә ул!

— Менә егет! — дип куйды Ваһапов сокланып.

— Әллә шул хакта сугышчылар белән берәр әңгәмә уздырасыңмы, ә? Яраны бәйләргә, ярдәм итәргә өйрәткәндә, сүз арасында, ә? Бу бик мөһим! Солдат күңелендә кимсенү ише нәрсә ятмаска тиеш! Ул аны әхлакый яктан какшата!

Ваһапов тәкъдименә Туфайлов каршы килмәде. Килешенгәч, алар төрле нәрсәләр турында сөйләшеп утырдылар. Ваһаповның кешеләрне кайгыртуы Туфайловка ошый иде. Тыштан кырыс күренгән бу кешенең күңеле әйбәт икән. Кырыслыгы да кешеләрне саклаудан килеп чыга. Соң кайбер адәм баласы, әмер бирмәсәң, берни дә эшләми, үзенә кирәкне дә. Баш очыннан пулялар очып торганда, боерык бирмәсәң, окоп та казымый ул. Бу хәл кайберәүләрнең үз гомеренә ваемсыз каравыннан гына түгел, ахрысы, ә гомумән, кеше психологиясе шулай төзелгән: ул үлә башламыйча үләренә ышанмый. Үлә барганда да яшәрмен дип уйлый әле ул!

Акимов мәшәкать кенә тудырды. Ул штабка язып җибәргән булган, ахрысы, тикшерергә җиденче бүлек кешесе килгәч, Мамак тагын аны

чакыртты. Ваһапов та керде. Моннан алда әллә ничә тапкыр сөйләшеп, Акимовның шантаж юлы белән бу һөҗүмнән качарга ниятләгәнен белделәр. Штабтан килгән кеше алдында да командирлар аны кысты: ялганлыйсың, утка керер вакыт житкәч, шүрлисең, бары шул! Бүтәннәр кан койсын, ә син исән кал! Менә шул мәкерле максатың! Крынкинга без ышанабыз, ул андый этләшә торган түгел! Акимов, йә, ир бул! Куркып калдыңмы? Була торган хәл. Ләкин һөҗүмгә кереп бер чирканчык алсаң, бетә ул!

Аны шулай оялтып карадылар. Ул, һаман күзгә чекерәеп кереп, Крынкинны пычратырга кереште.

— Яклаган өчен җавап бирерсез,— дип янады.— Үз сүзләрем өчен башымны фида итәргә әзер,— диде.

— Ярар, һөҗүм вакытында күрсәтерсең,— дип Мамак юмалаган кебек әйтеп куйды. Акимов, үз сүзендә калганлыгын белгертеп, бер сүз эндәшми таш кебек йөз белән басып торды. Штабтан килгән лейтенант башта Акимов, аннан Крынкин белән аерым-аерым сөйләште, аннары:

— Аларны алып китәргә туры килә,— дип белдерде.

— Акимов шуны гына тели дә! — дип ачулана башлады Мамак кызарып.— Аферист ихтыярына буйсынабызмы?! Юк! Беркемне дә җибәрә алмыйм! Сез нәрсә! Безнең операция белән генерал үзе җитәкчелек итә! Боерык үтәлми кала алмый! Шул биеклекне унбиш көннән бирле алып булмый! Фронт тоткарланып тора!

— Минем штрафнойга эләгүемне телисезме? — диде лейтенант, ничек шулай әйтергә телегез бара дигән төстә. Ул власть көченә һәм үзенең һәр чак хаклы, өстен чыгуына күнегеп беткән. Ә монда аның белән бәхәсләшергә җөрьәт итәләр! Әллә ситуация үзгәрдеме, мин сизми калдыммы?

— Һөҗүмгә барып карасагыз зыян итмәс! — дип куйды Мамак.— Анда четерекле хәлгә эләккәннәрне хөкем иткәндә гадел карар чыгарыр өчен ярап куяр иде!

— Болай да брак җибәрмибез!

— Сезнең тырышлык үзегез өчен генә шул! Алгы сызыкка эләкмәс өчен удар эшлисез! — дип Мамак урыныннан торды да янып торган тимер мич янына килде. Аңа бер утын алып өстәде. Кулын җылытып торган итте.— Илгә тугрылыкны ышыкта түгел, менә алгы сызыкта күрсәтәсез!

— Кайда ни таләп итәлә, шуны күрсәтербез!

— Телисезме, хәзер генералга шалтыратам, ул каршы килмәячәк, чын? — дип Мамак мич янынннан лейтенант каршына килеп басты. Теге күзен күтәрергә кыенсынды, аптырап калган иде.

— Шаяртасызмы? — диде ул йомшак елмаеп.

— Йә, хәзер генералга әйтәм, ә? — Мамак үзенең бик житди эш итүен төсе, тавышы белән дә белгертте. Аңарда ниндидер ужәтләнү сизелә иде. Лейтенант үзенең тулы алсу йөзе белән аңа күтәрелеп карады. Юк, Мамак аңардан шүрләми иде. Киресенчә, ул аны үчекләгән кебек итә. Ул бик нык карарлы, кискен текәлеп тора. Чынлап та шалтыратуы бар. Менә шайтан алгыры. Мамакны мондый кеше дип белми иде ул.

— Юк! — дип лейтенант урыныннан торды. Ул үзенең биредә көчсез икәнен тойды. Ә тегендә, тылда, аның алдында майорлар ялагайланып, аның өчен нишләргә белмичә йөриләр.— Алайса, эшне туктатып торырга, ә? — Лейтенантның тавышы килешүчән иде.

Ә Мамак исә һаман шырпылы булып калды.

— Анысы сезнең намуста, лейтенант! — диде астан уя торган итеп. Ләкин лейтенант моны аңламаганга салышып, башын ия төшебрәк ишеккә юнәлде. Янак калкымында: «Минем кулга эләксәң, күрсәтер идем намусны!»— дигән батырлану төсмерләре чагыла иде. Мамак бу лейтенантның тылдагы урыны өчен кемнәр алдында тәлинкә тотканын,

бер генералның үзеннән ун яшькә олы кызына өйләнгәнен белә иде. Энәләре шуңа тырпайган иде. Аннары тылда начальникларга ялагайлану, тәлинкә ялау бик күбәйгән иде. Шул әшәке күренешләрдән туган гаделсезлекләр Мамакның ачуын китерә. Шулар алдында үзенең көчсез булуын тою аңа бик авыр иде...

Төнлә боерык килде: алгы позициягә күчәргә. Бик ашыгыч җыендылар. Командирларның кискен, өзеп әйткән тавышлары ишетелеп торды. Бар сугышчылар кинәт җитдиләнеп китте. Нервылар бик каты тартылды, чак кына кагылдыңмы, өзелеп китәр шикелле иде. Кайсы солдат, киресенчә, эчендәге киеренкелекне бетерер өчен, кызык сүзләр сөйләп, көлгән итте, ләкин аңа беркем дә кушылып көлмәде. Сугышчылар һәрберсе үз уена, үз исәбенә чумган. Һәр кайсы кем беләндер эчтән генә саубуллаша иде. Сау бул, әни, улыңны бүтән күрә алмассың инде. Дуамал улың сине бүтән борчымас. Минем үле хәбәрне алгач, бер утырып еларсың да шуның белән онытырсың. Ник таптың син мине, әни, ник таптың? Минем газапларны, мин күргәннәрне әз генә күз алдыңа китерсәң, әни, бер сәгать эчендә чәчең агарыр иде. Юк, әни, сиңа улың күргән газапларны белергә язмасын. Мин сиңа, әни, гел кайгы-хәсрәт кенә китердем. Бер игелек тә итә алмадым. Игелек итәргә телимен дә, теләгемне тормышка ашыра алмый идем. Бәхил бул, әни, бүтән мине күрмәссең, бәлаләрем белән мин сине бүтән борчымам. Хуш! Каберем өстендә йолдызлар гына җемелдәп янар. Хуш, әни! Мине бары төштә генә күрә алырсың, өндә — бетте, юк инде. Бу соңгы нокта. Әмма, әни, шуны бел, мин бушка гына китмәм, үземә төшкән бурычны үтәп китәрмен. Анысын нык итеп әйтә алам, әни. Минем эчем тулы ачу, әни, берничә фрицның бугазын өзмичә ул ачу бетмәячәк. Бәхил бул...

Ротада шактый укыган, аңлы кешеләр бар. Алар башкачарак саубуллаша. Әйе, бу сират күпере, күпер аша чыгып буламы, юкмы? Әллә ул хакта уйламаска кирәкме! Әйе, тормыш белән үзгә-үз килеп кенә яшәп булмады, ызгышырга туры килде. Дөньяга мин бурычлымы, әллә дөньяның үзенең миңа бирәсе бармы? Юк, барча исәп-хисапны хәтердән кичергәч, шул килеп чыга: мин һаман дөньяга бурычлы икән.

Төнлә килеп траншеяларга һәм траншея чатлыкларына эшләнгән кечкенә блиндажларга урнаштылар. Бу иң алгы сызык. Немецлар калкулык өстеннән өзлексез ракета чөеп, тау итәген яктырта һәм пулеметтан атып тора иде. Төне буе, кара тактага акбур белән сызган кебек, баш очында утлы пулялар чыжлады. Мамак, Ваһапов сугышчыларны тизрәк эшкә куштылар. Траншеяларны тирәнәйтеп казырга кирәк табылды. Моның психологик астары бар иде: эш белән мәшгуль булып, солдат куркынычны азрак тоя, азрак күрә, эченә азрак үткәрә. Иң мөһиме сугышчы курыкмасын, тик торганда аңа шөбһә тизрәк төшә, аны тизрәк били. Бирелдәге хәл сугышчыны артык куркуга салмасын. Алдан курку бик начар, ул рухны сүндерә. Командирларның шундый исәпләре дә бар иде.

Менә таң атты, иренеп кенә яктырды. Немецлар атудан туктады. Сугышчылар бик сагая-сагая гына дошман позициясен күзәтәләр иде. Артык биек булмаган калкулык, бу сөзәк тауч ыкның итәге болар траншеясыннан 300 метрлар алда башлана икән. Калкулыкның ине өч чакрымнан артмас, әмма бер ягы калын урман белән капланган, икенче ягында сазлыкка әйләнергә йөз тоткан күл ялтырый. Шуларны күздән кичереп бетергәч, сугышчыларның дикъкате таучык итәгендә ятучы соры шинельле гәүдәләргә юнәлде. Нишләп болай? Нилектән? Нигә җыймаганнар? Безнекеләрдер ич алар? Сугышчылар янына килеп баскан Ваһапов теләмичә генә аңлатып бирергә мәҗбүр булды: менә бездән алдагы часть өч мәртәбә калкулыкка атакага барган, уңышка ирешә алмаган.

— Ә нигә җыймаганнар?

— Көне-төне атып тора, үзегез дә күрдегез бит, төнлә ул тирәгә барырлык идеме соң?

— Ә без нишләрбез инде?— диде кайсыдыр, һөҗүмгә баруны күз алдында тотып.

Ваһапов уйланып калды: җавап бирергәме, юкмы, әллә берәр шук сүз әйтеп котылыргамы?

— Туры барырга ярамас, уйларга кирәк,— диде дә траншея кырыйларына иңе белән ышкына-ышкына китеп барды.

Солдатлар башларын як-якка чайкап-чайкап алгалыйлар, немецның оборонаны ничек шулай җайлы җиргә ясавына аптырашалар. фронт юлын йозак белән бикләгән кебек иткән бит имансыз, диләр. Бу йозакны ватуы ансат булмас!

— Хәйлә кирәк, хәйлә,— ди икенчесе.— Хәйләсез дөнья файдасыз...

— Нинди хәйлә корып булсын монда, юләр сатма...

— Башны эшләтергә иренмәсәң, табыла ул, һи-и...

— Командирларның башы эшләсә, солдатка җиңел була.

Командирлар баш вата иде. Мамак беркем белән дә сөйләшми, йөзендә уй да уй. Алдында — чакрымлы карта. Карый да читкә этәреп куя һәм башын ике учына алган көе утыра, җилкәләрен селкетеп көрсенә, уфылдый. Аннан тез өстенә шап-шоп суккалый. Ничек тә бер төпле карарга килә алмый йөди кебек иде. Болай итсәң дә — шабаш, тегеләй итсәң дә — шабаш килеп чыга... Нәкъ шул вакытта якында гына каты шартлау бар җирне селкетте, колакны тондырды. Немец ерактан ата торган пушкалардан төшерә иде. Әллә яңа частьлар килгәнне сизенгәнме дип пошынып, Мамак блиндаждан чыкты. Траншеяларның ары башындагы чатта Ваһапов гәүдәсе күренеп калды. Мамак шул якка таба китте. Траншея буйлап барганда тагын бер снаряд йөрәк яргыч ачы сызгырып килде дә позициядән арырак шартлады. Ул туздырган балчык кантарлары һәм ярчыклар шыбыр-шыбыр траншея чокырына сибелде. Сугышчылар блиндажларда иде. Мамак бер ачык ишеккә керде. Берничә солдат автомат түтәсен алларына җайлап, шуңа кәгазь бите куеп, хат язалар иде. Мамак хәл белеште дә икенче блиндажга китте. Немец снарядлары бик якын төшеп шартлыйлар. Икенче блиндажда да хат язучылар күренде. Бер Акимов кына язмый, әллә нинди астыртын уйга өртелгән йөз белән утыра. Мамак тагы да пошынып китте. Нишләп болай хат язучылар бик күп? Хат язу беркемгә дә тыелмаган, билгеле, әмма менә алгы сызыкка килеп урнашып, һөҗүмгә барасы урынны күргәч кенә, солдатларның каләмгә тотынуы уйга калдыра иде. Мамак тиз-тиз атлап Ваһапов блиндажына килеп керде. Кирәк бит, Ваһапов та нидер язып утыра иде. Мамак хаттыр дип белмәде, эш кәгазедер дип уйлады. Әмма Ваһапов хат яза иде. Мамак керүгә кәгазь-каләмен сумкасына салып куйды.

— Нишләп сугышчылар хат язарга кереште әле? Син шайләмәдеңме? — диде Мамак блиндажның чыршы ботаклары җәйгән җир сәкесенә утырып. Ваһапов бераз сәерсенебрәк аңа карады. Ике тәүлек йокламау шунда ук үзен сиздергән, Ваһаповның күз кабаклары шешенкеләнеп тора иде.

— Язсыннар, нәрсәсе ярамый? — Ваһаповның аксыл, җыерчыклары күбәеп киткән чыраенда искитмәү иде.

— Әллә курку эчләренә төшә башлаганмы, дим?

— Ә-ә, ул яктан карыйсың икән...— Ваһапов карашын читкә алып уйланып торды да дәвам итте: — Һөҗүм өчен бигрәк өметсез урын иде. Сугышчылар моны сизәләр, билгеле...

— Йозакны ватмый булмый! — диде Мамак ничектер кайгылы тавыш белән.

— Шулай да бер әмәлен табасы иде? — Ваһаповка да кайгырган төс керде.

— Авыр туплар белән ваттырырга! — дип, Мамак әчке уйга чумган караш белән дәшми генә утыра башлады. Аннары башын калкытты:— Әйдә пушкарьларның кылын тартып карыйк әле? — дип урыныннан кузгалды.

Артиллеристларның күзәтү пункты кыр уртасыннан сузылган траншеяларның уң ягында, урманга барып тоташкан җирдәрәк иде.

Тупчылар командиры караңгы чырайлы, аз сүзле булып чыкты. Ул бик үк сәламәт кеше түгел иде бугай, кай төшедер сызлап, борчый сыман иде. Йөзе дә өнсезрәк иде, шулай да Мамак әйткәннәрне сабыр гына тыңлады. Сүз пушкаларның төгәл ату-атмаулары турында иде. Командир:

— Пушкаларыбыз иске, тузган, төгәллекне гарантияли алмыйм,— диде.

— Чәчелү күпме булыр? — дип кызыксынды Мамак.

— Ун процент бардыр дип уйлыйм.— Командир элемтәчегә ымлап телефон трубкасын сузылып алды да сөйләшә башлады. Үз эшләре буенча сөйләшә иде. Бу инде, сүз шуның белән тәмам, диган ишарә иде. Мамак иркен блиндаж идәнендә таптанып уйланып торды. Ваһаповка карап-карап алды. Алар сүзсез аңлаштылар. Артиллерист аларны төшенеп җиткермәдеме, әллә аңларга теләмәдеме? Кыскасы, якында урнашкан җиңел тупларга өмет аз иде. Ул үзенә тиешлесен генә эшләячәк, шуннан арыга бара алмый. Әмма бирелә тиешле генә җитми.

Командирлар гаубица батареяларына да сугылды. Гаубицалар тулысы белән квадратларга гына ата. Аерым нәрсәне юк итү максаты аларга куелмый да иде. Шулай да Мамак пушкаларының ату сыйфаты белән кызыксынды. Бөтен хикмәт зарядта диделәр алар, заряд коры, әйбәт дарыдан булса, снарядның барып җитмичә шартлавы бик аз очрый. Ә китерелгән зарядлар әйбәт түгел, юеш, шуның өчен өстәп куярга туры киләчәк.

Мамак кич белән полковник янына китте. Гадәттәгечә хәрәкәт итеп бу биеклекне алып булмаячак иде. Кешеләрне генә әрәм итеп бетерербез, бернигә ирешә алмабыз, дип уйлап, дәлилләрен башыннан кичереп барды ул. Авыр туплар зур эш башкарырга тиеш. Ныгытмаларны җиңел туплар гына җимерә алмаячак.

Бүген иртән Ваһапов белән бергә киңәшеп, һәр ягын уйлап, үзләре ышанычлы дип тапкан фикерләре дә бар иде. Ул түбәндәгедән гыйбарәт: иртәнге эңгер-меңгер вакытында артиллерия әзерлеге башларга. Ул озаккарак сузылырга тиеш. Шушы артхәзерлек шау-шуы астында, дошманның күзәтүе томаланып торганда, сиземлеге киметелгәндә безнең рота траншеялардан чыгар, алга ыргылыр, дошманга якынаер. Гадәттә артхәзерлек вакытында немецлар беренче траншеяны ташлап, икенче, өченче параллель траншеяларга күчеп торучан була. Безнең ут тынуга алар тагы беренче траншеяларга кайта. Менә шушы хәлне файдаланып булмасмы? Артхәзерлек башта гадәттәгедән артыграк беренче траншеяны тетсен, немецлар аны ташлап, арткарак күчсеннәр. Шул арада безнең рота немецның беренче траншеясына барып керсен. Полковникка ул шуларны әйтер.

Ваһапов исә блиндажына кайтып, яза башлаган хатын дәвам иттерде. Элеккеге Барановның хатыны — Фира Касыймовна белән языша иде ул. Комбат һәлак булганнан бирле бу эшне үзенең изге бурычы итеп санады. Сугышны кичергән хатынны авыр бәхетсезлегендә ялгыз гына калдыру ярамый иде. Намуска сыймый. Фира Касыймовнага ул ихлас сүзе һәм кайбер льготалар бирә торган кәгазьләр юнәтеп җибәрүе белән булышкалады. Аннары язышу дуслык төсенә керде. Ике яктан да ниндидер өметләргә юл ачты кебек. Һәрхәлдә Ваһапов өчен бу шулайрак була бара иде. Тылда аның кайтып егылыр бер җан иясе юк иде. Ул — детдомда тәрбияләнгән кеше. Белмәссең, Фира Касыймовна белән килешеп кителсә, аның янына кайтырга булыр дигән уй башына еш килә

иде. Сугышның азагы якынлашып килүе бу уйны тагы да көчәйтә. Әнә кичәге сводканы ул сугышчыларга укыды. Белоруссия фронты Варшава шәһәрен алып, һөҗүмне дәвам иттерә. Кайбер танк берләшмәләре Германия чигенә кадәр барып житкәннәр... Ләкин Фира Касыймовна соңгы хатын бераз салкын-битараф язган иде. Вәһаповның шуңа кәефе китте. Әллә бүтән бер кеше тапканмы, дигән шик килде аңа. Моны ничек ачыкларга? Алар бер-берсенә сүз бирешмәгәннәр, ышандыра торган нәрсәләр дә алышмаганнар. Һәркем ирекле. Бары ниндидер өмет талпыныш ясап куйган кебек иде. Әгәр күреп белмәгән булса, Вәһапов Фираның сүрән язуына әллә ни шикләнмәгән дә булыр иде. Һич таушалуны белми торган чибәрлеге белән гүзәл иде ул. Хәзер дә, мөгаен, шулайдыр. Андый чибәрләргә рәхимсез еллар да үзенең эзен тиз генә сала алмый... Кем белә, бәлки берәр кеше дә иялэнгәндер үзенә? Ачыклыйсы килә. Әмма хат язарга этәргән нәрсә ул гына түгел. Бәлки бу соңгы хат булыр? Язмышны белеп буламыни? Менә шулай язарга да кирәк: гаеп итмә инде, Фира Касыймовна, сугышка керергә торабыз; бәлки... Ничектер тылга — шул хатынга күренмәс бер җеп сузасы килә, шул җеп аны зилзилә вакытында үлем тырнагыннан тартып алыр шикелле тоела иде. Вәһапов бу хатның иң соңгы булуы ихтималын һаман сиздереп-сиздереп куйды. Фирадан үзен жәлләтәсе, исендә тоттырасы килә иде.

Туфайлов та, нидер сизенгәндәй, Мирага хат язды. «Үтерерме, исән калдырырмы?» — дигән уй аның миен бик каты интектерә иде. Нишләп болай? Алгы сызыкка беренче эләккән һәр кеше дә шулаймы? Әллә мин генә куян җаным өчен шулай калтырыйммы? Фу, үземә хәтта җирәнгеч! Үз яңагыңа үзең сугып булмый шул! Үтерсә үтерә инде, бер син генәмени? Кешедән кай җирең артык? Үзеңне әллә кемгә куйма!

Ротага медикаментлар китерә килгән бер санинструктор лейтенант Рудныйны белә торган кеше булып чыкты. Ул: «Рудныйның хатыны Казанга кайтып китте»,— диде. Ни өчен икәне аңлашыла иде. Туфайлов төпченмәде. Мираның кайда булуын белү дә аңа чиксез шатлык китергән иде... Кемгәдер эчтәге авыр тойгыларны бушатасы килә. Мира иң якыны, ул аңлар, ичмаса йөрәге бер чәнчеп куяр.

«Минем нинди бәлагә юлыкканымны, бәлки, ишеткәнсеңдер, Мира? — дип язып китте Туфайлов.— Менә шулай. Син булсаң, әлбәттә, мин мондый хәлгә төшмәгән була идем. Юк, ышанып әйтәм. Мин синнән башка чынлап та ялгыз калдым. Миңа нормаль яшәү өчен янымда кемдер һәрчак булырга тиеш, ахрысы. Бәлагә төшкәч шундый фикергә килдем.

Менә мин алгы сызыкта. Яшәү белән үлем сызыгы бу. Тиздән һөҗүм, шул сызык аша атлап алга китәчәкбез, йә үлем, йә яшәү. Икесенең берсе — бүтән юк.

Бер кызык нәрсә: син мине нидер сизенеп ташладың шикелле. Сизенүең дөрескә чыкты бит, Мира? Сизенүләре акылына барып житә торган кешеләр талантлы була. Ә минем кебек хисләре ярты юлда калган һәм акылына берни дә бирми торган кешеләр — уртакул адәмнәр. Әйе, Мира, синдә ниндидер талант бар иде. Син ташлау белән мине уңышсызлыклар эзәрлекли башлады һәм мене шундый хәлгә китереп төшерде. Хәер, хәзер берсе дә мөһим түгел, Мира, барысы да ерунда! Әмма мин төшенке уйларга бирелмим, аны гына аңларлык хәлем бар. Менә соңгы сызык, соңгы нокта, Мира! Хуш, бәхил бул!»

Хатны почтальонга биреп җибәргәч, Туфайлов ник язуына үкенде. Нинди көлке! Ул бит кеше хатынына хат язды. Мәгънәсезрәк эш булырмы? Һәрчак шулай, бер нәрсә эшләгәннән соң гына аңа акыл килә. Мин кем инде аңа хәзер? Ахмак! Бу алгы сызыкта күңел нечкәрәме икән әллә? Юк, һәр кеше үзенең әһәмиятен зурайтыбрак уйлый, аның бер дә эзсез генә югаласы, туфракка әйләнәсе килми шикелле.

Дегет кебек куе караңгы төн. Мамак блиндаж ишеге төбендә басып тора. Бүтәннәр ял итә, ә ул алгы сызыкны күзәтә. Биеклек өстеннән

немецлар ракета чөяләр. Тау буе яп-якты булып тора. Аннан сүнә дә тагы кабына, ракета нуры кара күкне зәп-зәңгәр иттерә.

Биеклеккә ике рота һөҗүмгә барачак. Мамакны күршенең нинди булуы да борчый. Командиры яңа, танышырга өлгерә алмады. Таянып буламы аңа, юкмы?

Мамак ротасы сигез йөз метр араны тотарга тиеш. Менә ике рота тоташкан җир бик сак булуны сорый. Шул «ялгау» нык булсын. Мамак, шул төштә сугышыр өчен яшьләрдән генә торган Пинский взводын билгеләде.

Кинәт җиргә авыр күсәк белән суккан кебек булды, аяк асты калтырап тора башлады. Авыр туплар дошман позициясенә атарга керештеләр. Баш очыннан снарядларның ачы сызгырып үтүләре җанга салкын йөгертә иде. Беренче залптан соң ук немец ракеталарны чөйми башлады. Алда авыр снарядлар шартлаганда чыккан кызыл ялкын гына төн караңгылыгын ертып-ертып алган кебек итә иде. Хәзер анда чын мәхшәр! Җирнең асты өскә килә. Бернинди җан иясе дә калырлык түгел! Әмма теоретик яктан гына бу шулай, ә гамәлдә алай булмый... Моннан алда шундый артхәзерлек ясап, бу биеклеккә әллә ничә тапкыр һөҗүм итеп карадылар, тик ала гына алмадылар.

Кырык минут үтте. Авыр туплар һаман ата. Сугышчылар траншеяларда алга кузгалырга әзерләнә. Туплар дошманның беренче, икенче траншеяларын тетеп алганнан соң утны эчкәрәк күчерә баралар.

Ниһаять, Мамак кулын селтәде. Кинәт ташкын арыгын ычкындыргандай, траншеялардан дәррәү сикереп чыгып алга атлап киттеләр. Сафларда киеренкелек көчәйде. Күкрәкне эчтән ниндидер вак кына энәләр чәнчеп бара кебек. Гүя күлмәк эченә тигәнәк тутырганнар... Җиргә басып атлаганны тоймыйсың шикелле. Тик җирдә яткан үле гәүдәләргә аяк тиеп киткәндә аркалар чымырдый, җанга авыр була.

Биеклек түбәсенә менеп житкәннәрен сизми дә калдылар. Караңгы, шулай да күз тәмам иялөнде инде, якындагы әйберләр шәйләнә. Мамак немецлар мина куярга өлгермәделәр микән, дип курка-курка бара иде. Куйсалар да шартлап беткәннәрдер, чөнки артиллеристлар бу төшләрне дә бик еш снаряд белән тапаганнар, бар җир актарылып ташланган, чокырлардан ачы төтен күтәрелеп ята иде.

Шул арада взвод командирлары үзләренең сугышчыларын ияртеп чокырлар, җимерелгән траншеялар эченә чабып кереп киттеләр. Ваһапов артына борылып карады: офык буе аксыллана башлаган иде. Снарядлар баш очыннан гына хәтәр сызгырып үтеп дошман ныгытмаларын һаман тетә әле. Нишләп автоматлар аткан тавыш ишетелми? Немецлар сыпыртканнармы, әллә тозак оештырганнармы?

Кинәт утлы пулялар һаваны сызып үтте. Каяндыр Щерба взводы киткән тарафтан бик каты кычкырган тавыш колакны ярды. Алда ракета чөелде, бар тирәне яктыртып торды. Шуның артыннан ук немецлар ата башлады. Мамак белән Ваһапов, икесе ике яктан, сугышчыларны барлап, иң элек окоп казырга, аннары атаканы кире кайтарырга әзерләп, оештырып йөрделәр. Немецлар, исләренә килеп, яшеренгән җирләреннән чыкты, каты ут ачтылар. Инде көн якты иде. Үзләренең траншеяларына кире кайтырга дип, берәм-сәрәм алга таба йөгерергә маташтылар. Безнекеләр, чокырларга ипләнеп алып, аларга бик каты ут яудыра иде. Тегеләр бәрелеп-сугылып кире тәгәрәргә мәҗбүр булды. Ләкин кечкенә миномётлардан атып траншея эченә үк мина төшерәләр иде. Сугышчылар шулардан яралана башлады. Бер җимерелми калган блиндаж табып, Туфайлов үзенең ярдәмчеләре белән яралыларны шунда ташыды, бәйләде, карады. Авырларына көчле дарулар биреп, хәлләрен җиңеләйтә иде.

Щерба взводы түш белән шуышып алга китте. Немец якынлыкны өнәми иде. Безнең якынаюны сизсә, шунда ук чигенү ягына борыла. Алга шуышсаң, ут секторыннан да чыгасың. Щерба шуңа исәп тотты.

Бу хакта Мамак аларга күп тукыган иде. Менә хәзер сынап карарга булыр. Шуышканда снаряд чокырлары ярдәм итә. Шунда башыңны яшереп бераз хәл җыеп аласың. Тырыша торгач, Щерба егетләре икенче траншеяга якынлаштылар һәм чокырлардан торып бик каты пуля яңгыры сиптерделәр. Барысында да трофей — кул пулеметы. Аның лентасын солдатлар иңнәренә аркылы-торкылы итеп бәйләгәннәр иде. Аргы траншеяда ике мөгезле каскалар әрле-бирле чабышырга тотынды. Утның якынлыгы да бик нык шүрләтте, ахрысы. Сугышчылар кинәт: «Ура-а-а!» дип кычкырып куйдылар. Бу психологик атака иде. Немецлар чәбәләнде, берничәсенең буйга казылган траншея буенча артка йөгергәне күзгә чалынды. Ләкин бронекалфактан пулемет хәтәр сиптерә иде. Менә шул юлны кисте дә куйды. Тагы бер ыргым ясап булмады, авызын корт чаккыры! Кул сузымында гына траншея, ләкин якын барып булмый. Щерба егетләре чокырларга сыенды. Нишләргә?

Вәһапов та алар артыннан үрмәләгән, бер җимерек блиндажга ышыкланып егетләрне күзәтә иде. Егетләр аны күреп алды. Щерба үрмәләп килеп җитте. Бите-йөзе корымга буялып беткән, танырлык та түгел. Тере күзләре генә елтырый, сөйләшкәндә ак теше ялтырып күренеп китә. Ул арада Турганов дигән кечерәк буйлы, җиңел сөякле солдат мышкылдап килеп җитте. Бераз уңдарак буш траншеяга чыга торган итеп эшләнгән блиндажга юлыккан икән, замполитны шунда чакыра иде. Вәһапов блиндаж табылуга бик сөенде. Арткарак шуышып, шуңа керделәр. Нишләргә? Бронекалфакны болай гына алып булмаячак. ПТРчылар арттарак. Ничек алар янына барырга? Баш күтәрергә дә ирек бирми. Җитмәсә, снайперлар эшкә тотынды. Безнекеләр арасында да оптикалы ике сугышчы бар иде. Вәһапов шуларга эш кушты. Пулеметның көпшәсенә төбәп атыгыз, диде. Менә алар яшеренеп ята башладылар. Ләкин пулемет тынарга уйламый да!

Блиндаж зур, ике бүлемле иде. Эчтәге бүлемдә өстәл, карасалар, телефон аппараты түгелме соң? Турганов шырпы сызды. Бер кәгазь кисәге яндырып, яктыртып торды. Блиндаж нык икән. Караңгыда аппарат өстендәге трубканы алып, колагына китерде. Юк, эшләми икән. Тышта атышлар тагы да көчәйде. Турганов торып, автоматын рәтләде дә, ишеккә атлады. Немецлар минометтан аталар иде. Бер сугышчы, яраланып, кычкыра башлады. Турганов тизрәк аны блиндажга өстерәп алып керде, ярасын бәйләргә булышты.

Вәһапов, траншея стенасына ышыкланып, биноклен күзенә китерде. Йөз илле метрда гына бронекалфак тоташ ут бөрки иде. Турыдан алып булмаячак. Ә җимермичә алга бер адым китә алмыйсың.

Уң якта атышлар көчәйгән шикелле булды. Нәрсә бу? Анда атакага баралармы? Шул очрактан файдаланып булмасмы? Читләтеп барып, калфакка граната ташлый алсаң, шәп булыр иде. Вәһапов биноклен күзеннән алмый, тирә-юньне күзәтте. Уң яктагы рота чыннан да, атакага күтәрелеп карады. Тик көчле ут стенасына бәрелеп, чокырларга төшәргә мәҗбүр булды. Алда да шул бронекалфаклар юлны бүлә иде. Ул Тургановны чакырып китерде.

— Мә, күзәт әле, кай төштән шул калфакка якын килеп булыр?— дип әйтеп, бинокльне аңа тоттырды. Турганов бик теләмичә генә, бик шикләнеп караган төстә, бинокльне алып күзенә китерде. Вәһапов аңа ориентирны төгәл юнәлдерү өчен, үзе күзәткән чокырларны, траншея өзекләрен әйтеп торды. Ниһаять, икесе бер тарафны билгеләгән кебек иттеләр. Вәһапов биноклен алып әйтте:

— Әйдә, Турганов, гранаталар ал да пластунски шуышып бар! Йөз егерме адым! Юлны беләсең!

Тургановның йөзе кинәт күмгәкләнеп китте.

— Үлемгә җибәрәсез, котыласыгыз киләме?!— диде тыңкыш тигезсез тавыш белән.— Йөз егерме адымда йөз егерме тапкыр үтерүләре мөмкин.

— Турганов, намусың бармы синең? — диде Ваһапов үзен кулга алып.

— Юк, иптәш замполит, намусны таптадылар, бетерделәр!— диде Турганов кинәт юашланып калып һәм кысылган әрнүле тавыш белән өстәде: — Җаныма төкерделәр.

— Әмерне тыңламагач, ник бирегә килдең? — Ваһапов тавышын күтәрә төшеп әйтте. Әйе, Мамак хаклы, командирдан куркырга да тиешләр. Тагы шул, биредә сугышчыга җәза биреп тә, янап та булмый. Нишләтә аласың син аны? Кулга алып, тылга җибәрергәме? Һич мөмкин эш түгел. Турганов, шушы ситуацияне бик яхшы исәпкә алып, тыңлаудан баш тарта. Кеше үзенең бурычы белән бергә-бер килгәндә намус кирәк шул! Биредә әмер власте бетә, намус кына кала. Намус булмаса...

— Мин сине егет дип торам, бичара куркак икәнсең! — диде Ваһапов һәм җирәнгәндәй төкереп куйды.

— Мин куркудан түгел, реаль хәлдән чыгып! Юкка әрәм буласы килми! Иптәш замполит, кич булганны көтик! — дип Турганов тел чарлады.

Ваһапов үзе барырга әзерләнә башлады. Документларын ординарецына бирде. Гранаталар салынган противогаз сумкасын иңенә асты. Ул Тургановтан әле дә: «Тукта, иптәш замполит, үзем барам»,— дигән сүз көтте. Ләкин тегесе аның карашы белән очрашмаска тырыша иде. Ординарец — өлкәнрәк яшьтәге Егорыч иде, борчылып, әле Тургановка, әле бүтән сугышчыларга карады.

— Ничек була инде бу, ә? Күз күрмәгәнне, ә? Кайнарлану юньлегә илтми! Неужели командирны җибәрәсез! — ди-ди бөтерелде дә бөтерелде. Ваһапов иңендәге погоннарны да алып Егорычка сузды. Ул-бу була калса, фриц сөенмәсен!

Ваһапов ниндидер җәнлек житезлеге белән бруствержга үрмәләп менде һәм шуышып снаряд чокырына төшеп китте, күздән югалды. Турганов хәлнең мондый борылыш алуын көтмәгән иде, нишләргә белмичә таптана башлады. Күңелендә нидер сәгать теле кебек тирбәлә, эчен кыра иде. Үз хәлен үлчәп газапланганы йөзенә чыкты. Ул үзен разведкадагы кебек тотты. Алай ярамый. Ниндидер мизгелдә дөрес карар тапкандай булды ул һәм Ваһапов артыннан үрмәләп китте. Егорыч нигәдер: «Тукта! Тукта!» дип кычкырды, Турганов аны ишетми иде инде.

Ә Мамак участогында немецлар психик атака ясады. Ул болай: үзләренең яшерен казыган юлларыннан безнекеләргә бик якын ук киләләр дә каршыда гына кинәт калкып чыгалар. Моны һич көтмәгән сугышчылар каушап калырга тиешләр. Тик немецларның болай мөгез чыгаруы барып чыкмады. Мамак моны алдан күреп барча сугышчыларны кисәтеп, дәртләндереп траншеяда кычкырып йөрде. Немецлар күтәрелүгә, барча пулеметлардан атарга команда бирде. Ут шундый дәррәү булды, немецлар маңгайлары белән стенага килеп бәрелгән кебек кинәт артка мәтәлделәр. Әмма моның белән килешәселәре килмичә, тагы күтәрелеп карадылар. Тагы көчле ут яңгырына эләгеп тибәрелделәр. Әле болай, әле тегеләй бәргәләнеп карадылар, этен-сугын килеп, артка йөгерделәр. Мамак шушы минутта Пинский взводына атакага барырга әмер бирде. Немецлар чигенгәндә үкчәләренә баса-баса бару иң җайлы очрак. Егетләр бик актив күтәрелеп ут сибә-сибә алга ыргылды. Өч йөз метрлар үткәч, каршыда гына бронекалфак җанланды, шуннан пулемет атарга тотынды. Егетләр җиргә ятарга мәҗбүр булды. Ләкин ачык төштә снайпер чүки башлады. Бүтән чара калмагач, җимерелгән траншея чокырына төштеләр. Аның бер башында блиндажга тап булдылар. Пинский яралыларны шунда ташырга боерды. Акимовның бер кулы яраланган икән. Бармаклары туракланып беткән кебек иде. Ул аны башта бинт белән бәйләде, аның өстеннән ыштыр өчен бирелә торган яңа бумази ертышы белән чорнады.

Пинский сугышчылары шактый алга киткән булган, хәзер алар

нейтраль зонада калганлыкларын чамалады. Артка да чигенеп булмый, алга да барырга мөмкин түгел иде. Мамак, атака оештырып, йолып ала алса гына инде. Моның өчен вакыт кирәк, көчне бер йодрыкка тупларга кирәк... Мамак боларның бүленеп калганын яхшы аңлады һәм бөтен коралларны файдаланды. Менә кече минометлар ут ачты. Ләкин алар бронекалфакны җимертә алмыйлар шул! ПТРларны эшкә җиктеләр. Алар бронекалфактагы пулеметларга төзәп атты. Чынлап та пулемет тончыгып калды шикелле. Икенчесенә күчтеләр. Анысы атудан туктаганда бая тончыкканы терелде. Шайтан алгыры, нинди хикмәт бу?! Пулеметларны алыштырып куяларммы? Әллә кешесе сафтан чыгып, пулеметка берни булмыймы? Юк, пулеметка зыян килә булырга тиеш... Әле бер, әле икенче бронекалфакка аталар, болай тигән дә кебек була, пулемет тынып кала, ләкин сугышчылар брустверга күтәрелгәнен күреп алалар да тагы ут сиптерергә керешәләр. Шулай итеп вакыт уза, инде патроннар да бетте диярлек.

Пинский дүрт күз белән ярдәм көтте. Взводта бары биш-алты кеше калган иде. Алар да яраланып бетте. Кечкенә мина траншея эченә туры төшеп харап итә иде. Барысының да аяклары эштән чыкты. Кайсыларының хәле бик авыр, эчләренә ярчык кергән иде. Менә бер мәл немецларның: «Рус, сдавайс»!, «Хенде хох!» дигән тавышлары ишетелде. Пинский барча автоматларны ишек төбенә җыйды. Берсен алып, шуышып чыкты да пулясы беткәнче атты. Аннан икенче автоматка тотынды.

— Тере килеш алмакчы, канечкечләр! Тотыгыз менә! Кая гранаталар! — дип кычкырды ул ачыргаланып.

— Нишлисең граната белән?

— Үзебезне-үзебез шартлатабыз! Юк, ала алмассын! — дип Пинский гранаталар җыя башлады.

— Уйнама, сержант! — дип куйды бер яралы.

— Безне коткарачаклар! — диде икенчесе ыңгырашып.

— Менә кич кенә булсын!

— Кичкә чаклы, бездән юеш урын гына калачак! — диде Акимов.

Пинский гранаталарны әзерли иде.

— Әнә үзең шартла, бик кызсаң,— диде яралы.

— Яралыларны атмаска тиешләр!

— Әһә, куян, бирелергә әзерләндеңме?! — дип кычкырды Пинский бик каты янап. Эченә ярчык тигән яралының хәле мөшкел иде. Ул:

— Зинһар мине атыгыз, зинһар газапламагыз! У-у-у,— дип уфылдый-уфылдый ялына иде.— Пинский, зинһар бер пуля жәлләмә, туган!! Мин барыбер беткән инде, газапланам гына! Ат, хәлемә кер, зинһар!

Ләкин аның сүзен ишетмиләр дә. Барысы да үзе хакында уйлый, күрәсең.

— Сержант, безне шартлатма! — дип ялвара башлады яралылар. Акимов та аларга кушылды.

— Яралыларны шартлатырга хакың юк! — диде ачы итеп һәм берике запалны алып тышка ыргытты. Шуны гына көткән кебек, Пинский кинәт котырып китте.

— Бирелергә әзерләндеңме, хәшәрәт! Барып чыкмас, җавап бирерсең! Дезертир! Эчеңдә хыянәтче утырган синең! — дип Пинский автоматын Акимовка төби иде. Акимов курка калды, бу котырган атып та егар, дип уйлады һәм үрмәләп ишектән чыга башлады. Пинский аның тышка таба шуышуын качу дип кенә кабул итте. Артыннан чыкты.

— Артка борыл! Хыянәтче! Качып котыла алмассың! — диде кайнар сулап. Акимов янына ук килеп яткан да янап кычкыра гына. Акимов нишләргә белми, Пинскийның болай булганын күргәне юк иде. Әмма исен җыя башлады.

— Юләр! — диде ачынып.— Нинди хыянәт эшләдем? Юләр!

— Ник иптәшләреңне ташлап, бирелергә барасың? Кире борыл!— Пинский Акимовның җилкәсенә автомат көпшәсе белән төртkәләде. Теге-

се аңа борылып төкерде дә блиндаж кырыендагы чокырга шуышып китте. Шуңа барып ышыкланды. Пинский аның артыннан килеп: — Трибуналга китәрсең, кайт! — диде үзен тыя алмыйча. Акимов аны тыңламый, ышыграк урын чамалап, тагын шунда үрмәли башлаган иде, Пинский тегенең табанына атып җибәрде. Кача дип белгәннән шулай эшләде ул. Акимов моны ук көтмәгән иде, каушап калды. Пинский, аны җибәрмәскә теләгәндәй, Акимов янына ук килеп ятты да, зур эш башкарган кеше кебек:

— Менә шулай,— диде.— Һәр дезертир белән шулай булыр! — Аның борын тишекләре киерелгән, күзләре акайган иде. Акимов яралы аягына тотынды, карганды:

— Юләр! Орден алмакчы буласыңмы? — аягы авыртудан аны кинәт ачу уты чолгап алды, калтыранган кулы куенындагы пистолетны тартып чыгарды. Шул мәл якында гына мина шартлады. Пинскийның башы бер якка бөгелеп төшкәч кенә, Акимов ни булганын шәйләде.

Акимов бик кыйналып үскән кеше иде. Башта аны әтисе кыйнады, колхозда эшли башлагач та төрле бәлаләргә юлыкты. Аны үзе җигеп йөри торган атларга дип бер-ике кило солы кибәге алган өчен утырттылар. Төрмәдә гел типкәләп кенә йөртәләр иде. Котылгач та ул инде яманатлы иде, аңа ышанмыйча, түбәнсетеп карадылар...

Шул арада немецлар якын ук килеп блиндажга граната ыргыттылар. Каты шартлауны Акимов ачык ишетте, андагылар берсе дә исән калмагандыр. Ул үзенең нидер сизенгән кебек аннан шуып чыгуына канәгать булган хис кичерде. Ләкин аягы коточкыч кисеп авырта иде. Пинский сөяккә эләктергән дип уйлады, ботинкасын салырга кереште.

Ваһапов ату секторына эләкмәс өчен уңга каерып хәрәкәт итте. Бер чокырга шуып төште, анысыннан чыгып икенчесенә ашыкты. Башны әз генә дә күтәреп булмый иде. Шактый ара үтте ул. Бронекалфак исә уйлаганнан ераграк булып чыкты. Артка юл юк иде, һаман үрмәләде дә шуышты. Бронекалфактагы пулемет бар эшне тоткарлый, тамак төбеннән кыскан кебек итә иде. Менә бер алтмыш адымнар гына калды, менә бу тирән чокырдан чыгып тагы бер-ике ыргым ясый алса, гранаталарны ыргытырга мөмкин булачак. Башта атарга җайлы саплы, җиңелрәк гранаталарны җибәрергә кирәк. Аларны ераккарак тондырып булыр. Утыз метрга. Бәлки утыз биш метрга. Шуннан арттырып булмас шул.

Нәкъ шул чакта чокырга төшеп бер кечкенә мина шартлады. Икенче минутта Ваһапов, табаны юешләнүен тойды, яраланганын аңлады. Ике аягының да табаннары юешләнүе аның котын алды. Ул бер аягын үзенә таба тарткан иде, бик каты авырттырды, күзләреннән очкыннар чәчрәде. Итек эче кан белән тула башлады. Ничек бәйләргә? Итекне салып булырлык түгел! Егорыч ничек җибәрмәскә итте, тәҗрибәле кеше, нидер сизенгән ул. Нинди мәгънәсез килеп чыкты! Шулай эчтән карганып чокыр кырыенда ятканда, нидер кыштырдаганга борылып караса, Турганов үрмәләп килеп ята. Ваһапов ачуланырга да, сөенергә дә белмәде. Йөзе яман чытылган, кыйшайган. Күнитек башлары умырылгаланган иде. Турганов шунда ук хәлне белеп алды.

— Иптәш замполит, яраландыгызмыни? — диде, үзенең гаебен йоларга тырышып.

Ваһапов аяк табаннарына ымлады. Итекләрне салып булырлык түгел, дип, кулы белән аңлатты. Турганов, бик япьтәшләнеп аның аяклары кырына ятты да үткен пәкесе белән итек башларын ярып ташлады. Яра үтәли чыкмаган кебек иде. Итекләрдән бушатып, яраларны тиз-тиз бәйләде. Аннары гранаталар салган сумканы алды.

Ул инде нәрсә эшләргә кирәген белә иде. Алдагы чокырга таба шуышып китте. Ваһаповның аңа булган ачулары беткән кебек булды.

Бераздан бер-бер артлы ике шартлау тавышы ишетелде. Пулемет атмый башлады. Хәзер нәкъ атакага бара торган мизгел! Әх, бу Щерба

форсатны кулдан ычкындыра бит! Нәрсә булды икән? Авызын корт чаккыры! Нәкъ шул чакта топ-топ килгән аяк тавышлары җанга җылы бирде. Ваһапов башын күтәрә төшеп күзәтте. Менә Щерба егетләренең алга таба килә башлаганнары күренде. Ләкин сулдарак икенче пулемет бар икән! Бетерде! Егетләр җиргә аудылар. Нишләргә? Әмма берничә минуттан: «Ура!»— дип ялгыз кычкырган тавыш ишетелде. Ваһапов тиз генә башын күтәрде һәм Тургановның граната ыргытканын күреп алды. Аннары үзе калкынып алга ыргылды. Ләкин пулемет телгә килде. Турганов кинәт сөртенгән кебек булды, куллары җәелеп китте, шулай да ул һаман алга атлый иде. Шулай дүрт-биш адым атлады да пулемет тамагы төбенә егылды. Пулемет шып булды. Гәүдәсе аша ата алмый иде. Щербаныкылар дәррәү кузгалдылар һәм траншеяга бәреп керделәр. Траншея озын иде. Блиндажлар да шактый күп икән. Бу дошман оборонасының үзәге булган шикелле күренә иде. Менә сиңа Турганов, дип уйлады Ваһапов, һәм, хәле китеп, аңын җуйды.

Караңгы төшеп килгәндә сул флангтан Мамак егетләре дә немецларга психик атака ясады. Моны, ахры, бер дә көтмәгәннәр, немецлар, траншеяларын ташлап, ничек кирәк алай сыпыртырга тотындылар. Шулай итеп, уң һәм сул фланглар тигезләште. Өченче траншея яулап алынды. Хәзер километр ярым тирәнлектәге дошман оборонасы безнең якта иде. Көч туплярлык, ныгырлык плацдарм бар дигән сүз. Немецның бу чигенү белән һич килешмәячәге билгеле иде. Күз бәйләнүгә, яңа көчләр килә башлады. Танклар, орудиеләр куярга әзер урын бар иде.

Старшина килеп, үзенең вазифасын үтәргә кереште. Ашамлыклар мул иде. Чөнки рота шактый сирәкләнгән инде. Нарком күчтәнәче шуңа күрә икешәр өлеш эләкте. Бераздан өстәмә солдатлар килде. Мамак шуларны тиешле җирләргә урнаштырып төне буе утырып та тора алмады. Ул танкистларга җайлы урынны күрсәтеп бирде. Танкны җиргә күмеп куярга тиешләр. Шунсыз монда бер минут та исән кала алмыйсың.

Мамак ярты төннәр узгач кына старшина билгәгән блиндажга кайтты. Телефон урнаштырганнар икән инде. Әз генә капкаларга да өлгермәде, зуммер тавышы сискәндерде. Телефонда Үзе иде. Ул Мамакны атыюлы белән сүгәргә тотынды. Боерык үтәлмәде, алга китеш булмады диярлек, дип, авызны да ачырмый иде. Ә Мамак, киресенчә, бүген җай булды, шактый уңышка ирештек, дигән фикердә иде. «Үзе» мондагы хәлне белми һәм бик кызыксынмый да кебек. Ул күбрәк телефон аша алга куалый. Болай ярыйсы мужик, әмма өстән кыздырсалар, бик кырыслана торган гадәте бар. Шуны эшли алмадың, моны үтәмәдең дип, менә хәзер дә гаепләргә тотынды. Үзен шактый пешергәннәр, ахрысы. Бер гаепне дә үз өстенә алырга теләми. Мамакның тәмам ачуы кайнады.

— Нишләп,— диде,— без бер-беребезне гаепләп лаф орырга гына торабыз? Бер-беребезне гаепләп мәсьәлә хәл ителми бит! Эшләргә кирәк, нәрсәдер булдырырга, табарга, алга этәрергә! Начальникларга ярарга тырышу үз йөгеңне бүтәннәр иненә аудару ул!

Шулай дигәч, «Үзе» йомшарды һәм сөйләшүне солых белән тәмамларга ашыкты. Шундый кеше иде инде ул. Каты бәрелгәндә, үзеннән каты итеп сөйләшергә кирәк. Йомшак якларына ишарә итәргә. Мамак аның йомшак якларын әйбәт белә иде.

Икенче көнне иртән безнең самолетлар немец оборонасының эчкәре өлешен бомбага тоттылар. Авыр туплар да шулай тылны тетте, якынга ата алмыйлар иде. Үзебезнекеләргә тияр дип курыктылар. Дошманның алгы сызыгына зыян булмады диярлек. Шулай да ату тынгач безнең пехота атакага алга ыргылды. Тик ун-унбиш адым киткәч тә җиргә аварга мәҗбүр булдылар. Дошман уты бик көчле. Атака башлау ялгыш адым иде. Немецның күтәрелүен көтәргә кирәк иде. Мамак шулай эшләргә исәпләде, ләкин бирелгән әмергә каршы килеп булмый. Фланглардан артта калу куркынычы да яный иде. Әйе, өстәгеләр бер төрле,

эшне конкрет башкаручылар икенче төрлерәк уйлый шул. Бу мәңгелек каршылык, ахрысы.

Әллә кайдан гына немец танклары пәйда була башлады. Болайга шуышалар, ә артларында мөгезле каскалар эрле-бирле чуала.

Танклар якынайгач, безнең ПТРлар атарга кереште. Кырык бишле орудиеләр дә ут ачты. Безнең берничә җиргә күмелеп яшеренгән танклар да үзләрен күрсәтергә тотынды. Дошманның бер танкы кинәт аксыл төтенгә чорналды, аннан икенчесе, өченчесе...

Ләкин уртадагы икесе берни булмаган кебек килә иде. Танкларны уздырырга да арттан килүче пехотаны ут белән кисәргә әмер булды. Бу самоходкаларның бронясы калын, пушка тишә ала торган түгел. Мамак танкка каршы граната белән сугышчы җибәрергә кирәк дип тапты. Ләкин кемне? Үткен зиһенле, еландай шома хәрәкәтләнүче булсын. Мамак траншеяда кул пулеметыннан атып торган ординарецы Чапбаев янына килде. Аңа күрсәтмәләр бирә башлады. Чапбаев барын да аңлады. Йөзе кинәт агарып китте. Противогаз сумкасына гранаталар салды, куллары калтырый иде. Аска караган килеш җыенды. Ул моны көтмәгән иде, ахрысы. Мамак та, аның җәймәдәй агарган йөзен күреп, әллә нишләп китте. Үзенең шәхси эшенә җибәргәндә була торган уңайсызлык тойды. Ниндидер чын җәлләү хисе күңеленә тулды. Туфайлов аның хакында ничектер кызганып сөйләгән иде. Бик авыр, гаять фәкыйрь гаиләдә үскәнен әйткәне хәтеренә килде. Чапбаев, аның ягына башын да бормыйча, рәнҗегән кыяфәттә үрмәләп алга таба шуышты, зур-зур кантарлар арасында күздән күмелде.

Мамак стереотруба окулярына ябышты. Чапбаевны, танкларны күзәтә иде. Чапбаев ату секторыннан читкәрәк чыгып үрмәләде. Чокырга төшкәч, шактый көтеп ята иде. Бер чокырдан исә чыкмады, танкны көтте. Менә танк тирән чокыр яныннан узып бара. Чапбаев каушавын тәмам җиңде, аңа көч кереп китте. Гранаталары бик мач төште. Танк туктагач та тагы бер граната томырды ул. Үзе чокырның төбенә тәгәрәде. Танктан аксыл төтен чыга башлады. Чапбаевның эчендә шатлык әтәч булып кычкыра иде. Ул кайту ягына борылды. Ләкин танктан чыккан ике немец аны күреп алды һәм ата башлады. Чапбаев та автоматын аларга төбәде, якында гына иде ике гәүдә, тик тәтене баса алмый калды, чигәсенә нидер бик каты сукканын тойды, күз алды кинәт кап-кара булды да бетте.

Мамак аның танкны җимергәнен ачык күрде. Бүләк исемлегендә беренче итеп куярга хәтеренә салды. Икенче танкка каршы кемне җибәрергә икән дип, траншея буенча атлап барганда муенына нидер пешереп узган кебек булды. Шунда хәле китте, тотынмакчы булды, куллары тотмады, траншея төбенә ишелеп төште. Аны сугышчылар күреп алып, ашыгып блиндажга керттеләр. Туфайлов аның ярасын эзләде. Кулы канга буялгач кына тапты. Муенның бик кирәкле тамырына тигән. Мамак һаман аңына килә алмады. Туфайлов һәм аңа булышучы санитар тырышып карадылар. Кичә килгән яңа замполит — Термоз дигән капитан борчылып штабка шалтыратты. Командалык синең кулга бирелә, дип боердылар. Ул, тиз-тиз җыенып, әмерне үтәргә чыгып йөгерде.

Яраланучылар бик күбәеп китте, алар ачы тавыш белән кычкыра, сүгенә иде. Туфайлов, монда бер иптәшне калдырып, сумкасы белән алга шуышты һәм бер тар гына траншеяга килеп төште. Корымга буялып, шайтан кыяфәтенә кергән булса да, Туфайлов Крынкинны таныды. Ул да санитарны күрде һәм яраланган аягын көчкә сөйрәп аның янына килде һәм:

— Танк! Танк!— дип шыраийлап акырып җибәрде. Кулында граната, ләкин ыргытырга хәле юк. Туфайлов траншея стенасына елышып башын күтәрде, алга карады. Танк аның күзенә бәрелерлек якын иде. Крынкин бер сүзсез запал куйган гранатын аңа суздь. Туфайлов та берни әйтми, кулларын гранатага сузды. Коточкыч шартлау танкны

бер якка чүмәйтте. Ул туктады. Бортында кызыл ялкын күренде.

Икенче минутта уңдарак тагы бер танк чокырдан чыгып килә икән. Крынкин тагы: «Санитар! Санитар!»— дип шырыйларга тотынды. Туфайлов шулайга таба берничә адым атлады һәм Крынкин сузган гранатаны үрелеп алды. Танк чокырдан чыгып житте дә бөтен гәүдәсе белән уңга борылды, шул якка пулеметтан сиптерергә керешге. Алдында беркем дә юк дип белгән, ахрысы. Туфайлов кулыннан граната ничек ычкынганын да сизми калды. Үзе аска чүкте. Граната шартлагач кына башын күтәреп карады. Танкның чылбыры өзелгән иде. Аның зырылдап кыегайганы һәм ян чокырга авышканы күзгә чалынып китте. Туфайловның күзләрен тир, тузан каплаган, томанлы пәрдә япкан кебек иде. Ул күзләрен сөртеп маташты. Яралыларның ярдәм сораган авазлары колагына кереп, хәрәкәтләрен тизләттерде. Ләкин медикамент тулы сумкасын тапмады. Балчык күмде микәнни? Шуны эзләп маташканда, тегендәрәк торган Крынкин тагын аны чакыра башлады. Үлә дип белерсең. Туфайлов тыңламый булдыра алмады. Сумкам шунда түгелме, дигән өмете дә бар иде. Барганда ук күз кырые аларга таба үрмәләүче танкның пушкасын шәйләп алды. Әле генә берни юк иде, дошман чокырга яшеренеп яткан һәм менә иң кискен моментта чыгып һөҗүмгә керешкән. Нишләп беркем дә юк, барысы да сафтан чыктылар микәнни, дигән уй Туфайловның миендә бөтерелде. Ул, җиргә тезләнеп, Крынкин аңа сузган гранатаны алды һәм ажгырып килгән соргылт чүмәләгә томырды. Граната танкның алдында шартлады, траншея стенасын Туфайлов өстенә ишеп төшерде, ул күкрәгенә нидер бик каты китереп сукканны тойды, тотынырга итеп кулларын җәйде. Ниндидер авырлык аны җиргә сылады. Баш чүмече каты нәрсәгә бәрелеп, бер генә минутка аңын җуеп торды. Ул күзләрен ачканда, аның янында тезләнгән Крынкин зур кантарларны алып-алып ташлый иде...

Нәкъ шул чакта алда «Ур-ра-а!» дигән тавышлар яңгырады. Бу сөенечле аваз тәнгә көч бирде. Туфайлов Крынкин иңенә тотынып аякка басты, теге иблис танк нишләде икән дип карыйсы килде. Әмма танкны тапмады. Аның урынына нәкъ шул турыдан безнең танкның алга китеп баруы күренде. Ул дошман танкысын чокырга мәтәлдереп киткән.

Туфайлов як-якка башын борып сумканы караштырды. Крынкиннан сорады. Ул да «белмим» дип баш селкеде, сүз әйтерлек хәле юклыгы күренеп тора иде. Шулай да Туфайловның эченә җылы керде, безнекеләр алга киттеләр дип, иркенәеп, шәбәеп калганын тойды. Блиндажга кире кайтып запас медикаментларны алырга һәм яралыларга ярдәм күрсәтү өчен алга барырга дигән карарга килеп, торды, өстен кагынды. Башының авыраеп калганы үзен нык белдерә иде. Крынкин нигәдер уфылдый башлады, ул җиргә сузылган иде. Туфайлов аның баш турына тезләнде. «Яраңмы?»— дип сорамакчы булды. Нәкъ шул минутта күзендә кызыл ялкын чагылып китте һәм ул берни сизмәс булды. Якында гына авыр снаряд шартлаган иде.

Кичке эңгер-меңгер вакытында яңа частьлар сугышка кертелде. Танкларга төялгән десант гаскәрләре иде. Немецларның көче бу ике көндә нык кына талкынган иде, каршы торырга әмәлләре җитмәде. Караңгылыктан файдаланып алар артка элдерде.

Бу юлы фрицлар Курляндиядә сигез чакрым чигенделәр.

Туфайлов белән Крынкинны яңа часть санитарлары шул кичне үк табып алды. Туфайловның ике аягы да яраланган, бүтән җире сау, ә Крынкин элеккеге ярасы өстенә тагын контузия дә алган иде.

## 2

Бу госпитальдә Ваһаповны бик яхшы карый башладылар. Яралы аякларны саклап калырга тырышалар. Ләкин бер дә алга киткән

эш юк. Врач Альбин Васильевич аның йөрәген тыңлап карый да, иреннәрен кысып, уйга кала. Бар хикмәт йөрәктә икән. Имеш, табигатьтән һәр кешегә бертигез санда йөрәк тибеше бирелә, ди. Шуны кем ничек, нәрсәгә тотып бетерә, гомер озынлыгы шуңа бәйләнгән. Безнең йөрәк тибешләре нәрсәгә тотылды соң? Һаман алгы сызыкта булырга туры килде. Исән калу да бары очраклы рәвештә генә килеп чыкты. Ул мәхшәр эчендә күп нәрсәне очраклылык хәл итә шул. Уттан исән чыгылды, хәзер яшәргә кирәк инде, әмма яралар бик авыр, йөрәкнең көче беткән. Китеп барылырмы икән?! Өйләнергә дә өлгереп булмады. Башта завод төзелешендә эшләде. Ял көннәрендә дә өмәгә чыгалар иде. Аннан армия... Тагы әз генә яшәп булмас микән?! Хирург, сиңа операция ясарга куркам, ди. Йөрәкнең рәте калмаганга күрә шулай әйтә инде ул. Менә Ася аның йөрәген ныгыту өчен үзенчә чаралар күрә. Врачлар кушканга түгел, үзенең дәвалау практикасыннан чыгып эшли. Өрек җимеше һәм кишмиш юнәлтеп китерде дә шуны ашаганны бик нык күзәтеп тора. Бер мәл ярты төн урасында температурасы кырыктан ашып китте. Ун сәгатьтән соң гына аңына китергәннәр аны. Күрше караватта ятучы полковник: «Ася булмаса, егет, беткән идең, теге дөньядан кайта алмаган булыр идең, валлаһи! Шәфкать туташы сине әллә нинди әмәлләр белән әҗәл кулыннан тартып алды», дип сөйләнә. Әйе, Ася аның өчен хәзер ниндидер кояш кебек. Өрек җимеше йөрәкне ныгыта икәнен каян белгән ул. Бар җаны белән эшенә бирелгән кеше генә эшли моны. Кризис вакытында ычкынмый калуым шул өрекнең файдасы тигәннәндер мөгаен. Нишләп начарланды икән йөрәгем? Элек аның күкрәкнең кайсы ягында икәнен дә сизми идем. Шул гангрена гаепле, ахрысы, йөрәкнең хәлен шул бетерә торгандыр. Ычкынып куйсам, бик үкенеч булачак! Хәер, мин генә ычкынаммы әллә? Һәр операция дә ике яклы шул. Әллә шуңа инде эч поша. Калып булмас шикелле тоела. Тегендә үлемнән курыкмый идем кебек, хәзер нигәдер икеләнеп маташам. Кемгә кирәк мин? Үлсәм, беркемнең бер төге дә селкенмәячәк. Гомеремдә бер бәхетле көнем булмагандыр, ә үләсе килми! Алгы сызыкта һөҗүм вакытында өчәр тәүлек буе бер тамчы йокы күрмичә чабасың. Тәмам эт буласың. Башың тубал, берни эшләми. Күз алдың караңгылана башлый. Аяк атларга хәлең юк, әмма йөрисең. Чыдаса да чыдый икән адәм баласы! Әмма бу юлы бирешермен кебек...

...Ваһаповны операциягә әзерлиләр иде. Менә кан җибәрергә Ася килгән. Подносында кан тутырылган шприц. Мөлаем йөзеннән, ак кулларыннан нур бөркелә. Ул тоташ нурдан гына тора, ахрысы. Ася аның күлмәк җиңен сыерып өскә менгерде дә беләген шул турыдан резина белән каты гына бәйләп куйды. Терсәген каты нәрсәгә терәп, беләктәге тамырларны ышкып кабарта башлады. Аннары зәңгәрләнеп кабарган тамырга шприц энәсен иплэп кертте, бәйләгән резинканы чишеп җибәрде. Шприцтагы кан тамырларына ага иде.

Кич белән температурасы күтәрелде. Артык пошынырлык түгел. Альбин Васильевич хәлен белешергә килгән иде.

— Күпме тырыштык, булмады,— диде ул уфтанып. Ягымлы йөзенә кайгы-пошыну билгеләре чыкты.— Соңгы чара — ампутация...

— Йә аяк, йә гомер, хәл шулайрак шикелле?— дип сорады Ваһапов, тән температурасыннан шәмәхәләнеп киткән иреннәрен көчкә кыймылдатып.

— Мәсьәлә җитди, әмма өмет бар!— диде Альбин Васильевич ышаныч булдыра торган чырай белән.

— Йөзгә бер өметме? Йөзенче итеп мине санама, диләр?

— Йөрәгегез бераз әйбәтләнеп киткән...— Пульс санап алганнан соң хирург күзендә чаткылар күбәйде.

— Бу арада чәнчүе бетеп тора...

— Амин! Күз тимәсен!

Ул киткәч, башын тагы уйлар сарып алды. Язмышның мине йөзен-

че итүе ихтимал. Шуңа күрә кайбер хәстәрләр күрергә кирәк. Иң элек Турганов турында реляция язарга. Аның батырлык эшләгәнен мин күреп тордым. Башкаларның күзенә чалынмагандыр да! Күргән шаһитлар да үлгән булуы мөмкин. Шулар белән бергә батырлык да җиргә күмелә... Турганов әз аралашучан солдат иде. Ни генә булса да, бер дә ата торган пулемет каршына кутәрелер сыман түгел иде. Салмак хәрәкәтле бу егетнең батырлыгы эчендә яткан булган. Йөргәндә дә ул ничектер кырынрак атлап йөри иде. Менә шундый, кыяфәте белән күзгә бәрелеп тормаган кеше сәләтле була. Ул, мөгаен, пулемет өстенә ташлануны уена да китереп карамагандыр. Үзенең батыр йөрәкле булуын моңарчы белмәгәндер. Кайчак хәл, шартлар кешене батырлыкка этәрә. Әмма шунысы да хак, йөрәгендә булмаган кешене бернинди җайлы шартлар да батырлыкка этәрә алмый. Хикмәт кешенең үзендә. Курыкмас булсаң, хәлләр ярдәм итә, диләр... Турганов яшь иде бит әле. Исән калмады микәнни? Кеше җибәреп эзләтә алмадым. Исемне җуяр-җуймас хәлдә ятканмын...

Башта батальон командиры Поликарповичка язарга кирәк. Ул үз урынында булырга тиеш. Мамак яраланган иде, хәзер аның эшен бүтән алып барадыр. Ротага язудан мәгънә юк. Тик Поликарпович минем сүзләргә генә ышанып җитмәс. Шундый кеше. Әй, сак та кеше булыр икән! Ул һәр нәрсәдән курка. Юк, үзе куркак кеше түгел ул. Пуляларга сәлам дә бирми. Снарядлар якында шартлаганда да сакланырга ашыкмый. Әмма башлыклардан, сүздән шүрли инде! Һәр сүзне ул тешләре белән тешләп караган кебек итә иде. Юк, минем язу гына аны кымшатмас. Каян тагы бер шаһит табарга? Ротадан кемнәр исән кала алды икән?..

Тагы шул: кенәгәсендә шактый мая җыелган икән! Үлсәм, иясез калуы бар. Кемгә булса да бирел калдырырга кирәк! Ә нигә ул аттестатын Фира Касыймовнага күчертеп бармады икән? Аңа ышанып җитмәүдәнме? Әллә саранлык галәмәтеме? Фира белән аралар ныгымады шул. Киресенчә, йомшый гына барды. Фираның соңгы хаты өметне өзә һәм ике төрле уйларга юл ача торган мәгънәләр белән тулы иде. Иш тапкандыр, күрәсең. Аңа калдыруда мәгънә юк! Ә кемгә соң? Тукта, ә Ася? Күпме вакыттан бирле мине үз туганы кебек итеп карый ул! Кризис булганда, гомер кыл өстендә торганда саклап алып калды. Әгәр мин бүгенге көнгә тикле исән икән, күбрәк аңа бурычлы. Моны да аңламаска! Мин үлеп, акчаларым аңа калса, һич тә әрәм булмаячак, нәкъ иясенә туры киләчәк. Бурычларым кайтарылачак! Әйе, Асядан да лаеклы кеше булмас! Дүрт ел буена күпме минем ишеләрнең гомерләрен саклап калмагандыр ул! Әйе, фәкать Асяга! Ичмаса бер шатлансын!

Даруларның файдасы тия, ахрысы, ул үзен әз генә ярыйсы сизә башлады. Сменадан соң Ася кереп утырган иде, шунда теге реляцияне аңа әйтеп яздырды. Штабтагы танышына бер-ике сүзле генә хәбәр дә җибәрде. Сөйләшеп киттеләр. Ваһапов үзе карар иткән теләген Асяга белдерде.

— Исәп кенәгәмне синең исемгә яздырам, үлсәм, үзеңә булыр,— диде.

Кыз моны тыңлап торганда, бите кызарып-алсуланып киткәләде, аннары кызыллыгы бетте, элеккеге аксыл, тыныч төсенә кайтты.

— Юк, кирәкмәс, нәрсәгә!— диде ул кыюсызрак рәвештә.

Ваһапов үзенчә нәтиҗә чыгарды: кыз риза, ләкин уңайсызлана гына. Ничек риза булмаска мөмкин! Чын күңелдән бирәм бит! Ул, билгеле, моңа ышанып җитми, шуңа уңайсызлана. Ничек аны ышандырырга?

— Ася, бернинди астыртын ниятем юк,— диде Ваһапов.— Беләсең бит, операциядә төрле хәл булуы мөмкин! Әгәр чыдый алмасам, дигәннән... Шул карарга килдем.

Ася уйланып торды. Башын бер якка, биек күкрәгенә таба ия төш-

кән иде. Нигәдер уңайсызлана. Ул башта ук бу майор алдында үзен киеренке тойды. Әллә майорның кырысрак күренгән йөзеннән, әллә авыруын күпертмичә, эчтән генә түзеп ятуыннан. Аралаша торгач, ул киеренкелек әзрәк кимеде кебек, ләкин бөтенләй бетмәде. Ниндидер ара калды. Кайбер авыр яралылар белән бернинди ара калмый. Тәмам бала булып бетәләр иде. Ә майор алай булмады. Бик горур, үз бәясен белә торган кешедер, ахрысы, дип уйлады Ася. Һәм бүлмәдәше Лия Никифировна: «Сугыш бетә, үзеңә бер кулай кеше чамала», дип, тормыш киңәшләре биргәндә, ни өчендер шушы майор исенә килә иде.

— Ә милләте бүтән булса?— дип сорау куйды Ася.

Лиянең аңа да җавабы бар:

— Яһүд, татар булса, шактый культуралы халык...

Асяда хатын-кыз хәйләсе юк иде, турысын әйтте:

— Берәү шулай начарлангач,— диде,— кенәгәсен миңа яздырган иде. Әйе. Әмма терелгәч, кире алды. Гаепләп әйтмим, шулай да була ул. Үлем исереклеге белән эшләгәнмен, дип гафу үтенде. Мин сөендем генә. Нәфесем юк минем...

— Үлем исереклеге белән әйтмим, Ася!

— Нигә миңа? Бүтәнгә яздырыгыз,— диде кыз һәм идәндәге кара сумкасына үрелде.

Ваһаповның тәмам хәле беткән иде, чуендай авырайган күз кабакларын тотарга ихтыяры калмады. Шуннан ул шактый вакыт черем итеп яткан икән...

Иртәгә операция буласы көнне Ваһапов канцеляриядән сержант кызны чакыртты да «исәп кенәгәсе»н Мишина Ася исеменә күчертеп куйды. Шушы эшне эшләгәч, күңеленә ниндидер канәгатьлек килде. Хәзер тыныч җан белән пычак астына ятарга була кебек тоелды. Әйдә ни булса шул! Ярый әле, бүген Ася дежурда түгел, юкса палатага кергәндә кызарыр, уңайсызланыр иде. Бу турыда әйтми торырга куштым. Әмма барыбер серне сакламаячаклар. Операциядән соң белсә дә була...

Өстәлгә җайлап яткыргач, авыз-борынына марля яптылар һәм шуның өстенә яшел тамчылар сала башладылар, тирән итеп суларга, санарга куштылар. Ваһапов утызга чаклы гына саный алды, аннан бу талды һәм тынып йоклап китте. Бер минуттан ниндидер төш күрә башлады. Имеш, Ася белән икесе бакча эчендәге эскәмиядә утыралар. Яшеллек, кояш нуры, җылы. Ася, шаярып елмая һәм:

— Син татар бит, мин сине ничек якын итим?— ди.

— Минем татарлык фамилиядә генә, мин детдом баласы,— ди Ваһапов тирән сулап.

— Татарлар кыргый булганнар, мин куркам.

— Миндә нинди татарлык сизгәнең бар?

— Алайса син шәхес түгел, ярым-йорты адәм!

— Характерым шактый нык минем, Ася. Моны рота командирым Мамак та әйтә торган иде. Син якын итә алмам дип куркасың! Ә ярату ул шулай: тегермән ташы кебек ике арадагы каршылыкларны он итә дә бетерә!

— Бетерми, барыбер күңел төбендә кала!

— Әйе, мин фәрештә түгел, Ася. Шулай да куркырлык әйбер күрмим!

— Туа мөгез чыкмый, тора мөгез чыга, дигән сүз дә бар! Шуңа куркам да мин!— дип йөрәк белән пышылдады Ася һәм китә башлады. Һавадан очып барган шикелле иде. Ваһапов кабаланды, аның артыннан ашыкмакчы булды, шунда аягы эскәмия баганасына эләкте. Ул, аягын ычкындырмакчы булып, тартылды, ләкин шырт итеп каймыгып чыкты. Авыртуга чыдый алмыйча җиргә ауды, күзеннән утлар чәчрәде. Тубыгы тагы да кисеп авырта башлады һәм ул шул авыртуга уянып китте. Тән буенча үтергеч авырту йөри иде. Аяк очында ниндидер шыгырт-шыгырт буын чыртлаган кебек тавыш чыкты, шул колагына килеп керде.

Кисә торган авырту миенә йөгерә һәм түзәр хәлне бетерә иде. Ул уфылдарга тотынды, аннары кычкырып җибәрде. Сестралар тыз-быз килеп ниндидер укол кададылар.

Операциядән соң ике тәүлек аның күзләрен ачтыра алмыйча интегеп беттеләр. Ася ял итәргә дә кайтмыйча аны саклады. Теге акчасын аңа яздыруын белгәннәр. Хәзер «синең майорың» дип кенә җибәрәләр иде. Бу хәлдән Ася бик нык уңайсызлык кичерде. Ваһапов алдында аерым бурычлы итеп тоюю авыр иде. Чөнки иптәш кызлар күпсенә, көнчелекләре килә. Адым саен шул көнчелекләрен чыгаралар иде. Хатын-кыз үзеннән уздырган икенче хатын-кызны бер дә өнәми. Дошман күрә ул аны. Менә шул нәрсә кыен иде.

Лия Никифоровна сүзләрендә дә көнчелек кушылмыйча калмады. Аның йөзенә әчке сөенеч нуры чыккан иде: Альбинда чын өмете булган икән.

— Син инде хәзер аныкы!— диде эштән кайтып чишенеп маташканда. Душ кергән, әчке күлмәге юешләнеп тәненә ябышкан.

— Ничек аныкы!— Асяның зәңгәрсу күзләре зураеп ачылды, күз аклары көмештәй елтырап алды.

— Ничек инде, шундый бүләктән соң да!

— Бүләк, әйе! Күңел бар бит әле!

— Бүләккә авышмаган күңел — таш күңел, күгәрченкәем — дип ачулана башлап әйтте Лия Никифоровна.— Бер аяксыз дисеңме? Анысы бар, билгеле. Йа хода, аяклыларның ниндие булмый! Һәр хатын-кызның хуҗасы булырга тиеш, Ася! Кәй генә булса да хуҗа кирәк. Юкса ул минем кебек ташландык бакчага әйләнә. Ташландык бакчага кәҗәләр тула, кәҗәләр кимереп бетерә аны. Кәҗәләр кимерә башлаганчы хуҗа канаты астына ышыклану хәерле!

— Башым катты, нишләргә дә белмим!— диде Ася, Лия Никифоровнага тарак сузып. Теге чәчләрен йөзенә тарап ташлады.

— Уйлама, хәлләрне үз агымына куй, сабыр гына көт.

Операциядән соң Ваһаповның хәле бик тиз алга китте. Бер аягын тез капкачыннан кистеләр, икенчесенең сөякләре таза иде, балтырындагы зур яраны эшкәрттеләр. Берничә көннән соң температурасы тигезләнде. Тамагына ашый башлады. Адәм баласы өчен ашау-эчү иң зур нәрсә шул. Майор тиз тернәкләнде. Ася буш вакыты булганда аның янына кергәли. Сөйләшеп алалар. Ул Асяның йөзеннән, кыяфәтеннән эчендәге уйларын да чамалый шикелле. Ася аңа бүләк уңаеннан ниләр булганын сөйләгәне юк әле. Ваһапов сүз арасында кыстырды:

— Ася,— диде,— сиңа минем турыда төрле сүзләр ишеттерерләр. Нык бул, берсенә дә ышанма! Минем намусым чиста. Әгәр намус пычранган икән, бернинди түләү белән дә аңардан котылып булмый. Бел!

— Четерекле эшләрдә булгансыз, диләр...— диде Ася курка-курка гына. Чөнки үзенең кем белән, нинди кеше белән эш итүен ныграк беләсе килә иде. Үзен караган, үлемнән алып калган шәфкать туташына бүләк бирү болай табигый тоелса да, күпләр моны кабул итә алмады. Һаман монда нәрсәдер яшеренгән булырга тиеш дип карадылар. Асяның колагына да килеп пышылдыйлар иде.

— Бурычны үтәү төсендә дә яман эш эшләргә туры килмәде, Ася! Чынын әйтәм. Уңай килеп торды миңа! Бер дә пычранмыйча чыга алдым. Моңарчы язмыш мәрхәмәтле булган иде, аяк белән генә эшне бозды. Ну, ярар!

— Җитте, бүтән сөйләшмә!— диде Ася аның хәле беткәнен күреп. Ул аңа хәзер үзенең хатын-кыз властен куллана башлаган иде. Бу властька майорның бик теләп буйсынуы һәм шуңа шатлануы Асяга ниндидер рәхәт минутлар кичерттерә иде.

Сугыш бетүгә таба бара иде. Шул сүзләрне раслагандай яралыларны Ленинградка, башка шәһәрләргә күчерергә тотындылар.

— Ася, мине ташлама!— дип әйтеп куйды Ваһапов.— Синнән

башка мин бетәм...— Ул, күзләрен мөлдерәтеп сестра йөзенә ниндидер өмет күрергә тырышып карап торды.

Ася, бераз кызарып китте, һәм:

— Борчылмагыз! — дип кенә әйтә алды. Тавышында ниндидер ныксызлык, карарсызлык беленеп калды: бу исә майорны катлаулы уйлар эченә ыргытты. Чөнки аны да икенче госпитальгә күчерәчәкләр. Ул анда ялгыз гына китәргә курка шикелле иде. Моны үз-үзенә икърар итәргә базмаса да, шундый хисе тынгы бирми. Ася минем белән китсә әйбәт булыр иде, дигән фикер нык утырды аңарда. Тик бу теләген әйтергә генә уңайсызлана. Ася ничектер икеле-микелерәк күренә. Ә административ яктан алганда бу бик мөмкин хәл. Ася риза булса. Яралы офицерны икенче госпитальгә озата барырга шәфкать туташы билгеләләр ич... Юк, мин моны Асяга белгертергә тиеш түгел. Аңа үземне тагарга бернинди хакым юк!

Ася да борылыш сәгате килгәнен белде. Ленинградта әнисе. Нишләргә? Аларны күчерәчәкләр. Сугыш бетәр, тыныч тормышта ничек яшәвеңне кайгыртырга кирәк. Фронтта барысы да әзергә өйрәнелде. Ә гомер уза бара. Аңа егерме алты яшь. Ниндидер тәгаен карарга килергә вакыт! Әйе, майор мине яратыр, ә минем хисләрем җавап кайтара алырмы? Минем андый сәләтем бармы? Мине ир-атлар «Син салкын», диләр иде. Ир-атларның да кайберләрендә була ул салкынлык, ләкин аларның хиссезлеге беленми, ә хатын-кыз хиссезлеге беренче көннән үк белена, имеш. Алар бала тапкач кына ирләрен ярата башлый, диләр. Әллә мин дә шундыйлар рәтенә керәмме? Ир-ат халкына әллә ни исем китми. Күңелем кайтып бетте кебек! Мин аларны күпме терелттем, җан биргән чакта саклап алып калдым. Күпме кан бирергә туры килде: шуңа, ахрысы, җанда ниндидер тую бар. Лия Никифоровна әйтә: «Синең ир-ат белән яшәп караганың юк, тую шуннан ул,— ди.— Яши башлагач, сиңа бөтенләй икенче дөнья ачылачак. Ир-аттан башка бер хатын-кызның да тормышы тулы була алмый. Ярым-йорты гына була».

Авыр яралыларны алып китү өчен санитар поезд төзелә башлады. Күңелләр урыныннан купты. Аерылу борчуы белән бәргәләнде, сукаланды. Ваһаповны Казанга илтә торган поездга билгеләделәр. Нишләргә? Майор болай сабыр гына карый, әмма күзләре нидер өмет итеп Ася йөзенә төбәлә иде. Аның күзләре белән очрашуга Асяның тәнендә кайнар елдырым чабып йөри башлый. Ул тизрәк палатадан чыгу ягына борыла иде.

## 3

Әнвәрне Казанда, поездан алу белән госпитальнең изоляторына китереп салдылар. Вагонда кайтканда хәле начарланган иде. Температурасы күтәрелде, ярасыннан кан китте. Болай венадан гына, артериядән түгел, шуңа куркыныч булмады. Артериядән кан китсә, фонтан булып бәрә, болай бинт белән туктата алмаслар иде.

Аны носилкадан караватка күчергәндә, изоляторда ятучылардан кемдер:

— Менә тагы бер «тере мәет»не китерделәр,— дип әйтеп куйды.

Әнвәр ул сүзне тоныкк кына ишетте һәм аңа әһәмият бирмәде. Үләрмен микәнни, дигән уй аның башына да килеп карамый. «Тере мәет» булып бик күп сират күперләрен кичте ул. Менә тагы күзен дә ача алмый ята. Янына килеп тә карамыйлар. Митавада ятканда аны караган Ася юк шул монда. Ася, Таня бигрәк изге җанлы шәфкать туташлары иде шул. Бала урынына иркәләп, бар сызлауларын җиңеләйтеп тордылар. Андыйлар хәзер төшеңә дә кермәс.

Берничә көн газапланып ятканнан соң аңа да чират җитте. Врач карады һәм укол бирә башладылар. Укол даруы килеште. Ул күзләрен

ачты, тирә-юнендәге дөньяны әз-әзләп кабул итәргә тотынды. Бигрәк тә татарча сөйләшү миенә бәреп кереп, җанынданиндидер сөенеч уята иде. Бүлмәдәшләре татарлар икән. Туган телнең һәр авазы аңа шундый тансык тоела. Бер кырыйдагы караватта хәле авырайган яралыны ниндидер туганы саклый иде. Шулар шыпырт кына быдыр-быдыр сөйләшеп ала. Почмактагы караваттагы яралының тыны-өне юк. Ул берни дә әйтә алмый. Ашау-эчүе дә беткән. Укол белән генә торалар.

Бер мәлне нәрсәдер шытырдаганга Әнвәр күзләрен ачты. Теге бичараның караватын чыгарып маташалар иде. Караватның иясе төнлә бер тавыш-тынсыз гына китеп барган икән. Нянялар, резина перчаткалар киеп, аның ятагын актарып ташладылар.

Хәле әйбәтләнә башлагач, Әнвәрне изолятордан палатага күчерделәр. Күбесе аяксызлар, берничәсенең сыңар кулы юк. Барысы да «йөри» торган яралылар. «Ята» торган бер Әнвәр генә булып чыкты. Кайсының ярасы төзәлеп беткән, протез көтә. Кайсына икенче операция ясарга тиешләр. Чөнки ярасыннан сөл килүе туктамый. Кулсыз Маринкин теш куйдырып йөри. Госпитальдә теш техникы юк икән. Ул шәһәрдәге кайсыдыр поликлиникага бара. Аңа кием дә биргәннәр, чыгып йөрергә рөхсәт тә иткәннәр. Кайчак соң гына кайта. Шәһәрдә күргән-ишеткәннәрен сөйләп ала. Кичә, ди, немец әсирләре Тукай урамында трамвай юлы төзәтеп маташалар иде. Әй әкрен дә кыймылдыйлар инде. Немецлар эшчән, имеш. Кая!

— Немецлар шактый тазалар! — диде икенче бер яралы. Колхоз базарына төшкәндә күргән икән. Безнең илнең читләргә мәрхәмәтле булуы хакында сөйләшә башладылар.

— Үзләре кебек кансыз булырга иде, белсеннәр иде!

— Алар фашист дип, безгә дә фашист булыргамы? Син нәрсә?

— Без йомшак булганга алар басымчак итәләр.

— Без беренче социализм иле, марканы төшерергә ярамый. Хәтта эшчеләргә такы-токы булса да, әсирләргә ярыйсы норма бирәләр...

Маринкин теш техникы хатын турында сөйләи:

— Бүген эштән өенә озата бардым. Тутырган туп кебек тыгыз тәнле. Ул минем авызга «күпер» куйса, мин аның күңеленә күпер салмакчы булам. Кызык! Ирем бар, дигән була үзе. Кача-посарак барабыз. Ләкин сизәм, ире юк шикелле. Хода белсен.

— Ул да күпер сала, син дә. Саперлар, димәк?

— Шулай килеп чыга,— дип көлә Маринкин тавышсыз гына. Өске казнасындагы сыңар теше күренеп кала.

— Чамала, сапер бер генә ялгыша.

— Күперне ачу тантанасы кайчан инде?

— Теге ярга кайчан чыгып җителер бит. Исән-сау чыгып җитеп булырмы, белмим.— Маринкин шаяруны ярата торган кеше икән.

— Әйттең, син гвардеец та чыкмагач? Төтен җибәреп кара?

— Юк, анысы булмый. Ул намуслы хатын.

— Әллә ул сине теге як ярда көтеп торамы? Күперен тизрәк салып бетерсен дип?

— Белмәссең, минем «күпер»не озак эшли әле,— дип Маринкин караватына чалкан ята да кулын баш астына куеп уйга кала.

Маринкин соң кайтса, төшкә хәтле йокы симертә. Төшкелекне ашагач, аның йөзенә төче, майлы елмаю җәелә. Шул серле көләчлеген күргәч, кайберәүләр үртәлеп куялар.

— Йә, Маринкин, тәмле серең бар, ахрысы, үзең генә кинәнмә, безгә дә сөйлә,— диләр.— Әллә берәр нәрсә таптыңмы?

— Таптым,— ди Маринкин һәм сергә чумып дәшми утыра. Нәрсә тапканын белергә теләп, тагы төпченәләр. Әмма серен бирми, җеп очын чуалту өчен бөтенләй икенче нәрсә хакында кызык сүз әйтеп куя да йөдәтүчеләрдән арына. Ахырда тагы:

— Оборонасын өзмәдеңме әле?

— Куперләр ничек соң, төзелеп бетәме инде? — дип сорыйлар.
— Куперга мина куелган булып чыкты әле,— диган була Маринкин.
Маринкин көннән-көн йомыла барды. Теге бүтәннәрне үрти торган елмаюы бетте. Теш техникы хатын турында да шаярып сөйләшми. Тел чарларга теләүчеләргә кул гына селти. Башында уйлары тарткалаша иде шикелле. Йөзендә үз эченә йотылганлык, ниндидер бер карарга килә алмыйча изалану сизелеп тора иде.
Ак җәймә, ак мендәр өстендә боегып кына яткан килеш, Энвәр палатадагыларны күзәтә. Әле ул яңа, бер сөйләшер кешесе дә юк. Каршы як почмакта ятучы мөлаем яралы аңа карап-карап алгалый иде. Энвәрнең аны кайдадыр күргәне дә бар шикелле тоела. Хәтерем ялгышадыр дип, эндәшүдән тыела. Бу ягымлы чырайлы, таза иңле, зур башлы аяксыз янына яралылар бик еш килә. Озак кына сөйләшәләр, нидер киңәшәләр. Биредә һәркем сафтан чыгып калган, ә яшәргә кирәк. Барча гәп шул хакта. Шуның өчен яралы үзен тормышның әле бер улчәвенә, әле теге улчәвенә салып, улчәп карый. Берәр нәрсәгә ярарлыкмы ул, түгелме? Бөтенесен яңабаштан башларга туры килә бит! Бөтенесен! Җимерелгән көймә белән тормыш дулкыннары эченә кереп китүләре ай-һай авыр. Уйламас җиреңнән кайгыга төшәсең. Яше кырыктан узган кеше барын да яңадан башлый аламы? Ул инде барын да югалтып бетергәнме? Ул яктан Энвәрнең хәле ярыйсы әле, аңа бары унсигез яшь тулды, унтугыз белән бара. Яңадан башларга көче калгандыр бәлки? Һәрхәлдә аңа яңадан башларга соң түгел әле.
Шул таза иңле, мөлаем чырайлы аяксыз обходтан соң аның караватына килеп утырды. Үзе Энвәрне җәлләгән кебек иде.
— Син мине хәтерлисеңме?
— Күргән кебек тә булам, юк та.— Энвәр мендәрләрен арка якка өеп, шуңа терәлеп утырды.
— Без синең белән Митавада бер палатада яттык. Хәтерләмәссең дә. Синең хәл авыр иде. Ася, Таня сине бик карадылар. Бигрәк тә Ася сине нык тәрбия итте. Бәйләргә булганда да сине, бала кебек юрганга төрә дә кочагына салып кына йөртә иде. Таза гәүдәле, көчле шәфкать туташы. Башта мин сине әллә, бу моның бер-бер туганымы дип уйлаган идем.
— Врач Анна Сергеевна да бик тырышты минем өчен.
— Әйе, сине икенче госпитальгә җибәрмәкче булганнар иде, Анна Сергеевнаның кулына башыңны куйдың да «җибәрмәгез» дип еладың.
— Күздән яшь атылганын үзем дә сизмәдем,— дип Энвәр кызарды.— Бигрәк кешелекле врач иде шул! Үлемнән алып калган кеше анаң кебек була... Сез теге Самохин фамилияле яралымы әле?
Бу кеше бик елгыр, акыллы сүзләр сөйләве белән исенә төште. Хәле авыр булса да, башына кереп калган булган.
— Госпиталь әллә күчтеме икән?
— Кем белә? Бәлки көнчыгышка җибәргәннәрдер? Мин яра төзәлгәч, шунда гына калырга да уйлаган идем. Латвия ошады миңа. Юк, бирегә озаттылар. Госпиталь күчә, диделәр.
— Алайса күчкәндер.
Самохин, Энвәрнең арыганлыгын күреп, үз почмагына китеп барды. Караватына чалкан ятып бераз торганнан соң, китап укырга тотынды. Ләкин ул әдәби китап укымый иде. РСФСРның законнар кодексы, Сталинның зур калын китабы, Маркснын бер томы. Хәтта аңарда «Библия»не дә күргәннәр. Ул аны яшереп кенә тота булыр. Аңарга күпләр киңәшкә килә. Кайсы аны үсендереп, комиссар, дип әйтеп җибәрә. Чынлап та, ул комиссар шикелле дә. Эшкә яраксыз, сафтан төшеп калган яралылар көне-төне уйланып ята. Хәзер нишләргә, кая барырга? Яралы үзен тормышның әле бу эшенә, әле теге төшенә куеп карый. Һәммә эшкә ярамый ул хәзер. Үе, исәбе-хисабы белән болайга, тегеләйгә барып карый. Тупикка килеп чыга. Алга китәр әмәл таба алмый.

Өйдә яшь балалары бар. Алар ач-ялангач. Ничек ярдәм итәргә? Нинди эмәл табарга? Грамотасы аз. Тазалыгы беткән. Тере кайгы, тере бала булып ничек алар янына кайтырга? Әтиләрен көтәләр бит, көтәләр. Күңел көтә бит ул, бигрәк тә балалар күңеле. Барлы-юклы ризыкларына кырау булып кайтсынмы ул анда? Мең төрле уй миен ермачлап бетерә.

Бер яралы өенә кайтмаска карар иткән ахрысы. Астагы катта җыештыручы булып эшләүче бер хатын белән танышып алган. Кичләрен качып-посып шуның янына баргалый. Тәме дә йөгергән бугай, бөтенләй биредә калырга ниятләп йөри. Үз гаиләсенә кайтса, авыр булачак аңа. Колхозда рәтле эше дә юк әле аның. Каравылдан башка. Монда квартир әзер, хатын әзер. Карточкага тамак ялгарлык бирел торалар. Эшләмичә дә көн итәргә мөмкин. Унга хәтле йоклыйсың, аннан торып сыраханә тирәсен әйләнеп кайтырга була. Чат саен сыра сата торган ларек...

Самохин аның шундый планын белеп алды, тегене әкрен-әкрен бу эшеннән кире түнтәрергә кереште. Әз-әзләп һаман төрттерә, ишарәли иде. Әмма мужик каты, үзенекен сукалый, авылга балалары янына кайтасы килми. Монда тынычта гына яшәргә итә. Адәм баласы үз җаен, үз башын күбрәк кайгыртучан бит.

— Балаларыңа хыянәт итмәкче буласыңмы? — дип тотынды Самохин ул иргә. Ачулана да белә икән. Хәер, кемгә каты, ачулы сүз утә, кемгә йомшак, миһербанлы сүз кирә. Самохинны өйрәтәсе юк. Палатадагыларны биш бармагы кебек белеп бетергән.

Агайның күзләре зураеп китте. Караватына торып утырып сыңар аягын идәнгә бастырды. Башы да аска иелгән иде, маңгаенда җыерчыклар хәрәкәткә килде.

— Әй, син, хыянәтче! — диде Самохин.

Теге башын күтәрде. Күзләрендә гаепле чаткылар биеште.

— Юк, мин хыянәтче түгел,— дип әйтергә ашыкты Коробов. Ләкин дәлилләр китерергә көче житмәде шикелле.

— Кем соң син?

— Сиңа бары да билгеле, нәрсә сорыйсың?

— Шуңа әйтәм дә: хыянәтче!

— Балаларыма хыянәт итмим. Мин алар янына кайтсам, тагы да начар булачак!

— Начар булмый, киресенчә, бик яхшы була!

— Бичара ризыкларына корт булыргамы?

— Син корт булмыйсың, бик кирәкле кеше буласың. Син балаларыңа икмәк кебек үк кирәксең!

— Шушы килешме? Алар миннән куркып качачак!

— Һаман үз файдаңны кайгыртасың. Нишләп качсын, юләр! Алар сине зарыгып көтә. Син алар янында үзеңне кеше итеп сизәрсең. Туган кан бит ул! Чит хатын янында кем син? Утын яргыгы. Беркемгә кирәгең юк синең. Берниндн кадерең юк. Аңлыйсыңмы шуны — берниндн бәяң юк! Монда чүп син, ә балаларың янында — алла! Ят итсәң, кабереңә балчык салырга да килмәсләр. Хыянәтеңне син фәкать шул чакта ныгытып аңларсың. Ә мин сиңа аны хәзер үк әйтәм. Кара акылың белән уйлап кара.

— Бу хыянәт түгел! Арттырып җибәрәсең лә!

— Бала килгәч, гаиләңне ташласаң — хыянәт! Иптәшеңне бала килгәндә ташласаң — хыянәт! Мәгънәсе шулай аның!

— Мин семьяга җәфа гына булырмын дип куркам!

— Җәфа булмыйсың, терәк буласың! Син ул балаларны дөньяга китергәнсең. Син аларны кеше итү өчен гомереңне кызганмаска тиеш! Үз бәяңне үзең төшермә. Әгәр хатының киң күңелле булса, син өйдә утырып кына торсаң да, аларны тәртипле итәчәксең, шаярып-тузып ялгыш юлга кереп китүдән саклаячаксың! Менә бит хикмәт нәрсәдә. Күз өстендә каш булачаксың. Хатының ниндирәк?

— Болай ярыйсы иде,— Коробовның тавышы калтыранып китте, ул ике кулын йөзенә каплады. Җилкәләре селкенә башлады. Башы ыграк иелде. Дулкынланып торган саргылт чәчләре сибелде.

— Үзең яхшы кеше син, Коробов,— диде Самохин, аның елавына тамчы да әһәмият итмичә.— Үзең хыянәт юлына басарга әзерләнгәнсең!

Шул сөйләшүдән Коробов бик уйчанланып калды. Аңа протез китерделәр. Көне буе шуның белән мәшәләнә иде. Беркем белән дә сөйләшми. Үзалдына караган килеш узып китә. Башында Самохиннан ишеткәннәрне кайната. Бызыр-бызыр кайный аның миендә фикерләр. Нәрсә пешереп чыгарыр? Протез белән бик тырышуына караганда аның нияте ганләсенә кайту ягына авышкан иде булса кирәк. Икенче каттагы җыештыручы да палатага сугылмый башлады кебек.

Һәр кешедә бер характер, һәр кешедә үзенчә язмыш. Кайберәүләр госпитальдәге рәхәтлеккә артык нык ияләнеп китәләр. Авыр тормышка чыгасылары, арбага җигеләселәре килми. Бер караганда, гаеплəп тә булмый. Кеше туган иле өчен канын койган, сәламәтлеген биргән. Ләкин гомер дәвам итә, моның белән генә тукталып калырга ярамый. Үзең тарта алырдай кечкенә бер мичәүгә булса да бер җигелергә тиешсең.

Аек, реаль фикер йөртүче Самохин янына Маринкин да килеп утыргалый. Кешене ялганлап юата торган ширбәтле сүз сөйләмәсеннәр, бала урынына башыннан сыйпап кечерәйтмәсеннәр, чын сүз әйтсеннәр. Алдамый торган. Адаштырмый торган. Нигә дөрес сүз сөйләүдән куркырга? Без үзебезнең хәләл җирдә, шөкер, азат җирдә. Азатлыкны кан, тир, күз яше түгеп саклап калдык. Барысы да үзебезнеке, яхшысы да, начары да. Кыены да, шатлыгы да. Тик нигә сүзнең дөресен генә сөйләмәскә икән дә нигә мактанырга икән? Мактану бүтәннәрнең ачуын гына китерә торган нәрсә бит!

Маринкин белән Самохин шул хакта сөйләнеп утырдылар. Аннары тирәнгә керүдән куркып, икесе дә бүтән нәрсәгә сүзне бордылар. Тирәнгә китеп булмый иде.

— Нишләргә инде, комиссар,— дип кайгырды Маринкин.— Ул хатын төшләремә генә түгел, йөрәгемә дә көмеш коронка кигерде кебек...

— Син бит туган җиреңә кайтырга әзерләнеп йөри идең?

— Әйе. Ләкин планнарны җимерде дә куйды!

— Шулай укмыни? Үзе яшьме?

— Бераз яшьрәк. Йөрәкне әсир алды, комиссар, валлаһи, һаман аны гына уйлап торам хәзер. Һич үземне аңламыйм. Мондый хәл минем белән булганы юк иде моңарчы!

— Китче! Нәрсәсе белән сихерләде?

— Белмим, белмим. Башымда рәхәт томан.

— Әллә «оборона»сын өздеңме, шайтан?

— Юк, ул як бик нык аның, комиссар. «Оборона»сын өздергән булса, болай да булмас идем, бәлки?

— Димәк, сезнең мәхәббәт?

— Теләсәң ничек әйт, мин аны уйламыйча тора алмыйм.

— Үтәр әле.

— Үтми, комиссар, үтми! — Маринкин катгый рәвештә башын чайкады.

— Синең тегендә хатының, балаң бар шикелле?

— Авырттыра торган нәрсә дә шул-шул! Дөрес, без хатын белән начар яшәдек. Бик алама холыклы. Юк нәрсә өчен дә талкый. Ярату да булмаганмы?

— Ә син үзеңне яратуга чаклы үскән дип уйлыйсыңмы? Кайберәүләр яратуга хәтле барып җитмиләр, гомерләре буе. Ярату алар өчен артык зиннәтлелек.

— Менә хәзер генә мин яратуны татыдым, комиссар. Моңарчы бу хиснең нинди икәнен белми идем. Чын. Юри сөйләнәләр дип уйлый

идем. Егет белән кыз бергә кушылалар да шуны ярату дип уйлыйлар. Әти-әнисе дә шулай эшләгән булганга күрә генә. Гореф-гадәткә карап. Инде белдем...

— Анда балаң бар бит? Бала бар нәрсәдән өстен, Маринкин.

— Өстен икәнен дә аңлыйм, комиссар.

— Бала синең өстә бит, Маринкин, синең җилкәдә.

— Бала дип тагы шул «пычкы» янына кайтыйммыни?

— Баланны яратсаң. Бала хакына күпләр «пычкы» белән тора.

— Беләм. Әмма хәзер «пычкы» белән тора алмам ахрысы. Бар төшем киселеп-туралып беткән, ул тагы кисә башласа? Кайт кына, кисәчәк! Хатка да сиздереп яза!

— Да, читен хәл! — Самохин, күзләрен читкәрәк алып, күрми торган караш белән уйланып калды. Аннары гына әйтте: — Яратуга алданып, баланны ташлыйсыңмы?

— Ничек ташлыйм?

— Хатынны ярату озакка бармый ул. Ә баланы мәңгегә яратасың! Мин шуны әйтәм.

— Нишләп ул алай?

— Кеше шулай корылган, күрәсең. — Самохин ир белән хатын арасындагы яратуның даими һәм тотрыклы булуына ышанып җитми иде.

— Балага моннан торып та яхшы ярдәм итәчәкмен. Бәлки, үз яныма алырмын? Юк, хатын бирмәс. Үч итеп! Мондый чакта хатын-кыз бала мәнфәгатен оныта!

— Җайлы эш таптыңмыни?

— Бөтен хикмәт тә шунда шул! Мондый эшне мин бер җирдән дә таба алмыйм.

— Мենә хикмәт! Рас эш дисең икән инде...— Самохин әңгәмәдәше белән килешкән аваз чыгарды. Маринкинның да йөзе яктыра төште. Самохин шикелле аек уйлый торган берәүдән раслау алу күңелгә ниндидер тынычлык бирә торган нәрсә иде шул.

Соңга таба Маринкин теш куючы хатын турында ачылып китү түгел, бөтенесен инкарь итеп сөйли башлады. Мин шаярттым гына, сез шуны чынга алдыгыз, кырчыннар, дип ачуланып, сүзне бетерә иде. Куйдырасы тешләре күп иде әле. Аның бу эшне һаман сузарга теләгәне дә сизелә иде.

Самохин янында кем дә булса булмый калмый. Тагы берсе үзенең бәлаләрен күтәреп кергән. Озын буйлы, эре сөякле кеше. Бар җире таза кешенеке төсле, тик бер аягы гына юк. Белоруссиядән икән. Немец таптап бетергән җирләр. Хатыны, баласы шунда калган. Хатыны сугышка чаклы башлангычта укыткан, сугыш килгәч, утын складында эшләгән. Баланы ачтан үтермәс өчен. Район үзәге, крестьяннныкы кебек бәрәңге бакчасы юк, юнәтү әмәле дә юк. Эшләргә мәҗбүр булган. Җан асрар өчен. Хәзер шелтәлиләр икән, немецларга эшләгәнсен, дип. Укыту эшенә дә алмаганнар. Инде нишләргә? Нинди хокукларыбыз бар? Бу хокук дәгъвалап килгән. Самохин брошюраларын актара, законнарны укып-укып карый. Газетада чыккан указларны да кисеп алып җыеп барган икән, шуларны караштыра. Инвалидларга нинди льготалар булуын пунктлап укып күрсәтә. Юк, берсе дә белорусның хәлен җиңеләйтә торган түгел.

— Немецка хезмәт итү сәяси мәсьәлә шул,— диде Самохин,— монда указлар көчсез!

— Баланы ачтан үтермәс өчен эшләгән бит! Әх, егетләр!

— Син хатыныңның хәлен яхшырта аласың, иптәш,— дип өметләндерергә керешә Самохин.— Ул партизаннарга ярдәм итмәгәнме?

— Иткән бер тапкыр. Бер машина торф брикеты җибәргән. Әмма ул кешеләр хәзер юк, ди. Үлеп беткәннәр...

— Менә син өеңә кайт та бу эшнең төбенә төшәргә алын. Дан

орденың, медалең бар! Аяксызлыгың үзе орденга торырлык. Партизаннарга булышканын кем дә булса хәтерлидер. Тап, исбат ит! Хокукларың күп! Җебеп торма. Берәү дә тәлинкәгә салып китереп бирмәс! Хатының нинди соң?

— Бик йомшак, яклаусыз бер нәрсә, ләкин өйдә, минем алда батыр инде. Мине үзе «сыер тизәге» дип ачулана иде. Шулай да аңардан якын кеше юк миңа! Ул бичара ниләр генә кичермәгән! Шуның өстенә менә бу хакарә. Монысы бигрәк тә авыр аның, белсәң.

— Аңлыйм, аңлыйм,— диде Самохин.

Белорусның күзләре дымлана башлаган иде. Тагы бер-ике сүз әйтсә, елап җибәрер.

— Бик нечкә, сизгер җанлы хатын ул, күңеле ташка әйләнгәндер инде, мескеннең. Шул чаклы кичерешләргә ничек түзмәк кирәк!

— Нужа ул шулай: йомшак күңелне ташка әйләндерә, таш күңелне йомшарта, диләр.

— Сугышка хәтле без җанга-җан булып, бик рәхәт яшәдек. Хәзер ул чаклар төштә күргән кебек кенә. Малга, чүпрәккә исебез китми иде. Бары бергә, югы уртак булды. Күз карасы кебек саклаган нәрсәбез үзара чын, риясыз булу иде. Хәзер ни булыр инде, ни булыр? Хатынның бәгыре катылангандыр, мөгаен? Күңелендәге яхшы нәрсәләрен сугыш бетергәндер инде. Уф-уф-уф!..

— Да-а... Әмма адәм баласы әрсез. Нинди генә хәлдә дә үзенең рухын төшермәскә тырыша ул! Моның өчен кешеләргә рәхмәт әйтергә кирәк!

Ваһаповның хәле шөкер итәрлек әйбәтләнеп бара иде. Болай булса, озак ятылмас, дигән уйлар килә аңа. Нишләргә булыр инде? Ася нәрсә әйтер соң? Бөтен хикмәт аңарда. Минем өчен шулай. Ә аның үзе өчен ничек? Күңеле нәрсә ди? Җанында ни?.. Ася сирәк-мирәк кенә майор янына килеп утыргалый. Бiредә Асяны күндәм ат шикелле җигәләр. Ул баш тарта белми. Килеп утырган чакларында бик алҗыган була, әледән-әле исни, күрсенә. Тегене-моны гына сөйләшәләр. Төп мәсьәләне һаман читләтеп үтәләр. Сүз шуңа килеп туктаганда да тизрәк бүтән якка борылалар. Ул мәгънәне тизрәк бүтән нәрсәләр белән күмеп китәләр. Капкын исен сизеп, юлын үзгәрткән җәнлекләр кебек. Юк, мин аңа карата булган тойгыларымны кыеп әйтә алмыйм. Каһәр суккан теге «кенәгә» комачау итә. Әмма миңа акчамны багышлау һич кенә дә жәл түгел. Ичмаса әз генә дә! Тик менә аның мөнәсәбәтләрне катлауландыруы бер дә көтмәгән нәрсә булды.

Әгәр мин таза, бөтен кеше булсам, Асяга булган хисләремне аңа белгертер идем. Без икебез дә тигез, исән кешеләр булыр идек. Ә болай мин ярты кеше, тигезлек юк. Бәлки ул үзенә тиң таза кеше табар? Моңа шикләнмәскә мөмкин. Асяга эчемдәге чын тойгыларымны әйтсәм, ул минем теге бүләгемә карап, үзенең хисләрен кысрыклар, көчләп минем якка авыштырыр. Шунда кайчандыр күргән төше хәтеренә килде. Әллә өн булды микән ул? Без икебез ике төрле, иптәш майор, дигән иде Ася. Ул саф күңелле, намуслы. Бурыч тойгысы көчле аңарда. Менә шулар аркасында минем якка авышыр да ул, соңыннан үзенә авыр булыр. Үкенү тойгысы килеп җанын кимерүе ихтимал. Чөнки мин ул өмет иткән нәрсәләрне бирә алмам. Ышанып булырлык түгел. Үз мөмкинлекләремне үзем сизәм. Шушы килеш күпкә үрелү, күпне әләктерү минем холыкка ятмый. Андый ертлачлык юк миндә. Асяга карата бигрәк тә алай эшли алмыйм. Үз яратуың өчен көрәшеп, сөйгәнеңне бүтәннәргә бирмәү егетлек санала. Әмма мин ул хокуктан мәхрүм. Әгәр Ася белән тигез булсам да, мин андый дәгъваны куймас идем. Ярый, барысын да Ася үзе хәл итсен.

Ася, өйләдән соң буш ара табып, Ваһапов янына килеп утырган иде. Поезд штабындагы сержант кыз аңа телеграмма китереп бирде.

Фроловтан, үзләренең госпиталеннән икән. Шундый хәбәр: «Ася, яралыларны Казанда урнаштыргач, кире кайт. Безнекен гарнизон госпитале итәләр. Сиңа әйбәт урын булачак».

Ася телеграмманы майорга сузды. Ул исә кәгазь өстеннән тиз генә күз йөртеп алды да Асяга төбәлде. Кызның йөзе эчке нур белән яктырган, ай кебек балкый иде. Үзенең кирәклеген тою, аның белән санашуларын белү һәркемгә күңелле шул. Әллә Митавага кире кайту мөмкинлеге аны шатландырдымы? Асяның анда торак бүлмәсе бар. Ә биредә торак мәсьәләсе бик кыендыр, моны алдан ук әйтергә мөмкин.

— Ни өчен бу телеграмма? — диде Ваһапов. Чөнки Асяның кире кайтуы үзеннән-үзе эшләнә торган эш бит. Кыз тыенкы гына көлеп җибәрде:

— Кияүгә чыгып, Казанда калмасын дип куркадыр.

Ваһаповның тел очына: «Шундый куркыныч бармыни?» — дигән сорау килде, ләкин ул аны әйтә алмады. Әмма Ася, үзенең комсостав яралыларны каравына ишарәләп, ачыклык кертте:

— Йолдызлар арасында булганга куркадыр.

Чыннан да, вагоннарда майор да капитан, хәтта байтак кына подполковниклар бар иде. Асяның тавышында горурлык. Ваһаповның сәер генә елмаеп текәлеп торуын күргәч, әйтте:

— Кияүгә чыксаң, гаскәр белән бәхилләш дигән сүз, ә минем демобилизацияләнәсем килми.

— Әйе, гражданскида авыр булыр шул,— диде Ваһапов, тормышның нинди икәнен күз алдына китереп.

— Званиене күтәрер вакыт җитеп килә, шуңа урынны югалтасы килми,— дип куйды Ася. Йөзе җитди төсмер белән сурәнләнде.

— Звание, урын мөһим нәрсә,— диде Ваһапов тулысы белән кызга фикердәш төстә.

Шунда Асяны чакырдылар. Ул, бик үз итеп Ваһаповка ияк кагып, саубуллашты да китте. Кыяфәтендә, йөзе-битендә исәп иде. Асяны ирексездән уйлар биләп алды: менә майор янында утырганда күңелем аның ягына авышкан иде, аның ягыннан киткәч, күңелем аңардан ераклашты. Нәрсә бу? Үз иткән кешең янында торганда, син аныкы булырсың да төсле тоела, ә аның яныннан киткәч, юк, син аныкы була алмассың кебек. Шундыйрак хис туа. Миңа майор бүләк биргәнгә күрә генә хисләрем аның ягына авыша түгелме? Аңа ничектер бурычлы булган өчен генә. Майор үзе ул хакта онытт, бүтән бервакыт та телгә алма, дип ачулана. Ә ничек онытып булсын?! Аңым белән мин бергә булырбыз дип уйлыйм. Ә күңелем һаман икеләнә, нидәндер шикләнә, курка. Майор болай ипле кеше, хатын-кызны хөрмәт итә торган зат кебек. Күп гомере партия эшендә үткән, хәзер дә аңа шундый эш бирми калмаслар. Аяксыз булуы, билгеле, эчне кыра инде, әмма нишләмәк кирәк? Гел эшчеләр, руслар арасында йөргән, шуңа күрә татарлыгы да әллә ни калмаган булса кирәк. Бу яклардан килеп караганда хәл ярыйсы кебек күренә. Ә тагы нәрсә таләп ителә соң? Нигә күңелдә эзләгәнен тапкандагы кебек җайлылык, иркенлек урнашмый? Тирәндә эчне нидер кымырҗытып, борчып ала? Нәрсәдән булыр бу? Намуссынырлык берни эшләгәнем юк шикелле? Әйе, ул һаман элеккегечә шуны тели: Ася майорны үз ирке белән генә сайлап алмасын, ә хәлләр үзләре аларны бергә берләштерсен, бергә итсен иде. Ул чакта соңыннан үкенмәскә сәбәп була. Тормыш барып чыкмаса да сәбәпкә сылтыйсың, минем башка чарам юк иде, дисең. Хәер, бу фикерләр аның башына әлеграк тә килгәннәр иде, хәзер менә яңа шартларда да шул ук уйлар аның күңелен борчыйлар. Чынлап та, нигә алдан баш ватарга, ничек килеп чыкса, шулай булыр?

Фроловның телеграммасы, эшкә чакыруы әһәмиятле! Ул үзе кайберәүләрдән тизрәк арыну ягын карый. Бик алдан күреп эш итә торган кеше. Фролов җитәкли һәм эшләтә белә коллективны. Җитәкче итеп

ясап куйган кебек үзен. Әйе, миңа үз эшемә кайтырга кирәк. Ә майор? Ул нишләр? Терелгәч синең янга килерме? Юк, берни дә уйламаска, язмыш үзе хәл итсен!

Поезд Идел күперен чыккан чагындарак Ася авырый башлады. Дөресрәге, берничә көн инде ул үзен бик начар сизеп, авыраеп, көчкә генә йөрде. Менә бүген егылды. Күз алды томаланды, башын, гәүдәсен күтәрә алмас булды. Температурасы кырыктан ашып киткән иде. Аңгы-миңге ята башлады. Үзен врачлар караганын һәм тиф дигән куркыныч диагноз куйганнарын да ачык тоймады. Казанга килеп җитеп, яралыларны госпитальләргә озатуда да катнаша алмады. Ваһапов үзен носилкага салганда: «Ася кая? Ася нишли, ник ул килмәде?» — дип кат-кат төпченде, ачуланды, шулай да аңа өзеп кенә җавап кайтаручы булмады. Ташучылар чит кешеләр иде, «белмибез»дән башка нәрсә авызларыннан чыкмады. Әле өченче көн кич кенә Ася аның янына килеп утырып: «Мин сине госпитальгә озата барырмын, шунда барысын да сөйләшербез»,— дигән иде. «Ни булды икән?» — дип Ваһапов бик нык борчуга төште.

Ася санпоезд врачларын да куркуга салды. Поезд көтеп тора алмый. Нишләргә? Соңгы нокта Ульяновск шәһәре иде, Асяны анда хәтле алып бару бик куркыныч. Аның гомере өчен куркыныч. Үзләре яралыларны урнаштырган госпитальдән телефон аша белештеләр, киңәштеләр дә Асяны инфекцион больницага илтеп салдылар. Бик кызганыч, әмма башка чара юк иде.

Ася шулай ялгызы чит-ят җирдә бик авыр хәлдә торды да калды. Хәер, моны үзе белмәде дә. Аны күчергәндә авыруның бик көчәйгән чагы иде. Барысы да куе томан эчендә генә булды. Кайгыра да, борчыла да алмады Ася, аңын җуйган, аңа хәзер барыбер төстә ятты да ятты.

Ася бу юлга чыккач та фронт госпиталендә бергә эшләгән Казан кызы Мирага хат язып салган иде. Шуның буенча Мира поезд килгән вакытны чамалап вокзалга төште. Ләкин поезд ике сәгатькә соңга кала, диделәр. Ул эшенә кайтып китте. Анда мәшәкатьләр аны берсе артыннан икенчесе эләктереп алып кына торды. Ул вокзалга төшәргә кичкә таба гына өлгерә алды. Санпоезд китмәгән иде әле. Мира поезд штабы урнашкан вагонга кереп, Асяны сорады. Шунда Асяның авырып китүен әйттеләр һәм, Мираның биредәге кеше булуын белеп, Асяны кайгыртуын бик нык үтенделәр.

Шәфкать туташы учларында югары күтәреп торган пыяла савыттагы сыеклык нечкә шлангтан тәнгә агып бетте. Энәне алдылар. Ася барын сизеп ята иде, бар көчен җыеп, күзләрен ачты. Янында бик мөлаем ачык йөзле врач хатын утыра, шәфкать туташы үзенең әсбапларын җыеп бүлмәдән чыгып бара. Кечкенә генә ак палата икән. Палатада бер генә караваТ. Ася врач хатынга карады, күзләрендә сорау, аптырау иде. Хатын аны шундук аңлады, хәлен сораша башлады. Ася, сәерсенеп, күзләрен челт-челт ача, йома иде. Врач:

— Температураң, кан басымың нормаль,— диде. Ася бераз исен җыеп ятты: аны нииндидер караңгы суык базга өстерәп алып төшкән кебек булган иде. Ул базда бик нык өшегәне, теше тешкә тиеп шыкылдаганы хәтерендә, аннан тәненең ут капкан кебек янганын миенең бер почмагы теркәп калган. Ә аннан соң ни булганын белми. Ася маңгай тирен учы белән сыпырып алды:

— Менә тир ага, димәк, чир чыга,— диде. Үз тавышын үзе танымады, ничектер карлыгып беткән иде. Ул әлеге хәлен аңы белән аңлап, кабул итеп җиткерә алмаган төстә ятты.

— Артур Федорович сезне бик карады, дарулады, бервакыт бик начарланып киттегез бит! — ди-ди врач хатын үзенең приборлары белән Асяны тикшерде.

— Кем ул Артур Федорович? — диде Ася болай гына.

— Баш врач ярдәмчесе. Менә командировкага киткәндә үз кабинетын сезгә калдырды, тынычта әйбәтрәк булыр, диде. Әллә ул сезнең танышыгызмы? — дип кызыксынды врач хатын-кызларга хас төстә. Ася уйланып торды:

— Юк, андый кешене хәтерләмим,— диде чынлап та белмәгән рәвештә. Хәле булмаганга, юк нәрсә турында сүз озайтасы килмәгән сыман иде. Ул томырылып врачка карап тора, нәрсәдер сорарга, белергә теләгән шикелле.

— Сезне кайдадыр күргән дә, күрмәгән дә кебек булам,— дип куйды Ася гаепле елмайган итеп. Врач хатын да елмайды.

Алар кайларда булулары, эшләүләре турында сөйләшеп алдылар. Әмма уртак нокталар табылмады.

Врач хатын чыккач, Ася үз хәле турында уйланды. Нишләп шундый чиргә дучар булды соң? Ул үзен бик яхшы сизә, кан тапшырган чакларында да өшәнү тоймый иде. Ләкин һич сәбәпсез генә берни дә килеп чыкмый. Канны ешрак тапшырдым шикелле. Шул йомшаткандыр, мөгаен. Моннан соң үзем турында да онытырга ярамас. Менә ничек картайганмын бит! Бу килеш кем күзе төшсен миңа? Гел бүтәннәр турында гына кайгыртып яшәлде, үзеңне дә бераз карарга кирәк икән. Ул көч-хәл белән торып тәрәзәгә килде. Агачлар яфрак яра, яшелләнә башлаган икән инде, форточкадан әчкелтем, җилемле яшь яфрак исе кереп, борынны кытыклый. Дөнья, сиңа берни дә булмаган кебек, һаман шул көе икәнсең. Менә мин бәндәңә әллә ниләр булып бетте. Кешеләрне үлем авызыннан тартып алу белән шөгыльләндем һәм үзем дә әҗәл тамагына китә яздым. Йа, хода! Нишләрмен мин бу таныш түгел җирдә? Шундый хәлдә япа-ялгыз, чит-ят җирдә калу бик ямән икән...

Бер көнне врач хатын ишектән үк яктырып, нур көлтәсе кебек булып килеп керде. Һәм сөйли башлады:

— Сез майор Ваһаповның бик якын дусты икәнсез бит,— диде.— Без аны, хаты буенча барып, ирем белән бер госпитальдә таптык. Исәнлек-саулык сорашкач та ул сезнең хакта әйтте. Ул Мишина Ася безнең больницада, дәвалаучы врачы мин, хәле әйбәт, дидем. Ә майорның ике күзеннән яшь ага. Чын менә! Уф! — Хатын урындыкка килеп утырды да учын биек күкрәге өстенә куеп торды. Ася әле берни дә аңламый, аңа бу хәбәрнең мәгънәсе барып та җитмәгән иде, хатын сумкасыннан алып Асяга кәгазь сузды.— Менә үзе бер язу да җибәрде,— дип куйды.

Ася бер хатынга, бер кәгазьгә карап алгалады. Йөзендә канәгатьлек нурлары беленде һәм ул:

— Сез Фира Касыймовнамыни? — дип сорады да, хатын ияк каккач, язуны икенче тапкыр күздән кичерде. Аның моңа ничектер ышанасы килмәгән кебек иде. Төшме бу, өнме, дигән сорау тагы аның алдына килеп баскан, шуңа җавап эзли иде.

Күзәтеп торган Фира Касыймовна, аның шикле йөзенә карап, аңлатырга кереште: әйе, барысы да дөрес. Ваһапов аның фронтта бергә хезмәт иткән танышы, дусты. Алар һаман хат алышып торганнар... Соңгы вакытларда Ваһапов хатларны сирәк язган, чөнки Фира Касыймовнаның тормышка чыгуын сизенгән булса кирәк. Хатын-кызга ия чыккач, чит ир-ат белән хатын-кыз арасындагы элекке дуслык кырт киселә дә бетә. Ә Ваһапов кырт кисеп бетермәде. Нәрсәдер сизгән шикелле...

— Мира Лучинская телефоннан сезне белеште,— диде Фира Касыймовна, йөзен нурландырып.— Ашыгыч кына Дөбъязга чакырганнар, кайту белән килеп җитәр. Менә Казанда күпме дусларыгыз бар икән!

— Без Мира белән бергә эшләгән идек,— диде Ася соры халатын иңенә рәтли-рәтли. Ничектер аркасы буйлап суык йөгереп узган кебек тоелды.

Ася Ваһаповның хәлен сораштырды, бите нигәдер кызарып-кызарып киткәләде. Язуында ул үзенең хәле әйбәт, гел алга гына баруын әйткән иде. Фира Касыймовна да шуны раслады. Асяның күңеле күтәрелде. Кара, ничек болай барысы да уңай булып кына тора әле,— дигән уй килде башына. Эчендәге шатлык, ак куян кебек, тәне буйлап чабарга тотынды. Фира Касыймовна Асяга витаминлы ризыклар: күрәгә, йөзем җимеше һәм чикләвек төше, кузы ише нәрсәләр алып килгән иде. Шуларны тумбочкага бушатты.

— Гел ашап кына торыгыз, сезгә хәзер ныгырга кирәк,— дип кат-кат тукыды. Бу кадәрле игелекле хатын булыр икән, дип рәхмәт хисләре белән уйлап калды Ася.

Ә Мира белән алар озак сөйләшеп утырдылар. Үзләре турында сорашып-аңлашып беткәч, сүз Мираның ире Рудныйга барып төртелде. Мираның йөзе кинәт сүрелде, күз кырыенда җыерчыклар күбәеп китте. Аның әллә ни ачыласы килми, ә Асяның бик беләсе килә иде.

— Ирне артык нык яратма икән, ул сине яратсын икән, Ася. Ачы тәҗрибә! Мин аны артык яраттым һәм, әллә шуның аркасында, аны үземнән суындырдым...

— Юк, син артык таләпчән булгансыңдыр,— дип сүз кыстырды Ася, аның матди яктан яхшы тәэмин ителгән булуына ишарәләп. Чөнки бүтәннәр карточка белән яшиләр, бер сынык икмәккә тилмерәләр, ә ул югары материя — ярату турында авыз тутырып сөйләүдән уңайсызланмый. Димәк, тормышы бик әйбәт. Тормыш җитеш булмаса, ярату турында тел тибрәтеп булмый.

— Мартта кайтып, сигез көн торып китте,— дип сөйләүдән тыела алмады Мира.— Көнләшеп үлә яздым. Ирем миннән суынган, ул инде минеке түгел шикелле. Мин яраткан саен ерагая бара кебек. Яратудан йөзенә бер шатлык әсәре чыкмый, кайгыга гына баткан шикелле була. Билләһи! Миннән суынганга күрә шулай ул. Күңелсезләнеп кайткан иде, тагы да күңелсезләнебрәк китте. Мине яратуы беткәнен сиздем аның. Үзенә дә белгерттем. Төгәл генә берни дә әйтмәде, кеме дә булса бар аның. Сизелә бит ул, Ася, бик нык сизелә. Сиңа чаклы берәрсе белән булганмы, юкмы, бик тиз беленә ул.

— Көнләшеп, теңкәсенә тигәнсеңдер әле?— диде Ася, Рудныйның хатын-кыз һушын җибәрә торган матур чырайлы, таза иңле булуын күз алдына китереп һәм Мираның мул тормышына кызыгып.

— Хәзер дә көнләшеп үлә язам, Ася. Шулай икән ул.

— Көнләшү артык яратудан була диләр бит.

— Артык яраттым шул, Ася. Көчле ярату бервакытта да җавап таба алмый, дип әйтәләр иде. Хак икән,— дип Мира ир-аттан өмет өзгәндәй кулын селтәп куйды. Тумбочкадагы кечкенә көзгене алып, ясаткан чәчләрен рәтләп маташты. Ул бик пөхтә һәм затлы киенгән иде. Шулай да йөзе-бите элеккегедән кайтышланган, таушала төшкәнгә охшый. Мираның һич бирешергә исәбе юк. Эш урынында да, ахрысы, абруе зур. Сөйләшүеннән шул нәрсә беленеп тора. Юк, үзгәргән Мира. Яхшы яккамы, яман яккамы, әле әйтүе кыен. Әмма рухы, күңеле үзгәргән. Менә Туфайлов турында Митавада нинди шау-шу куптарып йөргән иде, ә хәзер кызыксынып та карамый. Ася үзе сүз катып, Туфайловның фронтта күрсәткән батырлыклары турында сөйләп алды. Газетада аңа багышланган мәкалә басылуын әйтте.

— Улмы дүрт танкны яндырган?— дип ышанмады Мира матур иреннәрен бөрештергәләп.

— Шуның өстенә күпме фрицларны кырган,— диде Ася һаман мактап, сокланып.

— Булмас ла, шул мәхлукмы, кит!— Мира сусыл иреннәрен тибрәткәләп, көзгегә карап тора башлады.

Ася, караваt башындагы саквояжыннан актарып табып, Мирага газета сузды, «Рота санитары» дигән мәкаләне укырга кушты. Тын гына торды-

лар. Мира укыды. Ася аның нинди бәхетле булуы турында уйлады. Кая гына бармасын, ни генә эшләмәсен, гел уңышка ирешеп кенә тора ул. Нилектән шулай? Мира үзе бик япьтәш, уңган кеше. Сөйләшергә дә, эшкә дә бердәй булдыра. Гүзәл булмаса да, күңелне тарта торган мөлаемлелеге бар. Тагы нәрсә? Иң мөһиме, эти-әнисе югары урыннарда эшлиләр. Андый кешеләрнең балалары да җайлы урнаша, бәхетле тормышта яши. Язылмаган закон. Электән шулай килгән, хәзер дә шулайрак әле ул. Моны беркая куя да, берни эшләтә дә алмыйсың.

Мира, газетаны укып бетереп, йөзен чытты, бер дә исе китмәгәнлеген белгертте. Әмма тавышы уйчан, тәкәллефле иде.

— Ул бик әйбәт кеше, дөрес,— диде газетаны Асяга кире биреп.— Ләкин әйбәтлек белән генә яшәп булмый бит...— Мираның мөлаем чыраенда мөһимлек төсмере беленеп китте. Бу сүзләре белән тормыш турында күп һәм тирән итеп белгәнлеген, тик аны бүтәннәргә әйтергә ярамаганлыгын сиздерәсе килгән сыман булды.

Мира киткәч тә Асяның уйлары тынычланмады. Ул кешеләр, язмышлар, үлемнәр турында уйлады. Тормыш бик катлаулы, аның өсте бар, асты бар. Өс, ас — физик төшенчә. Аңардан котылу мөмкин дә түгелдер.

Икенче тапкыр килүендә Мира тагы бүтән төслерәк иде. Йөзендәге горурлык, үзен югары тотуы сизелми диярлек, гади, эшлекле. Ул Асяга бик файдалы киңәшләр бирде.

— Тормыш авыр, демобилизацияләнергә уйлама,— диде катгый итеп.

Ася үзе дә шул уйда иде, Мираның киңәшенә сөенде, җаны тынычланып китте.

— Әгәр демобилизацияләсәләр?— диде Ася, бала килгән чакта үзен ышыклау өчен әмәл эзләп.

— Риза булма. Кыссалар, миңа әйтерсең.

Бу иптәшләрчә кайгырту иде. Менә чын, фронттагы Мира. Ә теге көнне Мира чак-чак танырлык иде. Гражданкада әллә шулай төрле-төрле төскә кергән рәвештә генә яшәп була микән? Мин хәрби тормышта турыдан-туры әйткәнне, боерыкны үтәп яшәргә өйрәндем, тыныч тормышка яраша алмам кебек. Белеп торам, миңа ипләшүе бик авыр булачак. Шуның өчен хәрби хезмәтне ташларга ярамас! Гаскәри тормыш ышанычлы, эшләргә дә эшләргә...

Өйләдән соң шәфкать туташлары, няняләр ашыгып йөри башладылар. Артур Федорович кайтты, дип, бу хәбәрне бер-берсенә тиз-тиз җиткерәләр иде. Ася бүлмәдә шуны ишетеп, тоеп ятты. Үзләренең дә, кырыс врач госпиталь бусагасын атлап керүгә, тиз-тиз йөгерешеп эшкә керешүләрен, хәбәрне колактан-колакка пышылдап таратуларын исенә төшерде.

Кичен Асяны шул врачка чакырдылар. Аскы каттагы кабинетта кабул итә икән. Ася кергәндә бүлмә буш иде. Врач каядыр чыккан, ахрысы. Ба-
шына ак калфак кигән күзлекле врач кереп, үзенә якынайган саен, Асяның күзләре түгәрәкләнеп ачылды, шул күзлекле йөзгә тартылган кебек текәлде дә катты. Ниндидер бик таныш чалым миенә килеп бәрелгәнен тойды ул һәм халат изүен тоткан кулы читкә тырпайды, буыннарының көче беткән кебек булды, тамагында тыны тыгызланып, бугазны авырттырды. Ул бер учын ияк астына куйды, икенчесе белән таянмакчы итеп стенага сөялергә авышканда, врач аның беләгеннән тотып алды һәм өстәл янындагы урындыкка китереп утыртты.

— Ася! — диде йомшак, җылы тавыш белән. Ася, врачтан күзен аерып ала алмастан, тиз-тиз халат чабуларын япты, изүен кысып тотты. Врач күзлеген салды, кулъяулыгын чыгарып, юешләнгән битләрен сөртә иде.

— Артур, йа хода! Йа хода!— Ася һаман өнме бу, төшме дигән төстә врач йөзенә карап торды. Үзе тәмам каушады, кулын, аякларын тоймас булды. Артур да, башын игән килеш, каушаудан ни әйтергә белми торды. Менә ул үзен кулга алды һәм күзлеген киде, эчендәге хисләрен сиздермәскә итеп, елмайды, дәвалаучы врачка әйләнде.

— Ася!— диде һәм аның каршына утырды.

— Артур, бу синмени?— диде Ася еламсыраган, әрнешкән тавыш белән.— Юк, юк, мин төш кенә күрмимме? Яле, мине тотып кара?..

— Ася, тынычлан!— Артур калкынды, үрелеп дару шешәсе алды, тиз генә микстура салып, Асяга бирде. Икесе дә тыштан тынычланган кебек булдылар. Артур Асяга авыр була күрмәсен дип курка иде. Ул аңа карап-карап алды.

— Ася, әйдә, палатаңа илтеп куям.

Ася гаҗәпсенеп, аңа күзен текәп, сынап торды һәм элеккеге йомшак, юл куя торган төсмерләр күреп елмайды, башын як-якка чайкады. Карашы ялвара иде: ничек инде мин, барын да белмичә, бу көе китә алыйм? Бу килеш ничек яши, терелә алыйм? Артур Асяның шундый тансык, сагынылган, үртәлгән, өмет нуры белән тулган күз карашыннан җиңелде. Бу рәхәт җиңелү иде.

— Ася, кыскача болай,— диде ул, тавышын тигезләп, тамак кыргалап алды.— Мин монда врач булып эшлим. Санпоездан китерелгән авыруның тарихын өстәлгә куйдылар. «Мишина» фамилиясе күземә чалынды, йөрәгем еш-еш тибәргә тотынды. Элек тә ул фамилия очраганда йөрәк сикергәли торган иде, гел алдана иде. Бу юлы да шундый алдану гынадыр дип уйладым. Исеме, әтисенең исеме туры килгәч, түзмәдем, палата ишеген ачып карадым, сине таныдым. Хәлең әйбәт түгел иде. Сине саклар-га шәфкать туташлары куеп, үзем дежурда калдым. Командировкага барырга кирәк иде, соңга калып киттем. Кризис үткәчтен...— Артур тукта-ды. Асяга карады. Асяның йөзендә аптыраулы, сораулы нур йөри иде. Матур иреннәре ачылган, аннан энҗе кебек вак тешләре күренә. Ася исә аның карашыннан, «бүгенгә җитәр, өзлегә күрмә», дигән мәгънә аңлады да ашыгып:

— Юк, хәлем әйбәт!— диде Артурга бик көтеп карап. Артурда табиблек рухы көчле иде.

— Ася, бүгенгә җитеп торсын!— диде бик ялынган рәвештә.— Минем дә эшләрем күп, үзең беләсең...

— Институтны бетердеңмени?— дип сорады Ася чыга башлап.

— Әйе.

Ася үз палатасына кайтып, караватына менеп ятты. Менә нинди очрашу! Каян шулай туры килүе мөмкин? Әллә язмышларны очраштырып торучы бармы? Икенче яктан караганда, нәрсәсе искитәрлек? Артурның әнисе шушы шәһәрдә туган бит, әйе, хәзер генә хәтеренә төште. Бирелә кинәт авырып китүемне зур бәхетсезлек санап, күпме кайгырдым, тилмердем! Күпме йөрәк маем сызды. Ә мине һич искәрмәгән бәхет көтеп торган икән. Минем өчен микән соң бу бәхет? Тормыш миңа бәхетле ягы белән әйләндеме? Исәпләсәң, бу бит яшәрү. Мин үземне өшәнгән, картая башлаган кебек сизә идем, кинәт эчемдә дәртле дулкыннар кузгалып чабарга тотынды. Ул дулкыннар тормыш мәшәкатьләре, үз-үзеңне төрле тыюлар, кысулар аркасында күмелеп яткан. Мин аларны үзем күмгән идем. Әйе, әйе, тормыш кырыс, үз-үзеңне чикләп, качып яшәргә мәҗбүр буласың. Ә хәзер шуны аңым белән бик яхшы тоям: миңа яшьлегем кайткан кебек булды.

Утыз тугызынчы елның яңгырлы, томанлы көзе иде. Ленинград көзе ул үзенә аерым, бүтән җир көзенә охшамаган. Алар, фельдшер-акушерлык мәктәбенең соңгы курс кызлары, мединститут бинасына урнашкан практика кабинетына йөриләр иде. Практика дәресләрен институтның югары курс студентлары, ассистентлар алып бара. Ася беренче тапкыр Артурны шунда күрде. Ул да, Асяны ничәмә-ничә кызлар арасыннан аерып алып, дикъкатен аңа туктаткан булган. Ничек шулай була — күп кешеләр арасыннан синә бирәү аеручa ошый, шул күңелгә керә. Күңел моны аңнан башка үзе сайлыймы? Ә ник шул көнне, шул вакытта? Моны үзең сизми дә каласың. Яшь күңел, ахрысы, җәнлек кебек гел эзләнеп кенә йөри, безгә белгертмичә генә сайлап йөри? Һәм бервакыт эзләгәнен таба да. Чынлап та күңел күзе барлыгына ышана башлыйсың. Менә күпме кызлар арасыннан ул мине аерып куйган. Мин дә аның кай төшендер ошаткан идем. Артур берничә кыз-

га, безнең төркемгә, эшләр йөкләде. Ул соңыннан: мин синең эшкә кулың ябышуын да ошаттым, диде.

Танышлык дуслыкка әверелде. Яшь чакта шунардан башка булмый. Яшьлек моны үзе таләп итеп тора. Шул таләпкә буйсынасың. Бүтән егетләрнең миңа сүз кушканы булды, әмма Артурның сүзләре җанга май кебек булып ага иде. Нилектән шулай, һич белер хәл юк.

Асялар Охта поселогында, завод янындагы ике катлы агач йортта яши иде. Артурлар шәһәр үзәгендәрәк булып чыкты. Бераздан, аңлаша торгач, шул билгеле булды: әтиләре бер заводта эшли икән. Берсен-берсе яхшы беләләр. Артурның әнисе рәсемче, балалар журналын төрле рәсемнәр белән бизәүче, ди. Бер күпме вакыттан Артур Асяны үзләренә алып барды. Әнисе Асяга текәлде дә шаккатты: каян бу сирәк очрый торган рус хатын-кызы тибы дип, тизрәк үзенең пумалаларына тотынды. Башта акварель, аннан бүтән буяулар белән Асяның йөзен, чыраен рәсемләде. Төсен чыгара алмыйча йөдәде. Артур чәй әзерләгән иде. Кунакны чәйгә утырткач та, әни кеше дөньясын онытып, рәсем ясауда булды. Артур исә, Асяның йөзендәге гаҗәпләнүне, уңайсызлануны күреп, тынычландырырга теләи: әни шулай безнең, өйгә кергән һәр кешенең рәсемен ясамыйча калмый, дип юата. Ә үзенең төсендә горурлык: аның дус кызын әнисе бер карауда нинди ошатты, хуп күрде. Алай гына түгел, иҗат эшенә ярдәм итә торган, әйбәт натура итеп кабул итте. Натура эзләп художниклар әллә кайларга баралар икән... Тик сурәтче хатын тигез генә холыклы түгел иде, кычкырып сөйләшә, кинәт кенә бер шырпылы сүз кыстырып җибәрә. Асяны да кунак дип тормады:

— Кызым, синең эчең дә шулай тышың кебек ягымлы, матурмы?— дип сорап куйды, кыска гына көлеп алды.

Артур кино билетлары чыгарып:

— Әни, безне җибәр,— дип үтенде. Марина Карповна билетларны карарга гына алган шикелле итте дә ерткалады да атты.

— Рәсем белән чагыштырганда кино юк эш!— диде, тамак төбе белән кыска гына көлгән итеп. Асяның бу мизгелне һич онытасы юк: ул җәнҗал күтәреп бер әнисенә, бер улына күз йөртеп торды. Артур ник бер ачу чаткысы белгертсен, киресенчә, әнисенең бу кыланышшы аңа бик ошый, гүя ул шуның белән горурлана да кебек иде. Артур, Асяга ияк кагып, елмайды: безнең әни шундый инде, янәсе.

Асяга хатирәләр дулкыны яңа истәлекләр айкап китерә иде... Сәер иде аларның мөнәсәбәтләре, сәерлеге белән кызыклы иде. Артурга хат язам, ул да миңа яза. Аның хатларын укудан да рәхәт нәрсә юк иде. Ул да минем хатлар белән яшәгәнлеген яза. Билгеләнгән урында еш кына очрашабыз, әз генә сөйләшеп торабыз. Артур һәрвакыттагыча ашыга. Аерылганда үзенең язган хатын миңа суза, мин үземнекен — аңа. Тизрәк аның хатын укыйсым килеп өйгә ашыгам. Ул хатлар көнкүрешем, тормышым булып әверелде. Аның белән күрешергә очып барам, сөйләшәбез дә очып кайтып китәм. Хисләр мине шул тикле нык чолгап алды, мин алардан бер адым да читкә китә алмый идем. Бүтән берни күземә шәйләнмәс, колагыма кермәс булды.

Бер заман билгеләнгән урында Артур күренми башлады. Бер мәртәбә, ике, өч... Авыргандыр дип уйладым. Безнең белән ни генә булмый соң. Тормыш бит! Ул көннәрдә безнең өйдә дә нинидер киеренкелек иде. Әти белән әни табын янында сөйләшмиләр. Бер-берсенә карамый гына ашаган итәләр дә китәләр. Өйдә эчне пошыра торган авыр тынлык. Мин болай пыр-шылдашканнарын гына ишеткән идем: әтиләр эшли торган заводта корткычлык эшләгәне өчен кемнедер фаш иткәннәр, ди. Финнәр белән сату-алу эшендә нинидер чатаклык җибәргән: әйберләр белән бергә «яшерен» сызымнар да озатканнар. Шул эшне аңлымы, аңсызмы рәвештә бер кеше башкарган. Син моны аңлы рәвештә эшләгәнсең дип, гаепләгәннәр аны. Бу хакта әни дә ишетеп кайтты, ул завод поликлиникасында терапевт булып эшли иде. Безнең әти дә шул гаепләүдә катнашкан, имеш. Юкка

гына сөмсере коелып, карасына батып йөрми торгандыр, тиз кабына торган кеше, артыграк әйтеп ташлаган булгандыр.

Артур юк та юк. Мин әллә ничә хат язып салдым, бер җавап та алмадым. Бу хәл чынлап кайгыга төшерде. Йөрәгемне нидер авырттырып, сулыш алуымны тыгызлап тора иде. Күкрәгемдә нииндидер авырлык сизәм. Күңел әкрен генә сулык-сулык килеп сыза да сыза. Эчемдә ниндидер ут кебек нәрсә вакыт-вакыт эчтән көйдереп ала. Ул халәт әле хәзер дә хәтеремдә. Мин кая барып сугылыр урын таба алмый йөдим. Бар нәрсә миңа мәгънәсез булып тоелды. Артур килер, килми булдыра алмас, дип көтәм. Ләкин көтүем бушка гына. Ул хатларында дөресен язмады микәнни?— дип мең төрле шиккә бата идем. Бары да уен гына булып чыгар микәнни? Йа хода!.. Шулай да уйнарга мөмкинме? Бу тикмәгә генә булмаска тиеш...

...Ишекне Марина Карповна үзе ачты. Чәче-башы тузган, алъяпкычы төрле буяу тапларына буялып беткән. Йөзендә җыерчыклар күбәйгәнлеге күзгә чалынды. Ул артка чигенде дә миңа төбәлеп, йөзен чытты, гүя нәрсәдәндер җирәнгән шикелле иде.

— Ә-ә, син тагы сүзләр ауларга килдеңме? — диде тавышын күтәрә төшеп. Тешен кысканга аның яңак калкымнары тагы да ныграк чыккан сыман иде.— Ялганчы фәрештә! Башта Артурның башын миңгерәүләтеп, ышанычка кердең. Монда сөйләнгән сүзләрне тиешле урынга җиткереп бардыңмы? Бары син генә фетнә чыгардың! Синең аркада Самарецны эшеннән чыгардылар, миңа заказ бирми башладылар.

Марина Карповна шар-шор кычкыра, мин башыма китереп суккан кебек, берни аңлый алмый, тик катып торам. Нидер әйтмәкче булам, әмма бугазыма ниндидер төер килеп утырган, шуны эчкә йота алмыйм. Чөнки бу нахак сүзләргә әрнүем эчтән кайнар дулкын булып күтәрелә иде.

— Болар бары да ялган, ялган, Марина Карповна!— дидем ныклы тавыш белән. Ул, кулларын алдында буташтырып, минем сүзләрне кире какты, ишетәсе дә килмәде. Мин тагы нидер әйтеп, хурланудан елап җибәрүемне сизми калдым.

— Елап ышандыра алмассың, алдар фәрештә!— дип кычкырды Марина Карповна, тузгыган чәчләрен йөзеннән сыпыргалап.— Ычкын моннан!

Мин аның ерткычныкы кебек ачылган күзләрен, ыржайган тешләрен күреп алдым һәм елый-елый артка чигендем, тиз генә ишекне ачып, баскычка чыктым. Ябык ишек аша Марина Карповнаның ачы карганган тавышы гына колагыма керә иде.

Мин баскычтан аска ничек төшкәнемне сизмәдем. Бервакыт өстән Артурның:«Ася! Ася!»— дип кычкырганы ишетелде. Баскычтан шак-шок атлап төшә иде. Мин урамга чыккач та уңайга түгел, кире якка борылып китеп бардым. Артур ишектән чыкты да мине эзләп: «Ася, тыңла әле! Ася, тыңла әле!»— ди-ди сөйләнеп, әле болайга, әле тегеләйгә йөгерә башлады. Ерактан начар күргәнлектән, мине абайламады. Бик нык кимсенгән идем, аның янына таба аягым атламады, тиз-тиз качтым. Җанымда нидер сынды, авырта торган яра хасил булды. Мин көн һәм төн тойгысын югалттым. Башымда уйлар бер-берсе белән капма-каршы киләләр, сугышалар. Чыда гына!

Күпмедер вакыттан соң әни ишетеп кайтып сөйләде. Артурның әтисе Самарец зур бәлагә юлыккан икән. Теге корткычлыкта гаепләнгән кеше ул булып чыкты. Марина Карповнаның пыр тузуы хаклы булган икән. Аларның Ленинградтан китүләрен таләп иткәннәр. Самарец сирәк белгеч ди. Марина Карповна төрле җиргә йөреп, ул карарны кире алдырган, имеш. Әмма Самарец: монда барыбер кала алмыйм, дигән ди.

Бәла һәрчак кешене чыгырдан чыгара. Ачу ташыганда ниләр генә әйтеп ташламыйсың. Марина Карповна үзләрен гаделсезлек корбаны итеп таныган һәм Асяны шуның сәбәпчесе дип уйлаган. Ася Марина Карповна сүзләреннән бик рәнҗегән иде, ә бәлагә төшүләрен аңлагач, бар ачулары бетте дә китте. Аларның ярасы белән чагыштырганда Асяныкы әһәмиятсез.

бала-чагалык! Аңа шик төшүе дә бик аңлашыла. Зур бәлагә таргач, адәм баласы үзе янында йөргән барча кешеләргә шикләнеп карарга мәҗбүр. Үзе теләмәсә дә, уйлары шуны эшли. Марина Карповна хәзер суынгандыр, аңа аек акыл кайткандыр? Ә бит ул Асяны ничек ярата иде! Күпме рәсемнәрен ясады, күпме җылы сүзләр сөйләде. Соңыннан үзе дә кайнарланып киткәнен аңлагандыр, үкенәдер әле. Әллә аңлашыр өчен барыргамы үзләренә? Юк, иң элек Артурны күрергә кирәк. Институт бинасында үткәрелә торган практик дәресләр күптән беткән иде, алар ике айга якын кан тапшыру станциясенә йөри иде.

Институттан тагы яра алып кайтты.

— Самарец күптән инде укудан чыгарылды,— диделәр.

Соңыннан ишетте: ул әтисен яклап каядыр барган булган икән...

Эчендә ут яна, әмма шуны беркемгә дә белгертмәскә тиеш. Асяны бигрәк тә Марина Карповнаның нахак сүзләр әйтүе рәнҗетә. Ничек тә аңлашырга кирәк. Асяның тамчы кадәр дә гаебе юк бит! Иң ачысы — Артурның да аны шулай дип белүе, әнисенең сүзләренә ышануы мөмкин. Барса, аларда хәзер Ася кайгысымы, тагы бусагадан кумасlarмы?

Ул нишләргә белмичә, үз уйлары белән бәргәләнеп-суккаланып, газаплы икеләнүләр эчендә йөргәндә, Асяга тагы бер каза китереп сукты: Самарецлар Себергә кучеп киткәннәр икән. Кинәт бар җепләр шартлап өзелгәндәй булды. Бары да бетте! Аларның бер-берсенә үрелеп чәчәк ата башлаган тойгы-хисләре, хыял-теләкләре бер селтәнү белән чабып ташланды.

Фин сугышы башлану вакыйгасы Асяның ярасын төзәтте. Бөтенләй төзәтмәсә дә, үзенең вак хисләр белән йөрүе, аларга нык әһәмият бирүе оят һәм уңайсыз булып тоелды. Бу чынлап та шулай иде. Беренче көннәрдә үк әтисенең үзе теләп сугышка китүе юк-бар шыңшуларны күмде.

Әтисеннән хат бик көттереп килде. Иртәгә сугышка керәбез дигән көнне алгы сызыктан язган. Нәрсәдер сизенгән шикелле, эч серләрен әйтеп ташлаган: «Мин Самарецка карата зур начарлык эшләдем,— дигән.— Дуслыкка хыянәт иттем. Хәзер үземнең хаксыз икәнлегемне аңладым, аңардан гафу үтенер идем. Адресын алып җибәрә күрегез»,— дип үзен-үзе шелтәләгән... Шулай итеп Самарецлар баласенә әтисе дә, Ася да сәбәпче булып чыкты.

Аннары әтисенең үлү хәбәре килде. Әнисе дә, Ася да газаптан кара кисәүгә әйләнеп беткәндәй булды. Әнисе тәмам шаулагә әверелде. Кайгыхәсрәт бар нәрсәне оныттыра, күңелдәге хисләрне агулый, бетерә. Теге кайгылар барысы да артка чигенде, рәхимсез хәсрәт көлләре белән күмелде. Асяны эшкә Опочка шәһәренә билгеләделәр. «Мин әнине ташлый алмыйм», дип комиссиядән үтенде, ялварды. Ләкин тыңламадылар.

Бу зур сугыш башланып, ике-өч ай үткәч тә частьне Суздальгә күчерделәр. Ася әнисен үзе белән алып китәргә бик тырышты, әмма заводта теш-тырнак белән каршы килделәр. Шунда ул әнисе белән аерылды. Ул мәңгегә аерылу булды. Ленинград фаҗигасы аны соңгы өметтән дә өзде...

Ишек ачылу Асяның уйларын бүлде. Инде таң аткан икән. Няня аңа иртәнге аш кертккән иде.

Көндәге эшләр: дәвалану, укол, анализлар башланды. Үз чиратында врач Фира Касыймовна кереп, приборлары белән аның хәлен тикшерде, сорашты. Ул тагы Ваһаповтан хат алып килгән иде, чыкканда гына сумкасыннан алып шуны бирде.

Кичен Артур белән сөйләшеп утырдылар. Шәфкать туташлары, нянялар кереп-чыгып йөрделәр. Шул шартларда аңлаштылар. Хәлләргә ачыклык керттеләр. Күз яше, кайгы, аңлашылмау, шикләр, гаепләр көле астында күмелеп калган тойгыларда ниндидер чаткы пәйда булды. Ул үткәннәрдән сүнми калган загыйфь очкын иде. Очрашып сөйләшкән саен шәбәя барды. Көйрәп китәр өчен кечкенә чаткы да җитә икән. Ул күңелдә зурая, көчәя иде. Ләкин арага бик күп нәрсәләр тулган, тау өелгән. Ике арадагы юл бикләнгән. Һәркем үз сукмагы белән ерак киткән. Һәр икесе-

нең аерым-аерым үз язмышлары оешкан. Әмма иртә яшьлектә кабынып дөрләгән, тетрәткән хисләр бөтенләй бетмәгән икән, менә ихтыярдан тыш үзенең исәнлеген белгертте. Үлеп бетмәгән йөрәк кебек яңадан тибәргә тотынды. Һәрхәлдә бу Ася өчен шулай иде. Ул Артурны күзәтте. Аның эчендә дә элеккегеләрнең чаткысы уянган, көйри кебек иде. Ләкин ул хисләрен яшерергә өйрәнгән шикелле. Тормыш өйрәткәндер. Гаеп итеп булмый. Язмыш кешене кырыкка бөгә. Әйе, аңарда элек бер дә күзәтелмәгән чалым бар: ул сагаю. Нәрсәдәндер сагаю. Сүзләрне бик үлчәп кенә чыгару. Әллә бу акыллылык, үз холыгы утырып-ныгып җиткәнлекме? Мөгаен, шулайдыр. Әмма бер-берсе белән кызыксынулары көннән-көн арта, кайнарлана бара. Теге чаткы ялкынга әйләнеп үзенә юл яра, юлдагы комачау иткән нәрсәләрне яндырып-көйдереп бара сыман иде. Артур Асяның хатларын җыеп барган икән. Аларны китап кебек итеп катыргы тышка төпләгән. Егерме бер хат. Бишәр, алтышар битле. Бөтен бер роман. Хәзер Ася шуларны укып көнен уздыра. Укып барганда «аһ!» дип туктап кала. «Боларны мин яздым микәнни соң?»— дип таң калып, кабат-кабат укый. Оялып кызара, маңгаена тир бәреп чыга. Каян шундый сүзләр таба алдым икән?

«Артур, элеккеге бар җепләр өзелде. Мин беркемне дә ишетмим, тыңламыйм. Миңа эш кушалар, ә аны үтәргә кулымнан килми. Әни сукрана, ни булды сиңа, ди, төпченә. Ә мин, берни дә булганы юк, дип ялганлыйм. Мин бер ялганчы затка әйләнеп барам. Шуның белән генә яшеренеп, котылып калам. Андый кешене элек бер дә өнәми идем. Хәзер белдем, нужадан ялганлый икән адәм баласы, башка чарасы калмаганнан. Кыскасы, Артур, мин хәзер элеккеге Ася түгел, әллә кем шунда! Үземне танып бетермим. Ниндидер томан эчендә йөзәм сыман. Ул томан дулкыннары мине каядыр алып китәләр төсле. Мин куркам, Артур...

Артур, әни нәрсәдер сизенеп миңа әйтә: чыгарып ташла башыңнан шул ахмаклыгыңны, ди. Әледән-әле шул сүзне кабатлый. Төсемнән нидер күрә ул, йөземә чыккан булгандыр. Ә ничек мин әйткән нәрсәне башымнан чыгара алыйм, ди?..» Боларны мин яздым микәнни? Ничек саклаган ул аларны?

Ә Артур әтиемнең гаебе хакында беләме? Беләдер, мөгаен. Әмма хәзер ул хәлне кузгатуның бер мәгънәсе дә юк инде. Әти-әниләр хакында сөйләшергә икебез дә куркабыз шикелле. Иске яраларны читләтеп үтәргә тырышабыз. Ул да аңлый моны, мин дә.

Миңа укол салганда, ничектер сүз чыгып, шәфкать туташы пышылдап кына әйтте:

— Артур Федоровичның хатыны бик усал, сезә күрмәсен,— диде. Ул безнең Артур белән сөйләшеп утырган чакларга туры килгәләгән иде. Мин елмаеп кына җавап бирдем, ә ул җитди төстә калды.

Артур үзенең башлы-күзле булуын әйткән иде. Ул турыда сүз озайтмады, кул селтәде дә бетерде. Шуннан күп нәрсә аңлашыла иде. Әмма бу нәрсә миңа әллә ни тәэсир итмәде кебек. Югыйсә мине сүрелдерергә, чаткылап, көйрәп китә башлаган тойгыларны, уйларны йөгәнләргә тиеш иде. Башка төскә кертергә. Мин ничектер ул хакта уйлый белмәдем. Минем алда яшьлек тойгыларымны кабындырган һәм шул утта янарга дучар иткән Артур иде. Миңа калса, ул һаман да үземнеке кебек иде. Әмма аны алганнар, аңа кемнәрдер ия булып өлгергән. Ул инде ияле, синеке түгел! Шул уйларны уйлагач, йөрәгемне нидер авырттырып үтә.

Артурдан хатыны турында сораштым. Ул тагы, иренен бүлтәйтеп, кулын селтәде. Күпме төпченсәм дә булмады.

— Әйдә ул хакта ләм-мим,— диде. Ни өчен шулай әйтте? Ышанычымны казанасы киләме? Теге чакта аның хисләре, минем дә аңа булган теләкләрем киселеп калды. Безнең икебездә дә элеккеге чаткы бар. Аңарда йөгәнләнгән, яшеренгән. Миндә ирекле. Хәер, ирекле дип үк булмас. Минем майорга, сүз белән әйтелмәсә дә, төсем, мөнәсәбәтем белән белдерелгән вәгъдә шикелле бурычым бар.

Алар өстәл артында сөйләшеп утырганда ишек ачылып китте. Аннан

чәчләре тузгыган, йөзе бүртенгән, өске тешләре алга чыккан, биек күкрәкле бер хатын нәрсәдер шаулап кереп килә иде. Артур кинәт агарынып китте, торып басты, күзлеген рәтләде.

— Әһә, кызлар белән аулакта кәеф корам диген, ә!?— дип кычкырып җибәрде хатын, өстәл янына килеп, Асяга иелеп карый-карый. Ася эшнең нидә икәнен сизеп, тиз генә ишеккә таба омтылды. Хатын әче тавыш белән кычкырына, дулый, яный иде. Артур гаҗизләнеп ялвара:

— Зинһар шауламa! Зинһар тынычлан!— дип юмаламакчы, акылга китермәкче була.

— Син монда гыйшык уйна да, шаулама, имеш!— дип тагы дөрләп китә хатын.

— Ул авыру, тиф белән ята,— дип Артур тегенең кешелек хисләренә тәэсир итмәкче, оялтмакчы була, әмма хатынны туктатырлык түгел иде. Гаепле эш өстендә тотылганлык хисе кичерә-кичерә, Ася үз палатасына кереп посты. Артурны җәлләү йөрәген пычак сызып үткәндәй авырттырды. Элеккеге көйрәп терелә башлаган тойгыларга нindидер әрнү ачысы кушылды. Язмыш каһәрләгәннәрне кешеләр дә кимсетә. Шул нәрсә монда зур роль уйнаган булырга тиеш һәм хәзер дә әле ул бетмәгән. Ася моңа охшаш хәлләрне шактый күрде. Тыштан караганда бар кешеләр дә тигез шартларда яшиләрдер шикелле. Ә кешене якыннан белгәч... Артур элек тә юаш, яклаучысыз иде, шулай тәрбияләнгән. Ул ничектер ярдәм итәсе килү хисе уята иде. Чөнки аны бергә укучы иптәшләре дә санга сукмый иде. Ул хәзер дә шул көе калган. Тик аңарда нәрсәдәндер сагаю, ачылып бетмәү һәм шуңардан килеп чыга торган салкынлык күбәйгән кебек. Бу, мөгаен, тормышка, шартларга ярашудан килеп чыккандыр.

Икенче көнне Мира Лучинская, машина белән килеп, Асяны гарнизон госпиталенә күчереп куйды. Бу хакта күптән сөйләнеп йөри иде инде. Әлбәттә, биредә күпкә яхшы булачак. Бигрәк тә Мира ашау-эчү ягын кайгырта иде. Асяга ныклы тәрбия кирәк. Ул мәсьәләне монда хәл итү ансат. Госпиталь башлыгы Мира белән укыган егет. Мираның һәр гозерен үтәргә генә тора. Тагы бер мөһим нәрсә: монда күпме телисең, шул чаклы ятарга була, ә Асяга шактый озак ял кирәк икәне күренеп тора иде.

Иртән палата ишеген ачып кемдер:

— Җиңү! Сугыш бетте!— дип кычкырды. Ася уяу ята иде, караватыннан төшеп, тәрәзәгә килде. Урам тулы халык: демонстрациягә чыкканнармыни, җырлыйлар, гармун уйныйлар. Гармун уйнаучы янына төркем-төркем булып җыелганнар да, такмак әйтеп, җырлап-биеп баралар. Шат тавышлар тирә-юньне яңгыратып тора. Сугыш беткән! Чынмы бу? Ничектер ышанып та булмый һәм ышанмаска да мөмкин түгел иде.

Чуар төркемнәр арасыннан бортлары ачык машина күренде. Аның әрҗәсендә кемдер гармун уйный, ә клоун булып киенгәне Чарли булып бии. Кулында Чарлиныкы шикелле кәкре башлы таяк. Таякны бик шәп уйната. Аяклар да нәкъ Чарли хәрәкәтләре белән күз иярмәс тизлектә тыпырдыйлар. Шул машина артыннан зур фил килеп чыкты. Тукта, бу цирк лабаса! Цирк үзенең җәнлекләре белән тамаша ясарга чыккан. Әнә буй-буй сызыклы ике зебра аты, тагы ике кечкенә генә кызыл төстәге ат, алар янында каеш тезгенгә бәйләнгән берничә ат бара. Менә машина туктады. Филне кузов артына китерделәр. Шунда филнең борынына кемдер килеп сыенган шикелле итте һәм фил аны хортумы белән кочаклап алды да машинага менгереп куйды. Берне, икене, өчне шулай итте. Тамаша кылучылар гөрләтеп кул чаптылар, шатланып кычкырдылар. Аннары машина әкрен генә кузгалды. Аның артыннан зур фил һәм башка җәнлекләр дә хәрәкәткә килде. Кузовта клоун булып киенгән Чарли тагы биергә тотынды. Аларга бик күп бала-чага ияргән, шау-шу килеп, кычкырынып баралар. Халык урамда артканнан-арта шикелле иде. Менә бушабрак калган тротуарда бер төркем хатын-кыз күренде. Боларның йөзләрендә шатлык юк. Алар аска караган килеш атлый, беркемне дә күрми. Күзләрен-битләрен кулъяулык белән сөртеп алгалыйлар. Барысы да озын җиңле ир-ат пинжәге

кигән. Сугыш бетү аларның өметләрен бөтенләй өзеп ташлаган кебек тоела иде.

Өйләдән соңрак Фира Касыймовна килде. Кочаклашып күрештеләр. Жиңү бәйрәме белән бер-берсен котлаштылар. Фира Касыймовна Асяны сыйлады. Асяга, уңайсыз булса да, тыңларга туры килде. Фира чын күңелдән аның өчен нишләргә белми йөри, чын хөрмәт күрсәтә. Ризык бик тәмле иде, Асяның мондый нәрсәне татып караганы булмаган. Өчпочмакны ничек пешерү белән кызыксынды, бик мактады. Фира Касыймовна:

— Ваһаповка да ирем шундый ук бәйрәм ризыклары илтә китте,— диде. Беркөн үзе дә аның янына кереп чыккан икән, хәл-әхвәлен, тәэсирләрен сөйләде. Аның таныш ярасы төзәлеп килә, протезга үлчәм алганнар.

Ул киткәндә Ася ихластан күп рәхмәтләр әйтте. Бу хатынның илгәзәк күңелле булуына сокланды.

Лучинская Асяга тагы да зур шатлык алып килгән иде. Эш шунда, ул Асяны кайгыртып, Митавадагы штабка шалтыраткан. Анда да Мираның таныш кешесе икән. Аңа Ася турында сөйләгән, звание турында сүз каткан булган. Һәм менә шуның нәтиҗәсе: Асяга медицина лейтенанты дәрәҗәсен биргәннәр һәм аттестат җибәргәннәр. Мира, госпиталь башлыгына кереп, яңа киемнәр китерттерде.

Киенгәч, Ася тагы да матурланып китте. Агачны яфрак, кешене кием бизи шул. Мира аның иңнәрен врачларча тотып карады да әйтте: монда әле бик нык туласы бар, диде, госпитальдән чыгу хакында авыз да ачмаска кушты. Ася Мираның сынаулы күзе каршында әйләнгәләде, күңел күтәрелгән, эчендә шатлык дулкын булып йөри иде.

— Гәүдәң матур, тазаргач тагы да әйбәтләнер,— диде Мира, иптәше өчен шатланып.

— Синең дә гәүдәң бик килешле,— дип, Ася Мираның биек үкчәле лаклы туфлиләренә карап алды.

Ул корыч төсле яхшы габардин костюм-итәктән иде. Калкып торган биек күкрәкләре көлгәндә матур булып селкенделәр. Мира янында ничектер үзеңне җегәрлерәк тоя башлыйсың, тормышка һәм киләчәк гомереңә ныграк ышанасың. Ул сиңа да ниндидер көч-куәт биргән кебек итә.

Ә Артур килгәч, бакчадагы эскәмиядә сөйләшеп утыралар. Элекке больница урам аша гына диярлек, шуңа күрә Артур ак халаттан, ак калфак кигән була. Алар дымык кына сөйләшә, көлмиләр, елмаймыйлар. Артур тирән итеп сулыш ала, уфтана, Асяга нәрсәнедер әйтеп җиткерә алмый гаҗизләнә кебек. Хатыны үзеннән унбер яшькә өлкән икән. Әнисе Артурны Казандагы туганнарына калдырып киткән. Укуын дәвам итәргә җай табылмасмы дип өметләнгән. Тик өмет буш булып чыккан. Инде барысы да бетте дигәндә апасы шушы хатын белән таныштырган. Хатын мединститутның баш бухгалтеры икән. Менә ничек дипломлы булган...

— Акыл белән генә кушылып була микәнни?— дип, Ася Артурның йөзенә карый.

— Башта хис тә булгандыр инде, аннары...

— Хис була да бетә, шулаймы?— Ася ничектер үзе өчен нәрсәнедер ачыклыйсы килгән төслерәк сөйләшә иде.

— Ахрысы. Соңыннан бер-береңә хезмәт күрсәтү генә кала...

— Ә аның ничек? Аның өчен дә шулаймы?

— Күрдең бит, аңарда хис бар, хосуси милек хисе...

— Күңләшү хисе диген? Күңләшүне дә ярату диләр бит?

Артур кузгала, сәгатенә карап ала, китәргә кирәк икәнен ияк кагып аңлата да, бөкрәя төшеп, капкага таба юнәлә. Аңа карагач Асяның йөрәге сызып сулкылдый башлый. Үзенең энесе кебек итеп җәлли ул аны. Артур үзенең төсе, кыяфәте белән Асяны гына яратуын, аны оныта алмавын белгертеп тора. Теле белән әйткәне юк. Бу хәлләрдән Асяның күңеле әллә нинди чоңгылларга төшеп, биек якты тауларга күтәрелеп, дулкынлана.

*Ахыры бар.*

## ПОЭЗИЯ

# Нури Арсланов

## Яшьлегемә кайтып

Кызыксынып карыйм үземә инде,
Кайтам да бер егет чакларга:
Өзәнгеләр каешы өзелә иде
Без атларда алышып чапканда!

Бик күп булды күңел атын каулап
Тезгеннәрне юкка бушату:
Ошарлыкны ошатмыйча, сайлап,
Ошамастай эшне ошату.

Кемдер тыйган, кемдер акыл биргән...
Ә мин каршы бардым силләргә!—
Әллә инде шулай кирәк микән
Тар дөньяда күңеле киңнәргә?

Гел кирегә сукты<del></del>м каршыны мин,
Асау аттай тарпып, ялтарып...[1]
Тик үземне гаепле дип белмим,
Әйтүем дә түгел акланып.

Һәр ысул да аклый икән үзен
Азатлыкка хадим булганда,—
Авырлыклар кичерсәм дә түздем,
Яшь тә түктем... күңелем тулганда.

Кемнәргәдер җик тә булдым, беләм,
Тик салмадым йөгән холкыма:
Ялгышларым, язмышларым белән
Тугры калдым газиз халкыма!

## «Гласность» турында

Сез «Гласность» дисез, ул әйбергә
Күптән хезмәт итеп киләм мин.
Моның белән тик үземне бер дә
Күрәзәче итеп кинәнмим.

Ул бит күптән — яшерен-батырын түгел,
Һәркемгә дә ачык, бик хак эш.
Ә хаклыкны һәр вөҗданлы күңел
Күрсәтсен һәм күрсен шул килеш.

Ришвәт, ялган... Сарык туны кигән
Бүреләрнең йөзе ачылсын,
Масаюдан башы күккә тигән
Түрәләрнең түе басылсын!

---

[1] Арт аягына басу. Ялтару — кинәт бер якка борылу. Автор.

---

Нури АРСЛАНОВ *(1912) — шагыйрь, тәрҗемәче, татар һәм рус телләрендә басылган күп санлы («Зоя», «Моңсар», «Иделем — илем» һ. б.) шигырь, тәрҗемә китаплары авторы. Ул — ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Яңалык юк һич бу изге сүздә,
Томаланды тик ул бер ара:
Син әйт кенә чынын, карап күзгә,—
Ул яңадан туды дөньяга!

## Күңел көрлеге

Якут балкый, алтын чыңлап тора
Күзге миләшләрдә,—
Һәр көз шулай купшыланган була
Миләш — көләчләргә:

«Башкалардан безнең гомер озын,
Син дә шундый ич,— ди,—
Без әле,— ди,— кыш килгәч тә кызыл,
Бул син безгә иш,— ди.

Иш тә булам, биш тә итәм төсле
Кыска бер гомерне:
Хәятымны шулай итә көчле
Күңелнең көрлеге.

## Тагын миләш тәлгәшләре

Миләшләрем минем тәлгәш-тәлгәш,
Оешканнар кызыл мәрҗәннән.
Баш ияләр алар мине күргәч,
Якын алар миңа бар ямьнән.

Тәрәзәмнән карап көндез-кичен,
Сүзсез генә нидер серләшеп,
Җыр чыгара алар минем өчен...
Башка таллар тора көнләшеп.

Миләшләрдән кызлар колагына
Ике бөртек алып тагасы!—
Янсын иде алка булып кына...
Кызык та син адәм баласы!—

Миләшне дә, назлы кызларны да,—
Яратканга бөтен хәятны,—
Гел төшәсең бәхет тозагына.
Бүтәннәргә әллә бу ятмы?

Ят түгел! Бар тормыш кадерен белеп
Яшәүчеләр, Хәйям шикелле:
Аларга җир җәннәт булган кебек,
Алар белән җир дә сөйкемле.

## Хәзинә

Кәгазе ак, каләме дә шома;
Эзләр салып акка, шомага
Шагыйрь канын кара итеп сыга,—
Йөрәгеннән шигырь чыгара.

Язарына азык ил бирәсе,
Ни теләсә — шул бар тирәдә!
Дөрес, ләкин күңел хәзинәсе
Кабырчыкта, төптә — тирәндә.

Бер муенса өчен упкыннарга
Йөз мәртәбә кирәк чумарга:
Тезеп калыйм мин дә, дим, дәрт барда,
Тынгы белми җаным шуңарга.

Хәзинәне диңгезләрдән алып
Җиткерим дим һәрбер кешегә:
Торсын иде чордаш хәйран калып
Фидакарь чын сәнгать эшенә!..

## Язмыштан узмыш юк

Хәят белеп тора:
Картлар үлеп тора,
Яшьләр күреп тора,
Язмыш көлеп тора...

Гомер ул — бер атна,
Яшьлек тик бер чакма...
Мәңгелек хәятка
Искермеш-тузмыш юк!

Тик ул да карусыз:
Картларга дарусыз,
Яшьләргә калусыз,
Язмыштан узмыш юк...

## Юксынам

Йолдыз булып күктән бакмый икән
Бер атылса гомер ук сыман:
Китек күңел урын тапмый икән,—
Мин бит сине, Сибгат, юксынам...

Бер-беребезгә авыр сүз әйтмәдек,
Табигатьләр төрле булса да.
Дуслыкны да, хәер, көчәйтмәдек
Булсак та бик уйдаш, дустанә.

«Талантлылар белә, дия идең,
Үзләрендә талант барлыгын!»
Белә идең, киң булса да илең,
Хисләр өчен дөнья тарлыгын.

Тар дөньяда киң күңелле булып
Яши алса кеше — үлемсез!
Синең белән торган икән тулып
Безнең оя! Синсез — күңелсез...

Кайда син, әй замандашым минем!
Кочакларга әзер колачлар:
Кордаш булган өчен дияр идем,
Күп китте бит инде кордашлар.

Ятимлектә булмый күңелләр хуш,
Сагышлардан чара юк сыман;
Арабыздан киттең, урының буш,
Шагыйрь, сине мин бик юксынам...

## Алыштырмыйм

Һич каушамый китәм тыныч юлга,—
Кунак булып килгәч кайту бар[1]
Фәкать каушыйм сездән аерылуга,
Камап алыр төсле кайгылар...

Шул ук Нури инде мин, элекке,
Үзгәргәнсең дими беркем дә:
Алыштырмыйм сезсез мәңгелекне
Сезнең белән булган бер көнгә!

## Өмет илһам түгел

Телдән калдым әле бу арада,—
Шигырь чыксын ник бер кәлимә...
Алжып йөрим Переделкинода[2],
Кем күз салсын минем хәлемә?!

Илһамы да йөри әллә кайда,
Күренгәли иде кайчакта,—
Мин толпардан әвереләдем бер тайга,
Ул әйләнде тәмам качакка...

Япа-ялгызмыни инде дисәм,
Калган икән өмет иптәшкә;
Вәгъдә итә әллә ниләр исәр,
Өнди бер дә аһ-ваһ итмәскә:

---

[1] Кайту — кайтыш казакъча үлемне аңлата.
[2] Переделкино — язучыларның Мәскәү янындагы иҗат йорты.

— Минем белән генә яшә,— ди,— гел.
Буламмы соң аңа мөкиббән!
Ни әйтсәң дә өмет илһам түгел,
Чыгамыни шигырь өметтән!..

## Яшәү тарихы

*Борынгыда кешене — Уттан,*
*Судан, Җилдән, Җирдән яралган*
*дип уйлаганнар.*

Кеше туды: гомере аның
Акты Су төсле.
Җәйде җилкән канатларын,
Җил булып исте.

Көрәште — Утларда янды,
Көлләргә калды...
Мәрхәмәтле Җир кызганды —
Куйнына алды.

## Нәтиҗә бер

Гамьсезлектә яшьлек хозур таба:
Тирәсендә ише-дуслары.
Ә картлыкта күңел ятим кала,
Йола итә язмыш кушканны...

Тинтәк язмыш һәркем ишеген кага,
Булмый аны тыеп, үзгәртеп:
Яшьләр — белмәгәнгә каушап кала,
Ә без — белә торып, күзәтеп.

## Исең китми

Гел пышылдый, нидер сөйли диңгез
Аңлыйбызмы берәр нәрсә без?
Хикмәтме ул, ниме? Һич белмибез,
Тыңласак та бирелеп гәрчә без.

Диңгез — диңгез инде, тынмый-нитми,
Уф та итми... газап чиксәң дә,—
Синең дә бит шулай, исең китми
Бер дә минем исем киткәнгә...

## Кил син миңа

Иртә дә кил миңа, кич тә кил син,
Көндәгедәй бәхет алып кил.
Мин тау икән — син бит тау ишәр сил,
Җилкән икән — әйдәр көчле җил.

Күргән саен миңа өр-яңа син!
Сиңа карап мин дә яңарам.
Күрмәсәм дә, хәер, тоеп яшим,
Рухың белән кабат яралам.

Син Ләйлә, мин Мәҗнүн, якты көнем,
Мин бакчачы, син бер гөл сыман:
Күргән саен күтәрелә күңелем
Синнән алган шигъри тылсымнан.

## Ник карадың икән

Ник карадың, сылу, каш астыннан,
Белсәң иде бу ни икәнен:
Керфекләрең бәхет угы сыман
Йөрәгемә килеп тигәнен...

Карадыңмы: «Чал булса да шагыйрь,
Нәрсә икән диеп уенда?
Җырга дисәң алар инде маһир!
Чыгармасмы минем турымда?»

Шаяным, гел сезне мактап килдем —
Мәхәббәтне, бәхет кошларын,
Әгәр җинсәм — сезнең белән җиңдем,
Сезнең белән китте һушларым...

Соклануым, януым, язуыма
Сез сәбәпче, юк тиң килерлек,—
Тик бер генә карап алуың да
Җанга йөз ел гомер бирерлек!

## Гөнаһ турында

Берәүләр гомер буена
Гөнаһны кылалар да,
Тәңресе төшкәч уена,
Тотына догаларга.

Котылмакчы хәйлә белән —
Аятьләр укып кына:
Сәҗдәгә китеп йөзтүбән,
Иданнәр чукып кына:

«Ярлыка, дип, кичергүчем!»
Без менә үтенмибез,
Ялгыш гөнаһ кылган өчен
Без бик үк үкенмибез,—

Безнең гөнаһлар ялганнан,
Явызлыктан тумады,—
Ул иде тик җанда янган
Көчле дәртләр уйнавы!

Нигә итәргә ди аһ-ваһ,
Ник борчырга үткәнне:
Кем белгән яшьлектә гөнаһ
Я савап ни икәнне?!.

*

«Картлык — надан өчен гомер кышы,
Голәмәгә — урып-җыю вакыты»,
Дигән Вольтер. Мин дә хуплыйм шушы
Алтын көзне — җимеш җыяр чакны.

*

Сорасалар: «Ничек казандың, дип,
«Мәмлүк» атын, ерак гасырда?

Аргы бабаң әйтер: «Йосыф та бит
Колдан солтан булган Мисырда».

❁

Хәят нәрсә? Бәхет, шатлык асылда ул,
Михнәтенә түзалмасаң — асыл да үл!

❁

Кайчак шулай хәтта бик хөрмәтле
Хәкимнәр дә чыга чыгырдан:
Бөек дәүләт төзгән Мөхәммәтне
Вольтер да бит «юкка чыгарган». [1]

❁

Замандашлар ташлап китә бер-бер артлы,
Ятим итә кызганмыйча Нури картны.
Тик аңламыйм, язмыш озын гомер биреп
Әллә дошман миңа, әллә минем яклы?..

## Ялган ялганны тудыра

«Сезнең эшме бу?» диделәр.
Тандым:
«Юк!» дидем, ялганладым.
Вакыйганы бүтәннәргә сөйләп бирдем.
Сорадылар: «Ә син нәрсә дидең?»
Нәрсә диим: «Минем эш! дип җавап бирдем!»
Шулай итеп туды яңа ялган,—
Ялганларга мәҗбүр булдым оялганнан...
Хәзер ике ялганым да калмый артымнан,—
Нишләргә дә белмим оятымнан.

## Яшерен-батырыны юк

Мин бәхетле булмый кем бәхетле булсын?!—
Үз көнемне үзем күрәм,— көн күрсәтсәләр.
Үз саулыгымны үзем саклыйм,— саклатсалар,
Теңкәмә тимәсәләр.
Үз аякларым белән йөрим,— таяк белән.
Үз сүземне сөйлим,— «Чамалап сөйлә!» димәсәләр.

---

[1] Вольтер үзенең «Фанатизм, яки Мөхәммәт пәйгамбәр» дигән әсәрендә (1743) аның фәкать кире якларын гына күрсәтергә тырышып язган.

Үз акылым белән эш итәм,— акыл биреп аптыратмасалар.
Гел елмаям,— турсайтмасалар.
Үз кайгымны кайгыртам,— кайгыртмасалар.
Үз китапларымны чыгарам,— нәшриятта чыгарып торсалар.
Шатланып йөрим,— йөртсәләр.
Дарулар да эчәм,— башкача имли белмәсәләр.
Кешеләргә тимим,— тимәсәләр (хәер, тисәләр дә).
Бер дә аптырамыйм,— аптырауларга инде тәмам тук.
Яхшы кешедән дә яхшы кешем юк, яманда эшем юк!
Яратам,— яратуымны яратмасалар да.
Карыйм гүзәлләргә — җиңемнән тартып бик үк каратмасалар да...
Алдашмасалар ышанам,— ни әйтсәләр дә.
Бәхетлеләргә карап мин дә бәхетле,— бәхеттән азмасалар.
Түрәләргә дә сүзем юк,— түрәләнеп юлдан язмасалар.
Дошманнарны да хурламыйм,— чаттан посып атмасалар.
Кайбер «тел осталарының» телләрен яратмыйм,—
редакторлар яратсалар да.
Елакларны кызганмыйм,— еласалар да.
Гайбәтне тыңламыйм,— сөйләсәләр дә.
Юлымнан туры атлыйм,— юл бирмәскә теләсәләр дә.
Күп сөйләгәннәрне яратмыйм,— күп белсәләр дә:
Фикерең аран булсын, телең саран булсын!
Күрмим,— арттан шымчылар сөйрәлсәләр дә.
Ишетмим,— берәүләр хурлап сөйләсәләр дә.
Баш имәдем — июемне теләсәләр дә.
Тик берәү алдында гына мин баш иям.
Ул — минем мәңге бакый Иям!
Ул — минем туган халкым!
Шулай булгач,
Мин бәхетле булмый кем бәхетле булсын ди тагын!

*1986—1987*

## Ренат Харис

❁

Уйларымны ихлас килеш
сүзгә саласым килә —
башлап язучы яшь шагыйрь
булып каласым килә,
илле яшемә җиткәч тә,
алтмышымны үткәч тә,
котылгысыз куркыныч көч
басканда да үкчәгә...
Бу сүзләрем көнгә ярау
булып тоелыр кемгәдер.
Бәлки...
Ләкин көннән өстен
шагыйрь җирдә меңгә бер!
Башлап язучы яшь шагыйрь
нәкъ менә шул исәптә —
теленә килгәнне әйтеп,
гасырларны кисәтә...

### Гаеп кояшта...

Кичә аяклар җирдә иделәр...
Без салган эздән ямьсез көн шыткан...
Бүген аяклар җиргә тимиләр —
Заман якадан йомарлап тоткан,
күтәргән күккә, караган күзгә...
Салырмы суга, бәрерме ташка?.
Ә бездән чәчри кичәге сүзләр:
гаеп кояшта... Гаеп кояшта...

### Берсенә дә...

Яңа Заман килә... Килә җәя җәеп...
Күзебезгә терәп ата бик күп гаеп.
Урамнарда йөри күпме тере мәет!
Берсенә дә чыкканы юк моңлы бәет,
берсенә дә!..

---

Ренат ХАРИС *(1941) — шагыйрь, соңгы елларда татар һәм рус телләрендә чыккан «Гүзәл гөмбәз», «Ант суы», «Покатился мой клубок» («Советский писатель»), «Присядь к очагу моему» («Современник», М.) һәм башка китаплар авторы. Казанда яши.*

## Үзгәрәбез

Үзгәрәбез... Әйе, үзгәрәбез...
Үзгәрешләр шушы бүгенгә:
уйга ирек бирдек — ул сугыша,
телгә ирек бирдек — сүгенә,
каргый, әрли, вөжданыңа тибә,
чәнчи, сүтә, кисә, фаш итә...
Керфекләр дә тешкә әверелде,
күзләр сорый: «Кемне ашыйк, ә?..»
Телебезнең кырыс һәм давыллы
эчкәресе чыкты тышкары,
әйтерсең лә телдә язлар үлде,
җәйләр үлде — зәһәр кыш бары!..

Матур сүзләр тел читендә ауный,
әйтерсең лә юллар читендә
самосвалдан сибелеп калган ашлык!..
Сөйләшәбез кебек ят телдә...
Җылы сүзләр күбрәк чыксын диеп
киң ачылган урыс капкадан
нигә әле суык шаулап ага —
күңелнеңме миче якмаган?..
Ил йөгергән юлда өермәләр
күп нәрсәне читкә чөерә...
Ихлас сүзгә әле җылы җитми...
Зинһар, илем,
суык тидермә...

## Ачыш

Гаҗәеп ачыш ясадым...
Кинәттән... Бер дә юктан...
Тукай сүзендә йакут бар,
йакут сүзендә — Тукай!

Асыл шагыйрь асыл мәгънә
асрыйдыр исемендә...
Тукай дисәм балкып ала
асылташ хисе миндә...

## Ключарев

Көйләренә аркау җебе итте
Оренбурның дала җилләрен.
Урал тавы итәгендә үскән
якты, гади, горур гөлләрнең
тажларыннан тамган чыклар чыңын
кушып үрде аркау җепләргә,
Кырлай урманнары пышылдавын
аккорд итеп кушып җибәрде,

һәм өстәде халык моңнарыннан
берәмтекләп җыйган табышын —
Идел агышының татар җире
белән сөйләшүе тавышын!
Илгә нинди көйләр бүләк итте!..
Һәрбер көйдә гөлле, көләч рух.
Ул — Казанның җырлы бер символы,
Александр ага Ключарев!

## Шомырт суыклары

Шомырт чәчәге кар кебек...
Әллә суык шуңарданмы?
Әллә агач тамырыннан
кыш китәргә соңгарганмы?

тамыр төбендә калган кыш...
арыганмы давыллардан?..
Ел фасылын тоткарларлык
ни хикмәт бар тамырларда?..

Йорт казына гашыйк аккош
аерылгандай төркеменнән,
ишетмичә-тыңламыйча
киңәшләрен беркемнең дә

Кыш кинәт исенә килгән...
Чәчәк булып күккә аша...
Чәчәктә, фәкать чәчәктә
тамыр күк белән тоташа.

# Нинди сүзләр

— Нинди сүз куәтле була?
— Уйга дәрман салганы.
— Ә нинди сүз үткер була?
— Җанны телеп алганы.

— Нинди сүзләр авыр була?
— Күз яшь булып тамганы.
— Нинди сүзләр батыр була?
— Фаш иткәне ялганны.

— Нинди сүзләр салкын була?
— Дөреслекне танганы.
— Нинди сүзләр җылы була?
— Сиңа багышланганы.

— Ул сүзләрне кемнәр таба?
— Шагыйрь таба... Янганы:
бер саф сөю, мең хыянәт
татып исән калганы!..

*

Аруның да була төрлесе:
була сафы, була керлесе,
аркада тоз булып катканы,
шәүлә кебек җиргә ятканы,
сынган сука кебек тынганы,
хәлсез дулкын булып туңганы,
керфекләргә герләр элгәне,
каргыш булып канга сеңгәне,
кискән имән кебек ауганы,
сулыштан дым савып алганы...
Аруларның була төрлесе...

Аруларның була төрлесе...
Арада бар берсе — серлесе:
изге гөнаһлысы, яктысы,
гүя сүнгән назның чаткысы,
талган елмаюда калганы,
бәхет булып йөздә янганы,
йөрәккә аһ булып кергәне,
җырга тәмле сүзләр биргәне,
әйләнгәне олы табышка —
«Кабатлансын!..» дигән сагышка...
Аруның да була төрлесе...

*

Түбәнсеткән,
горурлыкны сыткан
газаплар да йөрттем йөрәктә...
Шул газаплар минем күзләремне
күккә карамаска өйрәткән.

Керфекләрем, туфрак сөрә-сөрә,
бетә язган чакта ашалып,
йөрәгемнән теге газапларны
беравыкка алып ташладың,

һәм тутырдың аңа яңа газап —
һәрчак сине күрү теләге...
Ә бу теләк күз нурымны минем
йолдызларга илтеп терәде:
утлы йолдызларга,
бозлыларга...

Яндым-көйдем, туңдым-өшедем...
һәм мин хәзер
чын бәхетнең газап
икәнлеген белгән кешемен...

Котылырга телим мин аңардан —
риза, риза бөтен тәүлеккә...
Ә ул миннән
сиңа багышланган
шигырьләтә генә түләтә.

❁

Кояш бата зәңгәр тау артына...
Яшел алан моңга күмелә...
Сагынудан шашам бугай инде —
Син кайларда хәзер?
Кем белән?
Күзләреңнең төпсез карасына
кемнәр бата?
Алар чыгамы?..
Кулда каләм.
Телдә каргыш... Язмыйм...
Нигә әле шулай чыдам мин!
Күңелемне кара шөбһә булып
талый, талый изге көнләшү.
Мин чынлап та үлеп гашыйк, ахры,
юктыр бугай җирдә тиңдәшем...
Мин шулай да
яңа Фәрһад түгел,
яңа Мәҗнүн, Йосыф түгелмен...
Каләм очындагы кара бит мин —
утлы шигырь булып түгелим...
Кояш батты зәңгәр тау артына...
Яшел алан моңга күмелде...
Күзаллагыз, сөеклесез калып,
төнгә әверелгән күңелне.

## Фәкать шулай гына!

Еласам — хәлдән тайганчы...
Көлсәм — моңсыз калганчы...
Сөйсәм — үзем җан биргәнче,
синең җанны алганчы!..

Көнләсәмме? — Көл булганчы...
Назлатсам — эрегәнче,
төсе үлгән чәчләремнең
чын төсе терелгәнче!..

Ялварсам — эзең үпкәнче...
Тибәрсәм — чикне үтеп:
гомер буе эзләсәм дә
таба алмаслык итеп...

# Гәрәй Рәхим

## Туган якта

*(Бернинди шаярусыз)*

«Яшь камышлар арасыннан
Зәңгәр күзле су карый...
Болыннарда билдән печән...
Яна кыргый кашкарый»...
Болар берсе дә юк монда,
Бары да беткән инде.
Без казыган чишмәләрнең
Улагы кипкән инде.
Ташусыз, дулаусыз гына
Килә тактичный язлар.
Ак булып туып, нефтьтән
Карала монда казлар.
Колыннар юк — колхоз күптән
Айгырлардан ваз кичкән.
Кайгылар бер дә калмаган,
Шатлыгы да аз икән.

Сары балчык...
Тузанлы юл...
Көтү таптаган ярлар...
Нахал оныклар үстерә
Без сөйгән асыл ярлар.

## Бөек хаклык

Төннәр буе елап чыгасыңмы?..
Саныйсыңмы һәрбер таңны да?..
Сагынуы авыр...
Әмма яшерен
Сагынуы авыр тагын да.

Бу яшеңдә инде яшерен сөю,
Күз яшьләре сыгу килешми...
...Олыгаеп беткәч йөрәк шундый
Халәт алды килә-килешли:
Рухларыбыз бер дә кебек,
Ләкин,
Алар яши ике тарафта.
Мин үземчә парлы ялгыз монда,
Парлы ялгыз
яңә
син анда.

Хәзер инде шундый чорга кердек —
Үсеп җитте бала-чагалар...
Без сокланган сулар бу дөньяның
Тегесенә табан агалар.

Безнең юллар инде кереп бара
Теге дөнья түренә табан.

---

Гәрәй РӘХИМ *(1941) — шагыйрь һәм прозаик. «Вәгъдә», «Моңнарым», «Гөрләвек» һ. б. татар һәм рус телләрендә дөнья күргән егермегә якын шигырь, проза китаплары авторы. Ул — ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Акылыбыз инде менеп җитә
Тәҗрибәнең үренә табан.
Ә шулай да, сабый балалардай
Җырлый,
сыкрый,
елый көнелләр...
Бөек хаклык:
Көнелләр бит алар
Безнең кебек үк карт түгелләр.

## Ватан

Учларымда «леп-леп» канатларын
Кагып торган кызыл күбәләк —
Ул — Ватаным!..
Минем илем дә бит
Күбәләктәй нәфис, түгәрәк.

## Космостан караганда

*Космонавтларның Йолдызлы шәһәрендәге музейда булганнан соң.*

Караңгы кич белән ак таң янәшә,
Ач чүл белән шау-океан янәшә.
Моннан карау гаҗәп икән дөньяга —
Мәскәү белән Вашингтон янәшә.

## Ерактан хат

Анда сездә көннәр ничек тора?
Мин сагынган сылу Казанда?
Җавап көтмим,
белеп торам инде:
Кара күзләрдә дә яз анда.

## Сулыш

*«Ә хәзер тирән итеп сулагыз»*

(Радио буенча иртәнге зарядка тапшыруыннан)

Тирән итеп сулый-сулый
Эчтә тыннар калмый.
Ә берәүләр гомергә бер
Тирән сулыш алмый.

## Хәсән Туфан елмаюы

Гомерендә бер шигырь дә язмый
Гел елмаеп кына торса да —
Туфан Туфан булып калыр иде,
Мәңге калыр иде дөньяда.

❁

Дәвер сыртын тунап барган ил камчысы —
Кайбер шагыйрьләрнең булды илһамчысы.

## Шундый бер хәл

Төлкеләрем күзәтәләр артымда,
Бүреләрем улап тора алдымда —
Тик боларны күрмәгән дә шикелле
Аргамагым дулап тора җанымда.

## Күңел

Җыр теле күңел.
Иске җыр түгел,
Яңа җыр теле
Бу иске күңел.

❁

Агачларның яшел яфраклары —
Ул аларның яшел фраклары.

## Иртә

Күп нәрсәне мин бик иртә, яшьли таптым.
Тәмәкене, шәрабларны яшьли каптым.
Кырык биштә инде мин чын бабай булдым —
Шунда туды кызым кызы — балдан татлым.

## Чама кирәк

Бу дөньяда һәр нәрсәнең бер рәте бар,
Күрче — җәен арба, кышын чана кирәк.
Яшәү татлы...
Тик шулай да җир йөзендә
Күпме яшәү өчен бер чик, чама кирәк.

# Зиннур Мансуров

## Җир җимертеп яшәү

Дөнья йортын азлап-күпләп
ничә буын җимерттек!
Күңел кошы кардәшләрен
җиргә күпме җим иттек.

(Кысылганнан кычкыручы
шүрәлене кем яклар?)
Кисеп оҗмах агачларын,
бастык Кызыл китаплар.

Һәм салават күпереннән
агулыйбыз... зиратны.
Халык түккән кан-яшь үчен
кайтарырга җир хаклы!

Шапырынмыйк, шагыйрькәем —
«чыктан куркыр чак» житкән.
Мескен кошлар оя кора,
үреп тимер чыбыктан.

Язып кына файда килмәс
язган чакта җир-көннән...
Ниргәләрне суырабыз
фани дөнья йортыннан.

Яэҗүҗ-мәэҗүҗ безнең кулдан
тора һаман җим көтеп.

— Хәлләр ничек, җирдәш туган?
— Яшәп яту җимертеп!..
Әлегә...

## Бульдозерга һәйкәл

Кайсындадыр дөнья каласының
кыяташка аны куйганнар.
Хәйран калдым, юкса, һәйкәлләрнең
әллә нинди{лә}рен күргән бар.

Бульдозерга ничек биргәннәрдер
данлау баскычының түр башын?!
Кешеләргә таулар күчерешеп,
каһарманлык кылган, күрәсең.

Шанлылыгы мине шикләндерми —
хәләл хезмәтенчә хөрмәте.
Әмма...
Иҗтиһатны кайчак илаһлыкта
күрә башлый корыч чор аты.

Ясиннарны күпме ясаттырды
пәри туен — соңгы өй туен!
Такташыбыз торган ташпулатны
вәхшиләрчә вәйран итүен
хәтерлимсең, хаким, хәтерлимсең
мәчетләрнең... мордар китүен...

---

Зиннур МАНСУРОВ *(1949) — шагыйрь, «Кул бирам», «Йөз суы» һәм рус телендә «Меңьяфрак» (Тысячелистник) исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Бульдозердай вандал булдыклыга
өлгер генә, кешем, эш биреп.
Башбаштаклык безнең башыбызны
төшермәсен җирдән эшереп.

Хөрмәтләүгә лаек хезмәтләрен
танымадым түгел һич кенә.
Утырттырмыйк аны узындырып
хәтер хәрабәсе өстенә.

## Әйләнмә урындык

Нигә шуны кеше кулы
ясамаган борын ук?!
Сынап сыйлый, сынап сайлый
әйләнмәле урындык.

Түмәрендә тамырланган
эшкуармы? Яшьме син?
Әйләнчеккә әйләндерә
әйләнүчән башлысын.

«Кресло... дөнья... кендек!...»— диеп,
уйлаучылар да була;
әйләнәли әйлән-бәйлән
уйнаучылар табыла.

Мөритләре майлаштыргач
Җирнең шушы «күчәр»ен,
узаманнар узынадыр
сизеп илаһ көч барын.

Кыска юлны әйләнечкә
әйләндерә кем диген?
Хәтта халык башын бутый
кечтек кенә «кендег»ең...

Башкайларны әйләндерә
урынбиләр әйдәүче.
Әйле-шәйле яшәүләрнең
хакыйкате әй ачы!..

Әйләнчеккә әйләнгәнне
айнытырга ырым юк...
Сынап сайлый, сынап сайлый
әйләнмәле урындык.

...Түнтәрелгән түрәләргә
тәкъдим итмим... төп башын.
Хәер, анда Җирең белән
әйләнгәнне тоясың.

## Бәдәл

Инде бездә күптән бетте бугай
кеше өчен хаҗга барулар.
Башка төрле уйлап баккан чакта,
бәдәлчелек әле бар ул, бар.

Яклаучының була көнлекчесе,
илаһ эшкуарның бар колы.
Фаворитлар данга адарына
бәдәлчедәй бәндә аркылы.

Күңелләрен изге ялганнарга
күнектергән затка аз болар!..
Кеше өчен нотык кына түгел,
булды хәтта китап язулар.

Чүпрәк ашап туймас бозау төсле,
күндәмнәре һаман кул ялый.
Башка кеше кылган гөнаһ өчен
хәтта утырулар булгалый.

Штрафнойга китте шагыйребез[1]
бронь сатып алган зат өчен...
Мәккәсенә болай баручыны
хаҗи диеп ничек атыйсың?!

Мондый чакта күпме тора икән
савап җыюларның әҗере?
Фидаилар өчен фидакарьлек
күрсәтергә бармы әзере?..

Бәдәлчеләр... Хәзер бюрократлык
битлегендә яши шул алар.
Башкаларның басып башларына,
пәйгамбәрлек итмәк булалар.

Канәгатьлек белән кылтаялар:
«Бирешергә әле исәп юк...»
Бәдәлчелек бездә бетмәячәк,
күрсәтелгән чакта ишәклек.

---

[1] Репрессиягә дучар ителгән Фатих Кәримнең сугышка китүе күздә тотыла. Автор.

...Берлиннарны алган баһадирлар
бердәм әйтте шундый сүз миңа:
«Халкың өчен бөтен изге эшне
башкарырга язсын үзеңә!..»

## Чәч алу

Сөйләмәскә иде исәпләрем,
искә төште менә тагын да.
Әти картның, кайтып, чәчен алдым
үлем көтеп яткан чагында.

Никрутларча тели алдырырга —
үзе, элеккечә, җор тагы.
«Менә шулай,— ди ул,— менә шулай
тузып бетә гомер йомгагы...»

Бүген язмыш хет бер генә тапкыр
сыйпап алса иде чал баштан!
Чуалышып беткән чәчләренә
еллар җиле кереп адашкан.

Белештерми торган чәчтараштай
ике учма кистем як-яктан.

Беренчесен бабам үтерелү,
икенчесен... сугыш агарткан.

Чәчләренең тонык яктысында
күрәм кара еллар шәүләсен...
Минем иңнәр тотып тора алмас
дөнья белән тулы чал башын.

...Ачылышып китте тәрәзәләр —
зәһәрләнеп, ахры, җил бәргән.
Соңгы тапкыр чәчен сыйпар өчен
әллә аны язмыш җибәргән?!—

Дөньядагы бөтен бәйләнешен
инде өзә барган чагында...
Сөйләмәскә иде исәпләрем,
искә төште менә тагын да.

## «Кем сукты?» уены

Дискотека белән дуслашкачтын,
яшьләр сине, ахры, онытты.
Өлкәннәрнең исә йөрәкләре
өзгәләнә кайчак: «Кем сукты?»

Уйламыйча хәзер уйнамыйлар,
бераз башкачарак алым да.
Сугучысы синә сулагайлап
сылый алмый халык алдында.

«Кем сукты?»

Каһкаһәле ымны кыйналучы
йөрәк үзе генә ишетә.
Сволочьлар сугу сәнгатенең
серен яхшы белеп эш итә.

Сугучылар өрәк сурәтендә
биешәләр чыгып алдыңа.
Этлекләрен типик битлекләргә
төрүчене танып кал димә.

Елатырлык итеп елмаялар
мәркәздәге мәшһүр мимнарча.
Игезәктәй охшаш йөзләреннән,
күрәм, кешелекле «Мин!» кача.

Кайтаваздай һаман кабатлана
кара донос кебек «Кем сукты?»
Сиздермичә арттан сугулары
йөрәкләрне ай-яй йончытты!

«Кем сукты?»га җавап эзләгәндәй,
эзәрлекли авыр уй мине:
зыялылар күбрәк оештыра
«культурасыз» мондый уенны.

«Кем сукты?..»

Суга бирсен, әйдә, суга бирсен,
әгәр булса безне җиңәр җан.
Яхшылыкның ап-ак фәрештәсен
бәреп төшертмәбез иңнәрдән!

**Рафаэль Мостафин**

# КАБАН КҮЛЕ СЕРЛӘРЕ

ТАРИХИ-ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬ

## 1

*Шул заман кем килде Мәскәү гаскәре*
*Бу Казанга туп атарга башлады.*
*Шул вакыт ханнар, вәзирләр качтылар,*
*Барча малны ушбу күлгә сачтылар.*
*Сачтылар алтын, көмешнең һәммәсен,*
*Ягъни «безнең мал кешегә калмасын».*
*Шул заманнан бирле кем алтын, көмеш*
*Күл төбендә һич хисапсыз күп имеш...*

Габдулла Тукай.

Бу вакыйга алтмышынчы еллар ахырында, мин «Казан утлары»ның баш редакторы булып эшләгән чакта булды. Кабинетыма бер бик сәер карт килеп керде. Башында кырпу бүрек, аягында тузып-кыршылып беткән читек-кәвеш. Кәзәкие дә революциягә кадәр үк тегелгән кебек...

Карт, билен тоткалап, аһ-ваһлап, тәкъдим ителгән урындыкка килеп утырды. Башта гаилә хәлләремне, балаларымның булу-булмавын, эти-әниемнең сәламәтлеген сорап белде, аннан, бермәтекләп, аларның һәркайсына дога кылды. Шуннан соң гына төп сүзен башлады.

Сүзе Кабан күле турында икән. Иң элек карт минем бу мәсьәләгә мөнәсәбәтем белән кызыксынды. Мәшәкатьләрем житәрлек иде, шунлыктан, артык җәелмичә, икеле-микеле генә җавап кайтардым.

Кабан күле, әлбәттә, Казанның горурлыгы, тарихи бизәге... Әйе, күл элекке данын югалта бара. («Югалта гынамы? Күз алдында чери, үлеп бара»,— дип бүлдерде мине карт). Ләкин... Ни хәлең бар — прогресс өчен бәһане зурдан түләргә туры килә... Ә күлне чистарту өчен миллионнар кирәк. Аны каян аласың?..

Шунда карт серен ачты. Хәйләкәр елмаеп, чепи күзләрен елтыратып бераз карап торгач, ярып салмасынмы?!

— Миллионнар, тыныч кына, күл төбендә ята бирә.

— Казан ханлыгының хәзинәләре турындагы риваятьләрне күздә тотасызмы?

---

Рафаэль МОСТАФИН *(1931) — тәнкыйтьче һәм публицист, филология фәннәре кандидаты. «Муса Җәлил эзләре буйлап», «Диңгез көндәлеге», «Өзелгән җыр эзеннән» һәм башка дистәләгән китаплар авторы, Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге бүләге лауреаты. Казанда яши.*

Бабай тантаналы төстә көлеп жибәрде:

— Кемгәдер, бәлки, риваятьтер... Әмма минем иманым камил. Сезнең алда — чын дөреслекне белүче бердәнбер кеше. Асылда, мин шул хакта сөйләшергә килдем дә. Исмәгыйль Әжемов булам мин,— дип дәвам итте карт.— Бу исем сезгә мәгълүмме?

Кайсыбызның гына Әжемнәрнең борынгы нәселе турында ишеткәне юк икән! Алар акчасына салынган данлыклы мәчет Казанда иң матур биналарның берсеннән санала...

— Шул-шул,— диде карт горур кыяфәт белән, җавабымны алгач, һәм, авыз ачарга да ирек бирмичә, борынгы исемнәрне тезеп китте. Мин аларның кемлеген искәреп өлгерә алмадым. Турысын әйтим, артык игътибар да итмәдем. Ярыйсы ук буталчык сүзнең асылын аңлап өлгергән идем инде: Исмәгыйль бабай ханнар хәзинәсе турындагы мәгълүматлар тапшырылып килгән шактый озын чылбырның соңгы буыны, «чыбык очы» икән.

Карт тыңлаусыз бармаклары белән төенчеген чишә башлады. Берничә папка, ә алардан, карап торуга, бик борынгы кәгазьләр килеп чыкты. Саргаеп көрән төскә кергәннәр, почмаклары сынган... Чит-читләре янганнары да бар. Аңлавымча, монда әлеге гаилә әгъзаларының хәзинәгә кагылышлы васыятьләре, хатлары һәм башка төрле язмалар тупланган.

Карт катлап-катлап төрелгән, таплы зур кәгазьне аеруча бер саклык белән җәеп салды. Ул аны аерым кисәкләрдән җыйды дисәң дә була, чөнки кәгазь бөкләнгән урыннарыннан ертылып ук чыккан иде. Кәгазьгә баштүбән торган агачка охшаш рәсем төшерелгән. Ботакларга, алма кебек, төрле төстәге түгәрәкләр тагылган. Кайбер ботаклар үсүдән туктап калган. Күбесе исә тармаклана бара. Бу — шәҗәрә. Шәҗәрәләр күргәнем бар анысы, әмма мондый да борынгыны һәм бу кадәр дә пөхтәләп-җентекләп төзелгәнен беренче очратуым иде.

— Бусы,— Исмәгыйль ага сөяк күк сары бармагы белән өстәге түгәрәкләрнең берсенә төртте,— Казанның соңгы ханы Ядгәр яраннарыннан. Укымышлы кеше — Кол Шәриф[1] мәдрәсәсендә гыйлем алган...— Дөрес аңлаган булсам, бу кемсә, хәзинәне яшерүдә катнашмаса да, серне белгән, әмма бәрелешләрнең берсендә һәлак булган.

Картның әйтүенчә, хәзинәнең төгәл урынын нибары ике яки өч кенә кеше белгән, тик берсе дә исән калмаган. Килмешәк дип, серне Ядгәр ханга да ачмаганнар. «Һәм бик дөрес эшләгәннәр,— дип өстәде карт,— ник дисәң, ышанычлы кеше булмаган ул. Шәһәрне саклый алмаган. Әсир төшкән. Белгән булса, язмышын җиңеләйтү өчен, серне һичшиксез чишкән булыр иде...»

Исмәгыйль ага сәгатьтән артык утырды, күп нәрсә сөйләде. Хәзер, менә егерме ел үткәч, кайта-кайта әңгәмәбезне хәтердә яңартам, аннан яңа мәгълүматлар табарга тырышам.

Урынын анык белмәсә дә, Исмәгыйль ага хәзинәне, күлнең төньягында, «Спартак» комбинаты тирәсендәрәк булырга тиеш, диган иде. Аны табу өчен башта Болак агып чыккан җирдән ерак түгел Кабанга койган инеш янына басарга кирәк булган. (Хәзер анда төзелмичә калган бинаның субайлары ыржаеп тора). Аннары күл буенча берничә ук атымы ара узарга, ярдагы билгеле бер урынны табарга, каршы ярдагы икенче бер шартлы урынга йөз төбәп, берничә дилбегә буе араны йөзеп үтәргә... Хәзинә күлнең нәкъ менә шул турысында ята инде! Әмма аны, тагын бер хәйләне белмәгән килеш, кулга төшерермен димә.

Исмәгыйль ага, күзләрен елтыратып, хихылдап алды:

— Безнең бабайлар аңгыра булмаган шул!

---

[1] Кол Шәриф — XVI йөзнең беренче яртысында яшәгән галим, дин әһеле. Казанның ул чордагы иң зур һәм атаклы мәдрәсәсе аның исемен йөрткән. 1552 елда һәлак була.

Исмәгыйл Әҗемов әйтүенчә, казна өч өлештән торган. Беренчесе— акча суга торган алтын, көмеш. Картның сүзләренә караганда, Уралда ханлыкның көмеш чыгара торган урыннары булган, Чулман һәм Идел буйлап алтын-көмеш Казанга китертелгән.

Икенчесе — казнада булган акча. Ул чакларда кәгазь акча чыгарылмаган, гамәлдә алтын, көмеш тәңкәләр йөргән: төрек, гарәп дирһәмнәре, фарсы, Мисыр, Көнбатыш Европа тәңкәләре, рус гривналары... Шул акчага бернichә меңле гаскәр тотканнар, хан вәзирләренә һәм ялчыларына хак түләп торганнар. Акча махсус ташпулатта саклаңган, аның өчен хан казначысы башы белән җавап биргән.

Казнаның төп өлеше ганимәт малыннан, ханга бирелгән бүләкләрдән, үз осталары ясаган алтын әйберләрдән тупланган: әстерхан чикләвеге хәтле зәбәрҗәтләр, шәрыкта да сирәк очрый торган асыл ташлар, куе кызыл якутлар, төсен үзгәртүчән серле ташлар, энҗе белән чигелгән калфаклар, алтын белән бизәлгән камәрләр, якут белән зиннәтләнгән хәнҗәрләр, фил сөягеннән ясалган тартмалар, алтын тәлинкәләр, комганнар, йөзек-балдаклар, муенсалар... Карт тәмам әсәрләнде, йөзе үк алсуланып китте, күзләре үзе тасвирлаган асылташлар сыман елкылдый башладылар.

Аеруча зур һәм кыйммәтле асылташларның үз исемнәре булган. Мәсәлән, Сөембикәнең йокы бүлмәсендәге алтын шәмдәлдә [1] Солтан исемле искиткеч зур, матур асылташ беркетелгән булган. Хан хәзинәсенә аның яраннары да якын килә алмаган. Әҗемов әйтүенчә, бу байлыкка хан үзе дә хуҗа булмаган. Әрәм-шәрәм итүчән ханны шунда ук тәхеттән очырганнар...

Сөйли-сөйли кызып киткән картны бүлдереп:

— Сез сөйләгән зиннәтләр чүлмәккә генә сыймас, ул күпме булды икән соң?— дип сорадым.

— Уннарча миллион сумлык!— дип кычкырып җибәрде Исмәгыйл ага.— Тик аларның кыйммәте акча белән генә бәяләнми ләбаса...

— Авырлыгы күпме тартыр икән?

Карт, җилкәсен җыергалап, башын кыегайтып, уйга калды.

— Бер киломы, икеме, өчме?..

— Ниткән кило ди ул? Төгәл үк әйтә алмыйм, тик, шулай да, тулаем авырлыгы уннарча, ә бәлкем йөзләрчә батмандыр [2], дим.

Шушы урында «каптырмакчы» булдым мин аны.

— Андый авыр йөкне камалган каладан ничек алып чыкканнар соң?

Әмма карт ирен чите белән елмаеп кына куйды.

— Камалыш вакытында дигәнне каян алдыгыз? Камалышка кадәр! Аңлыйсызмы? Күтәреп тә түгел, көймәләрдә, бөтен саклык чаралары күреп алып чыгалар. Казан ул чакта авыл чаклы гына бит. Сизүче, бу хакта чышын-пышын сөйләшүче булгандыр, анысы. Тик бераздан пышылдар кеше дә калмый.

— Ярый, калдырыгыз кәгазьләрегезне,— дидем мин, карттан котылыр өчен.— Белгечләр белән киңәшеп карармын.

Әмма Исмәгыйл агай кәгазьләрне калдырудан катгый баш тартты: кемгәдер калдырган булган да, иң кирәклеләре югалган янәсе. Үзе алдында гына карарга рөхсәт итте. Тик... гарәп теле белгечләрен исәп-

---

[1] Сөембикә шәмдәле тарихи чыганакларда да телгә алына. Ул 1223 елда шәһре Болгарда Мөхәммәтсабир ибне Конкарый әл-Шәһриболгарый тарафыннан ясалган.

Бату хан Болгар җиренә бәреп кергән елны Болгарның яшь падишаһы Әхмәт ибне Җаббарның соңгы оныгы Дүрткүз Җаббарый ибне Габделхак аны Казан җирлегендә яшәүче Кабан әмирлеге башлыгы Мөлек Әбүбәкри Җаббарыйга бүләк итеп җибәргән. Бу алтын шәмдәл Казан ханнарының олы улларына күчеп килә торган нәсел малына әверелгән. Шулай итеп, шәмдәл Сөембикә кулына килеп кергән. Шуннан соңгы язмышы билгесез.

[2] Батман — авырлык үлчәме. Бер батманга, төрле вакытта, 64 тән 192 килограммга кадәр кергән.

ләмәгәндә, минем кордашлардан кем генә бу борынгы язмаларны ерып чыга алыр иде икән? Революциягә кадәрге рус газетасыннан кисеп алынган хәбәрне генә укый алдым. Анда әллә Бельгия, әллә Америкадагы бер компаниянең Кабан күлен, бернинди түләүсез, ләмнән чистартып чыгарга тәкъдим итүе турында язылган иде. Бер генә шарт куелган: күлдән табылган һәммә нәрсә компания милкенә әйләнсен. Бабай хәбәргә мондыйрак аңлатма бирде: Әҗемнәр нәселеннән чит илдә яшәүчеләр дә була, шулардан берсе серне саткан булса кирәк. Эшнең хикмәтен чамалаганга, Казан думасы моңа ризалык бирмәгән.

Исмәгыйл Әҗемов әйтүенчә, шундый ук тәкъдим 1926 елда да булган. Америкадагы эмигрантлар Кабан күлендә эзләнүләр алып бару хокукын сорап безнең хөкүмәткә мөрәҗәгать иткәннәр, бер миллион доллар түләү вәгъдә иткәннәр. Монысында да, карт сүзләренә карагандә, Әҗемовлар кулы уйнаган (атаклы фантаст Айзек Азимовның ата-аналары Россиядән 1923 елда чыгып китә).

«Хәзер инде ни эшләргә?»— дигән кебек, карт, миңа текәлеп, туктап калды.

— Тарихчылар белән сөйләшеп карагыз. Алар расласа...

— Рәхмәт. Элек сөйләшкәннәрне дә онытасым юк.

— Нәрсә диделәр соң?

— Байбәтчә, хан калдыгы син,— дип сүктеләр.— Юк хәзинәне эзләү сылтавы белән ханлык идеяләрен яңартырга юл куймабыз! Егерме еллар элек килгән булсаң, бүтән урында һәм бүтәнчә сөйләшкән булыр идек,— диделәр...

Ишектә — инде ничәнче тапкыр!— җаваплы секретарь күренде. Ул, түземсезләнеп, сәгатенә төртеп күрсәтте — редколлегия утырышын башларга күптән вакыт!

Киткәндә Исмәгыйл ага шундый шарт куйды: бу турыда беркемгә дә сөйләмәскә. Ул хәтта суд белән дә янады.

Карт турында мин соңрак та ишеткәләдем. Редакцияләр һәм төрле учреждениеләрнең бусагасын шактый таптаган ул. Тик ханнар хәзинәсе турында бүтән авыз ачмаган бугай. Кабанны чистарту кирәклеген дәгъвалаган. Ләкин тыңлаган кеше сизеп тора бит: бабакай әйтеп җиткерми, җеп очын яшерә. Сүзен артык кызып-үртәлеп яклавы да шикләндерә: ай-һай, үз мәнфәгатен алга куймый микән бу? Өстәвенә аны бабалары яшергән байлыкка ия булу теләге исәрләндергән, дигән хәбәр дә килеп җитеп, картка мөнәсәбәтне кирәкмәгән якка борып өлгергән була. Мескен карттан артында да, алдында да көләләр. Бер редактор, икенчесен кызык итәргә теләсә: «Шул гына хәл итә инде аны»,— дип бүлмәсен өйрәтеп, бабайны шуңа җибәрә. Әҗемов шулай итеп аяклы мәзәккә әйләнеп китә.

Бераздан ул юкка чыкты. Үлгән дигән хәбәр таралды. Күрәсең, ул әҗәлен сизгәнгә үзенең соңгы һәм өметсез йөрүләрен башлап җибәргән булгандыр...

Карт үлеп, берничә ел үткәч, мин ул сөйләгәннәрне таныш тарихчыма әйттем. Кәгазьләр турында да ишеткәч, аңа җан керде керүен. Тик, аларның җуелуын белгәч, «алайса, бигайбә» дигән сыман куллары гына җәйде. Фән бары документларны, конкрет дәлилләрне генә санга суга. Аларсыз картның сүзләре мәгълүм риваятьнең мең дә беренче варианты гына булып кала. Өстәвенә, яшерелгән хәзинәләр турындагы риваятьләрнең исәбе-хисабы юк икән.

Шулай да, Исмәгыйл ага Әҗемов йөрүләре бөтенләй үк бушка булмагандыр. Бу очрашу мине Кабан күленең үткәне һәм бүгенге хәле белән ныгытып кызыксынуга этәрде. Кабан күленең искиткеч бай тарихы, ачылмаган серләре, үз җаны-яме барлыгына инандым. Дөрес, безнең гамьсезлек аркасында күл соңгы елларда үз ямен җуйган, һәлакәт дәрәҗәсенә килеп җиткән. Кайчандыр ата-бабаларыбызны туендырган күл үзе үк хәзер безнең ярдәмебезгә мохтаҗ булып чыкты...


Кабан тезмәсе өч күлдән тора: Түбән (үзәккә иң якын булганга аны Якын Кабан дип тә атыйлар), Урта һәм Югары Кабан.

Әйдәгез, көймәдә Г. Камал исемендәге театр яныннан кузгалып, үзенә күрә бер сәяхәт ясап алыйк. Кузгалып китүгә, иркенлеккә чыгасың, монда киңлек 320 метрлап. Уртага җитәрәк, күл тарая — 180, соңрак 120 метрга кала. Ишеп барсаң, күнекмәгән килеш тирләп-пешеп чыгасың. Түбән Кабанның озынлыгы ике чакрымлап (1850 метр).

«Вахитов күпере»н узгач, ике яктан автомобиль һәм тимер юл дамбалары белән чикләнгән сай гына бугазга килеп керәсең. Сул якта Ботаника бакчасы кала. Әлеге бугаз да «Ботан бугазы» дип атала. Бугазның озынлыгы — 750, киңлеге йөздән алып ике йөз метрга кадәр.

Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан монда тимер юл дамбасы салына. Шул чакта дамбада махсус су юлы — таш торба ясап калдыралар, бугазның үзен турайталар. Бораулап карагач, бугазның табигый юлында ун-унбер метр калынлыкта торф һәм ләм ятуы беленә. Димәк, ул кайчандыр шактый тирән булган (хәзер аның уртача тирәнлеге ике метрдан артмый), ике күл үзара көчлерәк алмашкан.

Тимер юл күпере астыннан йөзеп үткәч, тезмәнең иң зур күле —



Урта Кабанга керәсең. Монда киңлек 170, 320 һәм 580 метрга җитә. Җылылык энергоүзәге коймасы яныннан, аннары өч предприятиенең кайнар сулары агып төшә торган каналлар ягыннан үтәсең. Күлнең бу өлеше иң салкын көннәрдә дә катмый. Сул якта — күмәк бакчалар. Иң биек урында — элекке Архиерей дачасы корылмалары. Ишәсе дә ишәсе әле — күл өч чакрымнан артыкка (3300 метр) сузыла. Унда, күлнең аргы башында түгәрәкләнеп иңгән бәләкәй култык — «Шайтан почмагы»— күренә. Ул турыда киңлеге — ун-унике, тирәнлеге 1,5-2 метр булган монастырь бугазы башлана. Риваятьләргә караганда, аны моннан ике гасыр элек монахлар казыган.

Урыны-урыны белән ишеп яисә колга белән этенеп барып ике чакрымлап юл үткәч, күлләр тезмәсен Куйбышев сусаклагычыннан аерып торучы дамбага килеп терәләсең. Сунын артыгын суыртучы насос станциясе шушында урнашкан.

Ярты чакрымлап кире кайтып, йөз илле метр чамасы җәяү үтик әле. Карашларны рәхәтләндереп тагын бер киң сулык ачыла: Борис-

ково Кабаны. Озынлыгы — бер километр чамасы (930 метр), киңлеге өч йөз метрлап. Күл кавын формасында дияргә була, әмма бу «кавын»-ны күреп житкерү өчен каршы яктагы текә ярга менәргә кирәк.

Югары Кабан калган ике күл белән тоташмый. Табигатьнең бу «хатасын» төзәтер өчен Яңа Иерусалим монастыре монахлары без әле генә йөзеп килгән канал-бугазны казыганнар, тик Югары Кабанның суы, кимендә, бер сажинга биегрәк икәнлеген аңлагач, экологик тигезлекне бозарга базмаганнар — тоташтырмый калдырганнар. Якын Кабанның өслеге 56 гектар булса, Урта Кабанныкы нәкъ ике мәртәбә зуррак — 112 гектар, Югарыныкы исә — 25 гектар... Тулаем алганда, күл яссылыгы канал-бугазларны да кертеп, ике йөз гектардан арта.

Кабан системасына кергән күлләр белән беркадәр танышкач, шундый сорау тууы мөмкин: бу күлләр кайчан һәм ничек барлыкка килгән соң?

Каюм Насыйри хезмәтләрендә халыктан язып алынган бер риваять бар. Бу якларга беренче кешеләрне күп еллар элек Касыйм шәех исемле изге бер карт алып килгән, имеш. Тирә-якта бары камышлы сазлыклар, ерып йөргесез әрәмәлек, чытырманлыклар булган. Нигә әле син безне сусыз, черки-чебен арасына алып килдең, дип, халык сукрана башлагач, изге карт, бишмәтен җәеп, дога кылган, ди. Бишмәт салынган җирдә бик тә саф һәм сихәтле күл хасил булган, имеш.

Өстән карасаң, Якын Кабан чыннан да ике җиңе (Болак һәм Ботан бугазы) булган, җиргә җәелгән бишмәтне хәтерләтә. Бу риваятьтә күлгә милли ядкяр, халкыбызның мөкатдәс байлыгы итеп карау сизелә.

Билгесез авторның XVII йөздә язылган «Дәфтәри Чыңгызнамә» дигән әсәрендә (кайбер галимнәр уйлавынча, анда безгә килеп житмәгән, борынгырак татар елъязмаларындагы мәгълүматлар да чагылыш тапкан), хәзерге күл булган җирдән элек Этил суы аккан, соңрак, ул көнбатышка чигенгәч кенә, ярларына кешеләр килеп утырган, дип әйтелә, ягъни Кабан күле Иделнең калдыгы булып чыга.

Галимнәр сүзенә дә колак салыйк әле. Кабан күлләре тезмәсенә житмештән артык фәнни хезмәт, берничә монография багышланган, бу темага ике кандидатлык диссертациясе якланган. Галимнәрнең күпчелеге Кабанны чыннан да Иделнең әүвәлге агыш юлы дип саный. Күлләрнең җиңелчә бормаланган сузынкы формасы да, төпнең елга үзәнен хәтерләткән кисеме дә шушы фикергә куәт өсти. Галимнәр уйлавынча, Идел бу юлдан 30-40 мең еллар элек, бозлыклар бик нык эрегән чорда аккан. Ул чакта елга әлегедән 15-20 мәртәбә киңрәк һәм мулрак сулы булган. Соңыннан Идел үзенә, берничә чакрым көнбатышкарак, бүтән юл яра. Әгәр бу чыннан да шулай икән, Кабан тезмәсенең яше 25-30 мең елларга тигез.

Идел юлын үзгәртсә дә, аның элекке үзәнендә сулы горизонтлар сакланып калган. Кабан суы нык пычрангач, аның тирәсендәге промышленность предприятиеләре бер-бер артлы артезиан коеларыннан файдаланырга тотындылар. Эзләп интегәсе дә юк: бораулап тишкән һәр җирдән саф, салкын чишмә суы бәреп чыга. Бу су, галимнәр фикеренчә, борынгы Иделнең жир асты агымыннан хасил булган.

Соңгы еллардагы тикшеренүләр күлләрнең үткәненә тагын беркадәр ачыклык өсти. Әйтик, 1957 елда Кабан ярларын бораулаган «Гипрокоммунтранс» белгечләре мәгълүматларына караганда, берничә мең ел элек күл, ким дигәндә, ике тапкыр зуррак булган. Якын Кабанның төньяк-көнчыгыш яр сызыгы Куйбышев мәйданыннан да арырак, Свердлов урамы артындагы биек яр буйлап, Суворов тыкрыгынача һәм, калкулыклар тезмәсе буйлап, Борисковога кадәр сузылган. Суконный бистәсе, Һади Такташ урамы кебек урыннарда аерым утраулар калкып торган. Күлнең элекке чикләре, тулысынча диярлек Иделнең борынгы яр сызыгына туры килә.

Күл буйлары аз-азлап камышлыклар, таллыклар, төрледән-төрле яшеллек белән каплана, кысыла бара. Моңа якын-тирәдәге калкулыклардан тау токымнарының юылып төшүе дә ярдәм итә. Ярдагы агачлар киселеп беткәч, бу процесс бигрәк тә көчәя. Хәзер Архангельский зираты урнашкан җир, мәсәлән, кайчандыр күлнең уртасында була. Меңләгән еллар буенча үсә барган торф катламы бирeдә биш метрдан да артып китә. Аның өстенә балчыклы токымнар да утырган.

Күлләрнең кечерәюе әлегәчә дәвам итә, әмма хәзер инде — яшеллек һөҗүм итү сәбәпле түгел, бәлки кешенең эшчәнлеге нәтиҗәсендә. Сай урыннар, яр бормалары тигезләнә бара. Яр буйларында ике метрдан алып сигез метрга кадәр калынлыкта читтән китерелгән туфрак туплаган. Соңгы ун ел эчендә генә дә Якын Кабанның мәйданы берничә гектарга, озынлыгы 50 метрга кимеде. (Башлыча, театр һәм бетон белән нығытылган яр буе төзү нәтиҗәсендә.)

Җылылык энергоүзәгенең юшкын чүплеге Урта Кабанның ун гектар чамасын, башка чүплекләр тагын берничә гектарын тартып алды. Күлгә һөҗүм дәвам итә...

Әмма инде барлык галимнәр тарафыннан да диярлек танылган әлеге фаразга туры килеп бетмәгән нәрсәләр бар.

Аларның берсе күлнең тирәнлегенә бәйле.

Баһадир елгабыз үз юлында «чәчрәтеп» калдырган тугай һәм үзән күлләренең тирәнлеге, гадәттә, нибары өч-дүрт метр була, ара-тирә, генә, анда да бары иң тирән җирендә генә биш-алты метрга житкәннәре очрый. Ун метрлы тирәнлек исә бик сирәк күренеш. Ә менә Урта Кабанның үзәк өлешендәге чоңгыл тирәнлеге 1902 елда 31,3 метр тәшкил иткән! 1976 елга шул ук чоңгылның тирәнлеге инде нибары 24 метрга калган, 1986 елга исә егерме метрдан да кимегән. Ләм утыруның тизлеген күрсәтә торган гыйбрәтле саннар бу.

Якын Кабандагы иң зур тирәнлек 1902 елда — 16,5 м.; ә 1976 елда 15,5 метр булган. Бу турыда боздан торып бораулаганда күлнең табигый төбеннән шул чактагы төпкә кадәрге 15 метрлы ләм катламы алынган. 1986 елга ул тирәдәге тирәнлек 12 метрга калган, ләм катламы исә 18 метрга житкән. Әгәр иң зур күлнең табигый төбенә хәзерге тугыз катлы йортны утыртсаң, ул яртылаш ләмгә күмелер, түбәсе исә судан күренер-күренмәс кенә калкып торыр иде.

Күлнең төбе Куйбышев сусаклагычы төбеннән унбиш метрга диярлек түбәнрәк. Ничек болай була алган соң бу? Эшсөяр Иделебез юкса үзенең яңа юлын меңнәрчә ел буенча казып-тирәнәйтеп торган бит! Моны бары карст процесслары, ягъни җир асты горизонтларында су йөрү үзенчәлекләре китереп чыгарган күл төбе юылу-ашалу, җир убылуларга бәйләп кенә аңлатып була. Бораулау юка гына ком һәм кызыл балчык катламыннан соң, чыннан да, тиз юыла-ашала торган токымнар: көпшәк утырмалар белән аралашкан известьташ һәм гипс ятуын күрсәтте.

Мондый юл белән хасил булган күлләр Казан тирәсендә аз түгел. Әйтик, һәркайсыбыз белә торган Зур Тирән күл, Кече Тирән күл, Зәңгәр күл. Алар бар да тирән, салкын һәм чиста сулы булулары (пычратылмаганда, әлбәттә) һәм бүрәнкә сыман чоңгыллары белән Кабан күленә охшашлар.

Кабанның ашалу-юылуы әле дә дәвам итә. Менә моны раслаучы бер тарихи факт. Урта Кабанның куе катнаш урман сарган гаҗәп матур яр буйлары шушы гасырның егерменче-утызынчы елларына кадәр шәһәр халкының иң яраткан ял итү урыны булган. Ни гаҗәп, адәм кулы тимәгән бу кыргый, саф матурлыкны үз күзләре белән күргән кешеләр дә исән әле. Үткән гасырда бирeдә рестораннары, бильярд бүлмәләре, берсеннән-берсе матуррак беседкалары булган «Аркадия» паркы төзелә. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, монда ял итүчеләр кими. Аның каравы, армиягә товар сатып баеган һәртөрле эш-

куарлар тагын да җиллерәк итеп кәеф-сафа коралар. Бирedә, хезмәт кешесенең нәфрәтле күз карашыннан читтә, алар җилдән килгән акчаларын эчеп, картага оттырып, «сылу»лар куенында назланып тотып бетерәләр.

Һәм менә көннәрнең берендә әлеге «бозыкханә»ләр торган Шайтан почмагының текә ярлары ишелә башлый. Чатыр-чотыр килеп беседкалар янтая һәм суга авып төшә, нәфис павильоннар, челтәрле корылмалар пыран-заран килә. «Ходай орды»,— ди халык...

Сүз уңаеннан, аңлатып үтик — ни өчен «Шайтан почмагы» дидек соң әле? Бу турыда ике караш бар. Берсе күлнең бу тирәсенә хас табигый үзенчәлекләргә бәйле. Бүрәнкә сыман яр, хәтәр чоңгыллар хасил итеп, ун-унике метрга ук төшеп китә. Шуңа күрә монда заманында шактый кеше батып үлгән. Чын-чынлап шайтан почмагы инде! Икенчесе исә үтә гади: революциягә кадәр монда алпавыт Чертов утары булган, шуңа күрә руслар култыкны да «Чертов угол» дип атаганнар.

Шулай да, карст теориясе алдарак бәян ителгән карашларга каршы килми, ә бәлки аларны ачыклый, тулыландыра гына кебек. Күпчелек галимнәр, бу ике фаразны берләштереп, Кабанны үзән-карст күлләре исәбенә кертәләр. Әмма монда да кысага сыймый торган бер факт бар әле. Хәер, башта шул ук күлләр тезмәсенә караган Болакка хас үзенчәлекләрне күреп үтик. Болак — Кабанны Казан суы һәм, аның аша, Идел белән тоташтыру өчен казылган канал ул, дигән фикер киң таралган. Болакның җеп белән сызган кебек туп-туры һәм махсус авыш итеп тигезләнгән ярлы булуы шушы фаразга су коя. Тарихи чыганакларга да мөрәҗәгать итеп карыйк.

Әйтик, 1883 елда Казанда нәшер ителгән «Тәварихе Болгария» дигән китапта татар тарихчысы Мөхәммәтзариф Хөсәен углы тарафыннан язып алынган борынгы риваятьләр китерелә. Шуларның берсендә болай диелә: Габделлатыйф хан заманында (Казан белән 1497-1502 елларда идарә итә) ташу шулкадәр дә көчле була ки, Кабан ярларыннан чыгып, халык башына бәла-каза төшә, күл Идел суы белән тоташа. Ул чакта Болак елгасының казылмаган, сай үзәне генә була. Габделлатыйф хан, казытып, Болакның бер башын Кабанга, икенче очын Казан суына тоташтырта. Шуннан соң шәһәрнең Болак башындагы ягы югары як дип, Болак авызындагы очы исә түбән як дип йөртелә башлый.

Әлеге факт рус елъязмаларында да чагылыш тапкан. Алардан күренгәнчә, канал 1499-1501 елларда казылган, аннан бу эш 1530 елда дәвам иттерелгән. Озынлыгы — ике чакрым чамасы, өске киңлеге —60, су өсте турында 25-30 метр булган каналны казып чыгу өчен ничә мең кубометр җир алырга кирәк булгандыр? Чыганакларда ун мең нугай һәм «күп меңләгән чирмеш»нең канал казуда катнашуы телгә алына. Шулай да, шундый зур каналны бу арада казып бетереп булмас иде,— тарихчы Н. Ф. Калинин әнә шундый фикердә торган. Канал урынында элек озынча күл — үзенә күрә бер кече Кабан булган, дип саный ул. Кайбер хәзерге белгечләр дә шундыйрак фикердә тора.

Әмма бит риваятьләрдә сүз елга турында бара. «Болак» үзе дә төрки телләрдә «елгачык» дигән сүз. Мәсәлән, Раифа урманчылыгында Казаннан егерме биш чакрымда гына Сер-Болак елгасы агып ята. «Болак» атамасы башка җирләрдә дә очрый.

Соңгы елларда үткәрелгән тикшеренүләр канал казылганга кадәр ул урында кыска, ләкин шактый мул сулы елга акканлыгын бәхәскә урын калдырмаслык итеп раслады. Елганың киңлеге 60-70 метр булган, тирәнлеге урта тирәдә 6,5 метрга җиткән (моныcы ләм катламыннан билгеләнә). Якын Кабаннан су алган елга тармакланып Казан суына койган. XVI гасыр башында аның ике тармагы булган. Черек Болак дигәне Кремль үре яныннан ук агып үткән. Зур Болак дигәне икенче култык — хәзерге цирк урыныннан аккан. Бораулау нәтиҗәсендә 300-400 метр чамасы киңлегендәге һәм кайчандыр камышлыклар, куе

таллыклар каплаган сазлык булганлыгы ачыклана. Риваятьләрдә, сиздермичә генә дошман килеп чыкмасын өчен, бу камышлык-таллыкларның әледән-әле чабылып-яндырылып торганлыгы әйтелә.

Кайбер риваятьләрдә исә Болак төбендә, яр буйларында чишмәләр күп булуы искәртелә. Болакның йомшак һәм саф суын эчәргә тоталар. Аны кушып камыр басалар, хан табынына да куела торган бик тә уңган-кабарган калачлар салалар.

Болакның мул сулы булуы күлләр тезмәсенең су җыю мәйданы зур булу (йөз квадрат километрдан артык) белән аңлатыла. Кабан күлләре тирәсендә кул тимәгән кыргый урманнар шаулап торганда, күлләргә исәпсез-сансыз чишмәләр, инеш-елгалар койган. Әйтик, XVI гасыр уртасында хәзерге Пушкин һәм Куйбышев урамнары булган иңкүлектән шактый ук мул сулы инеш аккан. Куйбышев мәйданы булган җирдә ул Гүзәй күленә агып кергән, аннан, хәзерге Тукай бакчасы булган урындагы сазлык буйлап боргаланып ага торгач, Болак башланган җирдәрәк Кабанга койган. Тагын да зуррак икенче агым, Әмә тавындагы күлдән чыгып, Кабанга хәзерге «Спартак» берләшмәсе тирәсендә тоташкан.

Чишмәле Түбән күлдән агып чыккан тагын бер инеш, икенче яктан килеп, турыдан-туры Болакка коя. Әйтеп үтик, җитмешенче еллар азагында күптән онытылып беткән күл урынында җылылык үткәргече салдылар. Күрәсең, сулы катламга да кагылганнардыр, трасса гел су белән тула. Трассага тоташтырылган йортларның идән асларын да су баса, торбалар тутыга, җылылык күпләп әрәм була. Судан котылу әмәле берничек тә табылмый. Үткән белән исәпләшмәүнең гыйбрәтле мисалы бу!..

Болак агымын үзгәртә торган бик тә сирәк елгаларның берсе булган. Ул үзенең бу сәер гадәтен канал казылгач та — безнең гасырның илленче елларына кадәр саклап калган. Ел әйләнәсендә Болак Кабаннан Казан елгасына таба ага (урам исемнәре дә шуны раслый: «Уң Болак урамы», «Сул Болак урамы».) Ә менә язгы ташу вакытында Казан елгасының һәм Иделнең суы Кабан суыннан югарырак күтәрелә. Болак исә бераз гына аптырап туктап торган да кирегә сыптырган.

Су өсте биеклекләренең үзенчәлекле төрлелегеннән килеп чыга бу хәл. Куйбышев сусаклагычы төзелгәнгә кадәр Якын Кабан яссылыгы диңгез өстеннән 49,5 метрга, Ерак Кабанныкы исә 52,5 метрга биегрәк булган. Кыш азагына су тагын берничә метрга кими. Ташу вакытында исә, диңгез өсте белән чагыштырганда, Идел суының биеклеге 56 метрга җитә. Менә шуңа су Болакка ыргыла, аны мөлдерәмә тутыра да, ярсулы шарлама булып, Кабанга ашыга. Дүрт-биш атна буена шулай дәвам итә. Июнь урталарында Болак яңадан «акылга утыра».

Кайбер елларда исә Болак үзенең агышын берничәшәр тапкыр үзгәрткән. Казан елгасы ташыгач, аның суы кайту белән, Болак та элеккечә ага башлый. Аннан, бер-ике атна үтүгә, Идел ташый, Казан елгасының суы яңадан күтәрелә — бар да яңабаштан кабатлана.

Идел суы белән мөлдерәмә тулган Кабан ярыннан ташып чыга, күлнең суы яңарып, сафланып ала. Ташу көчле булган елларда күлләрнең суы икешәр, хәтта өчәр тапкыр алышына. Арткан су Урта Кабанга, аннан ике бугаз аша, Иделгә чыга. Югары Кабан бу күлләр белән тоташмаган, әмма ул да, Дәүләкәй чокырыннан аккан кар суы тулып, ташый, арткан су бугаз аша Иделгә коя. Шулай итеп, өч күл дә елга бер мәртәбә агым сулыга әйләнеп ала. Бу исә үсемлек һәм хайваннар дөньясы өчен менә дигән шартлар тудыра. Кабанның әкияти балык хәзинәләре башлыча шуннан килә. Әмма мондый хәл илленче еллар урталарына кадәр генә дәвам итә шул.

Башта әйтелгәнгә әйләнеп кайтыйк әле: шулай да, Болак нигә көньяктан төньякка аккан соң? Беренче карашка, җавап гап-гади кебек: күлләрнең үзәне Казан суына таба авыш булганга. Әмма Идел бит

әнә капма-каршы юнәлештә ага! Һәм, әгәр дә Кабан — Иделнең иске юлы икән, киресенчә булыр иде: Югары Кабан калган икесеннән түбәнрәк торыр иде (димәк, ул Түбән Кабан була), су, күлләрнең көньяк читеннән агып чыгып, көньякка агар иде.

Монын сере әлегәчә чишелгәне юк.

## 3

*«Бу төбәк шулкадәр дә ямьле вә уңдырышлы... шулкадәр бай ки, андый ямьле вә уңайлы урынны бөтен рус җиреннән таба алмассың, чит тарафларда да бар микән әле».*

Казан елъязмачысы [1]

Күл буенда басып торам.

Тонык соры су. Соры болганчык күк. ТЭЦ морҗаларыннан ургылып чыккан төтен белән аралашкан болыт сәламәләре «Татарстан» кунакханәсе түбәсенә ышкылып үтә.

Баш очымда ала каргалар каркылдый. Тавышлары шыгырдавык, ачулы — мин аларны ияләшкән җирләреннән куркытып җибәргәнмен булса кирәк. Ә урыны чыннан да «шәп»: төрле-төрле ташландык нәрсәләр, чүп-чар, әчеп-күпереп яткан азык-төлек калдыклары. Бераз арырак, суны ярдан аерган сызыкка тияр-тимәс, иеп беткән эт үләксәсе ята. Хәтердә борынгы риваять яңарды.

Кайсыдыр бер ханның яшь килене Казан елгасына су алырга төшкән, ди. Казан каласы ул вакытта әлеге шәһәрдән утыз-кырык чакрым читтә, Казан суының урта бер җирендә булган. Чиләкләре белән биек тауга менеп барганда, килен егылган. Каенатасына ачуы чыгып, әйткән ди: «Тапкан инде шәһәр салыр урын!» Ялчылар бу сүзләрне шунда ук ханга җиткергәннәр.

— Шәһәрне кайда төзик соң? — дип хан килененә сорау биргән.

Килен ике балыкчыны елга буена балык тотарга җибәрергә, алтын балык кайда эләксә, шәһәрне дә шунда салырга киңәш иткән.

Балыкчылар Казан суы буйлап киткәннәр, хәзерге Казан урнашкан урынга килеп җиткәннәр. Хәзер Сөембикә манарасы торган урын каршысында боларга чыннан да алтын балык эләккән. Бу җирнең бер өлеше таулы, икенче өлеше баткак булганга, хан янә килененнән яңа Казанны кайда төзергә иканлеген сораган. Килене болай дип җавап биргән:

— Җиргә күмелгән казанның суы кайда утсыз кайнаса, шәһәрне дә шунда төзегез.

Берничә урынга казанны күмеп караганнар. Бер урында казан суы чыннан да кайный башлаган. Шул урында шәһәр төзергә уйлаганнар. Беренче диварларны салганда хан хезмәтчеләренә болай дип әмер биргән: «Нигез казыганда сезнең янызга беренче булып кем килсә, шуны терелэй килеш кала астына күмегез».

Беренче булып төзүчеләр янына хан малае килгән. Алар аны терелэй килеш җиргә күмәргә батырчылык итмәгәннәр, жәлләгәннәр. Бер эт тотканнар да, аның урынына күмгәннәр. Соңыннан, бу турыда белгәч, хан әйткән, ди: «Димәк, минем шәһәрем дә озак яшәмәс, этләр кулына калыр»,— дигән.

---

[1] «Казан елъязмачысы» — XVI гасыр уртасында, Казан ханлыгы Рус дәүләтенә кушылгач язылган «Казан тарихы» исемле әсәр авторының шартлы исеме. Аның турында шул гына мәгълүм: ул рус рухание булган, егерме ел буе, але ханлык буйсындырылганчы ук, Казанда яшәгән, телне, гореф-гадәтләрне белгән, хан сараена кереп йөри алган, хәтта мөселман диненә дә күчкән.

...Ала каргалар батырайды. Мине санга сукмыйча, аяк очымда ук арлы-бирле йөренәләр. Эт үләксәсе янындагы чүпрәк-чапрак өеме тирәсеннән кыштырдау, чинау-чиелдау авазлары ишетелә, анда ниндидер ыгы-зыгы бар кебек. Дикъкатьләбрәк карасам — күселәр.

Яңа театр бинасы яныннан узам. Әле кайчан гына монда уйсу, сазламык җир булган. XIX гасыр азагынача, шәһәрнең беренче электр станциясе төзелгәнгә кадәр, бу тирәне «Мүкле баткаклык» дип йөрткәннәр.

Менә шуларны искә төшерү белән минем башка «китереп сукты» да инде. Корылыклы елларда, сазлыклар кипкәч, торф кабынып, айлар буе җир астында пыскып яна алган бит. Урманнарны төпләп-яндырып, ышна ачып иген иккәндә, ботак-сатак, агач төпләре әледән-әле яндырылып торганда мондый хәлләр аз булмагандыр. Риваятьтәге хикмәтле казанның сере ләбаса бу! Инде эт күмүгә килсәк, монысында гайре табигый нәрсә юк: Казан каласы җиде-сигез гасыр элек — корбанга кеше чалу гадәте бетеп барган дәвердә төзелгән.

...Күл буенда басып торам. Моннан мең еллар элек булган күренешләрне күз алдыма китерергә тырышам. Баш очымда җете зәңгәр күк гөмбәзе. Каршымда иксез-чиксез су. Күл сафлыгын, саз үләннәренең төчкелтем буын сеңдергән тыгыз җил җылы, вак дулкыннар куа. Зур-зур әйләнмәләр сызып, күл өстеннән салмак кына тилгән очып йөри. Кояш шәүләләре суда аллы-гөлле тасмалар булып балкып китәләр. Яр сызыгы буйлап симез энә караклары куышып оча. Өзми-куймый черки безелди. Яр буенда яшел дивар булып калкып торган әрәмәлекләр һәртөрле кош авазлары белән тулы. Бераз гына колак салып торсаң, шыгырдаугa охшаш тартар кычкыруын да, урман күгәрчене гөрләвен дә, чуллыкның сарык бәэлдәвенә охшаш өзек-өзек җырын да аерасың.

Һаваны сызгыртып ярып, бер көтү кыр үрдәге очып уза. Алар күл камышы, җикән камыш һәм күрән сарган сайлыкка төшеп утыра. Шундук эшкә дә керешәләр; озын муеннарын суга тыгып, тәпиләре белән ярдәм итеп, борыннары белән ләм сөзә башлыйлар. Башлыклары — чибәр, зур ата үрдәк, кайгыртучан бакылдап, тирәләп йөзеп йөри. Менә ул хәбәр салды. Көтү шундук һавага күтәрелде. Бераздан мин якындагы камышлыкта җирән-сары төлке койрыгын күреп алам.

Чип-чиста яшькелт суда агым тибрәтеп-селкетеп торган сүүсемнәр арасында зур-зур балыклар ялкау гына йөзеп йөргәне күренеп тора. Менә бер урында кинәт борчак сипкәндәй булды — йөзләрчә вак балык. Алар, көмеш җилпәвеч хасил итеп, төрлесе төрле якка атылды: чуртан-юлбасар йөри, димәк. Мин бары аның сырт сызыгын һәм яшендәй елкылдап алган корсагын гына күреп өлгерәм...

Тукта! Хыялга артыграк бирелеп ташламадыммы? Риваятьне искә төшерик.

Алтын балыкны күлдә күп булган бик тә тәмле кәрәкә дип тә аңлап була: Кабан күлләре тезмәсен Казан суы белән тоташтырган Болак Казан елгасына нәкъ менә Кремль тавы янында коя бит. Риваятьне кучерелмә мәгънәдә дә, иң туры мәгънәсендә дә аңлап була. Аквариумнарда йөзә торган хәзерге алтын балык гап-гади кәрәкәдән чыгарылган ләбаса! Әле хәзер дә мондый күлләрдә тач кызылсу-алтын төсендәге балыклар очраштыргалый. Миңа калса, риваятьнең асыл мәгънәсе шуннан гыйбарәт: кала салганда күлнең балыкка бай булуы да искә алынган.

Казан ханлыгы буйсындырылганнан соң ук сан алу кенәгәләре («Писцовые книги») төзелгән. Аларда күлнең корбан балык, сазан, чуртан, судак, мәрсин балыгы, кырпы кебек иң һәйбәт балыкларга бай булуы әйтелә. (Кызыл балык күлгә, ташу вакытында, Иделдән керә). Балыкны Мәскәүгә тундырып та, тозланган, кипкән, какланган-ысланган килеш тә йөге-йөге белән озатып торганнар. Уылдыкны, балык бавырын мичкә-мичкә сатарга алып киткәннәр.

«Казан суы белән Кабан күлләре арасында 750 дисәтинә болын бар,— диелә шунда ук.— Воевода, бояр балалары, стрелец йөзбашлары, дьяклар һәм подъячийлар моннан 21240 чүмәлә печән чабып ала. Кабан артында, Кече Утар авылы янында, Еналиев болыны бар, анысыннан 2100 чүмәлә чабалар».

Ханлык буйсындырылып күп тә үтми, Урта Кабан буенда Яңа Иерусалим монастыре (соңрак Воскресенский монастыре дип атала) салына. Күлләр монастырьның балык биләмәсе дип игълан ителә, балык сату исә монастырь керемнәренең төп өлешен тәшкил итә башлый. Монахлар балыкны Казан халкына сатып кына калмый, (Рыбнорядский урамында монастырьның махсус балык кибетләре була), тозлы, каклаган балык белән бөтен Казан губернасын тәэмин итеп тора.

Хәер, бу ганимәт XIX гасыр башына «кадәр генә» житә. Шуннан соң төп табыш чыганагын җуйган монастырьның эшләре кирегә китә башлый, ул тиздән ябыла.

...Кичке шәфәкъ офыкны һәм төньяк ярдагы биек наратларны алтын төскә манды. Тирә-як төн үткәрү урыннарына юнәлгән меңләгән кыр казлары, торналар, челәннәрнең сузынкы авазлары белән тулды. Яшел яр борылмасыннан күл уртасына патшаларча мәгърур бер пар аккош йөзеп чыкты... (Казан тирәсендә аккошлар XVII—XVIII гасырларга кадәр оялаган. Моны Казаннан унбиш чакрым көнбатышта булган Аккош күленең исеме дә раслый.)

...Зирек куаклыгында каты чытырдау, авыр мышнау һәм түземсезләнеп мыркылдау ишетелә: кабан дуңгызлары гаиләсе су эчәргә төшеп бара. Алар белән очрашмавың хәерлерәк...

Бу урында тагын бер аңлатма сорала. Каюм Насыйри язып алган риваятьләргә караганда, Кабан күле буендагы урман һәм әрәмәлекләрдә заманында исәпсез-хисапсыз кабан дуңгызы йөргән. Алар, игеннәрне таптап, түтәлләрне казып, кешеләргә зур зыян салганнар. Шундый да зур һәм явыз булганнар ки — хәтта, алыплар да күл буена ялгыз гына төшәргә җөрьәт итмәгән. Сан алу кенәгәләрендә дә Кабан күлләре тирәсе кабан дуңгызы, аю, поши, селәүсен, төлке, бүре, куян кебек җәнлекләр белән мыжгып торганлыгы әйтелә. Кондыз «хуҗалыклары» да, чолыклар да күп була. Күлләр тирәсе тикмәгә генә ханның аучылык урыны булып саналмаган.

Әлеге таныклamaларның дөреслеген геологик тикшеренүләр дә раслый. Күлләрне әрәмәләр — юеш, үтеп йөргесез таллыклар, зирек куаклыклары, камышлыклар уратып алган булган. Кабан дуңгызлары өчен җәннәт инде... Каюм Насыйри язуынча, Татар бистәсендә башлап яшәүчеләргә балта белән юл ачарга туры килгән. Җәйге челләдә дә монда салкынча куе күләгә хакимлек иткән, аяк астында су чапылдаган.

4

Казанның яңа аэропортыннан ерак түгел, Большой Кабан исемле рус авылы бар. Кабан күленә аның нинди дә булса катышы юкмы? Бу авылдан күлләрнең иң зурысы — Урта Кабанга — 24 чакрым. Югары Кабанга хәтле дә шул чама. Түбәненә хәтле утыз чакрымлап булыр. Янәшәдә генә Малый Кабан дигән икенче авыл (ул да күлләрнең иң баләкәе — Югары Кабаннан — бик ерак) һәм беразчиттәрәк Татарский Кабан дигән татар авылы бар. Нигә дип әле өч авыл һәм өч күл уртак исем белән аталган икән?

Авылларның тарихы белән танышып чыккач, әлеге рус авыллары урынында Казан ханлыгы чорында Зур Кабан һәм Кече Кабан дигән татар авыллары булуын ачыкладым. Татарский Кабан исә ул чорда Каракчы Кабан дип аталган (Ул шәһәрдән 37 чакрым ераклыкта урнаш-

кан, шуңа күрә, Казан ханлыгы җиңелгәч, халкын күчереп тормаганнар).

Сан алу кенәгәләреннән күренгәнчә, моннан биш гасыр элек, Казан ханлыгы чорында, бу төбәктә авыллар шактый күп булган һәм аларның барысының да диярлек исеменә «Кабан» сүзе кергән: Кабан-Селик, Иске Кабан, Өч Кабан, Ташкабан һәм, ниһаять, гап-гади Кабан. Шунысы кызык: бу авыллар һич тә күл тирәли урнашмаган, алар күлләрдән көньякта, гомуми озынлыгы 35—40 чакрым, киңлеге 15—20 чакрымлы төбәктә укмашып утырганннар. Кабан күленең төньягында исә мондый исемнәр бөтенләй очрамый.

Борынгы авылларның бөтенесе дә диярлек калку һәм коры урыннарга утырган. Алар тирәсендә элек-электән игелеп килгән кара туфраклы басулар, чабыла торган болыннар, көтүлекләр җәйрәп ята. Кабан дуңгызлары көн итә торган аймаклар исә бу тирәдә бөтенләй юк диярлек һәм, күрәсең, булмагандыр да. Димәк, башка аңлатма эзләргә кирәк.

Әле студент чакта ук күлнең исеме турында бик борынгы риваять ишеткән идем. Аны миңа бөтен гомерен Иске Бистәдә, Мәрҗани мәчете каршысында яшәп үткәргән Нәни апам (әниемнең бертуган апасы) сөйләгән иде. Күп гасырлар элек, әле «татар» дигән сүз дә булмаганда, бөтен татарлар да болгарлар дип аталып, шанлы шәһре Болгар тирәсендә көн итмәктә булганнар. Менә бер заман исәпсез-хисапсыз чиру белән кансыз Аксак Тимер җиһангир килә. Каланы яулап алгач, яшенкартын, хатын-кызны, бала-чаганы — берсен-бер аямыйча кырып бетерә. Бик азлар гына котылып кала. Алар арасында соңгы болгар ханы Габдулланың Кабан атлы улы да була. Бәк булганга, аны, олылап, «Кабанбәк» дип йөртәләр.

Эзәрлекләүдән качып, канга баткан Кабанбәк мул сулы Чулманны кичә, карурманнар һәм сазлыклар аша үтә. Менә ул зур вә гүзәл бер күл буена килеп чыга. Күл суы белән җәрәхәтләрен юуы була — алар төзәлә. Суны татуы була — тәнендә дәрман арта, күңелендә өмет уяна, бу кырагай төбәккә мәхәббәт бөреләнә.

Апам күл тирәсендә үтеп чыккысыз урманнар, әрәмәләр җәйрәп ятуы, аларның төрле киекләр белән мыжгып торуы турында мавыктыргыч итеп сөйли иде. Ләкин Кабанбәк белән килгән кешеләр куркып калмыйлар. Алар урман кисә, өй сала башлыйлар, иген игәләр, балык тоталар, кыргый бал кортларының балын җыялар. Кабанбәк артыннан аның дуслары, туганнары, бүтән болгар кешеләре дә килеп утыра. Тиздән күл буенда гүзәл сарай, ә аның янында зур гына авыл үсеп чыга. Күл исә, Кабанбәк исеме белән, Кабан дип йөртелә башлый.

Бу риваять чынбарлыкка ни дәрәҗәдә туры килә? Иң элек, «ябышып җитмәгән» урыннар күзгә ташлана. Кабан буендагы Татар бистәсе XVI гасырның икенче яртысында гына, ягъни, Казан тар-мар ителгәч кенә барлыкка килә. Мәрҗани мәчете янындагы археологик казулар вакытында бу урында XVI гасырдан элек бернинди корылма да табылмый. (Апам сөйләвенчә, Кабанбәк кешеләре нәкъ менә шул тирәгә килеп утырган булганнар).

Кайчакта апам риваятьне тәфсилләбрәк сөйли, яр буендагы иске зиратны да телгә ала иде. Укымышлылар кабер ташларындагы язулардан биредә Мөхәммәт пәйгамбәр дәвамчылары — суфилар күмелгәнлеген беләләр. Кабанбәк кешеләре монда килеп, гыйбадәт кыла башлыйлар. Соңрак бу урында җомга гыйбадәтләре өчен мәчет салалар. «Элек беркем дә булмагач, зират каян килгән соң?» Минем бу «көфер» соравым апамның ачуын китерә: «Ә син сөйләгәнне тыңла. Халык белми әйтмәс. Булган булгач, булган инде. Үзем уйлап чыгармадым, кана!»

Кабанбәк кешеләре салып, аның исеме белән аталган «җиз авыллар» турында да сөйләштергәли иде ул. «Җиз» — бакырдан ясалган мәгънәсендә түгел, чәчәк атып торган, җанлы, түбәләре калай белән ябылган өйләре булган дигәнне аңлата. Авыллар төп шәһәр тирәсендә

барлыкка килә. Казан алынгач, бу шәһәр мәчетләре, алтын гөмбәзле сарайлары, бакчалары, ташпулатлары белән күл төбенә киткән, имеш. Әгәр ап-аяз көндә, эңгер иңгән тып-тын сәгатьтә көймәдә күлнең уртасына йөзеп керсәң, төптәге гаҗәеп матур биналарны күрә аласың, су астындагы манарадан әйтелгән кичке азанны ишетә аласың имеш...

Мин бу хикмәтләрне исем китеп, әкият тыңлаган кебек тыңлый идем. Казан тарихчысы Н. Ф. Калинин тикшеренүләре белән танышкач исә, бу борынгы риваять миңа бөтенләй башка яклары белән ачылды.

Казан тирәсендә казу эшләре алып барганда, Калинин Урта Кабанның ерак ярында бер бик борынгы кала урыны — кала-тау тапкан. Кала Казаннан да элек салынган булырга тиеш (XII—XIII гасырларда). Галим таш корылмалар, кала тирәсендәге урларның аермачык эзләрен ачкан, кала-тауның мәйданын үлчәгән. Ул 7,5 мең квадрат метр тәшкил иткән. Кала үрдә (күл өстеннән 20-25 метрлар югарырак), соңрак Архирей дачасы (хәзер анда авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты) урнашкан җирдә салынган. Бер яктан — тирән күл. Тагын ике яктан махсус тирәнәйтелгән табигый ерынты-чокырлар уратып алган. Дүртенче якта — 7,5 метр тирәнлектәге, очлы казыклар ыржаеп торган сулы чокыр. Чокыр артында — шундый ук биеклектәге ур, аның өстеннән исә почмакларда манаралары булган имән дивар үткән.

Кала урыны риваятькә туры килеп бетми бетүен. Телдән-телгә күчә торгач, мәгълүмат үзгәрми калмый лабаса. Ә бәлкем, риваятьнең бүтән, борынгырак вариантлары да булгандыр әле, аларда каланың урыны да башкача күрсәтелгәндер? Тукайның «Кисекбаш»ына күз салыйк. Аның герое Карәхмәт Диюнең су асты шәһәренә... трамвайда бара. «Зур завод Крестовниковны» (Хәзерге М. Вахитов исемендәге химия комбинатын) үтә, көтмәгәндә, «бер сәхрәгә» ирешеп, «азрак җәяү алга табан» баргач, Кабан күленә җитә. Сүзнең Урта Кабан турында икәнлеге бәхәссез булса кирәк.

Кала өчен шәп урын булган бу. Бердән, Урта Кабаннан көньякка таба үзләштерергә гаять уңдырышлы кара туфраклы җирләр җәйрәп ята. Икенчедән, чакырылмаган кунаклардан, күчмә урдалардан саклану өчен бик уңайлы. Каланы Иделдән ерып чыккысыз әрәмәлекләр, вак күлләр, сазлыклар һәм инешләр челтәре аерып торган. Казан суы тамагыннан аны урман сарган, атлы гаскәр үтә алмаслык тирәнтирән чокырлар ермачлаган үр-калкулыклар чикләгән. Шәһәрчеккә бары күл аша, көймәдә генә килеп җитеп булган.

Кала-тау урынындагы чүлмәк ватыклары, корал, аяк киеме, көнкүреш әйберләре калдыкларын тикшергәч, Н. Ф. Калинин аларда болгар әйберләре белән тулы охшашлык таба. Димәк, каланың йә борынгы Болгар белән бәйләнешы әйбәт булган, йә аны Болгардан чыккан кешеләр XIII гасырларда ук салган.

Калинин үзе исә, калада тимерчеләр дә, коралчылар да, тукучылар һәм чүлмәкчеләр дә булган, табылган әйберләр шушында ясалган, дигән фикердә тора. Кабанбәк турындагы риваятьне дә телгә ала һәм: «Бик тә дөрескә охшаган»,— дип бәяли. «Бирегә, Кабан күле буенда, хәзерге Казан территориясендә шәһәрчек булган,— дип яза тарихчы.— һәм бу шәһәрчек кораллы отряд торган хәрби кальга гына түгел, даими торак урыны да булган».

Н. Ф. Калинин кала-тауның яшен тагын да төгәлрәк ачыкларга мөмкинлек биргән борынгы зират калдыкларын да таба. Ул чордан ике кабер ташы гына сакланып калган. Алар, болгар ташлары кебек үк, нәкыш төшереп, өске ягын михраб рәвешендә гөмбәзләп-уентылап ак таштан ясалганнар. Бормалы-сырмалы гарәп хәрефләре монда «Бөек әмир, хөрмәтле солтаннарның ярдәмчесе, җиңүче, ыругның мактанычы... Мир Мәхмүт углы Хәсәнбәк» күмелгәнлеге турында сөйли. Елын аерып булмый — әллә үзе ашалган, әллә соңрак кырып-юнып ташлаганнар.

Уеп язу техникасына карап, Калинин әлеге таш XIII гасырда куелган дип исәпли. Икенче таш асыл нәселдән туган Алтын Бөртек атлы хатынга куелган. Монысының үлгән көне аермачык укыла: һиҗринең 696 елы, зөлхиҗҗә аеның сигезенче көне, ягъни хәзерге вакыт исәбе белән 1297 елның 27 сентябре.

Апам телгә алган зират шул булса кирәк. Кабер ташы 1297 елда куелган икән, димәк, кешеләр монда шактый элек, үнөченче, ә бәлки, уникенче гасырдан ук яши башлаганнар. Бу вакытта әле Казан каласының эзе дә булмый. Монда исә — бәкләр, солтаннар күмелгән. Димәк, ул — гади авыл гына түгел, төбәкнең үзенә күрә башкаласы булган.

Бу таш нинди генә серләрне белми икән? Тарихчыларның: Болгар дәүләтендә хатын-кызлар күренекле урын тотканнар, политик тормышта да, сугыш эшләрендә дә катнашканнар, тигез хокуклы һәм мөстәкыйль булганнар дигән фаразын расламый микән ул? Бер шигырендә шагыйрь Гамил Афзал әнә шул турыда уйлана:

...Мөң булырлык, җыр булырлык
Хәлләреннән хәбәр көттек.
Ташларга уеп язарлык
Ниләр кылдың, Алтын Бөртек?

Бу ташлар хәзер Татарстан дәүләт музеенда саклана.

Шундый бер риваять тә бар: бүтән кабер ташлары, ханлык яулап алынгач, борынгы корылмаларның ташлары белән бергә, шушы урында ачылган Яңа Иерусалим монастыре нигезенә салына. (Соңыннан — Архирей дачасы). Ә бу икесе монастырь башлыгы Гурий кушуы буенча калдырыла — ташларның матурлыгы, бизәлеш камиллеге аның исен китәрә.

Кала янында гүзәл бакча да була. Аның турындагы риваять XIX гасыргача килеп җиткән һәм татар тарихчылары тарафыннан язып алынган. Казанлылар аны Сөембикә бакчасы дип йөрткәннәр.

Бакчада берсеннән-берсе матур биналар булган, гаҗәеп агачлар үскән, гүзәл болаңнар йөргән, имеш. Риваятьнең кайбер вариантларында «мөгезе мәрмәр болаңнар» (Г. Тукай. «Печән базары...»), ягъни скульптур сыннар искә алына. Әмма монысы, ай-һай, мөмкин эш микән — ислам сын ясауны тыйган лабаса. Бу бакчада, җәйге айларда, хезмәтчеләре һәм гүзәл җенестән булган күпсанлы тумачалары белән Сөембикә дә ял итәргә яраткан дип сөйлиләр. Бу хакта язма чыганакларда да әйтелә.

Калинин шундый нәтиҗә ясый: гади торак урыны гына түгел, төбәк үзәге, әмир резиденциясе булган бу. Шәһәрчек Болгар иленең төньяк чикләрен саклау максатында салынган булса кирәк. Әмма соңрак, XIV гасырда, Болгардан күпләп күчеп килүчеләр исәбенә ул бик нык үскән. Казып тикшерүләр каланың озак яшәмәгәнлеген күрсәтә. Якында гына салынган Казан каласы (аралары нибары алты чакрым) ханлыкның башкаласы буларак ныгып җиткәч, шәһәрчек сәүдә юлларыннан читтә калган, кальга буларак та хәрби әһәмиятен җуйгандыр. Шәһәрчек ханнарның җәйге ял урынына, ә Кабан әмирлеге җирләре аларның нәсел мирасына әйләнә.

Ханлык буйсындырылганнан соң, ханның мирас җирләре барлык авыллары белән Яңа Иерусалим монастырена бирелә, анда яшәгән халыкның күпчелек өлеше сөрелә. Князь Василий Шуйскийның 1555 елда архиепископ Гурийга биргән льготалар грамотасында бүләк ителгән җир турында болай дип әйтелә: «Ике мең чирек (ике мең гектар чамасы) сөрүлек җир, элекке патшалардан килгәнчә (ягъни Казан ханнары заманында булганча), барча урманнары, болыннары, күлләре, чолыклары, кондыз аулау урыннары, өч Кабаны белән монастырьга бирелә...»

Монастырь биләмәләренең чикләрен картага төшерсәк, «Кабан»

исемен йөрткән авыллар тупланган әлеге район килә дә чыга. Шулай итеп «Кабан» исемен йөрткән авылларның сере бик гади аңлатыла: алар барысы да кайчандыр Кабан күле буенда урнашкан Кабан әмирлегенә кергәннәр, шуның исемен йөрткәннәр. Хәер, соңрак мондый исемдәге авыллар бүтән төбәкләрдә дә барлыкка килә, аларның исемен элекке «Кабаннар»дан күчкән халык кушкан дип уйланыла.

Шулай итеп, борынгы риваять соңгы ноктасына хәтле диярлек раслана түгелме соң? Хәтта күл төбенә иңүе дә... Шунысын истән чыгармыйк: калатау Кабан күленең Шайтан почмагына, ягъни ашалуубылу процесслары актив барган зонага якын. Каланың мантый алмавы, ташлануының бер сәбәбе, бәлки, шулдыр да әле! Су асты археологлары бу тирәдә кайчан да булса «Татар Атлантидасын» тапмаслар микән?

Тагын бер сорау кала: болгарларда «Кабан» дигән кеше исеме булганмы?

Кабер ташларындагы язулар һәм язма чыганакларга таянып моңа да: «Әйе, булган»,— дип кисеп җавап бирә алабыз. Шактый киң таралган бу исемнең төрле үрнәкләре очрый: Кабан, Кабанбәк, Кабанай, Ташкабан һ.б. Әлеге исемнәрнең кайтавазы булган фамилияләр Болгар чорыннан хәзерге көннәргәчә килеп җиткән: Кабанаев, Кабанбаев, Кабанбиков һ.б. Күп кенә тарихчыларның фикеренчә, болгарларда үзенә күрә кабан дуңгызына табыну яшәп килгән. Бу куәтле киек батырлык, куркусызлык символы булып саналган. Шуңа күрә дә борынгы ата-бабаларыбыз бу исемне ир балаларга бик теләп биргән.

Шулай да... Борынгы риваятьнең ышандырмый торган яклары да бар. Беренчедән, Кабан яки Кабанбәк исемле әмир бер генә чыганакта да теркәлмәгән. Иске Казан салыну турындагы риваятьләрдә шул ук Габдулла ханның Алтынбәк һәм Галимбәк исемле ике улы гына булган, дип әйтелә.

Икенчедән, даталарның туры килеп җитмәве шикләндерә. Риваятьнең иң борынгы вариантларында шәһре Болгар Аксак Тимер тарафыннан һиҗринең 700 елында, ягъни 1300—1301 елларда тар-мар ителгән дип сөйләнә. Ә бит Аксак Тимер[1] ул вакытта тумаган да була әле. Тарихчылар фикеренчә, монда бөек каланы җир белән тигезләгән Алтын Урда ханы Мәңге Тимер күздә тотыла булса кирәк. Моның ише бутау-алыштырулар — була торган хәл. Әмма, шул ук кабер ташларына карап фикер йөрткәндә, Кабан күле буендагы кала моннан элегрәк салынган булып чыга. Кабан атлы бәк, чыннан да, булган булып, күл буена килеп чыккан очракта да, анда аны шау-гөр килеп яшәп яткан кала каршылаган булыр иде. Шәһәр халкы күлне берничек тә атап йөртмәгәнмени? Әгәр ул чакта ук, ягъни XII-XIII гасырлардан, күлнең үз исеме булган булса, киресенчә, каланың да, аннан чыккан кешеләр салган авылларның да, бөтен әмирлекнең дә бәк исеме белән түгел, бәлки күл исеме белән аталуы мөмкин.

Мәсьәләгә бүтән яктан карап карыйк. Топонимика белгече профессор Гомәр Саттаров «Кабан» сүзе борынгы төрки телдәге «Каб-куб» тамырларыннан ясалган дип исәпли. (моннан «кабу», «кубару» һ.б. сүзләр чыккан) Ә бу — нинди дер уентыны, чокырны аңлата. «Кабан»ның борынгы мәгънәсе «кабылган», ягъни «уелган», «убылган җир» булып чыга. Ул заманнарда күлләрне генә түгел, кайбер елгаларны да «Кабан — кабалган» дип атап йөрткәннәр. Мондый атамаларның кайберләре безнең көннәргәчә килеп җиткән. Шул ук вакытта кыр дуң-

---

[1] Аксак Тимер (1336—1405) — Урта Азиядә башкаласы Самарканд булган дәүләт төзегән, Европа һәм Азиянең күп кенә илләренә яу чапкан дәһшәтле җиһангир. Аның Болгарга җимергеч походы 1361 елда булган дип уйланыла.

гызларын да «кабан» дип йөрткәннәр. Бу сүз шул ук «каб» тамырына «ан» (җан иясе, җанвар) кушылып ясалган. Еллар үтү белән беренче мәгънәсе (сулык) онытыла, икенчесе генә (кыр дуңгызы) кала.

Шулай итеп, күл исеменең килеп чыгышын өч төрле аңлатып була. Бу бер үк сүзнең өч төрле мәгънәгә ия булуы белән бәйле:
1. Сулык.
2. Кыр дуңгызы.
3. Кеше исеме.

Кайсысы дөрес соң?

Минем үземә, икенче мәгънә чынбарлыкка якын кебек тоела. Ник дисәң, төрки кабиләләр күл буена килеп чыкканда (моннан мең еллар чамасы элек), сүзнең борынгы мәгънәсе («сулык») җуелып өлгергән булгандыр инде. Кыр дуңгызы мәгънәсендә кулланылган ялгызлык исемнәре күп очрау да шул хакта сөйли булса кирәк. Иң борынгы рус чыганакларында да «Кабан күле» «Свиное озеро» дип тәрҗемә ителгән. Соңрак, «кабан» сүзе рус телендә ныклап урнашып өлгергәч кенә, «Кабанье озеро» дип, тагын да соңрак исә «Кабан» дип кенә яза башлыйлар.

## 5

Бервакыт минем кулга кызыклы гыйльми китап килеп керде. Анда Казан һәм Кабан күле, риваятьләргә таянып, динозаврлы урыннар рәтенә кертелгән иде. Китапның исемен дә, авторын да хәтерләмим (чит ил галиме булса кирәк). Бер рәсем генә аермачык хәтердә калган: арткы планда — Сөембикә манарасы, алда — тыныч кына җәйрәп яткан күл, ә судан тешләрен ыржайткан аждаһа башы сузылып тора.

Чыннан да, риваятьләрнең берсендә, безнең шәһәр урынында кайчандыр берсе-берсе «бүрәнә хәтле» еланнар булган, диелә. Аларның башлыклары ике башлы, оча торган елан — Аждаһа, имеш. (Хәер, баш саны төрле вариантларда төрлечә йөри — бердән алып уникегә кадәр). Бу төбәктә кала салырга уйлаган ханның хезмәтчеләре сихерчегә мөрәҗәгать иткәннәр. Ул исә болай ди: агачларны кисегез, күп итеп салам, чыбык-чабык китерегез. Язын, җир кипкәч, еланнар салам астына кереп тулыр — ут төртәсе генә калыр... Шулай эшлиләр дә.

Еланнарны юк итәләр, ә башлыклары Аждаһа кап-кара төтенгә уралып очып китә дә Кабан күленә төшә. Шул заманнардан бирле ул күл төбендә яши, ди, һәм казанлыларга үч итеп, йә үзләрен, йә балаларын су астына алгалый имеш. Кайбер вариантларда Аждаһа су төбе патшалыгы төзеп, явыз Диюгә әйләнә. Тукайның «Кисекбаш»ында да әнә шул вариант уйнатыла:

> Әй дулый! Мәлгунь Дию, әй тартыла!
> Акыра ямьсез, каты — җир селкенә.

Халык фантазиясенә хас котылгысыз арттыруларны алып ташласаң, легенда шактый ук реалистик төс ала. Казан иң әүвәл салынган үр — Елан тавы дип йөртелгән. Хәзер анда — борынгы монастырь корылмалары. Ул да шул «елан» сүзенә бәйле рәвештә «Зилантов монастырь» дип йөртелгән. Үр белән янәшә бәләкәй генә Елан күле булган.

Легендада шул чаклардагы игенчелек тә чагылыш тапкан: яңа җирләрне үзләштерү — ышна ачу, урман төпләү-яндырудан башланган. Әлбәттә, инде, моның өчен тимер хезмәт кораллары булу шарт. Безнең якларда алар мең ел чамасы элек барлыкка килгән дип уйланыла. Күрәсең, нәкъ менә шул вакытлардарак Елантаудан ерак түгел Биш Балта дигән татар саласы барлыкка килгәндер дә. Исемгә керерлек булгач (бу исем безнең көннәргә дә килеп җитте), ул чакта шул кадәр (биш!) балтаның нинди зур байлык булуын чамаларга мөмкин.



Әлбәттә, легендаларның барыннан да элек халыкның иҗат җимеше икәнен, турыдан-туры, рационалистик аңлатуга кайтып калмавын истән чыгармыйк. Әйтик, оча торган елан турындагы легендалар борынгы Болгарда да, Суарда да, Биләрдә дә таралган булган. Чистай янындагы Юкәтау, Алабуга янындагы Шайтан каласы әнә шундый әкәмәт зур еланнарның яшәү урыны булган дигән сүз калган. Болгар иленең Чишмә елгасындагы чик буе шәһәрчеге Елантау дип аталган. Хәзер дә анда Елантово исемле рус авылы бар.

Кайбер галимнәр, Аждаһа, Змей-Горыныч кебек әкияти каһарманнар турындагы дөньяда киң таралган легендаларда кешелекнең оча торган кәлтә яисә башка төрле динозаврлар хакындагы тарихи хатирәләре чагылыш таба, дип исәплиләр.

Зирәк акыл һәм үлемсезлек символы — оча торган елан Идел Болгарының гербын да бизәп торган. Соңрак ул Яңа Болгар дип йөртелгән Казанга да күчкән. Иван Грозныйның бабасы Иван III, хан гаскәрен җиңеп, Казанны алгач, титулларына «Болгар кнәзе» исемен дә өсти, байрагына борынгы Болгар гербын төшертә. Бу сурәт ялган Дмитрийның печатендә, патша Алексей Михайловичның байрагында безнең көннәргәчә килеп җиткән: ул «аждаһа» бер башлы, тавыкныкы кебек дүрт тәпие бар. Кошныкы кебек гәүдәгә елан койрыгы тоташкан, зур итеп ачылган томшыгыннан елан теле чыгып тора.

XVIII гасырда әлеге «аждаһа» тагын бер үзгәреш кичерә. 1730 елда аны Казан губернасының рәсми гербы итеп раслаган Указда болай диелә: «Елан кара, алтын таҗ — Казан таҗы кигән, канатлары кызыл, төп төсе — ак». Мондый бизәлеш борынгы болгарларның күзаллауларына ни дәрәҗәдә туры килгәндер — анысын әйтүе кыен, һәрхәлдә, оча торган Елан бүген казанлыларның күбесенә күп төрле значоклар, открыткалар, сувенирлар аша әнә шундый «кыяфәттә» таныш.

Тик канатлы елан нигә әле нәкъ менә Кабан күленә «төшкән?» Монда күлнең ел саен берәр яки хәтта берничәшәр кешенең башына җиткән усал холкы хәлиткеч роль уйнагандыр. Күл төбендәге салкын чишмәләр, мәкерле чоңгыллар, су асты агымнары турында риваятьләр күп йөри. Кабанның бу үзенчәлеге төптә яши торган усал көчләр турында төрле-төрле легендалар туууга да сәбәпче булгандыр.

Андрей Протопоп 1560-1563 еллар арасында язган «Патшалар шәҗәрәсенең дәрәҗәләр китабы»нда [1] казанлылардан ишеткән тагын бер легенда китерелә. Мөхәммәт Әмин ханның Горшанда исемле искиткеч чибәр һәм акыллы сеңлесе булган, имеш. Татар гыйлеменә һәм «төрле җен күрәзәсенә» өйрәнгән бу кыз Казанның алыначагын берничә ел алдан әйтеп бирә. Күрәзәсе раска чыккач, җиңүчеләр кулына эләкмәс өчен, Кабанга ташлана һәм су анасына әйләнә. Айлы төннәрдә кыз судан чыгып шәһәр буйлап моңаеп йөри, имеш. Кремль үренә менә, хан сарае хәрабәсен урап чыга, җимерелгән мәчетләр янында озаклап басып тора. Татар бистәсендә яшәүчеләр әле XIX гасырда да сөйли торган булалар: хан кызы җәйге кичләрдә алтын тарагы белән чәчләрен тарап утыра, берәрсе күрә калса, йодрыгын янап, суга чума, имеш.

[1] «Книга степенная царского родословия».

Балаларны да шул гына ала — заманында аның киңәшен тотмаганга, үзара ызгышларны туктатмаганга үч итә, янәсе.

Г. Тукайның поэмасында бу легенда да чагылыш таба:

Су анасы, бик явыз, йөзе кара.
Ел да бер угланны йә бер кызны ала.

Легендада чынбарлык белән «шагыйранә ялган» бергә үрелгән. Мөхәммәт Әмин ханның (1518 елда үлгән) чыннан да Гәүшәркат исемле сеңлесе булган) рус чыганакларына йә Коршенда, йә Горшанда, йә Ковкошад булып кергән). Абыйсы үлгәч, ул Казанга нигез салган Олы Мөхәммәт династиясенең бердәнбер вәкиле булып калган. Гәүшәркат Мәскәү белән тыныч яшәү яклы була, халык та ярата үзен. Бер заман ул хәтта ханлык белән дә идарә итеп ала. Әмма сарай фетнәсе нәтиҗәсендә тәхеттә аны Җан Гали хан алыштыра...

Бер сорау туа. Кабан күле сулы горизонт аша Иделгә тоташкан булмадымы икән? Мондый фикергә мәкерле су асты агымнары турындагы риваятьләр генә түгел, XVIII гасыр азагында ук Кабанда үткәрелгән беренче фәнни тикшеренүләр дә этәрә. Ашалу процессларының гаять тиз баруы да шул фикергә куәт өсти — моның өчен су агымы кирәк бит.

Ләкин соңгы елларда Н. М. Минһаҗева үткәргән тикшеренүләр Кабанда бернинди су асты чишмәләре дә, су асты агымнары да тапмады, чөнки күлләрнең төбе ләм белән капланган: Якын Кабанның бөтен күләменең өчтән ике өлеше, Урта Кабанның өчтән бере, Ботан бугазының уннан тугыз өлеше, Болак — йөз проценттан да артыграк. (Хәзер Болак төбе элекке су өсте биеклегеннән дә өстәрәк!) Кипкәндә мондый ләм тоташ бер таш булып ката. Ләм үтәдән-үтә күкертле водород, авыр металл кушылмалары белән агуланган. Мондый күлдә хан кызы түгел, пәри дә чыдамас!

## 6

Исмәгыйл Әҗемов үлгәннән соң ун-унбиш еллар үткәч, яңадан хан казнасына «тап булдым». Бу юлы инде бу имеш-мимеш тә, җеп очы гасырлар төбендә җуелган риваять тә түгел, ә хәзинәне үз күзләре белән күреп, үз куллары белән капшап караган кешенең таныкламасы иде.

«Спартак» су станциясе өлкән тренеры Равил Хәйрулла улы Богдановны мин студент чаклардан ук беләм. Равил абый кырык елга якын гомерен Кабанда үткәргән, аны аркылыга-буйга йөзеп узган. Ул тәрбияләгән спортчылар арасында күренекле мастерлар да аз түгел.

Бер тапкыр шулай, яшь спортчыларның ишүен күзәтеп, ярда утырганда, ул әлеге вакыйганы сөйләде. Мин аны шунда ук (1980 елның җәе иде) язып та алдым. Алты елдан соң кабат очраштык. Равил абый инде күлнең каршы ярында — «Динамо» станциясенең директоры булып эшли иде. Элек сөйләгәннәрен, сүзгә-сүз диярлек, кабатлап чыкты. Дөреслегенә шикләнергә сәбәп юк, Богдановны бераз гына булса да белгән кеше раслар: ышанычлы кеше, сүзен җилгә очыра торганнардан түгел.

— 1949-1950 елларда булды бу. Җәй иде, июнь яки июльдер. Казанда ниндидер ярыш бара иде, баскетбол буенча икәнен соңыннан гына белдем.[1] Читтән килгән берничә спортчы миннән көймә алып торды. Бик яхшы хәтерлим: якшәмбе, аяз, эссе көн. Ярышлар беткәч,

[1] Бу ярышлар Казанның «Динамо» стадионында 1949 елның 10—15 июлендә үткән. Соныннан моны бу чор газеталары ярдәмендә ачыкладым.

бераз ял итеп, күңел ачып аласылары килгән, күрәсең. Бераздан күл өстендә шау-шу купты. Көймә капланып, берсе су төбенә киткән икән... Хәтерләп калган идем үзен — озын буйлы, кара-кучкыл йөзле чибәр егет иде. (Соңыннан бу вакыйганың да шаһитлары табылды.— Р. М.)

Батып үлгән егет Баку спортчысы булып чыкты. Зур гына бер түрәнең улы икән. Телеграмм суктылар, әтисе килде... Нишләмәк кирәк, зур кайгы инде... Без ул килгәнче үк ике көн рәттән мәетне эзләдек. Әтисе килгәч, безне тагы җыйды. Улымның гәүдәсен зинһар өчен табып бирегез, ди. Ни эшләсәгез дә эшләгез, тик ансыз кайтып китмим, ди. Мең тәңкә акча да вәгъдә итте...

Җыелышып баш ватабыз — нәрсә эшләп була? Җәтмәгә кермәде, нинди дә булса бүтән әмәл табарга кирәк. Заводта күп итеп берничә җәпле тимер ыргаклар ясаттык, күпме кирәк бау сатып алдык — шөкер, түләр кеше бар. Тотындык күлне буеннан буена «сөрергә». Алтымы, сигезме көймәдә. Һәр ике көймә арасында аркан сузылган. Арканга нечкәрәк бау белән дистәләрчә ыргаклар бәйләнгән. Ни генә тартып чыгармадык төптән! Солдат термосы, борынгы бил каешы, тимер шлем, Гражданнар сугышы вакытыннан калган кораллар дисеңме... Егетне генә таба алмадык... Кинәт бер ыргак нәрсәгәдер эләгеп калды. Көймә, комга утыргандай, шып туктады. Бөтенебез шул турыга өелештек, тартабыз бергәләшеп. Берничә ыргак кадалган булса кирәк, шуңа күрә берничә баудан тартабыз. Аз-азлап кузгалды кебек бу. Тик авырлыгы!.. «Ни булыр икән?»— дип баш ватабыз. Бәлкем, машина-фәләндер?

Һәм менә судан күренде... Ни дип уйлыйсыз? Мичкә! Кечкенәрәк кенә бер мичкә. Биеклеге күп булса бер метр булыр. Ә авырлыгы... Таш төясәң дә алай булмас... Кая ул таш! Тимер дә алай булмый! Баулар шартлап өзелер сыман. Суда килеш бит әле! Мәгънәле генә карашып алдык — хәерлегә булсын, янәсе.

— Нindирәк иде соң ул?

— Мичкәме? Әйтәм бит инде, гап-гади бер мичкә. Имән булса кирәк, шактый борынгы күренә. Ниндидер соры таплары бар. Ихтимал кайчандыр соры төскә буялган булгандыр. Ә бәлкем, күгәрек табы гынадыр.

— Бәлки анда тозлы кыяр, яки тозлаган кәбестә булгандыр?

Равил абый чын-чынлап үпкәләде:

— Үзем генә булсам бер хәер. Әйтеп торам бит, коточкыч авыр иде дип. Я алтын, я көмеш. Бүтән берни дә түгел. Соңыннан Казан университеты галимнәре белән исәпләп карадык. Әйе, тимер дә, хәтта кургашын да бу кадәр авыр булмас иде. Тыгызлап тутырган алтын-көмеш әйберләре генә шундый зурлыктагы мичкәдә, 20-25 пот, ягъни 300-400 килограмм тартачак.

— Ярый, шуннан ни?

— Ни дип... Тырышабыз инде, ничек тә сөйрәп чыгарып, көймәгә салмакчы булабыз. Астына бау кертер идең — буй җитми. Ике ягыннан дүртәүләшеп эләктереп өлгергән идек, кузгалмый гына бит!

Шуннан, арабыздан беребез (хәтерем ялгышмаса, Константин Фролов булса кирәк): «Юк, егетләр, болай булмый, моның өше тәрене күтәрергә көчебез җитмәс. Әйдәгез әкренләп ярга таба ишик... Сайрак җиргә җиткәч, ничек тә сөйрәп чыгарырбыз»,— диде. Ул көймәгә берүзе утырган иде. Безне кат-кат кисәтеп, мичкәдән кулын ычкындырды да, ишкәкләр янына китте. Әмма... Кулын ычкындыруы булды, мичкә коточкыч авырлыгы белән безне сөйри башлады. Мичкәнең ике ягыннан кадалган тимер ыргаклар, тураеп, баудан ычкынды. Без дә кулдан ычкындырырга мәҗбүр булдык, чөнки мичкә үзебезне дә күл төбенә өстери иде... Дөньяда күпме яшәп, бу кадәр авыр нәрсәне күргәнем юк иде... Ул урынны соңыннан ыргаклар белән кат-кат «сөреп» чыктык.

— Эләкмәдеме?

— Кая ул! Күрәсең, ләмгә чумган. Биш-алты метрлап булыр...
— Ә земснаряд анда эшләмәгән идемени?
— Юк.
— Берәр кая хәбәр итәргә уйламадыгызмы?
— Кая хәбәр итәсең ди? Кирәк кеше болай да белә. Артыгы белән. Ул имеш-мимеш таралды, мин сиңа әйтим! Минем янга гына да ничә кеше килде...

Равил абыйдан әлеге урынны күрсәтүен үтендем. Сер ясап маташмады. Иң гаҗәпләндергәне шул булды: бу урын Әҗемов карт әйткән җир белән нигездә туры килә иде.

Эзли торгач, тагы бер шаһит табылды. Исеме — Владимир, фамилиясе — Сучков. 1949 елда аңа унөч яшь булган. Ул ишкәкчеләр секциясенә йөргән һәм әлеге мичкә табылган көнне Равил Богданов көймәсендә утырган. Аның истәлекләре Равил абый сүзләрен тулысынча диярлек раслый. Ләкин кайбер җитди аермалар да бар.

Иң мөһим аерма шунда: Владимир сүзләренә караганда, күл төбеннән күтәрелгән әйбер мичкә түгел, сандык, имеш. «Мин ишкәктә утыра идем,— дип сөйли Володя,— Әлеге нәмәстәне күтәрә башлагач, көймәнең койрыгы суга иңде, су керә башлады. Шуңа күрә мин, ишкәкләрне кулдан ычкындырмыйча, көймәнең борынына сузылып яттым, әлеге әйбер миңа якыннанрак күренде. Өсте, чыннан да, түгәрәкләнеп килә, ләкин сандык икәнлеге аерым-ачык иде».

Аның сүзләренә караганда, сандык бик борынгы формада ясалган, тимер кыршаулар белән ныгытылган булган. Зурлыгын да ул, Богдановка караганда, зуррак итеп күрсәтә — 130—150 см чамасы, ди.

Икенче аерма. «Сандык кулдан ычкынып, яңадан күл төбенә төшеп киткәч,— дип сөйли Владимир,— көймәдәгеләр үз эшләрен дәвам иттеләр, баткан спортчыны эзләделәр. Ә икенче берәүләр исә, шундук ДОСААФ станциясенә барып, водолазлар алып килделәр». Алар озакламый килеп җитәләр һәм шул ук көнне күл төбенә төшеп әлеге хәзинәне эзли башлыйлар. Ләкин тимер ыргаклар белән «сөрелгән» күл ләм боткасына әйләнгән, суда берни дә күренми. Шуңа күрә водолазлар, күпмедер вакыт маташканнан соң, кире кайтып китәргә мәҗбүр булалар.

Бу вакыйгада катнашкан тагы берничә кеше исән булырга тиеш, ләкин аларны әлегә таба алганыбыз юк.

## 7

*«...Казан елгасыннан баксаң, тау шундый биектер, башны чөеп караны да кыен. Тау башында шәһәр: патша сарайлары, галәмәт биек таш мәчетләр торыр...»*

Андрей Курбский, XVI гасыр.

Камалыштагы Казан халкы су алган җир асты чишмәсе турында өлкән яшьтәге казанлылар арасында әле дә төрле имеш-мимешләр йөри. Риваятьләр дә бар.

Камаучылар качып чыккан сатлык җаннан чишмәнең кай турыда икәнен беләләр дә аны шартлаталар. Елъязмаларга караганда, бу хәл казанлыларны зур сагышка сала. Начар су эчүдән алар арасында төрле кизүләр башлана. Каланың язмышын шактый дәрәҗәдә әнә шул да хәл итә.

Бу чишмә XIX гасыр башларынача агып тора, күп тапкырлар әдәбиятта да тасвирлана. Кремль диварының тышкы ягында, Ленин күпереннән ерак түгел, хәзерге таш баскыч турысында булган ул. Болакка койган. Утыз меңлек гаскәр һәм тагын шул чама шәһәр халкы өчен

асылда бердәнбер ару су чыганагы була ул. Көчле чишмә, димәк. Тикшеренүләрдән күренгәнчә, су Кремль тавы астындагы известьташлы катламнар аша үтеп килгән. Чишмә суы чүлмәк торбадан кальга янындагы Таһир мунчасына да агып торган.

Чишмәдән Нургали манарасына яшерен җир асты юлы үткән (шуңа да руслар әлеге манараны соңыннан «Тайницкий» дип атаганнар). Сакланып калган таныкламалардан күренгәнчә, юлның өсте таш гөмбәз белән ныгытылган булган. Манара эченнән юл таш баскыч буйлап аска төшә, шәһәр дивары астыннан үтеп, чишмә чыга торган турыга барып җитә. Шул ук юл аша камалган шәһәрдән дә чыгып булган.

Чишмәне шартлатыр өчен, Таһир мунчасы диварларына ышыкланып, җир астында икенче бер юл казый башлаганнар. Йөз сажинлап үткәч, суга төшүчеләрнең тавышлары ишетелгән, имеш. Шуннан соң бернечә мичкә дары тәгәрәтеп керткәннәр. Риваять буенча, мичкә өстендәге шәмне кабызгач, Иван Грозный чатырында да шундый ук шәмгә ут алалар. Чатырдагы шәм янып бетә, шартлау ишетелми. Ярсыган патша шартлату остасының башын кисәргә боера. Аның башы патшаның аяк астына тәгәрәп төшүе була, көчле шартлау тавышы ишетелә. Патша җир астында шәмнең начаррак януын исәпкә алмаган, имеш.

Тарихчылар, риваятьнең бу өлешен хыял җимеше булырга тиеш, диләр. Чөнки шартлату эшләренә җитәкчелек иткән Бутлер атлы «немец» (милләте буенча ул инглиз булган, «немец» сүзе бу очракта чит ил кешесе дигәнне генә аңлата) исән кала, балда-майда йөзә. (Атаклы Казан химигы Бутлеров — аның токымыннан.)

Кагыйдә буларак, шәһәрләр кальгадан түгел, ә тышкы шәһәрдән башлана. Тарихчылар, безнең Казанны да эчәргә суы булмаган Кремль тавыннан түгел, Черек күл итәгеннән башланган, дигән карашка күнә баралар. Черек күл, Мунча күле, Пычрак күл һ.б.лардан торган күлләр тезмәсе турында күпләрнең ишеткәне бардыр. Ә менә аларның күлләр түгел, бәлки буалар булуын сирәк кеше беләдер. Буалар агым сулы була, су югарыдагысыннан түбәндәгесенә улаклар яки чүлмәк торбалардан агып төшә.

Геология-минералогия фәннәре кандидаты Е. Станкевичның тикшеренүләреннән күренгәнчә, бу тирән батынкылыкта борын заманда эрәмәлекләр басып киткән уйсулык булган, аны инеш ярып үткән. Инешне уң кул якта тибеп торган күпсанлы чишмәләр туендырган.

Шушы инеш һәм чишмәләр, соңыннан — буалар, шәһәр үсешенең беренче чорында аны су белән тәэмин итүнең төп чыганагы булган да инде. Халык арткан саен, күлләр пычрана барган. Күл исемнәре әнә шул хакта сөйли.

Пычрак күл... Иң астагы бу күлнең мәйданы ун гектардан артык була. Күл, дөресрәге, аның урынында калган баткак уйсулык (Батурин урамы тирәсе) безнең гасыр урталарына кадәр килеп җитә һәм, бары Куйбышев сусаклагычы төзелгәч кенә, тәмам юкка чыга. Ул, күрәсең, Казан елгасының иске эзедер. Ләм һәм торф катламыннан күренгәнчә, заманында күл шактый тирән булган. XV гасырга ул шулкадәр пычрана ки, суы малга эчерергә дә ярамый башлый һәм бары Кремльнең төньяк-көнчыгыш өлешен сакларга ярдәм иткән табигый тоткарлау төсендә генә күпмедер әһәмияткә ия була.

Мунча күле... Исеменнән күренеп тора: тирәсендә мунчалар тезелеп киткән. XVI гасыр урталарында, сан алу кенәгаләренә теркәлгәнчә, күпләгән хосусый мунчалардан тыш, монда таштан салынган зур бер казна мунчасы да булган. Ул заманнарда күбесенчә селте белән юынсалар да, бу күл дә аз-азлап пычрана бара һәм XVI гасырда шулай ук Пычрак күл (Югары Пычрак күл) дип йөртелә башлый.

Югары Пычрак күл катлам ашалу-юылу белән хасил булган дигән фикер бар. Инде тәмам сасып беткән күлне 1886 елда күмәләр. Күп тә

утми, бу урында яңадан уенты барлыкка килә, яңадан су җыела. Күл, әйтерсең лә, бирешергә теләми. Шәһәрдә бу хәл турында акылга сыймаслык сүзләр йөри... Күл үзен соңгы мәртәбә безнең көннәрдә дә сиздереп куйды: катлам юылу сәбәпле, Ленин урамындагы Пассаж бинасының төньяк өлеше ишелеп төште.

Черек күл... Н. М. Минһажева исәпләүләреннән күренгәнчә, бу күлнең дә мәйданы ун гектар чамасы булган. Шулай итеп, буалар системасының гомуми мәйданы Югары Кабанныкыннан зуррак булып чыга. Черек күл тирәсендә бораулагач, аның культуралы катлавы гаять зур булуы, егерме, урыны-урыны белән утыз метрга җитүе беленде. (Кремль тавында исә ул нибары ике-өч метрлап кына). Күрәсең, шәһәрнең кеше иң тыгыз утырган үзәк өлеше булгандыр бу.

Исеме үк күрсәткәнчә, бу күл дә хан заманнарында ук пычранган-черегән була. Моңа, күрәсең, янында гына урнашкан ат абзарлары да ярдәм иткән. Аларда утыз меңгә якын ат булган, дип сөйлиләр. Черек күл исеме (русчасы — Черное озеро) аның урынында барлыкка килгән парк исемендә сакланган.

Черек күлне Чишмә күленнән агып торган инеш туендырган.

Зур булмаган бу күл хәзерге Красин урамы тирәсендә, ягъни Черек күл батынкысының уң ягында була. Чишмә күленең суы кайчандыр аеруча тәмле булган, аны ипи пешерергә тотканнар, дигән риваять бар. XVI гасыр урталарына ул да пычранып-ләмләнеп бетә, 1774 елда күмелә.

XVI гасырда чагыштырмача чиста булып чылбырның өске буыннары — соңыннан Николай күле дип йөртелгән күл һәм Чиста күл генә кала. Кайбер таныкламаларга караганда болар икесе тагын да элегрәк бер тоташ күл — Ак күл булган. Күлләр тирәсендә тимерче һәм чүлмәкче алачыклары торган, бу да аларның пычрануына китергән. Яшерен чишмә шартлатылгач, камалыштагылар суны шуннан алырга мәҗбүр булган... Чиста күл 1812 елда, Николай күле 1842 елда күмелгән.

Борынгы шәһәр мәйданында, хәзерге Ирек мәйданы тирәсендәрәк Черек күл тезмәсенә кермәгән тагын бер күл булган. Элекке исеме безнең чорга килеп җитмәгән, соңрак аны Бассейн дип (якындагы Бассейн урамының исеме шуннан алынган) яки, Театр мәйданы исеме буенча, Театр күле дип атап йөрткәннәр. Аны да чишмәләр туендырып торган. Арткан су Касаткин тау урамы буйлап Казан елгасына агып торган. Монысын XIX гасыр уртасында күмгәннәр.

Әлеге күлләрнең язмышы безгә, хәзерге буынга, гыйбрәтле бер кисәтү булып тора.

Шәһәр дивары янынннан Болак агып торган, ул да Казан халкын су белән тәэмин итүдә зур роль уйнаган. Болакның уң ягында тыгыз урнашкан Түбән тышкы шәһәр, сулда Кыраиш бистәсе булган. Болактан төрле-төрле кярханәләр су алган, тотылган суны да Болакка түккәннәр.

Археологлар Кремль тавында аркылы кисеме кырыкка-кырык сантиметр булган агач улак таптылар. Улак хан сараеннан, Кремльнең башка җәмәгать корылмаларыннан Болакка таба сузылган. Күрәсең, Казандагы беренче канализация коллекторыдыр бу. Шәһәрнең төп өлеше, әлбәттә, мондый «унайлык»тан мәхрүм була, бөтен пычрак агынтылар ачык канаудан шул ук Болакка яки Черек күл батынкысына агып тора. Менә шуңа Болак инде XV гасырда ук эчә торган су чыганагы булудан туктап, асылда дренаж һәм канализация канавына әйләнеп кала. Әмма хикмәт пычрануда гына да түгел.

Соңгы елларда үткәрелгән тикшеренүләр шуны күрсәтә: күлләр тирәсендәге үтеп чыга алмаслык карурманнар инде XIII-XIV гасырларда ук тулысынча диярлек кисеп бетерелә. Җирләре сөрелә. Шуның нәтиҗәсендә Кабанны туендырып торган иксез-чиксез инешләр, ермаклар, чишмәләр башта зәгыйфьләнә, аннан бөтенләй кибә. Бу хәл Болакның да саегуына китерә. Болак ул заманда мөһим транспорт юлы

була бит: кораблар Иделдән һәм Казан елгасыннан аның аша Якын һәм Урта Кабанга иркенләп үтеп йөриләр.

Болак суы элек-электән берничә тегермәннең ташларын әйләндергән. Ике тегермән сан алу кенәгәләренә дә теркәлгән, берсе хәзерге пединститут бинасы янында, икенчесе Болак тамагында булган. Көймәләр үтеп йөри алсын өчен махсус шлюзлар да төзелгән. Шлюзларда су тирәнлеге ике метрдан да ким булмаган, бу исә шактый зур Идел корабларына да керергә мөмкинлек биргән.

XV гасыр азагында Болак нык кына саега, Кабанның яр буендагы Әрмән бистәсенә һәм башка торак пунктларга судноларга үтү кыенлаша. Елганы чистарту, тирәнәйтү ихтыяҗы туа. Һәм менә XV-XVI гасырлар чигендә Болакка беренче реконструкция үткәрелә. Төньяк урманнарыннан куып китерелгән «меңнәрчә чирмеш» һәм көньяктан килгән нугайлар, хан назирләре күзәтчелеге астында, яңа су юлы казып, Болакны турайталар. Тышкы шәһәр әйләнәсен дивар белән уратканда Болак ярын бурап ныгыталар, төбен ләмнән арындырып, имән ярка түшиләр. XIX гасырда булган зур янгын вакытында метр ярымлы ләм катламы астыннан көтмәгәндә әнә шул иске, әмма әле нык имән түшәмә килеп чыга... Елъязмалардан реконструкциянең хосусан оборона максатында үткәрелүе күренә — Болак кальганың ур чокырына әйләндерелә. Дренаж ягы да күздә тотылгандыр: инешнең түбән, баткак ярлары буендагы урамнар пычракка, мәңге кипмәс күлдәвекләргә күмелеп утыра торган була, Болакны тирәнәйткәннән соң аяк асты кипши төшә.

Болак турында князь Андрей Курбский болай дип яза: «...Көнчыгыш тарафтан — Казан елгасы, көнбатыш тарафтан Болак атлы инеш агып торыр, бик тә ләмле-лайлы вә кереп булмаслык, шәһәргә терәлеп агып, почмак манара эргәсендә Казан елгасына кояр, үзе Кабан дигеге күлдән агып чыгар, күл кечкенә булмастыр, каладан ярты чакрымда торыр». «Бик тә ләмле-лайлы вә кереп булмаслык» дигәндә Курбский зур Идел кораблары керә алмауны күздә тоткан булса кирәк, ник дисәң, көймәләр Болак буйлап XX гасырның 20 нче елларына кадәр йөреп торганнар.

Кешенең яман тәэсире эчке сулыклар һәм Болакта гына түгел, шәһәргә терәлеп торган табигатьтә дә чагыла. XVI гасыр башларында Казан янындагы тугай сокланып туймаслык була. Анда сабан туйлары, башка бәйрәмнәр үтә. «Казан елъязмачысы» болай дип яза: «Болактан Идел тарафынача искитмәле, күрекле вә олуг Патша болыны җәйрәп ятыр, җиде чакрымнар булыр, мул үлән ямь-яшел булып утырыр, төрледән-төрле чәчәкләр атар». Борынгы документлардан бу тугайдан ханның ат абзарлары өчен дисәтинәсеннән утызар чүмәлә печән чабып алынганлыгы мәгълүм. Әмма гасыр азагына, Болак аръягында Татар бистәсе барлыкка килгәч, тугай табигый матурлыгын җуя, чүп түгү урынына әйләнеп китә. Соңрак әлеге урын чын-чынлап шәһәрнең нәҗес чокырына әверелә, бу бәладән бары Куйбышев сусаклагычы гына «килеп йола».

Кабан шәһәрдән читтә булса да, тирәсендә авыл һәм бистәләр шактый күп була. Якын Кабанның көньяк-көнчыгыш ярында (хәзерге Татарстан һәм Париж коммунасы урамнары тирәсе) — ул заманнар өчен шактый зур таш мәчет (сан алу кенәгәләренә Үтәш мәчете дип теркәлгән) торкан Кыраиш бистәсе. Төньяк ярда (Свердлов һәм Калинин урамнары тирәсе) — Әрмән бистәсе, анда Әрмәнстаннан килгән осталар — ташчылар, тимерчеләр, зәркәннәр (ювелирлар) һ.б. яши. Археологлар бу урында христиан храмы, әрмән зираты калдыклары табалар. Бераз арырак, хәзерге зоопарк тирәсендә, Колмәмәт дигән татар бистәсе була.

Каршы ярдагы Плэтән дигән зур бер авылның исеме, Казанның шул төбәгенә беркетеп, бүгенге көннәргәчә килеп житте. Урта Кабандагы кала турында әйтеп үткән идек инде.

Кабан күлләре тезмәсе, шул исәптән, якын Кабан да XVI гасырга матурлыгын һәм чисталыгын саклап калган була әле. Әмма беренчел, табигый сафлык түгел инде бу. Кабанның суын эчәләр, төрле хуҗалык ихтыяҗларына тоталар, мал сугаралар, яшелчәгә сибәләр... Һәм... алдын-артын уйлап тормастан, чүбен-тиресен Кабанга түгәләр, юынтык су да агызалар.

Болак кебек үк, Кабан да мөһим су юлы була. Күл буендагы күп санлы пунктлар арасындагы алыш-биреш, авыл хуҗалыгы продуктларын — шәһәргә, һөнәрчелек әйберләрен авылларга илтү тулысынча диярлек елгачыларга йөкләнә. Балык тоту, сал агызу да бар бит әле. Хәрби походлар, борынгы Казанның сәүдә багланышлары елъязмаларына караганда, Идел, Казан суы, Болак һәм Кабан күле буенча төрле-төрле конструкциядәге кораблар йөзгән. Сан алу кенәгәләрендә аларның русча исемнәре китерелә: ладьялар, струглар, дощаниклар, устюжналар, ботлар, ботниклар, неводниклар һ.б. Кайберләренең озынлыгы 12-14 метрга җитә, аларда җилкән һәм уникешәр ишкәкче булган. Бер һәм ике мачталы кораблар йөзәр пассажир, 30—100 тонна йөк алган.

Мондый зур суднолар «бик тә ләмле-лайлы вә кереп булмаслык» Болактан ничек үткән соң? Йөк корабларының Болактан XIX гасыр башларынача йөрүен белгән хәлдә, бер фаразга урын кала: русларның Казанга походы алдыннан казанлылар Болакны махсус шундый хәлгә китергәннәрдер. Моның өчен буаларны ерып суын агызырга гына кирәк ләбаса.

Риваятьләргә караганда, хан һәм аның яраннары Урта Кабан буендагы җәйге резиденциягә зиннәтләп эшләнгән махсус көймәләрдә барганнар. Әнә шундый көймәләрнең берсендә Сөембикәне[1] Мәскәүгә алып китәләр. «Казан елъязмачысы» аның тасвирламасын калдырган:

«Аны алдан хәстәрләнгән патша көймәсенә алып керделәр. Ушбу көймәдә элгәре патша сафа кылырга йөргәндер. Бик тә тиз, очкан кош кеби барыр иде, бәгъзе урыннары алтын вә көмеш берлән бизәлгәннәрдер. Көймә уртасында пыяладан, ябып торган фонарь кеби тирмә эшләнгәндер, алтынлы такталар беләң ябылгандыр, анда патшабикә утырыр иде, патшабикәгә юанычка воевода тагын 70 хатын һәм вә күрекле утыз кыз алганнар иде — асыл зат нәселдән. Патшабикәне түшәккә хаста килеш салганнар иде».

Шулай итеп, Кабанның соңгы мең елда кешенең интенсив хуҗалык эшчәнлеге сферасында булуын икеләнми әйтергә мөмкин. XIII гасырның икенче яртысында Казан ханлыгының милли үзәген тәшкил иткән болгарлар күпләп күчеп килә башлагач, бу тәэсир аеруча көчәя...

## 8

Кабан күле турында мәгълүмат җыйганда, ханнар хәзинәсе турындагы риваятьнең иң борынгы язмаларын да эзләдем. Ни гаҗәп, алар табылмады. Бу — риваять түгел, гаилә эманәте диюе белән Әҗемов карт хаклы булды микәнни?

---

[1] Сөембикә — соңгы ике Казан ханы Җан Гали белән Сафа Гәрәйләрнең хатыны, нугай морзасы Йосыф кызы. Казанга 1532 елда китерелә. Гаҗәеп чибәрлеге белән, аннан да битәр зирәклеге белән дан тота. Халык арасында абруе, йогынтысы зур була. Сөембикә турында риваятьләр бик күп. Кремльдәге манара аның исеме белән аталган. Безнең көннәргә килеп җитмәгән бай китапханә һәм Кабан буендагы бакча да аның исемен йөрткән. 1551 елда Казан янына йөз меңле гаскәре белән Иван IV килеп җиткәч, канлы бәрелешне булдырмый калу һәм дә вакыт оту, шул ук вакытта көчле генә тәхет дәгъвачысыннан да котылу өчен, Казан морзалары Сөембикәне русларга бирәләр. Бәләкәй улыннан аерып, мөхтәрәм әсир итеп, аны Мәскәүгә алып китәләр.

Чыннан да, риваять — халык авыз иҗатының үз структурасы, сюжеты, образлар системасы булган проза жанрларыннан берсе. Күп кенә риваятьләрнең нигезендә чыннан да булган, әмма хыял белән баетылган вакыйгалар ята. Ә менә бу хәбәрнең сюжеты да, образлары да, фантастик төсмерләре дә юк. Асылда бу — имеш-мимеш, тикшерелмәгән мәгълүмат кына.

Әмма «имеш-мимешнең» гомере озын булып чыккан — ул дүрт йөз елдан артык яши бирә. Пугачев восстаниесеннән соң кайберәүләр Кабан төбендә яткан хәзинәләрне, Пугач патша килүдән куркып, байлар яшергән дип сөйли башлый. Тагын да соңрак исә, Октябрь революциясеннән соң, аны чит илләргә качкан байгуралларга китереп бәйлиләр. Егерменче елларда нык кына баеп калган нэпманнар яшергән, дигән сүзләр дә йөри.

Хәер, боларның да реаль җирлеге булуы бик мөмкин. Кырык еллап элек, тәрбиячеләре белән Кабан буенда һава сулап йөргәндә, бакча балалары яр буе комыннан яртылаш чыгып торган чүлмәк табалар. Бала-чага бит...

Башта тирә-ягын казып, күтәреп карамакчы булалар. Чүлмәк шактый саллы, бала күтәрерлек кенә түгел икән. Авызы ныгытып бәйләнгән. Шуннан таш белән бәреп, чүлмәкне ваталар. Чүлмәктән берничә кило алтын тәңкәләр, асыл ташлы бизәнү әйберләре: алкалар, йөзекләр, муенсалар коела... Тәрбияче апа аптыраганнан ни әйтергә дә белми. Табылдыкны милициягә тапшыралар. Ул, чыннан да, Казан байларыныкы булып чыга. Революция чорында яшерелгән булган, күрәсең. Башка шундый табылдыклар турында да сүзләр күп йөри.

Болак аръягы халкының ханнар хәзинәсенә ышанычы шундый зур була ки, НЭП елларында бер оста авантюрист аны табу өчен яшерен акционерлар ширкәте дә оештыра. Фаш ителгәнче, ул күп кенә Казан нэпманнарының акча янчыкларын җиңеләйтеп өлгерә. Фатих Хөсни «Алтын эзләүчеләр» повестеның сюжетын шул вакыйгага нигезләгән.

Моның өше һәр хәбәр-мәгълүмат җентекләп тикшерүгә, анализлауга мохтаҗ. Тарихи чыганакларга таянып, кайбер четерекле сорауларга җавап эзләп карыйк.

Беренче сорау: Казан ханлыгында яшерер мал булганмы?

Алтын Урда хәрабәләрендә калкып чыккан Казан ханлыгы Көнчыгыш Европаның иң зур мөстәкыйль дәүләтләреннән санала. Хәзерге Идел буе татарларыннан тыш, ул Урта Иделдәге күп кенә башка халыкларны да үз канаты астына берләштергән. Рус елъязмаларының берсендә 1469 елда Казан ханы Ибраһимның «Үзенең бөтен илләре — Кама, Чепья, Костяк, Идел, Вотяк һәм Башкорт иле белән» яу чабарга җыенуы язып калдырылган. 1552 елда Казанны алуда катнашкан воевода Андрей Курбский болай яза: «Ошбу патшалыкта татар теленнән гайре биш төрле тел бардыр: мордва, чуваш, чирмеш, вотяк яки ар телләре, бишенчесе башкорт теле булыр».

Әлбәттә инде, һәрбер феодаль дәүләттәгечә, Казан ханлыгында хезмәт халкын аяусыз изү дә, авыр салымнар да, фетнә-чуалышлар да булган. Хан ялчыларының зур бер катламы казнага акча кертүне кайгыртып торган: ясак, гошер һәм башка төрле салым җыючылар, тамгачылар (чик буе салымы җыючылар), үлчәүчеләр, бахшилар (язу-сызу эшен башкаручылар) һ. б. Ханлыкта яшәгән һәрбер кеше исәпкә алынып, бер яки берничә төрле салым түләгән. Сәхип Гәрәй ярлыгында хан казнасына керә торган җыемнарның унөч төре саналган: ясак, салым җан башыннан түләнә, клан (имана), сала хәреҗе (җир өчен) һ. б. Шулай итеп, хан казнасына зур гына сумалар агылып торган.

Тарихтан беләбез: Мәскәү белән Казан дәүләтләре арасында феодаль сугышлар тукталып тормаган. Хәзер, ярты мең ел узгач, гаепле-

ләрне эзләү, җаваплылык йөген теге яки бу халык иңенә салу ахмаклык булыр иде. Гади халык каны түгелсә дә, сугыш феодаллар тарафыннан алып барылган һәм иң элек ганимәт, мал табу өчен алып барылган. Ганимәт исә аздан булмаган. Никон елъязмасында, 1551 елгы солых буенча, Казаннан Зөя аркылы 60 мең әсир алып чыгылуы теркәлгән. «Казан тарихы»ның авторы Казандагы рус әсирләренең санын йөз меңгә җиткереп түгәрәкли (тарихчылар фикеренчә, бераз арттыра төшә). Казан ханлыгында әсирләрне кол буларак файдаланмаганнар. Бер өлешен, җир биреп, ясаклы крестьян иткәннәр, бер өлешен Кырым аша коллыкка сатканнар. Бу керемнәр казнаның шактый өлешен тәшкил иткән, зур хәрби башлыклар, солтаннар, әмирләр, карачылар, шәехләр, имамнар һ. б. өчен менә дигән баю чарасы булган.

Әмма иң күп керемне сәүдә биргән. XV—XVI гасырларда Казан, Көнчыгыш белән Көнбатыш арасындагы сәүдә үзәге буларак, борынгы Болгар урынын ала. Иделдәге Сәүдә утравында (ул соңгы чорда Маркиз утравы дип йөртелде, Куйбышев ГЭСы төзелгәч, су астында калды) ел саен Көнчыгыш Европадагы иң зур ярминкә үткәрелә. (Соңрак бу роль күпмедер дәрәҗәдә Нижний Новгород янындагы Мәкәрҗә ярминкәсенә күчә.) Монда Төркиядән — аш тәмләткечләр, Ираннан — китап, Урта Азиядән — әлү кагы, йөзем, өрек, Әрмәнстаннан — бизәнү әйберләре, Шәмәхәдән (Азәрбайҗан) — затлы тукыма һәм нефть, Көнбатыш Европадан кәгазь, дары һ. б. китергәннәр. Казаннан исә затлы мех, кызыл балык, бал, бодай икмәге, ат, күн аяк киеме һәм башка шуның ише әйбер алып киткәннәр.

Казанның төп сәүдәсе Русь белән барган. Шунысы игътибарга лаек: тыныч еллар һәр ике як өчен дә күп отышлырак булган. Р. Фәхретдиновның «Ташлар моңы», (Казан, 1986) китабында китерелгән бер вакыйга игътибарга лаек. Бервакыт, казанлыларга үч итеп, аларның сәүдә бәйләнешләрен бозарга теләп, Мәскәүнең бөек кенәзе Василий III рус сәүдәгәрен Казан ярминкәсенә барудан тыя. Әмма, Көнбатыш Европа сәяхәтчесе С. Герберштейн сүзләренә караганда, моннан Мәскәү үзе дә зыян гына күрә. «Чөнки, моның нәтиҗәсе буларак, Мәскәү илендә, Идел буйлап, Каспийдан, Әстерхан базарыннан, шулай ук Иран һәм Әрмәнстаннан китерелә торган товарларга җитмәүчелек һәм кыйммәтчелек сизелде». Шул ук Герберштейн Казан җиренең икмәккә, мал-туарга, балга, яхшы балыкка, кыйммәтле мехларга гаять бай булуын да әйтеп китә.

Ярминкә елга бер үткәрелсә, Казандагы Кәрвансарайда, Арча кырында, Казанның күп кенә башка базарларында сәүдә шау-шуы бер дә тынып тормый. Мәскәү сәүдәгәрләренең Казанда үз кибетләре була. Алар тукыма, тоз, корал, дирбия, балта-пычак, чалгы, энә, күзгә кебек нәрсәләр белән сату итәләр.

Шәрык сәүдәгәрләре исә ширван ефәге, димәшкъ корычыннан эшләнгән кылычлар, кызыл шәраб, тәм-том һ. б. саталар. Читтән килгән сәүдәгәрләрнең санын шуннан да чамаларга була: сәүдә өчен кулай булмаган хәвефле 1552 елда, шәһәрне Иван IV гаскәрләре камап алгач, рус елъязмалары әйтүенчә, казанлылар белән бергә биш мең чит ил сәүдәгәре: бохаралылар, төрекләр, әрмәннәр һ. б. да бикләнгән.

Ханнар, гадәттә, сәүдә кеременең уннан бер өлешенә канәгатьләнә торган булганнар. Анысы да шактый җыелган.

Кыскасы, тарихчылар йөз елдан артык вакыт эчендә хан казнасында зур хәзинә тупланганлыгына шикләнмиләр. Ханбикә Сөембикәне 1551 елда Мәскәүгә озатканда кенәзь Василий Серебряный төзегән опись әлеге байлыкның бер өлеше турында беркадәр мәгълүмат бирә. Ул вакытны Сөембикә белән «алтын-көмеш, алтын вә көмештән ясалган савыт-саба, зиннәтле урын-җир, төрледән-төрле патшалар киеме вә төрле сугыш коралы суга күмелердәй итеп төялгән уникe зур көймә» алып китәләр. Күрәсең, бу Сөембикәнең шәхси милке булгандыр. «Суга күмелер-

дәй итеп тәялгән» уникә зур кораб ул заманнар өчен аз түгел.[1]

Сөембикә китеп бер ел үтүгә үк, Казанны алган Иван Грозный «патша казнасын үз күзләрем белән күрим» дип хан сараена килгәч, анда телгә алып сөйләрлек берни дә күрми. Ганимәт буларак Мәскәүгә бары кызылсу алтыннан ясалган, асылташ белән бизәлгән хан таҗын («Казан бүрке» дип исемләнгән бу таҗ хәзер Мәскәүнең Корал палатасында саклана), хан байракларын һәм ханның шәхси коралын гына алып китәләр. Иван Грозныйны яңа гына алынган, дөрләп янган Казан буйлап озата йөргән хезмәтче шулай дип язып калдырган.

Икенче сорау. Яшерелгән хәзинәнең ниндирәк булуын безгә килеп җиткән чыганаклар буенча чамалау мөмкинме?

Ул чорда төп мал булып алтын-көмеш акча санала. Әлегәчә табылган борынгы хәзинәләр, нигездә, шулардан гыйбарәт. Әмма Казанда акча сугу йорты эшләгәнме?

Сорау җиңелдән булып чыкмады. Нумизматика белгечләре бер мәсьәләдә уртак фикергә килделәр: Болгар дәүләтендә акча сугу эшенык кына алга киткән булган. Табылган күп санлы Болгар хәзинәләре шуны күрсәтә: тәңкәләрнең саны буенча да, сыйфаты һәм төрлелеге ягыннан да Көнчыгыш Европа дәүләтләренең бик азы гына борынгы Болгар белән ярыша алган.

Р. Фәхретдинов фикеренчә, Алтын Урданың соңгы, Казан ханлыгының беренче чорында Урта Иделнең акча сугу үзәге элек Казан әмирлеге башкаласы булган Иске Казанга күчкән. Бер Светино хәзинәсендә генә дә 7779 тәңкә табылган. Шуларның 640ында «Болгар-эл-җәдид», ягъни Яңа Болгар дип (ханлыкның яңа башкаласы Казанны ул чакта шулай дип йөрткәннәр), калганнарына «Болгар» дип кенә сугылган. Фәхретдинов, сугу үзенчәлекләре буенча, алары да Иске Казанда сугылган дигән фикердә тора. Татар нумизматикасы белгече, Ә. Мөхәммәдиев исә моның белән килешми. Ул хәтта «Болгар-эл-җәдид» тәңкәләре дә яңа Казанда сугылган дип бара. Аның фикере белән тарихчы С. Алишев та килешә. Һәр галимнең үзенчә дәлилләре дә бар. Әмма... Әлегә XV гасырның уртасыннан соң яңа Казанда сугылган, дип кистереп әйтерлек бер генә тәңкә дә мәгълүм түгел.

Икенең берсе: йә Казан ханлыгы үзенең иң зур үсешкә ирешкән чәчәк ату чорында акча сугу йортына ия булмаган, йә... бөтен акча кинәт кенә һәм тулаем җыеп алынган.

Нинди генә очракта да ханлыкның алтын запасы тупланырга тиеш иде ләбаса. Казан ханлыгында гарәп дәрһәме, рус гривналары, Көнбатыш Европа тәңкәләре һ. б. да йөргән. Ләкин Иван Грозныйның ганимәт буларак акча кулга төшерүе турында бер генә чыганакта да әйтелмәгән. Савыт-саба, корал, затлы кием-салым санап кителә, ул заманнарда төп хәзинә исәпләнгән акча исә беркайда да телгә алынмый. XV гасырның икенче яртысы — XVI гасырның беренче яртысында сугылган Казан тәңкәләре дәүләт музейларында да, хосусый коллекцияләрдә дә юк.

Ә бит, рус елъязмаларына караганда, 1552 елда Казан ханының утыз меңлек гаскәре була. Хан гаскәриләргә алтын-көмеш акча түләп тора. Шуларга түләр өчен тупланган казнасы гына да шактый зур хәзинә булгандыр. Ул кая киткән?

Өченче сорау: Казан ханнарының яшерер нәрсәсе булсын да ди. Яшерү мөмкинлеге булганмы соң?

Әлегәчә, яшерелгән хәзинә турында сүз кузгалуга, тикшеренүчеләрнең фикер юнәлеше бер генә юнәлештә бара иде: камалган шәһәрдән шул кадәр малны алып чыгу мөмкин эшме?

Мәгълүм ки, камалыш ике ай дәвам иткән. Урта гасыр шәһәрләренең барысында да диярлек тышкы дөнья белән бәйләныш өчен яшерен

---

[1] Бу байлык Мәскәүгә исән-имин барып җитә, әмма соңыннан эзсез югала — талаеып-тузып бетә, күрәсең.

җир асты юллары ясалган. Мондый юллар Казанда да булган.

Нургали манарасы янындагы чишмәгә илткән яшерен юл турында күп язылды. Воскресенский калкулыгының көнчыгыш ягыннан Черек күл ягына сузылган чокыр турында да мәгълүматлар бар. XIX гасыр башында, шул тирәдә төзелеш эшләре алып барганда, хан заманнарыннан калган, ныгытып томаланган уем белән очланган җир асты юлына тап булалар.

Әмма сугыш вакытында бу юллар аша казнаны алып чыгуы ифрат кыен. Аннары... Чишмә юлын саткан җанның бүтән юлларны да белгән булуы ихтимал. Юлларның икенчесен шуңа томаламадылар микән? Беренче карашка, хәзинәне шәһәр эчендә яшерү, берәр подвалда, базга күмү җиңелрәк булыр иде кебек.

Әмма казанлылар Иван Грозныйның яу белән киләсен берничә ай алдан белеп торганнар. Башта алар Кырым һәм Төркия белән ярдәм хакында килешеп куярга омтылалар. 150 меңле рус гаскәренең якынаюы беленгәч, илне ныгыту чаралары күрелә: гаскәр җыела, якын-тирә авылларның халкы күчерелә, азык һәм кирәк-ярак запаслары туплана. Арча ягында озак камалышка исәпләнгән ныгытма корыла, анда Япанчы әмир кул астындагы атлы гаскәр урнаша (ул соңыннан камаучыларны нык бимазалап тора).

Ханның үз акылы җитмәсә, хакимнәрнең зирәкләре бу юлы эшнең ничек бетәчәген чамалагандыр. Рус чирүе биш тапкыр зуррак була. Корал да аларда күбрәк, дарысы да мулрак. Руслар шәһәр ныгытмаларын ваттыруда зур тәҗрибә туплаган чит ил белгечләре ярдәменә таяналар (шәһәрнең язмышын шактый дәрәҗәдә шул хәл итә дә).

Мәгълүм ки, Казанда ул елларда ике партия була. Берсе Мәскәү белән якынаю ягында торса, икенчесе солтан Төркиясе һәм Кырым белән союзга өмет баглый. Ахыр исәптә, соңгылары өстенлек ала. Әмма, ни генә булмасын, алары да мондый очракта җиңелү котылгысыз дип кисәтүчеләрнең сүзенә колак салмый кала алмаслар иде.

Әгәр дә хан казнасын коткару мәсьәләсе, эш узгач, шәһәр камалгач түгел, бәлки аңарчы алга баскан булса, хәзинәне җиңелгән килеш тә алып китә алырлык итеп яшерергә тырышырлар иде. Шәһәрдән читтәге берәр аулаграк урында күмүдән дә җиңеле юк, әлбәттә. Тик дошман шымчылары мыжгып торган, халык бик тыгыз утырган урта гасыр шәһәреннән казна кадәр казнаны сиздермичә генә алып чыгып кара әле! Кеше сатмаган хәлдә дә арба, тояк эзе яки көрәк эзе сатачак.

Кабанга тоташкан Болак исә шәһәргә ышкыла язып ага. Сүз таралса-нитсә дә, көймәнең (яки көймәләрнең) кай турыда туктаганын ничек чамалыйсың ди? Хәзинәне судан алыр өчен, күрәсең, нинидер бер хәйләсе дә булгандыр. Ни генә уйлап тапмас адәм баласы!

Шулай итеп, Кабан күле төбендә хәзинә булуы бик ихтимал. Ләкин моны исбат итү өчен бик җитди эзләнү-тикшеренүләр алып барырга кирәк. Мәсьәләнең шул ягы катлаулы: күл суы ике метр тирәнлектән күкертле водород белән агуланган, монда төшү сәламәтлек өчен куркыныч. Тагы бер кыенлык: бу тирәнлектә кыйммәтле металл хәзинәсен күрсәтерлек приборлар бездә юк. Шуңа күрә мәсьәлә әлегәчә чишелмәгән килеш кала...

*Ахыры киләсе санда*

## ӘДӘБИ МИРАС

# МӘҖМУГЫ-Л-ХИКӘЯТ

«Хәбәр сөйләүчеләр вә əсәр күчерүчеләр шулай риваять иттеләр...» — Бу хикәятләрнең күбесе, гадәттә, шулай башланып китә. Әйе, халкыбызның рухи мирасы булган күп кенә әдәби җәүһәрләр, әнә шулай телдән-телгә сөйләнеп, дәфтәрдән-дәфтәргә күчерелеп, күңелләрдә сакланып, еллар һәм чорлар аша үзгән.

Әдәби мирасны барлау, өйрәнү, халыкка басма китаплар рәвешендә яңадан кайтару эше соңгы вакытта аеруча җанланып китте. Кол Галинең мәшһүр «Кыйссаи Йосыф»ы, Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари һәм Габделҗаббар Кандалый әсәрләреннән төзелгән җыентыклар әнә шул зур эшнең матур үрнәкләре булды.

Әмма шуны да әйтергә кирәк: әдәби мирасыбызның урта гасырлардагы гаять бай һәм үзенчәлекле чәчмә әсәрләре әле күпләргә билгеле түгел. Һәм, гомумән, әлегә татар телендә урта гасырлар прозасы әсәрләреннән төзелгән бер генә китап та басылып чыкканы юк. Әдәбият тарихын өйрәнүче галимнәр тарафыннан соңгы вакытта илебезнең төрле китапханәләрендә, архивларында кулъязма хәлендә сакланган бик күп чәчмә әсәрләр табылды. Аларның кайберләре, хәзерге әдәби телгә күчерелеп, халыкка кабат ирешү юлында. Шундый кулъязма җыентыкларның берсе — XVIII гасыр татар әдәбиятының кыйммәтле ядкаре булган хикәятләр җыентыгы — «Мәҗмугы-л-хикәят».

Шактый зур күләмле бу кулъязма китапка Көнчыгышта һәм Европада киң таралган, берсеннән-берсе мавыктыргыч булган 33 хикәят тупланган. Җыентык 1775 елда Мөхәммәдрәхим бине Рәфыйк Казани тарафыннан төзелгән һәм күчереп язылган. Мөхәммәдрәхим үзе чыгышы белән Татарстанның хәзерге Арча районының Ташкичү авылы кешесе. XVIII йөздә бу авылда данлыклы мәдрәсә булган, анда үз заманының күренекле кешеләре укыган һәм укыткан. Мөхәммәдрәхим әлеге җыентыкны Себердә — Тубыл губернасы, Тара өязендә бараба татарлары арасында яшәгән чакта туплаган. Аның үзен Себер ягына нинди язмыш җилләре ташлагандыр — монысы билгесез. Патша Россиясенең көчләп христианлаштыру сәясәте нәтиҗәсендә сөрелеп китәргә мәҗбүр булганмы ул, әллә 1773—1775 еллардагы Крестьяннар сугышы җиңгә батырылгач, эзәрлекләүләрдән качып киткәнме — ни генә булмасын, Мөхәммәдрәхим бине Рәфыйк Казани, үзе белек ук катлаулы язмышлы шушы кыйммәтле әдәби ядкарьне туплап, киләчәккә мирас итеп калдырган. Ул чорда Тубыл губернасында төрле төбәкләрдән, бигрәк тә Идел буеннан һәм Урта Азиядән килгән укымышлылар һәм зыялылар күп булган. Алар монда үзенә күрә бер мәдәни үзәк тәшкил иткәннәр. Шуңлыктан, Себер ягында әдәби иҗат белән шөгыльләнү, китап күчерү, гарәп һәм фарсыдан әдәби әсәрләр тәрҗемә итү өчен мөмкинлекләр күбрәк булган. Күренекле татар язучысы һәм галиме Риза Фәхретдинев үзенең «Асар»ы исемле әдәби-тарихи энциклопедиясендә Себердәге укымышлылар хакында: «Ата-бабаларыбыз ядкарьләрен саклауда безнең Идел буе мөселманнарына караганда Себер мөселманнары гайрәтлерәк», дигән сүзләр язып калдырган. Тагын шунысын да онытмыйк: Себер — тамырлары бик тирәнгә киткән өч төрки әдәбиятының — уйгыр, үзбәк һәм татар әдәбиятларының очрашу, аралашу, бер-беренә тәэсир итешү мәйданы да ул. Әлеге әдәбиятларның һәр өчесе дә фарсы-таҗик әдәбиятының бәрәкәтле йогынтысын кичергән. Фарсы-таҗик әдәбияты исә, үз чиратында, гарәп, һинд һәм грек әдәбиятлары белән борын-борыннан нык бәйләнештә торган. Нәкъ менә шундый киң тармаклы бәйләнешләр нәтиҗәсендә, татар әдәбияты үзендә бөтен Көнчыгыш әдәбиятларына хас булган уртак сыйфатларны берләштергән, баеган, көч алган.

Мөхәммәдрәхим бу кулъязма китапка халык арасында йөргән берничә фарсы җыентыгыннан иң кызыклы әсәрләрне сайлап туплаган. Хикәятләр ирекле рәвештә тәрҗемәләнгән, кайбер урыннар төшереп калдырылып, кайбер урыннарда үзгәрешләр, өстәмәләр кертелгән. Башка чит телдәге әдәбиятлардан сюжет алу, аны үз әдәбиятың ихтыяҗларына туры китереп эшкәртү, ирекле тәрҗемә итеп файдалану — урта гасырлардагы әдәби хәрәкәтнең төп үзенчәлекләреннән берсе. Бу — татар әдәбиятына гына түгел, шул чорның башка әдәбиятларына да хас күренеш.

«Мәҗмугы-л-хикәят»тәге әсәрләр эчтәлекләре һәм төзелешләре ягыннан бөтен дөньяга мәшһүр «Мең дә бер кичә» әкиятләрен хәтерләтә. Ләкин, шул ук вакытта, бу хикәяләр үзләренең тормышка якынлыгы, геройларының эш-гамәлләре белән «Мең дә бер кичә» әкиятләреннән шактый аерылып тора. Аларның бу үзенчәлеген француз галиме Пети де ла Круа да бик сизгер күреп алган һәм әлеге җыентыкны 1712 елда фарсычадан французчага тәрҗемә итеп чыгарганда, китапка капма-каршы исем биреп, «Мең дә бер көн» дип атаган.

Шуннан соң, «Мәҗмугы-л-хикәят» җәүһәрләре бөтен Европа телләренә тәрҗемәләнеп, андагы вакыйгалар нигезендә бик күп яңа әсәрләр иҗат ителгән. Шуларның иң атаклылары — итальян язучысы Карло Гоццининың әкият-пьесалары, немец шагыйре Ф. Шиллерның театр өчен тәрҗемәсе һәм итальян композиторы Дж. Пуччинининың «Принцесса Турандот» операсы.

«Мәҗмугы-л-хикәят», ерак юллар үтеп, Мөхәммәд бине Рәфыйк Казанининың туган якларына да кайтып җиткән, халык арасында киң таралган, яратып укылган, кулдан-кулга йөреп, күчерелгән. Моны соңгы елларда китапханәләрдән, архивлардан һәм халык кулыннан табылган байтак кына кулъязма вариантлар да раслап тора. Без мөрәҗәгать иткән кулъязма китап исә Ташкичү авылының янәшәсендә генә урнашкан Кысна авылында 1963 елда табылган. Ул хәзер СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының кулъязмалар хәзинәсендә саклана. Шушы институтның фәнни хезмәткәре Нәҗип Исмәгыйлев «Мәҗмугы-л-хикәят»не хәзерге әдәби телгә күчерде һәм аны басма китап итеп чыгару өчен әзерләде. Журналның бу саныннан алып, без укучыларга әлеге әдәби җәүһәрләрнең бер өлешен тәкъдим итә башлыйбыз.

## Тозакка төшкән мәхәббәт турында хикәят



Хәбәрләрне сөйләүчеләр һәм әсәрләрне күчерүчеләр шулай риваять кылдылар:

Фарсы илендә бер падишаһ бар иде, тулы һөнәрле, атаклы шәһреяр [1] иде. Бер углы бар иде, чибәрлек-матурлыкта үз тиңе юк иде. Исемен Фәррухшад диярләр иде. Шәһәрендә йөреп, һәр көн атасы янына керер, янәшәсендә булып, хезмәт итәр иде.

Бер көн хәстә булды. Атасы шунда ук янына килде. Күрде: хәл башкача. Гаять тынгысызланды һәм борчылды. Боерды: барлык табибларны [2] китерделәр, шаһзадәне терелтсеннәр дип. Никадәр дәва кылсалар да, авыруы кире кайтмады. Ахырда белгечләр сиздeләр: шаһзадәнең авыруы тән авыруы түгел, җан авыруыдыр. Падишаһ әйтте:

— Бер чара белән моның серен белү кирәк,— диде.

Шаһ вәзиренең бер углы бар иде, Фәррухруз исемле. Шаһ аны чакырды, әйтте:

— Әй углым! Фәррухруз! Дустың катына бар. Сора, чиренең сәбәбе ни, гыйшык чире булмагае. Бәлки серен сиңа ачар,— диде.

Вәзир углы барды, дусты янында утырды. Шаһзадә, аны күреп, шат булды. Әйтте:

— Әй туган! Мине күрергә килдеңме?— диде. Фәррухруз йөзен җиргә куйды, әйтте:

— Әй җанымның җаны! Бу авыруыңның сәбәбе нидер? Әйтеп бирсәң булмасмы? — диде. Шаһзадә әйтте:

— Серемне яшерен тотсаң, кыйссамны сөйлим.

Фәррухруз аның аягына төшеп:

---

[1] Шәһреяр — хөкемдар, падишаһ

[2] Табиб — доктор

— Серләреңне күңелемдә җаным кебек сакларммын! — диде. Шаһзадә сөйләде:

— Әй атаклы дустым, вай, кайгыны уртаклашучы иптәшем! Дәртем бу: бер кичә төшемдә үземне бер болында күрдем. Шулкадәр матур — Ирәм [1] бакчасы кебек. Бер матур урында ай сыман нурлы бер чибәр кыз утыра. Алдында башымны җиргә куеп, догалар кылдым. Ул күңел юаткыч җиңен селкеде:

— Һай, кит! Миңа карама! — диде. Мин әйттем:

— Ни өчен!

Ул әйтте:

— Ирләрдә тугрылык юктыр,— диде. Мин:

— Ни мәгънәдән? — дидем. Ул әйтте:

— Төшемдә күрдем: бер аучы тозак корды. Бер ата киек аңа төште. Анасы килде — ул якка, бу якка йөгергәләп, тырышып, төрле хәйлә кылды, ахырда бушатты. Өч тапкыр бу хәлне кылды. Казага каршы, бер көн ана киек тотылды исә, ата киек килде, күрде: ана киек тотылган. Һич карамады, йөреп китте. Аучы килде, киекнең башын кисте. Миңа моннан мәгълүм булды: ирләрдә вафа [2] юк икән. Мин ул көннән бирле ирләрне уйлаудан бөтенләй азат булдым,— диде.

Ул сүзләрне аннан ишеттем исә, аерылу куркынычыннан каен яфрагыдай тетрәндем. Йокымнан уяндым, сөекләмнең эзен күрмәдем, гыйшык кайгысы бөтен барлыгымны биләп алды. Менә шуның өчен газапланам, инде үлем хәленә ирештем, хәлемне беркемгә әйтмәдем.

Фәррухруз дога кылды, әйтте:

— Әй шәһәрнең шаһзадәсе! Җан-күңелеңне иркен тот, хезмәтең билбавын биләмә баглап, җиһан сараен гизеп, сөйгәнеңне кулыма төшермичә, йокы йокламам,— диде.

Торды, падишаһның катына барды, ишеткәнен башыннан ахырынача падишаһка сөйләде. Падишаһ әйтте:

— Инде ничек итәрбез?

Фәррухруз:

— Әй теләгенә ирешүче шәһреяр! Бер чара итү кирәк, рөхсәт бирсәгез, җиһан сараен гизсәм, йә читтә сөрелеп йөрермен, йә бәхеткә ирешермен,— диде. Мәлик бу сүзне яхшы тапты, боерды, хәзинәсен ачты. Бәхет йолдызы астында Фәррухшад белән Фәррухрузны сәфәргә күндерделәр.

Берничә көннәр йөреп, ниһаять, Казвин шәһәренә ирештеләр. Шәһәр тышында бер җирне сайлап, шунда кундылар.

Казвин шаһы шаһзадәнең килгән хәбәрен ишетеп, хаҗипларны [3] җибәрде. «Җәяү барыгыз»,— диде. Алар килделәр, кабул иттеләр. Фәррухшад хаҗипларны кадерләде, падишаһның саламәтлеген сорады. Хаҗип әйтте:

— Хак ярдәмендә сәламәттер. Ләкин бер сөекле улы бар иде, вафат булды,— диде. Фәррухшад күңелсезләнде:

— Нинди үкенеч! Монда килмәсәк яраган булган икән,— диде.

Хаҗип, кире кайтып, шаһ янына барды, Фәррухшадның матурлыгын, камил акылын һәм гыйлемлеген сөйләде исә, падишаһка әсәр итте.

Менә таң атты. Бу якта Фәррухшад Казвин шаһы тарафына йөрде. Шаһ та нәрчәннәре белән сарай капкасыннан тышка чыгып каршылады, хөрмәтләп сарайга китерде. Тәхет өстендә түшкә-түш утырдылар, берберсенә матур сүзләр сөйләп, күңелләре хуш булды. Боерды, табын хәзерләделәр, ашау-эчүдән соң шаһ әйтте:

— Әй углым! Күңел юаткыч сүзең белән матәмнән чыгу кирәктер,— дип, матәм киемнәрен салды, бизәкле нәфис күлмәк-киемнәр киде.

---

[1] Ирәм — легендар Шәддат патшаның атаклы бакчалары

[2] Вафа — тугрылык, бирелгәнлек

[3] Хаҗип — кунак кабул итүче, арадашчы

Аннан боерды, мәҗлес ясадылар. Мәлик Фәррухшадның хәрәкәтен, үз-үзен тотышын, утырмыш-тормышын күреп, гаять сөйде, ничә көннәр мәҗлес өзелмәде.

Бер көн сөйләшеп утырганда шаһтан углы хакында сорадылар, әйттеләр:

— Шаһзадәнең вафат булу сәбәбе нидән иде? — дип. Падишаһ елады, әйтте:

— Аның вафатының сәбәбе гаҗәеп кыйссадыр,— диде. Шаһзадә әйтте:

— Ничек?

Шаһ сөйләде:

— Әй бәгырь итем! Углыма шәһәр бәкләренең кызларын тәкъдим итеп карадым, берсенә дә игътибар итмәде. Ул исә Кәшмир падишаһының кызына күрмәгән килеш гашыйк булган икән. Мин, хәлне белеп, алтын-көмеш, энҗе-җәүһәрләр белән вәзиремне аңа күндердем. Әмма ул кызның атасы мин биргән алтын-көмешкә караганда ике өлеш артык җибәрде. Җавап язган, болай: «Кызымны кәнизәклеккә булса да бирер идем, ләкин кызым бөтенләй ирләрне теләми. Шуңа күрә үз иркенә куйдым».— дип. Язу килеп житте, кызның ир кочагын теләмәвенә сәбәп бу имеш: бер төш күргән. Төшендә бер аучы тозак куйган, аңа бер ата киек төшкән, ана киек килеп, җанын фида кылып, аны коткарган. Өч тапкыр шулай казадан коткарган. Бер көн ана киек тозакка төшкән, ата киек аңа карамый йөреп киткән. Аучы килеп, киекнең башын кискән. Шул сәбәптән кыз гыйбрәт алган: «ирләрдә тугрылык юк» дип. Атасына әйткән:

— Әгәр көч белән бирсәң, хәнҗәргә кадалам, үләм,— дигән. Углым бу кыйссаны ишетеп, өметсез булып, бездән аерылып китте. Сәбәбе менә шул,— дип, сүзен тәмамлады. Шаһзадә бу хәлне ишетеп, бик нык гаҗәпләнде, өстәвенә сөйгәненең торган җире беленде, түземлеге калмады.

Казвин мәлиге шаһзадәнең бу хәлен сизеп, әйтте:

— Әй җаным, углым! Ни булды, борчулы хәлдә күрәмен,— диде. Шаһзадә җавап бирмәде. Фәррухруз алгарак килде, әйтте:

— Әй шәһреяр, юмартлык иясе! Бу шаһзадәбезнең мөлкеннән, йортыннан, әсбапларыннан аерылып, сөрелеп йөрүенә сәбәп шул ук кыздыр,— диде.— Төш күргән,— дип, маҗараны баштан ахыргача бер-бер артлы сөйләп бирде. Мәлик шул кыз икәнен белеп, «аһ» итте:

— Безгә ни булды — аңа да шул ук була икән. Бердәнбер углымны мең төрле нигъмәтләр биреп үстердем, бәла яшене аны харап итте. Бу ай йөзлене дә минем углым кебек бәлагә дучар иткән икән. Аһ, ни эшлим?! — диде. Аннан Фәррухшадка әйтте:

— Әй кадерлем! Сабыр итсәң, сиңа булышам, ул чибәргә сине җиткерәм,— диде.

Икенче көн мәлик Фәррухшад белән Фәррухрузны өндәде. Әйтте:

— Бу кичә йокламадым, шаһзадәнең чарасы ничек булыр икән? — диде. Вәзир углы:

— Мин баш орам, башка кешенең кулыннан килмәс, сәфәргә үзем чыгам. Шаһ миңа рөхсәт бирсә, барам, ул кызны бер сыйфат белән китерәм — гаҗәпкә калырсыз,— диде. Мәликнең бу сүзгә күңеле булды. Әйтте:

— Әй кадерлем! Әгәр син бу эшне булдырсаң, мин падишаһлыгымның яртысын сиңа бирәм,— диде, Фәррухрузга дога кылды.

Икенче көнне Фәррухрузны бер яхшы, җил аяклы атка атландырдылар. Ул, мәлик һәм шаһзадә белән саубуллашып, Кәшмир юлын тотып, берничә көн йөреп, бер болынлыкка җитте. Ул болында бер биек сарай күрде. Ул бакчалы сарайның капкасына бер зур якут куелган, төбендә кәүсәр чишмәсе сыман бер чишмә бар.

Фәррухруз атыннан төште, ятты, йоклады. Уянды, күрде: атлас тукыма япкан бер болан аның янында тора, алтын-көмеш, энҗе-җәүһәр-

ләр белән бизәлгән. Килде, Фәррухрузның алдында торды, «һай-һай» елады. Вәзир углы гаять гаҗәпкә калды.

Бераз вакыттан соң сыерга охшаган тагын бер болан чыкты, үзе гел хәрәкәттә. Фәррухрузның гаҗәпләнүе тагын да артты. Шулай итеп, ул Ирәм бакчасыннан шундый бизәлгән матур боланнар чыкты, саннары юк, аның алдына килеп тордылар. Вәзирзадә фикер кылыр иде: «Боларның бер хәле бар»,— дип, шул уйда иде. Кинәт, югарыдагы тәрәзәгә карады, күрде: бер чибәр кыз, алтынлы киемнәр кигән, дәрт ялкыны бакча эчен зиннәтле итте. Ул ай йөзле кыз Фәррухрузга көлде, кулы белән ишарә итте.

Фәррухруз шунда ук янына барырга карар итте, киекләр Фәррухрузның итәгенә бастылар, җибәрмәскә теләделәр. Булдыра алмадылар, боларның каршылык күрсәтүләренә карамады, эчкәре керде. Ул кыз Фәррухрузга игътибар, хөрмәт күрсәтеп, әйтте:

— Ни кеше син? Кайдан килдең, кая барасың?

Фәррухруз әйтте:

— Әй гүзәл! Читтән килгән егетмен, фарсы дәүләтеннән Кәшмир иленә барам,— диде. Кыз:

— Бу көн кунак булсагыз иде, без монда кунак хөрмәте өчен утырабыз,— диде. Аннан бер өйгә алып керде, артыннан ук ай йөзле кәнизәкләр һәм кояш йөзле хадимәләр [1] табын кирәк-ярагы һәм тәгам китерделәр. Фәррухрузга «аша!» дип тәкъдим иттеләр. Фәррухруз ул тәгамнәргә кул озатты, бер кисәк авызына алды, йотар вакытта кыз:

— Бер киек бул! — диде исә, Алланың кодрәте белән, вәзирзадә бер болан булды. Бөтен үзенчәлекләре һәм эчке халәте шул боланда калды. Шунда ук өстенә бер атлас тукыма түшәделәр, аяк богаулары һәм беләзекләр тактылар һәм шул киекләргә куштылар.

Фәррухруз, бу вакыйгаларга очрады исә, әйтте:

— Моннан артык ни булыр?! Терелмәс чиргә һәм бу казага очрадым,— диде. Аннан белде: ул үзе күргән киекләр барчасы адәм икән.

— Болар минa иптәшләр икән,— диде. Аларның арасында йөрде, үлән ашады, туктаусыз шуның белән мәшгуль булды.

Бер көн Фәррухруз бер агач төбендә ятты, йоклады. Бер заманнан соң уянды, күрде: берничә атлы хатыннар тора. Араларында бер чибәр кыз гарәп атына атланган, көмеш һәм алтын белән үзен бизәгән, каршысында бер җария [2] бар. Җариясенә карап, әйтте:

—Күр бу мескенне, нишләгән. Ул яман фигыльле карендәшем эшедер,— диде. Боерды:

— Алыгыз бу киекне, бәладән коткарабыз,— диде. Моны ишетеп, Фәррухруз сөенде.

Шулай итеп, җария киекне алып, бераз бардылар. Бер аланга ирештеләр. Эчендә бер биек сарай бар. Ул ай йөзле атыннан төште, сарайга керде.

— Киекне алып килегез! — диде.

Ул хур сыман кыз бер алтын тәхеткә чыгып утырды. Боерды, киекне алдына алдырды. Бер кәнизәгенә кушты:

— Бар теге шешәне китер! — диде.

Китерде, эче тулы май. Боерды — тәгам китерде. Ул майны тәгамгә кушты. Ул тәгамнән бер бөртекне киек авызына куйды. Киек чәйнәде, йотар вакытта, ул күңел юаткыч кыз кычкырып әйтте:

— Янә баягы кебек адәм бул! — диде. Фәррухруз шунда ук адәм булды. Һәм ул кыз, аны күргәч, бөтен күңеле белән гашыйк булды. Әйтте.

— Әй гүзәл егет! Ни кеше син, һәм ни егет син?

---

[1] Хадимә — хезмәтче хатын

[2] Җария — хезмәтче кыз

Вәзирзадә башыннан кичкәннәрне бер-бер артлы әйтеп бирде. Кыз әйтте:

— Әй егет! Син хәлеңне миңа сөйләдең, мин дә кыйссамны сиңа сөйлим,— диде.— Әгәр минем әйткәннәремне тотсаң, морад-максатыңа ирешерсең.

Фәррухруз түбәнчелек белән:

— Җаным-күңелем белән әмереңә буйсынамын! — диде. Кыз:

— Бел һәм аң бул: син эзләп килгән кызның атасы — Кәшмир шаһы. Мин — шул шаһ вәзиренең кызы, исемем Миһерафзай. Сине киек итүче — минем карендәшем, синең кебек күп адәмнәрне киек итте, исеме Хөснарай, үзе сихерче. Әгәр мин булмасам, сине кем дә аның кулыннан ала алмас иде. Әгәр бу хәлне белсә, арабызда үпкәләр булыр,— диде.

Кыз аңа зур кадер-хөрмәт күрсәтте.

— Әгәр теләсәң, барлык морадың хасыйл булсын дисәң, башта мине алырга вәгъдәләш, шул вакытта мин синең эшеңә җанымны да фида кылырмын һәм эшеңне җиреңә җиткерермен,— диде. Фәррухруз шатланды, исе китте. Кыз да моны күреп, гаять сөенде. Вәгъдә бирештеләр. Шунда ук алтынлы киемнәр китертте, Фәррухрузга киерделәр, башына — таҗ, биленә патшаларныкы сыман билбау бәйләделәр, тәхеткә кичерделәр. Эчтеләр, ашадылар, кичә-көндез зәвык-сафалар сөрделәр.

Бер көн Фәррухруз әйтте:

— И зур хөрмәткә лаек ханым! Күңелемне азат кыл, эшем вәгъдәсенә җитмичә, миңа бу сафалар һәм шатлыклар ирексезлек белән үтәдер,— диде. Шунда Миһерафзай торды, бер букча алды, раһиблар [1] киемен чыгарды, биленнән бер янчык алды, эченнән бер ак туфрак алды, аннан хәләленә әйтте:

— Әй тугрылыклы ярым! Әгәр син морадыңа җитсәң, мине онытма! — диде. Фәррухруз аяк өсте торды, йөзен җиргә куйды, әйтте.

— Әй гомеремнең чыганагы! Бу ни сүз — син әйтәсең? Әгәр син булмасаң, миңа җан да кирәкми! — диде. Тагын:

— Әмереңә буйсынам, ихтыярыңа каршы килмәм,— диде. Шул вакыт Миһерафзай әйтте:

— Киемнәреңне сал, раһиблар киемен ки, зөннар [2] бәйлә, һәм бу майдан, һәм бу ак туфрактан бер кисәкне кәгазьгә төреп, үзеңдә сакла, һәм бу әфсенне укып йөр, шуның белән эшең башланыр. Шәһәргә җитсәң, капкасында сакчылар торыр, сине күреп, каршы килеп, әйтерләр:

— Әй олуг раһиб! Кайдан киләсең, кая барасың? — диярләр. Син әйт: «Көнбатыш җиреннән киләм, бөек Гайсәне күреп, зиярәт итү [3] өчен»,— диген. Бу «бөек Гайсә» дигәннәре бер зур сындыр, бу халык аңа табыналар. Ул кешеләрнең олылары, синең зиярәткә килгәнеңне ишеткәч, аягыңны йөзәр мәртәбә үбеп, сине падишаһка китерерләр. Падишаһ сине Әһрәмәнгә тапшырыр. Бу Әһрәмән дигәне — ул дәүләтнең олуг, могтәбәр кешесе. Ул Әһрәмән синнән сорар:

— Монда ни өчен килдең? — дип. Син әйт:

— Бөек Гайсәне зиярәт итәргә,— диген. Әһрәмән, падишаһ һәм калган бәкләр сине бер сарайга илтерләр. Шәддат падишаһ сарае кебек биек һәм зур сарай, нәфис ефәкләр белән бизәлгән, төрле төстәге пәрдәләр асылган. Шунда чиксез тәкәллефләрдән [4] кичерерләр. Аннан бер сандыкка барырсың, озынлыгы егерме аршындыр, бер утрау сыман нәрсәдер. Бу сандыкның эче тулы су, утсыз да кайнап торыр. Сан-

---

[1] Раһиб — монах

[2] Зөннар — кылдан үрелгән билбау, аны мөселманнар арасындагы христианнар бәйләргә тиеш булган

[3] Зиярәт итү — күрергә, баш иярга, табынырга килү

[4] Тәкәллеф — церемония

дык уртасында булаттан бер тәхет куелган. Ул да утсыз кызып тора. Әһрәмән сиңа әйтер:

— Әй бердәнбер! Бу зиярәт теләге белән бик күп авырлыклар күрдең, ләкин моннан үтә-кичә алмассың. Гайсә шул ут пәрдәнең артындадыр, бу арадан гына сәҗдә [1] ит,— дияр. Син әйт:

— Шундый ерак илләр кичеп, шуның өчен генәме килдем?! Күрмичә, алдында сәҗдә кылмый кайтырга?! — диген. Шул вакыт Әһрәмән әйтер:

— Нәфес теләге белән булсаң, мәгъбүд [2] сиңа күренмәс. Әмма табынырга килгән кешегә үз нәфесен теләктән һәм гайредән чиста итү, юу кирәк, аннан соң гына мәгъбүден күрү кирәк,— дияр.— Бу судан кичеп, ул кызган утка төшеп чыгу кирәк,— дияр. Син:

— Көнбатыш иленнән туры ни өчен килдем?! — дип, каты кычкырып, кыю рәвештә аягыңны утка сал. Бу биргән майның хасияте шул: кеше аны өстенә сөртсә, утта янмас, суга батмас. Шуның өчен үзеңә сөртеп йөр.

Син аннан Гайсә янына барырсың, бер көн анда торырсың. Икенче көн кайтып, Әһрәмән катына килерсең, сиңа ышанычлары багланыр, югары урынга ирешерсең, Әһрәмән сине олылар. Анда тагын берничә көннәр торырсың. Ниятең шулай булсын: бу ак туфракны Әһрәмәнгә иснәтү чарасын күреп йөр. Әгәр иснәтсәң, ул үләр, падишаһ сине аның урынына куеп, барлык кәлисәләрен [3] сиңа тапшырыр. Аннан таяну мәйданың булыр, тәмам Һиндстан олугы булырсың, ул дәрәҗәгә житкәч, бу илдә мәшһүр булырсың. Олуг булып якын кешесе булгач, падишаһ сиңа бер хаҗәтен белдерер. Казасын өстеңә ал. Падишаһның бер улы бар, хәстәдер, дәваларга җиһан табибләре гаҗиздер. Аны терелтергә алынырсың. Шул заман улының катына бар, өйрәткән әфсеннәрне аңа өр, шул сәгать эчендә сихәт табар. Аннан соң барча халыкның сөеклесе булырсың, алар синең мөритләрең булырлар. Аннан соң ихтыяр үзеңдәдер — ни теләсәң, шуны эшлә,— диде.— Моннан гайресен өйрәтү хаҗәт түгел,— диде.

Фәррухруз, бу өйрәтмәләрне кабул иткәч, дога һәм афәриннәр итте. Торды, үзен бер раһиб сурәтендә төзде. Ул шәһәргә йөзләнде.

Берничә көн йөреп, берникадәр вакыттан соң шәһәргә житте. Баягы ул вәкилләр:

— Ни кеше син? — дип сорадылар. Фәррухруз:

— Раһибмын, көнбатыш иленнән киләм, йортымны ташлап, бөек Гайсәне зиярәт кылырга,— диде. Шунда ук падишаһка хәбәр булды. Әһрәмәнне һәм башка руханиларны хәзер итте. Бер җир төзделәр, Фәррухрузга каршы чыктылар. Гыйззәт белән алып килеп, бер яхшы җирдә кундырдылар. Кабул итү мәҗлесе оештырдылар.

Аннан соң алдылар, олы кәлисәгә илттеләр. Фәррухруз, вакытын табып, баягы майдан бөтен бәдәннәренә сөртеп алды.

Утны һәм фәрашны [4] күрсәттеләр. Ут янында ефәктән пәрдә бар, аны күрсәттеләр. Әһрәмән алга чыгып әйтте:

— Әй хөкемдар! Моннан торып зиярәт ит! — диде. Фәррухруз:

— Әй юлбашчы! Ирләргә хурлап карама! Мин көнбатыш иленнән бу арадан гына сәҗдә кылыр өчен килдемме?! — диде.— Мәгъбүдемне күзем белән күрмичә! — диде. Бәс, Әһрәмән әйтте:

— Газапсыз, кеше үзеннән ваз кичмичә, бөтен гөнаһлы теләкләрдән нәфесен юмыйча, мәгъбүден күрмәс,— диде. Бәс, Фәррухруз шунда ук торды, исереклек бар кебек булып, ул кайнар суга аягын салды, корыда йөргәндәй йөри бирде. Ул кызган булат фәрашның

---

[1] Сәҗдә итү — тезләнеп, башны җиргә иеп, дога кылу

[2] Мәгъбүд — табыну объекты, сын

[3] Кәлисә — чиркәү, гыйбадәтханә

[4] Фәраш — пьедестал

өстенә басты. Бер кылына да зыян тимәде. Падишаһ, Әһрәмән һәм барча халык күреп, хәйран булдылар, шаккаттылар.

Фәррухруз пәрдәдән үтте, Гайсәнең тәхет алдына барды. Күрде: бер гаҗәп сын, кызыл алтыннан, ике күзе җәүһәрдән, башында бер олы якут бар, фирүзәдән таҗ куелган, биленә бер кәмәр [1] бәйләнгән.

Фәррухруз аны күрде, бер төн һәм көн анда торды. Кәшмир кешеләре һәммәсе ышандылар:

— Раһбаннардан [2] моның кебек хәрәкәтле кеше килгәне юк иде әле,— диделәр. Аннан соң икенче көн Фәррухруз җәмәгатьләренә килде, алар аягына төштеләр:

— Безне ярлыка! — диделәр. Бер яхшы җирдә кундырдылар, кунак иттеләр. Аннары алдылар, бер күркәм сарайга илттеләр, ул сарай Шәддат бакчасы кебек иде. Күп төрле хөрмәтләр күрсәттеләр. Әһрәмән дә түбәнчелек белән хезмәт итәр иде.

Бер көн Әһрәмән йоклап ята иде, Фәррухруз ул туфракны аңа иснәтте. Әһрәмән уянды, шул кадәр тартышты — җанын җәһәннәмгә тапшырды.

Падишаһка тиз хәбәр булды. Килде, Әһрәмәнне җирләделәр. Фәррухрузны аның урынына куярга теләделәр, Фәррухруз чигенде, ялварды, әйтте:

— Бу илдә ничә мәртәбәле кешеләр, руханилар бар, мин бер яңа килгән кешемен, минем кулдан килмәс,— диде. Падишаһ боерды, бөтен олылар, күренекле раһиблар аягына төшеп ялындылар:

— Галимсең, Гайсәгә якынсың, безнең әсбабыбыз бар исә — барчасын синңа багышладык, «юк» димә,— диделәр. Бу вакыт Фәррухруз эченнән сөенер иде. Күп олуглар аны бу дәрәҗәгә куярга теләгәч, ирекле-ирексез кабул итте. Мәшәкатьләрдән азат булып, хөрмәтле һәм олы дәрәҗәле булып утырды. Һәр көн мәлик килеп, аны күреп китәр иде. Бер көн сүз барышында падишаһ әйтте:

— Әй бөек раһиб! Татлы җанымнан сөеклерәк бер углым бар, күп вакытлардан бирле хәстәдер, Һиндстан һәм Латинда ни кадәр оста табиплар һәм чын акыл ияләре җыелып, чара итә алмадылар, бу эштә гаҗиз һәм борчулы калдым. Инде шуны телим: чын күңел белән бер дога кылсаң, шаять, синең доғаң бәрәкәтендә бөек Гайсә углыма шифа бирер,— диде. Фәррухруз әйтте:

— Булыр, дөрес әйтәсең,— диде.

Падишаһ боерды, үзенең хосусый атын фарызга [3] чалдылар, сарайга китерделәр.

Аннан Фәррухруз падишаһ углының баш өстендә торып, бер җеп алдырды, ул җепне үнике җирдән төйнәде. Аннан бер әфсен укыды. Бер-бер артлы һәр төйнәгәнен чишкәннән соң, углан яткан җиреннән калыкты, селкенде, шунда ук терелде.

Бу хәбәр җиһанга җәелде. Фәррухрузга тагын да ныграк ышаныч багладылар.

Баягы ир кабул кылмас кызның исеме Фәррухназ иде бит әле. Җиһанда бердәнбер иде. Бу хәбәр аңа җитте. Ул раһибны күрергә һәм нәсыйхәтен ишетергә теләде. Раһибка хәбәр итте, рөхсәт сорады. Әмма Фәррухруз үз янына керергә юл бирмәде, әйтте:

— Мәсих [2] миңа әмер итте: «Падишаһ кызын янына җибәрмә», диде. Шуңа күрә куркып торам,— диде. Фәррухназ моны ишетеп, борчулы булды. Җариясе артыннан Фәррухруз тагын әйттерде:

— Әйт: Тәңрегә буйсынмый имеш, ирне кабул кылмас имеш, адашу юлында йөрер, гөнаһларга баткан имеш. Ул җария Фәррухназга килеп

---

[1] Кәмәр — билбау

[2] Раһбан — монахлар башлыгы

[3] Фарыз — мәҗбүри дини йола

[2] Мәсих — Христос

әйтте исә, кыз кайгылы булды, сараена кайтып, бу халне атасына әйтте: ул да борчылды. Бу вакыт шаһ торды, раһиб янына барды. Әйтте:

— Әй раһиб! Минем кызыма ни өчен юл бирмәдең?

Фәррухруз:

— Эшне әмерсез эшли торган урында түгелмен,— диде. Аннан Мәсих сүзен сөйләде:

— Миңа боерды: «Шул кызны беләсең, күрәсең ич: гөнаһлыдыр, җиһан яралганнан бирле бу вакыткача һичкем кылмаган эшне кылды. Инде аны дошман тотармын», диде. «Әгәр ул ярамас эшен ташламаса, аңа ярлыкану юк, әмма шул эштән тәүбә кылса, кабул булыр», дип әйт диде. Мәсихтән ризалык телим,— диде. Падишаһ моны ишетте исә, тынычланды. Аннан Фәррухруз әйтте:

— Әй галәмнең шаһы! Бер эш бар, шуны эшлә! — диде. Падишаһ:

— Ни боерсаң да — баш өсте! — диде. Фәррухруз:

— Сараең каршысында бер сарай төзет, зур һәм биек, болдырлары һәм тәрәзәләре матур булсын. Аннан соң оста куллы, ачык күңелле бизәкчеләр, рәссамнар җый. Ул сарайның капка һәм диварларын кытай нигәрстаны[1] кебек бизәсеннәр,— диде. Бәс, падишаһ боерды, ничәмә осталар ул эшкә мәшгуль булдылар, тиз заманда күркәм, күңел җәлеп иткеч бер сарай төзеделәр. Аннан Фәррухруз осталарның берсенә әйтте:

— Бу диварга[2] бер чишмә рәсеме төшер, янында аучы тозак корганын яз. Янә яз: бер ана киек тозакка төшкән булсын, өч мәртәбә ата киек килеп коткарганын яз. Янә бер җирдә яз: ата киек тозакка төшкәнен, анасы килеп, карамый куеп киткәнен, аучы килеп ата киекнең башын кискәнен яз,— диде. Оста, Фәррухруз әйткәнчә рәссамлык кылып, тиз арада эшләде, җиренә җиткерде. Аннан соң Фәррухруз рәсемнәр янына барды, күрде, күңеле булды.

Бер көн кызның күзе нәкъ шул рәсемнәргә төште. Гаҗәпләнде, әйтте:

— Бу — минем төшемдер. Ләкин мин ата киек ана киеккә тугрылыклы булмас дип саный идем, «үз җанын коткарды, ана киеккә карамый китте» дип. Ул бичара тозакка башка җиргә төшкән икән, ана киек килми ташлап киткән икән. Минем кыланмышым һәм ул уйларым хата икән,— диде. Үзен-үзе шелтәләде, инсафка килде. Фәррухруз яшерен җирдән карап, тамаша итәр иде. Кызның үкенүеннән хәбәрдар булды, сөенде, ләкин өн чыгармады.

Кыз, хәйран булып, бүлмәсенә кайтты.

Бу якта раһиб падишаһны чакырды. Әйтте:

— И падишаһ! Бу төндә мин Мәсихне төшемдә күрдем, миңа әйтте: «Әй мөбид[3]! Падишаһка миннән сәлам әйт, аннары әйт: «Сине ярлыкадым, озын гомер бирдем һәм күп мәмләкәт, нигъмәт багышладым. Сәбәбе шул: кызың яман ниятеннән кире кайтты, кылган эшләренә борчылды», дип. Янә боерды: «Фәррухназга моннан соң юл бир», диде. Шушы шатлык хәбәрен әйтергә чакырдым, кызыңа да әйт,— диде.

Кәшмир мәлиге шат булып, кызы янына килде, үткән кыйссаны кызына сөйләде. Кызның күңеле хуш булды, әйтте:

— Әй атам! Мөбид рас әйтә, ул уйдан киттем һәм ул бозык фикерне башымнан чыгардым,— диде. Аннан торды, атасы белән Фәррухрузның бусагасы катына бардылар, хөрмәт күрсәттеләр. Фәррухруз кызны өметләндерде, әйтте:

— Әй ай йөзле! Өстеңдә шөкраналәр бардыр, Мәсих сиңа ярдәм итүче булды, юкса, сиңа ирек бирмичә, шайтан һәлак итәр иде.

---

[1] Нигәрстан — картиналар галереясы

[2] Дивар — стена

[3] Мөбид — дин башлыгы

Инде сүземнән чыкмасаң, яхшы булыр,— диде. Фәррухназ риза булды, кулын үпте, үз өенә кайтты.

Фәррухназ һәр көн Фәррухрузны зиярәт кылыр иде, ул исә кызга күп нәсыйхәтләр бирер иде. Бер көн икесе дә аулакта калдылар. Фәррухруз әйтте:

— Әй чибәр кыз! Бу төндә төшемдә Мәсихне күрдем, ул әйтте: «Кызга әйт: аңа бер егет гашыйк, кыз аны эзләп китсен, ул егетнең кем икәнен белсен, аның уенда булсын, һәр икесе морадларына җитсен», диде.

Кыз бу сүзне ишеткәч, гаҗәпкә калды:

— Бу хәлдән хәбәрем юк, ни егет икән, белмим,— диде. Фәррухруз әйтте:

— Сабыр кыл, шаять, Рухулла [1] белән сөйләшсәм, сорармын: ул егет кай җирдән һәм ни кешедер, ачык итәрмен,— диде. Кыз:

— Сез үзегез беләсез,— диде, торды, китте. Әмма каты уйда калды. Ул көн һәм ул төн сабыр итте. Иртәгесен Фәррухруз янына барды. Әйтте:

— Әй юмарт раһиб! Мәсихтән җавап алдыңмы?— диде. Фәррухруз әйтте:

— Әгәр акылың колагын миңа тотсаң, әйтеп бирәм,— диде.— Бел һәм аң бул! Фарсы илендә бер шәһреяр бар, исемен Ширзад диләр. Аның дәүләт иясе, булдыклы бер улы бар, йөзе—ай-кояштан, сүзе балшикәрдән билге бирер. Мәгәр ул шаһзадә, сине хыялына китереп, синең камил матурлыгыңны ишетеп, кавышу теләге белән тынгысызланган, сабыры-чыдамы калмаган. Бу нәрсәне яратучы Алла аның җефете булуыңны тәкъдир иткән,— диде. Кыз, аның сүзеннән хәйран булып, көчле теләк уена батты. Фөрат [2] суына, Һират күленә чумгандай булды, бер сәгать хәрәкәтсез утырды. Аннан әйтте:

— Әй күпне белүче раһиб! Мине вәсвәсәгә салып, акылым күзен бәйләдең, сабыр ындырын утка ягып кол иттең, бу хәлгә җиткереп, юл күрсәттең, мине барасы урыныма ирештер,— диде. Кыз Фәррухрузга йөзмең зинһарлар белән үтенде, «бу серне беркемгә әйтмә» дип, хәлен-вакыйгасын тәмам итте. Фәррухруз ул күңел җәлеп иткечкә гаҗәп-хәйран калды. Янә кыз әйтте:

— Әй раһиб! Түземем калмады, инде монда тору файдалы түгел, эш шунда: мине кавышуга җиткер, хәзерләнеп юлга киту кирәк,— диде. Бәс, шул чара белән булдылар. Кызның бер сөт анасы һәм бер тәрбияче хатыны бар иде, аларга боерды: кирәк-яраклар, дүрт ат, дүрт корал хәзер иттеләр, кичәдән иртәнгәчә йөрделәр. Бер болынга җиттеләр, бер ягында матур бакча бар икән, эчендә матур бер җәйге сарай. Бер су янында кундылар. Фәррухруз белде: бу сарай Хөснарай җадуныкы [3]. Дулкынланды, тәненә калтырау төште. Кыз әйтте:

— Ни булды?

Фәррухруз әйтте:

— Әй җиһанның ихтыары! Бу бер мөшкел җир, бер сихерченең торган җире. Ул мине киеккә әверелдергән иде. Әгәр Миһерафзай Кәшмири йолып алмаса, минем һичкайчан кеше булачагым юк иде,— диде.— Мөшкел хәлгә дучар булдык. Ләкин шул теләктә булу кирәк: ул явызга бер эш кылу, галәмне аның начарлыгыннан пакь кылу кирәк,— диде.

Фәррухназ бу сүзгә шат булды. Фәррухруз кулына кылыч алды, сарайга таба китте. Керде — адәмнән һичкем юк. Тагын күрде: бер өй тора, ишеге бикле, эчендә ыңгырашкан аваз ишетелә. Фәррухруз йозагын ватты, эченә керде. Күрде: тәхет өстендә бер ай кебек гүзәл кыз ята, өстенә җилән бөркәнелгән. Фәррухруз якын барды, әйтте:

— Әй ай йөз! Ни кеше син?

Кыз Фәррухрузны күрде, аһ итте, һушсыз булды. Фәррухруз күрде:

---

[1] Рухулла — (Рухы Аллаһ) — Христос

[2] Фөрат — Ефрат елгасы

[3] Җаду — сихерче

Миһерафзай икән. Хәйран калды, әйтте:

— Әй жаннан сөеклем! Бу ни хәл? Монда ни кыласың, ни эшкә дучар булдың?!— диде. Миһерафзай әйтте:

— Сиңа яхшылык кылганымны бу жаду ишеткән. Бер көн мине аңсызда тотып, бу авыр богауга салды. Карендәш апам булса да, миңа рәхим итмәде, озак вакыт инде менә шул хәлдә ятам,— диде.— Әмма син бар, кит, син дә дучар булма,— диде. Фәррухруз әйтте:

— Әй газиз жаным! Сине болай бу рәвештә күреп, ни дип китим?! Монда, синең алдыңда үлсәм кирәк,— диде.— Әмма миңа әйт: бу эшкә ни чара кирәк? Берәр чара булырмы?— диде. Кыз әйтте:

— Бу эшкә жиһан халкының чарасы булмас,— диде.— Шулай да бер чара бардыр, әгәр дә булдырып булса,— диде. Фәррухруз:

— Ул нинди чара?— диде. Кыз:

— Сарай алдында бер матур бакча бар. Аның уртасында тагын бер сарай бар. Ул жаду анда тәхет өстендә йоклый. Ястыгы астында бер сандык бар. Әгәр кулыңнан килсә, беркемгә белдерми ала алсаң, минем богавымның ачкычы анда,— диде. Фәррухруз бу сүзне ишетү белән, шунда ук торды, барып, ул сарайның эченә керде. Ул куркыныч жадуның ятканын күреп, бераз уйланып торды. Әмма күңеленә Хак тәгалә илһам салды:

— Ул жирне-суны яраткан Алладыр, вакыты житмичә, черки һәм кырмыска да үлми,— дип, «Ни булса — шул булыр» дип, торган жиреннән барып, куркусыз булып, ул ястык астындагы сандыкка кул озатты, сандыкны кулына төшерде. Алды, йөри бирде. Миһерафзай янына килде, сандыктан ачкычны алып, Миһерафзайны коткарды. Миһерафзай Фәррухрузның аягына төште. Фәррухруз:

— Минем белән бергә йөр. Хак тәгалә гыйнаять итсә, күрерсең, нәрсә эшләрмен,— диде.

Тордылар, Хөснарай жадуның янына бардылар. Фәррухруз үзен белдерде. Миһерафзай Хөснарайның өстенә төште, ул уянды. Сырыштылар һәм көрәштеләр. Аллаһы тәгалә Фәррухрузга жиңү ярдәме бирде: ул шунда ук билбавыннан кылычын алып, артыннан килеп, Хөснарайга кылыч белән орды, башын тәненнән аерды. Миһерафзай бу хәлне күреп, шат булып, Фәррухрузга мактау сүзләре һәм афәриннәр әйтте.

Аннан Фәррухназ янына бардылар. Миһерафзай, шаһ кызын күреп, башын жиргә куеп, жир үпте, хезмәтләр итте. Фәррухназ да аңа чиктән тыш хөрмәтләр күрсәтте. Ул вакыт Миһерафзай Фәррухназга әйтте:

— Мәгълүм булды: ата киек, форсат булгач, кимчелекле булмады. Бу егетнең дә ахыр эше хәерле булсын, ул булмаса, миңа котылу мөмкин түгел иде,— диде. Фәррухназның бу сүзгә бик тә күңеле булды. Ир кешенең тугрылыгын белде һәм күзе белән күрде, үзе кылган бар эшләренә пошаман булды. Бозык уйларын юып, хуш булды.

Фәррухруз торды, сарай эчендә ни бар исә — алды. Аннан юлга кереп киттеләр, башларыннан кичкәннәрне сөйләшер иделәр.

Бу якта, таң аткач, Кәшмир мәлиге кызын күрергә барды. Карады: кызы юк. Раһиб янына барды исә — раһиб юк. Хәйран булды, ни булганын аңламады. Өенә кайтып уйланып торганда, бу хәлдән хәбәре булган бер жария килеп, мәликкә белдерде. Ишетте исә — ачуы килде, боерды, гаскәр жыеп, берничә олы бәкләр белән артларына төшеп, куа чыктылар.

Бу якта болар барыр икән, кинәт күрделәр: Кәшмир юлында тузан пәйда булды. Шунда ук торып, атларына атланып, гаскәргә каршы бардылар, туктаусыз сугыштылар. Миһерафзай әфсеннәр укып, дошман гаскәренә өрде, күп төрле яшеннәр пәйда булды, сафлар тармар килде. Фәррухруз батырларча шулкадәр орыш кылды, аның кебек Рөстәм Дастани да кылганы юк иде. Ләкин Кәшмир юлыннан гаскәр шулкадәр күп килә иде, санын Ходайның үзеннән башка һичкем белмәс иде. Гаскәрнең күплегеннән хәлсезләнделәр, йөзләрен ул бөтен те-

ләкләрне Канәгатьләндерүчегә тоттылар, әйттеләр:

— Әй чарасызларга чара табучы, вай бәхетсезләргә ярдәм итүче! Ярдәм итү һәм җину китерү синнән!— дип һәм:

— Бу хаклыктан тайпылганнар кавемен түбәнлеккә төшереп, хур кылу синә ансаттыр,— дип, башларын сәҗдәгә куйдылар.

Догалары кабул ителеп, шунда ук Хак булышлык итеп, Казвин юлыннан бер тузан күренде. Тузан эченнән коралланган һәм җиһазланган Рөстәм Дастани, Сам Нариман [1] кебек бер егет ерткыч арслан кебек атылып чыкты. Гаскәргә якын килгәч, атыннан төшеп, ияр каешын ныгытты, атына менеп, каты тавыш белән бер кычкырды ки, ишеткәннәр йөзтүбән төштеләр.

Фәррухруз белде: бу — Фәррухшад икән. Ул дошман гаскәренә һөҗүм итте, егетлек-батырлык күрсәтте. Фәррухруз Фәррухназ янына килде, әйтте:

— Әй җиһанның сылуы! Ул ишетелгән тавышның иясе батыр шаһзадә Фәррухшадтыр,— диде. Фәррухназ, моны ишеткәч, күз карашын шаһзадәгә төбәде, шаһзадәнең матурлыгын, камиллеген, буй-сынын, батырлык һәм осталыгын, сугышчан авазын һәм кайнарлыгын күрде, акылы китә язып, үз-үзен онытты. Янә һушына килеп, вәзирзадәгә әйтте:

— Әй мәхәббәтзадә! Әйткәннәрең рас икән, сүзеңә җаным фида булсын,— диде. Шаһзадәнең янына барырга теләде. Шаһзадә исә, Фәррухруз китеп күп вакытлар үткәч, сабырлыгы бетеп, гаскәр җыеп, эзләргә чыккан иде, аның гаскәр белән килү сәбәбе шул иде. Шул кадәр гаскәр, шаһзадәнең артыннан килеп, һөҗүмгә ташландылар, Кәшмир гаскәрен хәлсез итеп, кырдылар. Калганнары качып киттеләр.

Болардан бушаганнан соң, Фәррухруз, Фәррухназ һәм Миһерафзай шаһзадә янына килделәр, очраштылар-кавыштылар, җир үбеп, хөрмәт кылдылар. Шаһзадә боларны бик кадерләп алды, вәзирзадәгә күп рәхмәтләр әйтеп, баш иде. Вәзирзадә, югары затларга хас әдәп белән, башыннан кичкәннәрен матур тел белән, маҗаралар тулы кыйссасын башыннан ахырынача сөйләде. Шаһзадә, калган бәкләр һәм кара халык ишетеп, гаҗәпләнделәр.

Аннан тордылар, Казвинга таба йөреп киттеләр. Казвин шаһы боерды, шәһәрне бизәделәр. Барча халык, падишаһ якыннары һәм кара халык, югары урындагылар, каршы чыгып алып, шәһәргә китереп, туй хәзерләп, Фәррухназны — Фәррухшадка, Миһерафзайны Фәррухрузга никах белән беркетеп, ничә көн туйлар итеп, кавыштырдылар.

Морадларына ирешкәннән соң, падишаһ югары урындагыларны, түрәләрне җыйдырып, Фәррухшадны кулыннан алып, тәхеткә кичерде, дәүләт әсбапларын аңа тапшырды. Үзе бер почмак ихтыяр итеп, намазгыйбадәткә мәшгуль булды. Фәррухшад гадел хөкемгә кул сузып, бәхет нигъмәтен галәмгә чәчте.

Бу хәлләрдән соң берникадәр вакыт үтте. Бер көн шаһзадә шаһка әйтте:

— Шаһым! Дәүләтеңдә морадыма җитүгә син сәбәп булдың, инде теләгем бу: күңел морадым белән үз шәһәремә барып, ата-анамның йөзләре каршында булсам икән,— диде. Шаһ боерды, хәзерлек чарасын күрделәр, Фәррухрузны аның урынына тәхеткә кичерделәр, дәүләт әсбапларын аңа тапшырдылар. Ә Фәррухшад Фәррухназ белән, иярченнәре һәм хезмәтчеләре белән атка менеп юлга чыктылар.

Көннәрдән бер көн үз шәһәрләренә җитештеләр. Мәгәр атасы аның өчен сагышлы һәм газаплы булган иде. Шаһзадәнең хәбәрен ишетте исә, бәкләрен каршы алырга чыгарды, улының йөзен күреп, шатлыктан сихәт тапты. Күрешеп, елашып, барлык олылар һәм әмирләр килеп, шаһ-

[1] Легендар фарсы баһадирлары, Фирдәүсинең «Шаһнамә» әсәре геройлары

задәнең кулын үптеләр, тиешле йоланы үтәделәр.

Шаһзадә тәхеткә менеп, шәһәрне кулына алып, гадел хөкем итеп, бу фани җиһаннан кичеп, Фәррухназдан булган балаларына тәхет-таҗны тапшырып, бу дөньядан үтте.

Инде белегез: һәркем җиһанда ни эзләсә дә — Алла бирер. Һәр кешегә кодрәте җиткәнчә тырышлык итү кирәк. Тырышлыктан башка эш башкарылып чыга алмас. Шаһ булса да, ярлы-гидай булса да — үзеннән соң бер яхшы исем калдыру өчен тырышырга кирәк.

## Тугры һәм хәйләкәр хатын турында хикәят

Бизәнү әйберләре ясаучы бер оста бар иде. Малы-нигъмәте күп, әмма улы-кызы юк иде. Тагын да бер тыйнак һәм чибәр хатыны бар иде.

Бу останың бер мираб [1] күршесе бар иде. Ул мираб останың хатынын сөяр, әмма бу серне күңелендә саклар иде.

Останың мең флүре, ягъни мең алтыны бар иде. Бер көн, мөһерләп, мирабка кертеп бирде. Әйтте:

— Бу алтыннар синең янында әманәт булып торсын, бер көн кирәксә алырмын,— диде. Мираб кабул итте, янчыкны алып калды.

Бу эшкә байтак заман үтте, оста картайды һәм күзләре күрмәс булды, хәерче дәрвиш хәленә төшәргә аз гына калды. Хатынын чакырып әйтте:

— Күршебезгә кер, миннән сәлам әйт, әманәтне сора,— диде.

Хатын торды, бөркәнчеген иңенә салды, мирабның өенә барды.

Мираб, хатынны күргәч, торды һәм хөрмәтләп каршы алды. Хатын иренең сүзен җиткерде. Мираб көлде, әйтте:

— И гүзәл йөзле! Мин синең юлыңда җан һәм баш бирәм, синең монда атлап керүеңә шөкранә итәм, ни гомердән бирле сине күрәсем килә. Әгәр дә яныма алып, кочагыма кергезеп, иреннәреңнән бер үпсәм, мең түгел, ике меңне бирәм һәм дә үлгәнче колың булам,— диде. Аның гөл йөзеннән үбеп, шикәр тәнен татып карарга теләде.

Хатын чигенде, әйтте:

— И хәерсез теләкләр теләүче! Лаек булмаган сүзләр сөйлисең, шундый кеше була торып, мондый ярамас сүзләрне ни өчен сөйлисең?! — диде.— Ул ирем белән ничә еллар гомер кичердем, нигъмәтен күрдем, инде малы төкәнгәч ташлап китиммени?— диде. Чыкты, өенә китте. Мираб аның артыннан сүгенеп калды. Хатын күңелсезләнеп, өметсезләнеп өенә керде, иренә әйтте:

— Мираб шулай диде, инде нишлим?

Оста гаҗиз калды, мираб белән тарткалашыр иде — күзләре күрми. Хатынына әйтте:

— Тор, инде мөхтәсибкә [2] бар, минем аның белән электән үк дуслыгым бар иде. Сәламемне җиткер, әйт: «Фәлән кешедә әманәтем бар иде, ул кеше миңа шулай эшләде, ни итим», диген. Бу эштә ул ярдәм кылыр дип өмет итәм,— диде.

Хатын торды, мөхтәсибкә барды, иренең сәламен җиткерде. Мөхтәсибнең дә күңел кошы хатынның чәчләре тозагына дучар булды, әйтте:

— Мин динарларыңны ул мирабтан алып бирәм, мең динар тагын үземнән бирәм, тик шуны телим: шул ай кебек йөзеңнән бер үптерсәң, үлгәнче хезмәтеңдә булам,— диде. Хатын бу сүзне ишетте исә, гаять ачуы килде. Кире чигенде, әйтте:

— Син үзең мөхтәсиб буласың, Гомәр Хаттабның [3] урынында тора-

---

[1] Мираб — арыкларга су бүлеп бирү эшләре белән җитәкчелек итүче чиновник

[2] Мөхтәсиб — шәригать йолаларының үтәлешен күзәтүче чиновник

[3] Гомәр Хаттаб — Мөхәммәт пәйгамбәрнең сахабәсе, икенче хәлиф

сың, моның кебек кирәкмәс сүзләр сөйлисең. Әгәр йөз ел ирсез булсам да, йөзеңә карамасмын,— диде. Торды, китеп барды. Мөхтәсиб аның артыннан сүгенеп калды:

— Бар, эткә бул, мең динарны кем бушка бирер икән!— диде.

Ул хатын мең хурлык белән өенә кайтты, иренә әйтте:

— Файда юк,— диде. Оста әйтте:

— Мөхтәсиб янында да эш уңмагач, кайда гына уңар? Ни чара табарга?— дип, уйга калды. Хатынына әйтте:

— Тор, казыйга бар. «Арабызда шундый-шундый эшләр бар» диген, минем исемемнән догалар укы, минем хакымны алып бирсен иде.

Хатын торды, казыйга китте. Мажараларны сөйләде. Казый, хатынның чибәрлеген күреп, гашыйк булды, матурлык чылбыры белән күңеле богауланды. Әйтте:

— И көмеш тәнле! Әманәтеңне алып бирәм, әмма кулыңны муеныма сал, тагын шулкадәр динар бирәм,— диде. Хатынның бу сүзләргә күңеле кырылды, әйтте:

— Син мөселманнарның казые түгелме? Син мөселманнарның хатынына ни өчен тәмгы [1] итәсең?!— диде. Казый, моны ишеткәч, хатынны сүкте, хакарәтләп [2] яныннан сөрде.

Хатын, өметсезлеккә төшеп, өенә кайтты. Оста, ишеткәч, кайгыда калды. Әйтте:

— Тор, инде шихнә[3] катына бар, бәлки эшебезне ул башкарып чыгар,— диде.

Хатын торды, шихнәгә барды, хәлен белдерде. Шихнәнең дә күңелендә фетнәләр кайнады, әйтте:

— И талларның зифасы! Мирабтан мең динар алу ансат эш, тагын да өстәп мең динар бирәм, шул шарт белән: сине бәгъремә басып, янымда бераз вакыт булсаң,— диде. Хатын әйтте:

— Мин сиңа залимнең кулыннан елап килэм, ә син гыйшык уены тәкъдим итәсең. Бу эшне Хак тәгалә хуш күрерме, бу син кылган эш нинди мөселманлык булсын!— диде. Торды, чыгып китте.

Хатын өенә кайтты, остага бу хәлне белдерде.

Оста әйтте:

— Ни кылмак кирәк? Ходаның салганына чара юк,— диде. Күп уйлардан соң, әйтте:

— Бу заманга кадәр шәһәр вәлиенең [4] хезмәтләрен күп башкардым, күп кирәк-ярагым аның сәбәбеннән хасил булды. Аның янына бар, хәлебезне аңлатып бир, шаять файдасы тияр,— диде.

Хатын торды, вәли катына барды, хәлләрен әйтеп бирде. Хатынны күргәч, вәлинең дә гыйшкы тибрәнде. Әйтте:

— Бу хезмәтеңне башкарам һәм акчаңны мирабтан алып бирәм, әмма дә ләкин останы ташлап кит, безгә кил, кичке бакчамның гөле бул,— диде.

Хатын, хурланып, бәгыре көеп, өенә кайтты. Әйтте:

— И тереклегемнең яктысы! Бу халыкта мөселманлык беткәндер, һичкемнән безгә рәхим юк. Алла ул залим динсезләргә җәзасын биреп, бу дөньяда һәм ахирәттә оятка калдырсын иде,— дип озак зарланып утырды. Бу сүзләрне ишетеп, останың түземлеге калмады, йөзен күккә тотып әйтте:

— И бер Хода! Йа, бичараларга ярдәм күрсәтүче! Өметебез өзелеп, күңелебез төште,— дип мөнаҗәтләр укыды.

Аннан соң бу хатын үз акылы белән бер фикергә килде. Әйтте:

---

[1] Тәмгы — теләк
[2] Хакарәтләү — хурлау
[3] Шихнә — полиция башлыгы
[4] Вәли — шәһәр башлыгы, мэр

— Бу оятсызларга бер эш кылмыйча, бушка үткәрсәм, адәм булып та йөрмим,— дип шарт куйды.— Әгәр боларны шул килеш калдырсам, боларның җәберләре күпләргә төшәр, дөньяны бозарлар,— диде.

Өеннән чыгып, агач кибетенә барды. Балта остасына әйтте:

— Миңа бер сандык кирәк иде, дүрт бүлеме булсын, һәр бүлеме берәр кеше сыярлык булсын. Һәрберсенең аерым капкачы булсын. Кадак белән ныклап беркет, фәлән көнгә ясап бетер,— дип, акчасын биреп китте.

Балта остасы сандык ясауга мәшгуль булды, вәгъдә көненә хәзерләп, сандыкны китерде. Хатын сандыкны алды, бер җирдә урнаштырды.

Үзе өенә керде, киенеп-ясанып, алтын-көмешләр белән бизәнде. Хушбуйлар сибеп, шундый чибәр булды ки, нигә Йосыф күрсә дә, чәч тозагына төшәр иде. Үзе белән бер җарияне алып, мирабның өенә керде.

Мираб, хатынны күргәч, каршына чыкты. Хатын көлеп, наз белән сәлам бирде, тартынмыйча йөзен ачты, назлы рәвештә чытлыкланды. Мирабның, моны күреп, җаны чыга язды. Чибәр әйтте:

— И җаным! Ул сиңа күрсәткән тупаслыгым өчен але дә борчылам. Миңа синең түбәнчелекле колың булу кирәк иде. Шуның өчен шушы вәгъдә белән иртәгә иртүк таң вакытында үз яныма чакырам, хезмәт шартын җиренә җиткерәм,— диде. Барып, кулын үпте, үз кулларын мирабның муенына салып, йөзеннән һәм күзләреннән үпте. Тагын әйтте:

— Нәрсәм бар исә — синекедер,— диде. Мирабның сабыры-чыдамы калмады, ихтыярсыз, хатынның аягына төште. Хатын вәгъдә кушты.

Аннан китте, мөхтәсиб янына барды. Үзен күрсәтте, әйтте:

— И күңелемнең рәхәте! Ул көн яныңнан киткәннән бирле үкенәм, җаным синең мәхәббәтеңә дучар булды. Мин, уйламыйча, яман эш кылдым, шуңа үкенеп, күземә йокы керми. Синең кебекнең миңа күңеле төшсә, мин кире каксам — яхшы түгелдер. Инде болай итик: иртәгә иртә белән яныма кил, бергәләп сөйләшик,— диде. Аннан килеп мөхтәсибне үбеп алды.

Аннан хатын казыйга барды. Хөрмәт күрсәтеп, сүзләрен әйтте:

— Яхшылык синнән булсын — көннең яртысында безнең йортка кил. Ул көнге сүзләремне күңелеңнән чыгар, ихтыярсыз ычкынды, шул вакыттан бирле үкенәмен,— диде. Бу сүзләрне ишетеп, казый да казага дучар булды.

Аннан хатын торды, шихнә катына барды. Әйтте:

— И күзем нуры вә күңелем җимеше! Катыңнан киткәннән бирле, кич — йокы, көндез рәхәт булмады. Инде үтенечем будыр: таң белән көн тоташкан вакытта безнең өебезгә барсаң, мине гамь-кайгыдан чыгарсаң, мин синең кебек ай йөзле белән бер ястыкта баш куйсам, бу дөньяда үкенечем калмас иде,— диде.

Шихнә, бу сүзләрне ишетеп, ул көн ни утыра, ни тора белмәде, өметләнүдән чыдамы калмады.

Хатын торды, вәли катына барды, үзен күрсәтте. Вәли бу халне күргәч, өй-сараен ташлап чыгып китәрлек дәрәҗәгә җитте. Әйтте:

— И чибәр! Әгәр син бераз вакыт янымда булсаң, җаным-малым синең юлыңа фида булсын,— диде. Өметләнеп, бәла тозагына бәйләнде.

Аннан хатын өенә кайтты. Ширбәтләр һәм нигъмәтләр хәзерләде. Ә эчендә исә фетнәләр кайнады.

Ул кичә мираб, мөхтәсиб, казый, шихнә һәм вәли — һәрберсе хыялланып яттылар. Әмма бер-берләреннән хәбәрләре юк иде.

Таң атты. Мираб чиста, матур киемнәр киде, хушбуйлар сибенде, үзе белән йөз динар кызыл алтын алды, останың өенә барды. Капкага килде, хатын әзер иде, ризык һәм шәрабләр белән каршы чыгып алды. Эчкә кергәндә, үпте һәм кочты. Мираб, бу назларны күргәч, билендәге йөз динарны хатынга бирде. Хатын алды, мирабны үз бүлмәсенә кертте. Ашадылар, эчтеләр. Аннан хатын әйтте:

— И ходавəндə! Киемеңне салып, билбавыңны чишеп, иркенләп утыр, ашыкма, бу көн зәвык көнедер,— диде. Мираб сөенде, киемнәрен салды, ашап-эчеп, иркенләп утырды.

Шул вакытта кинәт капка шакыдылар. Хатын алдан әйтеп куйганча, моны хезмәтче кыз шакыган иде. Хатын:

— Ул кем?— диде. Җария әйтте:

— Карендәшегездер, капкада тора, ни боерасыз?— диде. Хатын мирабка әйтте:

— И күңелемнең рәхәте! Син утыр. Чыгып күрим, сөйләшим, аннан соң сафалар сөрербез,— диде. Хатын торып, башка бүлмәгә чыгып, шунда утырды.

Шул вакыт мөхтәсиб килеп капка какты. Ачтылар. Хатын эчкә кертте, хөрмәт итте, үпте-кочты. Мөхтәсибнең кулын алды, урынга утыртты. Мөхтәсибнең бик күңеле булды, алтын китергән иде — хатынга бирде. Аннан чибәр әйтте:

— Син киемнәреңне салып, иркенләп утыр,— диде.

Мөхтәсиб, ятарга дип, җиләнен салды. Хатын әйтте:

— И әфәндем, син ята тор, мин тиз генә чыгып керәм,— диде. Мөхтәсиб сөенде, йокы бүлмәсенә керде, ятты. «Хәзер чибәркәй килә» дигән өметтә иде.

Хатын бераз торды. Шул вакыт казый килеп җитте. Хатын мөхтәсиб янына керде, казыйның килгәнен хәбәр бирде. Мөхтәсиб:

— Монда ни өчен килгән?— диде. Хатын:

— Иремнең якын кешесе, аның белән сөйләшергә килгәндер,— диде. Мөхтәсиб курыкты:

— Мин кая барыйм?— диде. Хатын әйтте:

— Тор, бу сандыкка кер, бераз утырып тор, казый киткәч, эшебездә булырбыз,— диде. Сандыкның бер бүлеменә кертте, тышыннан бикләде.

Аннан боерды, капканы ачтылар, казыйны ишек алдына керттеләр. Хатын аның каршына килде, сәламләште, кече күңеллелек күрсәтеп, казыйны үпте-кочты. Казый, сөенеп, билбавыннан ике йөз алтын чыгарып, хатынга бирде. Хатын тиз генә табын хәзерләде, ашадылар-эчтеләр, күңелле сүзләр сөйләштеләр. Ашап-эчеп туйгач, казый әйтте:

— И күңелем рәхәте! Тиз торып түшәккә керик,— диде. Хатын әйтте:

— Бик урынлы әйттең, син кереп ята тор, мин әзерләнеп киләм,— диде. Казый, өс киемнәрен салып, ялангач булып, түшәккә керде.

Хатын бераз торды. Ул арада шихнә килеп капка какты. Хатын әйтте:

— Кем син?

Шихнә үзен белдерде. Казый бу таныш тавышны ишеткәч курыкты:

— Мине бер җиргә яшер! — диде. Хатын әйтте:

— Ярый, менә бу сандыкка кереп тор. Шихнә киткәч, теләгәнебезне эшләрбез,— диде. Казый куркуыннан тиз генә сандыкка керде, хатын шунда ук бикләп куйды. Аннары барып капканы ачты. Шихнә керде, өстендә — затлы озын тун, башында — чалма, биленә алтын билбау бәйләгән. Хатын аның каршына барды, кулын муенына салды, үпте һәм кочты, кече күңеллелек күрсәтте. Шихнә бу кыланышларны күргәч: «Бу назлы мине шулкадәр сөя икән»,— дип фикер кылды, өстенә бер яулык вак акча сипте. Хатын аны бүлмәгә алып керде, түшәк янына утыртты. Шихнә хыялга чумып утырды. Ашадылар-эчтеләр. Чибәркәй әйтте:

— И күзем яктысы вә күңелем җимеше! Түшәккә керик, күңелебезне күрик!

Шихнә тиз генә тунын, билбавын һәм кыйммәт бәяле киемнәрен салып, йокы бүлмәсенә керде, «Кайчан килер?» дип, көтеп ятты. Хатын тагын бераз торды, ул арада тыштан капка кактылар. Хатын кем икәнен сорады, шәһәр башлыгы үзенең килгәнен белдерде. Шәһәр башлыгы

белән дуслыгы юк иде, шуна күрә, аның авазын ишеткәч, шихнә бик курыкты, түшәктән сикереп торды, үзен эзләп килгән дип санады. «Ах, нинди үкенеч, ни эшлим?!» — диде. Хатын әйтте:

— Кайгырма. Иремнең дусты ул, һәрвакыт хәл сорарга килә, бераз утыргач китәр, аннан соң рәхәт кичәрбез,— диде.— Әмма син бу сандыкка кереп тор,— диде. Шихнә, ялангач килеш, сандыкка кереп ятты, хатын сандыкны бикләп куйды.

Хатын вәлинең каршысына чыгып, йөз-күзеннән үбеп, шулкадәр наз күрсәтте ки — вәли бөтен дөньясын онытты. Хисапсыз алтын китергән иде, барысын да хатын алдына сипте. Хатын, кулыннан алып, бүлмәгә алып керде, ашадылар-эчтеләр. Хатын әйтте:

— И шәһәребезнең башы! Мине көттерден, зар-интизар иттең. Бераз сафалар сөреп, зәвыклар кылу кирәк. Гыйшкым сиңа артканнан-арта бара. Йокы бүлмәсенә керик, түземем калмады, киемнәреңне сал инде,— диде. Вәли торды, «мине гаҗәп нык сөя икән» дип, бозык хыял белән өстен салып, ялангач калып түшәккә керде. Көтмәгәндә капканы шакылдаттылар. Бу үз хезмәтчесе каккан иде. Хатын кем икәнен сорады. Хезмәтче:

— Карендәшләрегездер,— диде. Хатын вәлигә әйтте:

— И бакчамның гөле! Карендәшем килгән икән,— диде. Вәли әйтте:

— Ах, мин нәрсә эшлим?! — диде. Хатын әйтте:

— Мин бер-ике сүз сөйләшеп килгәнче бу сандыкка кереп торсаң ничек булыр икән? — диде. Вәли, «яхшы булыр» дип, торып, ялангач көенчә сандыкка кереп ятты. Хатын тиз генә бикләп куйды, шуның белән сандыкның эше тәмам булды.

Хатын торды, мираб янына барды. Әйтте:

— И күземнең нуры, күңелемнең дәвасы! Карендәшләрем килгәнгә күрә, сине көтеп торырга мәҗбүр иттем, зинһар кичер,— дип үтенде.— Синең мәхәббәтеңнән аларның сүзе колагыма да кермәде,— диде.— Әмма инде хәзер күңел ачарбыз һәм сафалар сөрербез,— диде. Кулыннан алып, йокы бүлмәсенә алып керде. Мирабның муенына кулын салды, әйтте:

— И күзем нуры! Минем синдә бер үтенечем бардыр,— диде, мирабны сандык янына алып килде. Мираб әйтте:

— Нинди үтенеч?

Хатын әйтте:

— Син миңа әйткән идең: «Үземдәге әманәтне — мең динарны бирәм, тагын өстәп мең динар кушып бирәм», дип. Инде китереп бирсәң икән,— диде. Мирабның күңеле бик кызган иде, әйтте:

— И сәрбагарым! Мин вәгъдәмнән кире кайтмам, синең ике мең динарыңны төп-төгәл бирермен, бер динарына да хыянәт итмәм,— диде.

Хатын әйтте:

— Мин бер гаҗиз зәгыйфь хатынмын, син бер олы кешесең, миннән теләгәнеңне алганнан соң каршыңда ни хөрмәтем булыр? Башта бирәсеңне бир,— диде. Мираб:

— Әле монда янымда юк, соңыннан бирермен,— дип ант эчте.

Хатын:

— Бу сүзенә сандык эчендәгеләр шаһит булсынмы? — диде.

Мираб:

— Булсын! — диде. Сандыкка ант итте. Сандык эчендәгеләрнең дүртесе дә күңелләреннән хатынга сокландылар:

— Нинди уңган хатын! Кара инде, нинди хәйләләр белән мирабны ант иттерде,— дип, бармакларын тешләренә куеп, афәрин укыдылар.

Аннан мираб әйтте:

— И күзем нуры! Ятыйк инде,— диде. Хатын әйтте:

— Бик урынлы сүз, яхшы булыр,— диде.— Сез ята торыгыз, мин капкаларны бикләп, хәзер керермен,— диде.

Мираб чишенде, йокы бүлмәсенә керде. Хатын өйдән чыгып, хез-

мәтчеләрен мәхәллә халкына хәбәр бирергә җибәрде:

— Өебезгә карак килгән, тиз арада кешеләр җыеп килегез,— диде. Үзе мираб янына керде. Әйтте:

— Моннан китик, анда бер аулак җир бар, анда барыйк, кеше белмәсен,— диде. Мираб урыныннан торды. Хатын:

— Түшәк-ястыкны һәм юрганны алып бар,— дип бөтенесен мирабка күтәртте. Бичара мираб бу йөкләрне күтәреп, абына-сөртенә бара, хатынны янына салып кочу теләге белән хыяллана иде. Шушы хәлдә хатынның күршеләре йөгерешеп килеп җиттеләр, мирабны карак дип уйладылар.

— Һай, тотыгыз, качып бара бит! — дип, таяклар һәм күсәкләр белән шулкадәр кыйнадылар, мирабның качарга мөмкинлеге калмады, тотып бәйләделәр. Хатын әйтте:

— Ике мең динарны кая куйдың, китер! — диде. Ул әйтте:

— Моннан артык нәрсә юк иде, бу сүзе яладыр, Алланың казасына очрадым,— диде. Сүзенә карап, мирабны бушаттылар. Хатын ачуланды:

— Каракны ни өчен җибәрәсез? — дип, патша сараена китте. Падишаһка җитте, әйтте:

— И галәмнең падишаһы! Мирабтан ике мең динар аласым бар иде, бирми, зинһар алып бирегез,— диде. Падишаһ боерды:

— Казыйга бар!

Хатын әйтте:

— Казый өендә түгел.

Падишаһ әйтте:

— Мөхтәсибкә бар!

Хатын әйтте:

— Ул монда җибәрде,— диде.

Падишаһ мирабны алып килергә кушты. Китерделәр. Падишаһ әйтте:

— Һай, тугрылыксыз мираб! Синдә бу хатынның ике мең динары бар икән. Ни өчен бирмисең?— диде. Мираб әйтте:

— Дөрес түгел, миндә хәтта ике динары да юк, ялган сөйли,— диде, инкарь итте. Падишаһ хатынга әйтте:

— Шаһитың бармы? — диде. Хатын:

— Әйе, бар. Ат-арба бирергә боерыгыз, китерәм,— диде. Падишаһның ачуы килде, әйтте:

— Шаһит арба белән йөримени?! — диде. Хатын:

— Минем шаһитым арбасыз килмәс,— диде исә, падишаһ «Арба бирегез!» дип боерды. Бирделәр, арба белән барып, сандыкны салып, падишаһ янына китерделәр. Падишаһ бик гаҗәпләнде. Хатынга яңадан әйтте:

— Бу мирабка ни дәгъваң бар?

Хатын әйтте:

— Ике мең динарым бар,— диде. Мираб яңадан моңа каршы төште. Падишаһ әйтте:

— Шаһит кирәк.

Хатын шунда ук сандыкка әйтте:

— И сандык! Син шаһит, мирабның әйткәненә таныклык бир, югыйсә, утта көйдерермен,— диде. Сандыктан һич аваз килмәде. Падишаһ әйтте:

— Сандыкның теле бармыни инде, ничек ул таныклык бирсен? — диде. Хатын әйтте:

— Минем шаһитым бу сандыктыр һәм дә минем милкемдер. Ут китерергә боерыгыз, алай бик эреләнсә, утка салыгыз, көюдән куркып, шаять, сөйләр,— диде.— Әгәр сөйли икән — хакымны алып бирегез, сөйләми икән — акчам да китсен, сандык та янсын,— диде. Падишаһ моны хуш күрде, «бик гаҗәп эш» диде.

Аннан боерды, ут китерделәр, утын китереп, ягып җибәрделәр. Сандыкны арбадан төшереп, ут өстенә куйдылар, ут кызуына түзә алмыйча, сандыктагылар әйттеләр:

— Мираб ике мең динар бирергә ант итте, без шаһитбыз, хатын рас әйтә, сүзе хактыр! — диделәр. Падишаһ һәм сарай әһелләре бу хәлгә таң калдылар, шаккаттылар. Бу арада хатын, сандык янына барып, бикләрен ача башлады. Сандыктагылар, бер-бер артлы, ялангач хәлдә чыга башладылар. Адәм рисвае булып, оят-хурлыкка калып тордылар. Падишаһ бу күргән хәлнең ни икәнен хатыннан сорады. Хатын бу хәлне башыннан ахырынача сөйләп бирде. Падишаһ һәм барча сарай әһелләре бу хатынның зиһен-табигатенә, тугрылыгы һәм сафлыгына сокландылар, мактау сүзләрен әйттеләр.

Аннан падишаһ боерды, мирабны төрмәгә салдырды, ике мең динарны алып бирде. Мөхтәсибне — казый кулына, казыйны — шихнә кулына, шихнәне вәли кулына бирде. Бер-берсенә боерып, чәч-сакалларын йолыктырды. Вәлинең чәчен падишаһ үз кулы белән йолыкты, һәртөрле газаплар бирде. Дүртесен дә урыннарыннан төшерде һәм мал-әсбапларын алды. Хатынга зур хөрмәтләр күрсәтеп, олылап өенә җибәрде. Моннан соң да, ул хатынны сарайга алдырып, үз якыннары арасында шул башыннан кичкәннәрне сөйләтеп, күңел ачарлар иде. Ул хатын сарайның якын кешеләреннән булды, гомерен рәхәт үткәрде.

## Вәзирләрен эткә ашатучы патша турында хикәят

Хикәятләрдә шулай сөйлиләр: үткән заманда бер патша бар иде. Гадәте шул иде: һәр елда бер вәзирен, яманлап, этләргә ашатыр иде.

Патшаның бер дусты бар иде, ул әйтте: «Патша ел саен бер вәзирен этләргә ашата. Белмим, аның бу эшендә ни хикмәт бар икән? Бу елда мин вәзирлек итим әле, патшаның бу эшне ни сәбәптән кылганын белермен. Мөмкин булса, бу эшеннән туктатам»,— диде.

Яңа ел вакыты җитте. Патша, гаскәрен тезеп, уеннар ясады, бүләкләр өләштерде. Вәзирен этләргә ашатты.

Бу дусты аның янына барды, җир үпте: «Бу елны вәзирлекне миңа бирүеңне үтенәм»,— диде. Патша әйтте: «Син нинди теләк телисең? Беләсең бит: ел узгач, мин сине этләргә ташлармын. Ул вакытта хәтта дуслыгыбыздан да файда булмас»,— диде. Дусты әйтте: «Ярар, патша — син, үзең беләсең»,— диде.

Патша да риза булды, вәзирлекне аңа бирде.

Ул шул кадәр вәзирлек итте ки — барча халык аннан шат булдылар. «Шаһ моны этләргә бирер вакытта, шаһны үтереп, вәзирне шаһ итәбез»,— дип сөйләштеләр.

Менә бер вакыт ел ахыры җитте. Шаһ якыннарын җыйды, әйтте: «Мин аңа вәзир булма дип әйткән идем, үзе теләп алды, мин аны этләргә бирмичә куймыйм»,— диде. Вәзир әйтте: «Шаһ бу эшне надан-лыгыннан, бозык күңелле булуыннан эшләр, бу һич тә ярый торган эш түгел. Ни эшләсә эшләр, хөкем аныкыдыр»,— диде.

Бер көнне вәзиргә хәбәр бирделәр: «Өч көннән соң, патша сине этләргә бирер»,— диделәр. Вәзир уларын янына чакырды, аларга яхшы нәсыйхәтләр әйтте, күңелләрен басты. «Үз нәфсегезгә булышып, бер-берегезгә яманлык эшләмәгез, минем сүземне тыңлагыз»,— диде. Һәр-берсенә үзенә тиешлесен бүлеп бирде, хезмәтчеләрен азат итте. Аннан улларына әйтте: «Мине этләр ашаганнан соң, сөякләремне җыеп, берәр нәрсәгә төреп, атам кабере янына күмегез»,— диде.

Аннан соң, өйдә үзе генә калды. Хикмәт үлчәвен кулына алып, уйлар тәлинкәсенә хәйлә чарасын куеп, бераз утырды. Берничә алтын,

ит һәм икмәк китерде. Юлдашсыз, ялгыз гына, караңгы кичтә этләр карачы янына барды. Капка шакыды. Эт карачы чыкты. Вәзирне күрде, аягына төшеп, сәлам бирде, хөрмәт сүзләрен әйтте. «Ни хаҗәтең бар һәм ни хезмәт кирәк?»— диде. Вәзир әйтте: «Этләрне күрергә телим, капкаларын ач»,— диде. Эт карачы әйтте: «Чыгып китәрләр дип куркам»,— диде. Вәзир берничә алтынны эт карачының учына салды.

Икенче төнне дә, шул рәвешчә килеп, этләргә ит һәм икмәк ашатты. Өченче төнне дә шулай эшләде. Эт карачыга энҗе-җәүһәр һәм ризыклар бирде.

Яңа ел көне килеп җитте. Патша бөтен якыннары белән мәйданга чыкты, яңа елны игълан итте, бүләкләр өләштерде.

Аннан патша боерды, чи каеш китерделәр, этләргә салу өчен, вәзирнең аяк-кулын бәйләделәр. Патша әйтте: «Менә, үз-үзеңә артык ник ышансаң, шулай була ул»,— диде. Вәзир әйтте: «Үтенечем бар, кабул ит»,— диде. Патша: «Ни теләсәң телә, эшләрмен»,— диде. Вәзир: «Мине ташлар алдыннан этләргә ашарга бирмәсеннәр. Тагын берсе: минем сөякләремне улларым алсын, кабергә күмсеннәр»,— диде. Патша: «Үтенечләрең бик җиңел икән»,— диде. Эт карачыга боерды: «Этләрне ачыктыр, вәзирне сакла!»— диде.

Кич булгач, вәзирне ялангач калдырып, этләр алдына ташладылар. Этләр, бу кешенең берничә көн ризык биргәнен исләренә төшереп, янына килделәр, яландылар, ютмаландылар. Вәзир уйлады: «Болар мине икмәк китерде дип саныйлар. Ялыналар, бирмәгәнемне белгәч, ачыгырлар, мине ерткаларлар. Тәңрегә дога кылыйм, үлсәм, сәҗдәдә үлим»,— дип, башын сәҗдәгә куеп утырды. Этләр, икмәк һәм ит өмет итеп, бераз тордылар, бераздан соң өметләрен кисеп, һәммәсе вәзир тирәсенә елышып, башларын ал аяклары өстенә салып яттылар, иртәнгә кадәр кузгалмадылар.

Таң аткач, эт карачы килде, вәзирнең сөякләрен җыям дип, капканы ачып керде, ач этләр эт карачыга ябыштылар, бичара эт карачының канлы сөякләре генә калды.

Бу хәлне белделәр, патшага хәбәр бирделәр. «Вәзир сәламәт утыра, әмма эт карачыны ботарлаганнар», диделәр. Патша шул ук мизгелдә, ялан баш, ялан аяк килеш, атына атланып, ашыгып-чабып, этләр янына килде. Күрде, ишеткәне дөрес булды. Түбәнчелек белән вәзирнең аягына төште, әйтте: «Тәүбә булсын, моннан соң һичкайчан моның кебек эшне эшләмәм. Әмма миңа әйт: нинди хәер һәм яхшылыклар эшләдең, Хак тәгалә ничек сиңа моның кебек кадер-хөрмәт һәм котылу бирде, бу канечкеч этләрдән ничек котылдың?» — диде. Вәзир әйтте: «Мин әллә ни яхшылыклар эшләмәдем. Әмма шушы вакытка кадәр турылык һәм тырышлык белән сиңа хезмәт иттем, бер сәгать эшеңне калдырмадым. Ахырда шул булды: мине этләр авызына бирдең. Өч кич бу ерткыч җанварларга хезмәт иттем, бу өч кичәдә күрсәткән хезмәтемнең кадерен белделәр, миңа зыян тидермәделәр. Син үзең, җиһанның олы патшасы, шул этләр кадәре дә булмадың, ничә заманлык хакымны сакламадың. Синнән ни көтмәк кирәк?!»— диде.

Бу хикәяттән мәгълүм булсын: кешенең игелеген белмәгән кешедән эт яхшырак. Шагыйрьләр әйткәннәр:

Тоз-икмәк белмәк — олы һөнәрдер,
Тоз-икмәк белмәгән — эттән битәрдер.

## Таз бакчачы турында хикәят

Хәбәрләрне тапшыручылар һәм сүзләрне күчерүчеләр шулай сөйләделәр:

Фарсы илендә бер мәлик бар иде. Малы чиксез-чамасыз, биләгән җире очсыз-кырыйсыз, ә шәһәрләре сансыз-хисапсыз иде. Һичбер падишаһ үз заманында аның гамәленнән тыш хәрәкәт итмәс иде.

Ул падишаһның бер углы бар иде, матурлыкта кояш һәм йөз күркәмлегендә ай иде. Һәр төрле һөнәрдә булдыклы һәм камил, яхшылык белән эш итүче иде. Кульязмасы матур, язган әйберсе яхшы сыйфатлы иде. Сугыш кораллары уйнатуда гаҗәеп оста, кара-каршы көрәштә бердәнбер иде. Шулай ук шаһның тәрәге булуы һәм тиешле әдәп сыйфатлары белән бизәлгән иде.

Бер көн бу егет ауга чыкты. Кинәт күрде: читтән килүче сәфәрче ике егет бер тарафта торалар. Шаһзадәне күргәч, карап-күзәтеп, әйтәләр:

— Нинди тиңе юк егет! Яман күз бу егетнең чибәрлегеннән ерак булсын,— диделәр.

— Әгәр бу шаһзадә кәләш эзләсә, моңа лаек кайда булыр икән? Мәгәр Йәмән шаһы кызы Фәхренниса булса гына инде,— диделәр. Шул вакытта шаһзадәнең карашы ул егетләргә төште. Хәрәкәтләреннән белде: үзен сөйләшерләр. Шунда ук хезмәтчесен җибәрде:

— Бар, шул ике егетне өйгә илтеп кунак ит, яннарыннан китмә, мин дә шунда килермен,— диде. Хезмәтче барды, ул егетләрне сарайга китерде, хөрмәт һәм кадер күрсәтте. Шаһзадә аудан кайтты, ул егетләрне янына чакырды, хөрмәтләп кунак итте. Әйтте:

— Сезне мәшәкатьләдем, читтән килгән кебек күренәсез, читтән килгәннәр игътибарга лаек булалар, сый-хөрмәтебездә кимчелек булса, гафу итегез. Минем максатым — сезнең белән бераз дусларча сөйләшеп утыру,— диде. Бу егетләр түбәнчелек белән әйттеләр:

— Синең кебек падишаһтан моның кебек яхшылык гаҗәп булмас,— диделәр. Шаһзадә боерды, аш китерделәр, мәҗлес ясадылар, уенчылар күңелләрне юаттылар. Шаһзадә бер сазны[1] кулына алды, хәрәкәткә китерде. Ул егетләр таң калдылар. Шаһзадә әйтте:

— Сезгә бу көйне шуның өчен уйнадым: күңелсезләнеп утырмасыннар,— дидем. Егетләр рәхмәт белдерделәр, шаһка әйттеләр:

— Моның кебек мәҗлестә кайгы-хәсрәткә урын юк,— диделәр. Аннан шаһзадә боерды, ике төен кием китерделәр, ул егетләргә кидерделәр. Аннан, бераз вакыттан соң, шаһзадә сорады:

— Әй егетләр! Соравым гаҗәп булмас: кай җирдән сез? — диде.

— Без Йәмән вилаятеннән киләбез, бу шәһәргә килгәнебезгә өч көн булды,— диделәр. Шаһзадә:

— Әй егетләр! Бу икмәк ашау хакы өчен сездән бер нәрсә сорыйм, турысын әйтегез,— диде. Алар:

— Тыңлыйбыз һәм буйсынабыз! — дип җавап бирделәр. Шаһзадә әйтте:

— Анда, мин капкадан чыккан чакта, мине күреп ни дип сөйләштегез?

Әйттеләр:

— Без үз гомеребездә моның кебек һәр яктан җитешле матурны күргәнебез юк иде, тиңе-охшашы кем була, мәгәр Йәмән мәлигенең кызы Фәхренниса булса гына инде, дидек.

Шаһзадә Йәмән мәлиге кызының ниндилеген сорады. Берсе әйтте:

— Тырышлык белән танылган, язуда оста, йолдызлар гыйлемендә, киләчәкне юрауда, тоемда, нард һәм шахмат уйнауда осталыгы, зиһене бар, һәртөрле уен коралларында төрле көйләрне уйнарга оста, рәсем сәнгатенең һәртөрле ысулларын белә — диде.— Йөзе — ай һәм кояш,— диде. Шаһзадә Фәхренисаның сыйфатларын ишетте исә — күрми гашыйк булды, әмма һичкемгә белдермәде.

---

[1] Саз — кыллы музыка коралы.

Иртә торды, атасы янына барды, хезмәт итте, дога кылды. Аннан үзенең уен белдерде:

— Әй олуг атам! Минем күңелем теләр: бераз заман сәфәр йөреп, күңелем булса икән, дөньяны гизсәм, эшемне күрсәм икән, әгәр сезнең олуг тарафыгыздан рөхсәт булса, ярдәмегез булса икән,— диде. Падишаһ:

— Бу вакыт бу нәрсә яхшы түгел. Мин синсез тора алмыйм, мине ташлап кай җиргә китәсең? — диде. Шаһзадә әйтте:

— Йәмән тарафына йөреп, күңелем тамаша итәргә тели. Әгәр Хак тәгалә тереклек бирсә, янә тиз арада кайтып, хезмәтегездә булыр идем,— диде. Сүзендә нык торды, теләгәнен итәргә тырышты. Падишаһ күрде: углы сүзендә каты тора, карышып файда булмас. Боерды, сәфәр әсбабын хәзерләделәр, шаһзадәнең эшен кайгырттылар. Өч йөк алтын, ун голәм [1], ничәмә бәдәви [2] атлар, хезмәткәрләр, иярченнәр белән кәрван төзеп, шәһәрдән чыгарып, ике-өч авылны узганчы озатып, саубуллашып, атасы шәһәргә кайтты.

Шаһзадә шатлык белән йөзен Йәмәнгә тотты, торак урыннар һәм тукталышларны үтеп, Йәмән шәһәренә барып җитте. Бер зур кәрвансарайны вакытлыча файдаланырга алып торды, анда үзенең зур чатырын корды. Һәр көнне шәһәрнең төрле җирләрен гизеп йөрде, садака бирү, ятимнәргә күлмәк-чапан багышлау һәм халыкка ризык өләшү, сыйлауны үзенә гадәт итте. Йәмән халкы барчасы моның бу хәленә шатландылар, яхшы холкына, яхшы нигъмәтләренә һәм татлы теленә шәһәр халкы таң калды һәм афәриннәр укыды.

Шаһзадә Фәхреннисага гыйшкында карарсыз иде, ләкин бу серне ачарга бер кеше дә юк иде. Шаһзадә шуны гадәт итте: һәр көн базарда кибетләр алдында утырыр иде. Моңа берничә көн үтте.

Бер көн кинәт бер шау-шу кузгалды. Мөнади [3] кычкыра башлады, әйтте:

— Һәр кеше иртән иртүк өеннән чыкмасын, кибеттә утырмасын, әгәр шулай булса — каны үз муенына булыр, иртән шаһ кызы базардан үтсә кирәк! — диде. Шаһзадә бу хәлне белгәч, торды, өенә кайтты. Фикер итте:

— Бик яхшы. Мең җаным бар исә — фида булсын. Үз җаныңны бик сөйсәң, теләк үтәлми ул,— диде. Кичтән иртәнгәчә шул уйда булды.

Менә таң атты. Халык өендә утырды. Шаһзадә, кыю рәвештә барып, кибет алдында торды. Кинәт Фәхреннисаның хадимнәре килде, шаһзадәне күрделәр. Берсе:

— Ни өчен хөкемгә буйсынмыйсың? Каның — муеныңа! — дип үтте. Кылыч белән чалырга теләде, ләкин шаһзадәнең матурлыгын күреп, кыймады. Әйтте:

— Кызганыч, күңелеңне юата алмассың, үз җаныңны югалтырсың. Тор, кит! — диде. Үтеп китте, шаһзадәне кузгатмады. Кәнизәкләр килеп җиттеләр. Күрделәр: шундый бер сурәт, ай-кояш йөзле. Хәйран калдылар, эчләре көенде. Әйттеләр:

— Һай егет! Тор, кит! Шушы сәгатьтә үк һәлак булырсың,— диделәр.

Бер сәгать үтте, искиткеч матур сурәттә, купшылык, олысыманлык белән шаһ кызы килеп җитте. Шаһзадәнең күзе аның йөзенә төште исә, шундук һушсыз булып егылды. Аны күргән кешеләр һәрберсе бер сүз әйтте. Бере: «Дивана», бере: «Ул — тереклегеннән ваз кичүче»,— диде. Ни булса — ул булды: һәлак булудан котылды.

---

[1] Голәм — хезмәтче.
[2] Бәдәви ат — гарәп аты.
[3] Мөнади — сөрән салучы.

Ни эшләргә кирәклеген алдан уйлап, кыйммәтле киемнәр киде, бер янчык алтын алды, биленә бәйләде. Бакча ишегенә барды. Бакча караучы бакчаны ачкан, ишек катында тора. Шаһзадә алга барды, картка сәлам бирде. Бакчачы карт сәламен алды. Шаһзадә бакчачыга әйтте:

— Әй хөрмәтле карт! Ни булыр: әгәр бу бакчаны миңа күрсәтсәң? — диде. Карт әйтте:

— Әй егет! Тизрәк кит! Хәзер бер мәрхәмәтсез кеше килер, сине монда күрсә һәлак итәр,— диде. Шаһзадә янчыкны чыгарды, бакчачының алдына куйды.

— Бу мең динарны ал, сиңа бүләк булсын. Теләгем шул: мине бакчага куясың, шунда бер тапкыр гына кызның йөзен күрим,— диде. Бакчачы янчыкны алды, әйтте:

— Әй егет! Бүген вакыты түгел, тагын икенче бер вакытта килерсең; сине бакчага куям, бер җирдә яшеренеп ятарсың, күңелең теләгәнчә күрерсең.

Шаһзадә кире кайтты, элеккеге рәвешенчә булды. Вәгъдә көнендә бакчачы янына барды. Бакчачы, шаһзадәнең кулын үбеп, бакчага алып керде, ашатты-эчертте, кунак итте. Аннан әйтте:

— Әй егет! Бу синең уең яман уйдыр. Синең һәм минем башыбызга хәтәр бирер. Кит, азат бул, бушан, бу уйдан кич,— диде. Шаһзадә әйтте:

— Әй ата! Мин бер читтән килгән егетмен. Бу шәһәрдә белештанышым һәм дус кешеләрем юк, янә бу уй башымда бар. Синең ярдәмең белән генә аңа ирешә алам, булмаса һәлак булам,— диде. Бакчачы карт тыңламады, шаһзадә бик нык ялынды, бик борчулы булды. Бакчачының карчыгы шул вакыт шаһзадәне кызганды, картына әйтте:

— Әй картым! Бу кешенең әйткәне җинел эштер, нәрсәгә дип бәйләндең? Ул килгәч, бу кешене яшерәм, максаты бер күрү икән, аны кайгырту кирәк,— диде. Шаһзадә әйтте:

— Күрәм икән — күңелем була, сусаганымны басам,— диде. Карчык:

— Инде нык бул, шаһ кызы бакчага килгәндә яшерен, өстеңә пәрдә өретәм, сине араларына куям, шунда утыр. Шаһ кызы мәҗлес ясар, шәраб эчү белән мәшгуль булыр, шул вакыт кызлар арасында бер җирдә утырырсың, тамаша итәрсең, әмма сабырсызлык итмә. Синең өчен башымны һәм җанымны бирәм, җаныбызны җилгә очырма,— диде. Шаһзадә тамаша хакында вәгъдәсен нык беркетте.

Сүзләре тәмам булгач, бервакыт шау-шу, ыгы-зыгы кубып, шаһ кызы килде. Бакчага керде, гөлчәчәкләрне карап йөрде. Аннан тамашаханәгә керде, мәҗлес әсбапларын хәзерләделәр. Көмеш чүмечләр, тустаганнар, пыялалар китереп куйдылар. Бакчада сайрар кошлар, былбыллар агач башларына күчтеләр, сайраудан туктадылар. Шул вакытта Фәхренниса кулына саз алды, авазын чыгарды, сөйгән ярын өзелеп сагыну, әләү, аңа инәлү белән тулы көйләр, моңлы бизәкләр күрсәтте. Шуның кебек күңелне җәлеп итә торган, сокландыргыч көйләр уйнады — шаһзадә бөркәнчек астында бер һуштан язар, бер һушына килер иде.

Кинәт шаһ кызы башыннан таҗын күтәрде, йөзен каплаган пәрдәне алып ташлады, тәмам ачылды. Шаһзадә, күзе төшкәч, ихтыярсыздан кычкырып рисвай була язды. Мең мәшәкать белән үзен тыя алды. Ул арада кәнизәкләрдән берсе көй уйнады. Кыз уенга керде, биеде, күңел ачты. Кыз тирләде, шул вакыт сөт анасына әйтте:

— Күңелем булды, туйдым. Рөхсәт итсәгез, суга керәм,— диде. Путасын салды, киемнәрен чишенде, кәнизәкләр белән суга керде, уындыюынды. Шул вакыт ул зирәк кызның күзе шаһзадәгә төште, үткен зиһене белән белде: ят кешедер. Боерды:

— Тотыгыз! — диде. Кәнизәкләр аны тотып алып, бәйләп, сөйрисөйри алга таба илттеләр. Бөркәнчеген башыннан алдылар.

Аннан соң кыз, чыгып, җәйге сарайда күңелсезләнеп утырды, шатлыклары кайгыга алышынды. Бакчада күп төрле сүзләр булды. Хадимнәр шаһзадәгә бик нык суккаладылар, муенына бау тагып, сөйрәп, Йәмән шаһына илттеләр, вакыйганы белдерделәр. Йәмән шаһы каты ачуланды, әйтте:

— Әй шакшы юлбасар! Бу нинди әшәке эш, үзеңә һөнәр иткәнсеңме? Миннән курыкмадыңмы, кызым һәм кәнизәкләрне начар данга катыштыргансың? Хәзер үк боерам, сине икегә аерырлар! — диде.

Шаһзадә башын түбән салды, һич җавап бирмәде. Шаһ боерды:

— Җәллад килсен! — диде. Җәлладны китерделәр, ул шаһзадәнең күзен бәйләде, муенына ормакчы булды. Шунда вәзир әйтте:

— Бу кечкенә эш түгел. Шаһ боерса, ул угланны зинданга илтсеннәр, иртәгә шәһәрне гиздереп, «һәркем тыелганга кул сузса, җәзасы бу» дип йөртсеннәр. Анда, ни теләсәләр, шуны итсеннәр,— диде. Бу сүз белән зинданга илттеләр, иртәгесен эшен хәл итмәкче булдылар.

Очраклы рәвештә шулай булды: көнбатыш солтаныннан илче килде. Шаһ:

— Җәяү чыгып каршы алыгыз! — дип әмер итте. Түрәләр барып, кадер-хөрмәт белән шәһәргә китереп, кундырдылар, азык-төлек, киреккярак хәстәрләп бирделәр.

Иртән халыкка хәбәр бирделәр, дәүләт терәге булган олылар һәммәсе килеп, үз урыннарына утырдылар. Аннан илче бүләкләрен күрсәтте һәм бер язу чыгарды, шаһның алдына куйды. Шаһ язуны алды, укыды, вәзиргә бирде. Вәзир дә язуны укыды. Анда язылган иде: «И Йәмән падишаһы — адәм улларының шаһы, галәмнең бәхетлесе, җир йөзенең идарәчесе, үлемсез адәм! Кыйммәтле, кадерле гомерең озын булсын! Шул мәгълүм булсын, шуны телибез: сезнең белән якынлык булдырсак, бергәлек килешүе төзесәк икән. Минем бер угланым бар, төрле җирдә таҗ-тәхетсез сөрелеп йөри иде, бу вакыт мөлкәтебезне аңа багышладым. Әгәр шаһ ул угланымны кабул итсә, зур яхшылык кылган булыр иде. Вәссәлам!..» Хатның эчтәлеген укып белгәч, Йәмән шаһы башын түбән салды, бераз уйлап утырды, аннан башын күтәрде. Әйтте:

— Минем кызым ул угланны кабул итсә, дуслыгыбыз ныгыр, якынлыгыбыз артыр иде. Әмма мин кызымны беләм: ул әле ирләргә күз төшермәс һәм ир сөймәс дәрәҗәдә яшь,— диде. Боерды, аннан җавап язды, илчегә кыйммәтле киемнәр бирделәр, шаһларның гадәтенчә, тиешле хөрмәт күрсәтеп, күп төрле нигъмәтләр белән кайтарып җибәрделәр.

Илче кайтып, падишасына хәбәрне җиткерде, хикәятне белдерде. Мәгъриб шаһы бик нык ачуланды:

— Барам, кызын каһәр белән алып, вилаятен егып, тар-мар итәм! — диде.

Бу тарафта Йәмән шаһы үзе яман авыруга очрады, күп чаралар, дәвалар иттеләр — файда булмады, догага сыенды. Зиндан халкын һәммәсен азат иттеләр, шаһзадә дә шулар белән бергә азат булды.

Шунда ук өенә кайтты, бер янчык алтын алды, бакчачы хатынына барды. Хатын әйтте:

— Әй кадерлем! Исән-имин котылдың, инде батырчылык итмә, бер кыз өчен җаныңны кыйма,— диде. Шаһзадә афәрин укыды, янчыкны чыгарып боларның алдына куйды. Әйтте:

— Әй ана! Минем эшем гаҗәп эштер. Әгәр шулай булса, кыз бакчага килеп, мин аны күрмәсәм — үләрмен,— диде. Бакчачы әйтте:

— Әгәр бер күрүгә канәгать булсаң, мин сине күгәрчен кетәклегендә яшереп саклыйм, кара, тамаша ит, ләкин сабыр ит, артык хәрәкәт ясап, рисвай була күрмә,— диде. Шаһзадә:

— Шулай булсын! — диде. Аннан бакчачы шаһзадәне күгәрчен кетәклегенә илтте, яшерде.

Шаһ кызы килер вакытта хадимнәр һәм җыештыручылар бакчаны себерделәр, келәмнәр һәм паласлар түшәделәр.

Шаһ кызы килде, бакчага үтте. Дая һәм кәнизәкләр үз урыннарына урнаштылар. Кыз әңгәмә белән мәшгуль булды. Боерды, уен коралын китерделәр, кулына алды, күркәм аһәңнәр тибрәтте. Былбыллар сәрви агачына очып кундылар, моңлы көй тыңладылар.

Кыз ул коралны куйды, тагын бер саз алды. Гаять тә моңлы уйнады ки, ишеткән адәм аңа чак түзеп утырыр. Кыз җырлады. Шаһзадә утырган җирендә бер һуштан язып, бер һушына килер иде. Ләкин чарасызлыгыннан сабыр итәр иде. Кичтән таң атканчыга кадәр күңел ачу туктамады. Таң аткач, кыз сараена кайтып китте.

Шаһзадә, кыздан аерылуына чыдый алмый, «аһ-ваһ» кыла башлады. Бакчачы карт әйтте:

— Әй углым! Йөрәгебезне яндырдың, сиңа ни чара булыр икән?— диде, күгәрчен кетәклегеннән төшерде, өенә илтте. Бакчачы хатыны каршы чыгып әйтте.

— И кадерлем! Хәлең ничек?— диде. Шаһзадә:

— Әй анам! Хәлемне сорама, миңа бер чара табу артыннан булсаң, ни булыр?— диде. Бакчачы хатыны әйтте:

— Мин сиңа бер чара итәм, әгәр риза булсаң,— диде. Шаһзадә:

— Ни эшкә боерсаң да, башым китәр булса да, ризалык бирәм, шуның белән күрешүгә ирешәм,— диде. Бакчачы хатыны:

— Сине таз итеп ясыйм, минем иремнең шәкерте бул, бакчадан чыкма. Кыз килгән саен тамаша итәрсең,— диде. Шаһзадәгә бу сүз хуш килде.

Бер ишәкне суеп бирделәр, бакчачы белән карчыгы шаһзадәне юып, башына карындыктан башлык кидерделәр, чәчләрен яшерделәр. Аны күргән кеше «таз» дип санар иде.

Аннан ул сазларның берсен кулына алды, сазны сөйләтте, җырлады, елады. Бакчачы һәм карчыгы таң калдылар. Шаһзадә ул сазны куйды, тагын бер саз алды, көйгә китерде.

Ул көнне вәзирнең углы ауга барыр иде. Юлы бакча янына туры килде. Бу авазны ишетте, берәүгә боерды:

— Кереп күр, бу авазны кем чыгара?— диде. Ул кеше бакчага керде, күрде: бер кеше су буенда моңлы көй уйнар. Чыкты, вәзир углына әйтте. Вәзирзадә ишетте, әйтте:

— Бу кем икән, мондый бакчага юл табып кергән, моны яхшылап тикшерергә кирәк, буш кеше түгелдер,— диде, ат башын бакчага борды. Бакчага керде, туры су янына барды. Шаһзадә аны күргәч торды, китәргә теләде. Вәзирзадә әйтте:

— Әй ярсөяр! Монда синең өчен килдек, син кая китәсең?— диде. Шаһзадә теләр-теләмәс туктады, түбәнчелек итте. Әйтте:

— Сезнең кебек бәкләргә мин ничек лаек булыйм?

Вәзирзадә:

— Әй егет! Син ни кешесең, кайдан килеп, бу бакчага кереп торасың?— диде. Шаһзадә җавап биргәнче, бакчачы карт әйтте:

— Әй хөкемдар! Бу — минем шәкертем, бакчачылык гыйлемен яхшы белә, мин моның канаты белән очамын,— диде. Вәзирзадә:

— Кил, бу сазыңны бераз чал, җырла, ишетим,— диде. Шаһзадә:

— Мине мәсхәрә итәсез, сезнең кебек өлкәннәр алдында мин ни чара беләм,— диде. Вәзирзадә сүзен куймады:

— Ни булса булыр, безнең күңелебезне калдырма,— диде.

Шаһзадә «Ярар» дип, кулына танбурны [1] алды, моңлы бер аваз чыгарды, үзенә күрә бер ысул белән оста итеп кылларны сөйләтте.

[1] Танбур — кыллы музыка коралы

Вәзирзадәнең исеме Шәмселмөлек иде, иярченнәре арасында музыкантлар да бар иде, кичә-көндез бергә йөреп, көйләр көйләп җырларлар иде. Ул көн сазны тотарга оялдылар, барчасы оятка калдылар. Вәзирзадә әйтте:

— Әй таз! Сиңа бакчачылык тиеш түгел икән, син падишаһлар сохбәтенә[1] яраклы икәнсең!— диде. Вәзирзадә мондый яхшы сохбәтне күреп, аугa баруын онытты.

— Таз булмаса ни була иде, мин моны янымнан җибәрмәс идем,— диде, таңга кадәр мәҗлес корып утырды. Таз бакчачыны җырлатты, ашады-эчте, күңел ачты.

Торып китте, өенә кайтты. Аугa бармаганлыгын вәзиргә хәбәр иттеләр. Атасы углын чакырды, аугa бармаганының сәбәбен сорады. Вәзирзадә таз бакчачының сыйфатын, һөнәр белгәнен, уенга-җырга осталыгын, тагын да матурлыкта тиңсезлеген сыйфатлап бирде.

Вәзир бу сүзне ишеткәч, әйтте:

— Моны падишаһка әйтергә кирәк, күңел ачып утырырга бакчага барсын, шул рәвешчә без дә барып тамаша итәрбез,— диде. Шундук торды, шаһ янына барды, утырды. Шаһка бераз хезмәт итеп, күңеленә ярарлык, күзгә күрекле сүзләр сөйләшеп тәмам иткәндә, сүз уңаенда әйтеп куйды:

— Дәүләтегездәге бакчага барып, бераз күңел шатлыгын кылсагыз, ничек булыр икән?

Падишаһ әйтте:

— Бик яхшы булыр! Күңел теләгәнен алмак кирәк,— дип, хезмәтчеләренә боерды.

Бардылар, мәйдан хәзерләделәр, патшага хас түшәк түшәделәр, аш-сучылар һәм шәрапчылар кирәк-яракны хәстәрләделәр. Әсбаплар хәзерләнеп беткәч, хәбәр иттеләр. Падишаһ белән дәүләт терәкләре түрәләр, мәмләкәтнең байлары атларга атландылар, бакчага килеп җиттеләр. Килделәр, су янында утырдылар, әңгәмә кордылар, күңел ачуларга бирелделәр.

Әмма вәзирнең күзе һәм күңеле бакчачы картның шәкертендә иде, нинди кеше икәнен күрәсе килде. Ләкин бакчачы тазны яшергән иде. Бераз уткәч, вәзир бакчачыга әйтте:

— Синең бер таз шәкертең бар икән, ни булыр аны монда китерсәң һәм бу халыкны көлдерсәң,— диде. Бакчачы:

— Фәрманыгызны тыңлыйм!— диде. Тазны алдырырга сүз куештылар.

Бакчачы куышына керде, бер кисәк бүзне тазның биленә бәйләде, ике начар оек кидерде, бер савытка гөл салып, башына күтәртте, шаһ алдына китерде.

Кинәт шаһның күзе төште, күрде: бер таз. Ул таз китергән гөлен кыю рәвештә шаһның күз алдына куйды. Шаһ:

— Бу таз минем бакчамда ни эшләр?— диде. Бакчачы җавап бирде:

— Ул — минем шәкертем, бакчачылык гыйлемен яхшы белә,— диде. Аннан вәзир әйтте:

— Әй бакчачы! Бу тазыңны уйнат, күңелебезне күрсен,— диде. Шаһ шунда:

— Мәсхәрәләребез[2] уйнасын, ул таз ни белсен?— диде. Вәзир:

— Үз мәсхәрәләребез һәр көн уйныйлар, бу тазны карарга кирәк,— диде. Шаһ:

— Ярар, шулай булсын!— дип фәрман кылды.

Аннан бер мәсхәрә торды, уенга керде, уйнады. Тазны уртага алдылар, таз ике кулын як-якка сузды, тибрәнде, аннан бии башлады. Шул-

---

[1] Сохбәт — әңгәмә, сөйләшеп күңел ачып утыру.
[2] Мәсхәрә — уенчы, артист.

кадәр оста биеде — шаһ, вәзир, түрәләр, шаһның якыннары — һәммәсе таң калдылар. Шаһ әйтте:

— Нинди кызык! Таз булмаса ни булыр иде! — Тазны чакырды:

— Әйдә, утыр, шәрап эч! — диде. Таз түбәнчелек белән әйтте:

— Мин бер кол, миңа бүтән хезмәт боер, мондый падишаһларның мәҗлесендә нәрсәгә ярармын,— диде. Шаһ әйтте:

— Әлбәттә, ярамасаң да, музыкантлар янында утыр, шул уйнаганың җитәр,— диде.

Таз утырды. Вәзир шаһка әйтте:

— Боер, саз чалсын! — диде. Шаһ сорады:

— Саз чала беләме?

Бакчачы:

— Күп белмәсә дә, бераз белә,— диде. Шаһ боерды:

— Алсын, белгәненчә чалсын, янә халыкны көлдерсен,— диде.

Сазны шаһзадәгә бирделәр. Кулына алып, көйләп, шундый бер аһәң тибрәтте ки — ишеткәннәр, «аһ» орып, үксеп җибәрделәр. Мондый аһәңне шаһның ишеткәне дә юк иде. Хәйран булып, бармакларын авызына салып тешләр иде.

Шаһ вәзиргә әйтте:

— Таз бакчачыбыз һөнәр иясе икән!

Шаһ боерды, мең динар акчаны янчыгы белән тазның алдына куйдырды. Шаһзадә янчыкны ачты, ул динарларны уенчыларга өләште. Шаһ, моны күреп, хәйран калды. Боерды, күңел ачу мәҗлесен яңадан дәвам иттерде. Таз уен коралларын бер-бер артлы уйнатты, шундый итеп уйнады — һәммәсе хәйран калды. Шаһ яңадан мең динар боерды, калган якыннарына һәм уенчыларга да бүләк бирде. Бу яхшы бүләкләр өләшенгәннән соң, таз яңадан динарларны уенчыларга багышлады. Шаһ тагын моны күреп, вәзиргә әйтте:

— Монда булган бу киң күңеллелек падишаһлар күңеле кебек, ул күңелнең эчендә ниләр барлыгын белү Ходайдан башкага мөмкин түгел. Ләкин шул мәгълүм: бу буш кеше булмас, бакчачылыкка лаек түгел. Ни була иде моның чәче булса?! — диде. Аннан падишаһ сорады:

— Шахмат уйный беләсеңме?

Таз:

— Бераз йөрешен беләм,— диде. Шаһ боерды, бер ярдәмчесе белән шахмат уйнатты. Таз аңа мат куйды. Тагын берсе утырды — оттырды. Шаһ боерды, барча ярдәмчеләрен бер якка куеп уйнатты, ләкин төркемдә кем бар исә, һәрберсе оттырды. Бер кыю мәсхәрә бар иде, ул әйтте:

— Хәзер чират — шаһныкы,— диде.

Шаһ начар уенчы түгел иде, никадәр уенчылар аны бөгә алмаслар иде. Менә таз белән уйный башлады, бер йөрешендә хата ясады, җиңелде. Шаһ тазны мактады, яңадан сорады:

— Яза беләсеңме?

Таз:

— Кулыма каләм тота беләм,— диде. Каләм китерделәр. Таз каләмне кулына алды, шаһны мактап, берничә шигырь юллары язды, кулъязмасы бик матур иде. Шаһ күрде, гаҗәпләнде. Бармакларын күреп тә сокландылар. Шаһ вәзиргә әйтте:

— Моны бакчада тоту ярамас, шулай кирәк: минем янымда торырга лаектыр,— диде. Вәзир шаһка әйтте:

— Боерыгыз: моңа айлык хезмәт хакы языйк, бакчада торсын, кайчан кирәк була — шунда яңадан монда килербез,— диде.

Шаһ:

— Үзең беләсең,— диде. Айлык хезмәт хакы бирү турында таныклык язып, тазның кулына тоттырдылар. Таз әйтте:

— Сез киткәч мине бакчадан куарлар,— диде. Падишаһ үз кылычын аның кулына бирде, әйтте:

— Кем дә кем сине бакчадан куарга теләсә, моның белән муенын чал,— диде. Аннан сорады:

— Сугыш эшен беләсеңме?

Таз:

— Ул эш сугыш көнендә булыр,— диде.

Шаһ, барысын да сорашкач, боерды, бакчачыны китерделәр. Шаһ тазның кулыннан алды, бакчачыга тапшырды, әйтте:

— Моны хуш тот, яхшы сакла, әгәр югалса, сине җәмәгатең белән бергә җәзага тартырмын, шуны белеп тор,— диде. Атына атланды, сараена кайтты.

— Бакчабызда бер таз пәйда булган, бакчачыга шәкертлек итә, шундый хәрәкәтләр күрсәтте ки — һич әйтеп бетереп булмас,— диде.

Фәхренниса ишетте исә — карары калмады, тизрәк бакчага барып, тазны күрергә теләде, ләкин вакыты җиткәнче сабыр итте. Менә ул вакыт җитте, гадәтенчә әсбапларын хәзерләделәр. Барып, бакчага кереп, тәхет өстенә утырды.

Шаһзадә исә бу вакытта эшкә мәшгуль булыр иде. Шул вакыт «шаһ кызы килде» дип хәбәр бирделәр. Шаһзадә әйтте:

— Ул тарафка барам, кызны күрәм,— диде. Бу тарафта шаһ кызы даясенә [1] әйтте:

— Бакчага кереп кара, нинди кешедер, исеме шулай телгә менгән нинди таз икән ул?— диде. Шул таз сәбәбеннән, күрмәгән килеш, аның күңелендә бер уй урнашты.

— Күңелемдә шул тазны күрергә телим. Шул була: күреп, ярамаслык булса, бу уйдан котылам,— дип әйтте. Дая:

— Фәрман синекедер,— диде. Торды, бакчачыга барды, әйтте:

— Шаһ кызы сәлам әйтте, янә сорады: «Бу таз ни вакыттан бирле монда?» дип.

Бакчачы җавап бирде:

— Берничә айдыр. Шаһка да билгеле булды, шаһ аңа хезмәт хакы бирде, янә үз кылычын аңа бүләк итте. «Кем дә кем сине бакчадан куса, муенына ор», дип.

Карт торды, дая белән бакчага керде, барып тазны күрде, янына килделәр. Дая сәлам бирде, әйтте:

— Син нинди бакчачы?! Шаһ кызы бакчага килде, ә син гөл белән янына бармыйсың?— диде. Таз:

— Мин аның ачулануыннан куркам, кыюлыгым җитми,— диде. Дая:

— Һич нәрсә уйлап торма, чатырга бар,— диде. Таз торды, даяга иярде. Дая әйтте:

— Мине сиңа шаһ кызы җибәрде: «Бар, шул тазны тап, миңа китер!» дип әмер бирде, бер сәгать мәҗлестә булырсың,— диде.

Таз бер савыт гөлне башына күтәрде, кызның чатырына барды, ишектә торды. Дая эчкә керде, кызга әйтте:

— Мәҗлестәшне табып китердем, ни боерасың?— диде. Кыз канәгать йөз белән рөхсәт бирде.

Таз, гөлне күтәреп, эчкә керде, кызны күрде, йөзен җиргә куйды, гөлне кызның күз алдына урнаштырды. Кыз, шаһзадәне күргәч, ихтыярсыз аяк өсте басты, сәламләп һәм баш иеп, яңадан утырды. Тазны күргәч, карарсыз булды, күңелендә шәфкате, мәхәббәте тибрәнде. Таз, гөлне куйгач, кире китеп, бусагада торды. Кыз утырырга боерды. Шаһзадә утырды. Бераздан соң кыз, сазларны алып, көй уйнарга әмер итте. Шаһзадә танбурны кулына алды, боргалады, рәтләде. Моңлы аваз белән җырлады.

Ни булыр, әгәр якын ярым булсаң,
Исләремә син төшеп, онытылсам?

---

[1] Дая — сөт анасы

Иреннәреннең татлы тәмен эчсәм,
Гыйшкың оҗмахларына күчсәм?

Шул рәвешле җырны ишеткәч, кызның эчендә мәхәббәт орлыклары шытып чыкты, өзгәләнеп бер кычкырмакчы булды, шулай да, горурлык хисе һәм ныклык белән үзен тыярга тырышты, сабыр итмәкче булды — тәкате җитмәде, пәрдәсен йөзеннән күтәрде; ләкин суынды, акылын кулына алды, ганканы уйнатып, шулай көйләде:

Күз алдымда дәлил: бу хәл булды,
Күңелем кошы гөлгә кунды.
Аны күрсәм — инде күңелем тулыр,
Күрешүгә ирешү хыял булыр.

Шаһ кызы бу бәетләрне җырлады исә, Шаһзадә һушыннан язудан аз гына калды, бер «аһ» ормакчы булды, әмма үзен тотты. Кыз, бу моңлануыннан соң, ганканы шаһзадә алдына куйды. Шаһзадә ганканы кулына алды, көйгә китереп җырлады. Кыз күңеленнән шундый сүзләр әйтте: «Һичкемгә минем хәлемне бирмәсен, чөнки күңелем бу тазга шундый тартыла, аны күрми торсам, барча җиһан күземә күренмәс,— диде.— Тик моның асылын-нәсәбен, нилектән икәнен белмим,— диде.— Бу, бар булдыклыгы белән, бары тик таз гына булмаса икән... Минем ир сөймәслегем башыма ниләр китерде?!»— диде. Тәкатьсез булып утырыр иде. Шаһзадә, сазларны яңадан көйгә китерде:

Моңлы йөзләреңдә ай нурыдыр,
Толымнарың — ләйсән яңгырыдыр.
Чишмә челтерәве — көлүләрең,
Шикәр кебек татлы иреннәрең.

Кыз боерды, кулына саз бирделәр, чалып җырлады:

Гыйшкың синең — күкнең казасыдыр,
Ташлап китүең — тәкъдир җәзасыдыр.
Күңелемнең ярасы һич тынмыйдыр,
Тыңла яр: сазым һаман да чыңлыйдыр...

Шаһзадә, бу сүзләрне ишеткәч, хәйран калды.

Мәҗлес тә ахырына җитте. Шаһзадә торды, чыкты.

Кызның күзенә якты дөнья караңгы булып күренде. Төрле-төрле фикергә барды, таң атканчы уйланып утырды. Ашау-эчүдән калды. Атына атланды, сараена китте. Күңелендә әйтте: «Бармаган гына булсам икән, бу егетне күрмәгән генә булсам икән!...» Даясы моны тойды, әйтте:

— Әй кадерлем! Сиңа ни булды, мондый борчылуга төштең? Эшеңне миңа әйт, чара итәм,— диде. Кыз әйтте:

— Әй анам! Синнән ни яшерим — тазга гашыйк булдым, бел: карарсыз калдым. Ходa хакы өчен, бер чара тап, тапмасаң — үләрмен,— диде.

Дая, шунда ук, бер иске бөркәнчек бөркәнеп, бакчага китте.

Тазны эзләп йөрде, ерактан бер җирдә күрде: таз су янында утыра, башына кигән ярысын салган, ефәк кебек чәчләрен тарый.

Дая аны тамаша итте, ахырда кире кайтып китте, кыз янына килде. Әйтте:

— Яхшы хәбәргә бүләк булсын! И кадерлем! Таз түгел икән, башын коткару өчен үзен таз ясаган, тагын бер шөкранә бу: асыл нәсәптән икән, юкса гади угланда бу һөнәрләр кайдан булсын, бу кадәр мәртәбәле һөнәрләр өйрәнү юк-бар кешенең кулыннан килерме?!— диде.

Кыз, бу сүзне ишеткәч, бер гыйшкы мең булды. Янә даядән чара сорады. Дая әйтте:

— Чара шул: атаң хадимнәреннән берсен чакыр, ул барып, тазны чакырыр. Әйт: «Ни булыр икән барсаң, ул тазны минем исемнән ча-

кырсаң, аны күрәсем килә», диген.

Кыз бу чараны хуплады, бер хадимне янына чакырды, аңа шул рәвешчә сөйләде. Хадим, барып, алып килде.

Кыз күреп, сөенде, тәхет янында урын бирде, утыртты, ашау-эчүгә кыстады. Дая килде, әйтте:

— Әй таз! Үзеңне бу шәкелдә [1] төзеп, башыңа тире кигәнсең; шуңа охшаган: берәр серең бардыр, безгә шуны ач, ишетик, сереңне сакларбыз һәм сине сөярбез,— диде. Шаһзадә серен чиште, турысын сөйләде, нәсәбе кем икәнен күрсәтеп бирде, хикәятен түкми-чәчми, әвәл-ахырын тәмам шәрех итте.

Кыз, хәлне белгәч, шаһзадәне кызганып елады. Шунда ук боерды, бер букча шаһларга хас киемнәр китертте, шаһзадәгә кидерде. Шаһзадә әйтте:

— Искеләрне саклагыз, шаять бер кирәк булыр,— диде. Аннан Фәхренниса аның белән аулакта сөйләшеп, күңел ачып утыруга мәшгуль булды. Әйтте:

— Син минем өчен шулкадәр авырлыклар күрдең, инде мин синекемен, кайгырма, күңелеңне хуш тот, инде кайгы шатлыкка алышынса кирәк,— диде. Ул кичәдә таң атканга кадәр бергә булдылар.

Таң атты, яңадан мәҗлес ярагын әзерләп торганда, кинәт бер шаушу ишетелде. Шаһзадә «шәһәрдә бер-бер фетнә купты ахры» дип уйлады. Фәхреннисадан сорады:

— Нинди вакыйга?— диде. Фәхренниса сөйләде:

— Мәгъриб падишаһы мине углы өчен кияүгә сорады, минем аңа ризалыгым булмады. Хәзер инде шул ачудан атама каршы гаскәр җибәргән, көч белән алу өчен.

Шаһзадә әйтте:

— Синең гыйшкыңда, күр, ниләр башкарырмын, боер: сугыш киемнәре китерсеннәр, Хак үңдырса, шул эш хакында барам,— диде. Шунда ук хәзер иттеләр. Шаһзадә, атка атланып, атын куып, шаһ янына барып, аны сорады. Әйттеләр:

— Дошманга каршы сугышка китте,— дип. Шаһзадә атын куды, йөри бирде, сугыш кырына җитте. Күрде: ике гаскәр, кара-каршы торып, сафлар төзеп, мәйданга чыгарга кеше чакырып торырлар иде. Шаһзадә гаскәрне бу хәлдә күрде исә, ашыкты, мәйданга барып, ике сафның арасында торды, мәгъриб шаһыннан мәйданга ир чакырды. Бер пәвлеһан керде, аны күп сөйләштереп тормады — тәпәләде. Янә берсе килде — котылырга ирек бирмәде. Бер-бер артлы егерме ирне тәпәләде. Башка кеше мәйданга кермәде.

Йәмән шаһы әйтте:

— Бу бакчачы таз икән, әгәр бу гаскәрнең йөзен кирегә дүндерсә, Фәхреннисаны моңа бирәм, ни булса шул була,— диде.

Шул вакытта мәгърибләләрнең гаскәр башлыгы кычкырды:

— Әй кабахәт! Егерме кешемне ектың, аларның үчен синнән алам, сугыш ничек булганын күрсәтәм, бире кил!— диде. Шаһзадә, моны ишеткәч, гайрәт белән кычкырды:

— Сине дә алар эзенә җибәрәм!— диде. Ярсып, арыслан кебек үкереп, алга барды. Теге дә арыслан кебек гайрәт күрсәтеп, кара-каршы тордылар, бер-бере белән орыш кылдылар. Ахырда шаһзадә кылыч белән шундый чалды — гаскәр башлыгы калкан ябынды, калканы файда итмәде, шаһзадә аны калканы-ние һәм аты белән икегә аерды. Шаһзадә, аның башын алып, Йәмән шаһына илтте. Йәмән шаһы шаһзадәне олылап, ихтирам итеп, атыннан төшеп сөйде. Егет сугыш киемнәрен салды. Шаһ күрде ки: айның үндүртенче кичедәй бер егет, озын чәчле, күргәннең күзе камашыр. Йәмән шаһы сорады:

---

[1] Шәкел — форма

— Әй егет! Ни мәгънәдән чәчеңне яшергән идең һәм ни максат күздә тоттың?— диде. Шаһзадә әйтте:

— Әй падишаһ! Мин фарсы падишаһының углы идем, хикәятем бу-дыр,— дип, җәлеп итәрлек хәлләрне туры сүз белән бәян итте. Шаһ, ишеткәч, шатланды — күңеле булды. Әйтте:

— Без Йәмән дәүләтен Фарсы дәүләтенең рөхсәте, хуплавы белән идарә итеп килдек, хәзер дә аларның фәрманы белән хөкем итәбез. Без синең атаң хөкемендәбез,— диде. Шаһзадә бик шат булды, ихтирам күрсәтте, гафулар үтенде, дошман гаскәрен сындырып, шәһәргә кайт-тылар.

Шаһ боерды, шәһәрне бизәп, олылар җыелып, галимнәр һәм укы-мышлылар, әмирләр һәм кара халыкны чакырып, туй хәзерләп, Фәх-реннисаны никах итеп, шаһзадәнең янына куйдылар, аулак өйгә кергез-деләр. Алар исә бер-бере белән гашыйклык антын беркетеп, рәхәткә ирешеп, ике ел тыныч күңел, җайлы тормыш белән яшәделәр.

Бер көн шаһзадә Йәмән падишаһына үтенеч белдерде, әйтте:

— Озак вакытлар инде ата-анамнан аерылганыма. Аларның күңелләре миндәдер. Мин дә аларны күрергә, йөзләре каршында булу шәрәфенә ирешергә телим,— диде. Йәмән шаһы әйтте:

— Рас әйтәсең, гәрчә миңа синсез сабырлык-тынычлык булмаса да, сораганыңны кире какмам, ата-анаңның да күрәсе килгәндер,— диде. Аннан боерды, юл кирәк-ярагын хәстәрләделәр, чиктән тыш бүләкләр, әсбап-кораллар хәзерләп, Фәхреннисаны шаһзадә белән юлга озаттылар.

Шаһзадә үз юлында булды. Фарсы җиренә җиткәч, фарсы мәли-генә шатлык хәбәре иреште, барча олы һәм кече, дәүләт тәрәге түрә-ләр һәм мәмләкәтнең байлары гаскәр белән каршы алырга чыкты. Шәһәрне зиннәтләп, күңел ачулар һәм тамашалар кылдырып, туйлар ясап, шәһәргә кергезде. Аннан шаһ падишаһлыгын углына тапшырды, үзе гайбадәтханәгә кереп, Хак гыйбадәтенә йөз куйды.

Шаһзадә, падишаһлыкны кулына алып, гадел хөкем ишеген ачты, халыкка яхшы мөгамәлә күрсәтте. Утыз ел өзлексез падишаһлыкта утырды. Фәхреннисадан угланнары булды. Күп еллар падишаһлык ул нәселдән өзелмәде.

*Ахыры киләсе санда*

*Абдулла Алишның тууына 80 ел*

# ТУГРЫЛЫК

### А. АЛИШНЫҢ ТОТКЫНЛЫКТАГЫ ИҖАТЫ ТУРЫНДА

Аның илгә кайтып ирешкән унбишләп шигыре күптәннән билгеле. 50 нче еллар ахырыннан бирле алар әледән-әле басылып киләләр, кайбер җыентыкларга да кертеләләр.

Әмма Абдулла Алиш тоткынлыкта иҗат иткән шигырьләрнең болар белән генә чикләнмәве дә мәгълүм. Берлин төрмәсендә язган соңгы хатында бу турыда ул үзе дә әйтеп китә: «Бик күп уйланылган һәм язылган әсәрләр безнең белән мәңгелеккә китәләр...»

Шулай да әсирлектә булган кайбер кешеләр ятлап кайткан шигырьләр һәм истәлекләр аның тоткынлыктагы иҗатын тулырак күзалларга мөмкинлек бирә. Шулар арасында Алиш белән бергә Польшадагы Седльце лагеренда булган Газыйм Кадыйров истәлекләре һәм ул тапшырган шигырьләр аерым әһәмияткә ия. Матбугатта чыккан истәлекләрен укып, үзе белән күрешеп сөйләшкәч тә, бернича ел буена хат язышып, мин Газыйм абыйдан күп кенә өстәмә мәгълүматлар алдым. Ул Абдулла Алишның 50 еллыгына Казанга да килгән иде, БАССРның Туймазы шәһәрендә яшәп, 1972 елда вафат булды...

Седльце концлагере. 1942 елның җәе. Шушы үлем лагеренда меңләгән әсирләр арасында очрашып дуслашканнар алар, кайгы-сагышларын, уй-кичерешләрен бергә уртаклашканнар. Авыру һәм хәлсез күренсә дә, Алиш абый күп нәрсәдән хәбәрдар була, күмәкләп качу турында уйлана. Күңелләрдә өмет чаткысы уятырлык листовкалар да, шигырьләр дә укый ул иптәшләренә. Сөйләгән сүзләре алдагы көннәргә һәм җиңүгә ышанычны арттыра.

— Бервакыт ул лагерьда тәрҗемәче булып торуын әйтте. Радио аша сугыш хәлләре белән танышып баруын, хәзер фронт кайсы тирәләрдә көчлерәк булуын сөйли иде,— ди истәлекләрендә Газыйм абый.— Юату сүзләре әйтеп, күңелне күтәрә белә: «Хәзер иң мөһиме — нык булу, дошман алдында йомшаклык күрсәтмәү. Безнең урамда да бәйрәм булыр әле,» дип куя иде.

Лагерьга төрле кешеләр килә. Немецлар ягыннан килеп котырту, өндәү алып баручылар да була. Алиш аларны кискен рәвештә гаепли, «калҗа көтүчеләр» дип атый, алар турында нәфрәтләнеп сөйли иде.

Алиш абыйның капчыгында ике-өч блокноты булуын искә алды Газыйм абый. Алиш әсирләргә үзенең шигырьләрен укый, кайберәүләр аларны хәтердә калдыралар, кәгазь кисәге тапканнары күчереп тә алгалыйлар. Газыйм Кадыйров та Алиш шигырьләрен дәфтәренә күчереп алып ятлаган. «...Седльцеда мин аның шактый әйберләрен күчердем,— дип язды ул соңыннан.— Алар арасында шигырьләр генә түгел, әкият һәм башка язмалар да бар иде. «Сагынам илемне», «Ул төшне мин кабат күрерменме?», «Иркәм хаты», «Газиз анам» һәм башка шигырьләре белән бергә, «Сандугач» дигән нәсерен, «Керпе белән елан» исемле әкиятен дә күчергән идем. Бу әкиятнең эчтәлеге болай истә калган: елан керпене өйдәш итеп, үз янына кертә. Баштарак алар икесе бер өйдә ярыйсы гына тату яшиләр. Тора-бара керпе, еланга якынрак сырышып, энәләре белән аны чәнечкәли башлый, тиресен тишкәләп бетерә. Ахырда елан үз өен ташлап чыгарга мәҗбүр була.

Алиш абый миңа үзенең дәфтәрләрен бик теләп бирә иде. Шигырьләрне күчергәч тә тиз ятлап алуыма сөенә:

— Андый сәләтең булу бик яхшы. Илгә исән-сау кайтсаң, Казанга барып, тормыш иптәшемә, энигә, туганнарыма, дусларыма укырсың,— ди иде.

— Әй Алиш абый, белмим шул, кайсыларыбыз кайтыр да, кайсыларыбыз юлда бүленеп калыр,— дигәч, ул:

— Шулай шул, юллар озын, вакыт тиз инде. Өметне өзмик. Безнең урамда да бәйрәм булыр әле,— дип юата башлый.»

Шушы урында Абдулла Алишның «Өметем зур минем киләчәккә» дигән шигырен китереп үтсәк, әле легионга хәтле үк, аның нинди уйлар, кичерешләр белән януын тулырак аңларбыз:

*Өметем зур минем киләчәккә,*
*Җиңмәк булам тормыш агымын.*
*Ләкин дөнья көтә кич кунарга,*
*Алдан биреп үлем агуын.*

*Язмыш миңа усал караса да,*
*Бирешмәскә телим аңарга.*
*Яфраксыман үзем саргаймыймын,*
*Тик чәчләрем генә агара.*

*Агым иркенә имәм башымны,*
*Көчле колачларны салырмын.*
*Халкым өчен әгәр кирәк булса,*
*Агымга да каршы барырмын!*

Кинаяләп сөйләү остасы Абдулла Алишның «Керпе белән елан» әкияте кебек, бу шигырь дә төп фикерне укучыларына төгәл җиткерә. «Халкым өчен әгәр кирәк булса, агымга да каршы барырмын!» Бу сүзләр аның нинди язмышны сайлавын ачык аңлата булса кирәк. Германиядәге каршылык хәрәкәтенә, пролетар интернационализм көченә чын күңелдән ышанып, 30 нчы еллар башында ук антифашистик әсәрләр язган Алиш иң авыр шартларда үзе дә шул көрәшчеләр сафына басарга дигән ныклы бер фикергә килгән! Газыйм Кадыйров әйткәнчә, баштарак немецлар ягына чыгучыларны нәфрәтләнеп гаепләгән Алишның «кинәт» легионга язылуын, һәм, ниһаять, «Идел-Урал» газетасы редакциясендә эшләргә ризалык бирүен бары шулай аңлату гына дөрес булыр...

Инде соңрак (Берлинда) иҗат ителгән «Кайбер сызмалар» дип исемләнгән бер шигырендә Алиш «Идел-Урал» комитетына оялаган фашист ялчыларына тырышып хезмәт итүче «кайберәүләр»не күздә тотып, ачынып яза:

*Язмыш җиле мине, яфрак кебек,*
*Кыш иленнән сөйрәп китерде.*
*Европаның урта бер җирендә*
*Үзенең ачы суын эчерде.*

*Тормыш тәҗрибәсен аз күргәнмен,*
*Белмәгәнмен бик күп эшләрне.*
*Күзләрем дә ачык күрә алмаган,*
*Танымаган кайбер кешеләрне...*

Абдулла Алиш шигырьләрне аз язмаган. Һәм алар әсирләр арасында шактый таралган булса кирәк. «Очрашу» шигыренә эпиграф урынында Алиш бу хакта үзе дә язып куйган: «Әсирләр лагеренда бер иптәшем белән фаҗигале очрашуга карата язылган бу шигырьне күп әсирләр үзләренең дәфтәрләренә күчереп алганнар иде».

Язучының тууына 70 ел тулган көннәрдә Стәрлетамактан җибәргән бер хатында инде мәрхүм Тәлгать Гыйммранов үзендә сакланган шигырьләрнең күбесе Алишныкы булуы турында язган иде. Соңрак, бу дәфтәрдәге шигырьләрне укыганда, мин аларның күбесен бөтен кичерешләре белән Алишныкы дип кабул иттем. Газыйм Кадыйров Седльцеда ук күчергән «Иркәм хаты» шигыренең шунда ук булуы, бала чактан ук күңеленә кергән ямьле Идел буйларын, кадерле анасын сагыну хисләре чагылган шигырьләр эчтәлеге белән дә Алишныкы икәнлеген искәртеп торалар шикелле.

Рафаэль Мостафин да әле авторы билгеле булмаган кайбер шигырьләрнең һәм «Идел-Урал» газетасының сакланып калган саннарында табылган берничә шигырьнең Алишныкы булу ихтималын күрсәтә. «Галиша» имзасы белән басылганнарын шик астына алырга да кирәкми, минемчә. Билгеле булганча, Алишев фамилиясе тугыз бабадан торган нәсел шәҗәрәсендәге Галишаһ (Галиша) исеменнән ясалган...

Җәлил, Алишлар белән бергә Берлиндагы Тегель төрмәсендә утырган Михаил Иванович Иконниковның сөйләвенә караганда, Абдулла Алиш шигырьләре төрмәдәге тоткыннар арасында да таралган, укылган һәм ятланган. «Очкычка карап» дигән шигырен Алиш кайчан язган булгандыр, анысын белмим, әмма аның берничә куплетын капитан Русанов укыганы хәтеремдә. Ул аны төрмәдә утыручы тоткын татарлардан алганын әйтте,— дип сөйли Михаил Иванович.— 1944 нче елда Берлин өстендә союзникларның самолетлары еш күренә башлады. Һава һөҗүмнәре вакытында тоткыннарга үзара аралашырга, иркенрәк сөйләшергә мөмкинлек туа иде. Берлин өстендә очкан самолетлар тоткын күңелендә төрле хисләр, өмет уята иде. Алиш моны шигырендә бик дөрес чагылдырган. Шуңадыр, бу шигырь тоткыннар арасында тиз таралып укылды һәм ятланды:

*...Ал син, очкыч, мине үзең белән,*
*Бомбаларың калдыр бүгенгә.*
*Бомба итеп, илтеп ташла мине*
*Еракtагы торган илемә.*

*Йолдыз кебек атылып төшим әле*
*Туфрагында кабер табарга.*
*Дошманнарга булган көчле нәфрәт*
*Хисе белән мәңге янарга.*

*Юк, кирәкми, үлмим, табыш булып*
*Кайтып керим туган илемә.*
*Багышлансын калган гомерем дә*
*Иң кирәкле булган җиренә.*

Тагын шунысы хәтердә,— ди М. И. Иконников.— төрмә тәрәзәсе тимерләренә тотынган хәлдә, Алиш «Һәлак булган улыннан әнисенә хат» һәм «Җавап» дигән шигырь укыды. Ул аны шулкадәр тәэсирле итеп, тирән кичерешләр белән сөйләде, без дулкынланудан бер мәлгә тынып калдык, сөекле әниләребезне күз алдына китердек. Бу шигырьнең кемнеке икәнлеген тәгаен генә белмим, әмма ул үзенең эчтәлеге белән Алишның әнисенә багышлап язган «Көтмә инде, көтмә» исемле шигыренә бик якын. Башта ул аны үзенең дусларына татарча сөйләде, ә берничә көннән соң, капитан Русановның соравы буенча, рус телендә дә укыды. Аны русчага Әхмәт Симаев тәрҗемә иткән иде...»

Абдулла Алиш шигырьләрендә Туган илгә чиксез мәхәббәт, аны сагыну, Ватанга һәм халыкка тугрылык идеяләре чагыла һәм алар бу яктан Муса Җәлил шигырьләре белән авազдаш яңгырый. «...Алиш каләме белән язылган бу юллар да Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»ндәге шикелле нык ихтыяр көче, күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтә алырдай патриотик хис белән сугарылган»,— дип яза Рафаэль Мостафин «Өзелгән җыр эзеннән» исемле китабында, Абдулла Алишның «Үзем турында җыр» дигән шигырен мисалга китереп.

Шунысы да билгеле: Алиш туган илгә юллаган блокнотына үз шигырьләренең кайберләрен генә язган, шушы кечкенә генә дәфтәрчекнең калган битләренә Муса Җәлилнең дә 15 шигырен сыйдырган. Бу факт Абдулла Алишның каләмдәш һәм фикердәш дусты Муса Җәлил турында кайгыртучанлык күрсәтүенең бер мисалы буларак та әһәмиятле. Ул, Муса Җәлилнең иҗатын югары бәяләп, ничек тә аны саклап калырга тырышкан. Кайбер мәгълүматлардан күренгәнчә, ул әле кулга алулар башланганчы ук саклану чараларын күргән, һич булмаса Муса Җәлилне коткару турында кайгырткан. Ахыр килеп, инде төрмәдә утырганда да бу хакта күп уйлаган. Шуңа игътибар итеп, Р. Мостафин болай яза: «Әсирләрнең әйтүләренә караганда, Алиш Шәфи Алмаска да хат язган. Хатның эчтәлеге якынча болайрак булган: «Мин үзем өчен берни дә сорамыйм, тик бер нәрсәне генә үтенәм: Мусаны коткарыгыз. Ул бөтен татар халкына кирәк.»

Җәлилнең Алишка багышлап язылган «Дуска» шигыре менә шушы кайгыртучанлыкка җавап булып яңгырый. Андагы: «Мин теләмим андый исәнлекне...» дигән сүзләрдән дә шул фикер аңлашылып тора бит. «Дуска» шигырендә М. Җәлил һәр икесе өчен дә бу үлемнең Ватан алдында тугрылык билгесе булачагын әйткән...

Абдулла Алишның үз шигырьләрен, язмаларын укып уйланганда да безнең күз алдына Ватаны һәм халкы өчен үлемне дә батырларча каршыларга әзер булган көчле рухлы кеше килеп баса:

*...Ни булса да горур үлем бит ул*
*Европаның урта өлешендә.*
*Мондый үлем — бәхет. Теләсә дә,*
*Тими әле бик күп кешегә,—*

дип язган ул «Ничек килер үлем?» шигырендә.

«Үзем турында җыр» шигыренең һәр юлы шундый рух белән сугарылган:

*Сатмас илен алтын-көмешләргә,*
*Әгәр югалтмаса вөҗданын.*
*Алтынны ул чүпкә санар,*
*Иң кыйммәтле күрер ватанын.*

Берлин төрмәсендә язган хатындагы: «Без соңгы сулышыбызга кадәр халкыбызга турылыклы булып калабыз»,— дигән сүзләр үзләре генә дә ни тора!

Ниһаять, сугыштан соң шушы хатны Советлар Союзына җибәргән кеше — Алиш белән бер камерада утырган Бельгия коммунисты Эмиль Майзон хатын игътибар белән укысак, шуны ачык күз алдына китерә алабыз: фашист төрмәсенең салкын камераларында интеккәндә дә, Абдулла Алиш сөекле Ватанын уйлап юанган, белгән кадәр сүзләрен кулланып, чит ил кешесенә туган иленең гүзәллеге, андагы бәхетле тормыш турында сөйләгән. Алишның тормыш иптәше Рокия апага язган бу хатында Эмиль Майзон дустын сагынып һәм бик җылы хисләр белән искә ала:

«...Төрмәдә булуга карамастан, мин аның белән күңелдә ягымлы-яхшы тәэсир калдырган көннәр үткәрдем. Аңлашу ягыннан бик үк җиңел булмаган әңгәмәләребездә ул Россия турында, гаиләсе турында сөйли иде.

Мин сезнең иргезнең якты истәлеген һәрвакыт күңелемдә саклармын. Һәм үземдә булган соңгы истәлек әйберне сезгә җибәрәм. Бу — кечкенә генә конверт (пакет). Миннән аерылгач, Берлиндагы Шпандау төрмәсендә үлем җәзасы көткән көннәрендә, шуңа салып, ул миңа сигаретлар бирдерә иде...»

Кеше хәленә керә белү, башкалар турында кайгырту — Алиш характерының иң

күркәм сыйфатларыннан берсе — тоткынлыкта аеруча ачык чагылган. Көрәштәш дусты Рәхим Саттар Берлиннан китәр алдыннан, ул, аның шигырьләрен үзенә алып калып, ышанычлы кулларга тапшырган. Билгеле булганча, бу шигырьләр туган илгә кайтып ирештеләр һәм аерым китап булып басылып чыктылар.

Ә үз шигырьләренә Абдулла Алиш ничек караган? Шул кечкенә блокнотына кайберләрен сайлап язу белән генә чикләнгәнме? Әллә барысын бергә туплап, ышанычлы кешеләргә биргәнме, әсирләрнең хәтерендә я дәфтәрләрендә кайтып җитәрләр дип уйлаганмы? Ни генә булмасын — ул шигырьләренең бер өлеше генә булса да кайтып ирешүен теләгән, алар аша үзенең вөҗданы сафлыгын, иленә һәм халкына, якыннарына булган эчкерсез хисләрен, тугрылыгын белдерергә өметләнгән. Нигъмәт Терегулов күчергән дәфтәрендә иң соңгы сүзләр итеп, шул теләген язып куйган: «Әгәр шушы дәфтәр туган илгә исән-сау кайтып җитсә, мин бәхетле. Миңа башка берни кирәкми. Мескен анам, сөйгән иркәм бу язмаларны укысалар, дуслар аларның кайберләрен матбугатка чыгарсалар...»

Абдулла Алишның бу теләге үтәлде: шигырьләренең кайберләре әледән-әле басылып тора. Инде шуларга өстәп, озак еллар буе архивта яткан тагын берничә шигырьне өстисе килә. Алар яңа табылган яисә ачыкланмый яткан әйберләр дә түгел. Күптәннән билгеле шигырьләр һәм, бәхәссез, Алишныкылар. 1968 елда ук мин аларны Татарстан Язучылар союзы архивыннан күчереп алган идем. Тик әлегә хәтле матбугатта чыкканнары юк. Рафаэль Мостафинга рәхмәт: Алиш шигырьләрен рус теленә тәрҗемә иттереп, 1978 елда «Три поэта-воина» дигән җыентыкка кертте.

Бу шигырьләрне укучы хөкеменә тәкъдим иткәндә, шуны искәртеп үтү урынлы булыр кебек: ятлап хәтердә саклап кайтканга, аларның кайберләрендә ритм-рифма төгәлсезлекләре сизелер, кайсыларында аерым сүзләрнең алмаштырылган булуы да ихтимал. «Иркәм хаты» дигән шигырь, мәсәлән, Тәлгать Гыйммранов һәм Газыйм Кадыйров дәфтәрләренең һәрберендә бераз үзгәрәк. «Мин аны Седльце лагеренда ук күчереп алган идем»,— дип язды бер хатында Газыйм абый. Ул, Алиш шигырьләрен кат-кат күчереп, оригиналдагыча сакларга тырышкан. Төрле лагерьларда булганда, ул дәфтәрләрне кайларда гына яшереп сакламаган, әмма, кызганычка каршы, аларны алып кайтып җиткерә алмаган. Тугай илгә аяк басу белән, ул шигырьләрне хәтерендә яңартып, тагын дәфтәренә язып куйган. «Акчарлак», «Газиз анам», «Ялгыз каен» кебек онытылган кайбер шигырьләрдән калганнарын, Алишның үзендәгечә язып, Татарстан Язучылар союзына тапшырган. Аларның бер өлеше, шул исәптән «Үзем турында җыр» һәм башка шигырьләр «Совет әдәбияты» журналының 1956 елгы 6 нчы санында басылып чыктылар. Һәм менә журналның бу санында тагын берничә шигырь укучыларга тәкъдим ителә. Абдулла Алишның 1957 елда басылып чыккан «Сайланма әсәрләр»енә кереш мәкаләсендә Гази ага Кашшаф бу шигырьләр турында болай язган иде: «...Ул шигырьләр татар совет язучысының эчке дөньясын, рухи байлыгын, намус сафлыгын чагылдыралар. Дөрес, бу шигырьләрнең кайбер строфаларын Газыйм инде онытткан, кайбер шигырьләр исә бик үк эшләнеп тә бетмәгән. Шуның өстенә — иска төшереп язганда була торган хәл — кайбер шигырьләргә строфалар икенчесеннән килеп кергән кебек тә тоела. Әле боларны, билгеле, өйрәнәсе бар. Ләкин аларда совет кешесенең йөрәк тибеше бирелгән; аларда туган илгә булган сагышлы хис бар, алдагы көннең бәхетенә ышаныч бар...»

**Илсөяр СУНКИШЕВА**

# Абдулла Алиш

## Сагынам илемне

Сагынам илемне, нечкә билемне,
Яшь вакыт йөзгән зәңгәр күлемне.
Сагынам кич-иртә, онытмыйм һич тә,
Чөнки мин сөям: әйтмимен тиккә.
Сагынам җәйләрен, шул матур айларын,
Майлы коймаклы сабан туйларын.
Сагынам урманын, чишмә буйларын,
Иртә һәм кичтә кошлар җырлавын.
Нигә бу кадәр сөям илемне?
Җырыңа күмеп тибрәттең мине.
Үстерде илем батыр ир итеп,
Очырды яуга җитез җил итеп.
Барырмын таптап дошман тупларын,
Куркып чигенмәм зәһәр утлардан...

## Иркәм хаты

Күп вакыттан бирле сине сагынып,
Татлы уйлар уйлыйм ялгызым.
Бер минут та истән чыгармыйча
Көтәм сине, якты йолдызым.

Йокы арамда сине күргән булып,
Шатлыкларга чумып юанам.
Тәмле төшне озатып күзем ачсам,
Син булмыйсың, ялгыз уйланам.

Хәтерлим мин, иркәм, бүгенгедәй,
Хәтерлим мин хәзер барын да:
Синең белән тәүге очрашуны
Тар басмада, күпер каршында.

Шул су буйлап үскән яшел камыш
Шаулый җәйге җилләр искәндә.
Сине сагынып, ялгыз елап үтәм,
Тар басмалар аша кичкәндә.

Син бит миңа элек әйтә идең:
Теләгеңне таңда телә, дип,
Таңгы су юлында теләгән теләк
Һәрвакытта кабул була дип...

Югалттым мин сине, сөекле иркәм,
Гыйшыгыбыз чәчәк атканда,
Улларымның шомырт кара күзе
Беренче кат безгә бакканда.

Килми хәзер хәбәр-хатларың да,
Адресатың әллә күчтеме?
Канлы окопларның итәгенә
Салдың мәллә булган көчеңне?

Көннәремдә сине уйлап йөрим,
Төннәрем дә истән чыкмыйсың.
Кая киттең Идел буйларыннан?
Хыялымда гына яшисең.

Кайчан атар икән кавышу таңы?
Әллә шулай мәңге-гомергә,
Кара болыт булып, хәсрәт гизәр
Гомеремнең моңсу күгендә?

## Тормыш дустыма

Сез табынны тутырып утыргач та,
Бер урын буш калгач түрендә,
Ул үлгән дип сугыш кырларында,
Яшьләр тулган булыр күзеңдә.

Күбенә түзгән кебек, азына да
Борчылмачы, дустым, түз инде.
Без кайтырбыз җиңеп дошманнарны,
Юллар озын, вакыт тиз инде.

Озатып калдың мине, киткән чакта
Кайнар яшең тамды кулыма:
— Хуш, исән бул, ак бәхетләр телим
Көрәшләрдә барыр юлыңа.

## Кыр казлары

Бүген иртән күрдем: кыр казлары
Көнчыгышка табан киттеләр.
Канат җилпи-җилпи кыйгылдашып,
Тигез сафка тезелеп үттеләр.

Юллар озын сезнең, кыр казлары,
Урал таулары аша чыгарсыз.
Канатыгыз юлда тузанланса,
Агыйделгә төшеп юарсыз.

Әйтер идем, әгәр телен белсәм,
Әманәтем алып кит, диеп.
Туган авылым аша юллар тотсаң,
Сөйгәнемә сәлам әйт, диеп.

*

Төн. Бүлмәдә тыныч кына утырам ялгыз,
Күк йөзендә минем кебек ялгыз йолдыз.

Ул сүнмәде таң атканчы, Чулпан микәнни?
Көтте ашыгып алсу Кояш кайтып җиткәнне.

Һәркөнне ул таң атканчы тора постында,
Тапшыра җаваплы эшне Кояш дустына.

Әйт син, Чулпан, серле йолдыз, ничек армыйсың?
Күп йөзләгән еллар кичеп сүнеп калмыйсың?

Күр син мине, әгәр кичтән йокым туймаса,
Җуямын исәнлегемне, күзем кан баса...

Әйтегезче, иң бәхетле кем соң дөньяда?
Нигә мин дә йолдыз түгел, я гөнаһсыз яшь бала?

Син биектә, син иректә, иң бәхетле син генә.
Күк йөзендә урын булса, ал янына мине дә...

Тәүбә-тәүбә, тәүбә итәм, менмимен мин биеккә,
Бар теләгем: сөйгән халкым булсын иде иректә!

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

*Бәхәс дәвам итә: «Заман һәм шигырь»*

**Фәрит Бәширов**

## ШИГЪРИЯТ ЯЗМЫШЫ — ХАЛЫК ЯЗМЫШЫ...

Татар халык шагыйре Сибгат Хәкимнең 1979 елда «Халык язмышы — шагыйрь язмышы» дигән китабы басылып чыкты. Халкыбыз җанына, язмышына аерылгысыз береккән шагыйрьнең китап исеме итеп куелган гаять тирән мәгънәгә ия бу сүзләре кайта-кайта уйландыра. Шагыйрьгә ияреп, «шигърият язмышы да — халык язмышы» диясе килә.

Журналда башланып киткән бәхәс күп кенә борчулы җаннарны шигырьләребез, шагыйрьләребез турында уйландырып, каләм алырга мәҗбүр итте. Бу сөйләшү күптәннән өлгереп килә иде инде. Поэзия еллар буе биктә торып, үзенең пәрәвезләр белән чорналып беткән чоланнарын ачып җиләтүгә, кояш нурында сафландыруга мохтаҗ иде. Сөйләшергә чакыру гына кирәк булган икән — уяндык. Чөнки бәхәстә телгә алынганча, «буалар ерылган вакыт». Һәм шунысы мөһим: бүгенге сүз бүген әйтелергә тиеш. Иртәгә калдырып, сусыл вакытында өзмичә тәмен югалткан җиләк кебек кирәксезгә, аны кат-кат тәкрарлаудан ни мәгънә?

Р. Мостафин белән В. Нуруллин әңгәмәсе башлыча китап язмышына, шагыйрьләрне иң сызландырган мәсьәләгә кагылды. Китап язмышы ул шагыйрь язмышы да, ахыр чиктә шигъриятнең киләчәге дә. М. Вәлиев исә «Учагың сүрелмиме?», «Шигъри бушлык» мәкаләләре белән шагыйрьләр исеме артында мәш килүче соры шигырьчеләр төркеменең кәсепчелек пәрдәсен йолкып алып, аларны «каравыл» кычкырырга мәҗбүр итте. Бәхәс әнә шул рәвешле кискен, шигырьчеләргә карата мәрхәмәтсез, компромиссыз башланып китте.

Турысын әйтим, Р. Мостафин һәм В. Нуруллин әңгәмәсе каршылыклы фикерләр уятты. «Шагыйрь һәм китап» дигән проблеманың шактый четерекле, укучыга мәгълүм булмаган якларын ачыктан-ачык сөйләшүгә кую, китап тирәсендә очраштыргалый торган әшнәлек күренешләрен ачып бирү һәрьяктан хуплауга лаек. Ләкин китапка товар күзлегеннән бәя биргәндә бәхәсләшерлек, риза булмаслык моментлар да бар. Сер түгел, шигырь китабының бүген таралу һәм сатылу дәрәҗәсе тынычланырга ирек бирми. Моның сәбәпләре әңгәмәдә шактый тәфсилле ачыла. Ә менә шул хәлдән ничек чыгу, нинди чаралар кирәклеге турында сүз барганда конкрет тәкъдимнәр ясалмый, күбрәк ахыр нәтиҗәсе булмаган томанлы чишелешләр атала. Анык каравы, китапка тотылган чыгым турында сөйләгәндә әңгәмә җанланып китә. Бу очракта инде конкрет мисаллар да, төгәл саннар да сибелә генә. Шуңа күрә, сөйләшүнең аерым урыннары колхоз бухгалтерының исәп-хисап дәфтәрен хәтерләтә. Р. Мостафин хаклы: китап беренче чиратта, идеология, рухи байлык. Әгәр дә без «керем» дигән төшенчәне промышленность предприятиеләренә дә, себерке ясаучы кооперативка да һәм шул исәптән к и т а п к а да күчерсәк, киләчәккә шигырь укып түгел, ә акчасы кыштырдавына гына сөенеп узып баручы юлаучыларны юлдаш итеп алмабызмы? Үзфинанслау шартларында нәшрият күпмедер югалтадыр да, әмма ул «бөлгенлекне» экономиканың башка өлкәләре хисабына каплап булмыймыни? Илебездә төрле тармаклардан килгән файданың күп өлеше нәкъ менә культура-тәрбия, сәламәтлекне саклау, аң-белем тарату чаралары өчен тотыла да бит инде. Рухи матурлык, сәламәт аң, гражданлык сыйфатлары тәрбияләүче Китапны шулар рәтенә кертергә мөмкин

түгелмени? Әлбәттә, монда үзәкләштерелгән хәл итүләр, мәсьәләнең иң югары урыннарда каралуы кирәк. Бу бик җитди эш, аны уңай хәл итүнең төрле юлларын эзләргә, табарга кирәк.

«Шагыйрь һәм укучы» берлеге дигәндә иң әүвәл шигырьләрнең сыйфаты беренче урында торырга тиеш. Бармы соң бездә Шагыйрь исеменә лаек ир-егетләр? Бар! Ә шигырьчеләр, урта кул такмакчылар? Һәй, болары сөбханалла гына... Хәер, поэзия бер заманда да андыйларга кытлык кичермәде. Бүген алар күбрәк үзләренең зар елап йөрүләре, нәшрият тирәсендә хәл кадәренчә нагъра орып маташулары, йолкып ташласаң да тырышып-тырмашып тамыр җибәрергә азапланган алабутадай әрсезлекләре белән билгелеләр. Бүгенге тәнкыйть кыюланып принципиаль рәвештә аларны камчылый башлагач, бу соры массаның шактый ук зур булуы да ачылды. Сәбәпләренә аптырап торганда, тагын журналда дәвам итүче бәхәс ярдәмгә килде.

Бүген илебездә үзгәртеп кору бара, ул әдәбият торышына да кагыла. Кагылырга тиеш! Бүген шагыйрьләр дә, шигырьләр дә, тәнкыйть тә сынау уза. Яшерен-батырын түгел, инде салмак кына классиклар баскычына күчеп баручы язучылар да, төрле дәрәҗәдәге титулларга ирешкән каләм ияләре дә бүгенге таләпләр алдында имтихан тоталар. Хәтта, Г. Тукай исемендәге премиягә лаек булган шагыйрьләр дә сынау узалар. Киләчәккә уза алырлармы алар? Тәнкыйтьтә түгел, академик басмаларда түгел, ә халык җанында, аның бәгырендә? Тукайлар, Туфаннар кебек, Такташлар, Җәлилләр шикелле! Моңа кадәр сынауның иң «сыналган» формасы Вакыт булды. М. Әгъләмов сүзләре белән әйткәндә: «Тимерченең авыр чүкечедәй килеп төшә Вакыт — яньчә генә...»

Ләкин мәсьәләнең парадоксы да шунда, Вакыт хөкеменә генә ышану шигырьчекәсепчеләр өчен бик кулай булып чыга. Китаплары бер-бер артлы басыла, төче рецензияләр яздырып алалар һәм... төкерәләр синең киләчәгеңә. Аларга бүген рәхәттә яшәү кыйммәт, ә иртәгә — күз күрер әле... Бу очракта инде тәнкыйтьнең оператив, сугышчан булуы зарур. Тәнкыйть язучылар каршында төшкән абруен күтәрергә тиеш! Бүген бәхәс шуны күрсәтә. Шөкер, усал итеп, дәлилле фикерләр белән маңгайга бәреп әйтүчеләр кузгалдылар. Чын шигырьне ясалмадан, ялганнан аерып бирү — поэзиянең язмышы өчен борчылган һәр тәнкыйтьченең, галимнең, шагыйрьнең һәм һәр укучының намус эше. Шигырьнең киләчәге өчен кирәк бу. Әдәбиятыбыз иҗат чисталыгы, сафлыгы өчен көрәшкән, талантлы язучыларны үз вакытында ук күреп, күтәреп алып, әсәрләренә төпле, сүз тәменең бөтен нечкәлеген тоеп бәя биргән фидакарьләргә беркайчан да мохтаҗ булмады. Бу җәһәттән, эшем буенча үземә якын булган XX йөз башы татар әдәбиятына тукталасым килә.

1905 елгы революциядән соң әдәбиятта ташкын булып поэзия күтәрелә. Газета-журнал битләрендә шигырьләр күпләп басылалар. Аерым китап булып чыкканнарының да саны өзлексез үсә. Укучы яңадан-яңа исемнәр белән таныша тора. Саный китсәң, берничә йөз фамилияне атарга булыр иде. Ләкин Вакыт бүгенге көн укучысына аларның берничәсен генә китереп җиткерде: Тукай, Дәрдмәнд, Рәмиев, Бабич, Гафури, Думави...

Г. Ибраһимов үз вакытында ук талантларга гаять сизгер тоемы белән чын Шагыйрьләрне күрә һәм аларның иҗатына бәя бирә алды. Мин беренче чиратта аның «Татар шагыйрьләре» (1913) дигән хезмәтен күздә тотам. Әсәрнең язылуына инде 75 ел, ләкин хәзер дә әле ул үзенең тәнкыйди кыйммәтен югалтмаган, бүген дә аның турында бәхәсләр кимеми. Каршылыклы фикерләр дә әйтелә, Ибраһимов белән бәхәскә дә керәләр, аерым моментларын инкарь итәләр, яки киресенчә, хуплыйлар. Ләкин бер нәрсә бәхәссез, әсәр чын мәгънәсендә тәнкыйтьнең эчке сутын тоемлап язылган. Әдипнең Дәрдмәнд, С. Рәмиев турындагы фикерләре безне торган саен сокландыралар. Ләкин, поэзиядә романтиклыкны төп принцип итеп алган Г. Ибраһимов Тукайның реалистик шигъриятен кабул итә алмады. Тукай ул безнең бәгырь. Без Г. Ибраһимовның нәкъ менә безнең бәгырьгә кагылган аерым карашларын инкарь иттек. Ибраһимов үз вакытында Бабичның шигъриятенә дә югары бәя бирде, шагыйрь һәлак булгач та аның иҗатын барлау һәм халыкка җиткерү юлында зур көч куйды. Ә менә Тукайны — халыкның җаны, йөрәге, теле булган Тукайны ул танымады һәм бу фикерен гомеренең ахырына кадәр үзгәртмәде. Нишлисең...

Шуны гына ассызыклыйсы килә, шигърият һәм шагыйрьләр турында уйланулар-ның, кискен бәхәсләргә этәргән фикер йөртүләрнең бездә инде революциягә кадәр ук мәгълүм традициясе бар иде. 20-30 елларда тәнкыйтьчеләрнең яңа бер буыны үсеп чыкты. Барысына да тукталу мөмкин түгел, алай да ике исемне атап китмичә ра-мый. Болар — Г. Нигъмәти һәм Г. Гали. Г. Нигъмәтинең Такташ, Гафури, Дәрдмәнд иҗатларын тикшереп, поэтик талантларының үзенчәлеген ачып биргән һәм мәгълүм дәрәҗәдә аларның иҗат эволюциясенә кызыклы әдәби-эстетик анализ ясаган мәкала-хезмәтләре үз вакытында ук җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп иткән иде. Г. Гали

дә үзенең принципиальлеге һәм талантларга гаять сизгер булуы белән аерылып тора. Бер генә мисал: «Совет әдәбияты» журналының 1936 ел санында аның «Туфан иҗаты турында» дигән мәкаләсе басылып чыга. Авыр елларда — Х. Туфанга яла ягу, аны эзәрлекләү башланган бер чорда шагыйрь иҗатына тәнкыйть күзлегеннән карап (әлбәттә, кимчелекләрен дә күрсәтеп), аны Х. Вәли, С. Мортазин ише хәсрәт тәнкыйтьчеләрдән яклап мәкалә бастыру үзе үк гражданлык батырлыгы иде. Шәхес культы чорындагы башбаштаклыклар иң әүвәл әнә шундый фидакарьләрне әдәбияттан (бик күбесен тормыштан да) аерды. Моңа күбрәк тукталуымның сәбәбе шунда, без хәзер чаң каккан бик күп җитешсезлекләрнең, гарип күренешләрнең тамыры әнә шул фаҗигале елларда түгел микән? Иҗат мәйданы бит буш тормый! Поэзия ул табигать кебек, буш урыннарны яратмый. Иманнәре киселгән урманны куаклык баса. Чын талантларны иҗаттан аерганда анда башкалар — талантсыз, әмма ялагай, үтә ипле мәдхиячетакмакчылар, «лилипутлар» ябырыла. Хәзер инде ул чор саташулы ямьсез бер төш кенә булып күзаллана. Ләкин әле тарих булырга өлгермәгән ул заман төш кенә түгел. Ул елларның фаҗигаләрен дә, фәкыйрь шагыйрьләрен дә, пычрак мәкаләләрен дә, күпме акылларны харап иткән әләкләрен дә әдәбиятыбыз тарихыннан сызып ташлап булмый. Бүген алар безгә гыйбрәт өчен кирәк. Ул чорны без никадәр күбрәк белсәк, шул кадәр киләчәктә хаталардан хали булырбыз.

Университетта укыган еллардан бер мизгел истә калган. Безгә сугышка кадәрге татар поэзиясе турында лекция укыйлар. Шагыйрьләр атала, шигырьләрдән үрнәкләр китерелә. Ләкин хәтер тасмасына аларның берничәсе генә эләгеп кала алды. Такташ, Җәлил, Туфан поэзиясе күңелгә сеңеп калган, башка лекцияләр хәтер иләгеннән көнендә үк шыбырдап коелып беткәннәр. 30-40 еллар поэзиясеннән без бик фәкыйрь багаж белән «чыктык». Иң кызганычы, чынбарлыкта да бу шулай иде. «Заман һәм шигырь» проблемасы безгә әнә шуларны да тагын бер кат искәртә.

Әдәбият партиянең XX съездыннан соң гына иркен сулыш алды. Поэзиягә Туфан кайтты, дөнья шигъриятә трибунасына Җәлил күтәрелде. Дары исе сеңгән шинельләрен дә салырга өлгерми иҗат мәйданына ашкынган көчләрдән зур бер буын шагыйрьләр үсеп чыкты. 1936-1937 елгы репрессияләр һәм Бөек Ватан сугышындагы югалтулардан соң поэзия беренче күтәрелешен кичерде. Шагыйрьләр турында иркенләп сөйләшергә шундый мөмкинлекләр туды ки, хәтта әдәбиятта аларны буынлап өйрәнә башладылар. Без бүгенгә кадәр И. Юзеевлар буыны, Р. Фәйзуллиннар буыны дип укый-өйрәнеп киилдек. Хәзер уйланам: шагыйрьләр буынлап, калыпланган хәлдә иҗат итмиләр бит. Каләм иясе чын мәгънәсендә шагыйрь икән, аның кабатланмас дөньясы була, әдәбиятка ул үзенә генә хас яңалыклары, индивидуаль табышлары белән килә. Ә без аларны тырыша-тырмаша сафка тезеп, бер аяктан атлатырга маташабыз. Әлбәттә, болай өйрәнүнең бер үзенчәлеге бар, «буын» башына куелучылар иҗатына әдәби тәнкыйть тәфсилле анализ ясый (бу җәһәттән, И. Юзеев та, Р. Фәйзуллин да игътибар җитмәүдән зарланмаслардыр шәт), аннан соң башка шагыйрьләрнең фамилияләре генә диярлек санап кителә. Шул җөмләдән шигъриятә үз сүзен әйтергә килгәннәр тәнкыйть күзлегеннән читтә калып, акрын гына сүнәләр. Күләгәдә калган кәсепчеләр дә мыштым гына рифма калыплап яшәп яталар. Шагыйрьләр һәм шигырьчеләр арасында әнә шул рәвешле тигезлек билгесе куела. Шуңа күрә поэзия тәнкыйте бүген үзенең методикасын тамырдан үзгәртергә тиеш. Шагыйрьләр — шәхес, аларга мөстәкыйль якын килү кирәк. Г. Афзал, М. Әгъләмов, Зөлфәт, Х. Әюпов, Н. Акмалов, Р. Зәйдуллин, З. Мансуров — боларны бит һич кенә дә бутап булмый. Аларның үз иҗат дөньялары, шигъриятә үз урыннары, киң таралган термин белән әйткәндә «үз тавышлары» бар! Сөенеп, сокланып укый торган шагыйрьләребезгә күбрәк игътибар бирәсе, калыпларга этә-төртә кертеп күңелләрен рәнҗетмисе иде. Талантлы шагыйрь ни кадәрле рухи ныклыкка ия булмасын, барыбер игътибарга мохтаҗ. Саный китсәң күп түгел бит алар — бигрәк тә үзебезнең халык санына мөнәсәбәттә.

«Заман һәм шигырь» дискуссиясе бер яктан, поэзиягә кемнәр килә дигән мәсьәләне күтәрсә, икенче яктан, кайдан киләләр дигән сорауны бирергә мәҗбүр итә. Әйе, һәр заманның үз борчуы... Без еш кына җай чыккан саен дөньяда җиде миллион татар бар дип мактанырга яратабыз. Шул миллионнарга ничә шагыйрь туры килә икән дигән сораудан гына оялып качарга тырышабыз. Җиде миллионның күпмесе татар шигырен укый икән, аны аңлый алырлык дәрәҗәдә туган телне белә икән? — дигән сорау да җавапсыз кала. Рәсми статистика да моның белән шөгыльләнми. Аяныч, әмма чынбарлык күзгә карап кырыс рәвештә әйтә: Такташлар чоры узды. Элеккерәк чорда илебезнең төрле якларыннан килеп, татар поэзиясенең алтын баганаларын тәшкил иткән шагыйрьләрне генә барлап карыйк әле. Шигъриятебезне Тамбовтан чыккан Такташсыз, Оренбургтан күтәрелгән Җәлилсез, Куйбышев өлкәсеннән килгән Әнвәр Давыдовсыз, Казахстанда туып-үскән Нури Арслановсыз күз алдына китереп буламы соң? Бүгенге татар шагыйрьләренең килер географиясе исә автономия-

ле республикабыз кысаларына кереп бетте. Бары тик татар мәдәнияте өчен, гомер бакый бәрәкәтле булган Башкортстан җирендә генә әдәбиятыбызны баетучы чишмаләр, шөкер, челтериләр әле. Бу — әдәбиятыбызның бүгенге торышы һәм киләчәге өчен борчылган һәрбер кешене сызландыра торган хәл. Һәм ул котылгысыз рәвештә милли тел мәсьәләсенә килеп ялгана. С. Хәким радиодан ясаган бер чыгышында «мәктәбең булса — телең дә була» дигән иде. Татарстаннан читтә булган күп өлкә-республикаларда татар мәктәпләренең ябылуы әдәбиятка килүче никадәр чишмаләрне күмеп ташлады. Нәтиҗәдә, татар китабының таралыш географиясе дә бик нык тарайды. Торгынлык чорының ачы җимешләрен хәзер яшь чыкканчы, җаннар бөрешкәнче татырга туры килә. Безгә гел тукып килделәр, милли мәсьәләләр инде ахырынача, барыбызның күңеленә хуш килерлек дәрәҗәдә хәл ителде һәм аңа кире кайтырга җирлек калмады дип өйрәттеләр. Ләкин, сизә-күрә килдек, бу киндидер котылгысыз тарихи процесс түгел, ә башбаштаклык нәтиҗәсе, кемнәрнеңдер милли телгә искелек калдыгына караган кебек сәерсенеп һәм кырын күз атуыннан туган административ чаралар нәтиҗәсе иде. Студент елларында яшьлек кайнарлыгы белән шул хәлләргә әрнеп-сызланып сөйләүләр дә аз булмады. Әмма буыннар бик сыек булгандыр инде, үзара чәпчүдән уза алмадык. Хәер, инде хәзер демократия киңәйгән бер чорда, бу хакта тирәнрәк, мәртәбәлерәк, һәм күп тавышка сөйләргә мөмкинлекләр ачылгач та бик авыр кузгалабыз әле. Әнә, яшь шагыйрьләребездән Ркаил Зәйдуллин да — ә аны мы соң инде кыюсызлыкта гаепләргә?! — зур бәхәс куптарган мәкаләсендә («Татарстан яшьләре», 1988, 3 сан) «ашыкма, каләм, әнә, сиңа да кемдер бармак яный...» — дип, үзен-үзе тезгенли. Аның белән бәхәсләшкән кебек шул ук газетаның 15 санында Т. Миңнуллин «Кемнән куркабыз соң? Нидән куркабыз?» — дип кабаттан чакыру ташлый. Бу җәһәттән, Батулланың 50 яшьлек юбилее уңаеннан биргән интервьюсындагы бер җөмлә дә күңелгә сеңеп калган: «Безнең буын гел куркып яшәде, гел куркып язды, сез кыю булыгыз...» Кыю буласы иде дә бит... Ләкин куркабыз! Сүзне әйтер алдыннан тирә-якка бер карасак, кәгазьгә төшерер алдыннан тәмәке суыра-суыра ун кат уйланабыз. Нидән өркәбез? Бүген куркырга җирлек тә юк бит инде. Бу — аңсыз курку, бу — дәһшәтле курку! Аның очы әлеге дә баягы 30 еллы репрессияләргә, бер гаепсезгә дөньяның күпме акылларын харап иткән фаҗигале елларга барып тоташа. Курку чире геннар аша безнең замандашларга да үрмәләде. Саклану инстинкты утызынчы еллар ахырында ире хәбәрсез югалган (районга гына чакыртып алганнар иде!) күрше карчыгының «Бәбкәм, сак сөйлә, харап итәрләр»,— дигән әрнүле сүзләре аша, өлкән коллегаларымнан берсенең әле бүген дә «авызыңны чамалап ач, чамалап»,— дип искәртеп-өйрәтеп йөрүләре аша безнең ихтыярдан тыш канга сеңдерелде. Нәтиҗәдә, кайбер вакытларда кулыңнан каләмеңне бәреп төшерерлек эчке цензорны мирас итеп алдык. Һәм күбебез өчен демократия хакына бара торган көрәш, беренче чиратта, әнә шул шәхси судья белән бил алышудан гыйбарәт.

Мәктәп — туган тел — шигърият бәйләнеше... Бер-берен алыштыра алырлык төшенчәләрне ясалма теркәргә маташу түгел бу. Мәктәптә үз телендә укымаган татарлар әле культурабызның төрле өлкәсенә килергә дә мөмкиннәр. Ләкин — шигъриятькә
түгел! Бу катгый инкарь ителә. Поэзия канга бишек җыры белән иңдерелеп, мәктәпнең
бусагасын атлап керүгә үк Тукай, Җәлил, Такташ, Туфан шигърияте рухында укыган-
да, тәрбияләгәндә генә һәм һәр даим туган телнең көчле тәэсирен тоеп яшәгәндә генә
кеше күңелендә тамыр җибәрергә мөмкин. Шигъриятькә килүдә башка юлларны мин
күзаллый алмыйм һәм танымыйм.

Милли мәктәпләр мәсьәләсе... Үз республикабызда да әле ул бик аянычлы күре-
неш. Шәһәрләрдә андый мәктәпләр юк дип әйтерлек. Башкалабыз Казанда да бер-ике
бөртек кенә. Һәм нәтиҗә: татарларның мәккәсе булган Казан, әдәбиятка Ф. Әмирхан-
ны, Г. Камайны, Җ. Тәрҗемановны, Ә. Исхакны, М. Садрины биргән Казан, бүген
татар язучыларын тудырмый. Бүген татар поэзиясенең бар килере — авыллар. Баш-
кортстан шагыйре Әнгам Атнабаевның ярым шаяру, ярым ачыну белән әйткән сүз-
ләренчә:

*Шагыйрьләр бит авылларда туа,*
*Калаларга килеп үләләр.*

Бүгенге шәһәр шагыйрьләрне җыючы үзәк кенә. Хәзер шәһәрләребез үсте,
аеруча нефть төбәгендә калалар зур тизлек, куәт белән күтәрелделәр. Аларда яшь
һәм башлап язучылар саны да ишәйде. Әлмәттә, Чаллыда язучылар оешмасы төзелде.
Саннар үсә, әмма сыйфат ягы ничегрәк икән соң? М. Шабаевның «Төшсез чикләвек-
ләр» мәкаләсе («Казан утлары», 1988, 2 сан) бу хакта шактый күзалларга мөмкинлек
бирә: куанырлык түгел икән. Автор конкрет мисаллар белән сөйләп килә дә күңелсез,
әмма хак нәтиҗәгә килә: «...Һәр районда — әдәби берләшмә, һәр районда — халык

театрлары... Тик нигәдер яңа Тукай-Такташлар, Кариев-Мутиннар гына күренми...» Димәк, әдәби берләшмәләрдә дә тамырдан үзгәрешләр ясыйсы бар икән әле. Санны булдыру бер хәл, аны сыйфатка әйләндерү генә шактый кыен, монда һәрьяклап эзләнәсе, уйланасы бар. Бәлки төп игътибарны авыл мәктәпләренә юналтергә кирәктер, шигъри үрентеләрне биредә күреп алып, күз уңыннан ычкындырмаска тырышыргадыр? Шигъриятле күңелләрне берәм-берәм барлаганда да киләчәктә бик таманга туры килер иде.

Журналда дәвам итүче бәхәстә катнашучыларның бердәм фикеренчә, тәнкыйть чын шагыйрьләрне аерып алырга һәм аларны укучыга күрсәтә белергә тиеш. Бу яңа фикер түгел һәм ул гомер бакый тәнкыйтьченең иҗат кредосы итеп билгеләнде. Кызганычка каршы, моны бүгенгесе көндә теләсә кемне мактауга әйләндерделәр. Тәнкыйтьчеләр, әдәбият галимнәре «аһ» та «аһ» киләләр, бер-берсеннән калышмаска теләп шагыйрьләр макташалар. Кыскасы, рәхәт яшибез. Ә «Заман һәм шигырь» бәхәсе күзгә карап әйтә: поэзиянең бүгенге хәле мактанырлык түгел! Тәнкыйть үшәнләнгәндә шигырьчеләр үрчи, «шигъри бушлык» барлыкка килә. Шуңа күрә, баллы рецензияләрне укыганда үтә төчелектән, ясалма канәгатьлелектән чырай сытыла. Р. Зәйдуллин сүзләре белән әйткәндә «Тик җирәнсәм кемнәрдәндер, Кичерегез, Йөзләрендә тук елмаю». Иң сискәндергәне шул, яшьтәш каләмдәшләрем арасында да мактау чире, турысын әйтеп, кайберәүләргә авыр бәрелүдән курку өянәге нык сизелә. Аерым мәкалә-рецензияләрдә шыплап тутырылган «фәлсәфи гомумиләштерүләргә омтылучы», «гражданлык накалының зурлыгы белән шигъриятебезнең зур казанышы булырга лаеклы» кебек гыйбарәләрне укыганда мин шигырь тәнкыйте өчен оялам. Әдәбият галиме И. Нуруллин бер очрашу вакытында «тәнкыйтьче өчен нинди сыйфатлар кирәк?» дигән сорауга түбәндәгечә җавап биргән иде: «Иң әүвәл, гомерегез буена рәхмәт көтмәгез, ярашырга тырышмагыз, тәнкыйть һәрвакыт эзләнүчән булырга тиеш». Поэзия хакында да шуны ук әйтергә мөмкин. Шигырь, беренче чиратта, эзләнүчән булырга тиеш. Шигырь борчулы булырга тиеш! Әлбәттә, сандугач сайратып, каен шаулатып, мәхәббәт газабын җырлап та поэзиядә үз сүзеңне әйтергә була. Әмма ул көйгә генә гомер финишына кадәр йөгерә алу икеле. Икенче сулышы ачылмыйча ярты юлда туктаганнар азмыни? Ә гомер кышына кадәр каләмнәрен кулдан төшермәгән Х. Туфан, С. Хәкимне алыйк! Алар — шигъриятнең йөзек кашлары, шигырьләре бүген язылган кебек яратып укыла, сөендерә, сокландыра. Алар инде киләчәк шагыйрьләре. Хатлары, биографиясенә кагылышлы материаллар аша без Туфанны кабат ачабыз. Туфан — халык шагыйре, халык бәгыре, поэзияне һәм үз-үзен хөрмәт иткән һәр шагыйрь иҗат накалын Туфаннар белән чагыштырырга тиеш. Поэтик талантлар белән укучының мәхәббәтен яулаган М. Шабаев, Ш. Галиев, И. Юзеевларның иҗатлары сүлпәнәюнең сәбәпләре нәрсәдә? Соңгы елларда шигъри тулпарлары салмаклангән Р. Гатауллинга, К. Сибгатуллинга ни булды? Тәнкыйть шуны ачарга тырышсын иде. Шагыйрьләр үзләре шуңа җавап бирсәләр дә, бу — яшь шагыйрьләр өчен гыйбрәт һәм олы мәктәп булыр иде.

Шагыйрь үзен халыкның теле, җаны, вөҗдан авазы итеп тойганда гына шагыйрь исеменә лаек була. Укучы күңелендә бөреләнеп кенә килә торган уй-теләк шагыйрь тарафыннан инде әйтелгән булырга тиеш. Аның урыны һәрвакыт алда, ә бу поэзия гел генә хөрмәт һәм танылудан тормый. Кыен йота-йота булса да кыйбласыннан тайпылмаган шагыйрьләребез, шөкер, бар әле. Болай дигәндә, иң әүвәл телгә Мөдәррис Әгъләмов исеме килә. Инанып әйтәм, бу инде коеп куйган шагыйрь! М. Вәлив «Казан утлары»нда шагыйрь иҗатына карата зур, этрафлы мәкалә белән чыкты. Шуңа күрә сүзне озын-озакка сузуның кирәге юк. Шуны гына әйтәсе килә, миңа М. Әгъләмовның шагыйрь буларак борчулы җаны, хаклыкны, кыюлыкны гына юлдаш итеп алган, ярашулардан азат бунтарь кабилияте ошый. Бер вакыйга хәтердә калган: җитмешенче еллар ахырында — кайбер кызубашлар тарафыннан әдәбиятта Бабич исеменә тыю салынган бер вакытта — М. Әгъләмов Тукай клубында ярсып-нәфрәтләнеп «Заманадашым монологы» шигырен сөйләгән иде. Үзләрен шагыйрь дип йөргән күпләрнең бәгыренә тигәндер, әлбәттә, андый хәлләр, ләкин бит аларның тавышлары ишетелмәде. Бүген мирас мәсьәләсенә мөнәсәбәт тамырдан үзгәреш кичергәндә, кыю, үткен шигырь-мәкаләләр күренә башладылар. Ләкин күңел дигәнең барыбер рухи бозлануга күкрәкләре белән ташланган беренчеләр ягында. Ә М. Әгъләмов инде тагын да алга китте, аның бүген уянган кыюларны көтеп торырга вакыты юк. Шагыйрь аларга еракттан гына борылып карап, ирония катыш елмая сыман:

*Киләчәккә барасы бар,*
*Саубуллашыйк, иптәш.*

Бездә гомумән чын талантларны күрү, күтәреп алу, пропагандалау эше начар

тора. Кешене урынына-урындыгына карап бәяләү чире көчле. Әйтик, иҗат кичәләре уздыру кебек бик матур традициябез бар. Ләкин кайвакытта бу бәйрәмнәр бик тә уртакул шагыйрьләрне пропагандалау максатында да уздырыла. Популяр артистлар катнашында үткәрелә торган мондый кичәләргә тамашачы теләп йөри. Әмма андый очракта хөрмәтле тамашачыбызга фәкыйрь шигырьләрдән кыбырсып утырып, җыр-музыкадан, конферансьеның тембрлы тавышыннан ләззәт алырга гына кала. Бу инде укучының поэзиягә булган мәхәббәтеннән усал файдалану һәм ул дефицит товарга өстәп бирелгән арзанлы карамель конфетын хәтерләтә. Иң әүвал мондый культура чаралары чын талантларны пропагандалауга юнәлтелсен иде.

Шагыйрьләр миссиясе... Иҗат җаваплылыгы... Шигырь язучы һәркем моны бөтен тирәнлеге белән аңлап, тоеп каләм тибрәтә микән? Вак максатлы шигырьләр шагыйрьне дә мескенли, поэзияне дә фәкыйрьли. Шагыйрь, ышануымча, максималист булырга тиештер.

*Киләчәкләр әле уянмаган,*
*Үткәннәрдә инде тып-тыныч;*
*Вакыт океаны уртасында*
*Тик без генә, хәтта куркыныч!*

(Харрас Әюпов)

Шагыйрь әнә шул чиксез бурычны иңенә күтәргәндә генә ихтирам яуларга мөмкин.

*Кайберәүләр ашау өчен туып,*
*Үрчү өчен чыр-чу киләдер;*
*Чор намусын җан өстенә куеп,*
*Уйланырга кирәк кемгәдер...*

(Гамил Афзал)

Уйлан, шагыйрь! Эзлән, ялгыш, газаплан, хаклыкны тапканчы мең кат ян, әмма тынычланма гына!

*Соңгы сулышкача туктамаган*
*Грек сугышчысы шикелле,*
*Тормыштан да йөгереп узмыйбызмы?—*
*Күңелемә шундый шик килде.*

(Зиннур Мансуров)

Бу турыда да борчыл, шагыйрь. Шагыйрьләр тынычланса, халыкны йокы баса, дөньяны битарафлык каплый. Уяу бул, шагыйрь! Шигърият дигән тулпарның тезгене синең кулда. Шигърият язмышы — халык язмышы...

# БЕР БУЛСЫН — БЕРӘГӘЙЛЕ БУЛСЫН!

Башланып киткән бәхәскә «Заман һәм шигырь» дип исем бирелгән. Р. Мостафин белән В. Нуруллин исә нәшрият эшләре турында әңгәмә алып бара. Беренче карашка темадан тайпылган төсле тоела. Әмма беренче карашка гына. Чынлап та: буш тезмаләргә киртә куеп, шигъри җәүһәрләргә киң юл ачса, нәшрият шигъриятебезнең сыйфатына гаять зур тәэсир ясый ала бит...

Нәшрият эшенең нигезенә хуҗалыкта киң колач ала барган чыгымны каплау принцибын куярга иде. Вак тиражлы китапларның экономик яктан зарарлы икәне көн кебек ачык. Ленин бабайның «Лучше меньше да лучше» дигән сүзен искә төшерик. Күләм, сан артыннан кумаска, шигырьгә охшаган күп язмалар арасыннан җәүһәрләр эзләргә, табарга һәм аларны зур-зур тиражлар белән чыгарырга! Шигырь дигәч, шигырь булсын, җырлап торсын! Мәсәлән:

*«Җиктерер пар ат Казанга*
*Туп-туры киттем карап»...*

*«Җилләр, җилләр, сез җитез,*
*Сез исәсез кинди тиз»...*

*«Үлем турында уйлама,*
*Илең турында уйла!»...*

Әзмени алар безнең талантлы әдәбиятта!

Таләпчәнлек кирәк. Аптырап торам. Безнең борынгы шагыйрьләребез һәр юлны рифмалаштыра алганнар. Ә хәзерге шигырьләрдә 2-4 юлларны гына рифмалаштыру гадәткә кергән. Телебез ярлыланган дип әйтеп булмый — рифма табып була.

Хәзер бездә ак шигырь шаукымы тарала бара. Дөрес, әгәр әйтер сүзең булса, ул зур сүзең ритм-рифмаларга сыймаса ярыйдыр ул... Мәсәлән, «Мин табылдыклар өстәле!» дип, тирән мәгънәле уйларың белән бүлешәсең килсә, ярый, ак шигырь булса да. Ләкин бу чара күп очракта сәләтсезлекне яшерер өчен генә кулланыла шикелле.

Кулымда «Казан утлары»ның 1987 елгы 3 саны. Беренче күзгә чалынган шигырьнең рифмаларын карыйк: арып-алып, карасына-арасында, өздем-йөрдем, китте-төште, кипкәннәр-чүккәннәр, йөзләрем-бөгелмәдем, аңладым-алдым, китмәсеннәр-итмәсеннәр. Кем соң җитди килеш боларны рифмага саный ала? Редколлегия вәкиле Шәмсия Җиһангировага әйтергә тиеш иде: «Син яшь әле, сеңелем, тырышып эшлә, өйрән. Әнә «Казан утлары»ның 6 санында Гамил Афзалның, 9 санында Нури Арсланның тирән эчтәлекле һәм һәр юлы рифмалашкан шигырьләре басылачак. Шулардан өйрән»...

Әйтмәгәннәр. Басып чыгарганнар.

Шуңа күрә үз-үзеңә таләпчәнлек кими, графоманнар саны күбәя.

Гаҗәп хәл: Р. Мостафин да, В. Нуруллин да китап чыгару өчен Язучылар союзының иҗат секцияләреннән тәкъдим кирәк дип саныйлар. Безнеңчә, иҗат секцияләре юкка үзләренә хас булмаган административ функцияләрне өсләренә алалар. Аларның эш үзәгендә иҗат торырга тиеш.

Ә тәкъдим итү мәсьәләсе авторның үзеннән, аның әсәрләренең сыйфатыннан тора. В. Нуруллин бик дөрес әйтә: вакытлы матбугат шагыйрьләр өчен бик яхшы пропаганда чарасы. Егермедән артык китап чыгарган Гамил Афзалны мин бары тик журналлар аша гына беләм. Әйтик, аның «Азат хатын»да басылган «Әби каргышы» гына ни тора. Мин аның барлык китапларын да алыр идем дә бит — каян аласың соң? Ә менә «Офыкларга карап» (Казан, 1987) ялгыш кына очрады да даими юлдашыма әйләнде.

Гамил Афзал образлы сүзе белән генә түгел, бигрәк тә хакыйкатьне ярып сала белүе белән кадерле, эчтәлегенең актуальлеге белән үзенә җәлеп итә.

Аның образлары нәкъ үзебезчә халыкчан, табигатебезнең чиксез гүзәллеген, халкыбызның бай тормыш тәҗрибәсен чагылдыра. Шагыйрьнең иң яраткан образы җил бугай:

*Төнге җил тын ала, талларны тарап,*
*Алтын ай моңая, суларга карап.*

Җил төрле хисләрне аңлатыр өчен кулланыла. Тышта көз. Синең гомерең дә үзенең көзенә җитеп бара. Ә эшлисе эшләр күп әле. Күңел сине тарих тирәнлекләренә чакыра, язмышларны чагыштырып утырасың. Менә шундый уйланулар турында кечкенә шигырь: «Морҗаларда ачы җилләр елый»,— дип башлана һәм бу бердәнбер юл үзе үк тирән уйларга чумдыра.

Ә инде «Биттән сыйпап исә сәхрә җиле» яисә «Кичке җилләр колакка пышылдый» кебек юллар бөтенләй башка кәеф тудыралар. Тагын да җил — төтен ислесе.

*Төтен исле җилләр исте,*
*нефть тулып, ага елга.*
*Агачтан бер алма төште —*
*дерт итеп селкенде дөнья...*

Менә шул агачтан алма төшүе кебек бик прозаик, бик гади хәл бөтен дөньяны сискәндерүче экологик упкынның бер хәбәрчесе итеп аңлашыла.

Кыскасы, сокландырырлык образлар — китап тулы. Менә берничә мисал: «Еландай юллар бара», «Камыш бавы кебек чыдам мин», «Оялган кыз кебек ай», «Үлән үсте язмыш ярларына», «Сагыш сибелгәндәй урман юлы».

Тик мин шигырьләрне эстетик таләпләрдән чыгып тасвирлауны үземә бурыч итеп куя алмыйм. Сүзем икенчерәк: шигырьләрнең заманча яңгыравы турында. Редакция тәкъдим иткән «Заман һәм шигырь» исемле бәхәснең уртасында үрнәк булып Гамил Афзалның бу җыентыгы тора ала.

Заман, дибез. Заман ул иррациональ нәрсә түгел. Кешеләрнең үзара мөнәсәбәте, үткәнебезгә карашыбыз, киләчәккә омтылышыбыз, әхлакый хәлебезнең чагылышлары, инану объектлары — менә нәрсәләрдән тора ул заман. Күп еллар буе бер чиктән икенчесенә сугылып, өстән кушсалар, акны кара күрсәтергә тырышып, начар якларыбызны күрмәмешкә салышып яшәдек. Әхлак кагыйдәләренең какшавы — шундый уйсыз яшәешнең нәтиҗәсе буларак, заманыбызны характерлаучы төп компетент булып тора. Озак вакытлар үзебезнең кемлегебезгә күз йомып яшәгәннән соң, шагыйрьнең «Заман» исемле шигыре күпләрне уятып, уйланырга мәҗбүр итәрлек.

*Аң-белемгә юмарт, хиска саран,*
*Катлаулы син, безнең өлгер заман.*
*Шигъри сүзнең кадере беткән заман,*
*Матди табыш, файда көткән заман,*
*Исәп-хисап алга киткән заман.*

Шагыйрьнең бу мәсьәләгә кабат-кабат кайтып өзгәләнүе укучыны битараф калдырырлык түгел. Әхлак бозылуның сәбәпләрен аңларга тырышып, автор безне бергәләп уйлашырга чакыра. «Табыш эзләп йөргән вак кәсепчеләр»нең ничек патриот булып кыйланулары, «Чынбарлыкның кырыс кысасында» ышану һәм өметләнүнең чиксез була алмавы, хәрам байлык җыю шартларының киң таралыш табуы — болар, әлбәттә, яшь буынга уңай тәрбия бирүгә комачаулаучы факторлар.

Гамил Афзал тәрбиясезлекнең тагын бер сәбәбенә аеруча игътибар итә: ул да булса, табигатькә мөнәсәбәтебез. Шагыйрь «төтенсез һава сулап», «нефтьсез су эчеп», яшәргә хыяллана, «болынны сөрдереп, чишмәне күмдереп» кемгәдер ярарга тырышкан түрәләргә нәфрәт белдерә. Патриотизм ул туган табигатеңнең гүзәллегенә сокланып, аны саклау гына түгел, ул тагын да баетып, киләсе буыннарга мирас итеп калдырырга тырышудан башлана. Патриотизм ул шул гүзәл җиреңне ныгытып, беркемнән дә кул тидермәслек итеп яклауны күздә тота.

*Урманнарга барсаң — бер куян юк,*
*Алар, бәлки, күчеп киткәннәрдер.*
*Елгаларга төшсәң — бер балык юк,*
*Алар, бәлки, нефть эчкәннәрдер.*
*Басуларга чыксаң — бер тургай юк,*
*Самолеттан агу сипкәннәрдер.—*

дип ачынып яза Г. Афзал.

Шул уңайдан яңгыравыклы тавышлы шәһәрский шагыйрьләребезнең авылга сокланулары, аның тирә-ягын сагынулары турында ничәмә-ничә шигырьләрен укыганың искә төшә. Әйтәсе килә: шул чаклы сагынып-саргайганчы, нигә соң авылыңа кайтмыйсың, кем сине ташкалага бәйләп тота? Җавап булмаячак, чөнки андый авыл табигатен мактап, сагынып язган шигырьләрдә уй да, моң да, хис тә, эчкерсезлек тә юк. Юл тезмәләре генә... Гамил Афзал да «Әй, авыл» дигән шигырен бу җыентыкка керткән. Бу инде икенче төр соклану, юк, соклану түгел, гимн бу. Бу шигырьдән өзек китерү мөмкин түгел, аны бөтенләй йөрәк түренә салып куярга кирәк. Нәкъ дөресен әйткән ич шагыйрь: авыл ул үзендә «халыкның тере җанын саклап» торучыбыз.

Җыентыкта кычкырып әйткән «ура-патриотизм» сүзләрен очратмыйсың. Әмма аның һәр сүзе Ватанын сөю, аңа изгелек, матур киләчәк теләү хисе белән сугарылган. Һәм укучыда да шундый хис уята.

Теләсә нинди җәмгыятьнең тазалыгы аны тәшкил иткән гражданнарның әхлакый хәленә бәйле. Ә әхлак кануннары, аларга мөнәсәбәт буш җирдә үсмиләр. Бу тарафтан Гамил Афзал халкыбызның тарихына яңадан күз ташлый, ата-бабаларыбыздан мирас булып калган әдәпле, тыйнак, кешелекле, характердан тайпылмаска өнди. Һәм шуңа бәйле рәвештә халкыбызның шигъри мирасына соклана.

*Халык юаш, халык белми димә*
*Халык хаклы, халык хәтерле:*
*Мәкальләре меӊ еллардан килә*
*Җыры-моңы өзә бәгырьне.*

Ә икенче урында:

*Авылларга карый-карый үтеп китәм:*
*Чияле Тау, Салкын Алан, Якты Чишмә...*
*Валлаһи, дим, безнең халык шагыйрь икән,*

*Тормышына ука чиккән, энҗе сипкән*
*Ни тора бер Якты Чишмәң...*

Шул шигъри халыкны шигырь белән сыйлыйм дип каләмгә тотынган кешедә нинди зур җаваплылык булырга тиеш!

Гамил Афзал моны аңлый. Ул үзен борынгы шагыйрьләребез Кол Гали һәм Мөхәммәдьяр, Утыз Имәни һәм Кандалыйларның варисы дип саный. Ул үзен Тукай һәм Такташларның шәкертләре исәбенә кертә. Ул Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Муса Җәлилләргә соклана, Туфан һәм Хәким белән горурлана. Ул алар исәнлегенә лаеклы шигырьләр иҗат итә. Һәм ул башкаларны да шуңа өнди.

*Биеккә мен,*
*Биек җирдән сөйлә,*
*Шагыйрь сүзе җанны җилкетә.*
*Өмет тулы ярсу язлар килә,*
*Ил ни көтә, халык ни көтә?*

Нәкъ менә шул: «халык ни көтә?» Шагыйрь халыкка хезмәт итәргә тиеш, чөнки «барлык фәлсәфәләр — буш сүз, халык кадерсез булса». Шагыйрьгә «чын күңелдән кайнар хис кирәк»,— ди ул. Шуннан чыгып Гамил Афзал конъюнктурага язган флюгерларны фаш итә. «Басуларда арыш начар үссә — күрмәмешкә салыш»,— ди ул барабан кагучы шагыйрьләргә «киңәш» итеп. Андыйлардан ул ачы көлә:

*Син бер кочак начар шигырь яздың,*
*Син уртакул шагыйрь була яздың,*
*Сүз имгәтеп, син акылдан яздың,*
*Яза-яза аздың.*

Игътибар итик: «яздың» сүзе өч төрле мәгънәдә шундый үз урынында кулланылган! Менә, ичмасам, шигърият!

Гамил Афзал — танылган шагыйрь. Халыкка әйтер сүзе бар, ул аны оста итеп әйтә дә белә. «Офыкларга карап» исемле җыентыгы һәркемнең күңел дәфтәре булып хезмәт итәрлек кечкенә китап. Әмма ул, кечкенә булса да, зур-зур томнарга бирешми.

Шуннан чыгып нәшриятка ике сорау туа: нигә соң бу кыйммәтле китапның бәясе Ю. Макаров китабы кебек 20 тиен генә тора? Нигә соң аның тиражы 3800 данә генә? Бу авторның башка шигырьләрен дә уку өчен кеше бер тәңкәсен кызганмас иде! Ә тиражы...

Без бит җиде миллион чамасы. Халкыбызның дүрттән бер өлеше дә Татарстанга керми. Ә Казан нәшрияты бары тик Татарстан территориясе белән генә эш итә. Мәсәлән, тугандаш Башкортстанның Бәләбәй, Туймазы, Бүздәк кебек районнарында да татарча китап бик сирәк очрый. Ульяновск, Куйбышев, Пенза өлкәләрен әйтеп тә торасы юк. Әгәр дә нәшрият күрше өлкәләрнең мәдәни органнары белән элемтә тоггызса, бәлки без дә, Татарстаннан читтә яшәүчеләр дә, телебезне алай тиз югалтмас идек.

Шигъриятттән читтәрәк торган бер мәсьәлә, юк, проблема!— кайдан гына табыйм соң «Әлифба»ны?! Оныкларым рус мәктәбендә укыячак. Үзем булса да әлифба белән таныштырырга исәп аларны. Ә каян алырга аны?

Безгә Казан телевидениесе төшкә дә керми.

Шагыйрь әйтмешли, «казанский радионың радиусы бәләкәй».

Артистларыбыз бездә бик сирәк кунак.

Шул — китап кала инде. Һәм анысын да, күп артык түләп, «Книга — почтой» аркылы гына алып була. Туры килсә әле.

Халкыбызның бөтен почмакларга таралган булуын искә алсак, Казан нәшриятының Татарстанга гына кергән территория белән чикләнергә һич хакы юк.

**Айрат ИБРАҺИМОВ,**
Ульяновск шәһәре.

# ИХЛАСТАН СӨЙЛӘШИК

Шигърият турында бездә сүз алып барылмый дип булмый. Моннан берничә ел элек «Социалистик Татарстан» газетасында «Поэзиядә Тукай һәм Җәлил традицияләре», «Казан утлары» журналында «аңлаешлы» һәм «аңлаешсыз» шигырьләр яки поэзиянең гражданлык йөзе» исемле дискуссияләр оештырылды. Менә тагын шигырьнең аз укылуы һәм бу жанрда язылган китапларның аз таралуы турында сөйләшәбез.

Чыннан да, шигырьнең укучылар тарафыннан аз укылуы һәм поэтик китапларның аз тарала башлавы — олы бәла килү хакындагы хәбәр. Алай гына да түгел, барыбызны да чаң сугарга чакыручы хәбәр.

Шигырьләрнең аз укылуын, бу төр китапларның аз таралуын поэзия сөючеләребез эше итеп кенә карау дөрес булмас иде. Моны әдәби тәнкыйтьнең, бигрәк тә поэзия тәнкыйтенең үз югарылыгында булмавыннан һәм кайбер тәнкыйть материалларының артык тенденциоз булуыннан эзләргә кирәктер. Безнең Татарстан Язучылар союзында 200 гә якын кеше исәпләнә. Шуларның алтмыштан артыгы шагыйрьләр, егермедән артыгы тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме. Аларны шагыйрьләр исәбенә бүлгәндә, өч шагыйрьгә бер тәнкыйтьче туры килә. Ләкин без җитди анализлы тәнкыйть мәкаләләрен сирәк күрәбез. Әйтик, бик күптәннән язып килгән С. Баттал, Ә. Исхак, Н. Дәүли, Ә. Маликов, З. Нури, Х. Камал, Ә. Баян, М. Хөсәен, Р. Гәрәй, Н. Мадьяров, Э. Мөэминова, К. Булатовалар шигърияте турында бу көнгә кадәр нигезле, ныклы анализлы тәнкыйть бармы? Бу шагыйрьләрнең әдәби процессыбызда тоткан урыны нинди? Алар шигъриятка нәрсә алып килделәр, нәрсәләр ачтылар? Бу шагыйрьләрнең шигърият арсеналында иҗат авазлары ничек? Күрме? Әллә хәлсезме? Шигърият бер урында гына катып калган нәрсә дә түгел, һәм шулай ук бер төрле талант ияләреннән генә дә тормый... Гомер дигәнең дә чикле. Шагыйрьләр килә һәм тиешле бәһане алмый китә. Алар урынына яшьләр килә. Ә алар үзләренең шигъри юнәлешләрен нинди маякларга карап билгеләргә тиешләр?!

Тагын шунысы кызганыч, әдәби тәнкыйть укучыга һәр яңа әсәрнең уңышлы һәм кимчелекле якларын кыю ачып салырга, принципиаль партия бәһасе бирергә тиеш булса да, бездә әле аның чын ихласлыгы җитми. Моны тәнкыйтьче Рафаэль Мостафинның «Социалистик Татарстан» газетасының 1987 елгы 26 май санында чыккан «Файдалы киңәшләр» исемле әдәби фельетонына карата әйтергә була. Тәнкыйтьче авторларның үзләре белән дә һәм аларның әдәби эшчәнлеге белән дә бөтенләй таныш түгел, биргән бәясе дә тенденциоз. Ул Х. Хөснуллинның иҗат эшчәнлеген ныклап өйрәнәсе, аңа приципиаль бәһа бирәсе урында, аның «Май бәйрәме» шигырен аннан-моннан укый да, шундагы «Урам тулы халык агыла» дигән шигъри юлына тап була. Шуннан соң ул шагыйрьне Х. Туфанның «Агыла да болыт агыла» исемле шигырен, аның ритмик калыбын, интонациясен үзләштерүдә гаепләргә тотына. Бу шулаймы соң? Һич юк! Бу шигырьләрнең рухлары да, вакыйгаларга төшкән акценты да бер-берсеннән җир белән күк шикелле аерылып торалар. Аксакалыбызның шигыре кешенең фаҗигале язмышын гәүдәләндерсә, Х. Хөснуллинның шигыре илебезнең иҗтимагый үсешен, Май бәйрәме — халыкара бердәмлек көненең дәвамлыгын чагылдыра. Инде шигырь формасына килгәндә, болайга киткәч, аны «үзләштерүдә» Хәнифне түгел, ә Туфанны «гаепләргә» кирәк. Чөнки бу форма, бу ритмик калып танылган рус шагыйре С. Есенинның 1924—1925 елларда ук язылган «Фарсы моңнары» исемле шигырьләр циклыннан ук килә. Һәрхәлдә милләтләр һәм халыкларның күплеге, шуның бөек чагылышы буларак гомуми культурабыз, сәнгатебез үсүе һәм рухыбызның баюы бер дә начар нәрсә түгелдер?! Ул шулай үсте һәм киләчәктә дә шулай үсәчәк!

Әллә безнең тәнкыйтьчеләр бик хәтерсез, әллә кәефләренең нинди булуына карап кына эш итәләр инде. Шулай булмаса, алар бер үк авторның бер үк әсәренә төрле бәя биреп чыкмаслар иде. Менә Мансур Вәлиевне генә алыйк. Ул шагыйрь К. Сибгатуллинга язган ачык хатында («Авылыбыз моңын югалтсак» мәкаләсе — «Күңелнең көткәне» исемле китапта, Казан, 1984 ел) «Хыял» поэмасын хуплап: «Хатны тәмамлар алдыннан гына синең яңа әсәрең «Казан утлары» журналына басыла торган «Хыялыбыз башкаласы» исемле поэмаң белән танышып чыктым. Ул мине сөендерде: син олы төзелешнең кешелек моңына, поэзия өчен иң мөһим булган үзәгенә **якынаеп киләсең**. Синең күңелеңдә хәзер яңа җир, яңа төбәк моңы тулышуы сизелә. Әлбәттә, киләчәктә язылачак әсәрләреңдә алар **тагын да калкурак чагылыр**»,— дип үзенең теләктәшлеген белдергән иде. Ә «Шигъри бушлык» исемле

икенче мәкаләсендә исә («Казан утлары», 1987 ел, 8 сан) шул ук «Хыял» поэмасына карата тәнкыйтьче менә нәрсә ди: «К. Сибгатуллин китабындагы бик зур күләмле «Хыял» поэмасы үзенең фикри көпшәклеге һәм эчендә таушалып беткән газета тәгъбирләренең күплеге белән укыган чагында ук борчылу тудыра. Талантлы шагыйрьнең иҗатына, поэзиягә шулай җавапсыз карый башлавына, буш сүзләр тезеп уйнавына чын-чынлап гаҗәпләнәсең, ә инде «КамАЗ» дигән сүзнең бирелдә еш кабатлануы поэзия өчен бигрәк тә сәер».

Тәнкыйтьченең кайсы фикеренә ышанырга? Бу, йомшак кына итеп әйткәндә, әдәби тәнкыйтькә җавапсыз карау түгелме?

Мин шагыйрьләрнең шигырь иле гел чәчәкләрдән генә тора, анда утап ташланырга тиешле чүп үләннәре юк, иҗатлары тәнкыйтьтән югары, дип әйтергә һич тә җыенмыйм. Һәр шагыйрьнең үз язу стиле, үз дөньясы, уңышлары булган кебек, әлбәттә, аларның кимчелекләре дә бар. Әйе, ирешелгәннәр белән чикләнеп калырга да, масаерга да ярамый. Шул ук вакытта, үз-үзеңнән риза булмыйча гел сызланып кына яшәү дә бик үк килешеп бетми. Үлчәү сизгер булсын. Аның һәр ике башы да дөрес тартсын. Шул вакытта гына безнең шигъриятебезгә булган мөнәсәбәтебез хак һәм гадел булыр. Әгәр син әсәргә бәя бирергә алынгансың икән — ул дәлилле, төпле, анализлы, укучыны да, авторны да ышандырырлык булсын. Тәнкыйть дигәч тә, әдәби тәнкыйтьнең бурычы әсәрне ничек телисең шулай сүгеп, тетеп ташлаудан түгел, ә бәлки язучының уңышларын билгеләүдән, иҗади үзенчәлеген ачудан, булган кимчелекләреннән арынырга юл күрсәтүдән, укучыга әсәрнең сәнгатьчә асылын төшендерүдән һәм аны укырга омтылыш тудырудан гыйбарәттер.

Инде шигырь китапларының начар таралуына килгәндә, моның өчен шагыйрьләрне генә начар язуда гаепләмәскә, ә китап сәүдәсенең түбән оештырылуыннан эзләргә кирәктер. Чөнки әле бездә бер урында да китап укучыларның ихтыяҗы өйрәнелми. Һәр районда диярлек китап сату эше шул кибет сатучысына гына йөкләнгәндә хәл үзгәрмәячәк. Анда эшнең торышы белән райкомның пропаганда бүлеге дә, районның культура һәм мәгариф бүлекләре дә һич кызыксынмыйлар. Шундый битарафлык яшәгәндә, билгеле, яхшы нәтиҗә көтеп булмый. Ә бит болай да оештырып булыр иде. Әйтик, районнагы һәр сәүдә ноктасына китап сату планы җиткерелсә, аның үтәлеше урындагы башлангыч партия, комсомол оешмалары, авыл Советы башкарма комитетлары, мәктәп дирекцияләре тарафыннан тикшерелеп барылса начар булмас иде. Рухи байлык күп кешe кулына керер, мактаулы фидакарь хезмәттән соң халыкта китап уку дәрте уяныр, ялы да файдалы үтәр иде.

Әйдәгез, иптәшләр, барыбыз да үзебезнең шәхси китапханәбезне булдырыйк. Аны китап белән баетыйк, китапны укыганда да каш җыерып, йөз сытып, аннан кимчелек кенә эзләп түгел, киресенчә, гүзәллек эзләп, шул гүзәллек белән җаныбызны баетырга омтылып укыйк. Гомумән, шигъриятебез язмышына беребез дә битараф калмасын иде.

**Әзһәр ГАБИДИ,**
Сарман районы.

# АВЫЛЛАР СЕЗНЕ КӨТӘ

«Казан утлары»ның быелгы 2 санында Марс Шабаевның «Төшсез чикләвекләр» исемле мәкаләсен укып чыктым да уйга калдым. Күңелдә туган хисләрне сезгә дә җиткерергә булдым.

Миңа 24 яшь. Мәктәптә тарих фәнен укытам. Читтән торып Башкорт дәүләт университетының филология факультетында укыйм.

Әдип хәзергенең, киләчәкнең җаны, ялкынлы трибуны бит. Ул исеме һәм басылып чыккан китабы белән генә түгел, ә йөрәге, рухы белән укучыларга таныш, якын, кадерле булырга тиештер, минемчә. Әйе, кадерле булырга тиеш! Нигә соң Тукай, Такташ, Җәлил, Туфаннар күңелебездә мәңгелеккә саклана? Исемнәре матур яңгыраганга түгел ич. Хәзер исә сүз арасында, бәхәсләрдә ниндидер шагыйрь турында ишетелеп калса аптырыйбыз гына.

— Нишләп белмисең син аны? Биш-алты китабы чыкты бит инде,— диләр танышлар. Ләкин китап саны гына шагыйрьне шагыйрь итми икән шул. Шигырьләр укучы яратып укысын өчен, аңардан үзенә илһам алсын өчен языла. Ә хәзерге

яшьләрдән яраткан яңа берәр шигырен сөйләвен үтенсәң, күп очракта җавап өмет итмә. Шул вакытта зур абыйлар-апалар эш арасында да Тукай, Такташ, Җәлил шигырьләрен, хәтта поэмаларын өздереп сөйләп бирә ала. Яшьләрнең шигърияткә күңеле сүрелгәнме, мохтаҗы юкмы, әллә укырга вакыты җитмиме? Һич тә алай түгел. Алтмыш яшьлек «яшьләр» язганга шулай. Чәчләренә чал кунган хөрмәтле ул абзыйлар бүгенге көн егет һәм кызларының хисләрен, омтылыш, хыялларын аларга якын телдә әйтеп бирә аламы соң? Юк! Шуңа да үтемле түгел ул шигырьләр, шуңа күрә китап кибетләрендә генә түгел, ә китапханә киштәләрендә дә тузан җыеп ята бирәләр.

Заманнар үзгәрә килә, кешеләрнең дә таләпләре үсә бара. Ләкин минемчә, әлегә шигърият бер урында таптана: һаман да шул ук табигатькә соклану, «томанлы бушлыкларда» адашып йөрү укучының, дөресен генә әйткәндә, йокысын китерә. Китап итеп бастырыр алдыннан шигырьләрнең эстетик, тәрбияви ягына да, «шигырьлегенә» дә ныграк игътибар ителсен иде. Эче пошканнан яки шөһрәт, дан артыннан куып рифма төзүчеләр алдында нәшрият ишекләрен шапылдатып ябарга вакыттыр инде. Бездә төрле формаль булмаган берләшмәләр оештырыла, ә шул вакытта яшь иҗатчылар өчен (әлбәттә, поэзия, проза сөючеләр, тыңлаучылар өчен дә) бәхәс клублары ачылу турында бер генә хәбәр дә ишетелгәне юк әле. Каләмнәрен сынап караучы яшьләр аз түгел бит. Тоткарлык нәрсәдә икән?

Әлбәттә, яшь талантларны газета-журнал битләре ача. Тик шунда ук күккә чөяргә дә ярамыйдыр. Чөнки «кошчык»ның канаты ныгып бетмәгән булуы яки башы әйләнеп китүе бар. Беренче китапларның тиражларын да азрак итәргә кирәктер. Уңышлы китапларны соңрак укучылар соравына карап арттырып та чыгарырга була. Яза алган бар кеше дә әдип була алмый. Әдип исеме — значок түгел, шуңа күрә теләсә кемгә тагарга ашыкмасак иде.

Мәктәпләргә, бигрәк тә авылга, әдипләр килсә ул көн бәйрәмгә әверелә. Тик соңгы вакытта аларның сукмаклары суынып бара. Гомеремдә дисәм, күбрәк булыр, а зәвыгы, уй-карашлары формалашкан, ныгыган чорда бала чын әдипне күрмәгәч, автор авызыннан шигырьләрен тыңлый алмагач, аңарда поэзиягә карата кызыксыну, мәхәббәт уяна алырмы? Әдәбият дәресләре генә зур эффект бирә алмый. Болай да хәзер баланы телевизордан аеруы җиңел түгел. Берәр әсәрне укыдыңмы, дип сорасаң:

— Юк, ә киносын карадым,— дип җавап бирерләр һәм моңа аптырыйсы юк. Ә бит кино автор теленең барлык гүзәл энҗеләрен дә биреп бетерә алмый.

Күпчелек районнардагы әдәби берләшмәләрнең каләм сынаучылар өчен роле ничектер, ә менә халык белән элемтәләре юк дәрәҗәсендә. Алар үзләренә түгел, шул ук халык өчен язалар түгелмени? Ә актив эшләгән, гөрләп яшәгән берләшмәләр бик зур изге эшләр эшли, якташлары тормышына ямь өсти ала: күңелле кичәләр, шигъри бәйгеләр (клубларда), радиотапшырулар һәм башкалар, һәм башкалар...

Китап гасырлар төпкеленнән үк зирәклек, белем чишмәсе, иң кадерле әйбер булган. Ә хәзер шул ук китап киштәләрдә гасырлар тузаны җыя. Гафу итәрләр идеме икән бабаларыбыз? Демократиягә яшел урам ачылганга гына түгел, ә көндәлек тормышта укучыга да активлык кирәк. Газета-журнал битләрендә басылган яңа әсәрләр, яңа авторлар, китаплар турында йөрәктәгесен уртага салып сөйләшүләр ешрак булсын иде.

Бик күп шагыйрьләр авылда туган, аның яшел хәтфә яланнарында аунап, чылтыр чишмә суларын эчеп үскән. Ә авыл кешеләре чын шагыйрьләрне күрү өчен, алар сүзен тыңлар өчен, вакыты булганда, шәһәргә яки район үзәгенә барырга тиеш. Шагыйрь абыйлар, онытмагыз әле туган төбәкләрегезне. Авыллар сезне көтеп моңсулана.

**Илдус ХӘБИБУЛЛИН,**
Башкортстан, Дүртөйле районы,
Үткәнәй авылы.




# СӘНГАТЬ ТАРИХЫНА ЗУР ӨЛЕШ

**Червонная С. М. Искусство Татарии. История изобразительного искусства и архитектуры с древнейших времен до 1917 года. М., Искусство, 1987, 352 б.**

Алдымда яңа китап ята. Бүгенге көндә, милли мәсьәләләргә һәм халыкара мөнәсәбәтләргә, СССР халыкларының һәм рухи, һәм матди байлыкларына игътибар көчәйгән бер заманда, бу китап аеруча зур һәм актуаль вазифаны үти.

Совет Татарстаны җирлегендә бик борынгы заманнардан алып 1917 елга кадәр вакыт эчендә үскән һәм чәчәк аткан сәнгать төрләренең (төзелеш-корылыш, театр сәхнәсе, декоратив кул эшләре һәм сынлы сәнгатьнең) профессиональ башкаруда һәм халык иҗатында ни рәвешле чагылыш тапканын моңарчы берәүнең дә болай бергә туплап, фәнни тикшергәне юк иде әле.

Татарстан АССРның гасырларга сузылган сәнгать тарихы күп галимнәрнең игътибарын үзенә җәлеп итә. Аның бөтен ил күләмендә һәм чит илләрдә дә сәнгать сөючеләргә мәгълүм булган, зур популярлык казанган әсәрләре бар. Урта гасырлар каласы Бөек Болгардагы корылмалар, татар халкының чигү эшләре җәүһәрләре, алтынкөмештән ясалган бизәнү әйберләре, ташны уеп иҗат иткән ядкарьләр, XVI йөзнең икенче яртысында элеккеге Казан ханлыгы җирләрендә күренә башлаган борынгы рус сәнгате үрнәкләре, Зөя буена салынган чиркәүләрдәге фрескалар, Казан кремленең манара һәм диварлары, губерна башкаласында барокко стилендә яисә классицизм стилендә корылган биналар ансамбле, Николай Фешинның һәм 1895 елны Казанда ачылган сәнгать мәктәбендә укып чыккан рәссамнарның нәкыш әсәрләре әнә шундыйлардан.

Моңа кадәр төрле монография, альбом, каталог, юл күрсәткеч, мәкаләләрдә теге яки бу дәвергә, сәнгатьнең аерым төренә яисә берәр останың иҗатына бәйле рәвештә яшәп килгән мәгълүматлар С. М. Червонная китабында һәммәсе бергә тупланган, яңа яшәеш алган. Автор аларны үзенчә күреп, үзенчә анализ ясап, һәркайсының сәнгатьчә кыйммәтенә карата үз фикерен әйткән, үз бәясен биргән.

Шуның белән бергә, Татарстан сәнгате тарихында игътибарга лаек шактый әйбер киң катлам укучыларга бөтенләй билгеле дә түгел иде. Алар беренче мәртәбә әлеге китапта чагылыш тапкан. Республиканың Берләштерелгән дәүләт музее фондында сакланган шәмаилләр коллекциясе беренче тапкыр шушы китапта урын алган. XX гасыр башыннан бирле күбесе онытылып беткән, онытылмаганнары да русчага беркайчан тәрҗемә ителмәгән әдәбисурәтләү памфлетлары, шулай ук «Яшен» һәм «Ялт-йолт журналларында чыккан карикатуралар, «Ак юл» журналында басылган каллиграфия үрнәкләре сәнгать белгече күзлегеннән чыгып карап беренче мәртәбә тәкъдим ителгән. Моңа кадәр безгә билгеле булмаган исемнәр, ягъни рус сәнгать мәктәбендә тәрбия алган беренче татар яшьләре: 1904—1908 елларны Казан сәнгать мәктәбендә укыган Нәбиулла Вахитов, 1915 елны Мәскәүдә Строганов училищесында белем алган Хәдичә Акчуриналар — илебез сәнгать тарихына теркәлә. Казан сәнгать мәктәбендә XX йөз башында булып узган һәм хәзергәчә күләгәдә кала килгән фаҗигале хәлләр дә — әйтик, укучыларның 1901 елның мартында политик демонстрацияләргә, студент сходкаларына, социал-демократларның яшерен оешмаларына һәм, ниһаять, 1905 елгы революциягә актив катнашулары — архив материалларына таянып, беренче мәртәбә халыкка игълан ителә.

Авыл мәчетләре (арада берсе — Арча районы Казиле авылындагы кызыл кирпечтән корылган, тәрәзәләренә төрле төстәге пыялалар куеп бизәлгән мәчет), зиратларның матурлыгы (Балтач районы Түнтәр авылы зираты үзе генә дә ни тора!), сәнгатьчә матурлап язылган шәмаилләрнең мәчет диварын гына түгел, бәлки әле өйләрне дә бизәве (әйтик, Әлки һәм Куйбышев районнарында бу нәкъ шулай икән) шикелле фактив материалны, ягъни татар халык сәнгатен төрле яклап яктырткан гыйль-

ми мәгълүматны автор үзе башлыча 1984 елның җәендә СССР Сәнгать академиясе оештырган фәнни экспедиция вакытында туплаган.

Бу китапның байлыгын тәшкил иткән ачышларны санап чыгудан файда юк, аларны укучы үзе дә укый ала: китап бер генә республика өчен түгел, бәлки илдәге байтак укучыларга җитәрлек итеп чыгарылган. Әмма китапның кыйммәте моның белән генә чикләнми, анда әле тагын менә ни бар: өлешчә һәркайсыбызга мәгълүм булган, кайберләре хәтта әле сәнгать белгечләренә дә билгеле булмаган кызыклы фактларны автор бик матурлап бер тезмәгә тезгән һәм республикабызда яшәүче халыклар сәнгатенең эзлекле тарихын язган. Китапның төп кыйммәте әнә шул тарихи концепцияне фәнни яктан нигезләп күрсәтә белүдә.

Моңа кадәр әле фәкать союздаш республикаларның сәнгате генә бу дәрәҗәдә эзлекле, этрафлы өйрәнелә торган иде. Татарстан сәнгатенә багышланган китап исә яңа төр басмаларга — автономияле республикалар сәнгате тарихын фәнни өйрәнүгә багышланган басмаларга юл яра. Чыннан да, РСФСРдагы һәм Азәрбайҗан, Грузия, Үзбәкстан ССРдагы автономияле республикаларның культура казанышлары бүгенге көндә әнә шундый китаплар таләп итә.

Татарстан сәнгатенең тарихын өйрәнү мәсьәләсенә автор андагы этнокультураны тәшкил иткән һәммә өлешне дә үзара мөнәсәбәттә һәм бердәмлектә тулаем күрергә омтыла. Әнә шул үзара мөнәсәбәт һәм бердәмлек нәтиҗәсендә бу республиканың культура тарихына күпмилләтлелек хас булган, ягъни аның иҗади көчләр тарихында төрле ыруг һәм кабилә вәкилләре актив катнашып килгән.

Борынгы болгар культурасы нигезендә барлыкка килгән татар халкының гаять үзенчәлекле сәнгатен өйрәнү белән генә чикләнмичә, Татарстан туфрагында гасырлар буена гомер кичергән башка халыкларның сәнгатьләрен дә өйрәнеп, автор автономияле республика регионында милли культураларның үзара мөнәсәбәтләрен һәм бердәмлекләрен чагылдырган җанлы һәм гаять кызыклы модель тәкъдим итә. Шул ук вакытта бу китап бик борынгы фин-пермь, угро-фин һәм һинд-иран общиналары, болгар-татар һәм рус культуралары йөзен күрсәткән төрле элементларны механик «тигезләү»дән ерак тора. Идел буе татарларына карата Светлана Червонная болай дип яза: «Автономияле республикага үз исемен бирергә лаек табылган халык бу республиканың сәнгать тарихында икенче рольне уйнаучы гына була алмый. Әлбәттә, монда борынгы сәнгатьне бүгенге көнгә яраклаштырып күрсәтү күздә тотылмый... Һәр нәрсәдән «милли рух» эзләү дә алга сөрелми, бәлки тора-бара автономияле республиканы китереп чыгарган күпмилләтле регионда тарихи лидер булуны үз өстенә алган халыкның милли культурасы барлыкка килгән, чәчәк аткан дәверләргә, аның традицияләренә аеруча игътибарлы килү, күзеңне ачыбрак карау зарурлыгы алга сөрелә» (297 б.).

С. М. Червоннаяның китабы тулысы белән, бигрәк тә Казан ханлыгында XVI йөзнең беренче яртысында гөрләп чәчәк аткан сәнгатькә — «Казан Ренессансына» багышланган сәхифәләре белән татар халкы милли культурасының алтын фондын тәшкил иткән гүзәл әсәрләргә нәкъ әнә шулай күз ачыбрак карау, ихләтә игътибарлы килүнең үрнәге була ала.

Бу китапны мин, Мәскәү белән Татарстан арасындагы бәйләнешләрнең иҗади һәм гыйльми кадрларыбыз арасындагы хезмәттәшлек итүнең күркәм нәтиҗәсе сыйфатында, бик сөенеп укучыларга тәкъдим итәм. СССР Сәнгать академиясенең Сынлы сәнгать теориясе һәм тарихы институты өлкән гыйльми хезмәткәре язган, альбом өлешендә Татарстанның шәһәр һәм авылларындагы истәлекле корылмаларны, музейларда саклана торган гүзәл сәнгать әсәрләрен чагылдыручы, заманыбызның археология, этнография, тарих, сәнгать белеме, тел гыйлеме мәгълүматларына таянучы, һәм поэтик, һәм эстетик фикер чыганаклары буларак яшәгән үлемсез әсәрләргә мөрәҗәгать итүче әлеге китап безнең уртак казанышыбыз ул.

**Таһир САЛАХОВ,**
СССРның халык художнигы,
СССР Сәнгать академиясенең
хакыйкый әгъзасы.

## Газиз Кашапов

# ӘПСӘЛӘМОВ ХАТЛАРЫ

Габдрахман Әпсәләмов...

Китап киштәмдә өлгер солдатлар сыман тигез сафта тезелешеп торган «Алтын йолдыз», «Газинур», «Сүнмәс утлар», «Мәңгелек кеше», «Ак чәчәкләр», «Ак төннәр» һәм «Хәтер» исемле китапларына карап-карап торам да, ничәнче тапкыр инде сокланып куям, күңелемдә горурлык хисләре тоям. Язучының никадәр көч һәм хезмәт куйганлыгын, йокысыз төннәр, иҗат газаплары, тормыш мәшәкатьләре кичергәнлеген күз алдыма китерергә тырышам. Кайчагында үземне олы әдип урынына куеп үз-үземә: «Ул нишләр, ничегрәк язар, нинди рәк карарга килер иде икән бу очракта?» — дигән сорау бирергә батырчылык итәм. Аннары, иң кыен вакытларда, киштәмдәге әлеге китапларны берәм-берәм актарып чыгам, шушы сорауга гына түгел, үземнең тормышымдагы башка төрле нәрсәләргә, иҗатымдагы чишелмәстәй тоелган мәсьәләләргә җавап эзлим. Ничәмә-ничә кат укылган әсәрләрне укыган саен яңалык ачам, элек күрмичә узган үзенчәлекләрен күрәм, элек тоймаган тойгыларга чумам. Кайчагында өстәлемнең түрендә кадерләп саклана торган кызыл тышлы папканы алам. Ул юка гына, анда бу юллар авторының язмышына зур йогынты ясаган ике газета мәкаләсе һәм машинкада басылып каләм белән тигезсез хәрефләр төшерелгән — кул куелган берничә хат, күңелгә шундый-шундый якын хатлар ята.

Габдрахман Әпсәләмов...

Минемчә, татар әдәбиятының хәрби-патриотик темага багышлап язылган әсәрләре арасында бу әдип өлеше беренче урынга куелырга хаклы һәм ул шулай да. Безнең буын кешеләре сугыштан соңгы елларда Габдрахман Әпсәләмов хикәяләрен, «Ак төннәр» повестен йотлыгып укыйлар иде. Ул чакларда чыккан җыентыклар инде кулдан кулга йөреп, укудан тузып беттеләр, аларны иң тәҗрибәле букинистлар киштәсендә дә бик сирәк очратасың... Ә язучы өчен моннан да олырак бәхетнең булуы мөмкинме соң? Хәер, Габдрахман Әпсәләмов әсәрләрен безнең буын гына түгел, аннан соң килгән барлык буын вәкилләре дә үз итеп, инәсеннән җебенә хәтле укыйлар, минем моңа күп тапкырлар очраганым бар, ишеткәнем, күргәнем бар.

Язучы — гаять җаваплы исем һәм ул исем кешедән бөтен гомерен, аның һәр бөртеген үзенә багышлауны сорый. Габдрахман Әпсәләмов гомере һәм аның киң күңелле шәхесе язучы исеменә лаек, тулысынча лаек иде.

Габдрахман Әпсәләмовны без бүген яшь каләм тибрәтүчеләрнең иң якын киңәшчесе, олы җанлы, киң күңелле укытучы-остазы буларак та зур хөрмәт белән искә алабыз. Матбугатта басылган мәкаләләрендә булсын, аерым авторларга язган хатларында булсын, ул яшьләрнең иҗаты, димәк, әдәбиятыбызның киләчәге турында һәрвакыт кайгыртып яшәде. Мин моны үз мисалымда да бик ачык тоям.

Күп еллар элек мин Аксубай районының Яңа Үзи җидееллык мәктәбенең алтынчы классында «белем нигезләрен» үзләштерә һәм көн саен кимендә бер «хикәя», яки, алай гынамы, «поэма» язып Казанга — газета редакцияләренә җибәрә идем, кичекмәстән язучы булырга хыяллана идем.

Мәктәптә укыганда кайсыбыз гына шигырь-хикәя язмый да, кайсыбыз гына аларны көн саен диярлек газета-журнал редакцияләренә җибәрми икән? Мин шундыйларның берсе идем. Тик редакция хезмәткәрләренең һәрбер хатка аерым җавап язарга вакытлары таррак булгандыр, күрәсең, яшьләр газетасында эшләүче иптәшләр минем «әсәрләрне» язучы Габдрахман Әпсәләмовка күрсәткәннәр, минем ишеләрнең күплеген әйтеп, барысына да аңлашылырлык итеп, ачык хат язуын сораганнар. Габдрахман Әпсәләмов — яшь буынның кадерен белә торган кеше — рәхәтләнеп риза булган. «Ничек язучы булырга?» — дигән ачык хат Аксубай районы Яңа Үзи җидееллык (хал-

кыбызның сөекле шагыйре Хәсән Туфан хәреф танырга шушы мәктәптә өйрәнгән) мәктәбе укучысына атап язылса да, ул шушы елларда каләм тибрәтүче яшь буын вәкилләренең барысына да исемләнгән иде. Менә ул хат:

Кадерле дустым Газиз Кашапов!

Сез үзегезнең редакциягә җибәргән хатыгызда: «Мине хикәяләр һәм шигырьләр язарга өйрәтегез», дип үтенәсез. Әгәр язучы булырга теләгән барлык яшь иптәшләрне хат язып, берничә киңәш биреп кенә язарга өйрәтеп булса, язучылык эше бик ансат булыр иде.

Сезнең, әлбәттә, самолет күргәнегез бар. Ләкин сез аны йөртә белмисез. Шуңа да карамастан, әгәр Сез: «Апалар, абыйлар, әйдәгез мин сезне самолет йөртергә өйрәтәм!» дип кычкырсагыз, Сездән шаркылдап көләрләр иде. Ә әдәби әсәр язу ул бит, Газиз дус, самолет йөртүдән дә читенрәк, катлаулырак эш. Әдәбият әсәрләре кешеләрне яшәргә, тормышны аңларга өйрәтә, кешеләргә тәрбия бирә. Язучының тормыш тәҗрибәсе, белеме бай һәм тирән булырга тиеш. Әгәр Сезнең, яшьлегегез сәбәпле, тормыш тәҗрибәгез бөтенләй юк икән, белемегез бик кечкенә икән, Сез инде кешеләрне нәрсәгә өйрәтә аласыз? Кешеләргә әйтер өчен нинди сүзләрегез бар Сезнең? Хәзергә әле Сез кешеләрне бер нәрсәгә дә өйрәтә алмыйсыз, Сезнең әле үз фикерләрегез дә юк.

Иң элек, Газиз дус, сезгә укырга, укырга һәм тагын бер тапкыр укырга кирәк. Уку белән бергәттән, тормышны, кешеләрне күзәтегез, тел җәүһәрләрен — халык җырларын, мәкальләрен, әйтемнәрен җыйнагыз, өйрәнегез. Куен дәфтәре булдырыгыз һәм күңелегезгә кызыклы тоелган нәрсәләр турында яза барыгыз. Шигырь, хикәя язу белән артык мавыкмагыз, дәресләрегезгә зыян килмәсен. Хатыгыздан күренгәнчә дә, шигырьләрегездән күренгәнчә дә, Сез әле иҗат итәр өчен җитлекмәгәнсез. Бу әле Сезнең кулыгыздан килми. Бу әле Сезнең киләчәк эшегез.

Сез болай дисез: «Әгәр мин хикәя язарга уйласам, мин аны хыял рәвешендә язарга тиешменме, әллә чын исемен әйтепме?» «Алтын йолдыз», «Газинур» романнары ничек язылган? — дип сорыйсыз.

Сезнең беренче соравыгыз, тыштан караганда, хаклы да. Безнең әдәбиятта турыдан-туры тормыштан алынган әсәрләр белән бергәттән, Сез әйткәнчә, «хыял рәвешендә» язылган әсәрләр бик күп. Мәсәлән, А. Фадеевның «Яшь гвардия» романы, Б. Полевойның «Чын кеше турында повесте», Н. Бирюковның «Чайка» романы, Ә. Бикчәнтәевнең «Үлемсезлек» дип аталган әсәре (А. Матросов турында), минем «Газинур» романым һ. б. — болар барысы да тормышта булган, яшәгән, торган урыннары, исем-фамилияләре ачык күрсәтелгән кешеләр турындагы әсәрләр. И. Газиның «Гади кешеләр» романы, Ф. Хөснинең «Авыл өстендә йолдызлар» повесте, Ә. Еникинең «Саз чәчәге» повесте, минем «Алтын йолдыз» романым «хыялый рәвештә» язылганнар. Ләкин бу тыштан караганда гына шулай. Беренчеләрендә дә, икенчеләрендә дә язучы тормыш фактларыннан чыгып эш итә. Беренче төркем әсәрләрдә андагы геройларны тормыш үзе шулай шундый югарылыкка күтәргән, аларда совет кешеләренең уртак сыйфатлары шул кадәр көчле тупланган, алар, язучы тарафыннан гомумиләштерелмичә дә, әдәби әсәр герое булып керә алалар. Икенче төркем әсәрләрдә язучы бик күп кешеләргә хас булган төрле сыйфатларны җыеп, гомумиләштереп, типик образ тудыра, ягъни күп кешеләргә хас сыйфатларны исеме уйлап чыгарылган бер кеше образында гәүдәләндерә. Мондый әсәрләр матур әдәбиятта күбрәк һәм алар тормышны да киңрәк, тирәнрәк күрсәтәләр. Әмма мондый әсәрләрне язу — язучылардан бик зур осталык, бай тәҗрибә, тормыш тәҗрибәсе һәм белем таләп итә.

Киләчәктә, әдәбият теориясен ныклап өйрәнгәч, боларны Сез үзегез дә белерсез һәм бу мәсьәләләрнең хатта язылганга караганда күп тапкырлар киңрәк, тирәнрәк, катлаулырак икәнен дә күрерсез.

Хәзергә мин Сезгә бик тырышып укырга тагын бер тапкыр киңәш итәм. Матур әдәбият китапларын гына түгел, дәресләрегезне ныклап укырга, һәр фәннән бары тик бишле генә алу өчен тырышырга киңәш итәм. Мәктәптә начар укысагыз, Сездән беркайчан да яхшы язучы чыкмаячак. Монысын ачык итеп әйтергә кирәк.

Сезнең мәктәбегездә әдәбият түгәрәге бармы? Булмаса, киләсе уку елыннан шул түгәрәкне оештыру чарасын күрегез. Түгәрәк Сезгә бик зур ярдәм итәр иде.

Язган шигырьләрегезне укытучыларыгызга күрсәтәсезме? Алар белән киңәшәсезме? Алар Сезгә бик зур ярдәм итә алалар.

Тагын бер киңәш, шигырьләрегезне һәрвакыт редакциягә җибәреп тормагыз, ә стена газетасында бастырыгыз. Редакциягә бик-бик яхшы дигәннәрен генә, сайлап кына җибәрергә кирәк. Начар шигырьләрне редакциядә барыбер басмыйлар бит.

Хушыгыз. Дусларча сәлам белән

Г. Әпсәләмов, язучы.

Күренекле әдипнең газетадан пөхтәләп кисеп алынган ачык хаты минем өчен «Әдәбият теориясенә кереш» булды. Ул минем көндәлек дәфтәрләренең битеннән күчә-күчә башта туган авылымдагы җидееллыкны, аннары утыз чакрым ераклыгындагы Иске Ибрай урта мәктәбен бетерде, чирәм җирләрнең кеше аягы басмаган туфрагын күтәреште, Байкал аръягындагы кыялар арасында минем белән бергә солдат чыныгуы алды, Ерак Көнчыгышка барып Амур буендагы тау-урманнарда күкрәккә ятып «пластунча» шуыша-шуыша хәрби белем серләрен өйрәнде, Урта Азиянең кайнар чүлләрен аркылыга-буйга йөреп чыкты, Тянь-Шань тауларына менде, тоташтан дүрт елга якын бер дәверне Мәскәү, Ленинград, Ташкент, Алма-Ата госпитальләренең ак палаталарында яшәү даулашты, ниһаять, туган якларга кайтып Казан университетына укырга керде, Кама буйларындагы гигантларга хәленнән килгән өлешне кертте.

Шушы ачык хат «Татарстан яшьләре»ндә басылып чыгып нәкъ егерме ел узгач та «Казан утлары» журналында минем «Сәмум җиле» повестем дөнья күрде һәм... озак та үтмәде «Социалистик Татарстан» газетасы Габдрахман Әпсәләмовның «Икенче ачык хат»ын игълан итте. Дөрес, аңа кадәр сәламәтлеге начар булуга да карамастан, аның миңа «кош теле» кадәр хаты килеп төште. Соңрак, олы әдип белән очрашкач та ул: «Турысын әйткәндә, мин элегрәк тә кайда йөри икән бу егет» дип уйлап куйгалаган идем»,— диде.

Газиз туган!

Хатың өчен бер рәхмәт булса, «Сәмум җиле» өчен ун рәхмәт. Яхшы, кирәкле повесть язгансың. Рәхәтләнеп укып чыктым. Дулкынландым. Бу хат белән бер үк көнне «Соц. Татарстан» газетасына икенче ачык хат та җибәрәм — беренчесе, моннан егерме еллар элек булган икән. Бик формаль карамасалар, бәлки, басарлар. Шунысы кызганыч, үзем редакциягә бара алмыйм, уңлы-суллы инсульттан соң аяклар йөрми. Тәрәзәдән Иделгә карап ятам. Әйдә, яшьләр бирешмәгез, кыю иҗат итегез, гомер тиз уза.

Үзеңнең сәламәтлек ничек, язып буламы?

Гафу ит, озын яза алмыйм — арыдым. «Ачык хат» басылып чыкса, укырсың, анда тулырак язылган. Әдипкә сәлам.

Сәламәтлек һәм иҗат уңышлары телим. 11 август, 1976 ел. Г. Әпсәләмов.

«Икенче ачык хат» — яшь язучының беренче әсәренә төпле анализ-рецензия. Габдрахман Әпсәләмов кебек зур язучы йөрәгенең олылыгы, әдәбиятка яңа аяк баскан берәүгә игътибар ул. Гомумән, бу факт Габдрахман Әпсәләмовның әдәбиятыбызның бүгенгесе һәм киләчәге өчен чын күңелдән борчылып яшәүче шәхес икәнлегенә бер дәлил иде. Без беләбез: Г. Әпсәләмов яшь язучыларны үз итеп кенә калмады, аларга эчкерсез ярдәм кулын сузды, аларның сәләтен тулырак ачуга зур өлеш кертте.

Икенче ачык хат «Социалистик Татарстан» газетасының 1976 ел 22 август санында басылган.

Моннан егерме еллар элек Аксубай районының Яңа Үзи авылы мәктәбендә укучы, ул чакта бары тик каләм тибрәтүче Газиз Кашаповка беренче тапкыр ачык хат язганмын. Хәзер ул хатның тулы эчтәлеген дә, Газизгә хат язуымны да хәтерләмим. Гомумән алганда, үз гомеремдә әдәбият белән кызыксынучы, киләчәктә язучы булырга хыялланучы яшьләргә язбык хатлар да, ачык хатлар да язмадым. Аларның кайсы җавап бирә иде, кайсысы — юк. Газиз күптән түгел генә хат язды һәм барысын да искә төшерде. Аннары оялып кына өстәгән: барлык киңәшләрегезне дә үтәп булмады, еллар һәм тормыш үз билгесен салды, дигән. Моның өчен, минемчә, һич тә оялырга, уңайсызланырга кирәкми, бу табигый хәл. Әгәр дә Сез барлык киңәшләрегезне дә үтәдем, дип язсагыз, мин ышанмаган булыр идем. Ачык хатта мәсьәлә һәрвакыт киңрәк куела, анда әле адресаттан тыш башкалар да укымасмы, киңәшләргә колак салмасмы, дигән яшерен өмет була.

Газиз яшьтән үк әдәбият белән кызыксына һәм Совет Армиясендә офицер булып хезмәт итәргә хыяллана. Соңгы теләгенә ирешә, ул инде өлкән лейтенант. Бишалты ел үтеп тә китә. Ул мәшәкатьле офицер хезмәтен ярата, әтисе кебек бөтен гомерен аңа багышларга уйлый. Ләкин, сугыш еллары күптән үтеп киткән булса да, армия тормышы гаять киеренке... Венгрия вакыйгалары башлана. Совет солдатлары дусларга ярдәмгә ашыгып барганда өлкән лейтенантның машинасын шартлаталар, үзе каты яралана. Госпитальләрдә ятып, аннан армия хезмәтенә яраксыз хәлдә чыгарга туры килә.

«Сәмум җиле» дигән повесть («Казан утлары», 7 сан, 1976 ел) әнә шул вакыйгалар турында. Әсәрнең үзәгендә госпиталь айлары. Башта ук шуны әйтергә кирәк: Газиз Кашапов яхшы, гаять тә кирәкле һәм үзенчәлекле, кабатланмаган һәм оптимистик повесть язган. Вакыйгалар дәһшәтле, фаҗигале булса да, әсәрнең фоны якты, син барысына да ышанасың.

Повесть, күргәнебезчә, автобиографик материалга корылган. Анда фактик дөреслек

ярылып ята. Бу — әсәрнең иң көчле ягы. Газиз Кашапов моңарчы безнең прозада бик аз яки бөтенләй диярлек күренмәгән нәрсәләр турында яза. Мәсәлән, гаять үзенчәлекле Ана образы. Ул кадровый хәрби врач, әле сугышка хәтле үк ире белән бергә чик буе гаскәрләрендә хезмәт итә, аннары без аны Испаниядә — интернациональ бригада сафларында, соңрак Бөек Ватан сугышы фронтларында, сугыштан соң да хәрби госпитальләрдә күрәбез. Шунда, күптән үлгәнгә саналган улы Рамизны (баш геройның исеме шулай) очрата...

Мин повестьның тулы эчтәлеген сөйләп тормыйм — укучылар үзләре укыганнардыр — шулай ук әсәрнең уңай яклары турында да күп язарга җыенмыйм, чөнки рецензия язмыйм — моны бүтәннәр эшләсә эшләр. Минем уйларым киләчәккә төбәлгән, мин Газизнең, язучы буларак, киләчәген күрергә телим.

Моңарчы матбугатта Кашаповның шигырьләре да чыккалаган. Мин аларны, авторының кем икәнлеген белмәсәм дә, укыганмын, ләкин әллә ни игътибар итмәгәнмен. Күрәсең, шигырьне бик үк аңлап бетермимдер. Менә «Сәмум җиле» карт солдатның йөрәген айкап җибәрде.

Татар әдәбиятында сугыштан соңгы армиябез турында проза әсәрләре юк диярлек аз. Ә армия хәзер бөтенләй башка, сугыш заманындагыча түгел. Без, фронтны күргән өлкән буын язучылары, яңа армиябез турында күптән әдәби әсәр көтә идек. Менә, ниһаять, «Сәмум җиле» күренде. Дөрес, бу әсәр дә армия тормышын турыдан-туры тасвирламый, вакыйгаларның төп өлеше госпитальдә бара. Ләкин авторның армияне яхшы белгәне бик нык сизелеп тора һәм киләчәктә армиябез турында яңа әсәрләр күтәргә өметләндерә. Шул нәрсә мине Газиз Кашаповка икенче ачык хат язарга рухландырды.

Монысы мәсьәләнең бер ягы. Армия тормышы шулкадәр катлаулы һәм тирән мәгънәле, аны автобиографик материалга корылган әсәрдә бөтен тулылыгы белән бирел бетерүе кыен. Монда объектив дөреслеккә нигезләнгән әдәби әсәрләр кирәк. Объектив дөреслекнең фактик дөреслектән өстен булуын һәркем аңлый булса кирәк. Дөрес, моны тәҗрибәле художник кына эшли ала. Миңа калса, Газиз Кашапов шул яңа югарылыктагы баскычка омтылырга тиеш. Билгеле, бу кыен эш, ләкин совет офицеры эшләрне җиңел генә хәл итәргә өйрәнмәгән бит. Әдәби эш, сугышчан эш кебек, кыюлык сорый.

Ахыр килеп, армия тормышы турында турыдан-туры язарга кыен икән, Әлмәттә — хәзер Кашапов анда яши, газетада эшли — эшчеләр арасында кичәге солдатлар һәм офицерлар байтак бит. Алар турында язу — шулай ук мактаулы эш.

«Сәмум җиле» повесте турында тагын бер-ике сүз. Киләчәктә аның аерым китап булып чыгуын истә тотып, беркадәр тулыландырасы иде. Ана образын Ватан образы белән эзлеклерәк бәйләргә кирәктер. Болай ул, вакыт-вакыт гади анага охшап китә. Ананың баласына булган мәхәббәтен дә тирәнрәк ачасы иде. Югыйсә ул, хәрби эшне генә белә, нәни баласын ташлап китә кебек ямьсез тойгы кала.

Рамиз госпитальдә ятканда бер тапкыр да сугышчылары турында уйламый, алардан хатлар алмый. Ә бит ул алардан дәһшәтле вакыйгалар башлангач та аерылган иде. Хатлар Венгрия вакыйгаларына тулырак бәя бирергә мөмкинлек ачар иде. Аннары Рамизның ахырдан армиягә кайтырга омтылуын да аклар иде.

Фәгыйләнең дә образ дәрәҗәсенә күтәрәсе бар. Югыйсә, госпитальдә аның роле бөтенләй күренми. Ул Рамизның хатыны гына, ә кешелек сыйфатлары кайда? Фәгыйлә «җаным-бәгыремнәргә» мохтаҗ түгел, ләкин ул авылда бозлы елга буендагыча тагын бер ялтырарга тиеш!

Ниһаять, повестьның телен дә бер карап чыгасы иде. «Янында берөзлексез шәфкать туташы утыра иде», «ике мина кыйпылчыгы», «ике солдат койкасы», «Әллә кайчаннан бирле хәрәкәтсез» кебек җөмләләр — алар байтак — хәрефкә-хәреф тәрҗемә ителгәннәр шикелле.

Менә минем әйтәсе килгәннәр шулар иде. Авторга яңа иҗат уңышлары телим.

Сәлам белән
Габрахман Әпсәләмов

Шунысы әһәмиятле, дистәдән артык ел көчле авырулар белән көрәшеп яшәвенә карамастан, Габдрахман Әпсәләмовның хатларында шәхси мотивлар юк диярлек. Аратирә бер ике сүз кыстырып куя да шуның белән вәссәлам. Бу Язучы урын өстендә ятканда да, үлем белән күзгә-күз очрашып тарткалашкан минутта да, иң әлек язучы икәнлеген онытмады. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул күп эшләде, романнар язды, әсәрләрен яңартып эшләде, республика матбугатында төрле рецензия-мәкаләләр, публицистик чыгышлар белән әледән-әле күренеп торды. Илебез һәм дөнья тормышының бер генә вакыйгасы да аның игътибарыннан читтә калмады. Киң катлам укучылар язучының теге яки бу вакыйгага мөнәсәбәтен күреп килде. Бу язучы шәхесенең иң

актив позициядә торуын, аның һәрвакыт алгы сафта атлавын раслый торган дәлил, әлбәттә... Менә тагын ике хат.

Газиз туган!

Хатыңны алганга байтак булды. Үзем җавап яза алмадым — һаман Идел буенда яттым. Анда аның почтасы да юк.

«Икенче ачык хат»ны укыгансың һәм ошаткансың. Мин бик канәгать. Хатка өстәп тагын шуны әйтәсем килә: әсәрләреңне тиз яз, ләкин ашыкма. Минем үземә дә тиз язасың дип әйтүчеләр булды, ашыкма дип кисәтүчеләр булмады. Ашыгу белән тиз язу — икесе бер нәрсә түгел бит. Моны шәрехләү кирәкмәстер.

Синең планнарың зур, дәртең ташып тора. Һәр җәһәттән уңыш телим. Тик синең дә сәламәтлегең какшаган бит. Эш белән ялның акыллы аралашуын онытып җибәрмә. Картайгач ял итү соң була инде. Син үзең теләп бик кыен эшкә алынгансың икән — язучы эше хәтсез кыен бит ул — физик көчеңне чамала. Мин менә шуны чамалый белмәдем һәм бик иртә егылдым.

Әлмәттә язучылар байтак. Әдип белән Саҗидә яхшы дуслар дип беләм. Аларның киңәшләрен тыңла. Язучыга дуслар бик кирәк. Безнең юллар бормалы, сикәлтәле. Шома асфальт юллар безгә, язучыларга, түгел.

Ярый, киңәш бирү ансат ул. Ләкин кем сиңа укырга киңәш биргәндер, ул кеше мең кат акыллырак. Укымаган кеше язучы була алмый инде. Бигрәк тә безнең заманда. Укуда, иҗатыңдагы кебек, зур уңышлар телим.

Әлмәтлеләргә сәлам.

Хөрмәт белән Г. Әпсәләмов.

29.9.1976 ел. Казан.

Газиз!

Хатың өчен рәхмәт. Яңа урынга — КамАЗга күчеп эшләвең бик яхшы булган. Югыйсә, син дә нефтьче, мин дә нефтьче — атка печән кем сала? Инде ныклап заводны өйрән. Бу җиңел эш түгел, бигрәк тә үзең турыдан-туры заводта эшләмәгәч. Репортер өчен ике атна да җитә торгандыр, ә язучы өчен, кешеләрне өйрәнер өчен еллар кирәк. Кеше бит ул деталь түгел, аның җаны уйнап тора, салават күпере төсләренә кереп күзләрне дә чагылдыра, кайчак сукырайта да. Кыскасы, кешеләргә озак карарга, аларның күңел үзенчәлекләрен анык белергә кирәк. Сиңа, эшчеләрне якыннан белмәгән кешегә, бу башта кыенрак булыр. КамАЗда эшләде ни, нефтьтә эшләде ни, армиядә булды ни — бар да кеше бит дисең. Бу беренче карашта гына шулай. Хәлбуки аларның һәркайсының төсмерләре бар, үзләренә генә хас төсмерләре яши. Язучы үзе тасвирлый торган геройларны биш бармагы кебек белергә тиеш. Моны, зинһар, акыл өйрәтә дип аңлама, тора-бара син үзең дә боларны белерсең. Мин инде ул баскычларны үткән, шуның өчен генә язуым.

Русча эшләвеңә дә күңелең артык кыйналмасын. Әлбәттә, татарча булса каләмең ныграк шомарыр иде, ләкин русча эшләгәндә язучы буларак тәрбияләнүгә файдасы зур аның, моннан файдалана гына бел.

Беренче тәэсирләрең никадәр генә зур булмасын, ашыгып повестька тотынма, аны әкренләп хәзерлә генә, ә кыска хикәяләр яз. Теманы төрле яклап «капшап» кара. КамАЗ кешеләре әдәби калыпларга ничек сыя — анысын да үзең сына. Үз тәҗрибәң үзеңне күп нәрсәгә өйрәтер.

Чаллыда «Ләйсән» әдәби берләшмәсе бар. Син аның утырышларына йөрергә тырыш. Аралашу бик кирәк.

Сәлам белән Г. Әпсәләмов.

12.XI.1977 ел.

Бер баруымда Габдрахман Әпсәләмов аеруча җанланган, йөзендә шатлыклы елмаю билгеләре чалынып-чалынып китә иде. Ул, гадәтенчә, мөлаем елмаеп, үзенең шундый хәлдә икәнлегеннән уңайсызланган төсле:

— Менә, Газиз, яңа әсәремне басабыз диделәр бит әле. Кайбер нәрсәләрне карап чыгуымны, кыскарту-төзәтүләр кертүемне таләп иттеләр.— Язучыга сөйләшеп утыруы да җиңел генә бирелми иде.— Анысын гына инде аның, эшлибез,— диде, авыру куллары белән кульъязма өемен кадерләп сыйпап-сыйпап алды.— Мусалар турында бу әсәр, басылып чыкса, укырсың... Мин алар турында элегрәк тә, Маннурга хәтле үк материал туплый башлаган идем дә, ул керешеп киткәч тә туктаган идем. Еллар үткән саен минем күңелемне борчып торды бу тема. Ниһаять, түземлегем калмады, акрынлап булса да керешим дигән идем, менә, килеп тә чыкты... Кызганыч, көненә өч-дүрт, иң күбесе биш биттән артык баса алмыйм машинкада...

Мин сүзне икенчегә күчерергә ашыктым, чөнки язучының нинди көч белән эшләргә, тормышка ябышуының ныклыгын күрсәм дә, аның хәле көннән-көн йомшарта, авыруга каршы рәнҗүемне кузгата башлаган иде. Озакламый «Агыла болыт» романы «Казан утлары»нда басылып чыга башлады...

Газиз туган!

Хатларыңны алдым. Рәхмәт. «Соц. Татарстан»дагы мәкаләңне дә укыдым. Шулай язгалап торсаң — бик яхшы. Әдәбият күзләүне ярата, берәү дә күрмәсә — ул әкренләп онытыла. Дөньяга чыккан әсәр инде ул кемнең дә булса шәхси әйбере түгел, ул — халык милке, аңа караш та шуның белән аңлатыла. Яхшысын — яхшы, начарын начар диярга курыкмаска кирәк, монда әшнәлек һич ярамый.

«Агыла болыт»ны бик тиз укып чыккансың һәм, дөрес аңлаган булсам, ул синдә начар тәэсир калдырмаган булса кирәк. Мусалар турында күп язылды, ләкин бу әсәр соңгысы түгел, киләчәктә тагын язарлар әле — бу тема мәңгелек.

Аннары тагын шунысы бар: реаль геройлар турында язу җиңел түгел. Без әле аның чын үрнәген таба алганыбыз юк шикелле. Һәрхәлдә мин эзләнәм. «Газинур» да, «Мәңгелек кеше» дә шундый әсәрләр. Мин аларга төрле яклап килергә тырыштым. Жанрны тасвирлау ягыннан кайсы уңышлырактыр — белмим. Бүтән иптәшләр нигәдер игътибар итмәделәр. Ләкин мин ышанам, кайчан да булса тәнкыйть тә бу теманы күтәрер, чөнки мондый әсәрләр торган саен күбәя. Аларга бәясен дә бирергә кирәктер.

Вакытың булганда хат язгала.

Сәлам белән Габдрахман Әпсәләмов

26.2.1978. Казан.

Мәнә аның миңа язган соңгы хаты. Шуннан соң тагын ике-өч тапкыр аның бүлмәсендә сөйләшеп утырсак та, ул инде миннән: «Хатларыңа каршы хат язуы торган саен кыенлаша, Газиз, җавапсыз калдыра дип үпкәләмә, әмма үзең язгалап тор, яме» дип үтенде. Язучының бу хатында да шәхси мотивларга урын юк. Бу хатта да ул бары тик үзенә хас тугрылык белән минем инде китап булып басылып чыккан әсәремне анализлый.

Газиз туган!

«Сәмум»ны укып чыктым. Егет икәнсең, яхшы төзәткәнсең. Гомумән повесть яхшырган, бигрәк тә Ана образы тулы канлы булып чыккан. Бу образ безнең татар әдәбиятында гомумән яңа. Тәнкыйть аңа игътибар итсә бик яхшы булыр иде, ләкин яңалыкны бездә бик үк күреп җиткермиләр.

Ана образы хәзер вакыт-вакыт баш герой булып китә. Ананы артыграк «төзәткәнсең» димим, Рамизга игътибарың кими төшкән. Моңа киләчәктә сизгер булсаң иде. Баш герой — баш герой булып калырга тиеш. Әш монда бер-ике битне кыскартуларыңда гына түгел, баш геройны бөтен әсәр буенча күздән ычкындырмаска кирәк.

Тагын бер нәрсә: бу «сәмум» мәсьәләсе. Башта ул бөтен әсәр буенча сузыла иде кебек. Хәзер ул герой тормышыннан бер эпизод кына булып калган. Синең «сәмумың» табигый күренеш кенә түгел, ул геройның авыруы да. Миңа шуңа син җитәрлек басым ясамыйсың. Ә бу кирәк иде.

Боларны мин киләчәк эшләреңдә искә алсаң иде дип язам — үз әсәрең өстендә өйрәнү бик кирәк ул — монда барысы да аңлашыла. Әйтелгәннәрдән дә күбрәкне аңларсың дип уйлыйм.

Тагын бер нәрсә: сюжет мәсьәләсе. Бу әсәреңдә син аның бик уңышлы вариантын тапкансың. Ана образы сюжетны алып бара. Бу әсәрдә ул аңлашыла да. Киләсе әсәрләреңдә дә кызыклы, укучыны «тотып тора» торган сюжетка аеруча игътибар ит. Укучыны кулдан ычкындырма, чөнки аннары ул гомумән салкын карый башлый, «кызыксынуы» бетә. Ә бит бер язучы да китабын ярты юлда ташлауларын теләми.

Эшеңдә уңышлар телим.

Сәлам белән Габдрахман Әпсәләмов

19.4.78 ел.

Соңгысы итеп әйтәсе килгән сүзем шул: без әле киң күңелле, олы йөрәкле фронтовик язучы Габдрахман Әпсәләмовның иҗат мирасын туплауга, аны киң катлау укучыларга җиткерүгә, хатларын һәм замандашларының хатирәләрен җыеп алуга, бөтен иҗатын бергә туплап өйрәнүгә, әсәрләренең тулы басмасын чыгаруга ныклап керешә алмыйбыз. Безнең фикеребезчә, Габдрахман Әпсәләмовның музеен булдыру турында да ныклап уйланырга кирәктер. Без моңа ни кадәр иртәрәк керешсәк, шуның кадәр файдалырак булыр, дип уйлыйсы килә.

## Уфада культурабыз истәлекләре



**Башкорт дәүләт опера һәм балет театры бинасы**

Ленин урамы, 5-а йорт.

*А. Тимергалина рәсеме.*

# АКСАКОВ ЙОРТЫ

Бу — егерменче гасыр башында, классик архитектура үрнәкләреннән файдаланып төзелгән ике катлы мәһабәт бина. Аны элек Уфада «Аксаков йорты» дип атаганнар. Октябрь революциясеннән соң бу бина берара «Эш һәм сәнаигы нәфисә сарае» дип тә йөртелә һәм шәһәрдәге интернациональ культура учакларының берсенә әверелә. Бу исем җисеменә бик туры килгән. Бинаның сул ягындагы ишектән керсәң, сынлы сәнгать җәмгыятенә эләгәсең. Ә инде төп ишектән кереп, баскычтан берничә басма атлап менгәч — С. Т. Аксаков исемендәге китапханә. Китапханәгә шәһәр халкы теләп йөргән. Анда татар китапларыннан торган аерым бүлек тә булган. Егерменче еллар уртасына кадәр китапханә татар, башкорт язучыларының һәм гомумән культура әһелләренең очрашып фикер алышу урыны була. 1918 ел башында Уфаның татар эшчеләре шурасы (советы) каршысында Сәгыйт Сүнчәләй җитәкчелегендә «Музыка вә драма җәмгыяте» төзелә һәм ул вакытлыча Аксаков исемендәге китапханәдә урнаша. Бу җәмгыять Уфа халкына культура хезмәте күрсәтү, яшь иҗат көчләренә ярдәм итү максатыннан оештырыла. Җәмгыятьнең унбиш пункттан торган уставы да шул турыда сөйли. Бу җәмгыять җирле иҗат көчләре, «Нур» труппасы артистлары һәм башкалар ярдәмендә эшен киң җәелдерә. Ләкин гражданнар сугышы көчәеп киткәч, җәмгыятьнең эше туктала.

Гражданнар сугышыннан соң, 1922 елда Аксаков йортында «Нур» труппасы артисты Гыйлаҗ Казанский тарафыннан оештырылган «Үрнәк» исемле татар драма труппасы эшли башлый. «Үрнәк»тә исемнәре татар театр сәнгате тарихына алтын хәрефләр белән язылган Зөләйха Богданова, Вари Болгарский, Шакир Шамильский, Фәттах Латыйпов һәм башкалар иҗат итә. Монда эшләгән татар труппалары тарафыннан күренекле драматургларыбыз Фәтхи Бурнаш, Мирхәйдәр Фәйзи, Гафур Коләхмәтов пьесалары, атаклы азәрбайҗан композиторы Гозәер Хаҗибәков әсәрләре Уфа тамашачысына җиткерелә. Бу мәһабәт бина диварлары төрле әдәби-музыкаль кичәләрнең җанга якын күңелле гөрелтесен дә үзенә сеңдергән.

1922 елның көзендә Стәрлетамактан күренекле режиссер һәм артист В. Мортазин-Иманский җитәкчелегендәге драма труппасы Уфага күчеп килә. Бу труппа һәм «Үрнәк» үзара кушылгач, «Татар-башкорт труппасы» исеме белән йөртелә. Ә аннан соң, ул «Башкорт дәүләт драма театры» исеме белән, шушы бинада эшли башлый. Хәзерге вакытта анда Башкорт дәүләт опера театры урнашкан. Димәк, халыкка культура хезмәте күрсәтү традицияләре дәвам итә.

*Х. Гобәйдуллин һәм Җ. Миңнуллин тексты.*

# БЕР РӘСЕМНЕҢ ТАРИХЫ



Үзгәртеп кору һәм хәбәрдарлык тарихыбызны дөрес һәм тулырак яктырту мәсьәләсен бөтен кискенлеге белән көн тәртибенә куйды. Шуңа күрә соңгы вакытларда моңа кадәр матбугатта чыкмаган бик күп әдәби әсәрләр, тарихи документлар дөнья күрде. Әлегә кадәр шәхси архивларда саклананнары да шактый аларның. Күптән түгел миңа әнә шундый шәхси архивта сакланган кызыклы бер фоторәсем белән танышырга туры килде. Аны миңа күренекле татар мәгърифәтчесе һәм язучысы Фатих Кәриминең энесе Камилнең кызы Әминә ханым Кәримова бирде. Рәсемдә яшь хатыны белән мәһабәт генерал сурәтләнгән. Фотоның икенче ягында кыскача гына тарихи мәгълүматлар теркәлгән. Анда Кавказ халыкларының патша хөкүмәтенә каршы алып барган милли азатлык көрәшенең җитәкчесе имам Шамилнең улы генерал Мөхәммәдшәфинең 1906 елда Кисловодскида үлүе хәбәр ителә. Шулай ук аның бала вакытында Петербургка китерелеп, хәрби уку йортында — Пажский корпуста укыганлыгы язылган. Аннан соң ул хәрби хезмәттә була. 1984 елда Казанда Мәрьям Ибраһим кызы Апаковага өйләнә. Аларның кызы Фатыймаизәһрә 1912 елда Петербургта тимер юл инженерлары институтын тәмамлаган Мөхәммәд Али Дахадаевка кияүгә чыккан. Мөхәммәд Алиның Туапсе-Армавир тимер юлын төзүдә катнашуы, коммунистлар партиясе сафларына керүе мәгълүм.

Имам Шамилнең улы ничек итеп югары катлау балалары гына кабул ителгән Пажский корпуста укый алган соң? Билгеле булганча, Дагстанда Шамил җитәкчелегендә барган хәрәкәт патша хөкүмәте тарафыннан бастырыла. Әсир төшкән имам сөргенгә җибәрелә. Ул үзәк Россиядә яши, аңа йорт бирелә һәм генералларныкына тиң пенсия билгеләнә. Гомеренең соңгы елларында Шамилгә Мәккәгә хаҗ кылырга барырга да рөхсәт ителә. Әнә шундый «хөрмәтле әсир»нең уллары булганга алар югары дәрәҗәләргә ирешәләр («Знамя», 1988, 1 сан, 198 б.). Аның уллары арасында генерал дәрәҗәсенә ирешкәне — Мөхәммәдшәфи. Кияве һәм кызы өчен Казанның атаклы бае Ибраһим Апаков хәзерге Тукай урамындагы элек «Шамил йорты» дип аталган бинаны салдыра. 1986 елда бу бинада татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай музее ачылды.

Фатыймаизәһрәнең ире революционер М. А. Дахадаев (Махач) 1905 елның февраль-октябрь айларында «Крестьяннар үзәге» исемле яшерен түгәрәк оештыра. Дахадаев (Махач) 1918 елның җәендә контрреволюционерлар тарафыннан Петровск-Порт шәһәрендә атып үтерелә (БЭС, Т. 7. 1972, 493-494 бб.). 1922 елда Петровск-Порт шәһәренә Дагстанның күренекле революционеры Дахадаев (Махач) хөрмәтенә Махачкала исеме бирелә. (БСЭ. Т. 15. 1974, 522 б.)

Әнә шундый кызыклы язмышлар белән бәйләнгән бу фоторәсемнең тарихы.

**Хәсән ГОБӘЙДУЛЛИН.**

Әмирхан Еники

# ЧЫНБАРЛЫК ҺӘМ ТУГАН ТЕЛ

Чынбарлык... нидән гыйбарәт ул?.. Без, ниһаять, ике телле халыкка әйләндек. Ягъни, без хәзер ике телдә — рус һәм татар телендә — сөйләшәбез, укыйбыз, язабыз. Мәгәр рус теле безнең тормышыбызда беренче урында тора. Бу һич тә арттырып әйтү түгел. Чөнки рус теле ул дәүләт теле, шушы телдә эш йөртелә, сөйләшүләр алып барыла, балалар һәм яшьләр шушы телдә укытыла — ул фән теле, техника теле һәм дипломатия теле дә. Кыскасы, бу телне үзләштерү безнең өчен хәзер бер зарурияткә әйләнде — аңсыз инде яшәү дә, эшләү дә мөмкин түгел диярлек.

Шул ук вакытта безнең буыннардан-буыннарга күчә килгән үз телебез дә бар бит әле... Газиз туган телебез!.. Без бу телдә үзара сөйләшәбез, китаплар, газета-журналлар укыйбыз, хатлар язышабыз, эч пошканда җырлап та алабыз. Туган телебездә әле матур әдәбият, театр, җыр-музыка яшәп килә. Әмма шуның белән, телебезне гамәлдә куллану бетә дә дияргә ярый.

Күрәсез, ике телнең функцияләре арасында аерма бик зур. Шушы аерма телнең әһәмиятен дә һәм аңа булган мөнәсәбәтне дә һичшиксез билгели. Татар кешесе, мәсәлән, кая гына бармасын, яшәр һәм эшләр өчен ул беренче нәүбәттә рус телен яхшы белергә тиеш. Ә үз телен белү исә бу кадәр үк зарури түгел — хәзерге шартларда аңсыз да яшәп була.

Минем кулымда статистик мәгълүматлар юк, әмма һич тә икеләнмичә әйтергә мөмкин: татар халкының 60 яшькә кадәр булган иң зур күпчелеге русча сөйләшә дә һәм укый-яза да белә. Чөнки алар барысы да диярлек совет мәктәпләрендә укып, русчаны яхшы ук өйрәнеп чыккан кешеләр.

...Инде 20—30 яшьтәгеләргә килсәк, болар өчен рус телендә сөйләшү яки уку үз телендә сөйләшү-укуга караганда да җиңелрәктер дип уйлыйм. Чөнки бу яшьтәгеләрнең бик күбесе шәһәрләрдә яшиләр, фабрика-заводларда, төзелешләрдә, сәүдә һәм көнкүреш хезмәтендә эшлиләр — ә монда инде, билгеле булганча, беренче нәүбәттә рус теле гамәлдә йөри. Саф үзебезчә сөйләшүче яшьләрне бары авылларда гына күрергә мөмкин, ләкин аларның да урта мәктәп бетергәннәре русчаны да яхшы беләләр. Кыскасы, рус телен белмәүчеләрне авылыннан беркая да чыкмаган 70—80 яшьлек картлар һәм карчыклар арасында гына очратырга була. Мәгәр алар да күпмедер вакыттан соң «ахирәткә» китеп бетәчәкләр.

...Әйткәннәрдән күренә ки, рус теле безнең тормышыбызда хәзер беренче урында тора, ул кирәгрәк, ул күбрәк гамәлдә йөри, ә туган телебез исә икенче урында, арттарак, әһәмияте дә аның кечерәйде, кирәклеге дә шактый ук кимеде... Әгәр эшләр шулай барса, аның шигрин күн шикелле, акренләп кечерәя-кечерәя, бөтенләй юкка чыгуы да бик мөмкин. Әлбәттә, бу әле бары юрау гына, андый хәл, ихтимал, булмас, булырга тиеш тә түгел, әмма куркыныч бар, шуны тою безне менә ирексездән хәвефләнергә мәҗбүр дә итә.

Кыскасы, хәзерге көндә тел мәсьәләсендәге чынбарлык әнә шуңардан гыйбарәт. Әйтергә кирәк, безнең ике телле халыкка әйләнүебез ул күптән башланган процесс. Бу процесс аеруча сугыштан соң көчәйде. Хәтеремдә, илленче-алтмышынчы елларда татар урта мәктәбен бетерүчеләрнең күбесе рус телен тиешенчә белмәү аркасында вузларга керә алмый башладылар, хәтта алтын медаль белән килүчеләр дә конкурстан үтә алмыйча калгалыйлар иде. (Чөнки телдән имтихан биргәндә бернинди ташлама юк иде аларга). Инде нәкъ шул елларда ата-ананың баласын үзләре теләгән телдә укытырга хаклары бар дигән мәгълүм закон чыккач, шәһәр җирендәге татарларның бик күбесе балаларын тизрәк рус мәктәпләренә бирә башладылар. Һәм бу бик табигый иде, чөнки һәркем иң элек баласының киләчәген кайгыртырга тиеш иде. Нәтиҗәдә шәһәребездәге татар мәктәпләре бушап кала, ә дүрт-биш елдан инде алар ябылып та бетәләр. Шулай да татар балаларын туган телдән бөтенләй мәхрүм итмәс өчен ниндидер чара күрергә кирәк иде. Ахырда безнең мәгариф органнары бердәнбер чара рәвешендә рус мәктәпләрендә туган телне өстәмә дәрес итеп керттеләр. Дәрес, мәҗбүри түгел, имтихан бирәсе юк, өлгергәнлек аттестатына кермәячәк. Нинди бала бөтен дәресләрдән соң калып, шул «өстәмә» дәрестә күңел биреп утыра алсын ди?!. Һәм шушы бала өчен дә, укытучысы өчен дә бәрәкәтсез газаплы бер

эшкә әйләнгән «дәрес» менә 20—25 елдан бирле инде дәвам итеп килә... Ихтимал, кайбер аралаш мәктәпләрдә мондый укытуның зур тырышлыклар аркасында күпмедер уңай нәтиҗә биргәне дә барыр. Ләкин без моны ачык кына белмибез, гомуми хәлне чагылдырган мәгълүматлар да юк бугай, ә менә шәһәр мәктәпләрендә «өстәмә дәрес» алган татар яшьләреннән үз телендә юньләп сөйләшә белмәүчеләрне, кызганычка каршы, елдан-ел күбрәк очратабыз.

Безнең төп таянычыбыз моңарчы авыл мәктәпләре иде, шуннан чыга иде туган телне яхшы белүчеләр дә. Авыл әле үз телендә сөйләшә, баласын да бишектән үк үз телендә тәрбияли. Ә моның әһәмияте гаять зур, бала урта мәктәпне бетергәнче үзенең табигый мохитендә яши, укыту сыйфаты әллә ни югары булмаган тәкъдирдә дә ул инде ана телен гомерлеккә өйрәнеп, белеп кала. Шуның өстенә әле ул рус телен дә 8—10 ел буена укып, яхшы ук үзләштереп, чын грамоталы кеше булып чыга. Ата-ана да канәгать, үзе дә бик канәгать — теләсә кая бара, теләсә нинди эшкә керә ала ул хәзер!..

Бу табигый процесс иде. Авыл һәм аның мәктәпләре безгә моңарчы милли җирлегеннән аерылмаган заманга яраклы кешеләрне биреп килде. Әмма соңгы 15—20 ел эчендә республикада төзелгән яңа шәһәрләр авылны бик нык суыра башлады. Күпме кызлар һәм егетләр шул шәһәрләрнең торак йортларына, баракларына күчеп беттеләр. (Мин инде аңа кадәр Бөгелмә, Әлмәт, Алабуга, Чистай кебек иске шәһәрләргә күчкәннәрне әйтеп тә тормыйм). Хәзерге вакытта халкыбызның 70 проценты шәһәрләрдә тупланган булырга тиеш. Шунда яңа гаиләләр оеша, шунда уку яшенә җиткән меңнәрчә балалар үсә. Ә татар мәктәпләре юк, булганнары ябылган. Тагын балаларны «ата-ана теләге» дигән булып рус мәктәпләренә бирәләр, тагын шул ук бәрәкәтсез «өстәмә дәрес» белән ана телен укытып маташалар. Бала өчен бик кирәкле милли җирлек югала, телләрне үзләштерүдәге табигый процесс бозыла, нәтиҗәдә андый мәктәптән үз телендә юньләп укый-яза белмәгән космополитлар җитешеп чыга.

Баланы «ата-ана теләгән телдә» укыту милли телләрне чикләүгә, кысрыклауга китерәчәген алдан күрергә мөмкин идеме? Әлбәттә! Миңа калса, бу законны да моңарчы илебездә хөкем сөргән административ-бюрократик аппарат тудырган булырга тиеш, чөнки аның өчен бер генә телдә эш йөртү һәр җәһәттән һичшиксез уңайрак булгандыр. Билгеле, бу — милли телләр мәсьәләсендә Ленин принципларын бозу иде. Әгәр моннан соң да эшләр шулай барса, безнең яңадан бер телле халыкка әйләнеп калуыбыз бик ихтимал. Тагын берничә буыннан без, бәлки, рус теленә күчеп тә бетәрбез. Нәрсә югалтабыз?.. Туган телебезне,— бары шул гына... Әмма телне югалту ул милләт булудан туктау дигән сүз. Чөнки халыкны милләт иткән нәрсә — аның теле, шушы телдә тудырган милли мәдәнияте, шушы тел белән бәйләнгән гореф-гадәтләре, әхлакый кагыйдәләре — болардан башка милләт төшенчәсе үзенең мәгънәсен югалта. Кайбер «интернационалист», бәлки, әйтер дә: бик әйбәт, бөек рус культурасына күчәбез, үзебезнең иске культурадан да шәпләрен алырбыз, дияр. Ләкин бу — нәсел-нәсәбен югалткан демагог сүзе. Беренчедән, чын мәгънәсендә интернационализм булсын өчен иң элек милләтләр яшәргә тиеш. Икенчедән, рухи байлык нинди телдә тудырылган булса, бары тик шул телдә генә аның кадере һәм кыйммәте дә. Тукаебызны гына алыйк, ул үз телендә бөек, үз телендә укыганда гына аның бөтен шигърияте тоеп, ләззәтләнеп булачак. Бүтән телдә ләззәтләнү түгел, мәгънәсен дә дөрес кенә аңлап булмаячак (сыналган нәрсә). Аннары бер халыкның рухи хәзинәсеннән чүпләп кенә алган байлыкны икенче телдәге хәзинәгә күчереп булачак дип ышану — кысыр хыял, үз-үзеңне алдау гына ул... Без әле хәреф алыштыру нәтиҗәсендә генә күпме байлыгыбыздан аерылдык.

Шулай да мин туган телебезнең хәзерге хәвефле хәлен татар балаларының рус мәктәпләренә күчеп бетүләренә генә кайтарып калдырмас идем. Мондый хәлгә китереп җиткергән безнең үз хаталарыбыз да аз булмады. Шуларның берсе һәм иң зурысы — кыска гына вакыт эчендә ике мәртәбә хәреф алыштыру булды. Ашый торган ризык шикелле һәркемгә кагылган бу гаять мөһим, тәвәккәл чара халык хөкеменә куелмыйча гына хәл ителде ул чакта... Ә кирәк булган халык хөкеменә кую, бик кирәк булган икән!..

Дөрес, латинга күчәр алдыннан бәхәсләр бик күп булды. Күпчелек күчү ягында иде — бигрәк тә укучы яшьләр. Мәгәр тел галимнәре һәм өлкән буын язучылар күчүне мәгъкуль күрмәделәр. Аеруча Галимҗан Ибраһимов хәреф алыштыруның вакытсыз, кирәксез, хәтта зарарлы икәнен теше-тырнагы белән дигәндәй исбат итәргә тырышты. Халыкны уку-язудан гына түгел, гасырлар буенча җыела килгән рухи мирастан да аеру булачагын, моның культура революциясе барган чакта һич ярамаячагын кат-кат әйтеп чыкты. Латинга күчүнең вакытлы гына булачагын, иртәме-соңмы, барыбер руска күчәргә туры киләчәген дә ул алдан кисәтеп куйды.

Әмма без һичнигә карамастан, тәвәккәл адымны ясадык. Нәтиҗәсе ни булып чыкты? Культура революциясе вакытында (егерменче — утызынчы еллар арасында), ликбезлар аша халкыбызны камилләштерелгән гарәп әлифбасы белән грамотага өйрәтүебез җилгә очты, элегрәк мәктәп бетергәннәр укуязудан мәхрүм ителде, киләчәк буыннар исә бөтен язма мирасыбыздан аерылды да куйды. Ләкин монда бичара гарәп хәрефләренең бер гаебе дә юк иде. Шулар ярдәмендә

коръәнне генә түгел, Ленинны да бик җиңел укып була иде. (Алыштырган чакта гарәп хәрефләрен безгә дин белән килгән дип яманладылар, әйтерсең, башка хәрефләр дин белән таралмаган.) Ун елдан соң, латиннан руска күчкәндә инде бернинди дә шау-шу булмады, тыныч-шома гына үтте дә китте бу эш... Хәер, бәхәскә керерлек кешесе дә калмагандыр — Галимҗан Ибраһимовлар юк иде инде ул чакта.

Рус хәрефләренә күчкәндә нинди максат беренче нәүбәттә күздә тотылды?.. Күчүнең файдалы яклары турында сүз күп булды, әмма иң төп максат — рус теленә якынаю, рус телен өйрәнүне җиңеләйтү иде. Шушы максаттан чыгып, бездә рус әлифбасын үзгәртмичә генә кабул иттеләр, тик ахырына кайбер җитмәгән авазлар өчен рус шәкелләрен үзгәртебрәк хәреф өстәделәр, мәгәр телебездә иң күп очрый торган ике авазга — каты «г» белән каты «к»га — аерым шәкел бөтенләй алынмады да. Бу исә һәрбер тел өчен зарури булган канунны бозу булып чыкты: телне бит әлифбага түгел, ә әлифбаны телгә яраклаштыралар. Башка төрки халыклар рус хәрефенә күчкәндә шулай эшләделәр дә. Ә без менә күпме еллардан бирле инде телебезнең табигатенә туры килмәгән әлифба һәм гарип орфография белән яшәп киләбез.

Күчүнең янә бер нәтиҗәсен без алдан күрә белмәгәнбез. Әйткәнемчә, күчү рус телен өйрәнүне бик җиңеләйтергә тиеш иде бит. Әмма ике тел өчен дә хәрефләрнең бер үк булуы, өйрәнүне җиңеләйтүдән бигрәк, туган телне ташлап, рус теленә күчүне генә ансатлаштырды. Һәм моңа гаҗәпләнергә дә туры килми, чөнки уку-язу рәвеше белән русчадан һич тә аерылмаган ана телен өстәмә дәрескә калып, өйрәнеп утыруның бала өчен бер дә кызыгы юктыр, дип уйлыйм. Бала бит ул бер-берсенә охшамаган нәрсәләр белән күбрәк кызыксынырга ярата...

Билгеле инде, бу әйткәннәрем искегә кайтуны дәгъва итү түгел, һәм ул мөмкин дә түгел, тик шулай да без бер хакыйкатьне аңларга тиешбез: һәр халыкның мәдәни үсеше, шул җөмләдән мәгариф эшләре дә, өзлексез бара торган табигый бер процесс ул. Бу процесска яңалыклар өстәлүе, реформалар керүе мөмкин, иллә мәгәр ун ел эчендә ике мәртәбә хәреф алыштыру кебек табигый барышны шартлатып өзгән кинәт сикерүләр булмаска тиеш. Шул чагында гына көтелмәгән югалтулардан һәм авыр торгынлыклардан сакланып булачак.

Яңадан төп мәсьәләгә күчик. Югарыда әйтелгәнчә, без хәзер ике телле халыкка әйләндек. Бу әйбәт, бу кирәк, бу — заман таләбе... Рус теле ярдәмендә безнең халыктан күпме югары белемле белгечләр һәм галимнәр җитешеп чыкты (академикларга кадәр). Киләчәктә дә алар елдан-ел арта гына барачак. Тик бу үз телебезне оныту, ташлау исәбенә булмаска тиеш. Татар халкы гасырлар буена сузылган иң караңгы, иң авыр чакларда да үз телен, иманы шикелле, саклап килде, хәтта көчләп чукындырылганнары да үзенең газиз теленнән аерылмады. Революциядән соң туган телебез, яңа канатлар чыккандай, аеруча бер үсү, күтәрелү чорын кичерде... Кызганыч ки, бу озакка бармады. Ленин үлеменнән соң башланган тискәре үзгәрешләр әкренләп милли мөнәсәбәтләрнең ленинчыл принципларын бозуга да китерде. Ә торгынлык заманы исә бөтен нәрсәгә битараф, бөтенесенә күнеккән халыкны ирексездән «денем өчен түгел, көнем өчен» дип яшәргә өйрәтте. Бары шушы «көнем өчен» дип кенә яшәүнең аяныч бер нәтиҗәсе дип карыйм мин телебезнең бүгенге авыр хәлен дә.

Интернационализм — зур сүз, күп кырлы сүз. Без бу сүзне еш кулланырга яратабыз, ләкин кайчагында бер яклырак кына итеп тә... Мәсәлән, халыклар дуслыгы турында сүз чыкканда, без гадәттә зур төзелешләрдә, әйтик, КамАЗны салганда, күпме милләт кешесе катнашуын беренче нәүбәттә мисал итеп китерәбез. Әйе, бу мисал интернационализмның мөһим бер ягын һичшиксез чагылдыра. Әмма шуның белән генә чикләнәме соң ул?! КамАЗ әйләнәсендә өр-яңадан төзелгән Чаллыда хәзер 500 мең чамасы халык яши ди. Шуның биш кенә проценты, ягъни егерме биш мең е башкорт яки чувашлар ди. Менә шул башкортларга яки чувашларга балаларын үз телләрендә укытырга мәктәп бармы, бу халыклар өчен шәһәрдә аерым китапханә ачылганмы, үз телләрендә Уфада яки Чабаксарда чыккан газета-журналларга алар языла алалармы?.. Әгәр боларның берсе дә юк икән, ул чагында нинди интернационализм турында сүз булырга мөмкин? Хикмәт бит төрле халыкларның бер җиргә җыелып, бергә эшләүләрендә генә түгел. Иң мөһиме — һәр халыкның, үз илендәме, читтәме, бер үк тигез хокуклар һәм мөмкинлекләр белән гамәлдә файдалана алуында. Чын интернационализмны шулай аңларга кирәктер, минемчә.

Безнең татар халкы өчен моның әһәмияте тагын да зуррак. Мәгълүм булганча, алты миллионнан артыграк халкыбызның 75 проценты Татарстаннан читтә яши. Ул чиксез зур илебезнең бөтен почмакларында яши. Әмма ул, таралып яшәвенә карамастан, бөтен бер милләт. Һәм кайда гына яшәмәсен, телен, язуын, мәдәниятен саклаган халык иде. Революциягә чаклы ук әле ул Петербург һәм Мәскәүдән алып, бөтен Идел буе, Урал, Себер, Урта Азия шәһәрләрендә үзенең мәктәпләрен ачты, балаларын ана телендә укытты. Төрле шәһәрләрдә аның бөтен Россиягә даны таралган зур мәктәп-мәдрәсәләре бар иде. Күп шәһәрләрдә та-

тарча китаплар басыла, газета-журналлар чыга иде. Болар барысы да билгеле нәрсәләр, тик шуны гына өстәп әйтик,— татар халкының бу бөтенлеге утызынчы елларга кадәр әле сакланып килде. Административ чикләр дә моңа комачаулык итмәгән иде.

Шуннан соң күп сулар акты, күп җилләр исте, күп хәлләр баштан кичте, дөньябыз да бик нык үзгәрде. Боларны яза башласак, сүз бик озынга китәчәк. Җыеп кына әйткәндә, без, 6 миллион халык, һәр җәһәттән бер милләт булсак та, күптән инде элеккеге бөтенлекне югалттык, үзара бәйләнешләр өзелеп бетте диярлек. Һәм моның уку-укыту эшләренә дә, гомумән культурабыз үсешенә дә тискәре йогынтысы менә хәзер күз алдыбызда. Элек, мәсәлән, безнең әдәбиятка һәм сәнгатькә яңа көчләр төрле яктан килеп тора иде (Тамбовтан — Такташ, Оренбургтан — Муса, Уралдан — Туфан), хәзер инде мондый талантларның читтән килүен көтеп тә булмый. Сәбәбе дә билгеле. Әлеге күпләп татарлар яшәгән зур һәм кече шәһәрләрдә татар мәктәпләре ябылып бетте. Хәтта кайчандыр үзенең мәктәп-мәдрәсәләре белән дан тоткан Оренбург, Уфа, Троицк кебек шәһәрләрдә дә ана телендә мәктәп юк, калмаган... Ә бит халык бар, халык беркая да китмәгән, кайда укыта ул хәзер баласын?.. Тел бит ул буыннан-буынга күчә торган нәрсә. Әгәр шушы бәйләнеш өзелсә, (ә ул өзелгән инде), моның ахырын күз алдына китерүе читен булмас дип уйлыйм.

Бу язганнардан нәтиҗә ясап, нәрсә әйтәсе калды? Әйе, без хәзер ике телле халык. Әмма тормышыбызда аларның тоткан урыннары бер түгел — аерма бик зур. Үткәндәге хаталар, соңгы елларда көчәйгән игътибарсызлык, сансызлык аркасында, бигрәк тә совет һәм партия аппаратларында утыручыларның нигилистик мөнәсәбәте нәтиҗәсендә туган телебезне бүгенге хәвефле хәленә китереп җиткердек. Шәһәрләрдә мәктәпләрнең ябылып бетүе, рус мәктәпләрендә туган телгә бик кечкенә урын бирелүе, авыл мәктәпләрендә дә укыту сыйфатының түбән булуы әлеге хәвефне тагы да көчәйтә төште. Ниһаять без туган телебезне әкренләп югалту куркынычын тоя башладык.

...Милли телләрнең бүгенге хәле бөтен җирдә дә бер төсле генә түгелдер, билгеле... Мәсәлән, Азәрбайҗанда җиңелрәк, ә бездә, киресенчә, авыррак булуы мөмкин. (Чөнки шартлар һәм мөмкинлекләр башка). Бездәге хәлләр исә беренче нәүбәттә бездән туган телебезне тигез хокуклы итүне, үз урынына куюны, аның абруен күтәрүне таләп итә. Әмма моңа ирешүе җиңел булмаячак. Бигрәк тә шәһәр шартларында, чөнки мондагы ата-аналарны без балаларын ана телендә укытмаска өйрәтеп бетердек. Мәсьәләнең читен-четерекле ягы да әнә шунда. Мәгәр бөтен карарлардан да өстен, барлык халыклар өчен дә уртак, табигать бирмеш янә бер закон бар әле: бала бер генә телле булып туа һәм бу тел аңа анасыннан күчә. Шуңар күрә дә ул туган тел (родной язык) дип атала. Һәм бөтен дөньяда баланы укырга, язарга өйрәтү дә иң элек туган теленнән башлана. Без менә шушы тәртипне боздык түгелме?

Бу мәкалә партия Үзәк Комитетының Февраль (1988 ел) пленумына чаклы ук язылган иде. Аннан соң менә партиянең XIX конференциясе дә булып узды. Конференция, билгеле булганча, милли мөнәсәбәтләр турында махсус карар да кабул итте. Көтеп алынган бу карар безне борчыган күп мәсьәләләргә зур ачыклык кертте. Аны укып, танышып чыкмаган кеше юктыр дип беләм. Цитаталар китереп тору да кирәк булмас дип уйлыйм. Тик карарның тел мәсьәләсенә кагылган өлешенә генә игътибарны тупламакчы булам, чөнки минем бу мәкаләмдә, башыннан ахырына хәтле диярлек, туган телебез язмышы турында сүз барды.

Конференция карары телләргә карата нәрсә әйтте соң? Җыеп кына алганда, аның әйткәне ике төп моментка кайтып кала: беренчесе — милли телләр яшәргә, тәрәккый итәргә, тигез хокуклы булырга һәм гамәлдә кулланганда шул хокук белән тулысынча файдаланырга тиешләр. Ягъни милли телне бер яктан да, берничек тә чикләү булмаска тиеш — шулай өстәп аңлатасым килә минем бу моментны. Икенчесе — һәр халык үз теле белән бергә рус телен дә өйрәнергә һәм белергә тиеш. Рус теле ул күп милләтле безнең илдә халыкларның үзара аралашу теленә әйләнде, шуңа күрә аны белү, алда әйткәнемчә, үзе бер заруриятькә әверелде. Кыскасы, һәрбер милләт кешесе безнең шартларда ике телле булырга тиешле. Карарда тагын менә мондый сүзләр дә бар: туган телне өйрәнү һәм куллану хокукы үз республикасыннан читтә яшәүчеләргә дә бирелә. Безнең татар халкы өчен бу исә аеруча мөһим момент.

Инде әнә шул бик әһәмиятле карар нигезендә без нәрсә эшләргә тиешбез?.. Билгеле, һәр милләт тел мәсьәләсен үз ихтыяҗыннан чыгып хәл итсә кирәк. Безгә дә үзебездәге хәлләрдән чыгып уйланырга кирәк булачак. Ә хәлләрнең ни дәрәҗәдә хәвефле булуын без югарыда күреп уздык инде. Туган тел мәсьәләсе ул хәзер асылда татар халкының милләт буларак саклануы белән бәйләнгән утә җитди бер мәсьәләгә әйләнеп бара диярлек дә ярый. Арттырып әйтүем түгел, чынбарлык үзе безне шулай уйларга мәҗбүр итә; ялгышсам, бик әйбәт, әмма тыныч, ваемсыз булырга безнең хакыбыз бармы соң? Дөресен генә әйткәндә, телебезне әкренләп югалта баруны без инде күптән күреп килә идек, мәгәр милләтчелеккә гаепләнүдән куркып, озак еллар ул хакта дәшми йөрдек. «Милләт» дигән сүз өчен дә

авызга сугарга торган ортодоксаль догматиклар моңарчы һаман да булып торды, хәзер дә әле алар юк түгел, ләкин инде бүгенге шартларда алардан, Тукай әйткәнчә, «курку белән өркү хәрам».

Кыскасы, тел язмышы — милләт язмышы. Менә шуннан чыгып, без тел мәсьәләсен хәл итәргә дә тиешбез. Ничек итеп?

Әйткәнебезчә, без хәзер ике телле халык. Инде шушы ике телнең кайсысына игътибарны юнәлтергә, кайсысы анык менә хәзер «ашыгыч ярдәмгә» мохтаҗ?

Рус телен белүнең кирәклеген һичкем инкарь итмәячәк, аны белү — тормыш таләбе, шуңа күрә дә аны барлык мәктәпләрдә бик интенсив рәвештә укыталар да. Димәк, рус телен белмичә калу куркынычы бездә юк.

Ә туган телебезне укытуның никадәр түбән, зәгыйфь икәнен без инде күреп уздык.

Уз тарафымнан мин кичектергесез зарури чаралар итеп түбәндәгеләрне тәкъдим итәр идем: 1) баланы бары ана телендә укыта башларга; 2) бөтен сабакларны да саф ана телендә укыту дүртенче сыйныфка чаклы, ягъни башлангыч мәктәп программасын тәмамлаганчы дәвам итәргә тиеш; 3) рус телен балаларга икенче елдан гына укыта башларга. Шулай иткәндә бала үз телен, башка тел белән бутамыйча, җиңелрәк үзләштерәчәк. Рус телен үзләштерүе дә соңга калмаячак — бала бит аны урта мәктәпне бетереп чыкканчыга кадәр укыячак.

Татар балалары шул рәвешчә башлангыч мәктәп программасын үткәннән соң, теләгән мәктәпләренә күчеп, укуларын дәвам иттерә алачаклар. Шәһәрләрдә алар, билгеле, рус мәктәпләренә күчәрләр. Бик әйбәт, гимназиягә кергән шикелле булыр. Әгәр эш шулай куелса, бу беренчедән, татар баласын үз теленнән мәхрүм итеп калдырмаячак, икенчедән, әлеге «ата-ана теләге» дигән принцип та әллә ни бозылмаячак. Мәгәр эшне әнә шушылай оештыру ул тулысынча дәүләт органнары өстендә. Партиянең XIX Бөтенсоюз конференциясе карары моның өчен аларга тулы хокук та бирә һәм алардан чын эш тә таләп итә.

Конференция карарының тагын бик мөһим бер моментына тукталыйк. Сүз бирелә үз республикаларыннан читтә яшәүчеләрнең милли ихтыяҗларын үтәү турында бара. Карар менә шуларга да үзләренең милли ихтыяҗларын үтәргә, ягъни балаларын ана телендә укытырга, иҗади эшләренә мәйдан ачарга, культура учакларын булдырырга, шулай ук диннәрен тотарга да хокук һәм мөмкинлек бирә. Бирү генә түгел, бу эштә аларга булышлык күрсәтергә чакыра. Тик менә күптән көтелгән гаять кирәкле шушы карардан ничек итеп файдаланырга?

Яшереп торуның һич тә кирәге юк, төрле республика һәм өлкәләрдә күпләп яшәүче халкыбызның милли ихтыяҗларын үти алу мөмкинлеге бик кысылды, тарайды, бетте, дисәк тә була. Төрле шәһәрләрдәге кайчандыр гөрләп торган культура учаклары да күптән инде сүнде. (Оренбург, Әстерхан, Троицк, Уральскиларны искә төшерү дә җитә). һәм кайчандыр мәктәп-мәдрәсәләр аша, матбугат, әдәбият ярдәмендә яшәп килгән җанлы бәйләнешләр дә өзелде, онытылды, бердәмлек тә югалды — хәзер инде татарны бөтен бер милләт дип атавы да читен. Сталин заманыннан ук башланган бу аеру, таркату, кысрыклау безнең халыкны бүгенге торгынлыкка китереп тә җиткерде.

Әмма хәзер аңа яңадан терелергә, милләт буларак, үзенең рухи ихтыяҗларын үтәргә мөмкинлек бирелә. Моны партия инициативасы белән башланган үзгәртеп коруның гүзәл бер нәтиҗәсе итеп кабул итәргә кирәк. Инде эш бүген шушы мөмкинлектән файдалануга кайтып кала.

Әмма бу әйтергә генә ансат. Күптән сүнгән учакларны кем кабызыр, әллә кайчан ябылган мәктәпләрне кемнәр ачар? Инициатива бит һәр шәһәрнең, һәр төбәкнең үзендә туарга тиеш. Башлап йөрүчеләр кирәк булачак... Билгеле, алар табылыр, табылмыйча калмас, хәтта яшьләр арасыннан да, чөнки милли рух ул тиз генә сүнә торган нәрсә түгел. Бәлки әле алар берәр төрле законлы оешма төсен дә алырлар, үзләренең таләпләрен җирле оешмалар алдында да куярлар. Ихтимал, каршылыкларга да очрарлар. Бездә бит бер эш тә ансат кына эшләнми. Бюрократизм көчле, азаплар күп... Озын сүзнең кыскасы, минем әйтергә теләгәнем шул: татарлар яшәгән җирләрдә туачак бу табигый хәрәкәткә ниндидер бер үзәктән ярдәм итү кирәк булачак. һәм бу ярдәмне иң элек Казаннан көтәчәкләр. Казан,— татар халкының мәдәни үзәге булу белән бергә, ул — Татарстан дигән автономияле республиканың башкаласы да. Димәк, ярдәм дә бездән барырга тиеш. Ничек, ни рәвештә — культура һәм мәгариф министрлыклары ашамы, яки моның өчен махсус берәр идарә төзү кирәкме,— бу кадәресен безнең җитәкче органнар уйларга тиешләр. (Тик иске гадәт буенча инициатива күрсәтүдән, җаваплылык алудан куркып тору булмасын иде.) Әлбәттә, җәмәгатьчелек тә бу эштән читтә калмас дип ышанасы килә. Хәзерге вакытта табигатьне саклау, тынычлыкны саклау, культура истәлекләрен саклау кебек киң җәмәгатьчелекне үзенә тарткан җәмгыятьләр барлыкка килде. Милли культураларны саклау-үстерү дә әнә шундый кичектермәс бер эшкә әйләнде дияргә ярый. Кайда гына яшәмик, без бөтен бер халык, аралашырга да, ярдәмләшергә дә хакыбыз бар, бүгенге хәбәрдарлык һәм демократия шартларында административчылар моңа комачаулык итмәскә тиешләр дип беләм. Чын интернационализм да, XIX Бөтенсоюз конференциясе карарында әйтелгәнчә, халыкларның үзара аралашуы һәм ярдәмләшүе аркасында гына туачак.

**Гомәр Саттаров,**

филология фәннәре докторы, профессор

# ИСЕМНӘРДӘ — ИЛ ТАРИХЫ

Туган республикабыз Татарстан — гаҗәп кызыклы һәм үзенчәлекле регион. Ул иң кимендә биш этник регионның — борынгы сармат-алан кабиләләренең, фин-угыр, төрки, монгол һәм славян халыкларының «контакт зонасы». Безнең планетада иң киң таралган телләрне эченә алган әлеге биш тел төркеменә караган күп кенә кабилә һәм халыкларның тел стихиясе чал тарих дәвамында Татарстан топонимиясе, антропонимиясе, антропотопонимиясе һәм этнотопонимиясенең шактый катлаулы стратиграфик катламнарын тудырган, аларның үзара ныклы керешүләрен, бер-берсенә сиземле йогынтысын барлыкка китергән.

Татар ономастикасын, ягъни тел гыйлеменең барлык төр ялгызлык исемнәрен тикшерә торган тармагын фәнни өйрәнүнең борынгы телебезгә һәм тарихыбызга хас булган үзенчәлекләрне танып-белү җәһәтеннән әһәмиятен ачыграк итеп күз алдына китерү өчен, бу мәкаләбездә татар теле тарихында «шәһәр» һәм «авыл» төшенчәләрен белдергән ойконимик терминнарга һәм алардан ясалган географик атамаларга киңрәк тукталыйк.

Ономастика фәнендә торак пунктларның барлык төрләрен (шәһәр, крепость, авыл, кышлак, җәйләү һ. б.) җыйма рәвештә атау-белдерү өчен *ойконим* термины кулланыла.

Төрки халыкларның байтагының, шул исәптән болгар бабаларыбызның, моннан мең еллар элек үк күчмә тормыштан утрак тормышка күчүләре төрле тип торак пунктлар (шәһәрләр, кальгалар, авыллар, кышлаклар, кәрвансарайлар һ. б.) төзүдә бай тәҗрибә туплауга һәм камил осталыкка китергән. Идел-Кама Болгар иле, Сәмәрканд һәм Харәзм осталары — төзелеш-архитектура әшенең атаклы милли-профессиональ мастерлары — үз илләрендә генә түгел, бәлки тирә-юньдәге дәүләтләрдә дә яхшы билгеле булалар.

Борынгы төрки телдә «шәһәр» төшенчәсен белдерү өчен *тора* һәм *балык* ойконимик терминнары кулланылган.

Борынгы төрки телдә тура (тора) сүзе «ныгытылган торак пункт, крепость-кальга» мәгънәсендә кулланылган. *Тора* («шәһәр») сүзенең барлыкка килүе *тор-тору* «бер урында тору, яшәү, тормыш итү» тамырына барып тоташа. Шушы тамырдан телебездәге торак — «яшәү, тору өчен билгеләнгән бина, бүлмә яки «корылма», торлак — «мал-туар торагы (абзар, кура, кутан һ. б.)» [1], торгызу, тормыш һ. б. сүзләр ясалган.

Себер татарлары телендә (татар теленең көнчыгыш диалектында) *тора* сүзе хәзер дә «шәһәр» мәгънәсен белдерә. Себер татарларының бабалары — кидан-кыпчаклар XI—XII йөзләрдә үк үз биләмәләрен һәм дәүләтләрен барлыкка китергәннәр. «Себердә беренче татар биләмәләре Ишим елгасында була. Башкаласы булып Кызыл Тура («матур шәһәр» мәгънәсендә — Г. С.) санала» [2],— дип яза тарихчы Н. Абрамов.

Төмән шәһәре 1586 елда Тура елгасының уңъяк ярында элекке Чимги (Чинги)-Тура дип аталган шәһәрчек урынында корыла башлаган. Бу полисонимның Чинги өлеше Чыңгыз хан исеменә, ә *тура* татар сүзе «шәһәр», «шәһәрчек», «ныгытылган урын», «крепость»ка кайтып кала, Чинги-Тура — «Чыңгыз шәһәре» мәгънәсен белдерә дигән караш бар [3]. Себер татарлары хәзер Төмән өлкәсендәге бер шәһәрне Яулы тора («гаскәри шәһәр», русча Ялуторовск) дип атаганнар. Томск шәһәрен Том-Тура дип йөртәләр.

---

[1] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 т. Казан, 1981, 118—119 бб. (моннан соң ТТАС)

[2] Абрамов Н. Город Тюмень — Тобольские губернские ведомости, № 50, 1858.

[3] Матвеев А. К. Географические названия Урала. Свердловск, 1980, 255 б.

Г. Ф. Миллер Тобол елгасының сулъяк кушылдыгы Тура елгасы атамасының килеп чыгышын себер татарлары телендәге *тура тора* «шәһәр» сүзенә кайтарып калдыра[4]. Бу елга буенда Верхняя Тура, Нижняя Тура, Верхотурье, Туринск дип аталган шәһәрләр һәм Туринская Слобода (Слободо-Туринск районы үзәге) исемле авыл бар (Свердловск өлкәсе). Түмән өлкәсе Яркәү районында бер борынгы татар авылы Тобол-тура исемен йөртә.

XVI гасыр картасында Кама елгасында Алабуга шәһәреннән өстәрәк Алатур, Уфа елгасында Балатур шәһәрләре урнашкан була (карагыз: Материалы по истории русской картографии. Киев, 1899). Бу Алатыр Сура елгасы буенда (хәзерге Чувашстандагы) Алатырь шәһәре түгел. В. В. Радлов Алатырь шәһәре атамасының этимологиясен төрки *ала* «пестрый»+*тура* «жилище, город» сүзләренә кайтарып калдыра[5]. Э. Б. Булатов: «Алатор һәм Балатор шәһәрләре атамаларында *тор* (тура) сүзе «шәһәр» мәгънәсен (себер татарлары телендәге кебек); *ала (олы)* һәм *бала* сүзләре «зур» һәм «кече», «кечкенә» дигәнне белдерә»[6] — дип яза. Димәк, Алатор атамасы «Олы (зур) шәһәр», Балатор атамасы «Кече шәһәр» мәгънәсен белдерә булып чыга. Төрки топонимиядә *олы-кече, зур-кече* (кечкенә) антонимик сыйфатларның торак пункт исемнәрен ачыклап, аныклап килүче аергыч функциясендә шактый еш кулланулары характерлы. Мәсәлән, Олы Ачасыр — Кече Ачасыр, Олы Кайбыч — Кече Кайбыч, Зур Сәрдек — Кече Сәрдек, Олы Тархан — Кече Тархан h.б. — Татарстандагы авыллар.

Казан ханлыгы чорында Алат юлында Тура, Иске Тура дигән татар авылларының булуы мәгълүм. Бу ойконимнарның асылында да борынгы төрки *тура-тора* «шәһәр, кальга, крепость» ойконимик термины ятса кирәк. Татарстанның Биектау районында Иске Тура, Зеленодольск районында Яңа Тура дигән рус авыллары бар.

*Балык* ойконимик терминының борынгы төрки телдә «шәһәр» мәгънәсендә кулланылышта йөрүе дә «Борынгы төрки сүзлектә» теркәлгән (81 б.). Э. В. Севортян әлеге *балык* сүзенең борынгы төрки телдә тагын: 1) стена, 2) крепость һәм 3) загородь мәгънәсендә йөрүен күрсәтә һәм, С. Е. Малов фикерен куәтләп, килеп чыгышы «балчык» тамырына кайтып кала дигән карашны алга сөрә[7]. Тунгус-маньчжур телләрендәге *балаган* («торак», «шалаш», «йорт») сүзе дә шушы тамырга барып тоташа. Славян һәм төрки телләр белгече И. Г. Добродомов рус теленә *балаган* сүзе XVII гасыр азаклары — XVIII гасыр башларында тунгус-маньчжур телләреннән алынган дип саный. Чуваш телчесе Г. Е. Корнилов палы(къ) «шәһәр, башкала» сүзенең беренчел чыгышын «көтү, өер» төшенчәсенә кайтарып калдыра[8]. Бу мәсьәләдә без С. Е. Малов һәм Э. В. Севортян карашларына кушылабыз.

Татарстан топонимиясендә борынгы төрки *балык* «шәһәр» ойконимик терминына нисбәтле рәвештә Балык бистәсе районының үзәге Балык бистәсе авылы исеменнән барлыкка килгән булырга мөмкин.

Безнең регионда шулай ук «шәһәр» яки «крепость» мәгънәсен белдергән *кар, кирмән, ката-катау* (рус. *катав*), *курган, ор, тау* (соңгысы күчерелмә мәгънәсендә) кебек архаиклашкан ойконимик атамалар җирле топонимнар составында сакланганнар.

*Кар* топокомпоненты «шәһәр», «крепость», «авыл» мәгънәсенә ия булган хәлдә Шупашкар (рус. Чебоксар), Моркар, Муркар, Сыктывкар, Изкар, Кудымкар, Шурымкар, Шурышкар h. б. кебек көнчыгыш фин-угор (коми, мари, удмурт, бесермән, пермяк h. б.) халыклары шәһәр һәм авыллары атамалары составында урын ала. Э. М. Мурзаев *кар* тополексемасы борынгы иран телләреннән килә дип саный[9]. В. Г. Егоров аның архаиклашып, фольклорда һәм топонимикада гына саклануын әйтеп, «шәһәр», «крепость», «авыл» мәгънәсенә ия булуы турында яза[10].

Фин-угыр телләре белгече Т. И. Тепляшина «Топонимы на кар и некоторые вопросы, связанные с расселением бессермян» («Вопросы географии», М., 1970, № 81) дигән мәкаләсендә *кар* компоненты катнашып ясалган топонимнарның Удмурт АССРның нәкъ төньягына — Чепца елгасы бассейнына — утырган бесермәннәрдә күп таралу (ул 34 топоним күрсәтә) һәм бесермәннәрнең бу атаманы көньяктан төрки-болгар сүзе буларак алып килүләре турында яза.

Арча районындагы Кышкар авылы атамасы составында да әлеге *кар* «шәһәр, крепость, авыл» топокомпоненты урын ала: *Кыш* + *кар*, ягъни «кыш чыга торган торак пункт, шәһәрчек яки авыл». Алат юлындагы Кышкар авылының Казан ханлыгы чорында булуы тарихи чыганаклар буенча мәгълүм. Арча районында Кышлау дип

---

[4] Миллер Г. Ф. История Сибири, т. 1. М.—Л., 1937, 193 б.
[5] Радлов В. В. Опыт словаря тюркских наречий, т. 1, часть 1. СПб., 1893, 351 б.
[6] Булатов А. Б. Топонимы и этнонимы Волго-Камья у Ибн Фадлана, Идриси, на карте Каталанского атласа, Фра Мауро и на картах XVI—XVII вв.— Сб.: Ономастика Поволжья. Ульяновск, 1969, 180 б.
[7] Севортян Э. В. Этимологический словарь тюркских языков. М., 1978, 59 б.
[8] Корнилов Г. Е. Евразийские лексические параллели. Чебоксары, 1973, 92 б.
[9] Мурзаев Э. М. Топонимика Синьцзяна.— В сб.: Географические названия. М., 1962, 13 б.
[10] Егоров В. Г. Этимологический словарь чувашского языка. Чебоксары, 1965, 90 б.

атала торган татар авылы да бар. Исемнә караганда, ул да безнең республикадагы борынгы авылларның берсе булырга тиеш. Кышкар һәм Кышлау исемнәренең Урта Азиядә гомумән «авыл» төшенчәсен белдерә торган *кышлак* сүзенә семантик яктан якын торулары ачык сизелмәнә. Кышкар, Кышлау ойконимнарының безнең якларда яшәгән борынгы төрки кабиләләрнең күчмә тормыштан утрак тормышка күчү процессында барлыкка килгән дип уйларга урын бар. Шулай итеп, Кышкар ойконимы төрки *кыш* + борынгы иран *кар* «шәһәр, крепость, авыл» компонентларыннан гыйбарәт булган хәлдә, «кыш чыгу шәһәрчеге», саф төрки «Кышлау атамасы» «кыш кышлау авылы» мәгънәсенә ия булып чыга. Чаг.: *кышлау* — кышны үткәрә торган, кышын яши торган урын (ТТАС, 2 т., 243 б.), *җәйләү* — күчмә халыкларның җәй уздыру өчен төпләнгән урыны; җәйге тору урыны (ТТАС, 3 т., 806 б.); Аккыстау — Казахстанның Гурьев өлкәсе Новобогаткин районы үзәге булып санала торган шәһәрчек атамасы, Кыштау (русча Кыштовка) — Новосибирск өлкәсе Кыштау районы үзәге булып санала торган себер татарлары авылы атамасы, Кышту — Алтайдагы шәһәр һәм елга, Иске Кышлау — БАССРдагы авыл исемнәре һ. б.

Идел-Кама болгарлары телендә «шәһәр, крепость, кальга» төшенчәсен белдерү өчен *кирмән* ойконимик термины да кулланылган. Татар теленең урта диалектына карый торган, сөйләш булып формалашуында Рязань җирлегенә XV гасыр урталарында Казан арты авылларыннан күчеп килгән казан татарлары төп компонент ролен башкарган касыйм сөйләшендә (бу сөйләшне формалаштыруда казан татарларыннан тыш, әстерхан татарлары, нугайлар, мишәрләр дә катнашканнар) *кирмән* сүзе әле хәзер дә «шәһәр» мәгънәсендә йөри. Җирле татарлар Касыйм шәһәрен Кирмән дип атыйлар. Бу шәһәр башта (1152 елдан башлап) Мещерский городок яки Городец дип аталып йөргән. Аңа 1467 елда Казан ханнары нәселеннән булган Касыйм хуҗа булып ала һәм шул вакыттан башлап Касыйм кирмәне (русча Касимов город, хәзерге татар әдәби телендә Касыйм шәһәре) дип атала башлаган. Урта гасырларда төрки халыклар Киев шәһәрен Манкирмән (ягъни «Бөек шәһәр») дип атап йөрткәннәр.

*Кирмән* ойконимик атамасының килеп чыгышы, Н. И. Золотницкий карашынча, гарәп телендәге *эл-гарәм, хәрам* «кагылырга ярамый торган, әйләндереп алынган, ныгытылган» сүзенә кайтып кала[11]. Кыпчак телендә дә kärmän сүзе «крепость», «шәһәр» мәгънәсен белдерә.

Мари теленә *карман* «крепость» сүзе Идел-Кама болгарлары теленнән алынган[12]. Мари телендә болгарлардан кергән *ор* сүзе дә «крепость» мәгънәсендә кулланылган.

Болгар кабер ташы язмалары теле белән Татарстанның болгар катламына караган топонимик атамалары (бу очракта составларында *кирмән* ойконимик термин булган торак пункт атамалары) теленең уртаклыгы, ягъни шушы ике мөһим тарихи ядкарьләр (эпитафика һәм топонимика) теленең бер үк халык (болгар) теленә кайтып калуы борынгы безнең территориядә яшәгән болгарларның телен, килеп чыгышын һәм аларның казан татарларына нисбәтлелеген) ачыклауда зур әһәмияткә ия булып тора.

Казан арты җирлегендә хәзерге вакытта 13 торак пунктта XIII—XIV йөзләргә караган болгар кабер ташы язмалары табылган. Шунысы игътибарга лаеклы: Казан арты җирлегендәге болгар кабер ташы язмаларының күбесе II стильгә карый, ягъни аларның текстлары борынгы болгар телендә язылганнар. Һ. В. Юсупов, мәсәлән, Мамадыш районы Урта Кирмән авылы янындагы Кирмән шәһәрлегенең Ханнар зиратында үзе тикшергән 14 ташның борынгы болгар телендә язылуын хәбәр итә[13]. Мамадыш районының Түбән Яке һәм Питрәч районының Таутирмән авыллары зиратында табылган болгар кабер ташы язмаларының беренчесе шулай ук борынгы болгар телендә язылганнар.

Мамадыш районындагы Урта Кирмән авылы янындагы Ханнар зиратында 1336, 1337—1338, 1339—1340, 1351, 1352 елларга караган болгар кабер ташы язмаларының табылуы, беренчедән, бу торак пунктның нигезләнү вакытын якынча XIII йөзнең азагы, XIV йөз башы (шул заманнарда картаеп үлгән кешенең уртача яше 50 яшь дип санасак, 1340—50=1290 ел) дип билгеләргә мөмкинлек бирә. Икенчедән, әлеге кабер ташларының күбесенең борынгы болгар телендә язылуы бу авылларның болгарлар тарафыннан нигезләнүен, анда XIII йөз азагы — XIV йөздә болгарлар яшәвен раслый. Урта Кирмән авылы атамасы составында урын алган *кирмән* ойконимик терминының болгар теленә нисбәтле булуы да (бу атама болгар теленә гарәп теленнән кергән) югарыда әйтелгән фикерләрне куәтли. Икенче төрле әйткәндә, Урта Кирмән зиратындагы болгар кабер ташы язмаларында мәгълүматлар белән авыл атамасында сакланган тарихи-лингвистик информация *(кирмән)* бер-берсен үзара тулыландыра, фактик дәлилләү көчен арттыра.

[11] Золотницкий Н. И. Корневой чувашско-русский словарь. Казань, 1875, 261—262 бб.
[12] Марийско-русский словарь. М., 1956, 180 б.
[13] Юсупов Г. В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.—Л., 1960, 20—21 бб.

Идел-Кама Болгар илендә XIII гасырда барлыкка килгән шәһәрләр арасында Кирмән (Кирмәнчек) исемле шәһәрнең булуы болгар телендә «шәһәр, крепость, ныгытылган авыл» мәгънәсендә кулланылышта йөргән *кирмән* ойконимик терминына нигезләнеп әлеге шәһәр атамасы ясалуын раслый. Шунысы да игътибарга лаеклы: Идел-Кама Болгариясе белән территориаль-административ, экономика-хуҗалык, культура, тел һәм этник яктан тыгыз бәйләнештә булган хәзәр иленең Терек-Сулак елгалары арасындагы җирләрендә VII—XIII йөзләрдә үк Герменчик (~Кирмәнчек — Г. С.), Тенгкала, Бораул һ. б. кебек бик яхшы ныгытылган крепость-замоклары булган[14].

*Кирмән* ойконимик термины Казан арты җирлегендәге берничә авыл атамасы составында урын ала һәм бу торак пунктларның байтагы болгар бабаларыбыз тарафыннан нигезләнүе турында ерак гасырлар аша хәбәр китерә. Рус телендәге *кремль* сүзенең асылында да *кирмән* ойконимик термины ятса кирәк.

Кырымда Инкерман дигән мәгарә шәһәр, Украинда Кременчуг, Аккерман (хәзерге Белгород-Днестровский), Төньяк Кавказда Баксан тарлавыгында Керман, Болгариядә Кермен, Иранда Керман һәм Керманшах дип атала торган калалар бар.

Урта Идел-Урал регионында составларында *ката (кәтә), катау* (русча *катав*) ойконимик термины булган торак пункт атамалары да бар. *Ката (кәтә), катау* ойконимик термины да «торак, крепость»[15] мәгънәсенә ия. Ф. Е. Корш шактый күптән үк украин телендәге *хата* «йорт», остяк телендәге *хат* һәм борынгы һинд телендәге *кат, кот, «крепость»* сүзләре арасында уртаклык булуы турында язды[16]. В. И. Абаев *кат, ката* ойконимик терминнарының килеп чыгышын *кан*, «казу, (вал) өю» тамыры белән бәйли[17]. Шуннан *ката* «йорт», kanta «шәһәр», борынгы һинд телендә kantha «шәһәр стенасы» һ. б. фарсыча *кәнд* 1) шәһәр; 2) крепость, цитадель. Татарстанның Чирмешән районында Бәркәтә дигән зур гына татар авылы бар.

Үзбәкстанның Сәмәрканд өлкәсендәге бер шәһәр Каттакурган дип атала. Бу полисоним «шәһәр» + «шәһәр» төзелмәсеннән гыйбарәт: иран, һинд *катта* «шәһәр»+ +төрки *курган* «крепость, калкулык өстендәге корылма». Э. М. Мурзаев Урта Азия антик чорда *кат* термины «шәһәр, башкала» мәгънәсендә кулланылуын хәбәр итә[18].

Төрки халыклар яшәгән һәм яши торган территорияләрдә *курган* сүзе дә «ныгытма», «крепость», «шәһәр» мәгънәсендә СССРның төрки чыгышлы шәһәр атамалары составында сакланган. Л. Будагов иске татар телендә *курган* сүзенең «ныгытма, крепость, кальга» мәгънәсендә кулланылуын теркәгән[19]. Безнең карашыбызча, *курган* ойконимик терминының генезисы *корган* («төзегән, салган», соңрак «калку урындагы торак пункт, крепость, шәһәр») сүзенә кайтып кала. Идел буе регионында «авыл», «поселок» мәгънәсенә ия булган *курмыш, кормыш — кормаш* ойконимик термины да *кор «төзе, сал»* тамырыннан килә. Кормаш — Татарстанның Апас, Октябрь һәм Сарман районнарындагы татар авыллары. Курган — Уралдагы Курган өлкәсенең үзәк шәһәре.

Гарәп телендәге *кальга* «курган, крепость, ныгытма, замок» ойконимик термины болгар-татар теленә *кала* әйтелеше алып, «шәһәр» мәгънәсендә кабул ителгән. *Кала* ойконимик термины Калатау, Кызкала кебек борынгы болгар шәһәрләре атамалары составында урын алган булган.

Татарстанның хәзерге Яңа Чишмә районының үзәге Яңа Чишмә (русча Новошешминск) авылын элекtә татарлар Яңа кала дип атаганнар. Свияжск шәһәрен Зөя каласы дип атыйлар.

Татарстан топонимиясендә *кала* («шәһәр») ойконимик терминына нигезләнеп ясалган микротопонимнар да чагылыш тапкан: Кала сазы — саз исеме (Биектау районы Юртыш авылы), Кала тавы — тау исеме (Мөслим районы Яңа Сәет авылы), Калатау асты урманы — урман исеме (Зеленодольск районы Югары Шырдан авылы), Кала юлы — юл исеме (Лаеш районы Татар Сараланы авылы, Куйбышев районы Урта Йорткүл авылы), Калаяк басуы — басу исеме (Биектау районы Урта Алат авылы) һ. б. Составларында *кала* ойконимик термины булган географик атамалар Австралия белән Антарктидадан тыш, барлык материкларда да бар.

Татар теленә фарсы теленнән кергән *шәһәр* ойконимик термины, «шәһәр, кала» мәгънәсенә ия булган хәлдә, гарәпләрдән алынган *кала* («шәһәр») сүзенең абсолют синонимы булып кулланылышта йөри. *Кала* сүзе башлыча җанлы сөйләм телендә (Казан каласына барам, Зөя каласын күргәнем бар һ. б.), *шәһәр* термины исә фән һәм матбугат телендә кулланыла. *Кала* ойконимик терминыннан татар телендә башка-

---

[14] Магомедов М. Г. Образование Хазарского каганата. М., 1983, 191 б.
[15] Мурзаев Э. М. Словарь народных географических терминов. М., 1984, 263—264 бб.
[16] Корш Ф. Е. Несколько лингвистических данных для исторической этнографии Восточной Европы.— Сб. В честь 70-летия Д. Н. Анучина. М., 1913, 18 б.
[17] Абаев В. И. Этимологические заметки.— Труды Института языкознания АН СССР. М., 1956, 103 б.
[18] Мурзаев Э. М. Средняя Азия. М., 1957, 247 б.
[19] Будагов Л. Сравнительный словарь турецко-татарских наречий. т. II. СПб., 1871, 76 б.

*ла* кушма сүзеннән башка сүзләр ясалмаган (ТТАС, 2 т., 29 б.). *шәһәр* ойконимик терминыннан исә: *шәһәрара, шәһәрлек, шәһәрләшү, шәһәрчек, шәһәрчелек, шәһәрчә, шәһәрчәлек, шәһәрчәләнү* сүзләре барлыкка килгән (ТТАС, 3 т., 539 б.). Шушы юлларның авторы туплаган, 50 меңгә якын лексик берәмлекне үз эченә алган «Татарстан топонимнары һәм микротопонимнары картотекасы» материалларына таянып, составында *шәһәр* («кала») ойконимик термины булган бары тик бер генә микротопонимны мисал итеп китерә алабыз: *Ур шәһәре* — биеклек исеме (Кама Тамагы районы Олы Кариле авылы).

Фарсыларның «крепость, кальга» мәгънәсен белдерә торган *санҗар* ойконимик термины топонимиябездә чагылыш тапмаган, антропонимиябездә исә Санҗар исемендә татар-мишәрләрдә Санйаров, Санжаров фамилияләрендә сакланган. Гарәпләрнең «шәһәр» мәгънәсенә ия булган *мәдинә* сүзе дә топонимиябездә урын алмаган, антропонимиябездә хатын-кыз исеме булып еш кулланыла.

Көнбатыш диалектның чистай һәм хвалын сөйләшләрендә, урта диалектның мамадыш урынчылыгында «шәһәр» төшенчәсен белдерү өчен *гурт* (рус. город) сүзе кулланыла.

Татар теленең лексик хәзинәсендә «авыл» төшенчәсен белдерә торган сүзләр, архаиклашкан һәм диалекталь тәңгәлләрен дә исәпкә алганда, шактый зур гына синонимик оя тәшкил итәләр: *авыл, ил, кышлау, сала, йорт, юрта, кормыш, кырый, буләк, дирибнә, пүчинкә, хутыр, чат* (соңгысы Казан арты керәшеннәре телендә).

*Авыл* ойконимик термины — гомум татар телендә киң таралган, әдәби телебезгә дә, барлык татар сөйләшләренә дә хас булган һәм актив кулланыла торган лексик берәмлек. Борынгы төрки телдә *агыл* сүзе «загон для скота» мәгънәсен белдергән (ДТС, 18 б.). Гомум төрки *агыл; айыл, аул, авыл* «авыл» ойконимик терминының борынгы *агыл* «терлекләрне яисә аулап тотылган хайваннарны беркадәр вакыт ябып асрау өчен ясалган киртә, ихата, кура» сүзеннән ясалган булуы мәгълүм. *Агыл* сүзе үзе исә *аг ~ ан ~ ау* тамырына нигезләнеп барлыкка килгән дигән караш бар[20]. Чыннан да, борында кыргый яки ярымкыргый хайван көтүләрен берьюлы суеп, итен сакларга мөмкин булмаган (бигрәк тә эссе җәй көннәрендә), шуның өчен аларны киртәләп алынган бер урында туплап-җыеп тотканнар. Мондый зур хайван көтүе коллектив мал, байлык булганлыктан, әлеге киртә тирәсенә бөтен ыру торак корып утырган һәм *агыл* «авыл» барлыкка килгән.

Н. Б. Борһанова карашынча, татар халкы телендә *авыл* (awыл) сүзе чагыштырмача соңрак активлашкан булырга тиеш[21]. Казан ханлыгы чорындагы авыл атамалары составында бу ойконимик атама бөтенләй диярлек чагылмый.

Татарстан топонимиясендә *авыл* тополексемасы республикабызның өч зонасы (Казан арты, Тау ягы, һәм Кама аръягы) җирлегендә дә авыл атамалары составында артык еш булмаса да урын ала. Мәсәлән, Иске авыл — Октябрь районындагы татар, Яңа авыл, Әгерҗе районындагы Варкләд авыл — удмурт-татар авылы; Яңа авыл (Яңавыл) — Актаныш, Буа, Биектау районнарындагы татар авыллары атамасы. Зеленодольск районындагы Албаба дигән рус авылын җирле татарлар Яңавыл дип атыйлар. Шул ук районда Түбән Урысбага авылы халкы Югары Урысбага авылын Югары авыл, ә Югары Урысбага авылы халкы Түбән Урысбага авылын Түбән авыл дип, Олы Ачасыр авылы халкы Кече Ачасыр авылын Кече авыл, ә Кече Ачасыр авылы халкы Олы Ачасыр авылын Олы авыл дип атап йөри.

Республикабыз микротопонимиясендә *авыл* ойконимик термины катнашып, байтак кына микротопонимнар ясалганнар: Авыл асты — болын исеме (Биектау районы Чәмәк авылы), Авыл башы — авылга тоташкан кыр исеме (Зеленодольск районы Кече Шырдан авылы), Авыл елгасы — елга атамасы (Чирмешән районы Туймәк авылы, Биектау районы Айбаш авылы) h. б.

Борынгы төрки телдә *эл* сүзе: 1) кабиләләр союзы, 2) халык һәм 3) дәүләт мәгънәсендә кулланылган (ДТС, 168—169 бб.). Хәзерге төрки телләрнең күбесендә *ил ~ эл* шушы («кабилә», «халык», «дәүләт») мәгънәләрендә кулланыла. *Ил* сүзенең ойконимик термин буларак, «авыл» мәгънәсе татар (болгар теленнән үк килә), башкорт *ил*, комык, карачай-балкар *эл*, чуваш *ел* телләрендә билгеле. Мари теленә *эл* — «ил» «дәүләт» (шуннан *Марий эл* — «Марийская республика»), *илем* — яши торган *җир», «усадьба», илиш* — «тормыш»[22] сүзләре болгар-татар теленнән кергән.

Исемнәре составында *иле* («авыл») ойконимик термины кергән: Казиле, Кариле, Мулла иле, Дәрвиш иле, Кибәк иле, Тау иле, Улан иле, Чирмеш иле, Нократ иле, Кәче иле, Чүриле, Ялаг иле авыллары Казан ханлыгы чорында булулары мәгълүм

[20] Севортян Э. В. Этимологический словарь тюркских языков. М., 1974, 84 б.
[21] Борһанова Н. Б. Татар телендә авыл төзелешенә караган лексик-семантик төркемнәр.— Сб.: Исследования по диалектологии и истории татарского языка. Казань, 1982, 51 б.

булган борынгы авыллардан саналалар. Хәзерге Кукмара районында тагын Бүл иле, Йанил (Йаңа ил) дигән татар, Арча районында Иске Чүриле дигән рус, Яңа Чүриле исемен йөртүче рус-татар авыллары бар.

*Ил* ойконимик терминын «авыл» мәгънәсендә куллану татар теленең һәр ике төп диалектына (урта һәм көнбатыш) да хас. Аерым урынчылык һәм төбәкләрдә бу сүз әле хәзер дә шактый актив кулланыла (ТТАС, 144 б.).

*Кышлау* һәм *кышлак* ойконимик терминнарының төрки телдә XIV йөздә «кыш чыгу урыны», «авыл» мәгънәсендә кулланылуы документаль билгеле[23]. *Кышлау* ойконимик термины Татарстан җирлегендә Арча районындагы Кышлау дигән татар авылы атамасында гына сакланып калган. Шушы авыл исеменнән Кушловская (артистка) фамилиясе барлыкка килгән.

Казан артындагы Кышлау авылының Урта Идел буе җирлеге Хәзәр каганаты хакимлегендә булган заманнарда ук (VII—X гасырлар) барлыкка килгән булырга тиеш.

Татар теленә «авыл» мәгънәсенә ия булган *сала* ойконимик термины славян телләреннән кергән. Казан ханлыгы чоры язма истәлеге Сәхипгәрәй хан ярлыгында (1523 ел) бу сүз *сала харҗы* — «авыл салымы» рәвешле теркәлгән[24]. Касыйм сөйләшендә зур авылны *сала* (мәсәлән, Дүрт сала, Бием сала, һ. б.), кечкенә авылны *диривна* (рус. деревня) диләр.

Татарстан топонимиясендә, *сала* ойконимик термины катнашып, Арча, Биектау һәм Кама Тамагы районнарындагы Яңасала дигән татар авылларының исеме ясалган.

Казан татарларындагы *җорт*, әдәби телебездәге һәм мишәрләрдәге *йорт* ойконимик терминнары хәзер «авыл», «торак пункт» мәгънәсендә кулланылмый, бәлки «өй», «торак» төшенчәсен белдерү өчен генә хезмәт итә. Хәлбуки, иске татар телендә бу термин «өй», «торак» мәгънәсенә ия булу белән бергәттән, шушы мәгънәсенә нигезләнеп барлыкка килгән «авыл», «торак пункт» төшенчәсен белдерү вазифасын да башкарган. Себер татарлары «авыл»ны әле дә килеп чыгышы шушы *йорт* — *җорт* тамырына барып тоташа торган *юрта* сүзе белән дә (мәсәлән, Индрәюрта, Саускан юрта, Әримзән юрта) *ауыл* термины белән дә (Саускан ауыл, Әримзән һ. б.) атыйлар. Руслар себер татарлары авылын элек-электән *юрта* дип атап йөртәләр: Ембаев юрт, Епанчин (Япанчин юрт, Саусканские юрты, Сузгунские юрты, Шамшинские юрты һ. б. Төрки халыкларда *йорт (юрта)* сүзе борынгы заманнарда «күчеп йөри торган территория, тору урыны» төшенчәсен белдерү белән бергә, «ил, дәүләт» мәгънәсенә дә ия булган: Пулак йорты[25], Себер йорты, Болгар йорты, Казах йорты, Урыч йорты (Русское государство)[26] һ. б.

К. Насыйри язмаларында иске татар телендә *йорт* сүзенең «авыл», «торак пункт» мәгънәсендә кулланылуын сиземләп була: «Шырдан кыры элгәре Беловалга кырына тоташкан икән, дип сөйлиләр. Аннан соң, хәзер Иске йорт дип әйтәләр. Югары Шырдан кырында бер уйсу җир бар, шул җиргә ятып йоклап караганнар, аннан соң шул җиргә утырмакны мәслихәт күреп, шул алты кеше анда килеп утырганнар».

Кайбер татар авылларының басу-кырында яки башка җирендә кайчандыр авыл булган урыннарны *иске йорт*, *йорт өсте* яки *йортлар өсте* дип атап йөртү гадәте дә бар.

Татар телендә зур авылдан бүленеп чыккан «яңа авыл», зур (иске) авылның «бүлентеге, бүлеге» мәгънәсендә, чикләнгән рәвештә булса да, *бүләк* ойконимик термины да кулланыла.

Башта шуны әйтеп китәргә кирәк, *бүләк* сүзләре төрки халыклар ономастикасында омоним (бердә) яңгырашка һәм әйтелешкә ия булып, төрле мәгънә белдерә торган ономастик атамалар барлыкка китергәннәр.

*Бүләк* географик номенклатура терминының килеп чыгышы турында төрле фикерләр бар. Р. Х. Субаева *бүләк* термины *балак* → *булак* → *бүләк* эволюциясе нәтиҗәсендә барлыкка килгән дип саный. П. И. Кеппен «Хронологический указатель материалов для истории инородцев» (СПб., 1861) дигән китабында *беляк* дигән аерым халык булган дип карый. А. Артемьев «Казанская губерния. Список населенных мест по сведениям 1859 года» (СПб, 1866, 74 б.) дигән хезмәтендә П. И. Кеппенның бу карашын шик астына ала һәм ун мари авылы исемендә *беляк* сүзенең кабатланып килүе игътибарга лаеклы булуын әйтә. А. Артемьев: «Бу авыллар кайчандыр яшәгән казан татары Белякның — дәрәҗәле кешенең («именного человека») — күпләгән утарлары составына кергәндер»,— дигән нәтиҗә ясый һәм дөреслеккә шактый

---

[22] Марийско-русский словарь. М., 1956, 132, 722 бб.

[23] Изысканный дар тюркскому языку (Грамматический трактат XIV в. на арабском языке). Ташкент, 1978, 343 б.

[24] Вахидов С. Ярлык хана Сахиб-Гирея.— Вестник научного общества татароведения. № 1—2. 1925, 31—32 бб.

[25] Хисаметдин бине Шәрәфетдин. Тәварихы Болгария. Казан, 1879, 42 б.

[26] Радлов В. В. Опыт словаря тюркских наречий. Т.3, часть 1. СПб., 1905, 459 б.

якын килә. Тарихчы М. Г. Сәфәргалиев *бүләк* топонимик термины Алтын Урда чорында һәм аннан соңгы дәвердә дәрәҗәле кешеләргә, гаскәр башлыкларына, феодалларга кылган хезмәтләре өчен ханнар тарафыннан бирелгән, бүләк ителгән җир мәгънәсендә кулланылган *бүләк* сүзеннән ясалган һәм рус телендә аның *беляк* формасы барлыкка килгән дигән дөрес нәтиҗәгә килә. XVIII гасырда Мокша елгасы һәм аның кушылдыклары буенда 15 тән артык беляклар (бүләк җирләр) булуы, шунда татар бәгенә яки морзасына буйсынып татар-мишәрләр һәм мордвалар яшәве, белякларның (бүләкләрнең — Г. С.) элек татарлар кулында булган башка җирләрдә дә булуы турында яза[27].
Бу фикерне Татарстандагы Бай Бүләк (Сарман районы), Тигән Бүләк (Алексеевск районы) һ. б. кебек моннан дүрт-биш ел элек барлыкка килгән авылларның исемнәре раслый. Чаг.: Краснодар (1792 елда Екатерина II кушуы буенча Кубаньга күчерелгән запорожье казаклары тарафыннан нигезләнгән. Бу урынны килеп утыручылар «дар Екатерины» рәвешле кабул иткәннәр һәм шәһәр 1920 елга кадәр Екатеринодар дип аталган), Павлодар һ. б.

Татар теленең урта диалектына карый торган минзәлә һәм гәйнә сөйләшләрендә *бүләк* топонимик термины «вак урман, әрәмәлек» дигән мәгънәне дә белдерә. *Бүләк* терминының әлеге мәгънәсенә таянып Татарстанның Әлмәт районы Урсалыбаш авылы янындагы Озын бүләк, Чытырлы бүләк кебек урманнарның, Бүләк асты дигән басуның исемнәре барлыкка килгән. Балан Бүләк, ягъни «балан әрәмәлеге, урманлыгы» (Баулы районы), Таллы бүләк, ягъни «таллы әрәмәлек» (Азнакай һәм Бөгелмә районнары), Чикләвек Бүләк, ягъни «чикләвек әрәмәлеге, урманлыгы» (Азнакай районы) кебек татар авылларының исемнәре ясалган.

*Бүләк* термины зур авылдан бүленеп, күчеп утырган «яңа авыл» төшенчәсенә дә ия. Хәзер *бүлек, бүлекчә* дибез. *Бүләк* дигән авыллар заманында зуррак авыллардан күчеп, бүленеп чыккан бүлекләр («кисәкләр»), ягъни «яңа авыллар» алар. Татарстанның Актаныш һәм Мөслим районнарында Бүләк дигән татар авыллары бар. БАССРда мондый исем йөртүче авылларның саны дистәдән артык.

Татарстанның көнчыгыш районнарындагы Октябрь бүләге, Кызыл Бүләк, Яңа Бүләк, Керәш Бүләк, Көчле Бүләк, Ленин бүләге кебек авыл исемнәрендә *бүләк* терминының аергыч функциясендә килгән компонентлары аша, яңа төшенчә — социалистик революция, бөек юлбашчы, яңа җәмгыять, керәш бүләге дигән мәгънә белдерүе ачык сиземләнә. Бу авыллар — колхозлашу чорында зур авыллардан бүленеп чыккан бүләкләр, ягъни «яңа авыллар».

*Бүләк* топонимик терминнары һәм *бүләк* антрополексемасының асылында *бүләк* дигән кумәклек сүзе ята. Бу сүзнең этимологиясе исә *бүл* тамырына барып тоташа. *Бүл* («өлешкә, кисәккә бүл; өлеш, кисәк яса») тамырына — әк ясагыч кушымчасы ялганып *бүләк* сүзе барлыкка килгән.

Күреп үткәнебезчә, татар теле тарихында «шәһәр» һәм «авыл» төшенчәсен белдерүче ойконимик терминнар шактый күп була һәм алар, тарихның билгеле бер чорында кулланылышта йөреп, аерым тарихи-лингвистик сәбәпләр белән бәйләнешле рәвештә бер-берсен эзлекле алмаштырганнар һәм күбесе, безнең регионның топонимик берәмлекләре составында урын алып, бүгенге көнгәчә сакланып килеп җиткәннәр. Әлеге ойконимик терминнарны һәм алар катнашында ясалган җирле топонимнарны җентекләп тикшерү исә туган телнең тарихи лексикологик үзенчәлекләрен һәм үсешен, татар халкының тарихын өйрәнүдә үзеннән шактый зур фәнни өлеш кертә.

Географик атамаларда — чал тарих эзләре, исемнәрдә — ил хәтере, ил тарихы, аның тарихи үткәннәре, хәзергесе һәм киләчәге. Партиябез Үзәк Комитетының июнь (1987 ел) Пленумында сөйләгән докладында М. С. Горбачев әйткәнчә, кешеләр исә «илнең үткәне, хәзергесе һәм киләчәге турында күбрәк белергә телиләр».

---

[27] Сафаргалиев М. Г. К истории татарского населения Мордовской АССР (о мишарах). — Труды научно-исследовательского института языка, литературы, истории и экономики при Совмине Мордов. АССР. Вып. 24 Саранск, 1963, 70—72 бб.



# Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку-язу

## Беренче дәрес

*Мин «Казан утлары»н даими алдырам. Яратып укыганнарым роман һәм тарихыбызга багышланган мәкаләләр. Шул уңайдан миндә бер тәкъдим бар. Безнең гарәп хәрефләре белән басылган бик күп әдәби һәм тарихи әсәрләр әлегә кадәр хәзерге шрифтка күчерелмәгән. Ә анда күпме рухи байлык, күпме мәгълүмат тупланган. Әнә шул әдәби һәм тарихи ядкарьләр белән танышу өчен «Казан утлары» журналында гарәп алфавитын басып чыгарсагыз иде.*

*Илдар Идрисов*
*Уфа шәһәре*

Мәдәниятебезнең күп гасырлык тарихы белән азмы-күпме таныш булганнарга мәгълүм: болгар бабаларыбыз дәвереннән алып гасырыбызның егерменче еллар азагына кадәр татарларда гарәп хәрефләре кулланышта була. Әнә шул хәрефләр белән болгар заманнарында ук фәннең төрле тармакларына караган гыйльми трактатлар, әдәби әсәрләр, шул җөмләдән мәшһүр Кол Галинең сигез йөз елга якын халкыбызның рухи дөньясына даими тәэсир итеп килгән атаклы «Кыйссаи Йосыф» дастаны иҗат ителгән. Бөек гуманист Мөхәммәдьяр, атаклы галим Шиһабетдин Мәрҗани, сөекле шагыйребез Г. Тукай әсәрләре шул хәрефләр ярдәмендә безнең көннәргә килеп җиттеләр. Гарәп хәрефләре кабер ташларына да уелган, шәмаилләр булып йорт диварларына да эленгән. Язу булгач, аның осталары да булган. Гасырлар үтү белән язуны изге эшләрнең берсе дип санаган татар халкы арасыннан хаттатлар-каллиграфлар да үсеп чыккан. Алар арасыннан мәшһүр Гали Мәхмүдов яки Хөсәен Фәезханов кебекләр сәнгать дәрәҗәсенә ирешкән гарәп-төрки каллиграфиясеннән Казан һәм Петербург университетларында студентларга дәрес биргән. Татар хаттатларының каурый каләме белән күчерелгән меңнәрчә кулъязма китапларга халкыбызның күңел нуры, аһ-зарлары, өмет-хыяллары иңгән.

Мәгълүм ки, гарәп хәрефләренә нигезләнгән һәм хәзерге вакытта фәндә «иске татар язуы» дип йөртелә торган язу системасы Идел-Урал җирлегендә катлаулы һәм гыйбрәтле юл үтте. X гасыр башларында ул болгар бабаларыбызда кулланышта булган борынгы төрки руник язуны алыштыра. Идел буенда киң таралган гарәп язуы XIII гасырда монгол яулары белән килгән уйгур язуына да, Казан ханлыгы Рус дәүләтенә кушылгач, XVIII—XIX гасырларда көчләп тагылган рус алфавитына да бирешми. Тамырларын тагын да тирәнгәрәк җибәрә. Октябрь революциясенә кадәр Идел буе татарларында элементар грамоталылыкның киң таралган күренеш булуы әнә шул хакта сөйли.

Бишенче елгы революциянең шифалы йогынтысы нәтиҗәсендә мәйданга килгән татар вакытлы матбугаты да, Казан большевикларының ялкынлы прокламация һәм листовкалары, әче телле атеистик басмалар да, Совет властеның беренче декретлары, В. И. Ленин әсәрләренең татарчага беренче тәрҗемәләре дә әнә шул хәрефләр белән кәгазьгә беркетелеп халыкка таралганын онытмыйк.

Гарәп хәрефләре нигезендә татарча укырга-язарга өйрәтү дәресләре киң катлау укучыларга адреслана, ягъни гыйльми максатларны гына күздә тотмый. Классик гарәп әлифбасы 28 хәрефтән торган. Гасырлар үтү белән аңа фарсы-төрки телләр җирлегендә 8 яңа хәреф өстәлгән. Бу дәрестә журнал укучыларга әнә шул хәреф-билгеләрне берләштергән иске татар алфавиты тәкъдим ителә. Иске татар язуына өйрәтү дәресләре берничә еллар дәвамында Казан дәүләт университеты һәм Казан дәүләт педагогия институты студентларына укыту процессында кулланылып килә торган график-фонетик алымга нигезләнеп алып барылачак. Бу алымның нигезендә хәрефләрдәге формаль охшашлык һәм аермалылыкны ачыклау һәм шул нигездә язу билгеләрен махсус классификацияләп чыгу ята. Шулай ук үзләштергән белем берьяклы гына булып калмасын, нык булсын өчен, укырга күнектерү белән бергә дәрес язу күнекмәләре бирүгә дә игътибар ителәчәк. Гарәп хәрефләре нигезендә укуязуның тәртипләре, үзенчәлекләре турында да мәгълүматлар журналның киләсе саннарында биреләчәк.

*Дәресләрне Җәүдәт МИҢНУЛЛИН һәм Рәшит КАДЫЙРОВ алып бара.*

| ӘЛИФ(А) БЕЛӘН КУШЫЛЫП ЯЗЫЛГАНДА | УКЫЛЫШЫ | ЯЗЫЛЫШ РӘВЕШЛӘРЕ | | | | ХӘРЕФ ИСЕМ-НӘРЕ | ТӘРТИП САНЫ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | АЗАКТА | УРТАДА | БАШТА | АЕРЫМ ХӘЛДӘ | | |
| 8 | 7 | 6 | 5 | 4 | 3 | 2 | 1 |
| —— | А,Ә (И,Ы,О У,Ө,Ү) | ا ـا | ا ـا | ا | ا | ӘЛИФ | 1 |
| آب (АБ)، با (БА) | Б | ـب | ـبـ | بـ | ب | БИ | 2 |
| آت (АТ)، تا (ТА) | Т | ـت | ـتـ | تـ | ت | ТИ | 3 |
| آث (АҪ)، ثا (ҪА) | Ҫ (СЬ) | ـث | ـثـ | ثـ | ث | ҪИ(СЬИ) | 4 |
| آج (АЖ)، جا (ЖА) | Ж | ـج | ـجـ | جـ | ج | ЖИМ | 5 |
| آح (АХ)، حا (ХА) | Х(ХЬ) | ـح | ـحـ | حـ | ح | ХИ | 6 |
| آخ (АХ)، خا (ХА) | Х (ХЪ) | ـخ | ـخـ | خـ | خ | ХЫ | 7 |
| آد (Аð)، دا (ðА) | ð | ـد | ـد | د | د | ðАЛЬ | 8 |
| آذ (АЗЬ)، ذا (ЗЬА) | Ҙ(ЗЬ) | ـذ | ـذ | ذ | ذ | ЗӘЛ | 9 |
| آر (АР)، را (РА) | Р | ـر | ـر | ر | ر | РӨ | 10 |
| آز (АЗ)، زا (ЗА) | З | ـز | ـز | ز | ز | ЗИ | 11 |
| آس (АС)، سا (СА) | С | ـس | ـسـ | سـ | س | СЕН | 12 |
| آش (АШ)، شا (ША) | Ш | ـش | ـشـ | شـ | ش | ШЫН | 13 |
| آص (АСЪ)، صا (СЪА) | СЪ | ـص | ـصـ | صـ | ص | СЪАð | 14 |
| آض (АЗЪ)، ضا (ЗЪА) | ЗЪ(ð) | ـض | ـضـ | ضـ | ض | ЗЪАð | 15 |
| آط (АТЪ)، طا (ТА) | ТЪ | ـط | ـطـ | طـ | ط | ТЫЙ | 16 |
| آظ (АЗЪ)، ظا (ЗА) | ЗЪ | ـظ | ـظـ | ظـ | ظ | ЗЫЙ | 17 |

| 8 | 7 | 6 | 5 | 4 | 3 | 2 | 1 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| آع (АГЪ)، عا (ГА) | ГЪ (ӨРЕЛМӘ) | ـع | ـعـ | عـ | ع | ҒӘЙН | 18 |
| آغ (АГЪ)، غا (ГА) | ГЪ | ـغ | ـغـ | غـ | غ | ҒАЙН | 19 |
| آف (АФ)، فا (ФА) | Ф | ـف | ـفـ | فـ | ف | ФИ | 20 |
| آق (АК)، قا (КА) | КЪ | ـق | ـقـ | قـ | ق | ҠАФ | 21 |
| اک (ӘК)، کا (КЯ) | КЬ | ـک، ـك | ـکـ | کـ | ک، ك | КӘФ | 22 |
| آل (АЛ)، لا (ЛА) | Л | ـل | ـلـ | لـ | ل | ЛӘМ | 23 |
| آم (АМ)، ما (МА) | М | ـم | ـمـ | مـ | م | МИМ | 24 |
| آن (АН)، نا (НА) | Н | ـن | ـنـ | نـ | ن | НУН | 25 |
| آه (АҺ)، ها (ҺА) | Һ | ـه، ه | ـهـ، ـهـ | هـ | ه | ҺИ | 26 |
| آو (АУ)، وا (УА) | В(W) | ـو | ـو | و | و | УАУ | 27 |
| آی (АЙ)، یا (ЙА) | (И) Й | ـی | ـیـ | یـ | ی | ЙАЙ | 28 |
| آپ (АП)، پا (ПА) | П | ـپ | ـپـ | پـ | پ | ПИ | 29 (2А) |
| آچ (АЧ)، چا (ЧА) | Ч | ـچ | ـچـ | چـ | چ | ЧИ | 30 (5А) |
| آژ (АЖ)، ژا (ЖА) | Ж | ـژ | ـژ | ژ | ژ | ЖЭ | 31 (10А) |
| اگ (ӘГ)، گا (ГЯ) | ГЬ | ـگ | ـگـ | گـ | گ | ГӘФ | 32 (22А) |
| آنک (АҢ)، ڭا (ҢА) | Ң | ـنک، ـڭ | ـنکـ، ـڭـ | – | نک، ڭ | ҢЭ | 33 (22Б) |
| آڤ (АW)، ڤا (WA) | В(W) | ـڤ | ـڤـ | ڤـ | ڤ | УАУ | 34 (20А) |
| (ئا) ئه (ӘА)، ـئه (ӘӘ) | Ә | ـه، ه | ـه، ه | ئه | ئه، ه | Ә | 35 (24А) |
| آۆ (АӨ)، ۆا (ОА) | О,Ө | ـۆ | ـۆ | (ا)ۆ | ۆ | О, Ө | 36 (27А) |

# АШЛЫ

Монгол яулап алуларына кадәрге чорда бабаларыбыз төзегән тагын бер борынгы болгар шәһәре Ашлы исемен йөрткән. Рус елъязмаларында ул Ошель дип атала һәм 1184, 1220 елларда рус феодалларының Болгар дәүләтенә оештырылган яуларына мөнәсәбәтле рәвештә телгә керә.

Ашлы — тарихта бер болгар князлегенең башкаласы буларак мәгълүм. Бу шәһәр атамасы халык күңеленә, авыз иҗатына тамырларын нык җибәргән, ләкин шуңа да карамастан, аның төгәл генә урыны хәзергә кадәр тәгаенләп кенә ачыкланмаган. Бу хәл халкыбыз тарихының катлаулы, авыр еллар аша үтүен, шау-гөр килеп торган шәһәрләрнең көлгә әйләнүен, хәтта кайберләренең урыннары да билгеле булмавын, үсеш чорларының авыр булуын ачык чагылдыра.

Бер төркем галимнәр, мәсәлән, И. Г. Георги, В. Н. Татищев, С. М. Шпилевский, П. А. Пономарев һәм А. П. Смирновлар Ашлының урынын Татарстанның хәзерге Кама Тамагы районында Кирельский дип йөртелә торган авыл янындагы, Иделгә кушыла торган Кирель суының сулъяк ярына урнашкан Янтиковский шәһәрлеге дип уйлыйлар һәм шул урында табылган археологик истәлекләрне өйрәнәләр.

Г. Әхмәров, Н. Ф. Калинин, А. Х. Халиков һәм Р. Г. Фәхретдинов кебек археолог-галимнәр Ашлының Тәтеш районы Кильнә суы бассейнындагы Богдашкино авылыннан 900 метр төньяктарак, Идел ярыннан тугыз чакрым көнбатышта калкурак тигез урында урнашкан дип, шәһәрнең бу урында булуын дәлилли торган мәгълүматлар туплаганнар һәм шуннан җыелган археологик табылдыкларны тикшергәннәр. Алар фикеренә караганда, Богдашкин шәһәрлеге үзенең мәйданы, ныгытылган үзәк һәм бистәгә бүленүе белән 1220 елда Ашлы шәһәрен рус елъязмасы тасвирлаган билгеләмә белән туры килә.

Ашлы — Болгар дәүләтенең көнбатыш өлешендә, бер төбәк үзәге вазифасын үтәгән. Шәһәрнең бөтен ягыннан әйләндереп алган чокыр һәм валлар аның оборона линиясен хасил иткәннәр. Г. Әхмәров шәһәр урынын тикшергән вакытта валларның өч рәттән торуын ачыклаган. 1220 елда рус феодаллары гаскәрләренең Ашлыны алулары турындагы хәбәрдә дә шәһәрнең ныгытмалары чокырлар һәм имән стеналардан торганлыгы әйтелә.

Шәһәрнең көньяк-көнбатыш ягындагы үзәк өлеше махсус ныгытмалар, аерым алганда, ике тирән чокыр һәм ике биек вал белән әйләндереп алынган булган. Көньяк-көнбатыш ягында алар өлешчә җимерелгән. Үзәкнең формасы дүрткырлы, ә төньяк ягы түгәрәк итеп эшләнгән. Аңа көньяк һәм төньяктан ике капка илткән. Тышкы оборона линиясенең төньягында керер-чыгып йөрер өчен өч капка калдырылган булган. Шәһәрлекнең культура катламы 80 сантимер чамасы исәпләнгән.

Ашлының төзелеше дә нәкъ башка болгар шәһәрләренеке кебек. Ул ныгытылган үзәк өлеш һәм бистәдән торган.

Ашлының ашлыклы шәһәр булуы халык авыз иҗатында искә алына.

*Кала белән тулган йорт.*
*Ашлы белән Ибраһим*
*Ашлык белән тулган йорт.*
*Чулмандагы Җүкәтау.*
*Урмандагы Сабаны.*
*Ашлыгы иксемәс Ашлыны...*

Ашлы халкы Кирель һәм Идел елгаларыннан да хуҗалык алып бару өчен оста файдаланган. Суларыннан балык тотканнар. Болгарларның чит илләргә балык, кырпы җилеме һәм башка әйберләр чыгаруларын урта гасыр галимнәре дә билгеләп үтәләр.

Шәһәр һәм Идел арасындагы урманда халыкның бер өлеше чолыкчылык белән шөгыльләнгән. Урта гасыр галимнәре Әл-Бәлхи, Мөкатдисә, Ибне-Хәүкәл һәм башкалар болгарларның чит җирләргә кыйммәтле мехлар белән беррәттән, бал, балавыз чыгаруларын да язып калдыралар. Ибне-Фазлан исә үзенең язмаларында аларның балдан ясалган эчемлекләре булу турында ассызыклап әйтеп китә.

Археологлар язуына караганда, болгар керамикасы монда, нигездә, коңгырт сары төстәге савыт-саба ватыклары белән күз алдына килә. Шәһәр үзәгендә савыт-саба ватыкларының әйбәт сыйфатлысы 47 процент, ә бистәдә бары 12 процент кына. Бу күренеш шәһәрнең үзәк өлешендә югары катлау вәкилләре, ягъни феодаллар һәм сәүдәгәрләр яшәгән дигән фикерне дәлилли. Шәһәр урынында болгар чорына мөнәсәбәтле акчалар да табылган.

Болгар дәүләте иминлеге өчен Ашлы керткән өлеш аз булмаган. Ләкин, кызганычка каршы, кайчандыр күкрәп яшәгән Ашлы шәһәре дә җимерелгән. Тарихчылар язуына караганда, 1220 елда Болгар дәүләтенә рус феодаллары оештырган һөҗүм вакытында ул яндырыла һәм шуннан соң торгызылмый. Шәһәрне бөек князь Юрий Всеволодовичның туганы князь Святослав җитәкчелегендәге гаскәр яндыра. Русларның Воскресенский дип аталган елъязмаларында Ашлының алынуы һәм яндырылуы турында мәгълүмат бар. Рус елъязмаларында Исады дип аталган утрау каршындагы ярга төшкән гаскәрләрен Святослав түбәндәгечә урнаштыра: Ростов полкын уң кул якка, Переяславныкын сул якка куя, үзе Муром князьләре белән уртага урнаша, гаскәрнең бер өлешен көймәләр янында да калдыра. Шулай итеп, алар елга ярыннан кузгалып урманны чыгалар һәм кырлар буйлап Ашлы шәһәре янына кадәр килеп җитәләр. Аларны күзәтеп торып каршы алган болгар дружиналары шәһәргә кереп бикләнә. Ашлы янына ук килеп җиткән яулап алучылар шәһәр стеналарыннан болгарлар аткан бик күп санлы укларга чыдый алмый кире борылып китәргә җыенганда, Ермила Охотин дигән бер сугышчы үзенең туганы Вавило белән имән стена аркылы сикереп төшәләр һәм аңа ут төртәләр. Тирә-юньгә төтен тарала. Святослав һәм аның гаскәрләре төтенгә каршы, ягъни җилгә каршы яктан килеп, Ашлыны тар-мар итүләрен тәгәллиләр. Болгар князе үзенең кече дружинасы белән шәһәр капкаларыннан чыгып кача. Калган халыкның — хатын-кыз һәм бала-чаганың күбесе кырып бетерелә, ә бер өлеше әсир алына. Шулай итеп, Ашлы яшәүдән туктый, яңадан торгызылмый.

Ашлы атамасының аш өлеше зур игътибарга лаек. Лы — сүз ясагыч кушымча. Димәк, бу атаманы аш исемен йөрткән төрки кабиләләр куйган, шәһәрне алар төзегән һәм яшәгән дип әйтергә мөмкин.

М. З. Зәкиевнең соңгы елларда тикшеренүләренә караганда, ас һәм аның вариантлары дип исәпләнелгән аз, яз, яс, ус, уз, ош, аш, иш, уш сүзләре ар (эр, ир) белән бергә параллель рәвештә төрки телләрдә сөйләшә торган кабиләләрне атау өчен күптәннән кулланылып килгән. Атамаларына ас, аш, ош... сүзе кергән топонимнар шушы борынгы төрки кабиләләргә мөнәсәбәтле һәм аларның таралыш даирәсе бик киң. Ашлыдан ерак түгел урнашкан элекке болгар шәһәре, хәзер хәрабәсе булган Хулаш (хула «кала» — аш, ягъни аш каласы, аш кабиләләре шәһәре), Казан суының сул кушылдыгы Аша елгасы ярына урнашкан Ашабаш авылы атамасы. Моннан тыш, республикабызның Биектау районында Йуас (халык әйтүе буенча Җуас) һәм Чуваш иле (Һ. В. Йосыпов бу авыл зиратында XVI йөзгә караган кабер ташы язмалары таба) авыллары да бар. Чуваш иле авылы (хәзерге чувашларга түгел, бәлки суасларга, ягъни республикабыз җирлегендә әле болгарларга кадәр күп элек яшәгән җирле төрки суас кабиләләренә мөнәсәбәтле) Чуваш Караул исеме белән Казан ханлыгы чорында булган. Татарстанның Кама аръягы төбәгендә ага торган Шушма суының уң кушылдыгы Оша (татарча Аша) елгасы ярында Оша (Ашы) исемле рус авылы һәм Ошинский (Ашинский) дип аталган ике поселок бар. С. М. Шпилевский, Стрельбицкий картасында (XVIII йөз) югарыда сүз алып барылган Оша елгасы атамасының русча бирелешен дә Аша формасында булганлыгын яза. Оша дип аны руслар соңгы чорларда гына үзгәрткәннәр.

Составына ас-аш тамыры кергән атамалар хәзерге вакытта төркиләр яши торган һәм кайчандыр яшәгән урыннарда очрыйлар. Идел елгасының югары агымы кушылдыгы Кече Кокшага суына коя торган Ошлы исемле гидроним бар. Татарча Ашлы, рус чыганакларында татарның иренләшкән а авазы яңгырашы буенча аңа якын торган рус «о» сы белән алмаштырыла, мәсәлән, татарча татар, русча тотар, татарча алпут, русча олпут һ. б. Пермь татарлары яши торган борынгы үзәкләрдә,— дип яза М. З. Зәкиев,— соңыннан өяз шәһәренә әверелгән Оса һәм Көнгер атамалары этник ос (ас, эс, яс) һәм бәҗәнәкләрнең үзатамалары конгор — конгыр белән тап килаләр. Ас, аш һәм аның вариантларына беткән атамалар хәзерге Пенза өлкәләрендә, Урал Оренбург тирәләрендә дә очрыйлар. Шушы ук исәпкә карачай-балкар топонимнары Ас кала (крепость), Аш-Тотур (табигый урын исеме) топонимнары да керә.

Шулай итеп, Борынгы Болгар шәһәре Ашлы атамасының тамырлары чал тарихка барып тоташа.

Фирдәүс ГАРИПОВА,
филология фәннәре кандидаты.

**Ренат Гаффар**

# ТОТКА

**хикәя**

Мөштифәнең бүген кәефе юк. Бәйләнер кеше тапмагач, эштән кайтып кергән ире Гыйздигә тиктомалданябышты:

— Үбешкәй чакта бер күзең йомылып бетми! Утыз ике ел буе оялып йөрим шул күзеңнән. Әнә бит, кеше ирләре бер дә алай түгел!

Малай чагында ат көткәндә маңгаена тай типкән иде. И гарьләнде, и рәнжеде Гыйзди хатынының шул рәвешле мыскыллавына. Сыердан яманрак дулады Гыйзди.

— Каян беләсең әле син кеше ирләренең ничегрәк үбешкәнен, ә?

— Каян дип инде... Ни бит, сөйләшә ич хатыннар...

— Яле миңа бер пар оекбаш, запас күлмәк-ыштан! Әйе! Синең бер янасыны күптән көткән идем мин, күптән. Китәм бүген үк! Йорт тоткасына көн беткән икән монда!..

Шулай итеп, Мөштифә утыз ике елга бер ялгышты. Әмма нык ялгышты. Гыйздине бу йортта моннан соң аркан белән дә бәйләп калдырырлык түгел иде инде. Соңгы автобуска утырды да калага китеп барды.

Иң әүвәл, сәгатьче булып эшләүче авылдашы Һарун Һарунычка кереп чыгасы итте. Аңа юл таныш. Кочаклашып күрештеләр. Аннары «Дөнья җәннәте» ресторанына китеп бардылар. Утырдылар. Гыйздигә, көтмәгәндә генә, үтә җитди төс керде. Елап ук җибәрде.

— Ни булды!— дип кызыксынды Һарун Һарунычч.

— Булды инде, яшьти, булды! Көймә комга терәлде. Бәхетемне урладылар. Йорт тоткасы дип тормадылар.

— Кем? Ничек итеп?

— Мөштифә, кем булсын! Эт урынына өемнән куып чыгарды. Йөргән нәстәсе булганга охшый.

— Син инде, парин, бигрәк тагын. Йә, кемдә юк инде ул җөргән нәстә? Сөен син, Мөштифәнең карар төше бар икән әле, диген. Алай да ниең ярамады соң?

— Ни дип, физик кимчелегемне тапкан.

— Ну, парин, илле бишкә җит тә, физик кимчелегең булмасын ди. Унсигездә түгел ич. Мал-мөлкәтеңне бүлеп алдыңмы соң?

— Юграгые шул. Бар малым, әнә, кибеткә йөри торган букчада.

Һарун Һаруныч бичара дустының өстәл астындагы сумкасын ачып карады. Гыйздинең үтүкләнмәгән күлмәк-ыштанына ияреп, паркет идәнгә саллы гына бер тимер дыңгырдап төште. Ишек тоткасы. Әллә нинди рәвешләргә кертеп эшләнгән бик борынгы күренә, авыр, ике килолап булыр, шаять.

— Син бөтенләй үк шыр тиле, ахры, Гыйзди, име? Йорт-җиреңнән бабаң мирасы — шушы ишек тоткасыннан гайре әйбер тәтемәдемени, пешмәгән? Жебегән нәстә! Мөштифәң урынында булсам, мондый ир белән мин дә тормас идем. Мин булсаммы?! Йә, ярар инде. Бу тотканы бер дуска бүләк итәрбез. Теге әртис Гарәфигә. Ишек тоткалары җыя ул, җүләр.

— Чыгып киткәндә өй ишеген дыңгырдатып япсам, бу нәрсә шөребе-ние белән суырылды да чыкты. Туктале, мәйтәм, интексен Мөштифә ишекне ачып-япканда. Тыктым киттем тотканы букчага.

— Монысын яхшы иткәнсең. Миннән бу хәтле булмасые, парин.

Кофе китергән кызыл иренле официант кыз да, идәндәге ишек тоткасын күреп, хәрәкәтсез калды. Бер мәл агарып-күгәреп үк килде.

— Кайдан алдың моны, абыйсы?

— Синең ни эшең бар? Урладым!

— Кайдан? Мин дә урлаттырыр идем.

— Япуннан, моннан сиксән еллар элек.

— У, күптән икән. Минем Хәмферием анда хәтле үк барып житә алмас шул.

— Нигә ул хәтле күгәреп, тынсыз калдың соң әле син, кызыл авызкай! Синекен урламаганмындыр ич?

— Бигрәк затлы нәмәкәй бит. Мин Хәмферием белән ишек тоткасы жыям. Житмеш жиде булды инде.

— Мин әртис Гарәфи генә жыямы әллә, дип тора идем әле. Шулай ишлемени сез? Ул жыюның бер-бер хикмәте-фәләне юктыр ич?

— Мә, кофе эч, абыйсы!— диде кызыл иренле, ишек тоткасыннан колак какканына тәмам ибанып, боргалана-сыргалана атлап китеп барды.

— Их, моның кулларыннан гына бер тотып утырсаң икән!— дип хыялланды Гыйзди.— Сүрән генә ут яктысында. Бер айлык эш хакы да жәл түгел...

— Йә, ташла әле — панимаешь,— диде Һарун Һаруныч. Ул кара уйга баткан иде: «Монда нидер бар. Бу халык ишек тоткасын белми жыймыйдыр. Тәгаен бер-бер хикмәте бар! Теге әртисне алдап-йолдап серен алмый булмас, пыжалый».

Йа, ходаның рәхмәте! Өеннән эт урынына куып чыгарылган мәлдә Гыйздидән дә бәхетле зат булмаган икән, валлаһи! Авызына әтәч кабып, йөзенә хәйләкәр елмаю чыгарган төлке рәвешендә ясалган шушы ишек тоткасы белән Гыйзди үз язмышының авыр ишеген ачып жибәрмәсенме?!

«Дөнья жәннәте» рестораныннан чыкканда аларның кәефе көр иде. Авызлары колакта, жырлыйсылары килә. Гыйздинең кайгы-хәсрәт жилгә очты.

Ресторан ишеген дөпелдәтеп япкан чакта тоткасы суырылып чыкмасынмы? Үзе авыр, үзе зиннәтле итеп ясалган.

— Эчне төртеп тишмәс әле,— диде Һарун Һаруныч.— Без нәрсә, теге кызыл иренледән, аның Хәмфериеннән, я булмаса, әртис Гарәфидән кимме әллә? Тотка жыю модасы чыккан, күрәсең.

Яннарында эт тә юк иде. Ә менә әллә каян гына зәңгәр билле бер машина килеп туктады.

— Кая юл тоттыгыз болай, егетләр?— дип сорадылар.

— Кая булсын — өйгә!

— Әйдә, үзебез генә озатып куйыйк.

— Мәшәкатьләнмәгезче. Аяк бар бездә.

— Бәлки, алай да, бездә генә кунып китәрсез? Әнә, кулыгыздагы тотка да шактый саллы күренә. Өшәнерсез, өзлегеп-нитеп китмәгәегез...

Күп сөйләшеп тормадылар, икесен дә утыртып алып киттеләр.

— Тагын «тоткачылар»мы?— дип каршы алды аларны дежур.

— Әйе лә, жиде төн уртасында кем йөрсен инде?

«Тоткачылар» исемлегендә Гыйзди белән Һарун Һарунычның исеме юк иде.

— Яңалар,— диде дежур ниндидер канәгатьлек белән.— Соңрак керешкәннәр. Картаеп беткәч.— Аннан соң Гыйздигә төбәлде.— Кем син?

— Ат караучы.

— Кликуханмы бу?

— Нинди кәлле уха? Ат караучы, дим ич. Алдынгы! Ышанмасаң, авылыма шалтырат. Шоферлык та кулдан килә. Машинага правам бар. Машинасы гына юк.

Инде аңлашып беттек дигәндә генә, дежурның колагына берәү пышылдап өлгерде.

— Кит аннан, булмас!— дип шәрран ярды дежур.— Алай икә-ә-ән... Кара әле,— диде ул аннары Гыйздигә,— бу тотканы каян алдың?

Дуслар шүрли калды.

— Авылдан алып килдем. Теге әртис Гарәфигә дип. Ул ишек тоткасы жыя икән.

— Ә, беләбез аны, беләбез. Хәзер инде бер Гарәфи генә жыймый тотканы. Болай итик. Сүзеңнең хакмы-түгелме икәнен иртәгә ачыкларбыз. Сезне бүген шушында кундырып чыгармый булмый. Ятагы бераз катырак инде катысын. Нишлисең? Фирма башка.

Иртәгәсен монда болар белән бүтәнчәрәк сөйләшәләр иде инде. Үзгәрген-

нәр. Тавышлары йомшак, ягымлы, йокыны китерә торган.

— Кара әле, Гыйзди туган, синең бер гаеп юк икән бит. Менә теге «Дөнья җәннәте» ресторанының тоткасын илтеп кадакларсыз анысы. Ә авылыңнан алып килгән тоткадагы җиде кат буяу үз ишегегездәге буяуга тәңгәл булып чыкты. Минем бер хезмәткәр авылыгызга барып кайтты. Рәнҗемә инде, шулай кирәк иде. Алай да, кемнән калды соң ул сиңа? Элек кемнеке булган? Кем мирасы?

— Бабайныкы! Каян алганын аннан сора.

— Бабаңның адресы?

— Мәрхүмнең адресы бер генә инде анын, агайне. Сорап торган буласың тагын.

— Ә шулайрак бит әле, әйе. Кара әле, Гыйзди туган, бу тотканың чиреге синеке бит.

— Чиреге түгел, бөтенесе үзеңә булсын! Син мине авылга кайтарып кына җибәр. Атлар көтә.

— Юк, алай ярамый. Хуҗасы — син. Чиреге — синеке. Закон шулай куша. Кыскасы, алтын бу тотка.

Кәгазь китерделәр. Укып күрсәттеләр. Һарун Һаруныч бөтенләй катып калды. Аннары су уртлап куйды.

— Хәллә-ә-әр, парин!— диде ул Гыйздигә.— Череп баедың син болай булгач. Әйтәм бит, ул кызыл авызлар, Хәмфериләр, Гарәфиләр ишек тоткасын белми жыймый, дип. Мин аны шундук сизендем. Монда бер-бер хикмәт бар, ахры, дидемме? Болай булгач, сиңа машина алабыз. Күршедә генә берәү өр-яңа «Жигули»ен сата.

Гыйзди Мөштифәсе янына «Жигули»енә утырып кайтты. Кара күзлек алып киеп, яңача киенеп алган, үтүкләнмәгән күлмәк-ыштанын юл читенә атып калдырган иде. Менә сөенер дә соң хатыны! Машина күптәнге хыяллары иде. Күктән төшкән бәхет. Болай булгач, рәнҗүе дә таралыр. Машинада җилдерү тирәякта даны таралган ат караучыга язык булырмы әллә?

Гыйзди машинада җилфердәп кайтып кергәндә Мөштифәсе кадак-чүкеч күтәреп йөри иде. Ишекнең эчке ягындагы тотканы кубарып алган, тышкы ягына, Гыйзди кубарып киткән тотка урынына кадаклап маташа. Гыйздине күргәч, әллә ни исе китмәде.

— Ә, кайттыңмы? Мә, үзең кубардың — үзең кадаклап бетер, ишекне ачып керер хәл юк синең аркада,— дип, чүкечен-кадагын ире каршысына ыргытты. Гыйздинең дә бу хәлгә әлләни исе китмәде:

— Мин машинада кайттым!— дип авызын ерды.

— Йөрисең акча туздырып!— Мөштифәсе Гыйздинең өс-башына шикле караш ташлады.— Автобуста йөрсәң дә бик таман булыр иде!

Әмма эшнең нәрсәдә икәнен бер-ике сүз белән аңлаткан Гыйзди шул арада хатынының кочагында калды.

— Җаным! Хакмы бу?! Машинада гына җилдерәбез бит болай булса, әнекәччәем!— Мөштифә иренең битеннән чупылдатып-чупылдатып үбә башлады. Гыйзди, онытылып, китеп, күзләрен йомды. Әмма әлеге дә баягы бер күзе тәки йомылып бетми калды. Моны Мөштифәсе дә күрде:

— Теге ни... Күзеңнең йомылып бетмәве дә әйбәт бит әле, картым. Машинада барганда үбешә-нитә калсак, юлны рәхәтләнеп карап бара аласың, иеме?!— диде. Шул сүзне ишетүгә, Гыйздинең баш миенә кан саугандай булды.

— Ах, әле син тагын шул күзгә бәйләнәсеңме?!— дип ыңгырашып, хатыны кочагыннан атылып чыкты. Аннан соң, хатыны ишеккә кадаклый башлаган сары тотканы каерып алды.— Машина үзеңә булсын! Китәм! Миңа менә шушы тотка да бик җиткән!.. Йорт тоткасына тәмам көн беткән икән бу нигездә!

«Әртис Гарәфигә булыр», дип, бер уңайдан капка тоткасын да суырып алып китте Гыйзди.

— Нишлисең? Кая барасың? Тоткасыз нишлим мин?!— дип үрсәләнгән Мөштифәсенә бармак янады:

— Матри! Бүтән көтмә мине! Кайтып күренәсем юк!..

Шәһәргә килгәч, Һарун Һаруныч янына ашыкты. Икәүләп барып, тиешле урында тотканы чыгарып салдылар:

— Әйдә, агай-эне, безгә тотканың чиреген бүлеп бир дә, бигайбә!

Тиешле урында эшләүче белгеч ишек тоткасына бер генә күз салды:

— Моны кем әртис Гарәфигә илтегез. Бакыр тоткаларны ул җыя...— диде.

Өенә Гыйзди автобуста кайтты. Ә аныңчы, хуҗалык товарлары кибетенә кереп, йөз иллеле кадак сатып алды. Кубарылган тотканы бүтән купмаслык итеп кадаклыйсы бар иде...

# *Культура тормышы көндәлеге*

## ТӘРҖЕМӘЧЕЛӘР УТЫРЫШЫ

27—29 июньдә Казанда РСФСР Язучылар союзы идарәсенең әдәби тәрҗемә буенча советының күчмә утырышы булды. Анда катнашучылар татар әдәбиятының классик мирасын өйрәнү һәм русчага тәрҗемә итү мәсьәләсен карадылар. Пленар утырышларда «Татар халык эпосы» (Ф. Әхмәтова), «Борынгы татар поэзиясе» (Н. Хисамов), «XIX гасыр поэтик мирасы» (Р. Әхмәтов), «Революциягә кадәр татар драматургиясе» (Н. Ханзафаров), «Татар халкының рухи мирасын өйрәнү комиссиясенең эшчәнлеге» (Ф. Мусин) дигән темаларга докладлар, фикер алышулар булды.

## ТАТАР ГАЛИМНӘРЕ АМЕРИКАДА

Америка Кушма Штатларының Висконсин-Медисон университеты каршындагы Үзәк Азияне өйрәнү җәмгыяте 27-30 апрельдә «Үзәк Азиядә һәм аңа күрше регионнарда тел, әдәбият, тарих һәм иҗтимагый хәрәкәтләр» дигән темага халыкара фәнни конференция уздырды. Аның эшендә АКШ, СССР, Англия, Франция, Төркия, Бельгия, Швеция, ГФР, Кытай, Әфганстан, Пакистан һәм башка илләрдән күп кенә күренекле галимнәр катнашты. Алар арасында РСФСР һәм ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, философия фәннәре докторы, профессор Я. Г. Абдуллин һәм ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, филология фәннәре докторы Ә. Г. Кәримуллин да бар иде.

Конференциядә Я. Г. Абдуллин «Идел һәм Урал буе татарлары арасында мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм аның Урта Азия халыкларының иҗтимагый фикеренә тәэсире», Ә. Г. Кәримуллин «Америкадагы кайбер индеец кабиләләре телләренең Алтай телләренә охшашлыгы» дигән темаларга докладлар белән чыктылар, шулай ук татар халкының этник чыгышы, саны, таралышы, әдәбияты, культурасы турында сөйләделәр.

3-4 майда Ә. Г. Кәримуллин Бостон шәһәренең Гарвард университетында «Америкадагы кайбер индеец кабиләләре телләренең Алтай телләренә охшашлыгы» дигән темага лекция укыды, шулай ук татар халкының этник чыгышы һәм Казан университетының шәрыкне өйрәнүдә тоткан урыны турында сөйләде.

## ВЬЕТНАМ ЯЗУЧЫЛАРЫ КИЛДЕ

18-20 июльдә Казанда Вьетнам Демократик Республикасының бер төркем язучылары булып китте. «Ван Нге» («Әдәбият һәм сәнгать») көндәлек газетасының баш редакторы урынбасары Во Ван Чык, поэзия бүлеге мөдире Во Тхань Ан, «Ван-Хаук» («Әдәбият») журналы редколлегиясе члены һәм «Так фам мой» («Яңа әсәрләр») китап нәшриятының баш редактор урынбасары Там Чунг һәм башка иптәшләр әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә халыкара элемтәләрне тагын да ныгыту турындагы әңгәмәләрдә катнаштылар.

Вьетнам язучылары Казанның тарихи урыннары белән таныштылар, герой-шагыйрь М. Җәлил һәйкәленә чәчәк бәйләмнәре салдылар, В. И. Ленин белән бәйле урыннарда булдылар, Тукай-Кырлай мемориаль комплексын карадылар.

## Ш. МӘРҖАНИ ИСТӘЛЕГЕНӘ

5 июньдә Мәскәүнең Зуев исемендәге культура йортында күренекле татар мәгърифәтче галиме Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 170 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды.

Казан галимнәре М. Госманов, Я. Абдуллин, С. Алишев, М. Юсупов, Ә. Хәйруллин, язучы Ә. Еникинең, Сүрия галиме, философия фәннәре докторы И. Тәуфикъның, Мәскәү һәм Казан җәмәгатьчелеге вәкилләренең Шиһабетдин Мәрҗанинең күпкырлы фәнни иҗади эшчәнлегенә багышланган чыгышлары зур игътибар белән тыңланды. Кичәдән соң зур концерт булды. Анда Татарстанның халык артисткасы З. Сәхәбиева, Татарстанның атказанган артисты Р. Курамшин, Казан дәүләт университетының «Каз канаты» фольклор ансамбле, Мәскәү өлкә филармониясенең «Бәйрәм» ансамбле, шул филармониянең солистлары М. Сәнгатуллин һәм Татарстанның атказанган артисты Р. Харисов, РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе А. Монасыйпов иптәшләр катнашты.

## К. ТИНЧУРИН ИСЕМЕ БИРЕЛДЕ

РСФСР Министрлар Советы карары белән Татар дәүләт драма һәм комедия театрына татар әдәбияты классигы, драматург К. Тинчурин исеме бирелде.

## ӘДИП ЮБИЛЕЕ

12 майда Татарстанның Апас районы Чүти авылында Зариф Бәширигә 100 яшь тулу уңаеннан әдәби кичә үткәрелде. Партиянең Апас райкомы секретаре Р. Салахов, әдипнең якташлары З. Бәширинең киң кырлы эшчәнлеге хакында сөйләделәр. Язучының йөз еллыгын уздыруда күрше Чувашия республикасы вәкилләре, язучылар Т. Әйди һәм Җ. Дәрзаман катнашты.

# ЧӘМЧӘЛЕ ЧИТЕКЛӘР

Халкыбызның матурлыкка, нәфислеккә, төс-бизәкләргә аерата сизгерлеге һәм камиллеккә омтылуы аның кул эшләрендә бигрәк тә ачык чагыла. Борын-борыннан дан казанган чәмчәле читекләр — шуның яхшы мисалы булып тора.

Читекләрне читек тегүче яки чигүче дип кенә атау һич тә дөрес булмас иде. Һөнәрләрен иң югары камиллеккә җиткергән бу осталар — тегү, чигү, каю ысулларын берьюлы кулланганнар. Шушы өч ысулның берьюлы башкарылуы чәмчәләү дип атала да инде. Аны әле хәзергә кадәр «татар җөенең сере» дип атыйлар. Күннең аерым өлгеләрен чәмчәләп тоташтыру читекләрне «җөйсез» итә дә инде. Кәҗә күненнән тегелгән бу аяк киемнәренең гаҗәеп дәрәҗәдә йомшаклыгы һәм җиңеллеге, алардагы бизәкләрнең кабатланмас үзенчәлеге татар һөнәрчеләренең данын ерак-еракларга тараткан. XVIII-XIX гасырларда чәмчәле читекләр татар халкының милли товары булырак тарала, аларга Рәсәйнең эчке базарларында гына түгел, чит илләрдә дә ихтыяҗ зур була. Парижда, мәсәлән, татар читекләрен сатучы кибетләр эшләве мәгълүм.

Элегрәк читек җитештерү белән күбрәк хатын-кызлар шөгыльләнгән. Бу аңлашыла да: татар халкында кәләшнең үз туена бизәкле читек әзерләве элек-электән килгән күркәм гадәт булган. Бары тик XIX гасыр урталарында, мануфактура барлыкка килгәч, читек тегүдә ирләр дә күпләп катнаша башлый.

Читекләрне чәмчәләп әзерләү ысулының кайчан һәм ничек барлыкка килүе турында шактый бәхәсләр бара. Һәрхәлдә, аның тамыры хәзерге төрки халыкларның борынгы бабалары дип исәпләнүче Алтай төркиләренең көнкүрешенә барып тоташа дип уйлау дөрес булыр. Татар читекләренең эшләнеше, бизәк төсмерләре Алтайда табылган борынгы читекләрнекенә охшаш. Әлеге борынгы читекләр безнең эраның 5-6 гасырларында яшәгән скиф патшаларының туң бозга әверелгән каберләреннән табылган.

Кыйммәтле ташлар, алтын, энҗе һәм башка затлы әйберләр белән бизәкләнгән читекләр төрки халыкларның борынгы цивилизациясеннән юл алган. Һәм татар халкы үзенең әнә шул чорлардан башланган тарихын — 2,5 мең еллык тарих юлын — бизәкле читекләрен җуймыйча атлап узган дип әйтсәк кирә.

Әлбәттә, читекләрне чәмчәләп тегү борынгы бабаларыбыз тарафыннан кулланылган күпсанлы ысулларның бары тик бер төре генә. Быел, мәсәлән, Казанда яшәүче бер апа Татарстанның Сынлы сәнгать музеена шушы гасыр башында тегелгән гаҗәеп читекләр бүләк итте. Аларны эшләүдә моңа кадәр бөтенләй күренмәгән алым — укалап чигү файдаланылган. Әлеге ысул хәзер Арча читекләре тарафыннан кызыксынып өйрәнелә.

Арча читекчеләре — бүгенге көндә бизәкле милли аяк киемнәребезнең бай традициясен уяу саклаучылар алар. Мондагы осталар гасырлар буена килгән төсмерләрне, бизәкләрне саклап калырга, дәвам итәргә тырышалар. Нәкъ менә шундый оста куллы кешеләрнең күңел җылысы аша бизәкле читекләр бүгенге көннең өс-баш кием белән дә таңгал яраклашалар, үткәннәрдән бер истәлек булып, киләчәк буыннар өчен гаҗәеп бер табышмак һәм сер булып, заман белән бергә баралар.

Р. ШАҺИЕВА,
Татарстан сынлы сәнгать музееның
фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Казанның архитектура истәлекләре. Әҗем мәчете (XIX гасыр). Хәзер биредә культура хезмәткәрләренең белемен күтәрү курслары урнашкан.

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотолары.

# «КАЗАН УТЛАРЫ» 1989 ЕЛДА

Мәгълүм булганча, «Казан утлары» журналы киң катлау укучыларның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә зур игътибар бирә. Шуңа күрә аның сәхифәләрендә роман-повестьлар, шигырь һәм поэмалар, әдәби очерклар белән беррәттән халкыбызның катлаулы тарихын, күпгасырлы культурасын чагылдырган фәнни-популяр мәкаләләр дөнья күрә, әдәби мирасыбызның кыйммәтле ядкарьләре хәзерге заман укучысына җиткерелә. Җәмгыятебездә тамыр җәя барган хәбәрдарлык, демократияләшү шартларында тарихи характердагы мәкалә-язмаларга игътибар нык артты.

Мәшһүр Кол Галинең атаклы «Кыйссаи Иосыф» дастаны, күренекле язучыбыз Әмирхан ага Еникинең «Касыймга сәяхәт», шәхес культы шаукымы нәтиҗәсендә озак еллар буе читкә тибәрелгән тарихчы Һади Атласи, күренекле тарихчы һәм философ Ш. Мәрҗани юбилеена багышланган материаллар журнал укучыларда зур кызыксыну уяттылар. Редакциягә алынган күпсанлы хатлар шул хакта сөйли.

Укучыларыбыз киләсе елда да рухи хәзинәбезне тәшкил итүче әсәрләр белән танышачак. Шуларның берсе — «Идегәй» дастаны — татар халык иҗатының йөзек кашларыннан булган бер әсәр. Тарихи-легендар мажаралары, үткен фикер фәлсәфәсе, гүзәл шигърияте белән таң калдырып, гасырлар буе халкыбызның күңелен баеткан, иҗат чишмәләренә көч өстәгән бу дастан.

Дәверләр кичеп тә исән калган «Идегәй» кыйссасы бүген, бигрәк тә яшьрәк буыннар өчен яңа исем, яңа әсәр булып тоела. Моның сәбәбе — халык иҗаты җәүһәрләренә дә шәхес культы һәм торгынлык елларының шаукымы бәрелүдә. Халыкны үз иҗатыннан аеру, рухи яктан ярлыландыру өчен, хаксызга кара мөһер сугылып, катлы-катлы тыюлар астына бикләнгән иде «Идегәй».

Менә, ниһаять, ул халкыбызга яңадан әйләнеп кайта. Киләсе елда «Казан утлары» журналында «Идегәй» дастаны тулысынча басылып чыгачак.

Катлаулы тарихыбыз белән ихластан кызыксынган укучыларыбызны журнал битләрендә киләсе елда да кызыклы очрашулар көтә. Тарихчы галимнәр С. Алишев һәм М. Мулюков хәзергә кадәр матбугатта бик аз яктыртылган һәм шул ук вакытта халкыбыз тарихының гаять үзенчәлекле һәм гыйбрәтле бер сәхифәсе булган вәисевчеләр хәрәкәтенә багышланган язма алып килделәр.

Күренекле галим Ә. Кәримуллинның төрки телләр белән Төньяк Америка индеецлары телләренең охшашлыгына, ул халыкларның килеп чыгышына караган хезмәте укучыны ерак гасырларга алып китсә, язучы Җәмит Рәхимовның мәкаләсе XVIII гасырда Россиядә нефть ятмаларын беренче булып эшкәртә башлаган татар старшинасы Нәдер Үрәзмәтов белән таныштырыр.

Узган елларда укучылар журнал битләрендә Уральск, Оренбург һәм Уфада татар культурасына бәйле урыннар белән таныштылар һәм бу рубрика аларда зур кызыксыну уятты. Шуңа күрә алдагы елларда Ленинградта, Мәскәүдә, Әстерханда һәм башка шәһәрләрдә татар культурасына мөнәсәбәтле булган истәлекле урыннар һәм шулай ук халкыбызның төрле төбәкләрдә яшәүче төркемнәре тарихы белән укучыларны таныштырып бару күздә тотыла.

Инде хәбәр ителгәнчә, гарәп әлифбасы нигезендә татарча укырга-язарга өйрәтү дәресләре дә дәвам иттереләчәк.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)